ӘДӘБИЯТ

9

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ

Әдәбият 9

Сүзләмәкдә сән йөземни ак кыйл, –
Сүзләреми ил күңлигә йомшак кыйл.

Мөхәммәдьяр

Х. Й. Миңнегулов, Ш. Ә. Садретдинов

ӘДӘБИЯТ

(БОРЫНГЫ ҺӘМ УРТА ГАСЫР, XIX ЙӨЗ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ)

Татар телендә төп гомуми белем бирү мәктәбе
һәм гимназияләрнең **9** нчы сыйныфы,
урта махсус уку йортлары, педагогия училищелары,
колледж һәм лицей укучылары өчен дәреслек

Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгы
тарафыннан тәкъдим ителгән

Төзәтелгән дүртенче басма

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2011

УДК 373.167.1:821.512.145*09
ББК 83.3(2Рос=Тат) я721
М57

Дәреслекнең «Борынгы һәм Урта гасыр әдәбияты», «XIX йөзнең икенче яртысында татар поэзиясе», «Мифтахеддин Акмулла» бүлекләрен, кереш һәм йомгагын профессор **Хатыйп Миңнегулов**; XIX йөз татар әдәбиятының башка өлешләрен доцент **Шәйхелислам Садретдинов** язды.

Фәнни мөхәррире —
Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы,
профессор *А. Г. Әхмәдуллин*

Охраняется действующим законодательством об авторских и смежных правах (Гражданский кодекс РФ, ч. 4, гл. 70). Воспроизведение всей книги или её части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.

Миңнегулов, Х. Й.

М57 Әдәбият (Борынгы һәм Урта гасыр, XIX йөз татар әдәбияты) : татар телендә төп гомуми белем бирү мәкт. һәм гимназияләрнең 9 нчы с-фы, урта махсус уку йортлары, педагогия училищелары, колледж һәм лицей укучылары өчен д-лек / Х. Й. Миңнегулов, Ш. Ә. Садретдинов.— Төзәтелгән 4 нче басма.— Казан : Татар. кит. нәшр., 2011. — 407 б. : рәс. б-н.
ISBN 978-5-298-02069-5

УДК 373.167.1:821.512.145*09
ББК 83.3(2Рос=Тат) я721

ISBN 978-5-298-02069-5
© Татарстан китап нәшрияты, 2011, үзгәрешләр белән
© Миңнегулов Х. Й., Садретдинов Ш.Ә., 2011

Сәфәрегез уң булсын, дуслар!

Хөрмәтле укучылар! Сез инде халкыбызның шактый гына әдипләрен, фольклорны һәм язма истәлекләрне өйрәндегез. Әмма әдәби мирасыбызда әле сез белмәгән җәүһәрләр дә бик күп. Аларны белмәү, өйрәнмәү сезне рухи яктан нык ярлыландырыр иде. Акыл ияләре дә бит: «Һәрнәрсәнең чиге бар, тик белем алуның гына чиге юк»,— дип, кат-кат искәртеп килгәннәр. Шуңа күрә, яшь дуслар, гыйлем эстәү юлында сез дә туктап калмагыз.

Моңа кадәр сез өйрәнеп килгән әсәрләрнең барысы да диярлек соңгы дәвергә карый. Ә бит газиз халкыбыз узган юл озын, катлаулы, данлы, фаҗигале. Үзенең тарихи яшәешендә, гаять бай рухи хәзинә тудырып, гомумкешелек мирасына үзеннән зур өлеш керткән ул. Шунысын да белеп торыгыз: меңъярым еллык язма әдәбияты булган халыклар дөньяда бик сирәк! Ә төрки бабаларыбыз исә яңа эрага кадәр үк, үз алфавитларын булдырып, мөһим язма истәлекләр калдырганнар. Кызганыч, тарихның афәтле җил-давыллары элеккеге рухи ядкярләрнең күбесен юкка чыгарган, аларның кайберләре исә хәзергәчә табылмаган. Әмма сакланып калган, булган кадәресе дә халкыбызның бай әдәби мираска ия икәнлеген раслап тора.

Әдәбият халык тарихы, иҗтимагый тормыш белән тыгыз бәйләнештә яши. Шуңа күрә аны аерым әсәрләрне өйрәнү рәвешендә генә түгел, ә үзенә хас үзенчәлекләре булган процесс буларак та өйрәнү шарт. Сез хәзер әдәби мирасны хронологик эзлеклелектә, тарихи яссылыкта, ягъни әдәбият тарихы курсы рәвешендә үзләштерә башлыйсыз. Сез биредә бик күп яңа исемнәр, әдәби, тарихи күренешләр, гадәти булмаган сүзләр һәм төшенчәләр белән очрашасыз. Әдәбият теориясе буенча да сезне күп кенә яңа мәгълүматлар көтә.

Без җиңел юл вәгъдә итмибез: әдәби хәзинәләр иленә сәфәр вакытында кыенлыклар белән дә очрашырсыз, сикәлтәле урыннарга да тап булырсыз. Әмма сәфәрегезне дәвам итәрсез. (Моңа безнең иманыбыз камил.) Укытучыларыгыз сезгә бу изге сәяхәттә ышанычлы юл күрсәтүчеләр, остазлар булырлар.

Инде искәртеп куелырга тиешле тагын бер нәрсә бар: татар әдәбияты тарихы, гомуми белем бирү мәктәпләреннән тыш, гимназияләрдә, колледжларда, урта махсус уку йортларында да өйрәнелә. Аларның һәрберсендә әдәбият укыту буенча үзенчәлекләр бар. Әмма бу төр уку йортлары өчен аерым-аерым программалар, дәреслекләр язу, аларны тиз арада бастыру хәзерге вакытта бик үк мөмкин түгел. Шуңа күрә бу китап Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан татар телендә төп гомуми белем бирү мәктәпләре, гимназияләр өчен дәреслек итеп кенә түгел, ә колледжлар, урта махсус уку йортлары өчен ярдәмлек, әсбап рәвешендә дә тәкъдим ителә.

Хәер-фатиха сүзләребезнең тагын берсе шул: әдәби текстларның үзләрен мөмкин кадәр күбрәк укырга, алардагы тел байлыгын ныграк үзләштерергә тырышыгыз. Ул сезнең сәфәрегезне тагын да кызыграк һәм мавыктыргычрак итәчәк.

Сезне гаҗәеп күптөрле яңалыкларга бай булган озын-озак сәфәр көтә. Ул — гадәти генә сәяхәт түгел, ә сезнең өчен үз һәм якын булган дөньяга — газиз халкыңның күңел тарихына сәяхәт. Сәфәрегез уң һәм нәтиҗәле булсын. Зиһенегез, күңелегез баесын. Хәерле юл сезгә, яшь дуслар!

Авторлар

КЕРЕШ

Сүз сәнгатенең кайбер үзенчәлекләре.

Дастан һәм әкиятләрдән, Фирдәүси һәм Низамидан, Шекспир һәм Гётедан, Пушкин һәм Толстойдан, Исхакый һәм Тукайдан башка без бүгенге тормышыбызны да, үткән юлыбызны да күз алдына китерә алмыйбыз. Чөнки фольклор һәм әдәбият — кешелекнең аерылгысыз юлдашы, рухи елъязмасы, җәмгыять тарихының зарури өлеше.

Сүз сәнгатенең, ягъни фольклор һәм язма әдәбиятның үзәгендә — кеше, аның рухи дөньясы, эш-гамәле, табигать һәм җәмгыять белән үзара мөнәсәбәтләре. Әдәби әсәрдә теләсә нинди факт, күренеш, хәл, вакыйга чагылырга мөмкин. Әмма алар кеше аркылы, аның мәнфәгатьләрен, зәвыкларын, теләк-ихтыяҗларын күздә тотып гәүдәләндерелә.

Әдипне юкка гына иҗат иясе дип йөртмиләр. Чөнки ул тормышны гадәти рәвештә генә чагылдырмый, ә күргән, ишеткән, кичергән нәрсәләрен үз зиһенендә эшкәртеп, хис-кичереш, төрле сурәтләр, сәнгати кануннар ярдәмендә яңа чынбарлык — әдәби әсәр тудыра. Бу процесс вакытында адәм баласы өчен, гомумән, хас булган эзләнү, фикер йөртү, уйлап чыгару, фараз кылу, хыяллану, фантазия кебек сыйфатлар гаять зур роль уйный. Еш кына әдәби әсәрләрдә чынбарлыкта булырга гына мөмкин яисә бөтенләй булмастай күренешләр дә очрый. Мәсәлән, «Идегәй» дастанындагы Субра-җырчы «җитмеш җиде ил гизгән, йөз туксан биш яшәгән». Тукайның «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасындагы төп каһарман — гәүдәсез баш. Әмма ул гадәти кешеләр кебек сөйләшә, хәрәкәт итә. Ф. Әмирханның Фәтхулла хәзрәте, бер үлгәч, кабат терелә, бик сәер нәрсәләр белән очраша. Бу төр гайре табигый күренешләрнең тууы, әлбәттә, авторларның иҗат максатлары һәм сәнгати фикерләүнең үзенчәлеге белән аңлатыла.

Гомумән, кеше, ул кайсы җирнеке, кайсы чорныкы гына булмасын, күп кенә уртак сыйфатларга, эш-гамәлләргә ия. Ул туа, үсә, эшли, картая, үлә, сөя, сөелә, бала тәрбияли, сөенә, көенә һ. б. Кешегә хас бу төр гомуми уртаклыклар әсәрнең иҗат

ителешендә, эчтәлегендә дә охшашлыклар китереп чыгара, бер халык әдәбиятының башка халыклар арасында да аңлашылу, кабул ителү мөмкинчелеген тудыра, дөнья әдәбиятларының бердәмлеген барлыкка китерүдә нигез булып тора.

Сүз сәнгатенең төп асылы кешегә, тормышка хас гомуми сыйфатларны, хәл-вакыйгаларны мөмкин кадәр конкретрак, җанлырак, үзенчәлеклерәк эчтәлектә һәм формада бирүдән гыйбарәт. Бу процесс вакытында да иҗат ияләре кешенең, чынбарлыкның үзенчәлекләренә таянып эш итәләр.

Дөньяга ничәмә-ничә миллиард кеше килеп киткән, хәзер күпме яши! Әмма аларның берсе дә бер-берсе белән үзара тәңгәл килми. Һәрберсенең үз төс-кыяфәте, холык-фигыле, үз язмышы бар. Димәк, гомумән, кеше юк, ә конкрет адәм баласы, конкрет шәхес бар.

Әдипләр кешегә, тормышка хас булган әнә шул гомумилекнең һәм индивидуальлекнең гармоник берлеген, төрле сурәтләр һәм алымнар кулланып, конкрет һәм кабатланмас эчтәлектә, үзенчәлекле формада бирергә омтылалар. Шушы хосусият нәтиҗәсендә сүз сәнгатенең күп кенә ядкярләре, нинди чорда һәм җирлектә тууына да карамастан, дөнья укучылары өчен үз һәм якын. Мәсәлән, Хафиз да (XIV йөз), Байрон да, Дәрдемәнд тә мәхәббәт турында язалар, аның бөеклеген күрсәтәләр. Әмма аларның һәрберсе үзенчә, иҗади эш итә; шуңа күрә дә бу шагыйрьләрнең сөю-мәхәббәт турындагы шигырьләре кызыклы һәм мавыктыргыч.

Бер үк яисә үзара якын табигый, иҗтимагый шартларда озак дәверләр буе оешып, аралашып яшәү кешеләрдә билгеле бер охшашлыклар, уртаклыклар тудыра. Шуның нигезендә халык, милләт барлыкка килә. Этник берлекнең асылын тел берлеге, гореф-гадәтләр, инану-ышанулар уртаклыгы, тарихи вакыйга-хәлләрне бергәләп кичерү тәшкил итә. Кеше үзенең матди һәм рухи ихтыяҗларын иң беренче чиратта үзенең милли дөньясында канәгатьләндерү мөмкинчелеге ала, шулай итеп, шәхси һәм милли мәнфәгатьләр арасында билгеле бер ярашу, гармония барлыкка килә.

Сүз сәнгате кеше тормышын, чынбарлыкны билгеле бер дәрәҗәдә милли традицияләр аша тасвирлый, халыкның уйкичерешләрен, теләк-омтылышларын, мәнфәгатьләрен, гомумән, милләтнең тарихи язмышын үзәккә куя. Аның төп материалы, әсәрне төзү коралы — сүз, нинди дә булса конкрет бер халыкның теле. Ә инде тел, К. Ушинский сүзләре белән

әйткәндә, милләтнең нигезен тәшкил итә, «халыкның бөтен тарихын һәм рухи тормышын чагылдыра». Тел бетә икән, милләт тә башка халыклар тарафыннан йотыла, бетә.

Әдәби ядкярләрдә миллилек тел белән бәйләнешле башка нәрсәләрдә дә үзен нык сиздерә. Мәсәлән, Һиндстанда сыер изге хайван дип санала. Һәм шуңа мөнәсәбәттә бу илнең шагыйрьләре, хатын-кызларны мактаганда, аларны еш кына сыер белән чагыштыралар. Татарларда сылулыкны сөлек белән тиңләү бар. Рус фольклорында һәм язма поэзиясендә табигатьне руслаштыру көчле («русское поле», «русская берёза», «русская зима» һ. б.). Казахларда матур күзне дөя баласының (ботаның) күзе белән чагыштыру еш очрый. Татарның Алып батыры, Идегәе, Сөембикәсе, Шүрәлесе, Тукае кебек, башка халыкларның да үзләренең фольклор образлары, әкияти һәм тарихи каһарманнары бар. Шунысын да истә тотарга кирәк: милли җирлек, милли психология белән бәйләнешле аерым сурәтләр башка халыкларда кайвакыт капма-каршы тәэсир дә тудырырга мөмкин. Мәсәлән, татар телендәге «сөлек кебек» (как пиявка) чагыштыруы руста бөтенләй икенче төрле мәгънә тудыра. Шуңа күрә текстны бер телдән икенчесенә күчерүчеләр тәрҗемә процессында мондый үзенчәлекләрне истә тотарга бурычлылар.

Иҗтимагый-социаль күренеш буларак, кеше, халык һәм җәмгыять тормышы — тарихи үзгәрүчән төшенчәләр. Үз чорының, җирлегенең, халкының бер вәкиле булган әдип һәм аның иҗаты да,— объектив чынбарлыкка нисбәтән, тарихи күренеш. Авторны һәм ул чор укучыларын борчыган, дулкынландырган аерым мәсьәләләрнең, кайбер төшенчәләрнең вакытлар узу белән искерүе табигый. Әмма сүз сәнгатенең бер үзенчәлеге шунда: чын әдәби әсәр эчтәлек һәм форманың гармоник берлеге буларак картаймый, яңа буыннарга да эстетик яктан тәэсир итү көчен саклап кала.

Матур әдәбиятның кеше тормышындагы роле.

Алда әйтелгәнчә, сүз сәнгатенең чын ядкярләре вакытлар узу белән искерми, укучыларны һәм тыңлаучыларны һаман да дулкынландыра, күңел дөньяларын, хис-кичерешләрен кузгата, зиһеннәрен баета, эстетик тәрбия бирә.

Һәр әсәрдә билгеле бер мәсьәләләр гәүдәләндерелә, нәрсә дә булса раслана, кире кагыла. Әмма әдәби ядкярләрдән автор күздә тотмаган фикерләр дә саркып чыгарга мөмкин. Гомумән, әдәби әсәр эчке байлыгын, потенциаль мөмкинлекләрен бары тик укучы белән очрашканда гына ача ала. Укучы — әсәр

диалогының асылы исә бик күп факторларга бәйле. Шулардан иң мөһимнәре — укучының уй-фикерләү, кабул итү, кичерү (кичереш) һәм, гомумән, әзерлек дәрәҗәсе, психологик үзенчәлекләре. Ә инде кешенең ниндилеге, мәгълүм булганча, шактый дәрәҗәдә чор, җирлек, иҗтимагый һәм этник факторлар белән билгеләнә. Кыскасы, сүз сәнгате бер генә төрле кабул ителми, укучы — әсәр диалогы да — тарихи, үзгәрүчән күренеш.

Кешене әхлакый яктан тәрбияләүдә әдәбият һәм фольклор — чын мәгънәсендә остаз. Әдәби әсәрләр кешелек туплаган рухи байлыкны, әдәп-әхлак кагыйдәләрен, «нәрсә ул яхшы», «нәрсә ул яман» төшенчәләрен укучыга үтемле итеп җиткерә.

Сүз сәнгате кешегә мөнәсәбәттә чынбарлыкның күптөрле якларын бөтен катлаулылыгында, каршылыклары белән гәүдәләндерергә омтыла, тәрбияви һәм танып белү максатларын бергә куша. Әдәбиятны юкка гына «кешелек хәтере», «тормыш дәреслеге» дип йөртмиләр. Укучы әдәбият аша дөньяны, кешене танып белә, тормыш тәҗрибәсен үзләштерә, яшәешкә, тереклеккә дәрт ала.

Сүз сәнгате — элеккеге, хәзерге һәм киләчәк буыннарны ялгаучы мөһим чара да. «Китап,— ди А. Герцен,— бер буынның икенче буынга рухи васыяте, гомеренең соңгы чигенә җиткән аксакалның яңа гына яши башлаган кешегә киңәше, ялга китүче сакчының (часовойның) үз урынында калучыга биргән әмере ул».

Әдәби ядкярләр кешеләрне фикер йөртергә, хыялланырга, иҗатка өйрәтәләр, башкаларның кайгы-шатлыкларын, рухи халәтләрен аңларга ярдәм итәләр. Кешенең сөйләм һәм язма телен, гомуми культурасын үстерүдә дә сүз сәнгатенең роле зур. Шулай ук әдәбият һәм фольклор сәнгатьнең башка төрләрен аңлауда һәм үзләштерүдә дә нигез, төп фактор булып тора.

«Әдәбият тарихы» төшенчәсе.

Түбәнге сыйныфлардан үзгә буларак, хәзер әдәбият тарихи планда, процесс рәвешендә өйрәнелә башлый.

Әдәбият тарихы — әдәбиятны өйрәнү гыйлеменең мөһим тармакларыннан берсе. Ул әдәбият теориясе, әдәби тәнкыйть белән тыгыз багланышта тора. Әдәбият фәненең бу төп өч өлкәсе еш кына үзара керешеп тә китә.

Әдәбият тарихы ике өлештән: әдәбиятның үзеннән, ягъни хронологик эзлеклелектәге әсәрләр тупламыннан һәм әдәбият турындагы карашлар системасыннан тора.

Әдәбият тарихы әдәбиятның туыннан алып хәзергәчә булган хәрәкәт-үзгәрешен, нинди баскычлар үтүен үсеш процес-

сында карый, андагы үзенчәлекләрне, төп тенденцияләрне, закончалыкларны ачыклый, әдипләрнең тормыш юлын һәм иҗат мирасын тикшерә, әдәбиятның чынбарлык һәм иҗтимагый-мәдәни күренешләр, фольклор белән мөнәсәбәтен өйрәнә. Бер генә халыкның да сүз сәнгате үз кабыгында гына бикләнеп яшәми һәм яши дә алмый. Үз үсешендә ул башка илләрнең һәм халыкларның мәдәниятләре белән дә теге яки бу дәрәҗәдә бәйләнешкә керә. Шуңа күрә әдәбият тарихы әдәби бәйләнешләрне дә күз алдында тота. Әдәбият тарихының төп предметы — рухи эшчәнлекнең, иҗтимагый аңның бер формасы булган әдәбият. Ул үзенең тикшеренүләрен җәмгыять, халык тарихы белән тыгыз бәйләнештә алып бара.

Әдәбиятны өйрәнү әдәбият туган вакыттан ук башлана. Әмма, фән буларак, әдәбият тарихы чагыштырмача соңрак — XVIII—XIX йөзләрдә генә формалаша. Соңгы дәвердә дөнья, милли, аерым төбәк, ил әдәбиятларын өйрәнү юнәлешендә зур эшләр башкарылды.

Татар әдәбияты тарихы, фән буларак, XX йөзнең беренче чирегендә формалашып җитә (Г. Ибраһимов, Җ. Вәлиди, Г. Исхакый, Г. Сәгъди, Г. Рәхим, Г. Газиз һ. б. хезмәтләре). Соңгы берничә дистә елда шактый гына хезмәтләр, шул исәптән алты томлык «Татар әдәбияты тарихы» дөнья күрде.

Татар халкының килеп чыгышына (этногенезына) карата.

Әдәбият тарихы аны тудырган халык тарихы белән тыгыз бәйләнешле. Татар халкы төрле кабиләләрнең, этник төркемнәрнең катнашуыннан барлыкка килгән. Алар арасында угро-финнар да (ягъни хәзерге удмурт, мари, мордваларның бабалары да), монголлар, славяннар, греклар, гарәпләр, иранлылар һәм башкалар да бар. Әмма татар халкын барлыкка китерүдә төп һәм хәлиткеч урынны төркиләр алып тора.

Тарихтан төркиләрнең бик борынгы заманнардан ук Ерак Көнчыгыштан алып Дунай тамакларына, Карпаткача, аерым чорларда Үзәк Европагача җирләрдә яшәүләре мәгълүм. Дөрес, алар V гасырга кадәр һәм өлешчә аннан соң да башка атамалар (этнонимнар) белән йөртеләләр. Мәсәлән, скиф-сарматларның, һуннарның (сөннәрнең) зур өлешен төркиләрнең әби-бабалары тәшкил итә. Әмма инде V—VI йөзләрдән башлап төрки (төрек, түрк) атамасы, җыйнама исем буларак, тел һәм этник яктан үзара якын торган төрле кабиләләргә, халыкчаларга (уйгур, татар, болгар, карлук, хәзәр, кимәк, кыпчак, угыз һ. б.) карата кулланыла башлый.

Борынгы төркиләрнең төрле дәүләтләр төзүе мәгълүм. 375 елда, мәсәлән, төркиләрнең бабаларыннан берсе — сөннәр (һуннар), үзара берләшеп, Көнчыгыш һәм Үзәк Европаның, шул исәптән Идел-Җаек буйларын да биләгән зур империя төзиләр. Аның иң кодрәтле һәм мәшһүр патшасы Атилла (бу исем Итил, Әтил, Идел сүзе белән бәйләнештә) 434—454 елларда тәхеттә утыра. VI—VIII гасырларда Тын океаннан Кара диңгезгәчә, Дунайгача булган җирләрдә төркиләрнең Төрки, Көнбатыш Төрки, Көнчыгыш Төрки, Уйгур каганлыклары (империяләре, патшалыклары) яши. Алардагы халыкның бер өлешен «утыз татар», «тугыз татар» кабиләләре тәшкил итә. 632—652 еллар — Азов диңгезе, Дон елгасы буйларында Бөек Болгар дәүләте яшәгән дәвер. (Мөсәгыйт Хәбибуллинның «Кубрат хан» романында нәкъ менә шушы илнең тарихы һәм тормышы гәүдәләндерелә.) Якынча 632—970 елларда Хәзәр каганлыгы яши. Ул Төньяк Кавказны, Кырымны, Идел-Урал буйларының зур өлешен били. IX—XI гасырларда Көнбатыш Себердә (Иртеш буйларында), Көньяк Уралда, Җидесуда, Арал буе далаларында Кимәк каганлыгы яши. Аның халкын, нигездә, кимәкләр, кыпчаклар, татарлар тәшкил итә. IX—XIII гасырның беренче яртысы — Идел Болгарстанының яшәү дәвере. Монголлар һөҗүменә кадәр, ягъни XI—XIII йөзләрдә Түбән Идел, Төньяк Кавказ, Азов, Днепр, Дон буйларында кыпчак дәүләт берләшмәләренең яшәве мәгълүм. Үзәге Шәркый Төркестанда (хәзерге Төньяк-Көнбатыш Кытайда) булган Караханилар дәүләтенең дә төп халкын төркиләр тәшкил иткән.

Борынгы төрки дәүләтләр үзара тыгыз бәйләнештә булган. Еш кына алар бер-берсенең дәвамы булып та торалар. Мәсәлән, хәзәрләр һәм болгарлар әүвәл Төрки каганлыгына керәләр, бераздан үзләре мөстәкыйль дәүләт төзиләр. Азов буендагы Болгар, бу ил җимерелгәч, Хәзәр каганлыгына кертелә. Ә инде Хәзәр каганлыгы таралгач, аның халкы һәм җирләре Болгар һәм Кыпчак илләре арасында бүленә. Кыскасы, борынгы төркиләр арасында күчешләр, үзара керешүләр еш булып торган. Шуңа күрә аларның телләрендә, гореф-гадәтләрендә, рухи мирасларында, аеруча фольклорында һәм язма әдәбиятларында, уртаклык көчле.

Фәндә хәзерге төрки халыклар халыкча (этник кавем, «народность») буларак формалашканчы булган, ягъни якынча XIII йөзләргә кадәрге төрки телле сүз сәнгатен, язма истәлекләрне гомумтөрки әдәбият, уртак хәзинә дип тә йөртәләр. Чөнки бу

мәдәният үзеннән соңгы региональ (Урта Азия, Идел-Урал, Кавказ арты, Кече Азия) һәм милли (төрек, татар, үзбәк, азәрбайҗан һ. б.) әдәбиятлар өчен нигез, елга башы булып торды. Аның традицияләре татар әдәбиятында да ярылып ята. Әлбәттә, XII—XIII йөзләрдән соң да төрки әдәбиятлар арасында үзара керешүләр, күчешләр, уртаклыклар көчле була. Үзара бик якын төрки язма теле кулланыла, бер төбәктәге әсәрләр икенче төбәктә, нигездә, оригиналда, тәрҗемәсез укыла. Шуңа күрә XIII—XV йөзләрдәге төрки әдәбиятларны, язма истәлекләрне кайвакыт милли регионнарына нисбәтән төрки-татар (ягъни Идел-Урал буе, Идел-йорт), төрки-үзбәк (чыгтай, Урта Азия), госманлы төркисе (Кече Азия) һ. б. шундый атамалар белән дә йөртәләр.

Борынгы төркиләрдә мәҗүси (анда төп Алла — Тәңре, ягъни Күк), будда, манихей, зәрдәшт (зороастризм, аның асылын утка табыну тәшкил иткән) һәм башка диннәрнең таралуы мәгълүм. Ә инде VII—VIII гасырларда мөселман дине керә башлый. Рәсми рәвештә исламны хәзәрләр 737, ә болгарлар 922 елларда кабул итәләр.

Безнең борынгы бабаларыбыз Кытай, Һиндстан, Иран, Византия, Европа илләре белән төрле бәйләнешләрдә торалар, алардагы казанышларны теге яки бу дәрәҗәдә үзләштерәләр, үзләре дә башкаларга өлеш чыгаралар. Ислам дине кабул ителгәч, гарәп дөньясы, Урта Азия, Иран белән мәдәни, гыйльми бәйләнешләр аеруча көчәя, бу үз чиратында төрки-татарларның үсешенә зур йогынты ясый.

Борынгы төркиләрнең күпчелеге күчмә тормыш алып бара. Әмма утрак тормышта яшәүчеләрнең дә шактый булуы мәгълүм. Мондыйлар бигрәк тә Идел-Урал төбәгендә күп була. Биредә зур-зур һөнәрчелек үзәкләренең, шәһәрләрнең яшәве билгеле. Мәсәлән, Идел тамагында, хәзерге Әстерхан (Хаҗитархан) каласы тирәсендә, VII—X гасырларда Итил дигән шәһәр була. Үзенең зурлыгы, матурлыгы, гыйбадәт йортларының күплеге белән ул чит ил кешеләрен, аеруча сәүдәгәрләрне таң калдыра. Шунысын да искәртик: Идел-Урал төбәгендә утрак тормышның өстенлек итүендә, шәһәрләрнең үсешендә аның аркылы дөнья сәүдә юлларының узуы да мөһим роль уйный.

Шулай итеп, татарларның барлыкка килүендә төп урынны төркиләр, аеруча хәзәрләр, болгарлар, кыпчаклар, татарлар тәшкил итә. Шуңа күрә Борынгы һәм Урта гасыр татар тарихын һәм әдәбиятын, гомумән, төрки тарих белән тыгыз бәйләнештә генә тиешенчә аңлап була.

XIII йөзнең урталарында, монголлар һөҗүменә һәм Алтын Урда төзелүгә нисбәтән, «татар» этнонимы (исеме) киң тарала башлый, һәм тиз арада ул Идел-Урал төбәгендә элек-электән яшәгән хәзәр, болгар, кыпчак бабаларыбызның да уртак, гомуми исеме булып китқән.

Татар әдәбиятының чорларга бүленеше.

Мең елдан артык тарихы булган татар әдәбияты үзенең яшәешендә, үсешендә берничә баскыч, чор үткән. Шуннан чыгып, аны түбәндәге кисәкләргә бүлеп өйрәнәләр:

1. Борынгы һәм Урта гасыр татар әдәбияты. Ул якынча XIX йөзгә кадәрге вакытны үз эченә ала.
2. XIX гасыр әдәбияты.
3. XX йөз башы әдәбияты.
4. Октябрь революциясеннән, ягъни 1917 елдан соңгы әдәбият (аны элегрәк «Совет чоры әдәбияты» дип йөртәләр иде).

Хәзерге фәндә, соңгы ике чорны берләштереп, «XX йөз әдәбияты» дип атау да гамәлгә керә башлады.

Әдәбият тарихының чорларга бүленешендә төп ике фактор нигез итеп алына: иҗтимагый-тарихи шартлар һәм әдәбиятның билгеле бер дәверенә хас булган үзенчәлекләр. Мәсәлән, Совет чоры әдәбиятының төп асылын Октябрь революциясеннән соң башланган яңа иҗтимагый шартларда социализм өчен көрәш тәшкил итә.

Татар әдәбиятының бу дүрт чоры вакыт ягыннан бер-берсенең тарихи дәвамы булып торалар. Мәсәлән, Борынгы һәм Урта гасыр әдәби традицияләре (дини идеологиянең өстенлек итүе, Шәрыкка йөз тоту, романтик-шартлы фикерләү, күчмә сюжетларның һәм образларның еш кулланылуы һ. б.) әле XIX йөзнең соңгы чирегенә кадәр дә ныклап дәвам итә.

Татар әдәбияты тарихының һәр кисәге үз эчендә берничә чорга бүлеп өйрәнелә. Мәсәлән, Борынгы һәм Урта гасыр татар әдәбиятын мондый төркемнәргә аералар:

1. Гомумтөрки, ягъни борынгы төрки әдәбият. Ул якынча XII— XIII йөзләргә кадәрге вакытны үз эченә ала. Борынгы төрки әдәбият милли төрки әдәбиятлар үсешендә нигез, мөһим чыганак булып тора. Хәзерге төрки халыклар халыкча буларак формалашканчы туган бу рухи мирас уйгурларның, үзбәкләрнең, татарларның, төрекләрнең, азәрбайҗаннарның һәм кайбер башка төрки халыкларның уртак хәзинәсе дип тә йөртелә.
2. Болгар-хәзәр чоры, ягъни болгар-татар әдәбияты (XIII йөзнең урталарына кадәр).

3. Алтын Урда чоры әдәбияты (XIII йөзнең урталарыннан XV гасырның урталарына кадәр).

4. Казан ханлыгы чоры әдәбияты (XV йөзнең урталары —1550 еллар).

5. XVII йөз әдәбияты.

6. XVIII йөз әдәбияты.

XIX йөз әдәбияты исә, нигездә, шул гасырның беренче һәм икенче яртыларына бүлеп карала.

Борынгы һәм Урта гасыр, XIX һәм XX йөз татар әдәбиятының эчке бүленешләрендә дә шактый дәрәҗәдә үзара керешүләр, шартлылыклар бар. Аерым әдипләрнең иҗатлары, гәрчә алар төрле чорга карасалар да, бер генә урында өйрәнеләләр. Мәсәлән, Габдерәхим Утыз Имәни (1754—1834), XVIII—XIX гасырларда яшәвенә карамастан, XVIII йөз кысаларында гына карала. Ризаэддин Фәхреддин (1859—1936), Закир Һади (1863—1933) иҗатлары XIX йөз гасыр әдәбиятына кертеп өйрәнелә. Монда, әлбәттә, бу әдипләрнең яшәү вакытларыннан бигрәк, иҗатларындагы идея-эстетик хосусиятләр беренче планга куела.

Сораулар һәм биремнәр

1. а) «Әдәбиятның үзегендә — кеше» дигәнне сез ничек аңлыйсыз?

ә) «Әдәбият белеме сүзлеге»ннән образ, образлылык, типиклаштыру, индивидуальләштерү, гомумиләштерү төшенчәләре хакындагы мәкаләләрне укыгыз, фикер алышыгыз (индивидуаль бирем рәвешендә дә башкарырга мөмкин).

2. Матур әдәбият һәм кеше тормышы. Сез аларның үзара мөнәсәбәтен ничек күз алдына китерәсез?

3. Әдәбият тарихы нәрсәләрне өйрәнә?

4. а) Борынгы төрки дәүләтләр хакында нәрсәләр беләсез?

ә) *Төрки, төрек, төрки-татар, болгар-татар, төрки-үзбәк (чыгтай), госманлы* атамаларының эчтәлеген һәм кулланылышын аңлатып бирегез.

б) Ни өчен без татар дип аталабыз?

в) Н. Фәттахның «Сызгыра торган уклар» һәм М. Хәбибуллинның «Кубрат хан» романнарын кемнәрнең укыганы бар? Тәэсирләрегезне уртаклашыгыз. Бу романнар буенча китап укучылар конференциясе дә уздырырга мөмкин.

г) Ни өчен без иң борынгы төрки әдәбиятны гомумтөрки мирас, уртак хәзинә дип йөртәбез?

5. а) Әдәбият тарихын чорларга бүлүдәге төп принципларны әйтегез.

ә) Татар әдәбияты тарихы нинди кисәкләргә бүлеп өйрәнелә?

б) Борынгы һәм Урта гасыр әдәбиятының чорларга бүленеше.

6. Сүз сәнгатенең милли үзенчәлеге нәрсә белән билгеләнә, һәм ул нәрсәләрдән гыйбарәт?

БОРЫНГЫ ҺӘМ УРТА ГАСЫР ӘДӘБИЯТЫ

ТӨРКИ-ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНЫҢ ТӨП ЧЫГАНАКЛАРЫ

(Татар әдәбияты тарихына кереш)

ФОЛЬКЛОР ҺӘМ ЯЗМА ӘДӘБИЯТ

Теләсә нинди әдәбиятның нигезен кеше тормышы, реаль чынбарлык, тарих тәшкил итә. Әдәби процессның асылы кешене, аның эчке һәм тышкы дөньясын, җәмгыять һәм табигать белән мөнәсәбәтләрен ничек аңлау һәм ни рәвешле гәүдәләндерүдән гыйбарәт. Кеше табигатьнең бер кисәкчәсе яисә кодрәтле хуҗасы рәвешендә дә күзалланырга мөмкин. Ул изге шәхес тә, явыз зат та була ала. Кеше чынбарлыкка охшаш шартларда һәм эш-гамәлләрдә дә, бөтенләй әкияти планда да, уйдырма һәм реальлек керешкән дөньяда да күрсәтелергә мөмкин. Кол Галинең Йосыфы, Каюм Насыйриның Әбүгалисинасы, Тукайның Шүрәлесе, Гомәр Бәшировның Нәфисәсе («Намус»), Туфан Миңнуллинның Әҗәле («Әлдермештән Әлмәндәр») — бар да «кеше» төшенчәсен ничек аңлауның һәм сәнгати чагылдыруның конкрет мисаллары.

Язма әдәбият үзенең барлыкка килүендә, үсешендә һәм, гомумән, яшәешендә, реаль чынбарлыктан тыш, мифологиягә һәм авыруча сүз сәнгатенең мөһим тармагына — фольклорга бурычлы. Чөнки матур әдәбият алар нигезендә туган, үскән, күп материалларны һәм сәнгатьчә фикерләүнең шактый гына ысулларын, чараларын алардан алган.

Мифология (*грекча* «миф»: сүз, хикәят, вакыйга, легенда) — борынгы кешеләрнең хыял ярдәмендә дөнья (чынбарлык, табигать, җәмгыять һ. б.) хакында тудырган образлы күзаллаулары. Анда дөньяның яратылышы, табигатьтәге һәм

җәмгыятьтәге күренешләр, процесслар, вакыйгалар образлы итеп аңлатылалар.

Мифлар, нигездә, ыруглык дәверендә үк барлыкка килгәннәр. Бу чор кешеләре табигатьтән, ырудашларыннан үзләрен аерып карамаганнар һәм үзләрендәге, үз иҗтимагый даирәләрендәге сыйфатларны бөтен табигатькә, тирә-юньгә, барлык җанлы һәм җансыз нәрсәләргә күчергәннәр. Шул рәвешле, бөтен табигать, тирә-юнь, кош-кортлар, хайваннар, үсемлекләр, кояш, җил һ. б. кеше сыйфатлары алган, «кешеләштерелгән».

Борынгы кешеләр мифлар ярдәмендә дөньяны, бер яктан, танып белергә, үзләренчә аңлатырга омтылсалар, икенче яктан, аңа тәэсир итәргә, табигый көчләрне үз максатларына яраклаштырырга тырышканнар.

Мифологик фикерләү нәтиҗәсендә, күп санлы хикәятләрнең, сурәтләрнең, образлы гыйбарәләрнең тууы мәгълүм. Алар материал, чимал, әдәби чара рәвешендә, мифларга ышану кимегәннән соң да, фольклорда, язма әдәбиятта кулланылуын дәвам итәләр. Аның калдыклары хәзерге телдә дә сакланып калган. Мәсәлән, без, кояш көлә, җил елый, кошлар сөйләшә дип, үзебездәге сыйфатларны кешедән тыш нәрсәләргә күчерәбез. Әмма, борынгылардан үзгә буларак, без инде болай әйтүнең шартлы күренеш, образлы тәгъбир икәнлеген ачык беләбез. Элеккеге кешеләр исә мифларга ышанып караганнар.

Борынгы мифлар фольклорның нигезен тәшкил итә, аның белән тыгыз бәйләнештә тора. Хәтта аларны кайчак берберсеннән аеру да мөмкин түгел. Әмма фольклорда эстетик башлангыч, образлы фикерләү хакимлек итә. Ә инде мифологиягә, гомумән, үз кануннары һәм чаралары ярдәмендә аңлату, дәлилләү, ышандыру, танып белү хас. Ул — борынгы кешеләрнең үзара керешкән (синкретик) фәне дә, дөньяга карашы да, идеологиясе, дине һәм сәнгате дә.

Күп кенә борынгы мифлар телдән-телгә сөйләнеп тә, язуга теркәлеп тә сакланып калганнар. Мәсәлән, яһүди, христиан, мөселман диннәренең Тәүрат, Инҗил, Коръән кебек төп китапларында дөнья халыкларының күп санлы мифлары, мифология белән бәйләнешле сюжет-мотивлары, образлары, сурәтле тәгъбирләре теркәлгән. Бу төр китаплар исә матур әдәбият үсешенең мөһим баскычы да, бетмәс-төкәнмәс чыганагы да булып торганнар.

Матур әдәбият һәм фольклор гомер-гомергә бер-берсе белән җитәкләшеп, үзара керешеп яшәгәннәр һәм яшиләр. Әмма

Борынгы һәм Урта гасырларда алар арасында бәйләнеш аеруча көчле булган. Туып һәм үсеп килгән язма әдәбият мифология-гә, фольклорга ныклап таянган, иҗади материалны, сәнгатьчә фикерләү алымнарын һәм чараларын алардан күпләп алган. Мәсәлән, Йосыф — Зөләйха, Ләйлә — Мәҗнүн, Таһир — Зөһрә, Фәрһад — Ширин, Сәйфелмөлек һәм Бәдигылҗәмал сюжетларының һәммәсе дә диярлек язма әдәбиятка фольклор аша килеп кергән. Борынгылар кешенең җанын кош рәвешендә күзаллаганнар. Бу мифологик караш, шигъри сурәткә әйләнеп, Котб, Мөхәммәдьяр һәм башка бик күп шагыйрьләр иҗаты аша Тукайга ук килеп җитә:

Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңлем кошы,
Шат яратса да, җиһанга ят яраткан Раббысы...

(«Өзелгән өмид»)

Үз чиратында язма әдәбият та фольклорга йогынты ясаган. Аерым сюжет-мотивларның, образларның, шигъри сурәтләрнең язма әдәбияттан халык авыз иҗатына күчеп, теге яки бу дәрәҗәдә үзгәреп яшәүләре дә мәгълүм. Мәсәлән, Кол Гали әсәрендәге строфа, үлчәм үрнәгендә бәетләр, җырлар туа.

Сораулар һәм бирем

1. Мифология нәрсә ул?

2. Фольклор һәм мифологиянең үзара мөнәсәбәтләрен ничек күзаллыйсыз?

3. «Әдәбият белеме сүзлеге»ннән мифология, фольклор хакындагы мәкаләләрне укып, эчтәлекләрен сөйләгез.

4. Ни өчен мифология фольклор язма әдәбиятның нигезе булып тора?

РУН ЯЗУЛЫ ИСТӘЛЕКЛӘР

Борынгы төркиләрнең үз язулары һәм, гомумән, язма әдәбияты кайчан барлыкка килгән соң? Кайбер галимнәр безнең әби-бабаларыбызның моннан ике мең еллар элек үк язулы булуын искәртәләр. Тарихчы галим, профессор Әзһәр Мөхәммәдиев, мәсәлән, безнең эрага кадәр 200—150 елларда ук туран язуының кулланылуын әйтә. (Аерым чыганакларда борынгы төркиләр яшәгән җирләрне һәм мәмләкәтләрне Туран дигән җыйнама исем белән атаганнар. Андагы кавемнәрне шартлы рәвештә туранлылар дип атау очрый. «Туран язуы» гыйбарәсе дә нәкъ әнә шул җирлектә барлыкка килгән. Бу графиканы кайчак һун язуы дип тә йөртәләр.)

Ижевск, Пермь, Санкт-Петербург һәм кайбер башка шәһәрләрнең музейларында элеккеге эраның ахырларына һәм безнең эраның тәүге гасырларына караган язулы тәңкәләр һәм алтын-көмеш савытлар саклана. Аларның шактые Кама (Чулман) һәм Урта Идел буйларында, бүген татарлар яши торган төбәкләрдә табылган. Тәңкәләрдә хөкемдар сурәтләре, ай, кояш, төрле җәнлек, үсемлек рәсемнәре төшерелгән. Алар, зәвыклы итеп, сәнгати нәфислек белән ясалганнар. Тәңкәләр чагыштырмача борынгы чорга карый. Ә инде язулы һәм сурәтле савытлар Имәнкискә культурасы (IV—V гасырлар) белән бәйләнешле.

Галим Ә. Мөхәммәдиев бу төр тәңкәләрдәге һәм савыт-сабалардагы язуларның күбесен укуга ирешә һәм аларның төркичә булуын искәртә. Бу текстларда «тәңриг» (тәңре), «мәңиз» (йөз, кыяфәт), «күрк» (матурлык) кебек бүгенге көн укучыларына да аңлаешлы сүзләр очрый.

Борынгы төркиләр үзләренең рун истәлекләре белән дөньяга мәгълүм. Алар, нигездә, VI—IX гасырларга карый. Ә. Мөхәммәдиев фикеренчә, рун язуы борынгы туран язуына нигезләнеп туган. Чөнки алар арасында шактый гына уртаклыклар, охшашлыклар бар.

Борынгы төрки руник әлифбасы, нигездә, һәрберсе аерым язылучы 60 лап тамгадан гыйбарәт (төп хәрефләре — 36).

Текстлар уңнан сулга, өстән аска язылган. Борынгы төрки хәрефләр үзләренең язылу рәвешләре белән татар-башкортларда соңгы дәверләргә кадәр кулланылган гаилә тамгаларын хәтерләтәләр. Һәм бу табигый дә. Чөнки безнең борынгы әби-бабаларыбыз уйгур һәм гарәп графикаларын кулланганга кадәр рун әлифбасы белән эш иткән.

Рун язулы истәлекләр Себердә, Монголиядә, Алтайда, Шәркый (Көнчыгыш) Төркестанда, Казахстанда, Урта Азиядә, Идел-Урал буйларында, Төньяк Кавказда, Дунай тамагында һәм борынгы төркиләр яшәгән кайбер башка җирләрдә табыла. Әмма аларның күпчелеге хәзерге Монголиядә һәм Көньяк Себердә, төгәлрәк әйткәндә, Енисей елгасы башланган җирләрдә, Орхон (Урхун) буйларында очрый. Шуңа күрә борынгы төрки рун ядкярләрен еш кына, күпләп табылу урыннарына карап, Урхун-Енисей язма истәлекләре дип тә йөртәләр.

Төркиләрдә рун әлифбасы, нигездә, исламгача чорда, ягъни IX гасырга кадәр, актив кулланыла. Әүвәл аны уйгур графикасы кысрыклый башлый. Бераздан инде гарәп әлифбасы мөселман динен кабул иткән төркиләрдә төп графикага әверелә.

Рун текстларының күпчелеге төрле ташларга, диварларга, металл һәм сөяк әйберләргә, чүлмәкләргә язылган. VIII—IX гасырлардан башлап кәгазьгә теркәлгән текстлар да (мәсәлән, «Юрау язмасы») очрый. Әмма рун истәлекләренең төп өлеше эпитафик характерда, ягъни каберташ язмалары рәвешендә.

Борынгы төрки ядкярләрен уку, гыйльми өйрәнү, бастыру чагыштырмача соңрак — XIX гасырның 90 нчы елларында гына башлана. Дания галиме В. Томсен һәм Россия профессоры В. Радлов бу эшнең башында торалар.

Үзләренең идея-тематикалары, эчтәлекләре, жанрлары, вазифалары белән рун язмалары төрле. Арада әдәби, тарихи, юридик, дини, көнкүреш эчтәлегендәге текстлар да, фольклор үрнәкләре дә, аерым кешеләрнең язмалары да, шигъри һәм чәчмә юллар да бар. Әгәр дә бу истәлекләрнең һәммәсен бергә җыеп, бер система рәвешендә карасак, алар аркылы без борынгы төркиләрнең тормыш-көнкүрешен, гореф-гадәтләрен, телләрен шактый дәрәҗәдә күз алдына китерербез. Мәсәлән, язмалардан борынгы төркиләрнең уйгур, утыз татар (отуз татар), кыргыз (кыркыз), тугыз угыз (токуз огуз), карлук һәм башка кабиләләрдән торуы аңлашыла.



Рун (Урхун-Енисей), уйгур һәм гарәп алфавитындагы тамгалар

Борынгы рун истәлекләре арасында әдәби-тарихи яктан аеруча Күлтәгин, Билгә-каган (патша, император), Танъюкук хөрмәтенә язылган каберташ ядкярләре игътибарга лаек. Күлтәгин — гаскәр башлыгы (685—731), Билгә-каган —аның абыйсы. Ул 734 елда вафат була. Язмалар 732—735 еллар арасында Билгә-каганның якыннарыннан берсе —Йолыктәгин тарафыннан төзелгән. Ә Танъюкук — Туран-йортның (Төрки империясенең, каганатының, иленең) акыл иясе, гаскәр башлыгы, аксакалы. Ул зама-

нында Кытайда укып белем алган. Төркиләрнең бердәмлеген ныгытуга, көч-куәтен арттыруга зур өлеш кертә. Каберташ текстын ул үзе исән вакытта ук (716 елларда) яздырып куя.

Һәр өч ядкярдә дә мифологик материаллар, тарихи вакыйгахәлләр төп каһарманнарга фон, җирлек рәвешендә алынган. Үзәктә — Күлтәгин, Билгә-каган, Танъюкук, аларның кылган эш-гамәлләре, батырлыклары. Текстлардан шушындый фикерләр саркып чыга: каган хакимияте — ул илаһи власть, чын бәхет — каганга буйсынуда, аның әмерләрен җиренә җиткереп үтәүдә; хөкемдар акыллы, зирәк булырга, халыкта тупланган гореф-гадәтләр, әхлакый кануннар (түрү) нигезендә идарә итәргә тиеш; аларны сакламаган, бозган каган илгә, халыкка зур зыян китерә; бәхет, бәрәкәт — бердәмлектә, татулыкта.

Һәр өч истәлек тә, нигездә, рифмалы проза, шигъри юллар катнашмасыннан гыйбарәт. Язмаларның стиле шактый камил, аларда билгеле бер кануннар, жанр таләпләре саклана (бу үзе үк төрки язма теленең озын юл үтүен, бай тарихлы булуын сөйли). Текстлар тыңлаучыга эндәш, мөрәҗәгать рәвешендә, нигездә, беренче заттан язылган. Эмоциональлекне, тәэсир көчен арттыруда кабатлау алымы еш кулланыла. Бердәй яисә охшаш хәлләрне белдерүдә авторлар кайвакыт тотрыклы гыйбарәләр, сурәтләр белән дә эш итәләр. Мәсәлән, каһарманның башкаларны җиңүе, үз дошманнарын буйсындыруы болай сурәтләнә[1]:

Башлыларны йөгендерде (арытты, башларын идерде),
Тезлеләрне чүктерде.

Яисә:

Иллеләрне (иле барларны) илсез итте,
Каганлыларны — кагансыз.

Текстларда аерым сүзләрне, гыйбарәләрне, хәтта кайбер кисәкләрне шул килеш яисә бераз үзгәртеп куллану еш очрый. Бу — дәлиллекне, эстетик ышандыру көчен арттыра. Мәсәлән:

Илле халык идем,—
Илем инде кайда?..
Каганлы халык идем,—
Каганым (инде) кайда?

Биредә кабатлау антитеза, риторик сорау алымнары һәм чаралары белән кушылып бирелгән.

---

[1] Алга таба да текстлар, нигездә, хәзерге әдәби телгә тәрҗемәдә бирелә.

Энем Күлтигин кәргәк болты, үзем сакынтым:
Күрер күзем күрмәс тәг,
Белер белегем белмәс тәг болты, үзем сакынтым.

Ягъни:

Энем Күлтәгин үлде, үзем кайгырдым:
Күрер күзем күрмәс,
Акыл-зиһенем белмәстәй булды, үзем кайгырдым.

Бу текстта да без сәнгатьлелекне, эмоциональлекне көчәйтүдә кабатлау, синтаксик янәшәлек, шигырь һәм чәчмә юлларны кушу алымнарының уңышлы кулланылуын күрәбез.

Рун язмаларында фольклор, мифологик фикерләү белән бәйләнеш үзен нык сиздерә. Вакыйга-хәлләр еш кына өч мәртәбә кабатланып бирелә. Мәсәлән, бер язмада каһарман сугыш вакытында өч ат алыштыра. Җиде, җитмеш, җиде йөз кебек символик саннар еш очрый. Дастан каһарманнары кебек, Күлтәгин, Билгә-каган, Танъюкукның бөтен тормыш юллары тасвирлана. Биредә дә гадәттән тыш арттыру, тантаналылык, каһарманның үз-үзен мактавы күзгә ташлана, Танъюкук чын акыл иясе, аксакаллар кебек сурәтләнә. Аның сөйләме өчен дә фикри тирәнлек, афористик яңгыраш хас.

Рун ядкярләре моннан 1000—1400 еллар элек язылган. Күпчелеге эпитафик характерда. Ә инде каберташ язмаларының тел-стиле, кагыйдә буларак, архаик, ягъни үз чорыннан да борынгырак була. Әмма шуңа да карамастан рун язмаларында бүгенге укучыларга таныш сүзләр, гыйбарәләр, грамматик формалар күпләп очрый. Мәсәлән, «Энем Күлтигин йити йашда калты», «Энем Күлтигин әр-ат болты» (ир-ат булды.— *X. M.*), «Күлтигин йок эрсәр (ирсә), күп олтәчи әртигез» (күбегез үлер иде.—*X. M.*), «Бирин-бирин мең булыр, Таматама күл булыр» җөмләләренең сүзләрен һәм мәгънәләрен аңлау һич тә кыен түгел.

Әмма борынгы рун истәлекләрендә тел ягыннан бүгенге белән чагыштырганда үзгәлекләр дә шактый. Мәсәлән, халык, кара халык, масса «будун» сүзе белән йөртелә. Бераздан бу сүз язма телдә гарәптән алынган «рәгыйять» сүзе белән алыштырыла. Ажун — дөнья, яблак — начар, кәргәк болты — үлде, битиг (битик) — язма (бөти) — китап, көн тугсык — көнчыгыш һ. б. шундый сүзләр дә элеккеге текстларда актив.

Рун истәлекләрендәге күп кенә фикерләр, образлар, сүзгыйбарәләр, мәкаль-әйтемнәр, сурәтләр һәм тасвир чаралары үзләреннән соңгы төрки сүз сәнгатендә, шул исәптән татар

фольклорында һәм язма әдәбиятында да, билгеле бер дәрәҗәдә кулланылуларын дәвам иткәннәр. Мәсәлән, Күлтәгин, Билгә-каган истәлекләрендә һәм кайбер башка ядкярләрдә сүз мәрхүм кеше авызыннан үткәннәрне искә төшерү рәвешендә алып барыла. Мондый алым татар бәетләре өчен дә хас. Руник язмаларда көчле, батыр кеше — Алып, аның аты акбүз дип бирелә. Алып батырлар акбүз атка атланып чабулар белән без күп кенә фольклор әсәрләрендә очрашабыз.

* * *

Соңгырак дәвердә язылган рун истәлекләренең берсе — «Ырыг битиг», ягъни «Юрау китабы» («Тәгъбирнамә»). Кәгазьгә язылган бу ядкяр кытайча текстлар тәэсирендә якынча IX гасырларда төзелгән. Стиле — шигъри юллар белән аралаштырылган ритмлы проза. Әмма аерым кисәкләре синтаксик янәшәлеккә корылган шигъри парчалардан гыйбарәт.

«Юрау китабы» төрле зурлыктагы 65 бүлекчәдән гыйбарәт. Бу сюжетлы бүлекчәләрдә табигатьтәге, тормыш-көнкүрештәге, тирә-юньдәге төрле билгеләргә, галәмәтләргә карап, яхшымы, яманмы дигән нәтиҗә ясала. Мәсәлән: «Ир кайгылы (пошман), күк болытлы булды. (Ике) арада кояш чыкты. Кайгы урынына шатлык килде. Шуны белегез: изге (яхшы) ул!»

«Юрау китабы»нда төрле мифологик ышанулар, борынгы гореф-гадәтләр зур урын алган. Бер хикәяттә мондый сюжет бар: «Бер аккош (когу кош), аты арып, авыр хәлдә калган бер кешене канатларына утырта да әти-әниләре янына кайтарып куя. Егетнең ата-аналары бик куана». Ахырда мондый хәлнең «әдгү»гә, ягъни яхшыга юнәлтелгән булуы әйтелә. Күрәсез: хикәяттә аккош билгеле бер дәрәҗәдә тылсымлаштырыла, кешенең ярдәмчесенә әйләндерелә. Бу төр мотивлар, күренешләр исә татар халык экиятләрендә дә күпләп очрый.

Язмаларда ак төс, нур, тереклек уңай (изге), ә караңгылык үлем, яман галәмәт рәвешендә аңлашыла. Шунысы кызыклы: ак төс, нур чәчү,— гомумән, татар образлы фикерләвенә хас сурәтләр. Мәсәлән, Кол Галинең Йосыфы нурлы, нур чәчеп торучы рәвешендә тасвирлана.

Сораулар һәм биремнәр

1. Борынгы төркиләрдә язу кайчан барлыкка килгән?
2. «Рун», «Урхун-Енисей», «каган», «тәгин» төшенчәләрен аңлатып бирегез.

3. Борынгы рун истәлекләренең гомуми эчтәлеге, поэтикасы, идея-тематикасы хакында сөйләгез.

4. Борынгы төркиләрнең Кытай белән бәйләнешләре нәрсәләрдә күренә?

5. Рун истәлекләренең тел үзенчәлекләре.

6. «Күрер күзем күрмәс төг, белер белегем белмәс төг болты» җөмләсенең мәгънәсен ничек аңлыйсыз?

7. «Юрау китабы»ның төзелеше, эчтәлеге, идея-сәнгати үзенчәлекләре.

8. Борынгы руник әдәби традицияләренең татар фольклорында һәм язма әдәбиятында дәвам итүе хакында сөйләгез.

УЙГУР ЯЗУЛЫ ИСТӘЛЕКЛӘР

Татарлар, үзбәкләр, кыргызлар h. б. кебек, уйгурлар — төрки халыкларның бер төркеме. Аларның ватаны — Шәркый Төркестан, ягъни хәзерге Монголия, Алтай, Казахстан, Кыргызстан, Таҗикстан, Һиндстан, Тибет арасындагы җирләр. Уйгурларның күпчелеге бүгенге Көнбатыш Кытайдагы Уйгур автономияле районында, Гөлҗә, Өремче, Турфан, Хатан, Яркәнт, Кашгар, Аксу кебек калаларда яши. Бер өлеше — Үзәк Кытайда (Ганьсу провинциясендә) һәм Казахстанда.

Борынгы уйгурлар 745 елда үз каганлыкларын төзиләр. Урта Азия һәм Шәркый Төркестанның күп җирләрен, халыкларын үз эченә алган һәм 840—1212 елларда яшәгән Караханилар дәүләтендә дә хәлиткеч урынны уйгурлар алып торган (аның төп шәһәрләре — Кашгар, Баласагун). Борынгы уйгурларда, башка төркиләрдән үзгә буларак, мәҗүси диненнән тыш, Кытай, Һиндстан, Иран йогынтысы нәтиҗәсендә будда, манихей диннәре дә шактый нык тарала. Шуңа мөнәсәбәттә уйгур теленә күп кенә дини китаплар да тәрҗемә ителә.

Борынгы уйгурлар, — кытайлардан кала, кәгазь кулланган һәм җитештергән икенче халык. VIII гасыр урталарында ук инде аларның күпләп кәгазь җитештерүләре мәгълүм.

Уйгурлар әүвәл, башка төркиләр шикелле, туран, рун әлифбаларын кулланалар. VII гасырларда алар үз әлифбаларын төзиләр. Бу графика әкренләп башка төрки халыклар арасында да тарала башлый. Бераздан аны монголлар, маньчжурлар кабул итә. Әмма ислам дине тарала барган саен, төркиләр арасына гарәп әлифбасы да ныклап керә. Әүвәлге чорларда бу ике графика янәшә дә кулланыла. Аксак Тимер (XIV) һәм аның кайбер варислары уйгур әлифбасына өстенлек бирергә тырышсалар да, гарәп язуы мөселман төркиләрендә хәлиткеч урынны ала.

Уйгур әлифбасындагы тамгаларның бер өлеше, гарәп графикасындагы кебек, сүзнең башында, уртасында, ахырында килүенә карап, төрлечә языла. Язу юнәлеше уңнан сулга.

Безнең көнгә килеп җиткән борынгы төрки истәлекләрнең күбесе уйгур хәрефләре белән язылган. Алар арасында дини, әдәби, тарихи текстлар, тәрҗемәләр, оригиналь әсәрләр бар.

«Алтун ярук» («Алтын балкыш») — будда дине рухындагы зур күләмле әсәр. Ул Шәркый Төркестандагы Бишбалык (балык — борынгы төрки телдә шәһәр дигән сүз) төбәгендә X гасырда язылган. Авторы — Сынгку Сели Тудунг дигән кеше. Китап кытайчадан тәрҗемә ителгән. Аның тулы исеме: «Барлык нәрсәдән дә бөегрәк, алтын белән балкый торган шаһ-китап».

«Алтун ярук» будда динен тотучы уйгурлар арасында бик популяр була. Аны шифа, дәва китабы дип тә йөртәләр.

«Алтун ярук»тагы текстлар арасында легендалар да бар. Шуларның берсендә бер шаһзадәнең ничек итеп 7 балалы ач юлбарыска үзен корбан итүе, бу фаҗигале хәлне белеп, аның әти-әнисенең аһ-зар кылуы хикәяләнә. Кайгы киләсенә табигать, төш күрү ярдәмендә алдан ук ишарә ясала. Җир «тирбәлә», һава караңгылана, елга-сулар тулып таша. Шаһзадәнең әнисе (аның өч улы була) төшендә өч күгәрченнең берсен лачын алып китүен, күкрәгенең пычак белән кискәләнүен, урт тешләренең коелуын күрә.

Легендада вакытсыз гомере киселгән уллары өчен ата-ананың кайгыруы сәнгати яктан гаять үтемле итеп тасвирлана. Ана һушыннан яза. Аңына килгәч, чәчен-башын туздырып, ике кулы белән күкрәкләрен кыйнап, елый-елый шигырь-сыктаулар әйтә, судан «эссег комга» атылган балык кебек ауный. Нәрсә булды минем йөрәккә? Бу йөрәгем ярылып типми башлады, ди.

Будда дине тәгълиматы нигезендә кеше башка җан ияләре белән бер рәттә карала. Ул кылган эш-гамәленә мөнәсәбәттә бары төрле рәвешләр генә ала. Мондый караш «Алтун ярук»та да үзен нык сиздерә. Бер легендада, мәсәлән, хайваннарны рәнҗеткән шәһәр башлыгы төрле җәзаларга дучар була.

Гомумтөрки әдәбиятның, «Котадгу белек» (1069), «Һибәтел-хәкаик» («Хаклыклар бүләге», XII йөз) кебек мәшһүр истәлекләрнең гарәп язулы нөсхәләреннән тыш, уйгур әлифбасындагы кульязмалары да бар.

Элеккеге заманнарда Идел-Урал буйларында, рун әлифбасы кебек үк, уйгур графикасы да билгеле бер таралыш таба. Башка төрки һәм монгол халыкларына борынгы уйгур мәдәниятенең йогынты ясавы мәгълүм. Мәсәлән, Чыңгыз хан балаларын, монгол империясендәге асыл затларны тәрбияләүдә уйгур укымышлылары актив катнаша. Алтын Урда сарайларында да уйгур чиновникларының хезмәт итүе, гарәп әлифбасы белән бергә уйгур графикасының да кулланылуы билгеле. Мәсәлән, Туктамыш ханның Ягайлога татарча язма ярлыгы (1393) уйгур хәрефләре белән теркәлгән. Алтын Урда ханы Тимер-Котлуг ярлыгы (1398) гарәп һәм уйгур хәрефләре белән язылган. XIV йөз шагыйре Харәзминең «Мәхәббәтнамә» поэмасы 1432 елда уйгур хәрефләре белән күчерелә.

Борынгы төркиләрдә, туран, рун, уйгур әлифбаларыннан тыш, кытай, согыд, манихей, брахми һ. б. язуларының да кулланылуы мәгълүм. Әмма алар озын гомерле булмый. VII гасырларда ук ислам дине белән бергә керә башлаган гарәп әлифбасы мөселман төркиләренең, шул исәптән татарларның да, төп язуына әверелә. Меңьеллык төрки язма мәдәният ул, — нигездә, гарәп язуындагы мәдәният.

Биремнәр

1. Борынгы уйгурлар хакында сөйләгез һәм алар яшәгән җирләрне картадан күрсәтегез.
2. Таблицадан (16 нчы бит) уйгур хәрефләрен, аларның язылу рәвешләрен күзәтегез.
3. «Алтун ярук» әсәренең язылу вакыты, авторы, үзенчәлекләре турында сөйләгез.

МӘХМҮД КАШГАРЫЙНЫҢ «ДИВАНЕ ЛӨГАТЕТ-ТӨРК» КИТАБЫ (1072—1074 еллар)

Мәхмүд бине (улы) Хөсәен бине Мөхәммәд — XI йөздә яшәгән һәм иҗат иткән галим. Элек туган яисә укыган, яшәгән авыл-шәһәрләрнең атамаларын кушамат итеп алу киң таралган була (Болгари, Сараи, Казани һ. б.). «Диван...» авторы да шул гадәткә тугрылыклы кала: үзе яшәп алган Шәркый Төркестандагы Кашгар шәһәрен үзенә кушамат итә. Әмма тумышы белән ул Ыссык күл тирәсендәге Барсхан төбәгеннән. Мәхмүд Кашгарый Шәрык дөньясының кайбер башка урыннарында да яши.

Мәхмүд Кашгарыйның бу мәшһүр китабы тәүге мәртәбә 1915—1917 елларда Истанбулда 3 томда нәшер ителә. 1960—

1963 елларда 3 томлык үзбәк басмасы дөнья күрә. Китапның, андагы аерым өлешләрнең немец, рус һәм кайбер башка телләргә дә тәрҗемәләре бар. Нәкый Исәнбәт, Хатип Госман, Хуҗи Мәхмүтов хезмәтләре аша «Диван...»дагы аерым үрнәкләр татар укучыларына да таныш.

Диван — җыентык, тупланма, китап дигән сүз. Эчтәлегенә карап Мәхмүд Кашгарый китабын «Төрки телләр җыентыгы», «Төрки телләр сүзлеге», «Төрки сүзләр җыентыгы» дип төрлечә тәрҗемә итәләр.

«Диван...» — зур күләмле (1266 елгы кульязмасында — 638 бит) китап. Анда төрки халыкларның мифологиясенә, фольклорына, язма әдәбиятына, теленә, тарихына, тормыш-көнкүрешенә, гадәт-йолаларына кагылышлы күптөрле мәгълүматлар бар. Мәсәлән, «Болгар — төрки шәһәрләрдән мәшһүр бер кала», «Әтил — кыпчак илләрендәге бер елганың исеме» һ.б.

«Диван...», — барыннан да элек сүзлек характерындагы җыентык. Анда 9 мең тирәсе төрки сүзгә һәм сүзтезмәгә аңлатмалар бирелә, мисал (иллюстрация) рәвешендә 300 дән артык мәкаль, 165 дүртьюллык һәм 68 икеюллык шигъри строфа теркәлә. Китап үзе гарәп язуы белән гарәп телендә язылган. Әмма төрки сүзләр, сүзтезмәләр, мәкаль-әйтемнәр, шигъри юллар әүвәл оригиналда, аннан гарәпчәгә тәрҗемә итеп бирелгәннәр.

Мәхмүд Кашгарый сүзлек материалларын озак еллар буе, үзе йөреп, үзе туплавын искәртә.

«Диван...»дагы мәкаль-әйтемнәрдә тормыш-көнкүрешнең, кеше эшчәнлегенең төрле тармаклары гәүдәләнеш тапкан. Мәсәлән: «Андыз (каты үлән. — *Х. М.*) булса, ат үлмәс»; «Курыкмыш кешегә куй башы куш күренер»; «Ут төтенсез булмас, егет языксыз булмас» һ. б. Борынгы кешеләрнең тормыш тәҗрибәсен, күзәтүләрен туплаган мондый мәкаль-әйтемнәр өчен фикер тирәнлеге, интонацион нәфислек хас.

«Диван...»дагы мәкаль-әйтемнәрнең күпчелеге шул килеш тә, теге яки бу дәрәҗәдә үзгәрешләр алып та хәзерге төрки телләрдә, шул исәптән татар телендә дә кулланылуын дәвам итәләр. Мәсәлән, хәзерге телебездә «Тау белән тау кавышмаса да, кеше белән кеше очрашыр» дигән мәкаль еш ишетелә. Баксаң, моның төрдәше Мәхмүд Кашгарый китабында ук бар икән: «Таг тагка кавышмас, кеше кешегә кавышыр». Мондый мисалларны «Диван...»нан күпләп китерергә мөмкин: «Бер карга берлә кыш килмәс», «Ике кучкар башы бер ашачта (ка-

занда, аш савытында) пешмәс», «Кыш кунагы — ут», «Тегермәндә тугмыш сычган (тычкан) күк күкрәгеңә курыкмас», «Олыгны олыласа, кот (бәхет) булыр» һ. б.

Мәхмүд Кашгарый китабындагы шигъри строфаларны галимнәр, эчтәлекләренә, төзелешләренә карап, төркемләп чыкканнар. Нәтиҗәдә төрле күләмдәге һәм төрле жанрдагы текстлар барлыкка килгән. Алар арасында фольклор һәм язма әдәбият үрнәкләре дә, дастаннардан өзекләр дә, тарихи һәм лирик җырлар, мәдхия-мәрсияләр, мәхәббәт шигырьләре, табигать лирикасы һәм башка төр әсәрләр дә бар. Алар өчен идея-тематик киңлек, шигъри камиллек хас.

Мәхмүд Кашгарый үз китабына төрки халыкларның күп гасырлык бай рухи хәзинәсен туплаган. Анда хәтта VIII йөзгә мөнәсәбәтле материаллар да бар.

Элеккеге кешеләр тормышында, җәмгыять тарихында сугышлар зур урынны алып торган. Шуңа нисбәтән күп санлы фольклор һәм язма әдәби әсәрләр дә туган. «Диван...»дагы шигырьләрнең дә зур бер өлеше сугыш турында. Аларда кан коюлы орышларның рәхимсезлеге, үлем ачысы тасвирлана («Каны гөжләп акты», «Үлем аны кунак итте: Авыз эченә агу салды», «Аның гаскәре үлән кебек чабылды...»), каһарманнарның батырлыклары һәм кыюлыклары сурәтләнә. Биредә герой еш кына арыслан белән чагыштырыла. Мәсәлән:

Ачуым килеп үкердем,
Арысландай күкрәдем.
Алыплар башын турадым,—
Инде мине кем тотар?!

«Диван...»да үгет-нәсыйхәт, әхлак рухындагы шигырьләр дә шактый. Аларда юмартлык, кунакчыллык, сабырлык, белемлелек кебек сыйфатлар мактала:

Үгет ал син, угыл, миннән, игелек теләш,
Буйга җитеп, галим булып, белемең өләш.

* * *

Кунагыңны хөрмәт белән тот,
Ул синең даныңны халыкка таратсын.

Мәхмүд Кашгарый туплаган шигъри парчаларның бер өлешендә мәхәббәт, сөйгән ярның гүзәллеге сурәтләнә.

Йалвын аның күзе,
Йалкын аның үзе.
Тулун айы йөзе —
Йарды мәнең йөрәк.

(Сихерле аның күзе,
Ялкынлы аның үзе (күңеле),
Тулган айдай йөзе —
Телгәләде йөрәгемне.)

«Диван... »да фәлсәфи эчтәлекле шигырьләр дә бар. Аларда вакытның рәхимсезлеге, кеше гомеренең фанилыгы, үлемнең котылгысызлыгы тасвирлана. Кеше үз гомерен, мал-мөлкәткә кызыкмыйча, кайгы-хәсрәткә бирешмичә, игелекле гамәлләр кылып уздырырга бурычлы. Бер дүртьюллыкта «тавар» һәм мөлкәтнең кешенең дошманы икәнлеге әйтелә.

«Диван...»дагы шигырьләр өчен табигать дөньясы белән гадәттән тыш якынлык хас. Ул турыдан-туры да, иҗтимагый һәм шәхси мәсьәләләргә мөнәсәбәттә дә сурәтләнә. Шигъри текстларда төрки төбәкләрнең елгалары (Әтил, Әртиш, Или...), кош-кортлары (каз, сандугач...), хайваннары (ат, сыер, куй, буга (үгез), төлке, бүре, эт...), агач-үсемлекләре (артыш, тал...) телгә алына.

«Кыш белән Җәй бәхәсе» шигырендә табигать фасыллары кешеләштерелә. Кыш һәм Җәй бер-берсен тәнкыйтьлиләр, үзләренең өстенлекләрен күрсәтәләр, үз гаскәрләре белән бер-берсенә каршы көрәшкә ташланалар. Кыш, мәсәлән, Җәйне чир таратуда, төрле бөҗәкләрне, елан-чаяннарны үрчетүдә гаепли. Җәй исә Кышның салкынлыгы, җан ияләренә рәхимсезлеге белән риза түгел. Шигырьдә Җәйгә өстенлек бирелә: табигатьнең уянуы, агачларның яшәрүе, гөлләрнең чәчәк атуы, кош-кортларның, хайваннарның үрчүе җанлы, матур итеп тасвирлана. Бу шигырь үзенең төзелеше, конфликты белән халык дастаннарын хәтерләтә. Биредә дә Кыш белән Җәй, дастан каһарманнары кебек, үзара бәхәсләшәләр, орышалар.

Мәхмүд Кашгарый туплаган шигъри текстларның күпчелеге өчен вакыйгалылык, эпиклык хас. Дүртьюллыкларда еш кына чагыштырмача мөстәкыйль бер күренеш, эпизод гәүдәләнеш таба.

«Диван...»дагы шигырьләрдә сурәтләү чараларыннан аеруча чагыштыру иркен кулланыла. Зифа буй — тал, матур йөз — тулган ай («тулун айын йөзе»), күз яше яңгыр, елга, диңгез белән чагыштырыла, кешенең кычкыруы бүре улавы белән тиңләнә. Шунысы мөһим: табигать дөньясы белән бәйләнешле бу төр сурәтләр фольклорда һәм язма әдәбиятта Кашгарый дәвереннән соң да иркен кулланылалар. Мәсәлән, Мөхәммәдьяр бер каһарманының буен «ирерди тал чыбык тик буе» дип тасвирлый.

«Диван...»дагы дүртьюллыкларның күпчелеге төрки, шул исәптән татар шигърияте өчен хас булган 7 шәр иҗекле юллардан гыйбарәт. Арада 8 әр иҗеклеләре дә очрый. Рифмалашу, нигездә, *аааб,аааа* рәвешендә.

Икеюллыкларның күпчелеге 11 әр иҗекле, рифмалашулары *аа* схемасында.

Борынгы төрки фольклор һәм язма әдәби мирасының мөһим чыганагы булган «Диван...», рун, уйгур язулы башка ядкярләр белән беррәттән, үзеннән соңгы төрки мәдәниятләр үсешендә нигез, йогынтылы фактор булып хезмәт итте. Аның шифалы традицияләрен без татар әдәбияты мисалында да ачык күрәбез. «Диван...»дагы төрки текстларның тел-стиле, халкыбызның сөйләм теле белән берлектә, язма телебезнең нигезен тәшкил итә. Әдәбиятыбыздагы күп кенә образлар, сурәтләү чаралары, мотивлар, жанрлар (мәдхия, мәрсия, робагый, дастан, икеюллык һ. б.) үзләренең башлангычларын борынгы чыганаклардан ук алалар.

Кеше элек-электән гадел, имин, бәхетле тормыш турында хыялланган. «Диван...»дагы бер шигырьдә мондый җәмгыять бүре белән куй (сарык, бәрән) килешүе аша гәүдәләндерелә: «Куй чагасы бүре белән (бергә) үссен һәм кайгы китсен». Имин тормышны, социаль гармонияне куй — бүре, карчыга — үрдәк дуслыгы аркылы бирү Котбта, Сәйф Сараида, Мөхәммәдьярда һәм кайбер башка татар шагыйрьләрендә дә бар. «Төркичә Шаһнамә»дә (ул 1510 елда Мисырда төгәлләнгән) бу образларга күгәрчен белән каз да өстәлә: «...Лачын каз белән үрдәкләрне кочаклар. Күгәрчен белән лачын бер җирдә очар, үбәр «агызыннан» лачынны күгәрчен».

Мәхмүд Кашгарый китабында безнең борынгы бабаларыбызның берсе булган болгарлар хакында да мәгълүматлар теркәлгән. Хәтта анда Идел турындагы мондый шигырь дә бар:

Этил суы ака торур,
Кыя төбе кака торур,
Балык тәлим бака торур,—
Кулың тәкый кушарур.

Ягъни:

Идел суы ага торыр,
Кыя төбен кага торыр,
Бик күп балык багып торыр,—
Кулың белән кушырырлык (кушырып алырлык).

Әгәр дә «Диване лөгатет-төрк» берничә гасырлык фольклор үрнәкләрен һәм билгесез авторларның әсәрләрен тупласа, «Котадгу белек» — тулысы белән бер кешенең (Йосыф Баласагунлының) иҗат җимеше.

Сораулар һәм биремнәр

1. Мәхмүд Кашгарый хакында сөйләгез.
2. Ни өчен китапка «Диване лөгатет-төрк» исеме бирелгән?
3. «Диван...»дагы мәкаль-әйтемнәргә нинди сыйфатлар хас?
4. «Кеше аласы эчтин, елкы аласы тыштин», «Ничә йитиг (үткен) пычак ирсә, үзе (үз) сабын юынмас», «Корук кашык агызка ярамас, корык (коры) сүз колакка якышмас» мәкальләренең мәгънәләрен, кулланыш очракларын аңлатыгыз, хәзерге телдәге төрдәшләрен әйтегез.
5. «Диван...»да нинди жанрдагы шигырьләр теркәлгән?
6. Мәхмүд Кашгарый китабындагы шигырьләрнең идея-тематикасы һәм әдәби үзенчәлекләре хакында сөйләгез.

«КОТАДГУ БЕЛЕК»

Үзенең идея-эстетик байлыгы, фәлсәфи тирәнлеге, рухи тормыштагы роле белән бу ядкяр дөнья әдәбиятында иң мөхтәрәм урыннарның берсен алып тора. Аның акыл-тәҗрибәне, хистойгыны туплаган һәр юлы, һәр бәете (икеюллык строфасы) афоризм, хикмәтле сүз кебек яңгырый. Һиндстанлыларда «Махабхарата», грекларда «Илиада» һәм «Одиссея», фарсыларда «Шаһнамә», гарәпләрдә «Мең дә бер кичә», славяннарда «Игорь полкы турында җыр», итальяннарда «Илаһи комедия» нинди роль уйнаса, «Котадгу белек»нең дә төркиләрнең рухи дөньясындагы роле шундый ук. Аны төркичә ядкярләрнең шаһы, авторын төрки әдипләрнең даһи остазы дип атарга мөмкин.

«Котадгу белек»нең ватаны — Караханилар дәүләте. Китапның авторы Йосыф шушы илнең Баласагун каласында (ул Чу елгасы үзәнлегендәге хәзерге Токмак шәһәре тирәсендә урнашкан була) якынча 1019 елда туа. Бик тирән, төпле белем ала. Аннан Караханилар дәүләтенең мөһим мәдәни һәм сәяси үзәге Кашгарга күчеп килә һәм үз әсәрен шунда, нигездә, 1069—1070 елларда иҗат итә. Автор «Котадгу белек»не Караханилар хөкемдары («илиге») Богра ханга (1056—1103 елларда идарә итә) багышлый. Моның өчен патша Йосыф Баласагунлыны үзенең «олуг хас-хаҗибы», ягъни сарай идарәсе башлыгы итә. Шуңа мөнәсәбәттә авторны кайчак Йосыф Хас-Хаҗиб дип тә йөртәләр. Әдипнең үлгән елы мәгълүм түгел.

«Котадгу белек» әүвәл гарәп язуында иҗат ителгән булса кирәк. Әмма аның уйгур әлифбасындагы нөсхәсе дә бар. Әсәрнең чагыштырмача борынгы өч кулъязмасы — Каһирә, Вена, Наманган нөсхәләре сакланган.

Әсәр атамасындагы «кот» һәм «белек» сүзләре берничә төрле мәгънә белдерә: белек — билиг — белем, китап, белем (акыл) тупламы, мәҗмуга; кот — бәхет, игелек, дәрәҗә, рух һ. б. Адгу — әдгү, изге, игелекле сүзләренең борынгы варианты. Шуңа мөнәсәбәттә ядкярнең исемен дә төрлечә аңлату бар: «Бәхет китабы», «Бәхет турында белем», «Игелекле итүче китап» һ. б. Шунысы кызыклы: «Котадгу белек» үз чорында ук күрше халыклар даирәсендә дә киң тарала.

Йосыф Баласагунлы әсәре — зур күләмле шигъри ядкяр. Ул, нигездә, үзара рифмалашучы икеюллык строфалардан төзелгән. Аларның саны 6722 гә җитә.

«Котадгу белек» — лиро-эпик характердагы поэма. Аның сюжеты түбәндәгедән гыйбарәт: Көнтугды исемле кодрәтле, гадел патша («илик») була. Ул үзенә хезмәткә, вәзир итеп, Айтулдыны чакыра. Алар, үзара киңәшеп, акыл, гаделлек белән идарә итәләр. Айтулды вафат булгач, патша аның улы Үгделмешне этисе урынына вәзир итеп ала. Егет, яшь булса да, Көнтугдыга игелекле киңәшләрен биреп тора. Үгделмешнең Узгырмыш исемле бик тә акыллы, зирәк, тыйнак карендәше була. Ул, кешеләрдән читләшеп, бар булганына канәгатьләнеп, үзе генә яши. Көнтугдының Узгырмышны да үзенә хезмәткә китертәсе килә. Әмма монысы риза түгел. Өч мәртәбә чакыргач, кат-кат үгетләгәч кенә, Узгырмыш сарайга килә, хөкемдарга киңәш-теләкләрен белдереп, торган җиренә кабат кайтып китә һәм бераздан вафат та була.

Әсәрнең сюжеты схематик характерда. Анда без вакыйгалар киеренкелеген дә, көтелмәгән борылыш-үзгәрешләрне дә, көчле конфликтны да күрмибез. Сюжетта чагыштырмача шартлылык, гадәттән тыш салмаклык хөкем сөрә. Автор исә төп игътибарын фикри якка, акыл-тәҗрибәне җиткерүгә, уй-кичерешләрне гәүдәләндерүгә юнәлтә. Сюжет исә — аның өчен куйган максатларына ирешүдә бер чара, бер сылтау гына.

Йосыф Баласагунлы турыдан-туры да, персонажлар әңгәмәсе аркылы да табигать һәм яшәешнең гаҗәеп күптөрле мәсьәләләре һәм төшенчәләре хакында үзенең уй-мөнәсәбәтләрен белдерә. Үзәктә, әлбәттә, идарәчелек проблемасы тора. Шагыйрь фикеренчә, илнең, халыкның нормаль яшәеше хөкемдарга

бәйле һәм шуңа нисбәтән ул Көнтугды образын әсәрнең төп каһарманы итеп ала да. Көнтугды —«кояш чыкты», «чыккан кояш» мәгънәсендә. Кояш, көн булганда, яшәеш, тереклек бар. Әсәрдә Көнтугды патша ныклы кануннары булган гадел дәүләт символы булып тора. Әмма дәүләт, аның кануннары «кот»лы, ягъни игелекле, бәхеткә юнәлтелгән булырга тиеш. Моны исә вәзир Айтулды («Тулган ай») гәүдәләндерә. Аның игелеге, кодрәте шул дәрәҗәдә булырга тиеш ки, хәтта ул, кояш юк чакта, тулган ай кебек, җирне яктыртып, кешеләргә юл күрсәтеп торырга бурычлы. Әмма нормаль идарә, бәхетле яшәеш өчен акылтәҗрибә, уяулык, канәгатьлек, зирәклек кебек сыйфатларның да булуы зарури. Боларны инде калган ике персонаж гәүдәләндерә: Үгделмеш — үгет элмеш, ягъни үгет-нәсыйхәт туплаган кеше, ул — акыл-зиһен, акыллылык символы; Узгырмыш —уздыручы, үткәрүче, уяулык. Бу зат,— кеше тормышының вакытлы булуын белеп, зирәклеккә, уяулыкка, саклыкка чакыручы.

Димәк, автор карашынча, гаделлек, дәүләт, игелек, акыл, зирәклек, сакчыллык кебек төшенчәләр чын идарәчелекнең нигезен тәшкил итәләр. Әмма бу сыйфатлар һәрберсе аерым гына яшәмиләр, алар бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә, мөнәсәбәттә. Аларны үзара ялгаучы төп үзәк — кеше, аның эшгамәле, рухи дөньясы. Шуңа күрә поэмада кешене тасвирлауга, кешелеклелек төшенчәләрен җырлауга гаять зур урын бирелгән. Белемле, укымышлы, гадел, киң күңелле, сабыр, тәрбияле, әхлаклы кеше — авторның идеалы. «Белем һәм акыл,— ди Йосыф Баласагунлы,— кеше итә; әгәр дә бу сыйфатлар юк икән, ул хайван мисалында». Икенче бер урында шагыйрь болай яза:

Кеше булу өчен, киң күңеллелек һәм кешелеклелек кирәк.

Автор персонажлар әңгәмәсе ярдәмендә белем, һөнәр, гаилә, мәхәббәт, аралашу һ. б. шундый төшенчәләрне төрле яктан яктырта. Еш кына уңай һәм тискәре сыйфатларны капма-каршы куеп тасвирлый. Мәсәлән:

Белемнең нәрсә икәнен белемле белер,
Надан ничек белсен белемнең кадрен?

Йосыф Баласагунлы эчүчелек, икейөзлелек, ялганчылык, комсызлык, әрсезлек, ялкаулык һәм башка шундый сыйфатларны аеруча кискен тәнкыйтьли, аларның «кешелеккә» дошман икәнлеген күрсәтә. «Кем шәраб эчә,— ди ул,— акылын җуеп, ахмакка әверелә. Андый кешедән бәхет тә, игелек тә кача» («Ничә килмәгү эш исерсә килер...»).

«Котадгу белек»тә без вәзир, гаскәр башлыгы, илче, шагыйрь, хәзинәче, галим, игенче, сәүдәгәр, һөнәрче, табиб (утачы) һәм җәмгыятьтәге кайбер башка һөнәр ияләренә куелган әхлакый таләпләр белән дә очрашабыз. «Игенчеләр,— ди автор,— иң файдалы кешеләр. Чөнки алар бөтен җан иясен туендыралар. Шуңа күрә аларга хөрмәт белән карарга кирәк». Шунысы кызык: Йосыф Баласагунлыдагы бу мотив XVII йөз шагыйре Мәүла Колый иҗатында да дәвам ителә. Анда иген игүчеләр иң изге, иң саваплы кешеләр рәвешендә тасвирлана.

Йосыф Баласагунлы шагыйрьләрне, диңгез төбенә чумып, энҗе чыгаручылар белән тиңли. Сәүдәгәрләр исә кешеләрне бөтен кирәк-яраклар белән тәэмин итә. Ә инде галәмдәге бөтен искиткеч әйберләр — һөнәрчеләрнең иҗат җимешләре.

Авторның галәм, тереклек, яшәү һәм үлем хакында уйланулары да кызыклы. Аның фикеренчә, галәм, тормыш һәрвакыт хәрәкәттә, үзгәрештә.

Аккан су, йөгерек тел, бу кот туктамас,
Бар дөнья әйләнеп, йөреп тынмас.

Әмма кеше гомере чикләнгән. «Син,— ди шагыйрь,— бу дөньяда юлчы гына. Син баймы, ярлымы,— үлем өчен моның әһәмияте юк, чөнки кабердә барлык кешеләр дә үзара тиң».

Авторның аеруча үткән яшьлеген сагынып язган юллары көчле. «Мин,— ди ул,— ук кебек төз идем, хәзер җәя кебек бөгелдем, чәчләрем аккош төсе кебек агарды».

Әсәрнең үзенчәлекле төзелеше (сорау-җавап формасы, лирик чигенешләр, фәлсәфи уйланулар, үлем васыятьләре һ. б.) анда куелган мәсьәләләрне төрле яктан, кат-кат, тирәнтен яктыртырга мөмкинлек биргән. Поэманың интонациясендә шатлык-тантана да, моң-сагыш та, үкенеч-теләк аһәңнәре дә бар.

«Котадгу белек» төрле образларга, сурәтләү алымнарына һәм тасвир чараларына гаять бай. Автор вакыт, гомер агышын искән җил, аккан су белән чагыштырырга ярата: «Тереклек тәдекең бу йил тәг кәчәр» («Тереклек дигәнең бу җил кебек кичәр»). Күңелне диңгез белән тиңләү дә очрый:

Кеше күңле төбсез тиңиз тәг торыр,
Белек энҗү сани (кебек) төбиндә ятыр.

Йосыф Баласагунлы әсәре үзенең идея-мотивлары һәм поэтикасы белән шактый дәрәҗәдә борынгы рун язмалары, Мәхмүд Кашгарый китабындагы әдәби текстлар белән керешеп китә. Үлемне җан кошының очуы рәвешендә күзаллау,

социаль килешүне сарык (куй) белән бүре дуслыгы аркылы бирү, уяулыкны барс, куәтне бүре белән чагыштыру һ. б.— әнә шундыйлардан.

Поэмада, гомумән, гарәп, фарсы, төрки әдәбиятларга хас сурәтләр һәм мотивлар да очрый. Айтулдының Көнтугдыга язган васыятендә халык — сарык, ә патша көтүче белән чагыштырыла. Бу сурәт фарсы-азәрбайҗан шагыйре Низамида да, төрки-татар әдибе Сәйф Сараида да бар.

«Котадгу белек» үзенең табигате, эчтәлеге белән тормыш дәреслеге кебек. Анда, төрки һәм кайбер башка халыкларның рухи мирасына нигезләнеп, яшәеш тәҗрибәсе гәүдәләндерелә, укучыларга әхлакый сабак бирелә. Поэма — әдәбият тарихы өчен генә түгел, ә борынгы төркиләрнең фәлсәфи һәм педагогик карашларын, тормыш-көнкүрешен, җәмгыять төзелешен, телен өйрәнүдә дә мөһим чыганак. Ул үзеннән соңгы төрки укучыларга, төрки әдәбиятларга гаять көчле йогынты ясады. Моны без татар дөньясына мөнәсәбәттә дә ачык күрәбез.

«Котадгу белек» татар укучылары һәм укымышлылары тарафыннан укылган, өйрәнелгән. Әсәрнең Каһирә кульъязмасы заманында Идел-Урал буйларыннан Мисырга китерелгән.

Йосыф Баласагунлы поэмасында мондый бәет бар:

Үкеш (акыл.—*Х. М.*) күрке — тел ул,
бу тел күрке — сүз,
Кеше күрке — йөз ул, бу йөз күрке — күз.

1909 елда Җаек буендагы Сарайчык төбәгендә Алтын Урда чорыннан калган бер чүлмәк табыла. Анда мондый юллар язылган:

Кеше күрке — йөз ул, бу йөз күрке — күз,
Бу үз (барлыкның.— *Х. М.*) күрке — тел ул,
бу тел күрке — сүз.

Күрәсез, ике текст арасында аерма бик аз. Чүлмәктәге бәетнең «Котадгу белек»кә мөнәсәбәтле булуы һич бәхәс тудырмый. Йосыф Баласагунлы әсәрендәге юлларның көнкүреш әйберләренә дә язылуы — поэманың халыкта шактый киң таралуын күрсәтүче янә бер дәлил.

«Котадгу белек»нең идея-мотивлары, поэтикасы, теле татар әдәбиятының нигезендә ята, әдипләребез тарафыннан иркен файдаланыла, үстерелә. Берничә мисал гына китереп үтик.

Кол Гали, нәкъ үз остазы Йосыф Баласагунлы кебек, төш күрү, төш юрау алымнарыннан иркен файдалана, сабыр-

лык, гыйлем-мәгърифәт, әхлаклылык кебек төшенчәләрне кеше идеалының мөһим өлеше итеп карый. Мәхмүд Болгари (XIV йөз) өчен дә әчүчелек — бөтен начарлыкның нигезе, башы. Котбның «Хөсрәү вә Ширин» (1342) һәм Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан» (1369) әсәрләрендә «Котадгу белек»кә аваздаш, охшаш яклар гаять күп. Йосыф Баласагунлы, сугышчыны тасвирлаганда, «арыслан йөрәк» сурәтен куллана. XIV йөз шагыйре Харәзми дә үз каһарманының батырлыгын шушы ук метафора ярдәмендә бирә.

Көнтугды — Айтулды әңгәмәләренең берсендә мондый фикер әйтелә:

> Бу бәгләр ут ул, утка барма ягук (якын.— *Х. М.*).
> Кали бардың әрсә, көермәк анук.
> (Әгәр дә барсаң, шунда ук көяргә мөмкинсең.)

Шундый ук мотив Сәйф Сараиның «Гөлестан бит-төрки» (1391) әсәрендә дә бар. Йосыф Баласагунлы кебек, Сәйф Сараи да үз укучыларын, «игү» эш-гамәлләр кылып, дөньяда «игү ат» (исем) калдырырга, үзеңне мәңгелек тормыш белән тәэмин итәргә чакыра.

Сүз сөйләү, әңгәмә кору хакында фикер йөртеп, Йосыф Баласагунлы болай ди:

> Күңел, телеңне дөрес (ихлас) тот, холкың да бөтен булыр,
> Һәм сиңа килер бәхет (байлык), дөньяң да бөтен булыр.

Икенче бер урында шагыйрь: «Барлык нәрсә телдән: ул кешене күтәрә дә, аның башына да җитә»,— ди.

Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасында да (1542) «күни» (дөрес), тугры сүзне бөтен нәрсәнең нигезе итеп карау бар.

«Котадгу белек»тә: «Белем — зур байлык, аның хәтта өлешен дә бернинди оста карак та урлый алмый»,— дигән юллар язылган. Утыз Имәни өчен дә «данәш», ягъни белем, гыйлем —кешенең иң зур хәзинәсе, «гәүһәре»:

> Адәминең гәүһәре данәш улыр,
> Аны нә дошман вә нә угрый алыр.

Кыскасы, татар әдәбиятында «Котадгу белек»кә мөнәсәбәтле, аңа аваздаш яклар гаять күп. Бу исә очраклы хәл түгел. Чөнки Йосыф Баласагунлы әсәре, гәрчә ул Идел-йорттан еракта иҗат ителсә дә, татар халкын инде менә мең елга якын азыкландырып, тәрбияләп килә, аның авторы татар әдипләренең даһи аксакалы булып тора. Татар фольклорында да «Котадгу белек»тән алынган хикмәтле сүзләр, мәкальләр шактый.

Сораулар һәм биремнәр

1. Караханилар дәүләте нинди мәмләкәт ул? Кашгар, Баласагун шәһәрләре кайда урнашкан?

2. Ни өчен автор үзен Баласагунлы, Хас-Хаҗиб кушаматлары белән йөрткән?

3. «Котадгу белек» нинди мәгънәләр белдерә?

4. Поэманың сюжеты хакында сөйләгез.

5. Ни өчен автор үз персонажларына Көнтугды, Айтулды, Үгделмеш, Узгырмыш исемнәрен биргән?

6. «Котадгу белек»тә нинди мәсьәләләр гәүдәләнеш тапкан?

7. Әсәрнең тел-сурәтләү чаралары хакында сөйләгез.

8. «Котадгу белек»нең татар әдәбиятындагы традицияләре нәрсәләрдә күренә?

ӘХМӘД ЙҮГНӘКИ

Йосыф Баласагунлының шигъри традицияләрен гомумтөрки әдәбиятта турыдан-туры дәвам иттерүчеләрнең иң күренеклесе — Әхмәд Йүгнәки. Аның яшәгән еллары төгәл билгеле түгел. Шагыйрьнең гомерен якынча XII гасырга нисбәт итәләр. XIX йөз әдибе Шәмседдин Зәки кебек, ул да тумыштан сукыр була. Шагыйрьнең туган җире — Урта Азиядәге Йүгнәк төбәге.

Әдипнең хәзерге укучыларга бары бер әсәре генә мәгълүм. Ул «Һибәтел-хәкаик», ягъни «Хакыйкать бүләге» («Хаклыклар бүләге») дип йөртелә. Поэма жанрындагы бу язма истәлек гарәп һәм уйгур язуларындагы күчермәләрдә килеп җиткән.

Поэма (ул 500 тирәсе шигъри юлдан тора), нәкъ «Котадгу белек» кебек үк, традицион багышлаулардан, төп өлештән һәм бетемнән гыйбарәт. Авторниндидер Дад Сипаһсалар (Испаһсалар) дигән бәккә мәдхия укый. «Аның юмартлыгы,— ди ул,— диңгездән дә мең мәртәбә артыграк» («Диңгиздин кәримрәк шаһым мең ката»).

Китапны күчерүчеләрнең берсе әсәрнең 14 бүлектән торганлыгын искәртә. Әмма безгә мәгълүм кульязмаларда аның 7 бүлеге генә бар:

Беренче бүлек — белемнең файдасы һәм наданлыкның зыяны турында.

Дүртенче бүлек — юмартлыкның файдасы һәм саранлыкның зыяны турында һ. б.

Бүлек атамалары ук әсәрнең әхлакый-дидактик характерда булуын күрсәтеп тора. Автор, Йосыф Баласагунлы кебек үк, үз укучысына һәм тыңлаучысына образлы формада киңәш, үгет-нәсыйхәт бирү юлын сайлаган. Арага пәйгамбәр сүзләрен дә кертеп җибәрә.

Әхмәт Йүгнәки фикеренчә, белемлелек — кешене кеше итүче, тормышны алга алып баручы иң мөһим сыйфатларның берсе. Шуңа күрә аның күп юллары да «белек», белемлелек турында:

Белек берлә беленер сәгадәт юлы,
Белек, бел, сәгадәт йолыны була...
(Белек белән беленер бәхет юлы,
Белек, бел, бәхетнең үзәге була.)

Бәһалек динар ул белеклек кеше,
Бу җаһил белексез бәһасез бише...
(Кыйммәтле алтын акча кебек, ул белемле кеше,
Бу надан кешенең бишесе бер тиен тормый.)

Белекле ир үлде, аты үлмәде,
Белексез исән иркән аты үлек...
(Белекле кеше үлде, исеме үлмәде,
Белексезнең, исән чакта да, исеме үле.)

Шагыйрь белемсез кешене җилексез сөяк белән тиңли: «Белексез йилексез сүңәк тик хали (буш)». Белемле кеше эшнең асылын белеп башкара, ә надан, уйламыйча эшләп, ахырда үкенә. Белексез кеше хак сүзне, үгет-нәсыйхәтне кабул итүгә сәләтсез.

Әхмәд Йүгнәки кешегә мөнәсәбәтле башка сыйфатлар хакында да кызыклы гына фикерләр әйтә. Акылны ул кешенең күрке дип саный («Ирән күрке акыл ул...»). Ә инде «кәрәм», ягъни киң күңеллелек кешене кеше итә («Кәрәм кемдә булса, аны ир дигел»); бу сыйфаттан мәхрүм кеше җимешсез агач кебек. Шагыйрь «кәрәмлелек» төшенчәсенә ачыклык та кертә. Аның карашынча, киң күңеллелек ул — олыларны олылау, кечеләрне кечеләү, хәрам мал җыймау, игелекле гамәлләр кылу, шәфкатьле булу, гөнаһлыларның гөнаһын кичерү («Языклы кешенең языгын кичер»).

Әхмәд Йүгнәки өчен бу дөньяда иң кыйммәт, иң газиз нәрсә — кеше, кешелек («Бу көн бу ажунда кешелек газиз»). Шуңа күрә ул үз укучысын кешеләргә игътибарлы, юмарт булырга («Яраглык ашыңны кешегә йийдыр»), бәла-каза («көч-имгәк») китермәскә чакыра, игелекле эшләр генә кылырга өнди.

Бер урында шагыйрь болай ди: «Борын башка бүркне кияр баш кирәк», ягъни Бүрекне кияр өчен әүвәл баш кирәк». Димәк, баш (кеше) — беренчел, ә мал — икенчел. Шуңа күрә автор дөнья малы («ажун тавары») белән мавыкмаска, холкыңны («кылыкны») тәрбияләргә, игү гамәл кылырга чакыра.

Йосыф Баласагунлы кебек үк, «Һибәтел-хәкаик» авторы да сөйләшә белүне, «күни» (тугры, дөрес) сүзне «әдәпнең башы», кешелеклелекнең нигезе дип саный. Әхмәд Йүгнәки фикеренчә, кешегә ялган сүз — чир, ә «күни» (дөрес) сүз — шифа.

Антитезалы фикерләү — шагыйрь кулланган төп әдәби алымнарның берсе. Автор еш кына белемлелекне наданлык, дөреслекне ялган, тыйнаклыкны тәкәбберлек, юмартлыкны саранлык белән янәшә куеп тасвирлый. Шуның нәтиҗәсендә бу төр төшенчәләрнең асылы, әхлакый роле ныграк ачыла.

Үз элгәрләре кебек үк, «Һибәтел-хәкаик» авторы да тормыш агышын искән җил («кичәр йил») белән чагыштыра, дөнья матурлыгын тыштан «йомшак», эчтән агулы елан белән тиңли: «Ажун,— ди ул,— әле татлы («шәһд»), әле агулы («зәһәр») эчемлек тоттыра».

Үзенә кадәрге фольклор һәм әдәби традицияләрне уңышлы дәвам иттергән, үстергән «Һибәтел-хәкаик» үзеннән соңгы мәдәнияткә дә билгеле бер йогынты ясады. Аңа авазлаш мотивларны, сурәтләрне без татар әдәбиятында да күпләп очрата алабыз. Берничә мисал гына китереп үтик.

Әхмәд Йүгнәки:

...Мең ир дустың ирсә, үкеш (күп) күрмәгел,
Бер ир дошман ирсә, аны азлама (аз димә).

Котб (XIV йөз):

Мең ирсә дустларың һәм аз тиеп бел,
Бер ирсә дошманың, андин сакынгыл (саклан).

Әхмәд Йүгнәки:

Йимешсез агач диг кәрәмсез кеше.

Сәйф Сараи (XIV йөз):

Агач күрке — йимеш, ирнең — кәрәмдер.

Әхмәд Йүгнәкидә «Дөнья, пәрдәсен (пәрәнҗәсен) күтәреп, күзен ачар» дигән сынландыру бар. Шушыңа охшаш сурәт XIV йөз шагыйре Харәзмидә дә очрый.

«Һибәтел-хәкаик» авторы бу дөньяда берәүнең дә мәңгелек түгеллеге хакында яза. Кеше гомеренең чикләнгәнлеге, фанилыгы хакындагы мотив Хисам Кятиб, Өмми Кәмал, Дәрдемәнд һәм кайбер башка татар шагыйрьләре тарафыннан да эшкәртелә.

Әхмәд Йүгнәкинең максаты — игелекле эш-гамәлләр, «күркәм холык», яхшы исем («игү ат») белән кешелек хәтеренә кереп калу. Аның бу омтылышы үзеннән соңгы күп кенә әдипләрнең дә иҗат девизы булды.

Сораулар һәм биремнәр

1. Әхмәд Йүгнәки хакында нәрсәләр мәгълүм?
2. «Һибәтел-хәкаик» әсәренең төзелеше турында сөйләгез.
3. Авторның «белек» хакындагы юлларын укыгыз, мәгънәләрен аңлатыгыз.
4. «Кәрәм» нәрсә ул? Шагыйрь бу төшенчәне ничек аңлата?
5. Әхмәд Йүгнәки кешелеклелек, «тел», «куни сүз» турында ничек фикер йөртә?
6. Йосыф Баласагунлы һәм Әхмәд Йүгнәки әсәрләре кайсы яклары белән үзара охшаш?
7. «Һибәтел-хәкаик» поэмасының татар әдәбиятындагы традицияләре нәрсәләрдә күзәтелә?

ӘХМӘД ЯСӘВИ ҺӘМ СӨЛӘЙМАН БАКЫРГАНЫЙ

«Диване лөгатет-төрк», «Котадгу белек», «Һибәтел-хәкаик» кебек борынгы истәлекләрдән тыш, гомумтөрки әдәбиятта башка ядкярләр дә бар. Алар бигрәк тә XII йөзләрдә күбәеп китә. Бу төр истәлекләрдә, бер яктан, элеккеге төрки фольклор һәм язма әдәбият традицияләре дәвам иттерелсә, икенче яктан, аларда гарәп-фарсы мәдәни йогынтысы, ислам дине тәэсире нык сизелә.

Әхмәд Ясәви һәм Сөләйман Бакырганый иҗатлары гомумтөрки әдәби мирасында мөһим урынны алып тора. Аларның һәр икесе дә XII йөздә Урта Азиядә иҗат иткән.

Әхмәд Ясәви (Хуҗа Әхмәд, Кол Әхмәд) XI гасырның икенче яртысында Яса (Яссый — хәзерге Төркестан каласы) дигән төбәктә туган. Аның әтисе — шәех Ибраһим Мәхмүд углы — иртә үлеп китә. Булачак әдип Арслан-баб дигән кешедә тәрбияләнә. Бохарада бөтен мөселман дөньясының мәшһүр шәхесе, рухание Йосыф Хамаданиның шәкерте була. Остазы үлгәч, аның урынына шәех, ягъни суфилар башлыгы булып кала. Изгелеге, таланты, кылган эш-гамәлләре белән Әхмәд Ясәви исән вакытта ук үз чорының атаклы кешесенә әверелә. Үлгәч исә (ул 1166 елда вафат була) аның популярлыгы тагын да арта; күп санлы легенда-риваятьләр туу, әдәби һәм гыйльми әсәрләр язылу — шуның ачык билгесе. Әдипнең кабере изге урынга әйләнә. Аның өстенә Ак-

сак Тимернең зур корылма төзетүе дә мәгълүм. Еш кына «Мәдинәдә — Мөхәммәд, Төркестанда — Хуҗа Әхмәд» дип йөрткәннәр һәм Әхмәд Ясәви каберенә зиярәт кылуны ярым хаҗга бару белән тиңләгәннәр.

Шагыйрь әдәбиятта, барыннан да элек, үзенең шигырьләр тупламы —«Диване хикмәт» белән мәшһүр. Казан басмаларында аның күләме 300 биткә якын. Җыентыкта төрле зурлыктагы 135 шигъри әсәр бар. Алар, нигездә, строфа ахырындагы рифмаларның соңгы хәрефләренә карап, әлифба тәртибендә (а, б...) урнаштырылганнар.

Сөләйман Бакырганый (Кол Сөләйман) — Әхмәд Ясәвинең шәкерте. Остазы кебек үк, ул да— төрки дөньяның мәшһүр кешесе. Гомеренең зур өлешен Харәземдәге Бакырган төбәгендә уздыра һәм 1186 елда шунда ук вафат та була. Шагыйрь әсәрләренең бер өлеше «Бакырган китабы» дип исемләнгән җыентыкта тупланган. Антология, хрестоматия рәвешендә төзелгән бу китап татар мәктәп-мәдрәсәләрендә уку-укыту вазифасын башкара.

Әхмәд Ясәви һәм Сөләйман Бакырганый шигырьләре идея-тематик һәм поэтик яктан үзара аваздаш һәм охшаш. Алар дини-суфичыл характерда. Кеше һәм Алла мөнәсәбәте бу шигырьләрнең үзәгендә тора. Авторлар фикеренчә, бөтен нәрсәне Алла яраткан, бөтен нәрсә илаһи затка бәйле, кеше — бу дөньяда кунак кына. Шуңа күрә адәм баласы дөнья малына, таҗ-тәхеткә кызыкмаска, кешеләрне рәнҗетмәскә, күңелен пакьләргә, игелекле эш-гамәлләр кылырга, җан ияләренә шәфкатьле булырга, Алла турында гына уйлап яшәргә бурычлы. «Дөнья өчен гамь йийма, Хакъдин үзгәне димә, кеше малыны йийма...»— ди Әхмәд Ясәви.

Һәр ике автор да үз укучыларын гөнаһлардан арынырга, тәүбә кылырга чакыра.

Алланы бөтен нәрсәдән өстен кую, аңа күңел баглау, буйсыну, гыйшык-мәхәббәт тоту һәм ахырда илаһи зат белән кушылу Урта гасыр мөселман дөньясында киң таралган суфичылык тәгълиматының асылын тәшкил итә. Шуңа нисбәтән Ясәви һәм Бакырганый шигырьләрендә дә илаһи мәхәббәт темасын яктыртуга зур урын бирелә:

Бу дөньядин кем кичкәй, арада гыйшык булмаса,
Оҗмах капугын (капкасын.—*Х. М.*) кем ачкай,
арада гыйшык булмаса?!

(Бакырганый)

Сәнең дәрдең бәңа дәрмандин артык,
Сәңа кол булгам (булганым.— *Х. М.*) — солтандин артык.

Сәнең ядыңны әйсәм чүл эчендә,
Булыр ул чүл мәңа бостандан (гөлбакчадан.— *Х. М.*) артык...

(Бакырганый)

Әхмәд Ясәви бер хикмәтендә Ләйлә — Мәҗнүн, Фәрһад — Ширин кебек гашыйк булырга чакыра. «Чөнки,— ди ул,— гашыйк булмай Хәкъ дидарын күрсә булмас» («Гашыйк булмыйча, Алланы күреп булмый»). Авторлар илаһи мәхәббәт юлындагы җәбер-җәфаларга, кыенлыкларга түзәргә, сабыр итәргә өндиләр.

Сорау туа: ни сәбәпле соң Ясәви һәм Бакырганый әсәрләре озак гасырлар буе төрки дөньяда популяр була? Әлбәттә, моның сәбәпләре күп. Дини-суфичыл эчтәлек мөселман төркиләренең рухи ихтыяҗларына җавап биргән. Бу — бер. Әмма икенчесе һәм иң мөһиме шул: авторлар дини-суфичыл төшенчәләрне әхлакый кагыйдәләр, гуманистик мәсьәләләр белән тыгыз, табигый бәйләнештә карыйлар. Шул сәбәпле шигырьләрдә мөхтәрәм урынны кеше, аның рухи халәте, тышкы дөнья белән мөнәсәбәте ала. Әсәрләренең каһарманнары, лирик геройлары өчен ихласлылык, шәфкатьлелек, ярдәмчеллек, сабырлык хас. Нәфескә бирелү, гафиллек, гамьсезлек, наданлык — алар өчен дошман сыйфатлар. Ясәви дә, Бакырганый да үз укучыларын гарипләргә һәм фәкыйрьләргә, кыен хәлдә калучыларга ярдәм кулын сузарга чакыралар, бу эштә үрнәк итеп Мөхәммәд пәйгамбәрне күрсәтәләр.

«Диване хикмәт» һәм «Бакырган китабы»ндагы күп кенә шигырьләрдә Алла гаделлек, игелек, хакыйкать идеалы, өлгесе рәвешендә карала, һәм кешенең һәр уй-кичереше, һәр эшгамәле шул идеалга, өлгегә мөнәсәбәттә яктыртыла, бәяләнә.

Ясәви һәм Бакырганыйның Аллага мәхәббәтне күздә тотып язган күп кенә шигъри юллары билгеле бер дәрәҗәдә кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне дә белдерә.

Ясәви:

Гашыйк булсаң, гашыйк юлыга куйгыл кадәм (табан.— *Х. М.*).

* * *

Мәхәббәтне(ң) бостанында һәзар (мең.— *Х. М.*) дастан,
Былбыллары сайрар анда, әфган (аһ-зар.— *Х. М.*) кыйлыр.

Бакырганый:

Сәнең ядың әгәр китсә телемдин,
Вөҗүдем корыйур вәйрандин артык...
(Яшәешем корыр җимеректән дә артык.)

Ясәви һәм Бакырганый әсәрләренең халыкта яратып укылу сәбәпләренең янә берсе — аларның поэтик үзенчәлекләрендә, тел һәм стиль, форма ягыннан шактый үтемле, аңлаешлы булуларында. Авторларның күпчелек шигырьләре төрки фольклорга һәм язма әдәбиятка хас булган дүртьюллык строфалар белән иҗат ителгән. Бер өлеше икеюллык строфалардан — бәетләрдән гыйбарәт. Хуҗа Әхмәд Ясәви рифмалашуның *аааб* формасын аеруча яратып куллана. Еш кына строфаларның соңгы юлы кабатланып та килә. Шигырь юллары ахырында бер үк сүзләрне куллану да күзгә еш ташлана.

«Диване хикмәт»тә һәм «Бакырган китабы»нда юлбаш анафоралар (ягъни бер үк сүзләрне кабатлаулар) да очрый. Строфаларда һәм, гомумән, әсәрләрдә бер үк сүзләрнең эзлекле кабатлануы шигырьләрнең интонацион яңгырашын, нәфислеген көчәйтә.

Ясәви һәм Бакырганый шигъри сөйләмнәрен, нигездә, беренче заттан алып баралар, үзләре яктырткан мәсьәләләрне үз шәхесләренә бәйлиләр һәм ахыргы строфада үз кушаматларын, исемнәрен телгә алалар. Нәкъ шушындый ук күренеш XVII йөз шагыйре Мәүла Колый хикмәтләрендә дә күзәтелә.

Йосыф Баласагунлы, Әхмәд Йүгнәки кебек, «Диване хикмәт» һәм «Бакырган китабы» авторлары да укучыга, тыңлаучыга эндәш, мөрәҗәгать формасын яратып кулланалар, узган гомерне искән җил белән чагыштыралар («гомерең йил дик үтәр», «Гафиллекдин гомерен йилгә сатар булгай»). Ясәви күз яшен болак, ягъни елга белән тиңли («Болак яңлигъ акар күзем яше»). Бакырганый дөнья тормышын вафасызлыкта, ышанычсызлыкта гаепли:

Кемгә вафа кылды бу фани дөнья,
Безгә тәкый сезгә вафа кылгучы юк.

Ясәви һәм Бакырганый шәхесләре Октябрьгә кадәрге күп гасырлык татар тормышында иң мөхтәрәм, иң изге затлардан хисаплана. Идел-Урал буйларында аларның күп санлы иярченнәре булуы да мәгълүм. Ә инде бу авторларның әсәрләре әүвәл кульязма, XIX йөздән басма рәвештә татарлар арасында гаять киң тарала, татар уку йортларында ныклап өйрәнелә.

Әхмәд Ясәви һәм Сөләйман Бакырганый иҗатлары күп гасырлар буена татар әдәбиятын да тукландырып килде. Өмми Кәмал, Колшәриф, Мәүла Колый, Шәмседдин Зәки аларны үзләренең шигъри остазлары дип санадылар. Татар

әдәбиятында Ясәви һәм Бакырганый иҗатларына охшаш, аваздаш якларны билгеләү һич тә кыенлык сорамый. «Бакырган китабы»на Казан шагыйре Колшәриф әсәрләренең кертелүе үзе генә дә бу ике әдип арасындагы эчке якынлыкка ишарә ясый.

Ясәви «Дуслар...» исемле бер хикмәтендә үзен шәм («шәмгъ») янында очып йөрүче күбәләк («пәрванә») һәм, дәрьяга чумып, «мәгърифәт гәүһәрен» чыгаручы «гаувас» (водолаз) белән тиңли. Фарсы суфичылык әдәбияты белән бәйләнешле бу символик сурәтләр Ясәвидән соң да төрки-татар әдәбиятында иркен кулланылдылар. Илаһи мәхәббәтне белдерүче пәрванә һәм шәмгъ сурәтләре, мәсәлән, дөньяви эчтәлек алып, Тукай шигырьләренә дә үтеп кергән («Гашыйкмы соң бу!..», «Иһтида» һ. б.).

Габдулла Тукай Ясәви һәм Бакырганый әсәрләрен яхшы белгән, аларның поэтик казанышларын, аеруча строфа формаларын үз язмаларында иркен һәм иҗади файдаланган. «Бакырган китабы»нда «...мән егламай кем егласын» рәдифле шигырь бар. Анда, гомер узып, картлык, үлем җитү кайгысы тасвирлана («үтте егетлек куввәте, йитде карыйлык нәүбәте...»). Тукай да «Хатирәи Бакырган» шигырендә Сөләйман Бакырганыйның әдәби формасын файдалана. Әмма ул бу традицион формага үз чорының реаль эчтәлеген сала. Бозык бай балаларыннан көлеп, шагыйрь болай яза:

Кулда бильяр, карталары,
Эчеп сыра, тарта бары:
Бетрү йиңел ата малы,—
Бән егъламай, кем егъласын.

* * *

Күргәнебезчә, инде XIII йөзләргә кадәр үк, ягъни хәзерге татар, төрек, үзбәк, уйгур, азәрбайҗан һәм кайбер башка төрки кавемнәр халык буларак формалашканчы, төрки телдә язма әдәбият зур үсеш ала. Аның өчен идея-тематик байлык, гуманистик эчтәлек, поэтик яктан шактый камиллек, жанр төрлелеге, фольклор белән тыгыз бәйләнеш хас. Рун, уйгур, гарәп язуларында иҗат ителгән борынгы төрки истәлекләрдә кеше тормышының һәм рухи дөньясының, иҗтимагый яшәешнең күптөрле мәсьәләләре гәүдәләнеш тапкан. Алар аркылы без әби-бабаларыбызның уй-кичерешләрен, гореф-гадәтләрен, тарихларын да билгеле бер дәрәҗәдә күз алдына китерә алабыз.

Борынгы төрки телдәге әдәбият хәзерге күп кенә төрки халыкларның уртак мирасы булып тора. Ул,— фольклор белән берлектә, татар әдәбиятының да нигезе, төп чыганагы. Чөнки аны тудыруда, үстерүдә, таратуда безнең әби-бабайлар да катнашкан. Татар язма әдәби теле — борынгы төрки әдәби теленең яңа тарихи шартларда турыдан-туры дәвам иттерелеше ул. Борынгы рун истәлекләрендәге, Кашгарый, Баласагунлы, Йүгнәки, Ясәви, Бакырганый китапларындагы сәнгати һәм фикри казанышлар традициясе татар әдәбияты тарихында буйдан-буйга күзәтелә.

Төркиләрнең региональ, милли әдәбиятлары формалаша, үсә башлагач та, үзара керешүләр, уртаклыклар билгеле бер дәрәҗәдә дәвам итә. Мәсәлән, Алтын Урда чорының Рабгузый, Харәзми кебек каләм әһелләре татарларның да, үзбәкләрнең дә уртак әдипләре хисаплана.

Сораулар һәм биремнәр

1. Әхмәд Ясәвинең тәрҗемәи хәлен сөйләгез.
2. Ясәви һәм Бакырганый әсәрләренең идея-тематикасы нәрсәдән гыйбарәт?
3. «Илаһи мәхәббәт» төшенчәсен ничек аңлыйсыз?
4. Ясәви һәм Бакырганый шигырьләренең поэтик үзенчәлекләре (строфа төзелеше, рифмалашу, тел-сурәтләү чаралары һ. б.).
5. Хикмәт нәрсә ул? «Әдәбият белеме сүзлеге»ннән файдаланып, бу сорауга җавап бирегез.
6. Ни өчен Ясәви һәм Бакырганый әсәрләре халыкта популяр булган?
7. «Диване хикмәт» һәм «Бакырган китабы»ның татар әдәбиятында дәвам иткән традицияләре турында сөйләгез.

ШӘРЫК КЛАССИКАСЫ

Фольклордан, борынгы гомумтөрки әдәбияттан тыш, татар әдәбиятының башка чыганаклары, үзгә тамырлары да булган. Шуларның иң мөһиме — Шәрык классикасы һәм аның төп ядкяре — Коръән. Алар, турыдан-туры укылудан тыш, татар әдәбиятының формалашуына һәм үсешенә дә бик зур йогынты ясаганнар.

Шәрык — Көнчыгыш дигән сүз. Әмма татар телендә аның традицион мәгънәсе дә бар. Гадәттә, Шәрык атамасын мөселман Көнчыгышына карата кулланалар. Ә бу регион исә, нигездә, Урта һәм Кече Азия, Якын Көнчыгыш илләрен һәм халыкларын үз эченә ала. Гарәпләр, фарсы һәм төркиләр бу регионның төп халкын тәшкил итә.

Шәрык төбәге — элек-электән дөнья мәдәниятенең төп үзәкләреннән берсе. Анда берничә мең еллар элек үк инде төрле язуларның, әдәби истәлекләрнең, гыйльми хезмәтләрнең тууы мәгълүм.

VII гасырдан, ислам диненең барлыкка килүенә һәм таралуына нисбәтән, Шәрык дөньясында яңа этап, яңа чор башлана. Халыкларның дөньяга карашларында, гореф-гадәтләрендә, мәдәниятләрендә тирән үзгәрешләр туа. Иҗтимагый тормыш, идеология, кеше фикерләве, сәнгать бер аллачылык идеясе, Мөхәммәд пәйгамбәр карашлары, Коръән белән яраклаштырыла.

Шәрык рухи культурасы элек тә, ислам чорында да Көнчыгыш (Кытай, Һиндстан...) һәм Көнбатыш (Греция, Византия...) мәдәни казанышларының табигый кушылмасы, синтезы рәвешендә үсә. Моңа аның географик урыны, икътисади һәм сәяси мөнәсәбәтләре, этник, дини составы уңай йогынты ясады. Антик Грециянең, Борынгы Һиндстанның күп кенә ядкярләре, мәсәлән, дөнья укучыларына гарәп-фарсы телләре аша ирешә. Болар арасында Аристотель, Платон (Әфләтүн) хезмәтләре, «Панчатантра» («Кәлилә вә Димнә»), «Шукасаптати» («Тутыйнамә») һәм башка мәшһүр истәлекләр бар.

Мәгълүм булганча, Борынгы һәм Урта гасырларда латин Европаның халыкара теле, дин, фән, мәдәният теле рәвешендә киң кулланыла. Мөселман дөньясында исә гарәп теле шундый вазифаны башкара.

Урта гасырларда гарәп әдәбияты, фәне, сәнгате, матди культурасы гаять зур үсеш ала. Әбү-Нүвас (762—813), әл-Мөтәнәбби (915—965), әл-Мәгарри (973—1057/58) шигырьләре, мәсәлән, уй-кичерешләргә байлыгы, сәнгати нәфислеге белән бүгенге укучыларны да сокландыра. Гарәп фольклор һәм язма әдәбиятының кушылмасы булган күп томлы «Мең дә бер кичә» — бөтен дөньяга мәшһүр ядкяр.

X—XV йөзләрдә мөселман дөньясының фарсы төбәге бик нык үсеп китә. Хәзерге иранлыларның, таҗикларның, афганлыларның әби-бабалары, гарәп рухи казанышларыннан иҗади файдаланып, бай мәдәни мирас тудыралар. Шунысын да истә тотыйк: бу мирасны үстерүгә, фарсы телле халыклар белән бергә, аерым төрки вәкилләр дә үзләреннән билгеле бер өлеш кертәләр. Мәсәлән, үзбәк классик әдәбиятының олуг әдибе Галишир Нәваиның (1441—1501) күп кенә әсәрләре фарсы телендә. Азәрбайҗан җирлеге шагыйре Низами исә (1141—1209), гомумән, фарсыча гына язган. Фарсы телле әдәбият Урта

гасырларда Һиндстан ярымутравында да билгеле бер дәрәҗәдә тарала, үсә. «Һиндстан былбылы» дип йөртелгән атаклы шагыйрь Әмир Хөсрәү Дәһләви (1253—1325) үзенең үлемсез «Биш поэма»сын («Хәмсә»сен) фарсы телендә иҗат иткән.

Фарсы әдәбиятының Фирдәүси (якынча 935—1030), Гомәр Хәйям (1048—1122), Гаттар (1119—1223), Низами (1141—1209), Сәгъди (1203—1292), Җәләледдин Руми (1207—1273), Хафиз (1325—1389) кебек классиклары дөнья укучылары өчен үз һәм якын. Урта гасыр фарсы әдәбиятында без, икеюллык (фәрд) һәм дүртьюллыктан (робагыйлардан) алып, романнар белән дә очрашабыз. Мәсәлән, Фирдәүси үзенең «Шаһнамә» әсәре өстендә 30 елдан артык эшли. 100 меңнән артык шигъри юлны үз эченә алган бу эпопеясында ул Иран халыкларының берничә мең еллык әдәби тарихларын тудыра, Җәмшид, Фәридүн, Искәндәр, Хөсрәү һәм башка күпләгән шаһларны, Рөстәм, Кава кебек халык каһарманнарының образларын укучыларга бүләк итә.

Октябрь революциясенә кадәрге татар дөньясында гарәп-фарсы телләрен белү, бу телләрдәге әдәби, гыйльми китапларны уку — гадәти күренеш. Хәтта бу телләрдә иҗат итүчеләр дә шактый булган.

Дин уртаклыгы, ике арадагы бәйләнешләр, телләрне белү гарәп-фарсы әдәбиятының татарлар арасында гаять киң таралуына китерә. Шәрыкның күп кенә классик әсәрләре оригиналда, төрле тәрҗемәләрдә укыла, татар әдәбиятының үз ядкярләре кебек, халыкның рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерүдә гаять зур роль уйный.

Татар әдәбиятының формалашып җитүендә, үсешендә дә Шәрык классикасының роле зур. Ул нәрсәләрдә күренә соң? Беренчедән, татар әдәби телендә гарәп-фарсыдан алынган сүзләр, гыйбарәләр, төшенчәләр бик күп. Икенчедән, Урта гасыр һәм XIX йөз татар әдәби ядкярләренең шактые Шәрык белән бәйләнештә туган. Котбның «Хөсрәү вә Ширин»е (1342), Сәйф Сараиның «Төркичә Гөлестан»ы (1391), Мөхәммәдьяр (1497—1549), Утыз Имәни (1754—1834), Әбелмәних Каргалый (1782—1833), Кормаши (1855—1883) поэмалары һ.б. — әнә шундыйлардан. Биредә без тема, идея, сюжет, мотив, образ уртаклыкларын яисә охшашлыкларын күпләп күрәбез. Өченчедән, татар классик шигыре гарәп-фарсы гарузы йогынтысында формалаша. Татар әдәбиятында жанрлар оешуда һәм үсешендә дә Шәрык поэтикасының роле ифрат зур булды.

Мәсәлән, Сәйф Сараи, Акмулла, Дәрдемәнд, Г. Тукай яратып кулланган газәл, кыйтга, фәрд (икеюллык) кебек шигъри жанрларның тумышы Шәрык белән бәйләнешле.

Урта гасыр үзбәк, госманлы (төрек), азәрбайҗан әдәбиятлары уңай тарихи шартлар нәтиҗәсендә, гарәп-фарсы рухи мирасыннан мул файдаланып, чагыштырмача зур үсешкә ирешәләр. Аларда Йуныс Әмрә (1250—1320), Гашыйк Паша (1271—1332), Әхмәди (1334—1413), Нәсими (1369—1417), Лотфый (1366—1465), Нәваи (1441—1501), Физули (1494—1556) кебек олуг әдипләрнең иҗат итүе мәгълүм. Бу исемнәр татарлар арасында да үз һәм якын була. Тел якынлыгы, әлифба уртаклыгы нәтиҗәсендә иске үзбәк, госманлы, азәрбайҗан әдәби ядкярләре татарлар тарафыннан, нигездә, оригиналда укыла. Ул телләрдән тәрҗемә итүләр, кагыйдә буларак, XIX гасыр азакларында — XX йөз башларында гына гамәлгә керә.

Шәрык авторларының күп кенә китаплары татар мәктәп-мәдрәсәләрендә дәреслек, әсбап рәвешендә дә кулланыла. Мәсәлән, госманлы әдибе Язычуглының (Мөхәммәд Чәләбинең) зур күләмле «Мөхәммәдия» әсәре (XV) — әнә шундый китапларның берсе. Ул бигрәк тә хатын-кыз мәктәпләрендә иркен файдаланылган.

Шәрык ядкярләре татарлар арасында әүвәл кулъязмаларда, XIX гасырдан башлап басма рәвештә таралганнар. Казан, Оренбург, Уфа нәшриятлары аларны күпләп бастырганнар.

XIX гасырда ук француз, инглиз, немец әдипләренең күп санлы әсәрләре төрек теленә тәрҗемә ителә. Болар үз чиратында татар укучылары арасында да киң таралыш таба. Ә инде XIX йөзнең азакларыннан башлап татар мәдәниятенә рус әдәбиятының йогынтысы көчәя: оригиналда укудан тыш, рус теленнән күп санлы тәрҗемәләр эшләнә, әдәби казанышлар кабул ителә.

Шулай итеп, татар әдәбияты үсешендә, фольклор, гомумтөрки мирастан тыш, Шәрык классикасы да мөһим роль уйный. Ул татар әдәбиятын озак гасырлар буе тукландырып торучы бетмәс-төкәнмәс чыганак, әдипләребез өчен иҗади өйрәнү мәктәбе дә булган.

Үз чиратында татар әдәбияты да Шәрыкка бурычлы калмый. XIII—XIV йөзләрдәге Алтын Урда төрки-татар әдәбиятының төрек, иске үзбәк әдәбиятлары үсешенә уңай йогынты ясавы бәхәссез. Идел-Урал буйларыннан күчеп киткән мәмлүкләрнең ике гасырдан артык Мисыр белән идарә итүләре, гарәп мәдәниятенә зур йогынты ясаулары тарихтан мәгълүм. Татарның

күп кенә галим-әдипләре төрек, үзбәк, таҗик, азәрбайҗан һәм кайбер башка Шәрык халыкларының мәдәни һәм гыйльми үсешләренә үзләреннән зур өлеш кертте. Г. Тукай, Г. Исхакый, Г. Ибраһимов, М. Җәлил кебек әдипләрне Урта Азия, Казахстан, Кавказ укучыларының да үз һәм якын күрүе билгеле.

Сораулар һәм биремнәр

1. «Шәрык» төшенчәсен сез ничек аңлыйсыз?
2. Гарәп, фарсы классик әдәбиятларына күзәтү ясагыз.
3. Гарәп-фарсы әсәрләренең татарлар арасында таралу сәбәпләре.
4. Шәрык классикасының татарларга йогынтысы нәрсәдән гыйбарәт?
5. Урта гасыр үзбәк, азәрбайҗан, төрек әдипләреннән кемнәрне беләсез?
6. Татар әдәбиятының Шәрыкка йогынтысы нәрсәдә күренә?

КОРЪӘН ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

Коръән — мөселманнарның изге китабы һәм гарәп әдәбиятының классик ядкяре. Лексик яктан бу сүз гарәп телендә «уку», «яттан сөйләү», «кычкырып уку», «туплам», «китап» мәгънәләрен дә белдерә.

* * *

Коръәннең тууы Мөхәммәд пәйгамбәрнең эшчәнлеге белән бәйләнгән. Бу тарихи зат якынча 570 елда Гарәбстандагы Мәккә каласында урта хәлле гаиләдә дөньяга килә. Әтисе улы туганчы ук вафат була. Бераздан Мөхәммәд (Әхмәд бине Габдулла) әнисез дә кала, һәм ул бабасы гаиләсендә тәрбияләнә. Сәүдә эшләре белән шөгыльләнә.

Мөхәммәд яһүди, христиан диннәре, мәҗүсилек, Шәрык халыкларының мифологик ышанулары белән яхшы таныш була. Ул ялгыз уйланырга ярата. 40 яшьләрдә вакытта, илһамланып, төрле ачышлар ясый башлый. Риваятьләр бу ачышларның аңа Алла тарафыннан турыдан-туры яисә Җәбраил фәрештә аша иңдерелүен күрсәтәләр. Аларны халыкка җиткерү — Мөхәммәднең изге бурычы. Шуңа күрә Мөхәммәд үзен Алла сүзен халыкка җиткерүче рәсүл, пәйгамбәр (нәби) дип таный һәм бу изге эшкә ныклап керешә. Әүвәл аның ачышларына, үгет-нәсыйхәтләренә, мөрәҗәгатьләренә ышанмыйча, шикләнеп карыйлар. Әмма Мөхәммәд пәйгамбәрнең актив эшчәнлеге нәтиҗәсендә аның тарафдарлары күбәя башлый. Шулай итеп, яңа дингә — ислам диненә нигез салына.

Мөхәммәд үзе 632 елның июль башларында 63 нче яшендә вафат була. Кабере — Мәдинә каласында. Пәйгамбәр үлгәч,

аның эшен якын дуслары Әбүбәкер (572—634), Гомәр (585—644), Госман (575—656), Гали (VI йөзнең соңгы чиреге — 661) хәлиф буларак дәвам итәләр.

Мөхәммәд ачышларының күпчелеге, кагыйдә буларак, телдән таралган. Пәйгамбәр үлгәч, аның фикерләрен бергә туплау башлана. Әмма «Коръән» дип исемләнгән бу тупламалар арасында аерымлыклар килеп чыга. Хәлиф Госман әмере белән изге китапның җыйнама, бердәм текстын төзү бурычы куела. Бу эшне 650—656 елларда Зәйд бине Сабит җитәкчелегендәге махсус төркем башкара. Заманында бу зат Мөхәммәднең ярдәмчесе (шәхси секретаре) булып эшләгән була. Шуңа күрә аның пәйгамбәр сүзләрен яхшы белүе, хәтерләве табигый. Алга таба инде Коръәнгә җитди үзгәрешләр кертелми.

Коръән 114 сүрәдән гыйбарәт: 1) Фатиха сүрәсе; ... 3) Гыймран сүрәсе; 4) Хатыннар сүрәсе; ... 22) Хаҗ сүрәсе; ... 42) Киңәш сүрәсе; ... 62) Җомга сүрәсе; ... 114) Нәс (кешеләр) сүрәсе. Алар күләмнәренә карап урнаштырылганнар: әүвәл (беренчедән кала) иң озыны, аннан кечерәкләре. Һәр сүрә аятьләрдән (абзацлардан; бүлекчәләрдән) төзелгән. Кәүсәр сүрәсе (108 нче) 3 аятьтән, ә иң озын — икенче сүрә (ул «Бәкарә», ягъни сыер сүрәсе дип аталган) 286 аятьтән гыйбарәт. Сүрәләргә исемнәр эчтәлекләре һәм төп мәгънәләре буенча бирелгән.

Коръәннең буеннан-буена бер Аллага ышану идеясе үткәрелә. Ул — барысын да яратучы, тиңсез. Изге китапта ислам диненең асылы, төп таләпләре, икенче төрле әйткәндә, шәригать кануннары аңлатыла. Алар арасында иң мөһимнәре түбәндәгеләр: Алланың берлегенә, Мөхәммәд пәйгамбәрнең Алла илчесе икәнлегенә ышану («Ля иляһа илляллаһү вә Мөхәммәдүр рәсүлүлляһи»); биш вакыт намаз уку (ас-салат); рамазан аенда ураза тоту (ас-саум); мохтаҗларга өлеш чыгару (зәкят) һәм хаҗга бару.

Шәригать кануннары Коръәндә әхлакый кагыйдәләр, кешенең үз-үзен тотышы, эчке дөньясы, фикерләве белән тыгыз бәйләнештә бирелгән. Мәсәлән, Коръәндә тыштан изге булып кыланучы, әмма эчтән бозык кешеләр кискен тәнкыйтьләнә: «Ул монафикълар (икейөзлеләр. — *Х. М.*) Аллаһуны һәм мөселманнарны алдамакчы булалар, ләкин һич алдый алмаслар, фәкать үзләрен алдыйлар, шуны сизмиләр»,— диелә бер аятьтә.

Коръәндә тугрылык, ихласлылык, юмартлык, сүз һәм гамәл берлеге, шәфкатьлелек, ата-ананы хөрмәт итү, сабырлык һәм башка шундый матур әхлакый сыйфатлар мактала, аларның тискәреләре төрлечә хөкем ителә. Бигрәк тә ялганчылык,

кеше канын түгү, фетнә тарату, эчүчелек, зина кылу, хәрам мал туплау гаепләнә. Башка диндәге кеше белән гаилә кору хупланмый: «...аларга ир яки хатын булсагыз, үзләре белән җәһәннәмгә алып керерләр. Алардан ерак булыгыз!» Аллаһы Тәгаләгә ышанмаучылар, ягъни имансызлар иң куркыныч, иң яман кешеләр хисаплана.

Коръән конкрет тарихи җирлектә, иҗтимагый-сәяси шартларда барлыкка килгән. Бу аның эчтәлегендә дә, тел-стилендә дә ачык сизелә. Изге китапта шул дәвер кешеләренең гореф-гадәтләре, мифологик күзаллаулары, фикерләү үзенчәлекләре дә шактый дәрәҗәдә гәүдәләнеш тапкан. Әмма Коръәндә, вакытлы, тарихи күренешләрне тасвирлау аша, гомумән, кешелек, җәмгыять, яшәеш хакында да фәлсәфи уйланулар бәян ителә. Анда без Алла һәм галәм, илаһият һәм кеше, вакыт һәм пространство, яшәү һәм үлем, яшәү мәгънәсе һәм башка шундый мөһим проблемалар белән очрашабыз.

Коръән поэтикасы өчен фәлсәфи һәм эмоциональ фикерләүнең табигый кушылуы, көчле образлылык хас. Китапның тел-стиле ораторлык сәнгатенә хас булган эндәш, риторик сорау, мөрәҗәгать, кабатлау, инверсия алымнарына бай. Анда озын җөмләләр, фразалар аз. Күп кенә аятьләр ритмлы, рифмалы проза (сәҗегъ) белән язылган.

Кабатлаулар, сөйләмгә хас тулы булмаган җөмләләр аеруча китаптагы соңгырак, кечерәк сүрәләрдә еш очрый. Коръәндәге аерым юллар шигъри текст рәвешендә кабул ителә.

Коръәндә без генетик яктан Шәрык халыкларының мифологиясе, фольклоры, язма чыганаклары белән бәйләнешле гаять күп санлы исемнәр (Муса, Сөләйман, Дауд, Гайсә, Ибраһим, Ягъкуб, Локман һ.б.), сюжетлар, мотивлар белән очрашабыз. Аларның бер өлеше яһүдиләрнең һәм христианнарның изге китаплары Тәүрат һәм Инҗилдә дә бар. Ислам — чагыштырмача яшь дин. Шуңа күрә Коръәндә яһүди, христиан диннәре, мәҗүсилек, борынгы мифология белән бәйләнешле образлар, сюжетлар материал, чимал рәвешендә генә файдаланыла. Алар, иҗади эшкәртелеп, ислам диненең төп эчтәлеге, рухы белән табигый яраклаштырылганнар; еш кына бу төр алынма элементларның үзгә мәгънә белдерүләре һәм үзгә йөкләмә, вазифа алулары да күзгә ташлана.

Коръән — гаять катлаулы, символик мәгънәле ядкяр. Аны аңлау, төшенү кешенең рухи әзерлегенә дә бәйле. Гарәп телендә Коръәнгә күп санлы тәфсирләр, шәрех-аңлатмалар

язылган. Алар, әлбәттә, бу изге китап белән эш итүне шактый дәрәҗәдә җиңеләйтәләр.

Коръән, мөселман диненең төп изге китабы буларак, үзеннән соңгы дөнья тарихына гаять зур йогынты ясады. Түбәндәге мәгълүматлар, мәсәлән, үзләре генә дә күп нәрсә хакында сөйли. Чагыштырмача яшь булуына карамастан, ислам дөньяга таралган диннәр арасында хәзерге вакытта икенче урынны били. Ислам динен тотучылар саны хәзер 1,5 миллиардтан артып китте. Бу исә дөнья халкының чиреген тәшкил итә. 28 илнең рәсми дине — ислам. Соңгы вакытта мөселман динен тотучыларның саны артканнан-арта бара.

Коръән Көнбатыш Европа, рус, Америка дөньясында күптәннән мәгълүм. Аның тәүге тәрҗемәләре, шәрехләре инде Урта гасырларда ук дөнья күрә. Рус теленә ул әүвәл, нигездә, Көнбатыш Европа телләреннән тәрҗемә ителә. Казан университеты профессоры А. Казембек XIX гасыр урталарында Коръәннең тәүге өлешен оригиналдан тәрҗемә итә. 1878 елда Г. Саблуковның гарәпчәдән русчага тәрҗемәсендә Коръән басылып чыга. Бу изге китапның рус телендәге иң ышанычлы һәм тулы тәрҗемәсе академик И. Крачковский тарафыннан башкарылды. Ул тәүге мәртәбә 1963 елда нәшер ителде. Изге китапның русчага башка тәрҗемәләре дә бар.

Ислам дөньясында чын мөселман Коръәнне, кагыйдә буларак, гарәп телендә укый, аңлый белергә тиеш дип каралган. Дөрестән дә, фарсы, төрки һәм башка мөселман халыкларының күп кенә укымышлылары, руханилары оригинал телендәге Коръән белән иркен эш итәләр. Әмма вакытлар үтү белән, бу изге китапның гарәплләрдән тыш мөселман халкы телләрендә дә күп санлы шәрехләре, тәрҗемәләре дөнья күрә башлый. Хәзер исә алар бигрәк тә күп.

* * *

Коръән мөселман халыкларының әдәбиятына аеруча нык тәэсир итте. Без моны татар әдәбияты мисалында да ачык күрәбез. Тарихи фактлар күрсәтүенчә, Идел-Урал буйларына ислам дине инде VII гасыр азакларында — VIII гасыр башларында ук керә башлый. Хәзәр каганлыгында (VII—X гасырлар), Болгар, Алтын Урда ханлыкларында, Казан, Себер, Әстерхан, Кырым һәм башка татар дәүләтләрендә ул — күпчелек халыкның дине. Әмма шунысын да искәртик: бу мәмләкәтләрдә дин ирегe көчле була. Хәзәр дәүләтендә, Алтын Урдада, мәсәлән,

яһүди, христиан, мәҗүси, будда динен тотучыларга бернинди киртә куелмавы мәгълүм.

Әмма шунысы кызганыч: Иван Грозный яулап алуларыннан соң, Идел-Урал буе халыкларын, шул исәптән татарларны да, мәҗбүри чукындыру, руслаштыру башлана. Һәм Россия хакимияте өлешчә үз максатына ирешә дә. Кайбер татарлар руслашып, христианлашып китә. Алар арасында Россиянең тарихи язмышында мөһим роль уйнаган Карамзин, Радищев, Юсупов, Чаадаев, Куприн һәм күп санлы башка мәшһүр затларның әби-бабалары бар. Мөселман татарларының бер өлеше, чукынып, керәшен татарларына әверелә.

Әмма нинди генә кыенлыкларга, Россия хакимиятенең эзәрлекләүләренә дә карамастан, татарларның күпчелеге мөселман диненнән баш тартмады. Октябрь инкыйлабына кадәр татарлар яшәгән һәр төбәктә диярлек мәчетләрнең, мөселман мәктәп-мәдрәсәләренең эшләве мәгълүм.

Коръән, төрки-татар әдәбиятын мең ел буена туклландырып, аңа идея һәм сәнгать ягыннан төп юнәлеш биреп килгән. Ул әдипләрнең дөньяга карашында төп фактор була.

Гомумтөрки әдәбиятның олуг вәкиле Йосыф Баласагунлыдан алып Тукайга, Такташка кадәр (дөресрәге, аларны да кертеп) яшәгән күпчелек төрки-татар язучыларының әсәрләрендә без Коръәннең теге яки бу дәрәҗәдәге йогынтысын күрәбез. Ул аеруча нәрсәләрдә күзгә ташлана соң?

Борынгы һәм Урта гасыр әдипләре зуррак күләмле әсәрләрен, кагыйдә буларак, Алланы, Мөхәммәд пәйгамбәрне мактау белән башлыйлар. Аларда Коръәндәге фикерләр, сурәтләр мул файдаланыла.

Төрки-татар әдипләре Коръән сүрәләрен, андагы афористик юлларны, Мөхәммәд пәйгамбәргә мөнәсәбәтле фикерләрне (хәдисләрне) еш кына үз әсәрләренә кертеп җибәрәләр.

Г. Кандалыйның «Рисаләи-л-иршад» поэмасында без Коръәндәге күп кенә төшенчәләр, пәйгамбәр исемнәре, мифик затлар белән очрашабыз. Г. Тукай, М. Гафури, Н. Думави, Ш. Бабич, Һ. Такташ кебек соңгырак дәвер әдипләре дә дини-мифологик мотивларны һәм сурәтләрне читләтеп узмыйлар. Ш. Бабич үзенең «Гаед корбаны» шигырен (1916) мондый юллар белән башлый:

Сөенеңез, дускайларым! Бәйрәм бүген, корбан бүген;
Һәр мөселман кальбенә бәйрәм кошы кунган бүген.

Сайрый ул кош: «Алла әкбәр, Алла әкбәр! — дип куя,—
Сөй, мөселман, бәйрәмеңне, Алла яклар»,— дип куя...

Октябрь революциясенә кадәрге күп кенә әдипләр, теге яки бу проблеманы яктыртканда, образ тудырганда, Коръән рухында эш итәләр. Мәсәлән, Утыз Имәни, Шәмседдин Зәки күрергә теләгән идеаль кешеләр — һәр эшен, һәр сулышын изге китап белән яраклаштырган диндар затлар. Гомумән, Коръән әдипләр өчен илһам, фикерләү чыганагы, гуманизмның, гаделлекнең, камиллекнең өлгесе булып хезмәт иткән.

Татарлар арасында Мөхәммәд пәйгамбәр, аның якыннары хакында төрле легенда-риваятьләр, язма әдәби истәлекләр дә бик популяр булган.

Коръәннең татарча берничә тәфсире, тәрҗемәсе бар. Мәсәлән, бу эш белән Муса Бигиев (1875—1949), Морад Рәмзи (1855—1934) һ. б. галимнәр шөгыльләнә. Ногмани тарафыннан XIX йөздә башкарылган Коръән тәфсире соңгы вакытта кат-кат нәшер ителде. Рабит Батулла тәрҗемәсе дә укучыларга яхшы таныш.

Татар әдәбиятында Коръән белән бәйләнешле мөһим ядкярләрнең берсе — Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре. Әмма бу хакта сүз бераз соңрак булыр.

* * *

Татар әдәбиятының формалашуында һәм үсешендә төп чыганак, әйдәп баручы көч,— әлбәттә, халыкның үз тормышы, аның уй-теләкләре, эчке ихтыяҗлары. Башка факторлар исә — боларга бәйле күренешләр. Фольклор — язма әдәбиятның гомерлек юлдашы. Әмма әдәби үсешнең тәүге баскычларында аның роле гадәттән тыш зур була.

Гомумтөрки, ягъни борынгы төрки әдәбият — татар әдәбиятының нигезе, елга башы. Ә инде Шәрык классикасы, шул исәптән Коръән, Тукайгача чор татар әдәбияты үсешендә мөһим чыганак кына түгел, ә осталыкка өйрәнү мәктәбе, олуг остаз да булды.

Татарларның халыкча (кавем, народность), халык буларак формалашуы, үсеше һәм, гомумән, тарихи язмышы элек-электән үк Идел-Урал буйлары, икенче төрле әйткәндә, Идел-йорт белән бәйләнгән. Бу катлаулы процесста, тарихи вакыт агышында Болгар чоры — тәүге һәм мөһим баскычларның берсе.

Сораулар һәм биремнәр

1. Мөхәммәд пәйгамбәрнең тәрҗемәи хәлен сөйләгез.
2. Коръән нинди шартларда, кайчан һәм ничек барлыкка килә?
3. Нәрсә ул «сүрә» һәм «аять»? Коръәннең төзелеше.
4. Изге китапта гәүдәләнгән төп мәсьәләләр.
5. Ислам диненең дөньяда, Идел-Урал буйларында таралышы хакында сөйләгез.
6. Коръән тәфсирләре, тәрҗемәләре. Изге китапны татарчага кемнәр тәрҗемә иткән?
7. Коръәннең татар әдәбиятына тәэсире нәрсәләрдә күренә?
8. Коръәннең берничә сүрәсен укып, фикер алышыгыз.

«Кереш»кә һәм беренче бүлеккә карата гомуми сораулар һәм биремнәр

1. «Төрки», «туран», «гомумтөрки», «рун», «Шәрык» төшенчәләрен аңлатыгыз. Татар халкының барлыкка килүендә нинди төп элементлар катнашкан?
2. Ни өчен борынгы төрки (гомумтөрки) әдәбиятны без татар әдәбиятының нигезе дип әйтәбез?
3. Борынгы төрки әдәбиятның төп ядкярләрен, авторларын атагыз, аларга хас булган берничә сыйфатны күрсәтегез.
4. Гомумтөрки әдәбиятта нинди жанрлар кулланылган?
5. Борынгы төрки әдәбиятка, гомумән, нинди үзенчәлекләр хас?
6. Гомумтөрки әдәби традицияләр татар әдәбиятында ничек, ни рәвешле дәвам иттерелә?
7. Шәрык классикасындагы төп әдипләрне атагыз. Аларның нинди әсәрләрен укыганыгыз бар?
8. Шәрык классикасы татар әдәбияты үсешендә нинди роль уйнаган?
9. «Коръән һәм татар җәмгыяте» темасына әңгәмә оештырыгыз.

БОЛГАР-ХӘЗӘР ЧОРЫ: ТАРИХЫ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ

I

Идел-Чулман һәм Урал (Җаек) буйларында, ягъни хәзерге татарлар гомер кичергән җирләрдә, яңа эрага кадәр бик күп мең еллар элек кешеләр яшәве мәгълүм. Бу хакта төрле археологик истәлекләр сөйли. Биредәге борынгы кешеләрнең этник ягы тәмам ачык түгел. Мөгаен, аларның күпчелеген хәзерге угро-фин һәм төрки халыкларның әби-бабалары тәшкил иткәндер. Ә инде Идел-Урал буйларында — Иделйортта — безнең дәвернең (эраның) тәүге гасырларында ук төркиләрнең һәм угро-финнарның яшәве бәхәссез. Әлбәттә, биредәге кабиләләр этник яктан саф булып, үз эчләренә бикләнеп кенә гомер кичермәгәннәр. Алар үзара аралашып яшәгәннәр. Идел-Урал буйларына Себер якларыннан, башка тарафлардан да төрле кешеләр, кабиләләр килеп, урнашып торган. Мәсәлән, һуннарның зур бер дулкыны, 375 елда Иделне кичеп, Көнчыгыш Европаның шактый җирләрен яулап ала, андагы кабиләләр белән аралашып, кушылып китә. Һуннар (сөннәр) исә,— мәгълүм булганча, төркиләр белән этник яктан турыдан-туры бәйләнешле халык. Әлбәттә, Идел-Урал буе төркиләре этник җәһәттән бер генә төрле булмый. Алар арасында хәзәр, болгар, сувар (савир), бәҗәнәк (печенег), бәрсил, татар, кыпчак, башкорт, угыз, кимәк, искил (чигил, ишкил), канглы һәм башка күптөрле кабиләләрнең яшәве мәгълүм. Алар кайвакыт берләшеп тә киткәннәр. Мәсәлән, утигур, кутригур, бәрсил, сувар, искил кебек кавемнәрнең болгарлар составына керүе билгеле.

VII гасырның 30 нчы елларында Идел-Урал буйларында һәм Төньяк Кавказда болгарлар һәм хәзәрләр көчәеп китә. Тарихтан бу ике халыкның тел һәм этник яктан үзара якын булуы мәгълүм. Гарәп әдипләре Бәлхи белән Истәхри хәзәр һәм болгар телләренең якын, хәтта бердәй икәнлеген X гасырның 20—30 нчы елларында ук язып калдырганнар.

Хәзәрләр һәм болгарлар 630 елларга кадәр Төрки каганга буйсыналар. Ә инде аннан соң үз дәүләтләрен төзиләр.

Болгарларның V—VI гасырларда Төньяк Кавказда яшәүләре билгеле. 630—632 елларда Кубрат җитәкчелегендә Донның түбәнге агымындагы җирләрне, Азов буйларын, Төньяк Кавказның бер өлешен үз эченә алган Бөек Болгар дәүләте төзелә (башкаласы Тамань ярымутравында). Кыска гына вакыт эчендә бу дәүләт шактый үсешкә ирешә. Византия, Иран, гарәп илләре белән сәяси, мәдәни мөнәсәбәтләр урнаштыра. Халкы, нигездә, мәҗүси динендә була. Әмма ислам, христиан динен тотучылар булуы да мәгълүм.

Бөек Болгар дәүләте озак яшәми: хәзәрләр белән сугышта Кубрат хан һәлак була (якынча VII гасырның 40 нчы елларында). Аның бер улы (Аспарух) үзенең гаскәре белән Дунай тамакларына күчеп китә, җирле славян кабиләләрен буйсындырып, хәзерге Болгария дәүләтенә нигез сала. Әмма биргә килгән болгарлар телләрен югалтып славянлашалар.

Бөек Болгар дәүләте бетерелеп, аның җирләре, халкы Хәзәр патшалыгы составына кертелә. Бер өлеш болгарлар хәзәрләшеп тә китә.

Хәзәр дәүләте VII гасырның 30 нчы елларыннан X йөзнең 70 нче елларына кадәр яши. Бу — Көнчыгыш Европадагы Алтын Урдага кадәр булган иң зур дәүләт. Башкаласы — Түбән Иделдәге Итил шәһәре. Төп халкын хәзәрләр һәм болгарлар тәшкил итә. Дәүләт теле — хәзәр теле. Бу патшалыкның икътисади, мәдәни яктан шактый үсүе мәгълүм. Ул Көнбатыш Европа, Византия, Иран, Һиндстан, Кытай илләре белән сәүдә, сәяси, мәдәни бәйләнешләрдә тора. Гарәп хәлифәлеге белән берничә дистә еллар буена сугышлар алып баруы да билгеле. Урта гасыр гарәп, фарсы, латин, яһүд китапларында хәзәр атамасының еш очравы да күп нәрсә хакында сөйли. Каспий диңгезен заманында Хәзәр диңгезе дип атаганнар.

Болгарларда һәм хәзәрләрдә әүвәл туран, рун әлифбалары кулланыла. Ә инде ислам дине белән берлектә VII гасырның урталарыннан гарәп язуы да керә башлый. VIII гасырның икенче яртысында сугылган хәзәр акчаларында инде без гарәп әлифбасының кулланылуын күрәбез. 932—933 еллардан инде бу традицияне болгарлар дәвам итә.

Эчке һәм тышкы каршылыклар, иң беренче чиратта Киев кенәзе Святославның кан коюлы һөҗүмнәре нәтиҗәсендә, Хәзәр дәүләте 970 елларда яшәүдән туктый. Хәзәрләрнең

шактый өлеше хәзерге татарларның әби-бабалары — болгарлар һәм кыпчаклар белән кушылып китә. Л. Гумилёв фикеренчә, Әстерхан татарлары хәзәрләр белән аеруча тыгыз бәйләнешле.

* * *

Идел буендагы Болгар ханлыгы (этник һәм мәдәни яктан) — Бөек Болгар һәм Хәзәр дәүләтләренең турыдан-туры варисы, татар тарихының чираттагы бер баскычы.

Мәгълүм булганча, Бөек Болгар дәүләте яшәүдән туктагач, болгарларның бер өлеше Урта Иделгә күчеп килә һәм җирле угро-фин, төрки кабиләләре белән бергәләп яши башлый. Хәзәр патшасына салым түли. Әмма бераздан.биредә яшәүче халыкларның этник һәм сәяси яктан оешу процессы көчәя. Аның башында болгарлар тора. 865 елларда инде Болгар дәүләт буларак телгә алына башлый. Әмма чын бәйсезлеккә ул X гасыр урталарында гына ирешә. 922 елда ил рәсми рәвештә ислам динен кабул итә.

Болгар мәмләкәтенең дәүләт буларак оешу процессы, эчке тормышы Н. Фәттахның «Әтил суы ака торур» романында шактый тулы гәүдәләнеш тапкан.

Болгар дәүләте Ука, Нократ (Вятка), Агыйдел тамакларыннан алып Җаекка, Жигулига кадәрге җирләрне биләп тора. Гомумән, Идел-Урал буйлары болгарлар йогынтысында була. XI—XII гасырларда аерым чыганакларда Каспий диңгезенең Болгар исеме белән аталуы да шул файдага сөйли.

Болгар дәүләте — Урта гасыр дөньясының билгеле һәм алга киткән мәмләкәтләреннән берсе. Анда игенчелек, терлек асраучылык, һөнәрчелек бик нык үсә. Болгарлар, Европада беренчеләрдән булып, чуен коя. Болгар осталары җитештергән аяк һәм өс киемнәре, зиннәтле ювелир әйберләр бөтен тирәюньдә мәшһүр була. Мәсәлән, Болгар читекләрен Шәрык илләрендә «болгари» исеме белән йөрткәннәр. Тарихтан X йөздәге бер рус кенәзенең «болгар сугышчыларының һәммәсе итекле, ә без чабаталы» дигән гыйбарәсе билгеле.

Болгарның икътисади, мәдәни үсешенә аның сәүдә итү өчен уңайлы җирләрдә, бигрәк тә Идел буенда урнашуы зур йогынты ясаган. Бирегә Урта Азия, Һиндстан, Иран, Кытай, гарәп илләреннән, Әрмәнстан, Византия, рус кенәзлекләреннән, Көнбатыш Европа мәмләкәтләреннән күп санлы сәүдәгәрләрнең җыелуы мәгълүм. Үз чиратында Болгар кешеләре дә дөньяның төрле

төбәкләренә йөреп тора. Аеруча күршедәге рус кенәзлекләре белән тыгыз икътисади мөнәсәбәтләр урнаша. Мәсәлән, 985 елда Киев кенәзе белән Болгар ханы «мәңгелек» килешү төзиләр. Шартнамәдә фольклорга мөнәсәбәтле мондый юл да бар: «Каичан колмак су төбенә батар, таш су өстенә калкыр, бу вәгъдә шунда бозылыр». Болгарларның ачлык елларда русларга күпләп икмәк, азык-төлек җибәрүләре мәгълүм. Владимир шәһәрендәге иң зур биналарның берсе — Успенский соборы —Болгардан китерелгән ак ташлар белән безнең бабаларыбыз тарафыннан салына. Гомумән, рус кенәзлекләрендә болгар осталары төзегән биналар күпкә җыела. Аларның диварларында болгар-татар мифологиясенә, сәнгатенә кагылышлы аерым факт-мәгълүматлар да теркәлеп калган.

Башлангыч чорында Болгар халкының этник яктан төрле булуы мәгълүм. Әмма XII йөзләрдә инде чагыштырмача этник бөтенлек оешып җитә, һәм ул, нигездә, болгар исеме белән генә атала. Мәмләкәттә хәзерге чуваш, мари, удмурт, башкорт, мордва халыкларының да билгеле бер санда әби-бабалары яши.

II

Болгар үз вакытында ук чит ил кешеләренең игътибар үзәгендә торган. Рус елъязмаларында, мәсәлән, Болгарга мөнәсәбәтле шактый мәгълүматлар бар. XIII гасырның 30 нчы елларында венгр монахы Юлиан үзенең «Бөек Болгарстанга... , бай шәһәрләре булган бөек һәм кодрәтле патшалыкка» килүен яза. Шушы ук елларда Көнбатыш Европадан килгән католик руханилар Плано Карпини һәм Гильом де Рубрук та Идел буйларында булалар. Алар да «Мөхәммәд динен башкаларга караганда да ныграк тотучы» бердәм Болгар халкы турында белешмә биреп калдырганнар.

Идел буе мәмләкәте, болгар халкы аеруча мөселман дөньясы кешеләрен кызыксындырган:

«Болгарлар — игенчелек белән шөгыльләнүче халык; бодай, арпа, тары һәм башка шундый һәртөрле ашлык игәләр. Аларның күпчелеге ислам динен тота, авылларында имамнар вә мөәзиннәр җитәкләгән мәчет һәм мәктәпләр бар» (Ибне Рөстә, якынча 913 ел).

«...Болгар — гаять зур шәһәр... Аның халкы суыкка бик чыдам... Биредә гыйлемле кешене белер (белеквар) дип йөртә-

ләр. Һәм шуңа мөнәсәбәттә илләрен дә Болгар дип атыйлар...» (Әл-Гарнатый, XII йөзнең беренче яртысы.)

«Болгарлар — куркуны белми торган куәтле, бик гайрәтле олы бер халык. Аларга күрше булган халыклар барысы да буйсынып, баш иеп торалар...» (Әл-Мәсгуди, 943—947 еллар.)

922 елда Болгарга Багдад хәлифенең зур вәкиллеге килә. Аның секретаре Ибне Фадлан үзенең күргән, ишеткән, кичергәннәрен язып калдырган. Аның сәяхәтнамәсе — Болгарның тормышын, мәдәниятен, шул исәптән мифологиясен һәм фольклорын өйрәнүдә бәһаләп бетергесез чыганак.

Утраклык, шәһәр тормышының алга китүе, Шәрык дөньясы белән тыгыз бәйләнеш Болгарда мәгариф, фән һәм мәдәниятнең үсешенә уңай йогынты ясый. Күп санлы уку йортларында дөньяви гыйлемнәр, дин, гарәп-фарсы һәм төрки телләре, Шәрык авторларының китаплары ныклап өйрәнелә.

Болгарда күп санлы галимнәрнең булуы, аларның төрле тармаклар буенча хезмәтләр язуы мәгълүм. Мәсәлән, Болгар казые Ягъкуб Ибне Ногман әл-Болгари «Болгар тарихы» дигән китап яза. Әмма бу китапның хәзергәчә табылганы юк. XII йөздә Сөләйман бине Дауд әс-Саксини дигән галим һәм әдип яши. Аның хакында төрекләрнең атаклы галиме Хаҗи Хәлифә (ягъни Кятиб Чәләби — XVII йөз): «Сөләйман бине Дауд вәгазь, әхлак, әдәп турындагы әсәрләре белән бик мәшһүрдер»,— дип язып калдыра. Әс-Саксининең гарәп телендә язылган берничә китабы бар. Болар арасында аеруча «Авыруларның күңелләрен дәвалаган чәчәк бакчасы» («Зөһрәтер-рийаз») әсәре билгеле. Ул дини-әхлакый характерда. Анда төрле легенда-риваятьләр дә урын алган. Аларның берсен «Җөмҗөмә солтан» дастанында (1369) Хисам Кятиб тә файдаланган.

Шунысы үзенчәлекле: Болгар галим һәм әдипләренең күпчелеге (аларның саны берничә дистәдән артып китә) «Болгари» кушаматын йөртә һәм Шәрык дөньясында да билгеле була.

Мәхмүд Кашгарыйның «Диване лөгатет-төрк» китабындагы күпчелек шигъри текстларның, мәкаль-әйтемнәрнең болгарларга да билгеле, мөнәсәбәтле булуы шиксез. Чөнки аларга хас сурәтләр, тасвир чаралары татар әдәбиятында һәм фольклорында тулып ята. Ә инде Мәхмүд Кашгарый китабындагы мәкальләр турыдан-туры да, тәрҗемәләре ярдәмендә дә татар укучыларына үз һәм якын. Мәсәлән:

Берин-берин (берәм-берәм) мең булыр,
Тама-тама күл булыр.

Көз килеге йәен билгелег.
(Көз килеше җәйдән билгеле.)

Борынгы төрки гадәт-йолаларның, ышануларның да шактый өлеше татарларга хәзәр, болгар һәм кыпчаклар аркылы килә. Мәсәлән, Мәхмүд Кашгарый унике җәнлеккә мөнәсәбәтле ел исәбе турында сүз алып бара. Хәзәр-болгарларда да уникееллык хайван ел исәбе кулланылу мәгълүм. Барс елы, мәсәлән, туклык, иминлек елы хисапланган. Шунысы мөһим: Татарстан Республикасының туграсындагы барс — болгархәзәр, татарларның борынгы тотемы (табыну хайваны). Соңгы дәвер татар халык иҗатында да «барс елы — байлык» дигән гыйбарә еш очрый.

Күп кенә галимнәр соңгы дәвер татар фольклорындагы Алып батыр, Алпамша, Сак-Сок сюжетларының, Нәүрүз, Нардуган йолаларының да болгар-хәзәр чорларыннан ук килүен искәртәләр.

Язма әдәбиятта борынгы болгар кабер ташлары турында фикер-күзәтүләр еш очрый. Аларның күпчелеге Алтын Урда чорына карый. Ә бер өлеше, чыннан да, Болгар дәверенеке. Бу кабер ташлары — тарихны, телне өйрәнүдә мөһим чыганак. Ташларда төрле бизәкләр дә бар. Шуңа күрә алар сәнгати яктан да игътибарга лаек.

Гомумтөрки әдәбиятның Йосыф Баласагунлы, Әхмәд Йүгнәки, Әхмәд Ясәви, Сөләйман Бакырганый кебек күренекле әдипләре дә болгар-татар укучыларына яхшы таныш була.

Болгар — гомумтөрки мәдәниятнең мөһим бер үзәге, татар тарихының, рухи мирасының төп нигезләреннән берсе. Әмма, кызганыч ки, төрле сәбәпләр аркасында ул дәвернең күпчелек ядкярләре юкка чыккан. Безгә килеп җиткән иң мәшһүр истәлекләрнең берсе — Кол Гали дастаны. «Кыйссаи Йосыф», борынгы рун ядкярләреннән, «Котадгу белек»тән, бай төрки фольклордан килә торган традицияләрне Шәрык классик әдәби казанышлары белән кушып, төрки-болгар-татар әдәбиятын яңа баскычка күтәрде.

Сораулар һәм биремнәр

1. Борынгы заманда Идел-Урал буйларында нинди халыклар яшәгән? Тарихтан һуннар хакында белгәннәрегезне искә төшерегез.

2. Бөек Болгар дәүләте хакында сөйләгез.

3. Дунай тамагындагы Болгария мәмләкәтенең Идел-Дон буйларындагы болгарлар белән нинди бәйләнеше бар?

4. Хәзәр мәмләкәте хакында сөйләгез.

5. Болгар-хәзәрләрдә дини ышанулар. Ислам диненең кабул ителүе.

6. Идел буенда Болгар дәүләте төзелү, аның халкы, тормышы.

7. Чит ил әдипләренең Болгар турындагы фикерләре.

8. Ибне Фадлан язмасы.

9. Болгар галимнәреннән кемнәрне беләсез?

10. Алдарак өйрәнелгән «Диване лөгатет-төрк» китабын искә төшерегез. Анда Идел буена, болгар-татарларга мөнәсәбәтле нинди мәгълүматлар бар?

11. Татар фольклорында болгар чорына мөнәсәбәтле нинди ядкярләр бар?

12. Н. Фәттахның «Әтил суы ака торур» һәм М. Хәбибуллинның «Кубрат хан» романнарында борынгы болгар тормышы ничек гәүдәләнгән? (Сорау ирекле, ул теләгән укучылар өчен тәкъдим ителә.)

Кол Гали

(1183—XIII йөзнең беренче яртысы)

«КЫЙССАИ ЙОСЫФ»

Меңьеллык татар әдәбияты тарихында күренекле ядкярләр гаять күп. Әмма алар арасында «Кыйссаи Йосыф» кебек озак гасырлар буе укылып, халыкның рухи юлдашы, сердәше булып килгән әсәрләр, мөгаен, юктыр. Халык язучысы Гомәр ага Бәшировның «Әдәбиятыбызның бабасы» исемле мәкаләсендә мондый юллар бар: «Мин китапның әһәмиятен аңларлык яшькә җиткәндә, халык арасында төрле исемдә байтак кына әсәр укыла иде. Ләкин шулардан мин халыкның рухи хәзинәсен «Йосыф китабы» кадәр баеткан, халык күңеленә шулкадәр көчле тәэсир иткән башка бер китапны белмим. Бу әсәрне йөз еллар буенча безнең борынгы бабаларыбыз укып килгән, безнең әти-әниләребез, апа-абыйларыбыз укып үскән. Мин малай чакта безнең авылда «Йосыф — Зөләйха»[1] кыйссасы иң затлы, иң кыйммәтле китаплардан санала, кияүгә чыкканда, аны кызларга иң кадерле истәлек сыйфатында бүләк итеп бирәләр иде».

«Кыйссаи Йосыф» татар мәктәп-мәдрәсәләрендә уку әсбабы рәвешендә дә өйрәнелгән.

Кол Гали поэмасы — дөнья мәдәниятенең дә кыйммәтле ядкяре. Күренекле галим Георгий Ломидзе Кол Галинең «бөек шагыйрь, фикер иясе, һәрьяклап укымышлы кеше булуын» искәртә. «Аның гүзәл «Кыйссаи Йосыф» поэмасы,— ди ул,— дөнья әдәбиятының бөек җәүһәрләреннән санала».

[1]Кол Гали әсәрен «Йосыф — Зөләйха», «Кыйссаи Йосыф», «Йосыф китабы» һ.б. исемнәр белән йөрткәннәр. «Кыйссаи Йосыф» атамасы поэманың эчтәлеген, тематикасын тулырак чагылдыра.

Шагыйрьнең тәрҗемәи хәле. Кол Галинең тормышы хакында чыганаклар юк дәрәҗәсендә. Аның хәтта туган, үлгән еллары да билгесез. Әмма аерым мәгълүматлар шагыйрьнең тәрҗемәи хәле турында фараз кылырга мөмкинлек бирәләр.

Поэманың хатимә, ягъни йомгак өлешендә автор үзе хакында болай ди:

> Моны язган ул зәгыйфьнең аты Гали,
> Егерме дүрт иҗек белән тезде юлны[1].
>
> ...Кыл мәрхәмәт-шәфкать миңа — Кол Галигә,
> Кайгылы бу җанымны син шат кыл имди. (295 б.)

Димәк, шагыйрь үзен «Гали», «Кол Гали» дип йөрткән. Беренчесе аның үз исеме, икенчесе әдәби кушаматы булса кирәк.

Хәзерге фәндә Чулман (Кама) буе шагыйрьнең туган җире итеп карала. Кайберәүләр аны Зәй тамагына, икенчеләре исә Кашан (Кышан) каласына нисбәт итәләр. Кашан шәһәре хәзерге Саескан Тавы (Сорочьи Горы) тирәсендә булган дип фараз кылына. Заманында бу калада иҗтимагый һәм мәдәни тормышның гөрләп торуы мәгълүм. Шуңа күрә Кол Гали гомеренең Кашан белән бәйләнештә булуы бик ихтимал.

Күпчелек галимнәр шагыйрьнең туган елы итеп шартлы рәвештә 1183 елны алганнар. Ә инде Кол Галинең үлү вакыты XIII гасырның 30 нчы еллар азагына — 40 нчы еллар башына, ягъни монголлар һөҗүме чорына туры килә.

Кол Гали әүвәл Болгар мәмләкәтендә укыган, аннан Харәземдә һәм мөселман дөньясының кайбер башка төбәкләрендә дә белемен күтәргән, галимнәр, әдипләр белән аралашкан. Шагыйрьнең, үз туган теле — болгар-татар теленнән тыш, гарәп, фарсы телләрен дә камил белүе мәгълүм. Кол Галинең безгә бары бер әсәре — «Кыйссаи Йосыф» дастаны гына билгеле. Әмма аның аркылы да без авторның көчле талантка ия булуын, фольклорны, Шәрык әдәбиятларын яхшы үзләштерүен күрәбез.

---

[1]*Кол Гали.* Кыйссаи Йосыф (Йосыф турында кыйсса). Төп текстны (транскрипцияне) әзерләүче, кереш мәкаләне, искәрмә һәм аңлатмаларны, кульъязмаларның тасвирламасын язучы — филология фәннәре кандидаты Ф.С. Фәсиев (татар һәм рус телләрендә).— Казан: Татар. кит. нәшр., 1983.— 292 б. Алга таба бу чыганакның битләр саны җәяләр эчендә генә күрсәтеләчәк. Әмма төп текстның язылу рәвеше бераз гадиләштереп алына.

1973 елда Нурихан Фәттах өч пәрдәлек «Кол Гали» пьесасын иҗат итте, һәм бу трагедия берничә ел буе Татар дәүләт академия театрында зур уңыш белән барды.

Пьесада Кол Гали (ул Болгар ханының улы дип тәкъдим ителә) шагыйрь дә, үз иленең, болгар-кыпчакларның иминлеген саклаучы көрәшче итеп тә бирелгән. Ул — намуслы, туры сүзле шәхес. Кол Гали, нәкъ Йосыф кебек, теләсә нинди шартларда да атасына тугрылыгын саклый. Агасы Хаҗи бәкнең мәкер-гайбәте аңа Йосыф агаларының ярамаган эш-гамәлләрен хәтерләтә. Йосыф — Зөләйха мәхәббәтенә ул үзенең шәхси сөю хисләрен дә күчерә.

«Кол Гали» трагедиясе Болгар иленең һәлакәте белән тәгәлләнә. Һәр җирдә хәрабәләр, мәетләр. Әмма шагыйрьне өзелеп сөйгән Чәчәк исемле кыз исән. Аның кулында мәшһүр кыйсса. Китапны актарып, кыз болай ди: «Бөек кыйсса — мәңгелек истәлек. Мин саклармын, Гали, синең китабыңны. Мин өйрәнермен, мин укырмын, Кол Гали, синең Йосыф атлы батыр ир белән Зөләйха атлы гүзәл кыз турындагы тиңсез җыруыңны!» Шул сүзләрдән соң пәрдә төшә.

Әйе, шагыйрь үлгән. Әмма аның әсәре үлмәгән. Бу хакта Шәүкәт Галиевнең мондый юллары бар:

Сигез гасыр элек җырларыңны
Яраткан да халык, ятлаган,
Шуннан бирле аны онытмаган,
Күңелендә көйләп саклаган.

Әсәрнең язылу вакыты, кулъязма һәм басма нөсхәләре.

«Кыйссаи Йосыф»ның автор кулы белән язылган нөсхәсе (автографы) сакланмаган. Ә инде күп санлы күчермәләрдә әсәр иҗат ителүнең төрле вакыты күрсәтелә: ул, нигездә, 1212—1233 еллар арасында тирбәлә. Күпчелек кулъязмаларда 609 (1212) ел тора.

Әсәр күчермәләре арасында күләм, эчтәлек ягыннан аерымлыклар бар. Кулъязмалар арасындагы бу төр үзгәрешләр күчерүчеләрнеке генә була алмый, алар авторга да карый. Шуңа күрә хәзерге фәндә мондый фикер урнашкан: Кол Гали үз поэмасын 1212 елда иҗат иткән; әмма аңа 1233 елда да аерым редакцион үзгәрешләр керткән.

XIX гасырның 40 нчы елларына кадәр «Кыйссаи Йосыф» халыкта төрле кулъязмаларда тарала. Аның басма нөсхәләре дөнья күрә башлагач та, бу традиция, ягъни әсәрне кулдан күчерү, кулъязмаларда уку дәвам итә.

Хәзерге көндә поэманың бик күп санда күчермәләре билгеле. Аларның күпчелеге XVIII—XIX йөзләргә карый. «Кыйссаи Йосыф» кульязмаларының яртыдан күбесе Казан шәһәрендә саклана.

Күренекле шагыйрь һәм галим Габдерәхим Утыз Имәни 1824 елда, төрле кульязмаларга нигезләнеп, «Кыйссаи Йосыф»ның чагыштырмача дөрес текстын төзи. (Барлыгы — 998 строфа.) Әмма ул әсәрнең хатимә, ягъни йомгак өлешен, аерым строфаларны төшереп тә калдыра.

Кол Гали поэмасының беренче басмасы 1839 елда Казан университеты типографиясендә дөнья күрә. «Кыйссаи Йосыф галәйһиәссәлам» дип исемләнгән 120 битлек бу китап Утыз Имәни текстын нигез итеп алган. Әсәрнең башка басмаларына исә теге яки бу дәрәҗәдә үзгәрешләр дә кертелгән. Аларның кайберләрендә без Утыз Имәни төшереп калдырган юлларны да очратабыз.

Октябрь революциясенә кадәр «Йосыф китабы» ел саен диярлек басылып чыга. Аерым елларда аның хәтта икешәр, өчәр мәртәбә нәшер ителүе дә мәгълүм. Тиражы да зур була: хәтта аерым басмаларының саны 20—30 меңгә җитә. Китапның бу рәвешле күп басылуы үзе үк әсәрнең халыкта гаять популяр булуын ачык күрсәтеп тора. Һәр татар гаиләсендә диярлек «Кыйссаи Йосыф»ны укыганнар, көйләгәннәр (аның үз көе була). Казан басмалары тугандаш төрки халыклар арасында да билгеле бер таралыш таба.

Октябрьдән соң да, традиция нигезендә, «Кыйссаи Йосыф» халыкта укылуын дәвам итә. Әмма әлифбалар алышыну, төрле эзәрлекләүләр, әсәрнең озак еллар нәшер ителмәве Кол Гали поэмасы белән яшь һәм урта буын арасын ерагайтуга китерде. Бары тик соңгы еллардагы иҗтимагый үзгәрешләр генә бу тискәре процессны өлешчә туктата башлады. «Кыйссаи Йосыф» белән кызыксыну көчәйде. Әсәрнең берничә мәртәбә басылуы, аның хакында күп санлы мәкаләләр, гыйльми хезмәтләр язылуы — моның ачык дәлиле.

«Кыйссаи Йосыф» поэмасының төзелеше.

Әсәр баштагы өч юлы рифмалашкан, дүртенче юлы рифмасыз дүртьюллыклардан гыйбарәт. Строфаларның схемасы — *аааб,вввб,гггб* рәвешендә. Еш кына дүртьюллыкларда бердәй рифмаларның кабатлануы да очрый.

Поэмадагы һәр строфа «имди» («инде» мәгънәсенә якын) сүзенә тәгалләнә. Аның һәр дүртьюллык ахырында кабатла-

нып килүе строфаларның үзара бәйләнешен тәэмин итә, әсәрне укуда һәм кабул итүдә билгеле бер ритмик дулкын тудыра.

Һәр шигырь юлы, кагыйдә буларак, дүртәр иҗекле өч ритмик буыннан гыйбарәт. Димәк, һәр юлда — барлыгы 12 шәр, ә һәр строфада — 48 иҗек. Әсәрдәге дүртьюллыклар меңнән артып китә.

Поэма керештән, төп өлештән һәм хатимәдән, ягъни бетемнән гыйбарәт. 22 строфалык керешнең эчтәлеге традицион характерда: анда Аллага, Мөхәммәд пәйгамбәргә, тәүге хәлифләргә (Гомәр, Госман, Галигә) һәм пәйгамбәрнең якыннарына мәдех-мактау укыла.

Әсәрнең хатимәсе (ул 11 дүртьюллыктан гыйбарәт) эчтәлек ягыннан «кереш» белән кушылып китә. Биредә дә Тәңрегә сыгыну, аннан ярдәм, шәфкать сорау бар. Шагыйрь, «илһам биргәне» өчен, Тәңрегә рәхмәт укый, «шөкер кыла». Хатимәдә шулай ук авторның үзе, әсәрнең язылу вакыты хакында да мәгълүматлар бар.

Кол Гали үз әсәренең кыйммәтен үзе дә яхшы аңлый. «Кыйссалардан, хикмәтләрдән күреклесе, ялыкмыйча тыңлау өчен иң татлысы»,— ди ул Йосыф сюжеты хакында. Поэманың идея-эстетик кыйммәте турында хатимәдә дә кызыклы юллар бар. Автор фикеренчә, бу кыйсса кешеләрнең күңелен йомшартыр («Тыңлаучының күңле эрер, агар яше»), гөнаһларыннан арындырыр («Юкка чыгар гөнаһларының һәммәсе»). «Әмма,— ди Кол Гали,—бу әсәрне акылы булган кешеләр генә бәяли алыр».

Гәүһәр таш, ләкин һәр таш гәүһәр булмас,
Тикмә кеше гәүһәр кадрен белә алмас,
Бу назымның кадрен бары ахмак белмәс,
Гакыллылар тыңлар, аңлар, белер имди. (293 б.)

Поэманың төп өлеше 18 «фасыл»дан, ягъни бүлектән гыйбарәт. Аларның күләме төрлечә. Мәсәлән, беренче фасылда строфалар саны 80 нән артып китсә, ахыргы бүлектә алар 15 кенә. Дүртенче фасыл — иң күләмлесе. Андагы дүртьюллыклар саны 200 гә якыная.

Фасылларның һәммәсе дә исемләнгән:

I — Йосыфның төше;

II — Йосыф коесының сыйфатлары;

IV — Дәгыйр улы Маликның төш күрүе;

V — Зөләйха турында хикәят;

XVIII — Йосыфның вафаты.

Бүлек атамалары әсәрнең гомуми төзелешен, сюжет схемасын, вакыйга-хәлләрнең эзлеклелеген күз алдына китерергә ярдәм итәләр.

«Кыйссаи Йосыф» үзенең төзелеше, жанр табигате белән лиро-эпик характердагы поэмаларны хәтерләтә. Вакыйгаларның шактый катлаулы, берничә тармаклы булуына, күләменә карап, аны шигъри роман дип тә атарга мөмкин.

Әсәрнең сюжеты. Кәнган илендә Ягъкуб пәйгамбәр яши. Аның 12 углы була. Йосыф — шуларның унберенчесе. Ибне Йәмин — иң кечесе. Аларның аналары бер — Рәхилә. Ә калган ун туганның әниләре башка. Әсәрдә Ягъкубның ике кызы булуы да искәртелә: Динә — үз кызы, ә икенчесе — үги кыз.

Бервакыт унбер яшьлек Йосыф төшендә кояшның, «тулган ай һәм унбер йолдызның үзенә сәҗдә кылуын», ягъни баш июен күрә. Төшнең мәгънәсен әтисе Ягъкуб болай юрый: «синең исмең галәмара мәшһүр булыр», «пәйгамбәрлеккә» ирешерсең, «мәмләкәт иясе» булырсың, унбер туганың да «сиңа хезмәт итәр».

Ләкин, углым, әманәттер, яхшы тыңла,
Бу төшне син беркемгә дә мәгълүм кылма,
Саклан кеше кинәсеннән, шуны аңла:
Кешеләргә шайтан дошман булыр имди. (55 б.)

Әмма бу сөйләшүне тыңлап торган Ягъкубның үги кызы серне агаларына җиткерә.

Кардәшләре, моны белгәч, бик борчылды,
Көнләүләре бар нәрсәдән өстен булды. (55 б.)

Шуннан алар, әтиләрен алдап, Йосыфны сахрага алып чыгалар: рәнҗетәләр, кыйныйлар, хәтта үтерергә җыеналар. Әмма туганы Йәһүдә моңа каршы төшә: «Карендәш үз карендәшен һич үтермәс, аны коега гына салыйк»,— ди. Туганнары бу киңәшне кабул итәләр һәм Йосыфны ялангач килеш «еланчаян», «хәшәрәтләр» тулы ташландык коега аталар. Әмма Алланың кодрәте белән Йосыфка пәйгамбәрлек дәрәҗәсе ирешә, һәм коеда аңа әйбәт шартлар тудырыла.

Кардәшләре, бер бәрәнне суеп, аның канын Йосыфның күлмәгенә сөртәләр дә, «елашып», әтиләре янына киләләр. Йосыфны бүре ашады дигән сүзләрне ишеткәч, Ягъкуб һуштан яза.

Аңына килгәч, күлмәкне ул кулга алды,
Үбә-коча, егълый-егълый күзен салды,
Күлмәгендә ертылган җир табылмады,—
«Нинди шәфкатьле бүре бу?» — дияр имди. (85 б.)

Шуннан Ягъкуб улын ашаган бүрене тотып китерергә куша. Бүре, телгә килеп, үзенең гаепсезлеген әйтә («Пәйгамбәрләр ите безгә хәрәм имди!»).

Ягъкуб, балаларының алдашуын белеп, «бу казаны җибәргәндер Тәңре» дип, сабыр кылырга була.

Дүртенче фасыл Мисырдагы Малик Ибне Дәгыйр дигән олуг сәүдәгәрнең төшен сыйфатлау белән башлана: Кәнгандагы Гад коесы; күктән җиргә иңеп баручы кояш.

Кояшның җиргә иңгәнен тордым күреп,
Ул якамнан чыкты, куеныма кереп,
Энҗе-мәрҗән яуды җиргә, яңгыр кебек,—
Мин аларны итәгемә җыйдым имди... (89 б.)

Сәүдәгәргә төш юраучы болай ди: бик очсызга гына синең кулыңа «асыл затлы кол» керер, син, аны сатып, «күп байлык табачаксың, дәүләт һәм мөлкәт иясе булачаксың».

Малик Ибне Дәгыйр Кәнган иленә сәфәр тота. Әмма аңа, Гад коесы янында торганда, «50 елдан соң килерсең» дигән тавыш ишетелә. Сәүдәгәр кабат иленә кайта. Күрсәтелгән вакыт үткә янә аның кәрваны кое янына килеп җитә. Бәшир һәм Бошра исемле коллары коега чиләк төшерәләр. Йосыф, аңа ябышып, өскә күтәрелә. Аның «тулун ай тик нурлы йөзенә» кешеләр шакката. Кәрван янына Йосыфның кардәшләре, килеп: «Бер колыбыз бездән качып киткән иде, Шиксез, аны сез алгансыз!» — дип тавыш күтәрәләр. Малик, хәлне аңлап, Йосыфны туганнарына кайтарып бирә. Ә ун кардәш мәкерле уйларыннан һич баш тартмыйлар: Йосыфка нахак бәла ягалар («Колыбызның нәкъ өч төрле гайбе бардыр: Качучыдыр, урлаучыдыр, ялганчыдыр») һәм аны юк кына бәягә Маликка кол итеп сатып җибәрәләр.

Мескен Йосыф күзләреннән кан-яшь түгәр,
Зар-зар егълап, кардәшләрен кочар-үбәр,
Саубуллашып, дога кылыр һәммәсенә,—
Малик Дәгыйр түнә-түнә егълар имди. (101 б.)

Кәрван кузгалып китә. Куллары богауланган Йосыф юлда кабердәге анасы белән саубуллаша, аңа үзенең авыр хәлен, моң-зарларын сөйли. Әнисе улын юата.

Кылыч исемле кол кәрваннан аерылып калган Йосыфны кыйный («Нигә качтың?»— дия-дия кыйнар имди»). «Качкын колны» дөягә менгереп, каты итеп бәйләп куялар. Әмма шулчак, Алланың кодрәте белән, һава бозыла, «карлы-бозлы яңгыр» ява башлый. Кешеләр нишләргә белми куркып калалар. Шунда Кылыч, үз гаебен аңлап, Йосыфтан гафу үтенә. Аңа Малик та кушыла. Йосыф аларны кичерә.

Шул ук сәгать карлы-бозлы яңгыр тынды,
Ява торган яңгыр кинәт яумас булды,
Бозлар эреп, сулар агып, җиргә сеңде,—
Кояш чыгып, җир йөзе шат булыр имди. (109 б.)

Йосыфка кадер-хөрмәт, ихтирам арта.

Кәрван юлын дәвам итә. Ике шәһәр халкы, Йосыфның матурлыгын күреп, мөселман динен кабул итә. Әмма Йосыфның күңелен тәкәбберләнү биләп ала, ул: «Миңа охшаш беркем дә юк!»— дип уйлый. Өченче шәһәрне узганда, Йосыфка беркем дә игътибар итми. Чөнки анда матурлыгы белән мәшһүр затлар — пәриләр яши. Шунда Йосыф үзенең гаебен аңлый, горурлануына бик үкенә.

Аңа тагын Тәңресеннән ярдәм килде,
Тәңре аңа матурлыгын кире бирде. (117 б.)

Менә, ниһаять, кәрван Мисырга килеп җитә. Мондагы халык Йосыфның гүзәллеген күреп хәйран кала. Малик моның өчен акча алып тора: әүвәл бер, аннан ике, өч ... динар.

Малик Йосыфны сатарга карар кыла. Моны ишетеп, аның сараена сатып алырга теләүчеләр агыла башлый. Әмма берсенең дә малы җитми.

Бишенче фасылда әсәргә Зөләйха килеп керә. Ул — Мәгъриб патшасы Тәймуснең гүзәл кызы. Зөләйха да, нәкъ Йосыф кебек, әтисе алдында йоклаганда төш күрә.

Зөләйха беркөнне йоклап ятар иде,
Шунда Йосыф сурәтен ул төштә күрде,
Күрү белән шундук аңа гашыйк булды,—
Егълый-егълый ул уянып китәр имди. (129 б.)

Кыз, Йосыфны уйлап, йокысыннан кала, ашамас-эчмәс була. Бер елдан соң ул төшендә егетне янә күрә. Йосыф аңа болай ди:

Син бел шуны: син — минеке, мин — синеке,
Була күрмә миннән башка һичкемнеке. (131 б.)

Әтисе кызына берничек тә ярдәм кыла алмый. Табиблар да көчсез. Өченче елда Йосыф тагы кызның төшенә керә. Зөләйха аның кем булуын, кайда яшәвен сорый.

Йосыф әйтте: «Йа Зөләйха, әйтим шуны,
Мин Мисырның хөкемдары, бел син моны,
Мисырга кил, теләр булсаң әгәр мине,—
Табарсың син, шиксез, мине шунда имди...» (131 б.)

Һәм кызга сабыр итәргә куша.

Зөләйха, үзенә килгән бик күп яучыларны кире кагып, Мисыр хөкемдарына кияүгә чыгарга карар кыла. Бу хакта Тәймус Мисырга хат яза. Илнең ул чактагы хөкемдары Кыйтфир, ризалыгын белдереп, җавап җибәрә.

Менә зур кәрван, күп байлык белән Зөләйха Мисырда. Аны Кыйтфир каршы ала. Мисыр хөкемдарының Йосыф түгел, башка кеше икәнен белеп, Зөләйха һушыннан яза. Аңына килгәч, хезмәтчеләре аны юата, сабыр кылырга кушалар. Шуннан кыз Мисырда Кыйтфир хатыны булып калырга риза була. Әмма тышкы яктан гына. Ходай Тәгалә аны Кыйтфирдан саклый: Зөләйха урынына «пәри кызын» җибәреп тора.

Җиде ел гомер үтә. Кыйтфир кол сатылу хәбәрен ишетә. Аны үз янына чакырта. Йосыфны китерәләр. Зөләйха, аны күреп, һушын җуя. Исенә, акылына килгәч, «колны» сатып алуларын үтенә. Ире риза була. Малик сатып алучыдан Йосыфның «авырлыгы кадәр» алтын сорый.

Кыйтфир шундук мондый шартка риза булды,
Шул ук сәгать хәзинәгә үзе барды,
Үлчәүгә ул нәкъ биш йөз алтын куйды,—
Барлык алтын Йосыф кадәр тартмас имди. (141 б.)

Алтынга өстәп, хөкемдар бөтен байлыгын сала. Әмма барыбер алар Йосыф авырлыгын тартмый. Шунда Кыйтфир болай ди:

Бу бәһагә бөтен дөнья малы җитмәс,—
Җитмәгәнен бүләк ит син миңа имди. (141 б.)

Дәгыйр бу шартка риза була. Әмма бераздан Йосыфны хөкемдарга сатуына һәм бүләк итүенә үкенә. Элеккеге колы аңа үзенең кемлеген сөйләп бирә.

Кыйтфир исә «хәзинәдә алтын-көмеш һич калмады, мохтаҗлыкка төштек» дип пошаманда кала. Йосыф аңа хәзинәдәге бөтен малының да үз урынында булуын әйтә. Моның шулай икәнлеген белеп, хөкемдар хәйран кала.

Кыйтфир Йосыфны карау, тәрбияләү эшен Зөләйхага тапшыра.

> Тырыш миннән артык аны олыларга,—
> Йосыф безнең үз углыбыз булсын имди. (147 б.)

Зөләйха аны олылый, хөрмәтли, «өч йөз алтмыш төрле кием» генә әзерли, чәчләрен тарый, үрә. Әмма гыйшкыннан «һич сабыры калмас» иде: йокыдан яза, йөзе сула, ашау-эчүне оныта. Ире нишләргә белми.

Бервакыт Зөләйха үз хәлен яшермичә даясенә, ягъни хезмәтче хатынга сөйләп бирә.

> Дая әйтте: «Малың сарыф кылу кирәк,
> Гыйшкың өчен малың корбан булу кирәк,
> Мал-мөлкәттән күңлең тәмам тую кирәк,—
> Гашыйк булсаң, бар хәзинәң түк син имди!» (155 б.)

Зөләйха, дая киңәше буенча, «күргән кеше хәйран калырлык» сарай төзетә. Эчендә төрле сурәтләр. Арада Зөләйха һәм Йосыф рәсемнәре дә бар. Сарай әзер булгач, Зөләйха, киенепясанып, тәхеткә утыра, үз янына Йосыфны дәштерә һәм егеткә мәхәббәт хисләрен аңлата. Әмма Йосыф гөнаһ кылудан, Кыйтфирга хыянәт итүдән баш тарта, Зөләйханы ашыкмаска, сабыр итәргә өнди. Зөләйха ишеккә юнәлгән Йосыфны, куып җитеп, «итәгеннән ныклап тота».

> Арт итәге Йосыфның ертылып китте,—
> Тыш капкадан ал-артлы чыгарлар имди. (171 б.)

Аларның чыгуын Кыйтфир күреп кала. Шунда Зөләйха Йосыфны «әдәпсезлек»тә гаепли, аны җәзаларга куша. Йосыф исә үзенең гөнаһсыз булуын әйтә. Аның гаепсезлеген бер айлык бала да телгә килеп раслый: «Арт итәге ертык кеше гаепсез имди». Шунда Кыйтфир Зөләйханың гаепле булуын төшенә, аны битәрли, егеттән гафу үтенә.

Мисырдагы бер төркем хатын-кызлар арасында Зөләйханың үз колына гашыйк булуы хакында сүз тарала. Бу хәлне белеп, Зөләйха зур мәҗлес җыя.

> Ул хатыннар көрсиләргә утырдылар,
> Берәр пычак һәм әфлисун тоттырдылар:
> «Әфлисунны турагыз!»— дип боердылар,—
> Нәкъ шулвакыт Йосыф килеп керер имди. (177 б.)

Хатыннар, егетнең гүзәллеген күреп, әфлисун урынына бармакларын турый башлыйлар.

Зөләйха әйтте: «Инде сез күрдегезме,
Йөзем нидән сулганлыгын белдегезме,
Бер күрүдә кулыгызны кистегезме,—
Акылыгыз җуйдыгызмы?» — дияр имди. (177 б.)

Зөләйха карар кыла: Йосыфны я әмеремә буйсындырам, яисә зинданга яптырам. Егет соңгысын сайлап ала.

Кыйтфир үлеп китә, солтанлык аның кардәше мәлик Рәййанга күчә. Йосыф зинданда утыра. Хөкемдарның элеккеге икмәкчесе һәм шәрабчысы да аның белән бергә. Бу ике зат бервакыт төш күрә. Йосыф аларның төшен юрый: шәрабчының азат булып, элеккеге хезмәтенә кайтачагын, ә икмәкченең үтереләчәген әйтә. Чыннан да, аның сүзләре дөрескә чыга.

Мисыр шаһы Рәййан бервакыт җиде симез сыер һәм җиде арык сыер күрә. Симезләренең аркаларына менеп йөри. Арыклары симез сыерларны ашый.

Тагын күрдем тулып җиткән җиде башак,
Йәнә корып-кибеп беткән җиде башак,
Бодайлары очып китте күккә шулчак,
Тик өч бөртек җирдә торып калыр имди. (195 б.)

Патшаның бу төшен берәү дә юрый алмый. Төрмәдән азат булган шәрабчы Йосыф хакында әйтә. Рәййан аның янына барырга куша. Йосыф солтан күргән төшне болай юрый:

...Нәкъ җиде ел иген уңа,
Төрле нигъмәт-азык белән дөнья тула,
Аннан соңрак корылык һәм кытлык була,
Нәкъ җиде ел зур авырлык булыр имди. (199 б.)

Алга таба исә «байлык-муллык» киләчәк.

Рәййан Йосыфны азат итәргә әмер бирә. Ул, Йосыфның матурлыгын, акыллылыгын күреп, аңа «мөлкәт-тәхтен» тапшыра, үзе мөселман динен кабул итә.

Йосыф гаделлек белән идарә итә. Туклык елларында күп итеп ашлык әзерләтә. Корылык башлангач, икмәк биреп, барлык Мисыр халкын үзенә карата. Ашлык беткәч, кешеләр, Йосыфның матурлыгына карап, «ашау-эчүләрен» оныталар.

Зөләйха картая, күзләре күрмәс була. Әмма ул Йосыфны һич оныта алмый, мөселман динен кабул итә. Бервакыт Йосыф күп санлы гаскәр белән узып барганда, аның каршысына Зөләйха килеп чыга. Карчыктан хөкемдар кемлеген сорый. Зөләйха үзенең хәл-әхвәлен кыскача әйтеп бирә. Мәхәббәтенә дәлил итеп, Зөләйха Йосыфның камчысына өрә, камчы шунда

ук яныи китә. «Ул ут мине кырык ел көйдерә имди»,— ди хатын. Тәңренең кодрәте белән ул элеккеге кебек яшь, гүзәл рәвеш ала. Никах укыла. Йосыф Зөләйханың саф булуын белә. Алар гомер буе бергә торалар, унике уллары була. Олысы — Мөсалим исемле.

Ачлык Кәнган иленә дә килә. Ягъкуб 10 углын, ашлык сорап, Мисырга җибәрә. Ибне Йәмин өйдә кала. Йосыф агаларының килгәнен белеп сөенә, мәҗлес җыя, туганнарын кунак итә. Аларны улы Мөсалим һәм вәзире сыйлый. Бу хәлгә Йосыфның ун кардәше аптырый. Бераздан аларны хөкемдар үзе кабул итә, сораша. Агалары этиләре хакында, Йосыф белән булган хәлләр турында сөйлиләр, икмәк бирүен үтенәләр. Йосыф бушка күп ашлык, бүләкләр бирә. Әмма туганнарының берсен Мисырда калдыра һәм икенче килүдә Ибне Йәминне алып килергә куша. Тегеләре нәкъ шулай эшлиләр дә. Кече туганын Йосыф үзе каршылый. Әңгәмә кора. Беләзек бүләк итә. Әмма үзенең кемлеген сиздерми.

Йосыф гаҗәеп зур, гүзәл сарай салдыра. Аның диварларына этисенең, туганнарының сурәтләрен, үзенең ничек итеп кол булып сатылуын ясата. Сарайга кунакка туганнарын чакыра. Тегеләре рәсемнәрне күреп куркып калалар, гөнаһ эшләре өчен үкенәләр, «егълыйлар». Шуннан Йосыф аларны икенче сарайга дәшә. Агалары ашый-эчә. Әмма Ибне Йәмин һаман елый. Кабат теге сарайга кайтып рәсемнәрне карый. Аны Мөсалим озатып йөри. Һәм шунда үзенең кемлеген әйтә. Куанышалар. Йосыф та йөзеннән пәрдәсен ала. Ике туган эч серләрен уртаклашалар. Ибне Йәмин үзенең унике улы барлыгын, аларның исемнәрен әйтә (ул исемнәр «бар да синең кайгың белән багълы имди»). Йосыф энесенә болай ди:

«...Синең йөккә мин бер кясә (савыт.— *Х. М.*)
яшерермен,
Шуны табып, угры ул дип белдерермен,
Шулай итеп, үз янымда калдырырмын,—
Минем белән бер сүздә бул»,— дияр имди. (249 б.)

Бераздан нәкъ шулай эшләнә дә. Йосыф Ибне Йәминне һәм Йәһүдәне үз янында калдыра. Тегеләре кайтып китә. Ягъкуб бик нык кайгыра. Мисыр хөкемдарына, улын азат итүне үтенеп, хат яздыра.

Пәйгамбәрләр беркемнең дә малын алмас,
Мәгълүм инде, алар бозык эшкә бармас,

Угланнары шулай ук угрылык кылмас,—
Гаепләнгән нахакка ул, шиксез, имди. (261 б.)

Уллары, ул хатны алып, янә Мисырга киләләр. Йосыф этисенең хатын укый, үзе дә җавап яза. Ягъкуб бу хатта язылганнарны «Пәйгамбәрләр сүзе бу сүз!» дип кабул итә. Улларын Йосыф янына җибәрә. Йосыф, ниһаять, үзенең кемлеген туганнарына белдертә, аларның гөнаһларын гафу итә. Бәшир исемле бер колы аркылы Ягъкубка хат һәм үзенең күлмәген җибәрә. Сукыр карт шул күлмәк белән йөзен сөртә: аның күзләре ачыла. Хатны укыгач, Йосыфның исәнлеген белә. Бераздан Ягъкубның башка уллары да кайта. Этиләре аларның языкларын кичерә.

Ягъкуб үзенең бөтен гаиләсе белән Мисырга күчеп килә. 70 ел аерым торганнан соң, Йосыф белән этисе очраша.

Ягъкуб Мисырда 40 ел яши. Һәм ахырда Кәнганга кайтып вафат була.

Дин мәсьәләсендә Йосыф белән Рәййан арасында каршылык чыга. Шуннан Йосыф, барлык мөселманнарны җыеп, Мисырдан икенче бер җиргә күчеп китә. Яңа шәһәрнең нигезен сала. Аңа «Әмин» дип исем бирә, шәһәрдә мул тормыш урнаша.

Ул арада Зөләйха да вафат булды,
Кайгысыннан Йосыф тәмам зәгыйфьләнде,
Аннан соңра өйләнмәде, ялгыз торды,—
Угланнарын тәрбияләп яшәр имди. (289 б.)

Бераздан Йосыф үзе дә үлеп китә. Аның табутын әүвәл Мисырга урнаштыралар, аннан Кәнганга — атасы кабере янына кайтаралар. Шуның белән әсәрнең сюжеты төгәлләнә.

Поэманың сюжет нигезе. Борынгы һәм Урта гасыр әдәбиятларында билгеле, моңа кадәр теге яки бу дәрәҗәдә эшкәртелгән сюжетлар, образлар, материаллар белән эш итү — киң таралган күренеш. Прометей, Фауст, Александр Македонский (Шәрыкта ул Искәндәр Зөлкарнәйн дип йөртелгән), Ләйлә — Мәҗнүн, Таһир — Зөһрә, Ромео —Джульетта һәм башка мәгълүм затлар хакында төрле телләрдә гаҗәеп күп санлы әсәрләр язылу — шуның ачык билгесе. Йосыф кыйссасы да әнә шундый киң таралган, мәгълүм сюжетлар рәтенә керә. Ул үзенең тамырлары белән Якын Көнчыгыш халыкларының, иң беренче чиратта яһүдиләрнең, мисырлыларның, ассириялеләрнең, вавилоннарның һ. б.ның, борынгы мифологиясенә, фольклорына барып тоташа. Хәтта

кайбер галимнәр Йосыф образының һәм аңа бәйләнешле аерым вакыйгаларның тарихи нигезе булуын да искәртәләр. Йосыфның акыллы, зирәк вәзир булуы, корылык, ачлык елларында илне һәлакәттән саклап калуы күп кенә борынгы чыганакларда теркәлеп калган.

Йосыф турындагы аерым материаллар яңа эрага кадәр үк яһүдиләрнең изге китабы Тәүратта (Библиядә) гәүдәләнеш тапкан. Анда ул пәйгамбәр сыйфатында бирелә. Бу образ христианнарның изге китабы Инҗилгә (Евангелиегә) дә кертелгән.

Мәгълүм булганча, VII гасырның беренче яртысында Корьән төзелә. Анда, борынгы мифологик, фольклор материаллары белән берлектә, яһүдиләрнең һәм христианнарның изге китапларындагы аерым мәгълүматлар да чимал рәвешендә файдаланыла. Алар арасында Йосыф хакындагы сюжет та бар. Ул Корьәннең 12 нче сүрәсе итеп урнаштырылган.

Йосыф сюжеты фольклор һәм язма чыганаклар аша да, яһүди, христиан һәм мөселманнарның изге китаплары аркылы да бөтен дөньяга тарала, күп санлы әдәбият, сәнгать әсәрләре тууга этәргеч ясый. Мәсәлән, X—XI гасырларда иҗат эше белән шөгыльләнгән фарсы шагыйре Фирдәүси Йосыф — Зөләйха сюжетына поэма яза. Урта гасыр Шәрык укучылары арасында атаклы суфи Габдулла Әнсарига (1002—1088) нисбәт ителүче «Әнисел мөридин вә шәмсел мәҗалис» («Мөритләрнең дуслары һәм мәҗлесләрнең кояшы») исемле ядкяр дә бик популяр була. Бу чәчмә әсәрнең үзәгендә — шулай ук Йосыф — Зөләйха темасы. Болардан тыш, госманлы Шәйяд Хәмзәнең (XIII йөзнең икенче яртысы), таҗик Җаминың (1414—1492), үзбәк Дөрбәкнең (XV йөз башлары) һәм башка күп кенә әдипләрнең бу сюжетка әсәр язулары мәгълүм. Татар язучыларыннан Мәхмүд Болгари (XIV гасыр), Мәҗит Гафури, Кәрим Әмири, Зәйни Шаһиморатов, Нурмөхәммәд Хисамов һәм башкалар да Йосыф — Зөләйха сюжеты нигезендә яңа әсәрләр тудыралар.

Йосыф темасы Европа әдипләренең дә игътибарын үзенә җәлеп иткән. Немец язучысы Томас Манның дүрт томлык «Йосыф һәм аның туганнары» романы (1933—1943), латыш әдибе Янис Райниснең мәшһүр пьесасы (1919) — шуның ачык дәлиле.

Кол Гали, төрки әдипләрдән беренчеләрдән булып, Йосыф турындагы билгеле сюжетка мөрәҗәгать итә һәм оригиналь яңгырашлы, мөстәкыйль идея-эстетик кыйммәткә ия булган әсәр тудыра. Ул үз китабына нигез итеп Корьәндәге Йосыф сүрәсен ала.

Һәр ике текст та Йосыфның төш күрүеннән башлана. Төшне юрау, агаларының Йосыфны коега салуы, аннан сатып җибәрүләре һ. б. төп күренешләр һәм вакыйгалар әсәрдә Коръәндәге тәртиптә бара. Гомумән, изге китаптагы эчтәлек тулысы белән диярлек «Кыйссаи Йосыф»та гәүдәләнеш тапкан. Әмма болгар-татар әдибенең әсәрендә Коръәндә булмаган шактый гына эпизодлар да бар. Бүренең һәм дөянең телгә килүе, «Йосыф коесының сыйфатлары», Малик Ибне Дәгъйр белән бәйләнешле вакыйгалар, Зөләйха тарихы, сарай салдырулар, «Кәнган гарәбе кыйссасы», Йосыфның гаилә коруы, үзенә ничек вәзир сайлавы һ. б. — әнә шундыйлардан. Коръәндәге сүрә Йосыфның атасы белән очрашу күренешен тасвирлау белән төгәлләнә. Кол Гали әсәрендә исә төп каһарманнарның ахыргы гомерләрен сурәтләү дә бар.

Изге китап белән «Кыйссаи Йосыф» арасындагы башка күптөрле аермалыкларны да күрсәтергә мөмкин. Мәсәлән, Коръәндә Йосыф — Зөләйха мәхәббәте бөтенләй юк. Хәтта Зөләйханың исеме дә телгә алынмый. Ул — ниндидер бер кешенең хатыны. Кол Гали изге китапта атап кына кителгән урыннарны еш кына киңәйтә, җанландыра. Мәсәлән, Коръәндә туганнары Йосыфны юк кына бәягә сатып җибәрделәр диелә. «Кыйссаи Йосыф»та исә бу эчтәлек шактый тәфсилләп берничә биттә бирелә.

Кол Гали аерым вакыйга-күренешләрне Фирдәүси, Әнсари әсәрләреннән һәм кайбер башка чыганаклардан да ала. Әмма поэмада «Кыйссаи Йосыф» авторы үзе керткән факт-мәгълүматлар да шактый. Мәсәлән, Г. Таһирҗанов фикеренчә, Йосыфның гыйбрәтле язмышын сарай диварларында рәсемнәр аша тәфсилле гәүдәләндерү Кол Гали әсәрендә генә күзгә ташлана.

Борынгы һәм Урта гасыр әдәби истәлекләре белән эш иткәндә, бер мөһим хакыйкатьне истә тоту зарури: аларда сюжет яңалыгы беренче планда тормый, хәлиткеч роль уйнамый. Иң әһәмиятлесе — авторларның таныш материаллар белән ничек эш итүе, нинди әдәби әсәр коруы, анда нинди уй-кичерешләрне гәүдәләндерүе. Кол Гали исә, билгеле сюжеттан иҗади файдаланып, оригиналь формалы, вакытның җил-яңгырына түзәрлек мәһабәт бина корып калдырган. Инде менә ничә гасыр буена ул бина, ягъни «Кыйссаи Йосыф», нур бөркеп, укучыны җылытып килә! Мондый бәхет әдәбият тарихында бик сирәк әсәрләргә генә насыйп була.

Әсәрнең идея-проблематикасы.

Ни өчен соң Йосыф турындагы сюжет меңәр еллар буе укучыларның, әдипләрнең игътибарын үзенә җәлеп итеп тора? Әлбәттә, моның сәбәпләре күптөрле. Беренчедән, Йосыф вакыйгасы мифология, халык иҗаты белән тыгыз бәйләнешле. Анда бай фантазия ярдәмендә халыкның уй-хыяллары, иҗтимагый, әхлакый идеаллары гәүдәләнеш тапкан. Икенчедән, бу сюжетның киң таралуына аның изге китапларга кертелүе дә зур йогынты ясаган. Өченчедән, Йосыф темасы эчке каршылыкларга бай. Бу исә үз чиратында әдәби әсәр өчен зарури булган конфликт тудыруга, укучының күңел дөньясын кузгатуга менә дигән мөмкинлек бирә. Дүртенчедән, Йосыф сюжеты билгеле бер чор, җирлек белән конкрет бәйләнмәгән. Андагы Кәнган, Мәгъриб, Мисыр кебек атамалар, нигездә, шартлы мәгънәдә алынганнар. Иң мөһиме шул: бу традицион материалда, гомумән, кеше, яшәеш өчен хас булган аерым күренешләр, сыйфатлар гәүдәләнгән. Алар белән һәр чор әдибе, укучысы мөнәсәбәткә керә, аларны иҗади эшкәртә: кабул итәрдәен кабул итә, үзенә аваздаш булмаганын кире кага. Кыскасы, Кол Гали әсәренең идея-проблематикасы хакында сүз барганда, югарыда телгә алынган әнә шул дүрт факторны истә тоту зарури.

Һәр әдип, ул кайчан гына яшәп, нинди генә әсәр иҗат итсә дә, үз алдына, төп максат итеп, кеше проблемасын яктыртуны куя. Ягъни кеше кем ул, аның асылы, иҗтимагый вазифасы, яшәү мәгънәсе нәрсәдән гыйбарәт? Шушы гомуми сорауларга һәр автор конкрет уй-кичерешләр, җанлы вакыйгалар аша үзенчә җавап бирергә омтыла. «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә исә кеше проблемасы аеруча кискен куелган һәм аның әдәби гәүдәләнеше дә шактый кызыклы.

Кол Гали поэмасы — жанры белән биографик характердагы әсәр. Чөнки анда башыннан алып азагына кадәр Йосыф язмышы гәүдәләнә. Вакыйга балигъльк яшенә якынаеп килүче Йосыфның төш күрүе белән башланып китә. Бу төш этисе янында бәхетле, имин тормыш кичерүче Йосыфның гомер юлын бөтенләй икенче якка борып җибәрә: ул үлем алдында да кала, коега да салына, кол итеп тә сатыла, матурлыгы белән кешеләрне дә сокландыра, сабырлыгы аркасында нахакка зинданга да эләгә, хөкемдар да була... Ягъни язмыш төп каһарманны төрлечә сыный. Төрле шартларга куелу аның нindилеген, асылын ныграк күрергә, аңларга ярдәм итә.

Кол Гали Йосыф мисалында идеал кеше образын туды-

рырга омтыла. Бу максатка ирешүдә төп каһарманның мәгълүм пәйгамбәр булуы авторга иҗади мөмкинлек тудыра. Пәйгамбәр кем ул? Иң беренче чиратта ул — алдан күрүче, тирән фикерләүче, башкаларга юл күрсәтүче, үрнәк кеше; матур сыйфатларга, эш-гамәлләргә ия булган мөхтәрәм инсан. Йосыф та әсәрдә нәкъ әнә шул рәвештә тасвирлана. Алланың берлегенә һәм барлыгына, ислам диненең хаклыгына ышану —аның төп сыйфаты. Ул күп аллачылыкка, сыннарга табынуга каршы. Әмма Йосыф башка дин тотучылар белән дә әдәплелек, кешелеклелек кагыйдәләрен саклап эш итә, аларны рәнҗетми, эзәрлекләми. Кяферләр белән мөнәсәбәттә аның төп чарасы — дәлилләү, ышандыру, аңлату.

Үз элгәрләре Ясәви, Бакырганый кебек үк, Кол Гали өчен дә Алла, илаһият — көч-кодрәт, гаделлек, шәфкать иясе. Ул галәмдәге барлык уңай сыйфатларның, игелекле эш-гамәлләрнең тупламы, чыганагы, өлгесе, символы рәвешендә күзаллана. Менә шундый олуг Тәңре — Йосыф өчен төп үлчәм, өлге. Ул һәр адымын, һәр эш-гамәлен илаһият белән яраклаштырырга омтыла.

Йосыфтагы хәлиткеч сыйфатларның берсе — тугрылык. Әсәрдә бу эпитет «сыйддыйк» рәвешендә берничә мәртәбә бирелә. Бу сүз, тугрылык төшенчәсеннән тыш, ихласлылык, дөреслек кебек мәгънә төсмерләрен дә үз эченә ала. Коеда утырганда Йосыф Алла тарафыннан пәйгамбәр дип игълан ителә һәм шунда тәүге мәртәбә «сыйддыйк» дип атала.

Йосыф кемгә тугрылыклы соң? Иң беренче чиратта гаделлек, кодрәт, намус кебек күркәм сыйфатларның символы булган Тәңрегә. Илаһияткә тугрылык ул — үз намусыңа да тугрылык дигән сүз. Чөнки кешенең асыл, затлы сыйфатлары турыдан-туры Тәңрегә барып тоташа.

Йосыф сабый чакта ук әнисез кала. Ягъкуб — аның өчен ата гына түгел, ана да. Шуңа күрә Йосыф һәрчак атасына хөрмәт, ихтирам белән карый, аңа тугрылыкны үзе өчен иң изге гамәлләрнең берсе дип саный. Атага тугрылык әсәрдә туган җиргә, туган илгә, туган халкыңа да тугрылык булып аңлашыла. Ягъкубның, ахыр чиктә Йосыфның да Кәнган илендә күмелүе күп нәрсә хакында сөйли.

Муса табутны Кәнганга алып килде,
Аталары кабре кайдалыгын белде,
Табутны шуларның янына күмдерде,—
Бүген дә халык анда барып йөрер имди. (291 б.)

Димәк, Йосыф кебек асыл затлар онытылмый. Аларның кабере — халык өчен зиярәт кылу урыны. Кол Галидәге бу мотив Котб, Пушкиннар аша Җәлилгәчә килеп җитә:

Эш күрсәткән ирне ил онытмас,
Каберенә эзне суытмас.

Коръәндә үк макталган сабырлыкны тасвирлауга Кол Гали дә нык игътибар итә һәм бу сыйфатны кеше идеалының мөһим бер өлеше итеп карый. Сөйгән улы Йосыфны югалткач, Ягъкуб мондый нәтиҗәгә килә:

Йагъкуб әйтте: «Бу казалар Тәңредәндер,
Сабырсызлык бөекләрне түбән кылыр,
Мин кылырмын инде моңа күркәм сабыр,—
Сабыр белән морад хасил булыр имди». (87 б.)

Ә инде сабырлык — Йосыфның табигатен, һәр эш-гамәлен бизи торган сыйфат. Ул кыен чакта гына түгел, чагыштырмача имин вакытта да сабыр итә белә. (Зиннәтле сарай эчендә Зөләйха белән очрашу күренешен генә искә төшерегез!) Аның фикеренчә, сабырлык кешене намуссызлыктан саклый, рухи яктан үстерә, баета. Йосыф бу мөһим сыйфатны башкаларда да күрергә, булдырырга тели. Зөләйха күргән төштә Йосыф аңа болай ди:

Сабыр белән эшлә, ләкин син бу эшне,
Сабыр белән эшләнә һәр эшнең башы,
Морадына тиз җитә сабырлы кеше,—
Мондый эштә күркәм (күрекле) сабыр
кирәк имди. (133 б.)

Автор сабырлыкны кешеләрнең инсанлыгын (кешелеклелеген) сынаучы бер бизмән рәвешендә дә карый. Ни өчен Зөләйха мәхәббәттә дәвамлы газапларга дучар була?Чөнки ул сынга табына, Йосыф киңәшен тотмыйча, сабырсызлык кыла. Бары тик михнәтләр кичерү генә аңа үз хаталарын аңларга, алардан котылырга ярдәм итә. Күзләре сукырайган, картаеп беткән Зөләйха Мисырның мәшһүр хөкемдары Йосыфка болай ди:

Икърар итеп, инандым Хакъ берлегенә
Һәм инандым синең пәйгамбәрлегеңә,
Калмады һич шигем Хакъ мөэминнәргә,—
Үзем дә чын мөэмин булдым, дияр имди. (215 б.)

Шуннан соң Зөләйха, нәкъ әкият каһарманнары кебек, Алланың кодрәте белән кабат яшәрә («күзе ачыла, япь-яшь

була», «йөзенең нуры тулган айдай балкый») һәм Йосыф белән никах кыла, шулай итеп, михнәттән соң рәхәткә, үз максатына ирешә.

Автор фикеренчә, идеаль кешенең тышкы кыяфәте дә аның эчке дөньясы белән туры килергә тиеш. Ягъни ике арада ярашу, гармония булу шарт. Шуңа күрә Кол Гали Йосыфның искиткеч гүзәл, нурлы булуына даими басым ясый:

Йөзендәге пәрдәне ул салу белән,
Сарайдан нур тышка балкып чыгар имди. (123 б.)

Йосыфның матурлыгы ул — эчке, илаһи гүзәллекнең тышкы гәүдәләнеше. Аның балкышы кешеләргә көчле тәэсир итә, хәтта кытлык елларда ачларны үлемнән саклап кала.

...Мәйданга ул аена бер чыгар иде,
Йөзеннән пәрдәсен ачып куяр иде,
Олугъ-кечек, бай һәм юксыл карар иде,—
Соңра бер ай ашамыйча түзәр имди. (205 б.)

Поэмада Йосыф образына җыйнама характеристика да бирелә. Сату алдыннан, аның «ун төрле һөнәре бар»лыгы игълан ителә:

Беренчедән — буе зифа, сылу үзе,
Икенчедән — күрекле һәм нурлы йөзе,
Өченчедән — теле бик саф, тугры сүзе,—
Җитмеш ике телне тәмам белер имди!

Дүртенчедән — кешелекле һәм шәфкатьле,
Бишенчедән — Алып батырдай йөрәкле,
Алтынчыдан — бик күпләрдән ул куәтле,—
Көч-куәте кырык ирдән артык имди.

Җиденчедән — дине бөтен, диянәтле (аллачыл),
Сигезенче — хыянәтсез, әманәтле,
Тугызынчы — холкы гүзәл, теле татлы,
Унынчыдан — пәйгамбәрләр нәсле имди. (141 б.)

Бу тасвирламадан Йосыфта әкият, дастан каһарманнарына хас сыйфатлар да булуы күренә. Мәсәлән, ул — Алып батырдай кыю, куәтле. Мисырга барганда, Йосыф үзен куа килгән Кодес бәгенең 12 меңлек гаскәрен бер карау белән «һушсыз» итә.

Шунысы мөһим: автор төп каһарманын сөттән ак, судан пакь рәвештә генә күрсәтми, аның аерым хаталарына да игътибар итә. Мәсәлән, Йосыф ни өчен кол итеп сатыла? Чөнки ул берчак көзгегә карап масаеп алган була:

Әйа, Йосыф, син көзгегә бактың бер көн,
Бик масайдың, ул көзгедә күреп күркең,
Әйттең: «Мин сатылыр бер көн кол булсам, һичкем
Чын бәһамне түли алмас»,— дидең имди. (193 б.)

Малик Ибне Дәгыйр кәрванындагы Йосыфны күреп, кешеләр таң калалар, мөселман диненә күчәләр. Кодес бәге гаскәрен җиңү дә төп каһарман күңелендә үз-үзенә соклану хисен уята: «Миңа охшаш беркем дә юк!»— ди ул. Ходай Тәгалә әмере белән пәриләр яшәгән калада Йосыфка беркем дә игътибар итми. Шунда ул үзенең ялгышуын аңлый. Йосыф холкының үзенчәлеге шунда: ул мондый хаталанулардан тиешле нәтиҗә ясый, Алладан гафу үтенә.

Кыскасы, Йосыф образында авторның кеше, камил инсан турындагы күзаллаулары, уй-кичерешләре шактый тулы гәүдәләнеш таба. Кеше идеалына мөнәсәбәттә Кол Гали күптөрле мөһим мәсьәләләрне яктырта. Инде аларның кайберләре (кеше һәм Алла, тугрылык, ата һәм бала һ. б.) хакында сүз булды. Хәзер исә шул идея-проблемаларның берничәсенә тукталып китик.

Хәтерлисездер: «Котадгу белек»тә төп мәсьәләләрнең берсе хөкемдар проблемасы иде. Йосыф Баласагунлыдан үзгә буларак, Кол Гали бу мәсьәләне Йосыф образы белән тыгыз бәйләнештә, дөресрәге, аның эш-гамәле аркылы яктырта.

Поэманың төп каһарманы, әкият-дастаннардагы кебек, төрле кыенлыклар, сынаулар аша, үзенең зирәклеге, алдан күрүчәнлеге ярдәмендә хакимияткә килә. Дөрес, ул илнең шаһы түгел. Әсәрдән бу урынны мәлик Рәййанның биләве аңлашыла. Әмма чын идарәчелек, төп хакимият — Йосыф кулында.

Кол Гали фикеренчә, ил белән Йосыф кебек һәр яктан камил затлар, пәйгамбәрләр идарә итәргә тиеш. Бары шунда гына халык төрле авырлыкларны, шул исәптән ачлыкны да, исәнимин кичерә ала. Гомеренең ахырында баш каһарманның, Мисырны ташлап, башка җиргә күчүе, анда шәһәр коруы, Әмин дип аталган ил-каланың «нигъмәт белән тулуы», Мисырга исә зур кытлык килүе — болар бар да Йосыфның игелекле, кодрәтле, гадел хөкемдар булуын ачык күрсәтеп торалар.

Шунысын да искәртик: Йосыф, хакимият башлыгы буларак, кирәк вакытта кырыс та, каты куллы да, хәтта хәйләкәр дә була белә. Бу бигрәк тә ачлык елларында, агалары белән мөнәсәбәттә, сарай салдыру күренешләрендә ачык күренә. Мәсәлән, агалары Ибне Йәминне алырга килгәч, Йосыф аларга үзен кол итеп сатканда язуларын (аны Шәмгун язган була)

күрсәтә. Тегеләре аңламаганга сабышкач, Йосыф аларның ялган эш-гамәлләрен ачып сала һәм болай ди:

Сезнең берәр кулыгызны кистерермен,
Һәммәгезне муйныгыздан астырырмын,
Барчагызны мин җәзалап үтерермен,—
Сез Йосыфка кылган җәбер өчен имди! (265 б.)

Агалары куркып кала, Йосыфтан шәфкать-мәрхәмәт сорыйлар. Дастандагы төп каһарманның олылыгы, киң күңеллелеге, гаделлеге шунда: ул үз гаебен таныган кешеләрне кичерә, гафу итә белә. Хөкемдар буларак, аның кан түккәне әсәрдә телгә алынмый. Бу — әхлакый яктан бик мөһим момент.

Дастанда мондый күренеш бар: Малик Ибне Дәгыйр Йосыфны сатарга җыена. Моны ишетеп, сарайга кешеләр агыла башлый. Мисыр хөкемдары Кыйтфир да, Зөләйха киңәше белән, Йосыфны сатып алырга ниятли. Малик Ибне Дәгыйр исә аннан төп каһарманның үз авырлыгы кадәр «алтын» һәм «тагын малның күп төрлесен» сорый. Әмма хөкемдар хәзинәсендәге бөтен «алтын-көмеш», «җөмлә мал» да Йосыф кадәр тартмый. Шуннан Малик Ибне Дәгыйр «бу бәһагә җиткән кадәр»енә түләү ала, ә калганын хөкемдарга «бүләк кыла».

Әсәрдәге бу кол сату күренешенең тирән, символик мәгънәсе дә бар. Беренчедән, ул коллык, кешене алу-сату шөгыленең гайре табигый хәл булуын күрсәтә. Икенчедән, Йосыф кебек затлы, идеаль кешеләрнең, пәйгамбәрләрнең бәһасез булуын дәлилли. Димәк, кеше үзе — табигатьнең, яшәешнең зур байлыгы. Кешене олылавы, хөрмәтләве белән Кол Гали поэмасы фәндә шартлы рәвештә Яңарыш (Ренессанс) дип йөртелгән күренеш белән тыгыз бәйләнешле. Йосыф кебек затларны һәм, гомумән, кешеләрне рәнҗетергә ярамый. Әгәр дә мондый ярамаган гамәлне кыласың икән, аның авырлыгы үзеңә төшә. Әгәр дә инде син кешеләргә, Йосыф кебек затларга игелек эшлисең икән, аның әҗере игелек булып кабат үзеңә кайта. Мәсәлән, Кыйтфирның Йосыфны сатып алганнан соң бушап калган хәзинәсе Алла кодрәте белән «кабат тула».

Ни өчен соң пәйгамбәр дәрәҗәсенә ия булган Ягъкуб кайгы-газапларга дучар була? Бу сорауга әсәрдән берничә төрле җавап табарга мөмкин. Ягъкубның 12 улы бар. Йосыф белән Ибне Йәминнең аниләре бер (Рәхилә), ә калган балаларының — башка. Ана төрлелеге үзе үк туганнар арасында каршылыклар туула җирлек бирә. Шунысы мөһим: Йосыф

бары Зөләйха белән гомер кичерә. Аның да 12 баласы бар. Әмма аларның ата-аналары бер.

Ягъкуб Йосыфны гадәттән тыш нык ярата, хәтта илаһилаштыру дәрәҗәсенә барып җитә. Атаның бер баласына гына мондый игътибары, әлбәттә, башка улларында көнчелек хисе тудыра.

Ягъкубның, яраткан улыннан аерылып, 70 ел буе аһ-зар белән яшәвендә янә бер җитди сәбәп бар. Әнисе Рәхилә үлгәч, Йосыф сабый килеш ятим кала. Аны карар өчен, Ягъкуб бер «карауаш» (тоткын) хатынны үзенә хезмәтче итеп ала. Бу хатынның яшь баласы була. Ягъкуб аны кол итеп сатып җибәрә. Сабыеннан аерылган хезмәтче хатын, нишләргә белмичә, аһ-зар кыла. Шунда автор Ходай Тәгалә исеменнән мондый сүзләр ишеттерә:

Халикъ әйтте: «Ә мин шулай боерырмын,
Аны да сөеклесеннән аерырмын,
Аерылу утларында яндырырмын,—
Нәкъ җитмеш ел егълатырмын аны имди!

Әүвәл сине(ң) углың белән күрештерәм,
Соңра аны Йосыф белән кавыштырам,
Кодрәт белән сүземне эшкә ашырам,—
Мин биргән сүз һич үтәлми калмас имди!» (269 б.)

Әсәрдә вакыйгалар нәкъ шул юнәлештә үсәләр дә. Шунысы мөһим: ул хатынның баласын (Бәшир исемле) Йосыф үзенә сатып алган була. Автор бу колны болай тасвирлый:

Холкы күркәм, үзе гаять мәрхәмәтле,—
Һәрбер эшне иглек белән эшләр имди. (271 б.)

Йосыф, хат язып, үзенең күлмәген биреп, нәкъ менә шушы Бәширне Ягъкуб янына җибәрә. Бала белән ана кавыша:

Йагъкубның өенә алар бергә керде,
Хатын шатлыктан нишләргә белми иде,
Бәшир, килеп, Йагъкубка күлмәкне бирде,
Йагъкуб йөзен сөртте — күзе ачлыр имди. (273 б.)

Димәк, кеше, ул кем генә булмасын (хәтта Ягъкуб кебек пәйгамбәр булса да), үз гамәле өчен үзе җавап бирә. Игелек игелек булып, яманлык яманлык рәвешендә, иртәме-соңмы, барыбер кабат үзеңә кайта.

Автор фикеренчә, бәхетле тормышның нигезе — бердәмлектә, татулыкта, иминлектә, кешелекле мөнәсәбәтләрдә.

Йосыф, Зөләйха белән гаилә корып, балалар үстерә, туганнары белән уртак тел таба, этисе белән кавыша, илдә гадел тәртипләр урнаштыра... Әсәр, гәрчә ул төп каһарманнарның үлеме белән тәгалләнсә дә, оптимистик, тормышчан рухлы. Йосыфның үлеме табигый күренеш буларак кабул ителә. Чөнки бу каһарман гомерен намус белән, кешеләргә файдалы, игелекле итеп үткәргән. Шуңа күрә ул халык хәтерендә мәңгелеккә уелган.

«Кыйссаи Йосыф»ның сәнгатьчә эшләнеше.

Теләсә нинди әсәрдә сәнгати як башка компонентлар белән тыгыз үрелеп, кушылып, укмашып бара. Шуңа күрә мәсьәләнең «сәнгатьчә эшләнеше» дип куелуы — чагыштырма шартлы күренеш. Без алдагы бүлекчәләрдә «Кыйссаи Йосыф»ның төзелешенә, сюжетына, идея-проблематикасына, әсәрнең поэтик ягына кагылышлы күп кенә фикерләр әйттек, мисаллар китердек. Хәзер исә бу мәсьәләгә махсус тукталып китәрбез.

Әсәрдә авторның уй-ниятләрен сәнгатьчә гәүдәләндерүдә, төп каһарманнан кала, Зөләйха да зур роль уйный. Аларның әдәби бирелешендә билгеле бер охшашлык та бар. Зөләйха да, Йосыф кебек, искиткеч гүзәл:

> Тулган айдай балкыр иде аның йөзе,—
> Оҗмахтагы хур кызына охшар имди. (129 б.)

«Тулган айдай балкыр иде аның йөзе» сурәтен автор Йосыфка карата да куллана. Зөләйха да — этисенең яраткан баласы. Ул да, Йосыф та, этиләре итәгендә йоклаганда, төш күрәләр. Һәм бу төш аларның һәр икесенең дә гомер юлларын икенче якка борып җибәрә: аталарыннан, туган йортларыннан аера, кайгы-шатлыкларга дучар итә... Әмма Йосыф акыл, сабырлык белән эш йөртә; бу аның гамәлендә дә, афористик сөйләмендә дә күренә[1]. Зөләйха исә — хис-тойгы кешесе. Аның бөтен күңелен, яшәешен мәхәббәт хисләре биләп алган. Йосыф белән кавышу — Зөләйха тормышының төп максаты. Бу юлда ул бик күп шаһзадәләрдән килгән яучыларны да кире бора, атасы йортын да калдыра, сөймәгән кешесе Кыйтфир белән дә торырга мәҗбүр була, байлыгын да сарыф итә, гайбәттән дә курыкмый... Зөләйха, нахак бәла ягып, сөйгәне Йосыфны зинданга да яптыра. Әмма психологик яктан аны бу ярамаган эше өчен

[1]Биредә, әлбәттә, Йосыфның изге китап белән бәйләнешле пәйгамбәр булуы да мөһим роль уйный. Мондый билгеле зат белән автор ничек теләсә, шулай эш итә алмый.

гаепләү авыр. Чөнки ул, Йосыф белән кавышу өчен, никадәр корбаннарга барды, ә сөйгәненнән җавап юк та юк. Мондый очракта кешенең акылсыз эш-гамәлләр кылуы, әлбәттә, билгеле бер дәрәҗәдә табигый дә. Шунысын да искәртик: Зөләйха уйламыйча эшләгән гамәле өчен үзе дә рухи газапка, әхлакый җәзага тартыла, сөйгәнен күреп тору бәхетеннән мәхрүм була, картая, сукырая. Зөләйха гыйшкы билгеле бер дәрәҗәдә Ләйлә, Ширин, Зөһрә мәхәббәтләрен искә төшерә.

Зөләйханың рухи халәтен тасвирлауда Кол Гали гаять кызыклы сурәтләү чаралары, әдәби алымнар куллана.

Ул бик мөшкел хәлдә сиздe, соңра үзен,
Берәр сәгать күрми торса Йосыф йөзен,
Сабры бетте, аңламады һичкем сүзен,—
Ни әйләсә, «Йосыф!» диеп әйтер имди. (149 б.)

Аңа тамырыннан кан алдырганда тамган кан да җиргә Йосыф исемен язган кебек күренә. Йолдызлар да әйтерсең Йосыф диеп эндәшә. Зөләйханың мәхәббәт ялкыны, сөйгәне өчен эчтән януы шулкадәр көчле, ул өргәч, Йосыфның камчысына «ут кабына».

Кол Гали, үз каһарманнарын тасвирлаганда, әкият-дастаннарга, борынгы төрки әдәбиятка хас булган гадәттән тыш арттыру алымын, сыйфат-күренешләрне максималь югарылыкка күтәреп сурәтләү ысулын яратып куллана. Мәсәлән, Йосыф хакында мондый юллар бар:

Дөньяда һич синдәй кеше булганы юк,
Сиңа охшаш бер кеше дә туганы юк,
Мондый сыйфат беркемдә дә булганы юк,—
Әллә син бер фәрештәме?—дияр имди. (125 б.)

Йосыфның туганы Йәһүдә шундый тавышка ия ки, ул кычкырса, «ишеткәннәрнең барысы да һәлак була».

«Кыйссаи Йосыф» әсәрендә сыйфатны сан аша тасвирлау һәм, гомумән, саннар символикасыннан файдалану еш очрый. Йосыф 72 тел белә, аның көче «кырык ирнең» куәтеннән артык. Зөләйха Йосыфка «өч йөз алтмыш төрле кием әзерләтә». Ата белән угыл 70 ел аерым торалар.

Поэмадан мондый мисалларны күпләп китерергә мөмкин. Алардагы саннар, туры мәгънәдән бигрәк, күплекне, гадәттән тыш арттыруны белдерәләр. Шунысына да игътибар итик: саннарның, нигездә, теләсә нинди түгел, ә символик мәгънәгә ия булганнары күбрәк алына. Мәсәлән, Мисыр патшасының

төшендә җиде саны еш кабатлана: җиде симез сыер, җиде арык сыер, җиде тук башак, җиде ач башак. Мәгълүм булганча, табигатьтәге аерым күренешләр белән бәйләнгән бу сан (атнаның җиде көне, җиде планета, җиде төс һ. б.) мифологиядә, фольклорда һәм язма әдәбиятта образлы, символик вазифа үти. Өч саны белән дә шундый ук хәл: Зөләйха Йосыфны өч мәртәбә төшендә күрә, агалары үз туганнарының «өч төрле гаебе барлыгын» күрсәтәләр.

Поэмада каһарманнарның яшьләрен бирүдә дә шартлылык, экияти традицияләргә иярү күзгә ташлана. Мәсәлән, Кәнган коесындагы Заһидка (изге кешегә) — 1200 яшь. Укучыга 11 яшьтә дип тәкъдим ителгән Йосыф 50 елдан артык коеда, 12 ел зинданда утыра, 30 яшендә хөкемдар булып, бик озак вакыт Мисыр белән идарә итә, 60 еллап гомерен Әмин каласында уздыра. Шактый өлкән яшьтәге Ягъкуб улыннан 70 ел буе аерылып тора, аннан соң да әле 40 ел яши. Ягъкубның да, Йосыфның да, Ибне Йәминнең дә «12 углы бар» дип күрсәтү — мифологиядән, фольклордан килә торган күренеш.

«Кыйссаи Йосыф»та төш күрүләр һәм аларны юрау гаять күп. Аны Йосыф та, Ягъкуб һәм кызы Динә дә, Зөләйха, Малик Ибне Дәгыйр, Кыйтфир, икмәкче, шәрабчы һ. б. да күрә. Бу нәрсә белән аңлатыла соң? Төш күрү һәм юрау Борынгы һәм Урта гасыр тормышында игътибар үзәгендә торган. Мифологик ышанулар нигезендә, төш киләчәкне, язмышны алдан күрү чарасы итеп каралган. Борынгылар фикеренчә, төш юрау —зирәкләр, акыл, могҗиза ияләре, пәйгамбәрләр шөгыле. Тарихтан патша сарайларында махсус төш юраучыларның булуы мәгълүм. Димәк, «Кыйссаи Йосыф»та төш күрү һәм юрау эпизодларының күп булуы шул чор чынбарлыгының, электәге традицияләрнең йогынтысы белән аңлатыла. Бу — бер. Икенчедән, автор төш күрүне әдәби чара, сәнгать алымы буларак та файдалана. Йосыфның төш күрүе, төш юравы аның алдан күрүчәнлеген, зирәклеген, пәйгамбәрлеген күрсәтә. Язмыштан узмыш юк. Төштә күргәннәр дә барыбер киләчәк. «Кыйссаи Йосыф»та бу шулай. Ягъкуб төшендә унбер бәрән көтүен, шуларның берсен бүре (корт) алуын күрә. Тиз арада бу төшләр юш килә: Йосыфны агалары сахрага алып чыга, кыйныйлар, коега салалар... Әсәрдәге башка төшләр дә чынбарлыкка аша. Төш күрү һәм юрау алымы сюжетның ышандырырлык юнәлештә үсешен, композициянең табигый корылышын билгеле бер дәрәҗәдә тәэмин итә.

Романтик рухлы «Кыйссаи Йосыф» үзенең табигате белән реаль һәм хыялый күренешләрнең кушылмасын (синтезын) хәтерләтә. Ягъкубның Кәнганда яшәве, балаларының мал көтүе, Йосыфтан көнләшүләре, аны кол итеп сатулары, төп каһарманның зинданда утыруы, хөкемдар булуы, гаилә коруы, үлеме һ. б. — болар бар да чынбарлыкка охшаш яисә булырга мөмкин хәлләр. Аларга бик күп хыялый күренешләр, вакыйгалар ялганып китә. Ни өчен Йосыфны агалары үтерергә ашкына? Чөнки аларны бу начар эшкә Иблис тә котырта.

Йосыфның Кәнган коесындагы тормышы, аңа биредә Җәбраилнең булышуы, Зөләйханың кабат яшәрүе, хайваннарның телгә килүе, сабый баланың гуаһлык кылуы кебек күренешләр — иң беренче чиратта хыял-фантазия җимешләре. Аларның күпчелеге дини-мифологик ышануларга, фольклорга барып тоташа. Мәсәлән, Зөләйха, ялгышып үзе яратмаган Кыйтфирга кияүгә чыккач та, саф булып кала. Ни өчен? Бу сорауга әсәрдә мондый җавап бирелә:

Зөләйха шунда Йосыфка болай диде:
«Халикъ мине синең өчен саклап торды,
Миңа охшаш пәри кызы килеп йөрде,—
Мин дип белеп, Кыйтфир аны кочар имди». (219 б.)

Дини-мифологик риваятьләргә караганда, һәр кешенең пәри рәвешендәге ише дә була. Алар икесе бергә туа, яши, үлә. Бу хакта Кол Гали дә искәртә:

Адәм углы белән бер пәри дә булган,
Йосыф белән дә шулай бер пәри туган,
Һәркем туса, бер пәри дә туып торган,—
Әгәр үлсә, ул пәри дә үлгән имди. (111 б.)

Күп кенә әкият-дастаннарда, «Кәлилә вә Димнә», «Тутыйнамә» кебек борынгы ядкярләрдә кош-кортларның, агач-үсемлекләрнең, хайваннарның телгә килүе, кеше кебек сөйләшүләре — гадәти һәм киң таралган күренеш. Мифологик ышанулар белән бәйләнгән мондый эпизодлар «Кыйссаи Йосыф»та да бар.

Ягъкубның уллары: «Йосыфны (бүрегә) алдырдык»,— дип, әтиләренә кайтып әйтәләр. Кайгыдан «акылы шашкан» ата «ул бүрене тотып килергә» куша. Әмер үтәлә. Бүре, шунда телгә килеп, үзенең гөнаһсыз булуын, унҗиде көн буена бернинди «тәгам»сез, югалган баласын эзләвен әйтә. Бу эпизод Ягъкуб белән Йосыф мәхәббәтен, ата һәм бала аерылуның

гайре табигый хәл булуын тагын да үтемлерәк, тәэсирлерәк итеп күрсәтүгә ярдәм иткән.

«Кыйссаи Йосыф» вакыт һәм урынның (пространствоның) бирелеше белән дә әкият-дастаннарга якын. Андагы вакыт йомык, ул билгеле бер тарихи чор белән бәйләнмәгән. Әсәрдә телгә алынган Кәнган, Мисыр, Мәгъриб кебек вакыйгалар бара торган урыннар да шартлы, Ягъкуб һәм аның балалары «гыйбричә» (яһүдчә) сөйләшкән дип әйтүләр дә — элеккеге традицияләр йогынтысы гына.

Поэмада сәнгати һәм тарихи яктан гаять мөһим булган сарай салдыру күренешләре бар. «Дая» (хезмәтче хатын) фантазиясе белән тудырылган сарайда һәм аның бизәлешендә никадәр осталык һәм нәфислек! Нәкышләнгән баганалар (терәкләр), аларның түпләрендә — көмештән коелган үгез сыннары... «Саф һәм кызыл алтыннан ясалган атлар», яннарында — агачлар, аларда — төрле-төрле кошлар. Түшәмнәрдә «җәүһәр кандилләр» эленгән. Диварларда, түшәмнәрдә гаҗәеп күптөрле сурәтләр, алар арасында Йосыф һәм Зөләйха рәсемнәре дә бар... «Күргән кешеләрне хәйран итәр»лек бу күренеш авторның архитектура һәм рәсем сәнгатендә, төсләр эстетикасында гаять хәбәрдар булуын күрсәтә.

Йосыф төзеткән «гаҗәеп биек» сарай диварларында төп каһарманның атасы, туганнары, башыннан кичкәннәре (сахрага алып чыгулар, коега салулар, алдап, кол итеп сатулары һ. б.) сурәтләнә. Бу күренеш Йосыфның туганнарына шулкадәр көчле йогынты ясый ки, алар «каты егълап, берсе дә бер ризык капмас» була, аларның күңелен яман гамәлләре өчен үкенү, тәүбә кылу тойгысы биләп ала. Автор сүз сәнгатендә, рәсем сәнгате мөмкинлекләрен дә файдаланып, эстетик яктан гаять отышлы адым ясаган. Зөләйха төзеткән сарай һәм андагы сурәтләр дә каһарманнарның рухи асылын һәм әхлагын ачуга, сюжетның киеренкелеген көчәйтүгә ярдәм иткән.

Кайвакыт шушындый фикерне ишетергә туры килә: имеш, элеккеге Шәрык, шул исәптән татар дөньясында рәсем сәнгате үсмәгән, чөнки ислам дине моны тыйган. Әмма тарихи чынбарлык бу фикернең ялгышлыгын күрсәтә. Урта гасыр мөселман илләрендә рәсем сәнгате зур үсеш ала, патша сарайларында мәшһүр рәссамнарның эшләве мәгълүм. Рәсем сәнгатендә кеше сурәтләрен ясау да мөһим урынны алып торган. Мәсәлән, элеккеге кульязмаларда әдәби әсәрләргә ясалган күп санлы рәсем-миниатюралар — моның бер дәлиле. Ислам

дине рухындагы «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә кеше сурәтләренең рәсемләнүе дә — бу дәлилне көчәйтүче бер факт. Алтын Урда әдибе Котбның «Хөсрәү вә Ширин» поэмасында да (1342) кеше рәсемнәрен ясауга зур урын бирелә. Мәсәлән, анда Шавыр Хөсрәү, Ширин сурәтләрен ясый, һәм әсәр тукымасына бу күренешләр табигый рәвештә ялганып китә. Кыскасы, сарайга мөнәсәбәтле эпизодлар хыял җимеше генә түгел. Аларны тудыруга Шәрык чынбарлыгы, шул исәптән Болгар калаларындагы мәһабәт корылмалар да көчле этәргеч биргән. Гомумән, Идел-Урал буе төбәгенең, борынгы болгар-татар тормышының, фольклорының «Кыйссаи Йосыф»та чагылышына галимнәр нык игътибар итәләр. Ул күп кенә вакыйгахәлләрдә, факт-мәгълүматларда, сурәтләү чараларында ачык күренә. Мәсәлән, бер карчык, Йосыфны сатып алырга башка малы булмагач, «бер киләп йеб» күтәреп килә. Кылыч Йосыфны кыйнап рәнҗеткәч, «карлы-бозлы» яңгыр ява башлый (бу — табигатьнең гаделсезлеккә нәфрәт билгесе) һ. б. Әсәрдән мондый күренешләрне һәм детальләрне күпләп китерергә мөмкин. Идел-Урал буйларында, Болгар мәмләкәтендә элек-электән үк язуның шактый киң таралуы мәгълүм. Бу «Кыйссаи Йосыф»та ачык сизелә. Андагы каһарманнар өчен укуязу — гадәти күренеш. Поэманың борынгы болгар-татар халкы белән тыгыз бәйләнешы аеруча аның телендә ачык күренә. Бу тел — борынгы төрки язма телнең Идел-Урал буйларында, хәзәр-болгар-кыпчак-татар җирлегендә тарихи дәвам ителеше. Алга таба ул Алтын Урда һәм татар ханлыклары чоры татар язма әдәби теленең үзәген, төп нигезен тәшкил итте.

«Кыйссаи Йосыф» поэтикасында башка төр сәнгати үзенчәлекләр дә күзәтелә. Шагыйрь капма-каршы кую, ягъни антитеза алымын кулланырга ярата. Ул киң планда да, аерым строфа, шигырь юлы кысаларында да башкарыла. Мәсәлән, әсәрнең тәүге өлешендә Йосыфның ата янындагы бәхетле чоры телгә алына. Бераздан исә моның киресе туа: Йосыф инде рәнҗетелгән, кимсетелгән зат — ул кол. Алга таба да Йосыфның гомер юлы шундый капма-каршылыклар аша бирелә. «Аh, аяныч, газиз идем, түбән булдым», «Азат идем, коллыкка мин төштем имди» һ. б. шундый юлларда Йосыф хәле аерым шигырь юллары, строфалар кысасында гына капма-каршы куела. Шушындый ук ысул Зөләйха образын тасвирлаганда да кулланыла. Картаеп беткән Зөләйха, Йосыфны туктатып, болай ди:

...«Шаһе җиһан, менә күр син,
Хәлем зәгыйфь, күзем сукыр, янә бел син:
Мисыр хакиме Кыйтфирның җефете мин,—
Шундый хәлдән бу хәлләргә төштем имди!..» (215 б.)

Кол Гали анафора, кабатлау, эндәш, мөрәҗәгать, сорау, синтаксик янәшәлек кебек шигъри чаралардан һәм поэтик фигуралардан да теләп файдалана. Мәсәлән, «Йосыф вәзир кыйссасы» бүлегендәге бер строфаның өч юлы да «ике йөз бең ир ашар», ягъни «ике йөз мең гаскәр барыр» сүзләре белән башланып китә (анафора). Текстта аерым сүзләрнең, гыйбарәләрнең, хәтта шигъри юлларның кабатланып килүе әсәрнең эмоциональ тәэсир көчен арттыруга ярдәм итә.

Поэмада автор сөйләме персонажлар әңгәмәсе белән үзара тыгыз үрелеп бара. Диалогик сөйләм әсәр стилен җанлы сөйләм интонациясенә якынайта төшә. Поэмада эндәш, мөрәҗәгать, сорау формаларының күп булуы нәкъ әнә шул үзенчәлек белән дә аңлатыла. Персонажлар сөйләме, гадәттә, бер яисә аннан да күбрәк строфаны үз эченә ала. Туры сөйләм еш кына «Йосыф әйде», «Йагъкуб әйдүр» кебек гыйбарәләрдән соң башланып китә. Мәкаль-әйтемнәр, канатлы сүзләр куллану да — «Кыйссаи Йосыф» поэтикасына хас күренеш. Бу яктан автор Йосыф Баласагунлы, Әхмәд Йүгнәки традицияләрен дәвам иттерә. Кол Галинең дә күп юллары хикмәтле сүз, афоризм кебек яңгырый.

Кол Гали Ягъкубны һәм аның балаларын бер урында 12 ботаклы зур агач белән тиңли. Мондый чагыштыру үзенең тамырлары белән элеккеге мифологик күзаллауларга барып тоташа.

«Кыйссаи Йосыф»та, рун язмаларындагы һәм «Котадгу белек»тәге кебек, кеше җанын кошка охшату бар. Ягъкубның үлеме болай тасвирлана:

Изге тәннән аерылды газиз җаны,—
Кошка охшап, оҗмах таба очар имди. (283 б.)

Кеше җанын кош (шоңкар) рәвешендә күзаллау 1522 елгы бер каберташ язмасында да бар:

Үлем куанычысы йитте,
Безем куанычымыз китте,
Мәгәр шоңкар булып очты...

Кол Гали аерым персонажларга карата даими эпитетлар кулланырга ярата. Мәсәлән: газиз Йосыф, Йосыф сәүчи (изге, пәйгамбәр), ярлы Ягъкуб һ. б.

«Кыйссаи Йосыф»та гаҗәеп уңышлы кулланылган чагыштырулар, метафоралар, сынландырулар тулып ята. Йосыфыннан аерылуны күңеле сизгән Ягъкубның рухи халәте баласын җуйган дөя хәле белән тиңләштерелә («Бутасын җуйган дөядәй иңрәр имди»). Йөзне — тулган ай, тешләрне — энҗе, иреннәрне — бал-шикәр, кашны — яңа туган ай, бармакларны — талчыбык, битне кызыл якут белән чагыштыру да әсәрдә еш күзәтелә.

Лексик составы, фонетик һәм грамматик төзелеше белән «Кыйссаи Йосыф» иске татар язма әдәби теленнән җитди аерылмый. Әмма анда хәзерге сөйләм һәм язма телебез өчен бик үк хас булмаган аерым күренешләр дә бар. Мәсәлән, сүз башында хәзерге [*т*] авазы урынына [*д*] килү еш очрый: *татлы —датлы, тора — дора, төрле — дөрле*. Сүз уртасында яисә ахырында *г — у* (*в*) чиратлашуы да күзәтелә: *тау — таг, бау — баг, авыр — агыр* һ. б. Лексика өлкәсендә *тәлим (күп), йаулак (бик, начар), кани (кайда), бән (мин), үгәр (мактар)* кебек борынгы төрки сүзләрне куллану дәвам итә. Фигыльләрдә *-гыл, -гел, -мага, -мәгә, -мыш, -меш, -ар, -әр, -ыр, -ер* кебек кушымчалар чагыштырмача актив: «Йагъкуб анда кермәгә деләр имди», «үгетләгел», «дүндермәгел», «бина кылмыш», «сорар имди» һ. б. Кол Гали кайвакыт, эчтәлек һәм шигъри үлчәм таләбе белән, бер үк яисә синонимик сүзләрне янәшә куллана: «малым-мөлкем җөмлә фида кылсам иде», «дөрлү-дөрлү теләкләр» һ. б.

Кыскасы, «Кыйссаи Йосыф» әсәренең поэтикасы — телстиле сүз-сурәт, сәнгати алымнар һәм чаралар белән иҗади эш итүнең матур бер үрнәге. Анда бүгенге сөйләм һәм язма телебезне, әдәбиятыбызны тагын да тулыландырырлык, баетырлык чаралар искиткеч күп.

Әсәрнең традицияләре, халкыбызның рухи дөньясында тоткан урыны.

«Кыйссаи Йосыф» — дөнья мәдәни үсешенең олы юлында туган ядкяр. Ул үзенең тамырлары белән төркиләрнең бай фольклорына һәм язма әдәбиятына, Шәрык һәм Гареп халыкларының күп гасырлык мәдәни мирасына барып тоташа. «Кыйссаи Йосыф»ның тууы, бер яктан, болгар-татарларның рухи ихтыяҗлары үсү, икенче яктан, Кол Гали кебек олуг талантның барлыкка килүе белән бәйле. Бу ядкяр фольклордан, борынгы төрки истәлекләрдән, аеруча «Котадгу белек»тән килә торган мәдәни казанышларны, туплап, баетып, алдагы буыннарга җиткерүдә мөһим этап булды. Аның күп гасырлар буена яратып укылуы,

мәктәп-мәдрәсәләрдә «төп уку һәм төрки текстларны өйрәнү» (В. Радлов) әсбабы рәвешендә кулланылуы хакында инде алдарак әйтелгән иде. «Кыйссаи Йосыф» халкыбызда тугрылык, сабырлык, әдәплелек, итагатьлелек, рух күтәренкелеге кебек сыйфатлар тәрбияләүдә остаз да булды.

Кол Гали әсәре үзеннән соңгы мәдәнияткә искиткеч зур йогынты ясаган һәм ясый. Аның традицияләрен рухи мирасның бик күп ядкярләрендә күзәтергә мөмкин. Хәзер шуларның берничәсен генә атап китик.

Татар язма телен үстерүдә һәм баетуда «Кыйссаи Йосыф»ның да роле зур булу бәхәссез.

Шәрык мәдәниятендәге рухи казанышларны иҗади үзләштерүдә Кол Гали кулланган ысулларны алга таба Котб, Хисам Кятиб, Сәйф Сараи, Мөхәммәдьяр, Утыз Имәни, Тукай һәм башка әдипләр иркен файдаландылар. Татар әдәбиятында Йосыф сюжетының күпләгән әдипләр тарафыннан эшкәртелүендә дә болгар-татар шагыйренең роле зур.

«Кыйссаи Йосыф» башка төрки әдәбиятлар үсешенә дә йогынты ясаган. Аның казахча, комыкча, кыргызча вариантлары да бар. Төрек шагыйре Шәйяд Хәмзә (XIII йөзнең икенче яртысы), үзенең «Йосыф вә Зөләйха» поэмасын иҗат иткәндә, Кол Гали әсәреннән дә мул файдалана.

Татар әдәбиятында «Кыйссаи Йосыф»ка аваздаш, аңа мөнәсәбәттә туган күренешләр шактый.

Мәхәббәттән акылын җую дәрәҗәсенә җиткән Зөләйха Йосыфка сөю хисләрен ачыктан-ачык белдерә, аның гүзәллеген мактый. Шунда Йосыф кеше гомеренең чикләнгән булуы, адәм матурлыгының вакытлы икәнлеге хакында искәртә:

Үткен күзләр күрми торган булып сулыр,
Энҗе кебек ап-ак тешләр һәм коелыр,
Алтмыш сөяк, корып-кибеп, тузан булыр,—
Ите череп вәйран булып калыр имди... (162 б.)

Моңа охшаш мотивлар Хисам Кятиб, Сәйф Сараи, Өмми Кәмал һәм татар әдәбиятының кайбер башка әдипләре тарафыннан да эшкәртелә.

Кадыйр Галибәк үзенең «Җәмигъ эт-тәварих» әсәрендә (1602) Касыйм ханлыгы тәхетенә Уразмөхәммәд ханны утырту күренешен тасвирлый. «Ханны,— ди ул,— алтынлуг сандалының өстенә утырттылар, ...өстенә нисарлар (тәңкәләр. — *Х. М.*) кылдылар». Мондый тантаналы, шатлыклы вакытта тәңкә чәчү татарда, гомумән, киң таралган. Бу күренеш «Кыйссаи

Йосыф»та да бар. Йосыфның зинданнан котылуын бөтен Мисыр халкы бәйрәм итә:

...Алтын-көмеш, энҗе-мәрҗән нисар кылды,—
Хас вә гамләр арзу кылыб йөгрер имди
(Олуг-кечек күрер өчен йөгерер имди). (200—201 б.)

Саба (таң) җиле Тәңре рөхсәте белән Ягъкубка Йосыфның исәнлек хәбәрен җиткерә. Атага бу шатлыклы хәбәр улының исе булып ирешә. Ягъкуб, җилгә дәшеп, болай ди:

Акрын исче, сәбах җиле, бик ашыкма,
Китерәсең Йосыфымның исен миңа,
Дәвам булчы йөрәгемнең ярасына,—
Син искәндә, күңлем шат була имди. (271 б.)

Таң җилен хәбәр җиткерүче, илче рәвешендә күзаллау, аңа дәшү татар фольклорында, язма поэзиядә еш очрый. Без аның үрнәкләрен Кандалыйда, Дәрдемәндтә, Такташта һәм башка шагыйрьләрдә очратабыз.

Әгәр барсаң, саба җил, безнең илгә,
Сәламнәр әйт, сәлам ул нечкә билгә,—

ди, мәсәлән, Дәрдемәнд.

«Кыйссаи Йосыф»та гаҗәеп тәэсирле, күздән яшьләр агызырлык бер эпизод бар. Ул — кол итеп сатылган Йосыфның әнисе кабере белән бәхилләшүе, вафат булган анасы белән елап сөйләшүе. Нәкъ шушыңа охшаш мотив Г. Тукайда да бар:

Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең кабрең ташы,—
Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы!

(«Өзелгән өмид»)

Кол Гали кулланган строфа, рифмалашу төрләре татар сүз сәнгатенең популяр формаларына әверелде. Моның мисалларын фольклордан һәм язма әдәбияттан күпләп табарга була. Мәсәлән:

Менә, дустлар, мин сезләргә бер сүз сөйлим,
«Йосыф-Йагъкуб китабы»ның көен көйлим;
Ушбу милләт ертыгының җөен җөйлим,—
Җебем кара, инәм каләм булсын имди...

(Г. Тукай. «Дустларга бер сүз»)

«Йосыф китабы» халык телендә махсус көйгә салынып укылган. Аңа нигезләнеп, күп санлы әсәрләрнең язылуы, бәет-мөнәҗәтләрнең, җырларның тууы мәгълүм.

Бер мөнәҗәттәге лирик герой үзенең авыр рухи халәтен ялгыз агачка, баласын җуйган Ягъкубка тиңли:

...— Ботакларымны җил кисте, яфраклар саргаеп төште,
Минем хәлем — баласындин аерылган Йагъкуб төсле...

(«Ялгыз агач мөнәҗәте»)

Гомумән, Йосыф һәм Зөләйханың матурлыгы, аларның көчле мәхәббәте, ахыр чиктә кавышулары, Ягъкубның түземлеге, олы җанлылыгы — татар халык иҗатында идеал төшенчәләр.

Фольклор тәэсире астында «Кыйссаи Йосыф»та кулланылган күп кенә тел-сурәтләү чаралары Кол Галидән соң аеруча активлаштылар. Мәсәлән, кашны — яңа ай, йөзне тулган ай белән чагыштыру, сүзне, иренне — бал-шикәр, тешләрне — энҗе, бармакларны талчыбык белән тиңләү һ. б. сурәтләр — әнә шундыйлардан.

Кашлары — ай аның яңа туган,
Йөзе — айның тулган көннәре. *(С. Рәмиев)*

Алтынкайның яңа туган ай кашы бар,
Колагында бриллиант күк алкасы бар. *(Ш. Бабич)*

«Кыйссаи Йосыф» поэмасына, аның авторына мөнәсәбәттә театр, музыка, рәсем сәнгате әсәрләре дә туган (Кәрим Әмири, Нурихан Фәттах пьесалары, Бакый ага Урманче, Тавил Хаҗиәхмәтов рәсемнәре һ. б.). Казан шәһәренең бер урамы шагыйрь исемен йөртә.

* * *

Кол Гали, моннан сигез гасырлар элек яшәп, якты дөньядан киткән. Әмма аның хис-фикерләргә бай әсәре үлмәгән: ул халкыбыз белән бергә яшәгән, яши һәм яшәячәк. Бу — шагыйрь өчен иң зур бәхет.

ЮНЕСКО (Берләшкән Милләтләр Оешмасының фән, мәгариф һәм мәдәният бүлеге) карары белән 1983 елда Кол Галинең тууына — 800, әсәре язылуга 750 ел тулу дөнья күләмендә билгеләп үтелде. Бу да — «Кыйссаи Йосыф»ның кешелек хәзинәсендә тоткан урынын, аның үлемсезлеген күрсәтүче мөһим дәлил. Кол Гали — әдипләребезнең олуг остазы, укучыларыбызның мөхтәрәм шагыйре.

Сораулар һәм биремнәр

1. Кол Галинең тормыш юлы хакында нәрсәләр беләсез?
2. Нурихан Фәттах трагедиясендә шагыйрь образы ничек бирелә?
3. «Кыйссаи Йосыф» кайда һәм кайчан язылган? Аның кулъязма һәм басма нөсхәләре.
4. Әсәр ничек төзелгән?
5. Поэманың кыскача сюжетын сөйләгез.
6. Әсәрнең бүлек (фасыл) атамаларына игътибар итегез, аларның ни өчен бу рәвешле исемләнүен аңлатыгыз.
7. Йосыф сюжетына нинди әсәрләр язылган?
8. Ни өчен без Кол Гали поэмасын, гәрчә ул билгеле сюжетка язылса да, оригиналь әсәр дип әйтәбез?
9. «Кыйссаи Йосыф»ның идея-проблематикасы нәрсәдән гыйбарәт?
10. Йосыф, Зөләйха, Ягъкуб образларына характеристика бирегез.
11. Йосыф агаларының эш-гамәлләрен сез ничек бәялисез?
12. Әсәрдә ни өчен сарай салдыру күренешләрен бирергә кирәк булган?
13. «Кыйссаи Йосыф»та кемнәр төш күрә, һәм төшләрнең әсәрдәге вазифалары нәрсәдән гыйбарәт?
14. Әсәрнең шигырь, строфа төзелеше хакында сөйләгез.
15. Поэмага тагын нинди сәнгати чаралар куллану хас?
16. «Кыйссаи Йосыф»ның тел-сурәтләү чараларын күзәтегез.
17. Әсәрнең фольклор белән бәйләнеше нәрсәләрдә күренә?
18. Кол Гали поэмасының татар әдәбиятындагы традицияләре.
19. «Кыйссаи Йосыф» поэмасының татар халкының рухи тормышындагы роле» темасына инша языгыз.
20. Әсәрдән аерым өзекләрне ятлагыз.

ДАСТАН ЖАНРЫ

Фольклор әсәрләре һәм элеккеге язма истәлекләр белән эш иткәндә, без еш кына дастан атамасы белән очрашабыз. Ул термин «Идегәй»гә, «Кыйссаи Йосыф»ка, «Сөһәйл вә Гөлдерсен»гә, «Таһир белән Зөһрә»гә һәм башка шундый күп санлы ядкярләргә карата кулланыла.

Дастан — лиро-эпик характердагы әсәр. Анда вакыйгаләр уй-кичерешләр белән үреп бирелә. Эпик табигатьле дастаннар да очрый. Бу жанрдагы күпчелек әсәрләр шигырь белән язылган. Тезмә һәм чәчмә юллар катнашмасыннан төзелгән дастаннар да бар. Проза белән язылганнары да очрый. Дастаннарда әкияти сюжетлар, легенда-риваятьләр, шулай ук тарихи вакыйгалар эшкәртелә, хыялый һәм чынбарлык күренешләре, вакыйгалары үреп, үзара катнаштырып бирелә. Мәсәлән, «Кыйссаи Йосыф»та Җәбраил Алла белән кешеләр арасында илче булып йөри. «Идегәй»дә төп каһарман

фантастик сурәтле Кара Тиен Алып белән сугыша. Дастаннар поэтикасы өчен шартлылык, гадәттән тыш арттыру хас.

Дастан атамасы төрки һәм фарсы әдәбиятларында һәм фольклорында кулланыла. Ул кайвакыт хикәят термины белән янәшә дә йөргән. Хәзерге әдәбият белемендә элеккеге язма әдәбияттагы дастаннарны поэма дип атау да бар. Фольклорда дастан һәм эпос терминнары синоним рәвешендә дә кулланыла.

Сораулар һәм бирем

1. Дастан жанры өчен нинди сыйфатлар хас?
2. Тагын нинди дастаннарны беләсез? Аларга хас аерым үзенчәлекләрне әйтегез.

ТРАДИЦИЯ ҺӘМ НОВАТОРЛЫК

Бу ике төшенчә әдәби иҗатта һәм, гомумән, әдәби процесста үзара тыгыз бәйләнгән. Традиция сүз сәнгатендә тупланган тәҗрибәне, казанышларны һәм аларның буыннан-буынга күчешен белдерә. Ә инде новаторлыкның нигезендә яңалык ята. Дәвамчанлык һәм яңалык үзара табигый кушылганда гына, чын әдәби әсәр туа, сүз сәнгате үсә ала.

Һәр әдип үзенә кадәрге әдәби тәҗрибә, сәнгать казанышлары белән эш итә. Тупланган бу байлык әдәби телдән, сурәтләү алымнарыннан һәм чараларыннан, жанрлардан һәм башка элементлардан гыйбарәт. Автор булган хәзинәне, тәҗрибәне үзенә чимал, материал, яңалыкны тудыруда чара рәвешендә генә файдаланырга бурычлы. Шулай итмәгәндә идея-эстетик һәм тарихи яктан әһәмияте, кыйммәте аз булган ядкярләр генә туа. Үз чиратында халыкның рухи казанышларын, эстетик зәвыгын исәпкә алмыйча язылган әсәрләр дә уңышсызлыкка очрый, аларның гомере озын булмый.

Фольклорда, Урта гасыр әдәбиятында традицияләрнең роле чагыштырмача көчле. Ул сюжетта, идея-мотивларда, кеше образларының бирелешендә, сурәтләү һәм тасвирлау чараларын куллануда аеруча ачык күренә. Мәсәлән, Йосыф — Зөләйха, Таһир — Зөһрә, Ләйлә — Мәҗнүн сюжетларына язылган әсәрләр күп. Йөзне — ай-кояш, кашны —җәя, керфекне — ук, тешләрне — энҗе, иреннәрне — бал-шикәр, зифа буйны тал, сәрв (кипарис) белән чагыштыру фольклорда да, язма әдәбиятта да еш очрый. Төш күрү, сыйфатны сан аша бирү, хыялый һәм чынбарлык күренешләрен кушып сурәтләү

актив. Эпик әсәрләрдә вакыт, урын шартлылыгы көчле. Урта гасырның күп кенә талантлы әдипләре, билгеле сюжетларны, чагыштырмача таныш материалларны иҗади эшкәртеп, баетып, чор таләпләренә җавап бирерлек оригиналь әсәрләр тудырганнар. Ә инде яңа дәвер, ягъни реализм чоры әдәбияты өчен, кагыйдә буларак, моңа кадәр таныш булмаган чынбарлык материаллары белән эш итү хас. Әмма бу процесста да элеккеге сәнгать казанышлары нигез итеп алына.

Традицияләрдән башка чын новаторлык була алмый. Бу — сәнгать үсешенең, иҗат процессының төп кануны.

Сорау һәм бирем

1. Дәреслектән, «Әдәбият белеме сүзлеге»ннән традиция һәм новаторлык хакындагы мәкаләләрне укыгыз, аларның төп эчтәлекләрен аңлатыгыз.

2. «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә традицияләр һәм новаторлык (яңачалык) нәрсәләрдә күренә?

АЛТЫН УРДА ЧОРЫ ӘДӘБИЯТЫ

1242—1243 елларда төзелгән Алтын Урда дәүләте, нигездә, ике гасыр буена, ягъни Кырым, Казан, Әстерхан (Хаҗитархан), Касыйм, Нугай, Олы Урда, Себер кебек татар ханлыклары оешканчыга кадәр яши. Ул еш кына башка исемнәр белән дә йөртелгән һәм йөртелә: Дәшти-Кыпчак, ягъни «Кыпчак даласы», «Кыпчак улусы» (иле, олысы. «Волость» сүзе шуннан алынган), «Татар иле», «Җучи улусы» (Җучи — Чыңгыз ханның олы улы. Ул 1227 елда үлә), «Бәркә улусы» (Бәркә— Батый ханнан соң 1256—1265 елларда идарә иткән хан), «Үзбәк улусы» (ул 1312—1342 елларда хан була) һ. б.

Монголлар һөҗүме нәтиҗәсендә барлыкка килгән Алтын Урда мәмләкәте Евразиянең гаять зур мәйданын били. Аның составына Дунай тамагыннан, Карпат тауларыннан алып Үзәк Казахстанга, Иртешкәчә кадәрге җирләр керә. Нократның (Вятканың) түбәнге һәм урта агымнары, Чулман (Кама), Агыйдел буйлары, Урал таулары, Кырым, Арал диңгезе, Амударья һәм Сырдәрья елгаларының түбәнге өлешләре (Харәзем) — болар бар да Алтын Урда төбәкләре. Кавказ сырты — Дәшти-Кыпчакның көньяк чиге. Аерым елларда Алтын Урда составына хәзерге Азәрбайҗан һәм Төньяк Иран да кереп ала. Әмма илнең төп өлешен Идел-Урал (Идел-Җаек) тәшкил итә. Шуңа күрә ул еш кына Идел-йорт дип атала да. Мәмләкәтнең башкаласы да Идел буенда була: әүвәл Сарай-Батуда (ул Әстерханнан бераз төньяктарак), аннан Сарай-Бәркәдә (Бәркә хан төзеткән бу кала хәзерге Волгоградтан 70—80 чакрым көнчыгыштарак урнашкан була).

Алтын Урданың төп халкын элек-электән Евразиядә яшәгән төркиләр, угро-финнар, Кавказ халыклары, славяннар тәшкил итә. Болар арасында кыпчаклар һәм болгарлар күпчелекне алып торганнар. (Мәгълүм булганча, тел һәм этник яктан үзара бик якын торган бу ике кавем,— хәзәрләр белән берлектә, татарларны барлыкка китерүдәге төп компонентлар.)

Батый хан гаскәре, нигездә, монголлардан һәм төркиләрдән тора. Хакимлек монголлар кулында була. Аларга буйсынган кавемнәрнең зур өлешен моңа кадәр Үзәк Азиядә, Көнбатыш Себердә, Урал аръягында яшәгән татарлар тәшкил итә. Батый хан гаскәре белән килгән монголларның күпчелеге үз ватаннарына кайтып китә. Дәшти-Кыпчакта калган монголлар тиз арада төркиләшә.

Алтын Урданы төзүче төп сәяси һәм хәрби көч Батый җитәкчелегендәге татарлар була. Шуңа мөнәсәбәтле рәвештә татар атамасы киң таралыш таба. Татарларның үзләреннән тыш, илнең төп халкын тәшкил иткән болгарлар һәм кыпчаклар да бу исем белән атала башлый. Шулай итеп, безнең халкыбыз тарихының татар дип йөртелгән сәхифәсе ачыла. Берничә дистә ел эчендә элеккеге болгар, кыпчак, татар, хәзәр һәм кайбер башка этник кавемнәр, үзара керешеп, кайбер үзгәрешләр кичереп, хәзерге татар дигән халыкны, телне формалаштырып җиткерәләр. Бүгенге Әстерхан, Сарытау, Пенза, Мордовия, Түбән Новгород, Сембер, Самара, Оренбург, Пермь, Екатеринбург, Башкортстан, Чиләбе, Төмән һәм Евразиянең кайбер башка төбәкләрендәге милләттәшләребез — моннан берничә гасыр элек бер дәүләт (Алтын Урда) составында, үз җирләрендә яшәгән татарларның турыдан-туры варислары. Хәзерге Кырым татарлары да элек бердәм татар халкының тик бер өлеше генә булган. Әмма Алтын Урда таркалганнан соң, аларга госманлы төрекләренең йогынтысы көчәя. Шуның нәтиҗәсендә Кырым татарларының телләрендә, мәдәниятләрендә билгеле бер аерымлыклар барлыкка килә.

Алтын Урдада рәсми һәм күпчелек халыкның сөйләме, аралашу теле татар теле булган. Аны кайчак «кыпчак», «төрки-татар», «иске татар» теле дип йөртәләр. Бу телдә күп санлы язма истәлекләр, сүзлекләр, әдәби әсәрләр, рәсми документлар язылган. Гарәпчә, фарсыча язылган текстлар да очрый. Гарәп теле аеруча фәндә иркен кулланыла.

Алтын Урдада калаларның күп булуы, шәһәр тормышының алга китүе мәгълүм. Хаҗитархан, Сарытау, Камышлы, Азак (Азов), Кафа (хәзерге Феодосия), Болгар, Казан, Үргәнеч, Сарайчык, Гөлестан һәм башка калаларда иҗтимагый, мәдәни тормыш кайнап торган. Ә инде илнең башкаласы Сарай Көнчыгыш Европаның гына түгел, дөньяның иң зур шәһәрләреннән берсе исәпләнгән. Күп кенә чыганакларда аның олылыгы, гүзәллеге мактала, мәдәни, гыйльми яктан абруйлы булуы, югары дәрәҗәдә торуы искәртелә.

Алтын Урда язма мәдәнияте аның үз җирләре белән генә чикләнмәгән. Ул билгеле бер дәрәҗәдә мәмлүкләр идарә иткән Мисырда да таралыш таба, үсә. Мәгълүм булганча, мәмлүкләрнең төп өлеше чыгышлары белән Идел-Урал буйларыннан, кыпчак-татар кавеменнән. Алар үзләренең телләрен саклыйлар, асыл ватаннары — Идел-йорт белән тыгыз бәйләнештә торалар. Алтын Урданың да күп кенә галимнәре һәм әдипләре (Мәхмүд Сараи Гөлестаный, Сәйф Сараи, Бәркә Фәкыйһ һ. б.) Мисырга күчеп китә. Нәтиҗәдә мәмлүкләр мәмләкәтендә төрки-татар теле киң таралыш таба, күп санлы сүзлекләр, фәнни хезмәтләр, әдәби әсәрләр туа. Алтын Урда таркалганнан соң да, бу илнең шактый гына традицияләре мәмлүкләр илендә дәвам иттерелә. Биредә XV гасырда — XVI гасыр башында да күпләгән төрки галимнәрнең, шагыйрьләрнең яшәве, иҗат итүе мәгълүм. Мәмлүк солтаннарының үзләре арасында да әдәби иҗат белән шөгыльләнүчеләр була. Мәсәлән, әл-Әшрәф Сәйфеддин Кайтбай (1468—1469 елларда идарә итә), әл-Әшрәф Кансау әл-Гаури (1501—1517) һ. б. Шунысы мөһим: Татар Гали әфәнденең (ягъни Шәриф Гамидинең) атаклы «Төрки Шаһнамә»се (кульъязмада 1170 биттән торган бу шигъри әсәр 1501—1510 елларда иҗат ителә) нәкъ менә солтан әл-Гаури заказы буенча языла да.

Алтын Урда чоры язма истәлекләре.

Алтын Урда дәүләтендә язма әдәбият зур үсешкә ирешә. Моның сәбәпләре күптөрле: шәһәр тормышының, һөнәрчелекнең алга китүе, төрки-татар теленең киң таралуы, дөньяның шактый гына илләре һәм халыклары, аеруча мөселман Шәрык дөньясы белән икътисади, сәяси һәм мәдәни бәйләнешләрдә торуы, дин иреге, элеккеге төрки әдәби традицияләрнең көчле булуы, язуда төп материал итеп кәгазь куллану һ. б.

Тарихның афәтле җил-давыллары аркасында Алтын Урда чоры язма истәлекләренең тик бер өлеше генә безгә мәгълүм. Мәсәлән, XIV йөздә иҗат иткән Мәүла Казый Мөхсин, Әхмәд Хуҗа Сараи, Габделмәҗид һәм кайбер башка мәшһүр каләм ияләренең бары берәр газәле генә билгеле. Безгә мәгълүм истәлекләрнең дә бер өлеше чит ил китапханәләрендә (Котбның «Хөсрәү вә Ширин»е Франциядә, Хәрәзминең «Мәхәббәтнамә»се Англиядә) саклана. Киләчәктә, бәлки, бу чорның кайбер башка ядкярләре дә табылыр?!

Алтын Урда чорыннан безгә килеп җиткән язма истәлекләр төрле характерда. Хәзер шуларны карап китик.

1. **Ярлыклар.** Ярлык исеме белән, гадәттә, хөкемдарның язма указын, фәрманын, грамотасын атыйлар. Болар арасында аеруча Туктамыш хан һәм Тимер Котлыг ярлыклары (1392, 1398 еллар) игътибарга лаек. Алар илнең сәяси, иҗтимагый-социаль тормышын һәм рәсми язма телне өйрәнүдә мөһим чыганак булып торалар.

2. **Каберташ язмалары.** «Болгар эпитафик истәлекләре» дип йөртелгән ядкярләрнең төп өлеше Алтын Урда чорына карый. Аларда тарихка, тормыш-көнкүрешкә мөнәсәбәтле күп кенә факт-мәгълүматлар бар, шигъри юллар да очрап куя. Бизәлү, язылу рәвешләре белән бу ядкярләр — сәнгатьчеләр өчен дә менә дигән материал.

3. **Фән.** Шәрыкның Ибне Гарәбшаһ (1388—1451) кебек Урта гасыр авторлары да, Әмин әл-Холи шикелле хәзерге тарихчылары да Алтын Урдада мөселман дөньясында мәшһүр булган күп санлы галимнәрнең яшәвен, Идел-Урал мәдәни үзәкләрендә гыйльми фикернең гаять югары торуын бертавыштан раслыйлар. XIV йөздә Идел-йортта яшәгән атаклы кешеләр арасында галим Котбеддин Рази, философ Сәгыддин Тәфтәзани, табиб Ибне Нәҗам, астроном Камаледдин Төркмәни, Мөхәммәд Бәззази, шагыйрь Әхмәд Хөҗәнди һ. б. билгеле шәхесләр бар.

Әгәр дә Алтын Урда төзелүнең баштагы елларында бирелә бүтән илләрдән килгән галимнәр һәм әдипләр өстенлек итсә, Үзбәк (1312—1342 елларда идарә итә), аеруча Җанибәк (1343—1357 елларда хан була) дәверендә инде икенче күренеш. Бай традицияле гарәп-фарсы мәмләкәтләрендәге, Харәзем, Болгардагы укымышлыларның катнашы һәм тырышлыгы аркасында Сарайның үз иҗат мәктәбе барлыкка килә. XIV гасырда Идел-йортта, бигрәк тә Сарайда җитешкән әдип-галимнәрнең күпчелеге «Сараи» кушаматын йөртә.

Җучи улусында фәлсәфә, хокук, медицина, педагогика, математика, астрономия, логика, тарих һәм фәннең башка тармаклары буенча китаплар языла (нигездә, алар гарәп телендә). Әмма бу хезмәтләр, гәрчә алар Шәрык дөньясында теге яки бу дәрәҗәдә күптәннән үк мәгълүм булсалар да, хәзерге татар кешеләренә бөтенләй диярлек билгеле түгел.

4. **Сәяхәтнамәләр.** Урта гасырларда аеруча популяр булган бу жанрдагы әсәрләр төрки-татар телендә дә язылганнар. Әмма шунысы кызганыч: алар сакланмаган. Шулай да Плано Карпини, Вильям Рубрук, Марко Поло, Ибне Баттута, Ибне Гарәбшаһ кебек сәяхәтчеләрнең Көнбатыш Евро-

па, гарәп телләрендә язылган ядкярләрендә Алтын Урдага да мөнәсәбәтле мәгълүматлар бар. Мәсәлән, Ибне Баттута (XIV йөз) Дәшти-Кыпчакта, төрки-татар теленнән тыш, гарәп, фарсы телләренең дә киң таралышы, хатын-кызларның җәмгыятьтә зур хокукларга ия булулары хакында яза.

5. **Сүзлекләр.** Алтын Урда чорында ике, өч телле (гарәп, фарсы, латин һ. б.) күп санлы сүзлекләр төзелә. Моның сәбәбе — илнең Мисыр, Византия, Иран, Көнбатыш Европа һәм башка дәүләтләр, халыклар белән төрле мөнәсәбәтләрдә торуы, Идел-Урал төбәгендә рухи тормышның чагыштырмача югары булуы. Бу чор сүзлекләрендәге лексик хәзинә, нигездә, хәзерге телебездә дә кулланылуын дәвам итә. Көнбатыш Европа кешеләре тарафыннан Сарай шәһәрендә төзелгән латинча-фарсыча-команча (кыпчакларны элек «коман» дип тә йөрткәннәр) сүзлектә, ягъни «Кодекс куманикус»та (1303), лексик-грамматик материаллардан тыш, җаваплары белән 46 табышмак та теркәлгән. «Кодекс куманикус»тагы табышмакларда табигать күренешләре, төрки-татар халкының образлы фикерләве, тормыш-көнкүреше билгеле бер күләмдә гәүдәләнеш тапкан.

XIV йөз әдәбиятына хас сыйфатлар.

Алтын Урда чоры язма истәлекләре арасында төп урынны матур әдәбият әсәрләре алып тора. Алар өчен поэтик камиллек, идея-тематик байлык, жанр төрлелеге хас. Әдипләр хикәят, дастан, кыйсса, шигъри роман, касыйдә, газәл, робагый, повесть, мәсәл, поэма һәм башка жанрларда иҗат итәләр. Поэзия һәм проза төрләренең икесе дә иркен кулланыла. Чәчмә һәм шигъри юллар катнаштырып язылган әсәрләр дә бар («Кыйссасел-әнбия», «Гөлестан бит-төрки»). Ритмлы, рифмалы проза үрнәкләре дә еш очрый. Нәзыйрә (ягъни җавап, охшатып язу) алымы да актив кулланылган.

Алтын Урданың күпчелек әдипләре, китап укучылары, төрки-татар теленнән тыш, гарәп, фарсы телләрен дә белгәннәр. Язма истәлекләрдә гарәп-фарсы сүзләренең, гыйбарәләренең еш очравы шуның белән аңлатыла. Арада гарәпчә яисә фарсы телендә иҗат ителгән әсәрләр, өзекләр дә бар. Гомумән, бу чор әдәби язма теле искиткеч бай. Котб, Харәзми, Сәйф Сараи әсәрләрендәге тел-стиль, шигъри нәфислек, матур интонацион яңгыраш, мәгънә һәм форма гармониясе хәзерге каләм әһелләрен дә кызыктырырлык.

Алтын Урда әдипләре, бер яктан, борынгы төрки истәлекләрдән, «Котадгу белек» (1069), «Диване лөгатет-төрк» (1074) ке-

бек ядкярләрдән, Ясәви, Бакырганый, Кол Гали иҗатларыннан килә торган традицияләрне дәвам итсәләр, икенче яктан, гарәп-фарсы классикасы, аеруча әл-Мәгарри, Фирдәүси, Хәйям, Низами, Гаттар, Сәгъди әсәрләре белән актив мөнәсәбәттә торалар: аларны иҗади өйрәнәләр, тәрҗемә итәләр, еш кына үз остазлары белән шигъри бәйгегә чыгып, нәзыйрәләр дә язалар. Шул сәбәпле XIV йөз төрки-татар әдәбиятында Шәрык классикасы белән идея һәм поэтик яктан охшашлыклар күп. Аларның бер өлеше алынма булса, икенче өлеше — типологик характерда, ягъни бер-берсенә бәйсез туган охшашлык.

Татар әдәбиятына, алдарак әйтелгәнчә, газәл, касыйдә, кысалы кыйсса жанрлары, каймалы (тартмалы) композиция, гаруз формалары Шәрыктан керә. Әмма алар җирле әдәби традицияләр, элементлар белән табигый рәвештә ярашалар. Көнчыгыш классикасы аркылы төрки-татар әдипләре Борынгы Һиндстан, антик Греция казанышлары белән дә билгеле бер дәрәҗәдә танышалар. «Кәлилә вә Димнә», «Тутыйнамә» ядкярләренең Идел-Урал буйларында күптәннән билгеле булуы генетик яктан Борынгы Һиндстан белән дәвамлы бәйләнеш барлыгы турында сөйли. Искәндәр Зөлкарнәйн (Александр Македонский), Әфләтүн (Платон) исемнәре бу чор әдәбиятында, уңай образ буларак, еш телгә алына. Урта гасыр Шәрык дөньясы өчен хас булган **суфичылык**, ягъни **тәсауфчылык** та, Идел-йортта үзенең тамырларын тирәнгә җибәрә. Бу бигрәк тә Мәхмүд Болгари, Хисам Кятиб кебек әдипләрнең иҗатында ачык күренә.

Ислам дине һәм аның төп ядкяре Коръән — мөселман дөньясының барлык халыкларын, шул исәптән Алтын Урда татарларын да, рухи, мәдәни яктан берләштереп торучы төп фактор. Хөкемдар һәм халык, әхлак тәрбиясе, яшәү мәгънәсе, мәхәббәт, белем-мәгърифәт, кеше-вакыт проблемалары Шәрык һәм Алтын Урда әдипләренең игътибар үзәгендә торган. Билгеле темаларга, сюжетларга әсәрләр язу, традицион персонажларның (Йосыф, Хөсрәү, Ширин, Фәрһад, Ләйлә, Мәҗнүн, Нәүширван, Локман, Карун, Ибраһим, Әдһәм һ. б.) иркен кулланылуы, әдәби иҗатта шартлылыкның, романтик фикерләүнең өстенлек итүе — Урта гасыр гарәп, фарсы, төрки-татар әдәбиятларын характерлаучы төп сыйфатлар.

Алтын Урда әдәбиятының үзәгендә — кеше, аның эчке дөньясы, эш-гамәлләре, җәмгыять һәм табигать белән бәйләнешләре. Авторлар иң беренче чиратта персонажларның нинди диннән булуына түгел, ә әхлакый йөзенә, холык-фигы-

ленә игътибар итәләр. «Котадгу белек», «Һибәтел-хәкаик», «Кыйссаи Йосыф» традицияләрен дәвам итеп, Алтын Урда әдипләре белемлелек, әдәплелек, итагатьлелек, шәфкатьлелек, сабырлык кебек сыйфатларны кеше идеалының мөһим өлешләре итеп саныйлар. Болардан аеруча юмартлык, киң күңеллелек алгы планга куела.

Бу чор ядкярләрендә «Нә иксә — ургай аны» мәкале очрый. Ул — без күнеккән «Ни чәчсәң, шуны урырсың» мәкаленең тәрдәше. Бу мәкальнең мәгънәсе — Урта гасыр, шул исәптән Алтын Урда әдәбиятының да девизы, персонажларны бәяләүнең төп әхлакый чарасы. Ягъни кеше үзенең сүз-фикере, эш-гамәле өчен үзе җаваплы. Яхшылыгың да, яманлыгың да, иртәме-соңмы, кире үзеңә кайтачак. Шуңа күрә авторлар үз укучыларын игелекле, шәфкатьле булырга чакыралар.

Алтын Урданың каләм әһелләре кешене төрле юллар белән зурларга, сакларга омтылганнар, аны кимсетүгә, түбәнсетүгә кискен каршы чыкканнар.

Теләсәң игү атың мәңгү калгай,
Аяктан төшкән әлен тотгучы бул.
(Аяктан төшкәннең, ягъни кыен хәлдә
калганның, кулын тотучы бул. — *Х. М.*)

Сәйф Сараиның бу шигъри юллары XIV йөз әдәбиятының гуманистик асылын гәүдәләндерә.

Суфичылык. Моңа кадәр инде без бу атама белән берничә мәртәбә очраштык. Аңа хас аерым сыйфатлар хакында да сүз булды. Бу күренешнең гомумтөрки әдәбиятта гына түгел, Алтын Урта чорында да күзәтелүе искәртелде. Хәзер исә суфичылык төшенчәсенә махсус тукталып китик.

«Суф» сүзе гарәпчә «йон», «йон тукыма» мәгънәләрен белдерә. Әүвәлге суфилар йон тукымадан тегелгән кием киеп йөргәннәр. Шәрык телләрендә суфи исеме еш кына «диндар», «дәрвиш», «тәкъва», «акыл иясе», «изге» дигән сүзләрнең синонимы булып та йөри. Кайвакыт бу атаманы грек телендәге «софос» (акыл иясе) сүзе белән дә бәйләп аңлаталар.

Идеологик күренеш буларак, суфичылык VIII гасырларда гарәп дөньясында туа һәм IX—XII йөзләрдә фарсы, төрки һәм башка мөселман халыклары арасында тарала. Аның тууы һәм таралуы шул дәвердәге феодаль тормыш, социаль тигезсезлек, иҗтимагый каршылыклар һәм башка сәбәпләр белән аңлатыла.

Суфичылык — ислам дине белән бәйләнешле гаять катлаулы һәм каршылыклы күренеш. Ул кешенең үз-үзен рухи яктан камилләштерү юлы белән Аллага якынаюын һәм кушылуын күздә тоткан төрле системадагы дини-фәлсәфи карашлардан һәм йолалар җыелмасыннан гыйбарәт. Суфичылык үзенә, конкрет шартларны исәпкә алып, тарихи якын килүне таләп итә. Чөнки аның исеменнән реакцион, консерватив көчләр дә, халык мәнфәгатьләрен, демократик идеалларны яклаган алдынгы фикер ияләре, олы гуманистлар да эш йөртә. Тарихта суфичылык байрагы астында барган халык кузгалышларының да булуы мәгълүм. Күп кенә суфилар хөкемдарларның, өстен сыйныфларның эш-гамәлләрен фаш итәләр, еш кына кешенең кешене изүен, башкалар хезмәтенә яшәвен гайре табигый күренеш дип саныйлар. Алар фикеренчә, Алла каршында бар да тигез.

Суфичылыкта аскетик башлангыч, протестның (ризасызлыкның) пассив формасы өстенлек итә. Суфичылык фәлсәфәсе дөньяви тормышка түбәнсетеп карый, илаһи мәхәббәтне, ялгызлыкны идеаллаштыра. Бу исә үз чиратында кешеләрне иҗтимагый мәсьәләләрдән читләшүгә, пассивлыкка, төшенкелеккә этәрә.

Суфичылык кешегә хис-тойгылар, эмоцияләр аркылы тәэсир итүне өстен күрә. Шуңа күрә ул сәнгать чараларыннан — әдәбият һәм музыкадан — иркен файдалана. Урта гасыр Шәрык дөньясының күп кенә мәшһүр суфилары бер үк вакытта үз чорының күренекле фикер ияләре һәм әдипләре дә булганнар. Имам Газали (1058— 1111), Фәридеддин Гаттар (1119—1223), Җәләледдин Руми (1207— 1273), Мөхәммәд Нәкышбәнди (1314—1389), Габдрахман Җами (1414—1492) һ. б.— әнә шундыйлардан.

Суфичылык әдәбиятына хас булган үзенчәлекләр, традицион образлар бар. Алла, мәсәлән, еш кына абсолют хаклык, гаделлек, сафлык, шәфкать, куәт, кодрәт, юмартлык кебек уңай сыйфатларга ия булган өлге, иң бөек идеал рәвешен ала. Лирик герой шуны сөя, шуңа тартыла, һәр адымын, һәр эш-гамәлен шуның белән яраклаштырырга омтыла. Кеше табигатендәге кимчелекләр, җәмгыятьтәге бозыклык һәм начар яклар да нәкъ әнә шул өлгегә, идеалга мөнәсәбәттә тәнкыйтьләнә. Геройның рухи халәтен, Аллага мөнәсәбәтен белдерү өчен, суфи шагыйрьләр еш кына ике катламлы (гадәти һәм символик мәгънәле) махсус образлар кулланалар. Мәсәлән, гөл һәм

былбыл, күбәләк һәм шәм ике гашыйкның үзара мәхәббәтен белдерә; бу образлар илаһи мәхәббәтне гәүдәләндерүгә дә хезмәт итәләр. Суфичылык поэзиясендәге бу төр ике планлылыкны гадәти мәгънәдә кабул итү мөмкинлеге дә кала. Шуңа күрә Руми, Хафиз һәм башка мәшһүр шагыйрьләрнең илаһи мәхәббәтне гәүдәләндергән аерым әсәрләре дөньяви сөю шигырьләре кебек тә кабул ителә. Бу хәл суфичылык белән бәйләнешле әдәбиятның иҗтимагый-тарихи әһәмиятен арттыра, аның буыннан-буынга яшәешен, дәвамчанлыгын да билгеле бер дәрәҗәдә тәэмин итә.

Сыйнфый тигезсезлек, милли-колониаль һәм социаль изү, төрле сугышлар һәм каршылыклар, җәбер-золым Идел-Урал буйларында суфичылыкның Болгар чорыннан алып Октябрь революциясенә кадәр яшәвендә төп факторлар булды. Урта Азия суфи шагыйрьләре Әхмәд Ясәви һәм Сөләйман Бакырганый (XII йөз) әсәрләре озак гасырлар буе укылып килде. «Нәһҗел-фәрадис» (1358), «Җөмҗөмә солтан» (1369) әсәрләрендә, аеруча Өмми Кәмал (XV), Колшәриф (XVI) иҗатларында суфичылык мотивлары һәм образлары шактый зур урын алган. XVII йөз шагыйре Мәүла Колый, бер яктан, суфилыкны кәсеп итеп, үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртучыларны кискен тәнкыйтьли, икенче яктан, «Суфи нинди булырга тиеш?» соравына җавап бирергә омтыла. Аның аңлавынча, чын суфи ул — сүзе һәм гамәле бердәм булган идеал кеше. Утыз Имәни, Шәмседдин Зәки һәм кайбер башка татар әдипләре дә суфичылыкка теге яки бу дәрәҗәдә мөнәсәбәтле әсәрләр иҗат итәләр.

Кыскасы, суфичылык — Шәрык, шул исәптән татар дөньясында мең елдан артык тарихы булган гаять катлаулы, киң таралган күренеш.

Сораулар һәм биремнәр

1. Ни өчен без Алтын Урданы татар тарихының мөһим сәхифәсе дип атыйбыз?

2. Дәшти-Кыпчак, Җучи улусы, Бәркә улусы, Идел-йорт атамаларын аңлатып бирегез.

3. Картадан Алтын Урда шәһәрләрен, илнең якынча чикләрен күрсәтегез.

4. Мисыр мәмлүкләре кемнәр алар?

5. Алтын Урда чорыннан безнең көннәргә нинди төр язма истәлекләр сакланган? Аларга аерым-аерым аңлатма бирегез.

6. «Әдәбият белеме сүзлеге»ннән сәяхәтнамә хакындагы мәкаләне укыгыз һәм төп эчтәлеген аңлатыгыз.

7. Алтын Урда чоры әдәбиятына нинди гомуми сыйфатлар хас?

8. XIV йөз төрки-татар әдәбиятының Шәрык классикасы белән бәйләнеше нәрсәләрдә күренә?

9. Суфичылык тәгълиматының асылы нәрсәдән гыйбарәт?

10. Суфичылык әдәбиятының үзенчәлекләре хакында сөйләгез.

11. Идел-Урал буйларында суфичылыкның таралу сәбәпләре, әдәбиятта гәүдәләнеше хакында ниләр беләсез?

XIV ЙӨЗ ӘДИПЛӘРЕ

Алтын Урда чоры әдәбияты каләм әһелләренә гаять бай була. Әмма аларның тик кайберләре генә безгә мәгълүм. Билгелеләренең дә иҗат мираслары тулысынча сакланмаган. Хәтта кайбер шагыйрьләрнең бер-ике шигыре генә килеп җиткән. Хәзер Алтын Урда әдипләренең берничәсенә кыскача гына тукталып китик.

Рабгузый. Ул Алтын Урданың көнчыгышындагы Харәзем төбәге белән бәйләнешле. XIII гасырның икенче яртысында — XIV йөзнең беренче чирегендә яши һәм иҗат итә. Үз исеме — Борһанеддин углы Насреддин. Әдип Рабатугыз каласында казый булып та эшли. Шуңа мөнәсәбәттә әдәби кушаматын Рабгузый дип ала. Татарларның һәм үзбәкләрнең уртак әдибе.

Рабгузыйның «Кыйссасел-әнбия» («Пәйгамбәрләр тарихы») исемле әсәре мәгълүм. Ул 1310 елда язылган. Шәрык телләрендә «Кыйссасел-әнбия» исемле кайбер башка әсәрләр дә булуын исәпкә алып, бу китапны кайвакыт «Кыйссаи Рабгузый» дип тә йөртәләр.

«Кыйссасел-әнбия» — зур күләмле чәчмә әсәр. Арада шигъри юллар, газәл, робагый, мәдхия үрнәкләре дә бар. Китап төрле зурлыктагы кыйссалар тупламыннан гыйбарәт. Аларның үзәгендә —Адәм, Нух, Ибраһим, Муса, Дауд, Сөләйман, Ягъкуб, Йосыф, Гайсә, Искәндәр, Мөхәммәд, Кабил, Һабил һәм башка мифологик затлар, пәйгамбәрләштерелгән шәхесләр. Автор үз әсәрен Коръәннән, гарәп, фарсы, төрки телләрдәге төрле чыганаклардан, мифологик һәм фольклор материалларыннан файдаланып язган.

Күпчелек кыйссалар төзелешләре ягыннан үзара охшаш: әүвәл пәйгамбәр һәм аның төп сыйфатлары хакында гомуми белешмә бирелә, алга таба бу образга мөнәсәбәтле гыйбрәтле хәлләр, вакыйгалар бәян ителә. Еш кына сорау-җавап формасы, иллюстратив сюжетлар китерү алымы кулланыла. Хи-

кәяләү — җанлы, хәрәкәтчән; тел-стиле — образлы. Аларда гарәпчә юллар да очрап куя. Кыйсса каһарманнары, пәйгамбәр булудан бигрәк, дастан, әкият геройлары рәвешендә дә күз алдына килеп баса, аларның эш-гамәлләре укучыларны һәм тыңлаучыларны дулкынландыра, әхлакый һәм, гомумән, рухи яктан камилләштерүгә ярдәм итә.

Китапта төрле мифологик ышанулар да урын алган. Мәсәлән, кыйссаларның берсендә шушындый сюжет бар: Нух көймәсендәге тишекне каплап андагы җан ияләрен коткарганы өчен, елан үзенә дөньядагы иң тәмле итне сорый. Черки аңа адәм итен тәкъдим итәргә җыена. Әмма карлыгач аның телен өзеп ала да черки исеменнән «иң тәмле ит» дип баканы күрсәтә. Бу гыйбрәтле мисал аша автор кеше — карлыгач мөнәсәбәтләренең ни өчен уңай, ә еланның бакага һәм карлыгачка ни сәбәпле дошман булуын аңлатырга омтыла.

Гомумкешелек идеалларын алга сөргән «Кыйссасел-әнбия» — Октябрь революциясенә кадәрге татар укучыларының иң яраткан китапларыннан берсе. Аның күп санлы кулъязмалары бар. Ул Казанда 1859 елда дөнья күрә һәм аннан соң күп мәртәбәләр нәшер ителә. Казан басмалары башка төрки халыклар, аеруча үзбәкләр һәм казахлар арасында да киң тарала. Татар әдәбиятында Рабгузый китабына мөнәсәбәттә туган әсәрләр дә шактый[1].

«Кыйссасел-әнбия» традицияләре «Нәһҗел-фәрадис», «Сираҗел-колуб» («Күңелләр чырагы»), «Рисаләи Газизә» кебек китапларда дәвам иттерелде.

Котб һәм аның «Хөсрәү вә Ширин» әсәре.

Котб (якынча 1297—XIV гасырның урталары) заманының гаять талантлы, укымышлы кешесе булган. Тел үзенчәлекләренә һәм кайбер башка фактларга карап, Котбны Урта Иделнең уң ягындагы мишәр татарлары, ягъни хәзерге Пенза, Мордовия төбәкләре белән дә бәйләүчеләр бар. Аның безгә бары «Хөсрәү вә Ширин» әсәре мәгълүм. Бу поэма — Алтын Урда җирлегендә Шәрык классикасына мөнәсәбәттә туган ядкярләрнең, мөгаен, иң күренеклеседер. Ул 1342 елда Сарай шәһәрендә төгәлләнгән. Әсәрнең 1383 елда Мисырда Бәркә Фәкыйһ тарафыннан күчерелгән кулъязмасы Париж милли китапханәсендә саклана.

---

[1] 1992 елда «Кыйссасел-әнбия»дәге аерым хикәятләр Фәрит Яхин хикәяләвендә «Пәйгамбәрләр тарихы» исеме белән нәшер ителде.

«Хөсрәү вә Ширин» әсәре XX йөзнең урталарыннан башлап Варшавада, Казанда, Ташкентта, Төркиядә нәшер ителде.

Бәркә Фәкыйһ — Идел буеннан Мисырга күчеп киткән кеше. Фикъһе, ягъни хокук белгече. Шуңа күрә Бәркә үзенә «Фәкыйһ» кушаматын ала. Ул шигырьләр дә язган. «Хөсрәү вә Ширин» күчермәсенең ахырына ул автобиографик эчтәлектәге үзенең дә 51 бәетлек шигырен теркәгән.

Котб мөрәҗәгать иткән Хөсрәү — Ширин тарихы, Ләйлә — Мәҗнүн, Таһир — Зөһрә, Сәйфелмөлек — Бәдигылҗәмал кебек, Шәрык дөньясында киң таралган сюжетларның берсе. Аңа нигезләнеп төрле телләрдә күп санлы әсәрләр язылган (Фирдәүси, Низами, Әмир Хөсрәү Дәһләви, Җами, Нәваи һ. б.). Котб үз поэмасына нигез итеп Низаминың 1181 елда фарсы телендә язылган әсәрен ала. Урыны белән тәрҗемә итә, иҗади эшкәртә, үзеннән дә күп юллар өсти. Шуңа күрә Котб әсәре фәндә мөстәкыйль идея-эстетик кыйммәткә ия булган ярым оригиналь, ярым тәрҗемә характерындагы истәлек итеп карала. Анда Алтын Урда тарихына, аның эчке тормышына, гореф-гадәтләренә кагылышлы күп кенә детальләр, фактмәгълүматлар бар. Әсәр Алтын Урда ханы Тәнибәккә һәм аның хатынына багышланган.

Поэмада Хөсрәү, аның туууыннан алып үлеменә кадәрге тормышы, ил белән идарә итүе сурәтләнә. Төп каһарман, нигездә, Куһистан хөкемдарының сеңлесе Ширин белән мөнәсәбәтләрдә ачыла. Әсәрдәге вакыйгаларның үстерелешендә, куелган мәсьәләләрнең сәнгати гәүдәләнешендә Фәрһад, Шавыр образларының да роле зур. Шириннең апасы Мөһинбану, Хөсрәүнең улы Шируя һәм беренче хатыны Мәрьям дә поэма сюжетында теге яки бу дәрәҗәдә катнашалар.

«Хөсрәү вә Ширин» 4659 икеюллык строфадан (бәеттән) гыйбарәт; аны күләме, идея-проблематикасы һәм сюжет-композициясе белән шигъри роман дип атарлык. Харәзми поэмасындагы кебек үк, Котб әсәрендә дә чын мәхәббәтнең олылыгы, кешеләрне рухи яктан баета, үстерә торган көч икәнлеге эстетик яктан гаять тәэсирле итеп бирелә. Ширин — Фәрһад образлары тышкы матурлыклары, эш-гамәлләре, рухи сафлыклары белән укучыны сокландыра. Автор фикеренчә, чын мәхәббәт булган җирдә гадел, кешелекле мөнәсәбәтләр урнаша, хакимиятнең, байлыкның әһәмияте югала.

«Хөсрәү вә Ширин» — синкретик табигатьле әсәр. Анда мәхәббәт темасы белән табигый бәйләнештә яшәешнең, таби-

гатьнең күптөрле мәсьәләләре гәүдәләнеш таба. Тән һәм җан берлеге, галәмнең чиксезлеге, вакыт агышы, хөкемдар һәм халык мөнәсәбәте, яшәү мәгънәсе һ. б.— әнә шундыйлардан. Автор вакыт агышын объектив процесс рәвешендә күзаллый. Шуңа нисбәтән кешенең тууы, яшәве, үлеме дә табигый хәл итеп карала. Дөнья кеше өчен, кеше дөнья өчен яратылган. «Сәнең өчен ирер бу барча галәм, Кечекләп күрмәгел үзеңне сән һәм кәм (ким.— *Х. М.*)»,— ди шагыйрь. Кеше — галәмнең олуг заты, ул үзен түбәнлеккә төшерергә тиеш түгел: дөньяга килгән икән, гыйлем-һөнәр тупларга, холкын тәрбияләргә, игелек кылырга, сөяргә һәм сөелергә бурычлы. Бары шул вакытта гына кеше, гәрчә бу дөньядан китеп туфрак булса да, буыннар хәтеренә «игү ат» (игелекле исеме) белән кереп кала. Фәрһад — әнә шундый затларның берсе.

Котб әсәренең кыйммәтен үзе дә тойган. Китапның ахырында ул бу ядкярен «каләмнең күзендин... бәгърем канын» агызып яздым, ди; бу төр кыйссаларның күп булуын искәртә. «Әмма,—ди шагыйрь, — аларның катында бу — җәүһәр...»

Каю кем укыса, белгәй ул,
Мәгәр кем ул ирнең бар ирсә җаны.

Харәзми. Яшәешнең иң мөһим сыйфатларыннан берсе — мәхәббәт элек-электән үк төрки-татар әдипләренең дикъкать үзәгендә булган. Алтын Урда чорында бу тема шактый нык эшкәртелә. Харәзминең «Мәхәббәтнамә» (намә—китап, әсәр, хат) поэмасы (1353) тулысы белән диярлек сөю-мәхәббәт хисләрен җырлауга багышланган. Автор карашынча, сөю — кешедәге хис-кичерешләрнең, эчке байлыкның иң олысы, иң изгесе. Поэмада сөйгән яр барлык нәрсәдән дә өстен куела, илаһилаштырыла, яшәешнең төп мәгънәсенә әйләндерелә: «Кешенең синсезин ни җаны булсын? Аның тик гомеренең ни саны булсын?», «Мәңа синсез үлемдер бу хәятем», «Синсез күңел ике җиһанны күзгә элмәс», «Колыңыз мин тәнемдә җан барынча» һ. б.

Әсәрдә сөйгән ярның (дилбәрнең) матурлыгын, лирик каһарманның рухи халәтен тасвирлауга зур урын бирелә. Автор гадәттән тыш арттыру, сыйфатны эреләндерү алымын кулланырга ярата. Мәсәлән:

Әгәр көн (кояш.—*Х. М.*) тугмаса, һәм якты кылгай
Йөзең нуры бу дөньяның сараен...

...Ашар йилдин синең йилгәндә (чапканда.—*Х. М.*) атың,
Кояш яңлигъ (кебек.— *Х. М.*) җиһанны тотты атың...

Кара кашыңда йөз мең фетнәләр бар,
Күзең аһусы (карашы, явы.— *Х. М.*) арысланнарны аулар.

Гомумән, Харәзминең шигъри теле гаять нәфис, тәэсирле. Әдип аеруча телдәге омонимия, ягъни тәҗнис, күренешеннән оста файдалана:

Мәхәббәтдин туган бер төрле әсрар,
Күңел әсрарыны җан берлә әсрар.

Бу бәеттәге «әсрар» сүзенең беренчесе «серләр», икенчесе «асрар» (туендырыр, тәрбияләр) мәгънәсен белдерә. «Ашар йилдин...» дип башланган шигырьдә дә (ул югарыда китерелде) «атың» сүзе ике төшенчәне аңлата (атың, исемең). Мондый мисалларны поэмадан күпләп китерергә мөмкин.

«Мәхәббәтнамә» әсәренең төп өлеше 11 «намә»дән, берничә «газәл»дән, «мәснәви»дән һәм берәр мөнәҗәт вә кыйтгадан гыйбарәт. Аларның кайберләре фарсы телендә язылган. Бу лирик поэма Алтын Урданың көнчыгыш өлкәләре белән идарә итүче Мөхәммәд Хуҗа биккә багышланган. Автор аның идеал портретын тасвирлый.

Лирик табигатьле «Мәхәббәтнамә» поэмасы үзеннән соңгы төрки әдәбиятларга зур йогынты ясады. Татар поэзиясендә Харәзми традицияләре Сәйф Сараи, Мөхәммәдьяр, Г. Кандалый, Дәрдемәнд, Ф. Бурнаш һәм башкаларның иҗатларында ачык күзәтелә. «Мәхәббәтнамә» авторы вакытның, гомернең тиз узуын искән җил белән чагыштыра («Кем уш йил тик кичәр әййаме фани», ягъни фани көннәр; «Җиһан йил тик, гомер гөл тик вафасыз»). Бу төр чагыштыру татар фольклорында һәм язма әдәбиятында еш очрый.

«Мәхәббәтнамә»дә мондый бәет бар:

Аның кем ал иңендә (битендә.— *Х. М.*) миң яратты,
Буе берлә сачене тиң яратты.

Шушы юллардан файдаланып, Дәрдемәнд үзенең «Рәсем» шигырен иҗат итә:

Тәнкәен ак, түшкәйләрен киң яраткан,
Биткәенең иң очында миң яраткан,
Саклар өчен зифа буен яман күздән,
Чәчкәйләрен аяк белән тиң яраткан!

XIV йөзнең урталарында иҗат иткән Харәзми, кушаматын-

нан күренгәнчә, Алтын Урданың көнчыгыш төбәге белән бәйләнешле. Әмма ул Идел буенда, Сарай шәһәрендә дә яшәгән, Якын Көнчыгыш илләрендә дә булган. Харәзминең төркичә һәм фарсыча язуы мәгълүм. Ул үз дәверенең күренекле шагыйре булган. Автор үзен хөр һәм бәйсез табигатьле, символик һомай кошы (феникс) белән тиңли.

Харәзминең касыйдә жанрында язылган лирик әсәре дә бар. Анда автор табигать матурлыгына, тереклеккә, тулы канлы яшәешкә дан җырлый, шигъри сүзнең үлемсезлеген күрсәтә:

Харәзминең әгәр тәне тупрак булса һәм
Атын тере тотар җиһан эчрә сүзләре.

Бу касыйдә, С. Сараи әсәрләре белән берлектә, Лейден университеты китапханәсендә сакланган. С. Сараи аңа нәзыйрә язган.

Хисам Кятиб. Котб кебек үк, аның ватандашы, кече чордашы Хисам Кятиб тә үзенең төп игътибарын яшәешнең мәңгелек мәсьәләләренә юнәлтә. Аны, барыннан да элек, яшәү һәм үлем, кеше һәм тормыш кебек мәсьәләләр борчый. Шагыйрьнең «Җөмҗөмә солтан» (1369) поэмасы фәлсәфи һәм шигъри яктан гаять көчле яңгыраучы «кереш» белән башланып китә. Анда Нух, Хәлил, Җәмшид, Хөсрәү, Зөлкарнәйн, Дәкъянус, Рөстәм, Нәүширван, Мәхмүд Газнәви, Ибраһим Әдһәм, Чыңгыз хан кебек билгеле пәйгамбәрләр, атаклы хөкемдарлар, тиңсез каһарманнар телгә алына. Алга таба автор мондый нәтиҗә ясый:

Һәрбересе бу җиһанны тоттылар,
Иллә, ишет кем, соңында киттеләр,

Киттеләр, бер парә бәзгә (кәфенлек тукыма күздә тотыла.— *Х. М.*) чолганып.
Тәннәре үз каннарына болганып,

Монча төрлүк мал вә нигъмәтен куеп,
Мөлкәте һәм тәхете һәм бәхтен куеп.

Чөнки килдең дөнья(г)а — китмәк кирәк,
Бар көчең йиткинчә хәйр итмәк кирәк.

Димәк, дөньяда беркем дә мәңгелек түгел: килгәнсең икән, китәргә дә кирәк; шуңа күрә үзеңә бирелгән гомерне игелекле эш-гамәлләр белән үткәрү шарт.

Поэманың төп өлешендә автор «кереш»тә куелган үзәк мәсьәләне легенда материалы нигезендә яктырта.

Җөмҗөмә атлы бер солтан була. Ул — куәтле, бай, гадел. Бервакыт бу патша бер фәкыйрьнең үтенечен канәгатьләндерми. Шуннан соң озак та тормый, ул авырып үлеп китә. Теге дөньяда аны тәмугка ташлыйлар. Җир йөзендә «мең ел яшәп» киткән Җөмҗөмә тәмугта «дүрт мең ел» газап чигә. Аннан, Алла кодрәте белән, ул «коруг баш» рәвешендә җир йөзенә кайтарыла һәм анда 70 ел тора. Гайсә пәйгамбәр үтенече белән Ходай Тәгалә «коруг баш»ны кеше рәвешенә китерә. Җөмҗөмә янә 70 ел яшәп, гыйбадәт кылып, кабат теге дөньяга китеп бара.

Әсәрдә байлыкка, хакимияткә тискәре мөнәсәбәт үзен нык сиздерә. Солтаннарның иң каты тәмуг газапларына дучар ителүе дә шуның белән аңлатыла. Поэманың буеннан-буена кеше үзенең эш-гамәлләре өчен үзе генә җаваплы дигән мөһим идея уздырыла. Ялганчылар, хәрәм мал җыючылар, гадел эш итмәгән судьялар, юлбасарлар, рибачылар (ростовщиклар), сараннар — һәммәсе дә теге дөньяда тиешле җәзага дучар ителәләр. Автор тәмуг күренешләрен сурәтләү аша үз укучыларын рухи яктан тәрбияләргә омтыла, кешеләрне игелекле гамәлләр генә кылырга чакыра.

Хисам Кятиб поэмасы күтәрелгән идея-проблематикасы, төзелеше, теге дөнья күренешләрен тасвирлавы белән гарәп әл-Мәгарри, фарсы Гаттар, италияле Данте әсәрләренә типологик яктан аваздаш.

«Җөмҗөмә солтан»да төрки-татар, Алтын Урда көнкүрешенә мөнәсәбәтле кызыклы гына детальләр бар. Сарай тормышын тасвирлаганда, автор, мәсәлән, күптөрле музыка коралларын саный (чәң, кубыз, быргы, табыл, чалгы, дәф һ. б.). Әсәр Гайсә пәйгамбәр белән Җөмҗөмә арасында әңгәмә рәвешендә корылган. Сорау-җавап формасы сюжет-композициянең корылышында табигыйлек тудыра. Вакыт шартлылыгы, чынбарлык һәм хыялый күренешләрнең үрелүе, урын (пространство) киңлеге (теге дөнья, бу дөнья...), сыйфатны сан аша бирү, гадәттән тыш арттыру яисә киметү, романтик фикерләү, анафора, кабатлау, ялгау, риторик сорау һәм эндәш фигураларын куллану —болар бар да әсәрнең поэтикасына хас сыйфатлар.

«Җөмҗөмә солтан»,—«Кыйссаи Йосыф», «Нәһҗел-фәрадис» кебек, элек-электән үк татар укучылары арасында киң таралган әсәр. Ул казахчага да тәрҗемә ителгән. «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасын язганда, Г. Тукай, иске «Кисекбаш» белән беррәттән, Хисам Кятиб әсәреннән дә иҗади файдаланган.

* * *

«Кисекбаш» әсәре үзенең рухы, аерым образлары, таралышы белән Хисам Кятиб поэмасына якын тора. Әмма аның язылу вакыты, урыны, авторы күрсәтелмәгән. Шуңа күрә бу мәсьәләләрдә фараз кылырга гына кала.

Тел-стиленә, эчтәлегенә һәм кайбер башка фактларга карап, аерым галимнәр «Кисекбаш»ны XIV—XV йөзләргә, ягъни Алтын Урда чорына кертәләр. Ш. Мәрҗани аны болгар чоры әсәре дип саный. Аерым нөсхәләрдә «Гали» исеме телгә алына. Мөгаен, бу зат я китапның күчерүчесе, я тәрҗемәчесе, яисә аның авторы булгандыр.

«Кисекбаш» (аны «Кисекбаш китабы», «Кыйссаи Кисекбаш», «Дастаны Кисекбаш» кебек исемнәр белән дә йөртәләр) татарлар арасында киң таралыш тапкан. Ислам дине рухындагы бу ядкярнең күп санлы кулъязма һәм басма (тәүге мәртәбә 1846 елда нәшер ителә) нөсхәләре бар. Ул татар мәктәп-мәдрәсәләрендә әдәби текст буларак та өйрәнелә.

«Кисекбаш»ның сюжеты түбәндәгечә: бервакыт Мөхәммәд пәйгамбәр үзенең якыннары белән әңгәмә корып утыра. Шулвакытта алар янына бер Кисекбаш тәгәрәп килә. Ул, елый-елый, үзенең моң-зарын сөйли: «Бер Дию,— ди ул,— гәүдәм белән улымны ашады, хатынымны алып китте». Мөхәммәд пәйгамбәрнең якыны — Гали батыр — Кисекбашка ярдәм итәргә алына. «Зөлфәкар» кылычын алып, Дөлдөл исемле атына атланып, Гали, Кисекбаш белән берлектә, бер кое янына килә. Аркан бәйләп, коега «җиде төн» һәм «җиде көн» төшкәч, бер ишекне ачып, җир асты патшалыгына керә. Диюләр патшасын үтерә, «500 кеше», шул исәптән Кисекбашның хатынын да, Җәбраил фәрештә ярдәмендә җир өстенә алып чыга. Кисекбаш, аның улы, пәйгамбәрнең Ходайдан үтенече белән, элеккеге хәлләренә кайтарылалар.

Күрәсез: «Кисекбаш» эчтәлеге һәм поэтикасы белән экиятлегендаларга тартым. Явыз көчнең матур хатын-кызны урлап китүе, бәхетсезлеккә тарыган бу затны батыр ир-атның коткаруы — фольклорда еш очрый торган хәл. Җир асты патшалыгы, Дию белән сугыш, кешеләрнең кабат терелүе һ. б. — болар бар да экият-легендаларга хас күренешләр. Автор шулар ярдәмендә Мөхәммәд пәйгамбәрнең изгелеген, Гали батырның көч-куәтен, кешелекле эш-гамәлләрен күрсәтүгә ирешкән.

Поэмадагы бөтен вакыйга-хәлләр гаделлек, кешеләр иминлеге өчен көрәш рухы белән сугарылган. Явызлык җиңелә,

тоткыннар коткарыла, гаилә торгызыла, кеше гомере саклап калына. Әсәрдә Гали батырның бөтен тырышлыгы хатын-кызны коткаруга, аны гаиләсе белән кавыштырып, бәхетле итүгә юнәлтелгән. Поэманың халык тарафыннан яратып укылуына, әлбәттә, аның гуманистик рухта булуы зур йогынты ясаган.

«Кисекбаш» икеюллык строфалар — бәетләр белән язылган. Аларның саны 135 тән артып китә.

«Җөмҗөмә солтан» дастаныннан үзгә буларак, «Кисекбаш»-та дөньявилык көчле. Әсәрнең бәхетле төгәлләнеше — шуның ачык мисалы.

Әхмәд Үргәнчи. XIV йөзнең икенче яртысында яшәгән бу шагыйрь Алтын Урданың Үргәнеч шәһәрендә я туган, яисә гомеренең бер өлешен анда уздырган булырга тиеш. Харәзми кебек үк, ул да Идел буенда да яшәгән. Гомеренең ахырын Мисырда үткәргән булса кирәк. Шагыйрь үзенең «күзсез адәм», ягъни сукыр булуын искәртә.

Әхмәд Үргәнчинең бары өч шигыре генә билгеле. Берсе мәхәббәт эчтәлегендә (газәл), икесе иҗтимагый-социаль характерда. Автор аларда үзенең авыр рухи халәтен, тормыштагы гаделсезлекләрне күреп борчылуын искәртә. Әмма шуңа да карамастан ул төшенкелеккә бирелми, имин, тыныч яшәеш киләчәгенә ышана:

Качан тынычлык гөле йортка (илгә.— *Х. М.*) сачылгай,
Шу(л) дәм (шулчак.—*Х. М.*) Әхмәднең дә күзе ачылгай.

Әхмәд Үргәнчинең бер шигыре Аксак Тимергә сатира рәвешендә язылган. Биредә автор бу «җиһангир»ны «залим», «канхур» (кан эчүче), тәмугка ягасы нәрсә, «бибаш» (башсыз) дип атый, аның «Җәйхун илә Сәйхун (Амударья белән Сырдәрья.—*Х. М.*) тулы күз яшь» агызуын, «илгә каза» китерүен күрсәтә. Шагыйрь тормышчан детальләр, афористик стиль ярдәмендә Аксак Тимер сәясәтенең гайре табигый булуын, хөкемгә дучар ителәчәген сурәтли:

Үрләде күккә аh-у фөган (аh-зар.— *Х. М.*), илгә килде каза,
Белгел ки, килмәйен калмас илдин сиңа һәм җәза.

Куйлар(г)а килгән корт (бүре.—*Х. М.*) очрар чупан
(чабан.—*Х. М.*) таягына,
Кем күтәрсә агыр таш, төшәр үзене(ң) аягына...

Әхмәд аһын тыңлаб, Алла сәне тәмуг(к)а салыр,
Дөньяда безгә дустлык, гадәләт шаһы кылыр.

* * *

Алтын Урда чорында кайбер башка әдипләрнең дә иҗат итүе мәгълүм. Мәсәлән, Габделмәҗид әүвәл Идел буенда, аннан Кырымда яши. Аның әле 1410 елларда исән булуы билгеле. Чыганаклар бу авторның Йосыф — Зөләйха сюжетына күләмле шигъри әсәр язуын да искәртәләр. Әмма поэма сакланмаган. XIV йөзнең икенче яртысында Мәхмүд Сараи Гөлестаный исемле әдип тә иҗат итә. Ул Идел төбәгендәге Гөлестан шәһәрендә туа, Сарайда укый, эшли, аннан Мисырга китә. Гыйлемлеге, аеруча гарәп, фарсы, төрки телләрне камил белүе белән танылган Мәхмүд Сараи Мисыр хакимиятендә вәзир (министр) булып та эшли. 1398 елда вафат була. Әхмәд Хуҗа Сараи — үз чорының мәшһүр шагыйре һәм тел галиме. Гомеренең күп өлешен Идел буендагы Сарай шәһәрендә уздыра.

Аерым парчалары аркылы без XIV йөздә Мәүла Казый Мөхсин, Туглы Хуҗа, Мәүлана Гыймад Мәүләви, Мәүлана Исхак, Хаҗәми кебек талантлы шагыйрьләр дә яшәвен беләбез. Болардан тыш, башка әдипләрнең дә барлыгын истән чыгарырга ярамый.

Алтын Урда язучыларыннан Мәхмүд Болгари һәм Сәйф Сараи иҗатларына аерым тукталыйк.

Сораулар һәм биремнәр

1. Ни өчен «Кыйссасел-әнбия»не «Кыйссаи Рабгузый» дип тә йөртәләр?

2. Мәктәптән тыш вакытта «Пәйгамбәрләр тарихы»н (Казан, 1992) укып, дәрестә шул китап турында фикер алышыгыз (укытучы ихтыярында).

3. Харәзми иҗатына нинди үзенчәлекләр хас?

4. Хөсрәү — Ширин сюжетына кайсы авторлар мөрәҗәгать иткән?

5. Бәркә Фәкыйһ кем ул?

6. Котб әсәрендә нинди мәсьәләләр гәүдәләнеш таба?

7. Дәрестән тыш «Хөсрәү вә Ширин»нән өзекләр укыгыз, фикер алышыгыз.

8. «Җөмҗөмә солтан» дастанының идея-эстетик үзенчәлекләре турында сөйләгез.

9. «Кисекбаш» нинди әсәр ул? Аның фольклор белән бәйләнеше нәрсәләрдә күренә?

10. «Җөмҗөмә солтан» дастаны һәм «Кисекбаш» поэмасының охшаш һәм аермалы якларын әйтегез.

11. Әхмәд Үргәнчине ни өчен без оптимист шагыйрь дип әйтәбез?

12. Алтын Урда чорының тагын нинди әдипләрен беләсез?

13. Мөстәкыйль рәвештә «Кисекбаш» әсәрен укыгыз.

Мәхмүд Болгари
һәм аның «Нәһҗел-фәрадис» әсәре

Тәрҗемәи хәле. Кушаматыннан күренгәнчә, әдип Алтын Урданың Болгар төбәге белән бәйләнешле. Ул биредә якынча 1297 елда туган дип карала. Аның әтисе Гали, ә бабасы Гомәр исемле була. Шуңа күрә әдипне еш кына Мәхмүд бине Гали, кайчак Мәхмүд бине Гали бине Гомәр дип тә йөртәләр. «Нәһҗел-фәрадис» авторының әтисе дә, бабасы да үз дәверенең дәрәҗәле кешеләре, күренекле руханилары булганнар.

Булачак әдип әүвәл Болгарда белем ала (бәлки, үзенең әтисендә дә укыгандыр). Кайбер фактлар аның Урта Азиядә дә белем алуын искәртәләр. Әмма Мәхмүд Болгари үз гомеренең шактыен Алтын Урда башкаласы Сарайда уздыра. (Шуңа күрә әдипне Мәхмүд Болгари Сараи дип тә атау бар.) Биредә ул дини, гыйльми, тәрбияви, иҗади эшләр белән шөгыльләнә, зур ихтирам, хөрмәт казана. Чыганакларда Мәхмүд Болгарига карата шәехебез, остазыбыз, хуҗабыз, шәригать әләмен кадаучы, халыкның һәм диннең зирәк юл күрсәтүчесе, аятьләрнең асылын ачып бирүче һәм башка шундый сыйфатламалар кулланыла.

«Нәһҗел-фәрадис» авторы 1360 елның 22 мартында Сарай шәһәрендә («Мөхәммәд пәйгамбәр яшендә») вафат була.

«Нәһҗел-фәрадис»ның кулъязмалары. Әсәр 1358 елның 20 гыйнварында Алтын Урда башкаласында төгәлләнә. «Фәрадис» фирдәвес (оҗмах бакчасы) сүзенең күплеген белдерә. Ә инде «нәһеҗ» (нәһҗ) ачык (хак, сыналган) юл дип тәрҗемә ителә. Шуңа мөнәсәбәттә фәндә әсәрнең исемен «Оҗмахларның ачык юлы» дип тә йөртәләр.

«Нәһҗел-фәрадис»ның 1360 елда төзелгән Сарай кулъязмасы Алтын Урда белән тыгыз икътисади, сәяси, мәдәни һәм этник мөнәсәбәтләрдә торган мәмлүкләр Мисырына барып эләгә. Аннан — Истанбулга. Хәзерге вакытта Истанбулда

сакланучы Сарай кулъязмасының (ул 443 биттән гыйбарәт) фотокүчермәсе 1956 елда Я. Экман тарафыннан Төркиядә нәшер ителде. Мәхмүд Болгари әсәренең тулы тексты 2002 елда Казанда да басылып чыкты.

«Нәһҗел-фәрадис»нең борынгы кулъязмаларыннан берсе 1390 елда Касыйм бине Мөхәммәд тарафыннан күчерелә. (Күләме —549 бит.) 1928 елда Кырымда табылган бу нөсхә хакында Ялта музее хезмәткәре Якуб Кемал махсус мәкалә бастыра. Әмма 30—40 нчы елларда кулъязма юкка чыга.

«Нәһҗел-фәрадис»нең татар кешеләре тарафыннан соңрак күчерелгән янә берничә кулъязмасы бар. Аларның күпчелеге Казанда, берничәсе Санкт-Петербургта саклана.

Гомумән, Мәхмүд Болгари әсәре тулы килеш тә, аерым кисәкләр рәвешендә дә татарлар арасында элек-электән киң таралган.

«Нәһҗел-фәрадис» Ш. Мәрҗани, Б. Яфаров, Х. Хисмәтуллин, Ш. Абилов, Ә. Нәҗип, Х.Миңнегулов, Ф. Нуриева һәм башка татар галимнәренең игътибарын үзенә тарткан. Аларның бу ядкяр хакында кызыклы гына мәкалә-хезмәтләре бар.

Әсәрнең төзелеше.

«Нәһҗел-фәрадис»— зур күләмле, дини-дидактик характердагы чәчмә әсәр. Аның төп өлеше дүрт бабтан (бүлектән) гыйбарәт. Ә һәр баб унар фасылга, ягъни бүлекчәгә аерылган. Барысы — 40 фасыл. Әсәрнең бу рәвешле төзелүен автор Мөхәммәд пәйгамбәр сүзләренә (хәдисенә) бәйләп аңлата. Әгәр дә берәү, диелә ул хәдистә, пәйгамбәрнең 40 данә хәдисен үзгәләргә өйрәтсә, ул кеше галим-голәмәләр рәтендә хисаплана; мондый зат, үлгәч, шәһидләр (дин юлында корбан булучылар) җөмләсеннән санала. Шунысын да әйтик: мондый төзелештәге әсәрләр язу, гомумән, Урта гасыр мөселман дөньясы, аеруча гарәп әдәбияты өчен чит түгел.

«Нәһҗел-фәрадис»тагы тәүге ике бабның үзәген Мөхәммәд пәйгамбәрнең, аның якыннарының, гаиләсенең, беренче хәлифәләрнең, имамнарның тормыш хәлләре, эш-гамәлләре һәм бу персонажларга мөнәсәбәтле гыйбрәтле сюжетлар тәшкил итә. Соңгы ике бабның тематикасы — Аллага якынайтучы һәм аннан ераклаштыручы эш-гамәлләр турында. Китапка, баб һәм фасылларның тематикасына нисбәтән, төрле зурлыктагы күп санлы хикәятләр кертелгән. Рабгузый кебек, Мәхмүд Болгари да хикәят сюжетларын Шәрык халыкларының фольклорыннан, язма чыганакларыннан (Коръән, Газали, Гаттар әсәрләре

һ. б.) алган. Әмма ул аларны үзенең иҗат максатларыннан чыгып үзгәртә, эшкәртә. Шуның нәтиҗәсендә Йосыф — Зөләйха кебек билгеле сюжетлар да теге яки бу дәрәҗәдә үзгәрәк яңгыраш ала.

Әсәр эчендәге һәр бабның, һәр фасылның гомуми корылышында билгеле бер охшашлыклар күзәтелә. Автор, кагыйдә буларак, әүвәл Мөхәммәд пәйгамбәр хәдисен китерә, аның эчтәлеген, төп мәгънәсен аңлата, төрле абруйлы кешеләргә мөнәсәбәтле аерым фикерләрне, эпизодларны бирә. Алга таба исә укучыларга хәдис темасына туры килешле хикәятләр тәкъдим ителә. Ахырда әйтелгәннәргә йомгак ясала, гыйбрәтле нәтиҗәләр чыгарыла. Китапта аерым хәдисләр, галимнәрнең фикерләре, кагыйдә буларак, әүвәл гарәпчә, аннан шәрех юлы белән иске татар телендә бирелә.

Хикәятләрнең идея-эстетик үзенчәлекләре.

Мәхмүд Болгари фикеренчә, кеше — үзенең табигате, яратылышы белән олуг зат. Шуңа күрә аның әхлакый йөзе, эш-гамәлләре җисеменә лаек булырга тиеш. Автор сабырлык, тугрылык, гыйлемлелек, тыйнаклык, ата-ананы хөрмәт итү, Аллага бирелгәнлек, тәүбә кылу, хәләл көч белән яшәү һәм башка шундый уңай сыйфатларны, эш-гамәлләрне төрлечә зурлый, аларның капма-каршыларын (тәкәбберлек, гайбәт сату, комсызлык, икейөзлелек, үч тоту, ялган сөйләү, мәкерлелек, зина кылу, хәмер эчү һ. б.) кискен тәнкыйтьли. Автор карашынча, оҗмах ишекләре бары тик матур әхлакый сыйфатларга, гуманистик эш-гамәлләргә ия булган кешеләр өчен генә ачык; начарлык исә Алладан ераклаштыра, тәмугка якынайта. Шуңа күрә ул укучыларны үзе идеал күргән рухта тәрбияләргә омтыла.

Хәзер аерым хикәятләргә тукталып китик. «Шәйх Ибне Гыймран һәм казый» хикәятенең сюжеты түбәндәгечә: бик юмарт, кешелекле бер шәйх була. Аның өеннән мосафирлар, дәрвишләр өзелми. Шәйх Ибне Гыймран үзендә нәрсә бар, килгән кешеләрне шуның белән хөрмәт итә. Бервакыт аңа күп кенә кунаклар җыела. Әмма өйдә һич ризык юк. Нишләргә? Шәйх үтенеч белән шәһәр казыена бара. Әмма казый аңа ярдәм итми. Күңеле төшкән Ибне Гыймранга юлда бер яһүд очрый, шәйх аңа үтенечен белдерә. Шунда яһүд Ибне Гыймран сораганча алтын бирә. Шәйх шул алтынга азык-төлек алып өенә кайта, андагы «мосафирлар»ны, «дәрвишләр»не сыйлый. Кунакларның һәммәсе дә «яһүдигә иман догасы кыла».

Шул кичтә казый төш күрә: «кыямәт булмыш», халыкның бер өлеше оҗмахка, икенче өлеше тәмугка бара. Казый оҗмах капкасына («капугына») килә. Эчтә бик матур «күшек» (өй, сарай). Казый анда узарга тели. Әмма аны фәрештәләр туктата. Шунда казый бу гамәлнең сәбәбен сорый. Фәрештәләр аңа болай ди: «Бу күшек синеке иде. Әмма син шәйх Ибне Гыймранның үтенечен канәгатьләндермәдең. Шуның өчен Хак Тәгалә бу күшекне яһүдкә бирергә фәрман кылды».

«Нәһҗел-фәрадис» — ислам дине рухы белән сугарылган әсәр. Әмма анда кешеләргә бәя, нинди диннән булуларына карап түгел, кылган гамәлләренә мөнәсәбәттә бирелә. Шәйх һәм казый турындагы хикәяттә кешегә ярдәм иткән яһүд саран мөселман казыеннан өстен куела.

Хикәятләрдә тормышка, иҗтимагый мөнәсәбәтләргә хас булган аерым мөһим күренешләр гәүдәләнеш таба. «Ата һәм бала мәхәббәте» бу яктан шактый гыйбрәтле.

«Бервакыт бер ата үзенең кечкенә улы белән сахрага йөрергә чыга. Бер кош болар алдыннан очып китә. Бала этисеннән бу кошның нинди икәнлеген сорый. Этисе:

— И углым! Бу кош аты фәлән,— дип җавап бирә. Бераз йөргәч, янә ул кош очрый. Бу хәл җиде (символик сан!) мәртәбә кабатлана. Этисе улының һәр соравына, «һич агырыксынмыйча», «лотыф» (әдәп, итагать) белән җавап бирә.

Еллар уза, ата картая, улы егет була. Шулай бер очрак туры килә: ата белән угыл кошның исемен сораган теге җирдән узалар. Этисе тәҗрибә өчен улыннан очып киткән кошның исемен сорый. Улы җавап бирә. Икенче мәртәбә ул кош күренгәч, карт ата улына янә сорау белән мөрәҗәгать итә. Шунда ул мондый җавап ишетә:

— И ата! Картайдың, акылың зәгыйфьләнде, юләр булдың. Әле яңа гына ул кошның исемен әйттем, ә син шунда ук оныттың.

Шунда ата, күзеннән яшьләр түгеп, үзенең хәтере калуын әйтә. «Мин,— ди ул,— теге вакытта синең җиде соравыңа да әйбәтләп җавап бирдем. Ә син икенче сөалемдә үк мине рәнҗеттең». Мәгълүм булды кем, угыл-кыз мәхәббәте ата-ана мәхәббәтенә йитмәс ирмеш».

Мәхмүд Болгари, гомумән, ата-ана һәм бала мөнәсәбәтләрен яктыртуга зур урын бирә. Әсәрдә, бер яктан, бала ата-анасын хөрмәт итәргә бурычлы дигән фикер уздырыла. Икенче яктан, бала тәрбияләү — ата-ананың төп вазифасы, дип карала.

«Нәһҗел-фәрадис»та суфичылык үзен нык сиздерә. Изгелек, дәрвишлек мактала, хакимияткә тартылу, байлык җыю, нәфескә бирелү тәнкыйтьләнә. Бу яктан, «Төрмәгә бару» хикәяте игътибарга лаек.

Матур әхлакый сыйфатларны, гуманистик эш-гамәлләрне автор иң беренче чиратта фәкыйрьләрдә, дәрвишләрдә, гадәти кешеләрдә күрә. Бер хикәяттә Ибне Габбас дигән бер зат сәфәр вакытында бер ярлы гарәптә туктый. Йорт хуҗасы, соңгы куен чалып, Ибне Габбасны кунак итәргә җыена. Шунда хатыны: «Бу куйдан башка безнең бернәрсәбез дә юк, аны да суйсак, балаларыбыз ач калыр, ничек яшәрбез?» — диюенә, ире: «Миңа саран булып яшәүдән үлем артык»,— дип җавап бирә».

Әмма, гомумән, Мәхмүд Болгари, кайбер суфилар кебек, дөньяви тормышны кире какмый, яшәештә ул гаделлекне, хәләл көч белән мал табуны яклый. Аның идея-эстетик карашлары әхлакый кануннар белән тыгыз үрелгән.

Урта гасырның күп кенә әдипләре кебек үк, «Нәһҗел-фәрадис» авторы да үз идеалын уңай образлар, үрнәк эш-гамәлләр аркылы гына гәүдәләндерми. Ул еш кына аларның капма-каршыларына да мөрәҗәгать итә. Мәхмүд Болгари фикеренчә, бөтен начарлыкның нигезе — хәмер эчүдә. «Бәрсыйса һәм хәмер» хикәятендә изгелеге белән танылган кеше дә хәмер эчү аркасында зина кыла, кеше үтерә һәм, теге дөньяга киткәндә, иманыннан да мәхрүм ителә. Хәмер эчү кебек үк, ялган сөйләүнең дә нәтиҗәләре аянычлы.

«Нәһҗел-фәрадис»та шушындый бер хикәят бар: «Берәү, кол алу өчен, базарга килә. Тиешлесен сайлый. Кол хуҗасы: «Бу колның бер гаебе бар...—Ул ялганчы торыр...»— ди. Кол алучы: «Бу ялган сүзләмәк анча (бик.— *Х. М.*) яман гаеп ирмәс. Мән бу гаепкә разыймын»,— дип, колны өенә алып кайта.

Беркөн кол, хуҗасы юк чакта, аның хатынына болай ди:

— И хатын! Күрермен кем, бу хуҗаның сезгә һич мәхәббәте юк. Мән сихер кылмак белермен. Ирегез каты йоклаган вакытта кайчы белән аның берничә чәчен миңа кисеп бирегез. Мин алар белән сихер кылырмын, шуннан ирегез сезне каты сөя башлар һәм һич тә сезнең фәрманыңыздан чыкмас.

Хатын риза була.

Кол исә, җаен туры китереп, хуҗасына болай ди: «Бу хатын сине үтерергә форсат көтеп йөри. Аннан сакланыгыз».

Икенче көнне өйлә вакытында хуҗа йоклаганга сабышып ята. Күрә: хатыны, кайчы алып, әкрен генә аның янына килә.

Ир «бу мине үтерергә уйлый» дип белеп сикереп тора да хатынын үтерә. Хатынның туган-тумачалары, бу хәлне ишетеп, ирне үтерәләр. Үз чиратында ирнең якыннары да хатынның кардәшләре белән орышалар, үлүчеләр дә шактый була». Хикәятнең ахырында бу хәлләр «ялган сүзләмәк шомлыгындин» диелә.

«Нәһҗел-фәрадис»тагы хикәятләрнең идея-тематикасы баб һәм фасылларда куелган мәсьәләләргә мөнәсәбәттә бирелгән. Бу— әсәрнең бер үзенчәлеге булып тора.

Хикәятләр күләм ягыннан төрлечә. Мәсәлән, Йосыф — Зөләйха турындагы хикәятләрнең берсе шактый зур күләмле (дистә биттән артык). Анда Кол Гали һәм Рабгузый әсәрләрендәге Йосыф сюжетының төп эчтәлеге гәүдәләнеш тапкан. Образлар системасы, вакыйгалар бирелешенә карап, бу хикәятне повесть дип тә атарга мөмкин.

Китаптагы күп кенә хикәятләр кечкенә күләмле. Алар, кагыйдә буларак, бер-ике эпизодтан гына тора. Әмма ул күренешләр гыйбрәтле.

Еш кына хикәятләр ахырында мәгънәви нәтиҗә ясала. Мәсәлән, мәгънәсе белән «Бәрсыйса һәм хәмер»не хәтерләткән бер хикәяттә Һарут һәм Марут исемле ике фәрештә, хәмер эчү аркасында, Зөһрә белән якынлык кылалар, аның ирен үтерәләр, потка (сынга) табыналар. Ахырда аларны аякларыннан асып куялар. Хикәят ахырында фәрештәләрнең бу хәлгә төшүе «хәмер эчү» аркасында булды дигән нәтиҗә ясала.

Мәхмүд Болгари вакыйга-хәлләрне кабатлау алымын да куллана. Хикәяләү еш кына диалог белән үрелеп бара. Күп кенә хикәятләрнең башламы әкиятләрнең тәүге өлешен хәтерләтә: «Бер хәлифә бар ирде»; «Бер шәйх бар ирде»; «Вакыт эчендә бер падишаһ бар ирде» һ. б. Сүзләрне, җөмләләрне ялгауда «кем», «ирсә» кебек ярдәмче бәрәмлекләр актив кулланыла.

Аерым җөмләләрдә гарәп, фарсы телләренә хас булган синтаксик төзелеш күзгә ташлана. Бу — автор файдаланган аерым материалларның Шәрык телләреннән алынуы белән аңлатыла.

«Нәһҗел-фәрадис» әсәре, «Кыйссасел-әнбия»дәге традицияләрне тагын да баетып, татар прозасын үстерүгә сизелерлек өлешен кертте, мәдәниятебезне күп кенә образлар, фикерләр белән баетты. Татар әдәбиятында XIV йөздә хикәят жанрының активлашып китүе дә Рабгузый, Мәхмүд Болгари, Сәйф Са-

раи исемнәре белән бәйле. «Нәһҗел-фәрадис»ның аерым сюжетлары, мотивлары, образлары кайбер башка әдипләр тарафыннан да файдаланылды. Мәсәлән, Мәхмүд Болгаридагы «Көнчелек һәм комсызлык» хикәятенең сюжеты аерым үзгәрешләр белән Каюм Насыйриның «Кырык вәзир кыйссасы» китабында да кабатлана.

Сораулар һәм бирем

1. Ни өчен Мәхмүд бине Гали Болгари, Сараи кушаматлары белән йөртелә?

2. Әсәр ни өчен «Нәһҗел-фәрадис» дип аталган?

3. «Нәһҗел-фәрадис»ның төзелеше турында сөйләгез.

4. Хикәятләрнең идея-тематикасы нәрсәдән гыйбарәт?

5. Хикәятләргә нинди үзенчәлекләр хас?

Сәйф Сараи

(1321—1396)

Алтын Урда чоры төрки-татар әдәбиятының кульминациясе, — әлбәттә, Сәйф Сараи иҗаты. Анда фольклор һәм борынгы төрки рухи казанышлары, әл-Мәгарри, Сәгъди, Кол Гали, Рабгузый, Котб, Харәзми традицияләре мул файдаланыла, яшәешнең күп кенә идея-проблемалары сәнгатьчә гәүдәләнеш таба.

Сәйф Сараи төрки-татар әдәбиятын, аеруча шигъриятне үстерүгә, язма телне камилләштерүгә үзеннән зур өлеш кертә. Галимнәр аның әсәрләрен XIV йөз төрки әдәбиятның «иң гүзәл үрнәкләре»ннән саныйлар. Әдипнең шигъри таланты үз замандашлары тарафыннан югары бәяләнә.

Сәйф Сараи әсәрләренә шигъри җаваплар да языла.

Әдипнең иҗаты хәзер дә игътибар үзәгендә. Әсәрләренең төрле илләрдә кат-кат басылуы, шагыйрь хакында татар, төрек, үзбәк, рус, венгр галимнәре тарафыннан фәнни хезмәтләр һәм мәкаләләр язылуы — моның ачык мисалы.

«Камышлы йорт бәнем туган илем иде».

Сәйф Сараиның тәрҗемәи хәле хакында мәгълүматлар бик аз. Тормышын ачыклар өчен, әдипнең үз әсәрләренә мөрәҗәгать итәргә туры килә. Бер дүртьюллыгында ул «Камышлы йорт»та тууы, Сарайга белем алырга килүе һәм анда шагыйрь буларак танылуы хакында яза. «Камышлы» — хәзерге Камышин шәһәре урынындагы кала.

Шунысы да мәгълүм булсын: рус патшалары Түбән һәм Урта Иделдә шәһәрләр, крепость-кальгалар салдыруны XVI йөзнең икенче яртыларында — XVII гасырларда башлап җибәрәләр. Мондый калалар, кагыйдә буларак, Хәзәр, Болгар, Алтын Урда, татар мәмләкәтләре заманында төзелгән һәм соңрак җимерелгән шәһәр-авыллар урынында корыла. Күп очракта шәһәрләрнең элеккеге исеме дә шул килеш саклана: Самара (Самар), Саратов (Сарытау), Астрахань (Хаҗитархан, Хаҗтархан, Әстерхан), Симбирск (Сембер) һ. б. Яңа шәһәрләр

искеләренең биналарын, сарай һәм мәчетләрен сүтү, алардан алынган кирпеч, таш исәбенә салына.

Аерым мәгълүматларга таянып, Сәйф Сараиның туган елы 1321 ел дип фараз кылына.

Алтын Урда башкаласына килгәч, Сәйф Сараи кайда укыган, остазлары кемнәр булган, нинди хезмәтләр башкарган — болар хәзергә мәгълүм түгел. Тик шунысы ачык: Сәйф Сарай шәһәрендә белем алып, шунда шагыйрь булып танылган; кушаматы да Алтын Урда пайтәхетенә мөнәсәбәтле.

XIV йөзнең 60 нчы елларыннан башлап Алтын Урда дәүләтендә яшәү һәм иҗат итү өчен шартлар кыенлаша. Шул сәбәпле галим-әдипләрнең күбесе башка җирләргә китәргә мәҗбүр була. Аларның бер өлеше Кече һәм Урта Азиягә, зур төркеме Мисырга барып чыга.

70—80 нче елларда Сәйф Сараи да Идел буен калдыра. Ул үз ватаныннан аерылып читтә яшәүне авыр кичергән, һәм бу тойгылары аның шигырьләрендә дә гәүдәләнгән.

Сәйф Сараи, Алтын Урда башкаласыннан киткәч, туп-туры Мисыр-Сүриягә эләккәнме я булмаса башка төбәкләрдә дә бераз яшәп алганмы — монысы хәзергә караңгы. «Гөлестан бит-төрки» әсәре әдипнең 80 нче еллар азагында — 90 нчы еллар башында инде Мисырда яшәвен һәм иҗат итүен төгәл күрсәтә.

Идел буеннан күчкән галим-әдипләр төрле фәннәрне һәм гарәп, фарсы, төрки телләрне яхшы белгәннәр. Шул сәбәпле алар Мисыр-Сүрия кебек бай мәдәниятле илләрдә җаваплы һәм җитди урыннарда (мәдрәсәләрдә, хакимият оешмаларында, дипломатиядә һ. б.) эшләгәннәр. Мисырга килгәч, иҗаттан тыш, Сәйф Сараи солтан сараенда да эшләгән булса кирәк.

Сәйф Сараиның, язуда теркәлеп, безгә килеп җиткән әсәрләре 1394 ел белән чикләнә. Озак та үтми, 1396 елда әдип үзе дә үлеп китә.

Әдипнең иҗат мирасы.

Сәйф Сараи иҗат иткән әсәрләрнең бер өлеше безнең заманга «Китабе Гөлестан бит-төрки» һәм «Ядгярнамә» дип исемләнгән ике кульязмада килеп җиткән. Аларның беренчесе (ул XIV йөз азакларында төзелгән) хәзер Голландиянең Лейден университеты китапханәсендә саклана. Кульязманың фотокүчермәсе 1954 елда төрек профессоры Фәридүн Үзлүк тарафыннан Әнкарада нәшер ителде. Лейден нөсхәсендәге текстлар 1968, 1973, 1986 елларда үзбәк, 1969 елда Будапештта латин, 1980 елда Казанда гарәп шрифтында нәшер ителделәр.

373 биттән гыйбарәт булган «Китабе Гөлестан бит-төрки» («Төркичә Гөлестан китабы») кульъязмасының төп өлешен (3—356 б.) Сәйф Сараиның «Гөлестан бит-төрки» әсәре алып тора. Башка битләрдә сигез төрки-татар шагыйренең парчалары (җиде газәл һәм бер касыйдә) һәм Сәйф Сараиның аларга шигъри җаваплары бирелгән. Болардан тыш, авторның дүрт газәле, «Шагыйрьләр хакында»гы шигыре, бер бәетлек хикмәтле сүзе, биш робагые (шуларның икесе төрки-татар, өчесе фарсы телендә) урнаштырылган.

Сәйф Сараи әсәрләрен туплаган икенче кульъязма — «Ядгярнамә»—1960 елларда Үзбәкстанның Коканд районында табылган. Аны китап иясенең XVIII гасырда яшәгән ерак бабасына, Гарәбстанга хаҗ сәфәренә барганда, бер сәүдәгәр бүләк иткән.

«Ядгярнамә»— дистәдән артык битле кечкенә бер җыентык. Ул Әбүл Ибне Кадыйр дигән мосафирның кереш сүзе белән ачыла. Бу кеше үзенең Мисырга килүе һәм анда әлеге җыентыкны төзүе турында яза. Керештән соң Туглы Хуҗа һәм Мәүлана Исхакның берәр газәле, Мәүлана Әхмәд Үргәнчинең өч шигъри парчасы урнаштырылган.

«Ядгярнамә»нең 4—12 нче битләрен Сәйф Сараиның өч робагые, ике икеюллыгы һәм «Сөһәйл вә Гөлдерсен» дастаны алып тора. Сәйф Сараиның хәзергә мәгълүм иҗат мирасы шушы ике җыентыктан гыйбарәт. Алар, нигездә, шагыйрь гомеренең соңгы 5—6 елына гына карый.

Сәйф Сараи әсәрләренең тулы басмасы 1999 елда «Гөлестан. Лирика. Дастан» исеме белән Казанда нәшер ителде.

«Гөлестан бит-төрки».

Сәйф Сараи — тәрҗемә, оригиналь һәм нәзыйрә әсәрләр авторы. Аның иҗат мирасында мөһим урынны «Гөлестан бит-төрки» («Төркичә Гөлестан китабы», 1391) алып тора. Ул Сәгъдинең фарсы телендәге «Гөлестан» әсәренә (1258) мөнәсәбәттә туган. Бу китап — дөнья күләмендәге мәшһүр ядкяр. Ул тулы килеш тә, өлешләп тә бик күп телләргә тәрҗемә ителгән, йөзәрләгән әсәрләр туудa чыганак, материал рәвешендә файдаланылган. Үтемле, гыйбрәтле «Гөлестан»ның мәктәп-мәдрәсәләрдә дәреслек-хрестоматия рәвешендә кулланылуы да мәгълүм. «Кәлилә вә Димнә», «Мең дә бер кичә», «Тутыйнамә» кебек, бу әсәр дә татар дөньясында бик популяр була. Аның оригиналь нөсхәләре, тәрҗемә-шәрехләре бездә күпләп очрый.

«Гөлестан» тоташ сюжетлы әсәр түгел: ул, шигырь белән аралаштырылып, рифмалы проза белән язылган чагыштырма-

ча мөстәкыйль хикәятләр (барлыгы 180 нән артык), шигырьләр тупламыннан гыйбарәт. «Нәсыйхәт», «Хикмәт» дип исемләнгән парчалар да бар. Әсәрдәге хикәятләр һәм башка төр композицион берәмлекләр, тематик яктан 8 бабка (бүлеккә) бүленеп, түбәндәгечә исемләнгәннәр: I — патшалар тормышы турында, II — дәрвишләр әхлагы, III — аз белән канәгать булуның хәере, IV— эндәшмичә торуның файдасы, V— мәхәббәт һәм яшьлек, VI — картлык һәм зәгыйфьлек, VII — тәрбиянең тәэсире һәм VIII — сохбәт (сөйләшә, аралаша белү) әдәбе турында. Китапның берничә битен традицион кереш һәм бетем өлешләре тәшкил итә.

Сәйф Сараиның «Гөлестан бит-төрки»е, гомумән, тәрҗемә әсәр дип хисаплана. Чөнки анда әдип, нәкъ Котбның «Хөсрәү вә Ширин»ендәге кебек, оригиналның төзелешен, төп эчтәлеген саклаган. Бу аеруча чәчмә текстларны бирүдә ачык күренә. Шигъри өлешләрдә исә төрлелек күзгә ташлана: биредә без төгәл һәм ирекле тәрҗемәне дә, нәзыйрә ысулы белән язылган юлларны да, оригиналь шигырьләрне дә очратабыз. Мәсәлән,

Сәгъди (тәрҗемәдә):

Бакчада үлән шыткан саен,
Йөрәгемә шатлык тулды.
Язларын кил, и дустым, (каберемә),
Күрерсең үләннең минем туфрактан үсеп чыкканын.

Сараи:

Шад булыр күңел ничә күрсә,
Җөмлә (барлык.— *Х. М.*) сәхра йөзен чичәк тотмыш.
Килсәң, и дуст, күргәсән (күрерсең.—*Х. М.*): элек яз
Тубракым өстенә яшь ут бөтмеш (үлән чыкмыш.—*Х. М.*).

Бу шигырендә Сәйф Сараи оригиналдагы эчтәлеккә, сурәтләргә һәм шигъри үлчәмгә тугрылыклы калган.

«Картлык һәм зәгыйфьлек турында»гы бабта Сәгъдинең мондый шигыре бар:

Карчык чәчен карага буяган,
Мин аңа әйттем: «И карт анакай,
Чәчеңне тырышып каралта алырсың,
Тик бөкрең инде турайммас!»

Сәйф Сараи исә, шушы робагыйга таянып, 12 юллык шигырь иҗат иткән. Үз тезмәсендә ул хатынның картлыгын яңадан-яңа детальләр, троплар ярдәмендә («теше аз», «киселде йөк күтәргән көч билеңдин», «җәмалың багы, гөлзары сулыб-

дыр» һ. б.) тасвирлый. Сәгъди, ничектер, карчыкны гаепләп сөйләгән кебек, Сараи исә карт анага рәхимле карап, аның хәленә кереп сөйли.

Шигырьнең соңгы юллары да мәгънәлерәк һәм моңсурак яңгырый:

Ул әйтте: «Раст (дөрес.—*Х. М.*) әйттең, әй егет сән,
Нәдайим кем, җәһандән туймайуб бән»
(Нишлим соң, җиһанда яшәүдән туймадым мин.—*Х. М.*).

Бу күренеш, ягъни, бер шагыйрьнең юлларын алып, андагы эчтәлеккә бәйләнешле рәвештә үзеннән өстәп иҗат итү, әдәбият белемендә контаминация дип тә йөртелә. Бу алым Шәрык, шул исәптән татар әдәбиятында бик киң таралган була.

Сәйф Сараи әсәренең нәзыйрә (охшатма) һәм контаминация юлы белән язылган юллары оригинал белән чагыштырганда кайвакыт үзенчәлеклерәк фикерне белдерсә дә, гомумән караганда, Сәгъди рухы белән каршылыкка керми. Киресенчә, бу алым төрки-татар укучысы өчен үтемлерәк булып чыга. Мондый хәл аның оригиналь шигырьләре өчен дә чит түгел. Мәсәлән, Сараи китабының керешендә яз күренешен тасвирлаган биш бәетлек шигырь Сәгъдидә юк. Әмма «Гөлестан» авторы да нәкъ шул урында чәчмә рәвештә язгы табигатьнең үзгәрүен тасвирлап китә. Сәйф Сараи, шушы күренеш белән рухланып, язның гүзәллеген шигырьдә чагылдырган. Шунлыктан «Гөлестан бит-төрки»дәге оригиналь юлларның төп текст белән бәйләнешен һич тә онытырга ярамый.

Мәгълүм ки, бик күп гарәп-фарсы сүзләре төрки-татар теленә кергән. Алар, кагыйдә буларак, фарсы һәм татар телләрендә уртак мәгънәдә йөриләр. Сәйф Сараи бер урында аларны турыдан-туры үз текстына кертеп җибәрсә, икенче урында татарның үзендәге синонимнар белән алыштыра: *дуст — йар, абруй — йөз суы,саба — таң,камәр — ай* һ. б.

«Гөлестан бит-төрки» авторы фарсы текстында тотрыклы тәгъбирләр, фразеологизмнар белән төрлечә эш йөртә. Әгәр дә бу төр берәмлекләрнең эчтәлеге татар укучысына аңлаешлы икән, Сәйф Сараи аларны турыдан-туры тәрҗемә итә. «Җәһан диде бесийар гуйәд доруг» (Сәгъди) — «Җиһан күргән кеше күп ялган әйтер» (Сараи).

Аерым очракларда төрки-татар әдибе, үз укучысының образлы фикерләү үзенчәлеген исәпкә алып, оригиналдагы элементларны теге яки бу дәрәҗәдә үзгәртеп тәрҗемә итә.

Сәгъди (тәрҗемәдә):

Бик нык сусаган (кеше) саф чишмәгә барып җитсә,
Ярсу филләрдән куркып калыр димә.

Сараи:

Йитсә татлы суга сусамыш ир,
Курыкмас алдында булса аждәрһа.

Татар укучысы өчен «аждаһа» (аждәрһа) «котырган фил» образына караганда тәэсирлерәк. Чөнки «аждаһа»ның иң куркынычлы мифик сурәт булуы татарлар күңеленә үз экиятлегендалары аркылы сеңдерелгән. Мондый үзгәртүләр кайвакыт ритм, үлчәм һ. б. таләпләр белән дә эшләнә.

Сыйгар бер хөҗрәгә уникке миһман,
Бер икълимә сыйгышмас икке солтан.
(Бер бүлмәгә унике кунак сыяр,
Бер илгә ике солтан сыешмас.)

Оригиналда бу фикер чәчмә рәвештә бирелгән. Тәрҗемәче Сәгъдидәге «ун дәрвиш бер паласта да йоклый ала» дигән юлны үзгәртеп биргән. «Ике солтан»га нисбәтән рәвештә «уникке миһман» дию төп идеягә зыян итмәгән. Чөнки контекст эчендә 10 яки 12 саннарының һәм «дәрвиш», «миһман» сүзләренең образлы вазифалары уртак.

Шактый гына урында автор фарсы фразеологизмнарын татар телендәге эквивалент (бердәй мәгънәле) әйләнмәләр белән алыштыра.

Сәгъди (тәрҗемәдә):

Остаз вә мөгаллим кырыс булмаса,
Балалар базарда «аю куып» уйнар.

Сараи:

Мөгаллим булмаса һәйбәтле, и йар,
Сакалыңдан тотыб угланлар уйнар.

Кыскасы, Сәйф Сараи оригиналга, Сәгъдинең образлы фикерләү чараларына иҗади якын килгән. Шагыйрьнең фарсы һәм төрки телләрен, әдәбиятларын камил белүе, көчле таланты, бай иҗат тәҗрибәсе аңа мөстәкыйль идея-эстетик кыйммәткә ия булган әсәр тудырырга ярдәм иткән. Шуңа күрә дә «Гөлестан бит-төрки» татар әдәбияты тарихында гына түгел, гомумән, Урта гасыр төрки дөньясында да кыйммәтле ядкярләрнең берсе исәпләнә.

* * *

Бабларның исемнәре үк «Гөлестан бит-төрки»дәге тематик төрлелекне күрсәтеп тора. Автор чынбарлык һәм кешеләр тормышының гыйбрәтле, гаҗәеп күптөрле күренешләре аша безнең бүгенге яшәешебездә көннән-көн кими барган гаделлек, тыйнаклык, сүз һәм эш берлеге, тугрылык, юмартлык, киң күңеллелек кебек матур әхлакый сыйфатларны алга сөрә, төрле чаралар ярдәмендә аларның капма-каршыларын (антиподларын) гаепли, кире кага. Шунысы мөһим: әдип әхлакый төшенчәләрне еш кына яшәешнең башка мәсьәләләре белән тыгыз мөнәсәбәттә карый. Мәсәлән, автор фикеренчә, хөкемдарның гадел, кешелекле, белемле булуы шарт; бүре куйларга көтүче була алмаган кебек, «залим» патша да «рәгыйятькә», ягъни халыкка, җитәкче була алмый — андый хөкемдар алып ташланырга тиеш. Күрәсез: бу мәсьәләләрне хәл итүдә Сәйф Сараи Йосыф Баласагунлыга һәм Котбка аваздаш эш итә.

Гамәлсез галимне балсыз корт белән тиңләп, Сәйф Сараи белемлелек төшенчәсенә иҗтимагый мәгънә сала.

Мозаик төзелешле «Гөлестан бит-төрки» әсәре аша укучы күз алдына бүгенгедәй катлаулы, ыгы-зыгылы, каршылыклы чынбарлык килеп баса; әсәрне укыганда, без комик, драматик, фаҗигале хәлләргә юлыгабыз. «Гөлестан бит-төрки»нең үзәгендә төрле табигатьле һәм төрле социаль хәлле кешеләр, аларның эш-гамәлләре, уй-теләкләре, фикер-кичерешләре. Бер тәннең әгъзалары кебек үзара бәйләнештә торган җәмгыять кешеләренең төп вазифалары һәм яшәү мәгънәләре — игелекле хезмәттә һәм бер-берсенә, башкаларга бәхет, шатлык китерүдә. Бу — әсәрдән саркып чыккан төп фикер.

Сәйф Сараи төрле юллар белән шәхесне олылый, аны түбәнсетүгә, кеше гомерен кисүгә каршы килә.

> Тере ирне иңән асан (бик ансат.—*Х. М.*)
> орып үк берлә үлтермәк,—
> Вәликен үлене мең кем ирсә тергезә белмәс,—

диюе белән шагыйрь чын гуманистларча чыгыш ясый.

Сәйф Сараи шигъри сүз белән гаҗәеп иркен эш итә, шуның нәтиҗәсендә аның күп кенә юллары чагыштырмача гадәти, әмма гаять үтемле яңгырый. Мәсәлән:

> Эчереп илгә кашык берлә шурпа,
> Чүмеч сабы белән күзен чыгарма.

«Гөлестан бит-төрки» өчен тормышчанлык, фикри тирәнлек, үгет-нәсыйхәт белән образлылыкның табигый кушылуы хас. Кечкенә генә хикәятләрдәге, шигъри парчалардагы фикерләр зур-зур әсәрләр өчен нигез булырлык. Сәйф Сараи иҗатында без Йосыф Баласагунлы, Котб әсәрләреннән, халык мәкальләреннән һәм дастаннарыннан килүче афористик фикерләүнең, хикмәтле сүз әйтүнең интертекстуаль кулланылышын, үстерелешен күрәбез. Шунысы куанычлы: бу традиция алга таба «Идегәй»дә, Мөхәммәдьяр, Акмулла, Дәрдеманд әсәрләрендә дәвам итә.

Сәйф Сараиның «Гөлестан бит-төрки» әсәре төрки-татар әдәбиятын мөһим фикерләр, яңа сурәтләр, кызыклы шигъри алымнар белән баетты, телебезнең шигъри офыкларын тагын да киңәйтеп, сүз белән иҗади эш итүнең матур үрнәкләрен бирде. Бу ядкяр,— фарсы һәм татар әдәби багланышларын өйрәнү өчен дә, мөһим бер чыганак.

«Сөһәйл вә Гөлдерсен».

Бу дастан (1394) — Сәйф Сараи язган оригиналь әсәрләрнең иң күренеклесе. Аның кыскача эчтәлеге болай: Аксак Тимер гаскәр белән Үргәнечкә һөҗүм итә, анда күп явызлыклар эшли: игенче өйләре яндырыла, җирдә «су кебек» кан ага. Сугышта Сөһәйл исемле бер гаскәри әсир төшә. Аяк-кулларын богаулап, аны тирән чокырга — зинданга ташлыйлар. Якыннары белән күңел ачып йөргән шаһ кызы Гөлдерсен бу хәлне күреп кала, һәм егетнең төс-кыяфәте шунда кызны җәлеп итә. Бу вакыйгадан соң Гөлдерсен Сөһәйл белән очрашу чарасын эзли башлый. Ниһаять, юл табыла: беркөнне кич Гөлдерсен зиндан сакчысы янына бара һәм алып килгән азыкларын аңа бирә. Сакчы аларны ашау белән йокыга китә (мөгаен, Гөлдерсен ризыкка берәр төрле йоклаткыч кушкандыр). Форсаттан файдаланып, кыз Сөһәйл янына төшә, һәм алар күрешәләр. Шул кичне ике гашыйк бергәләп качалар; шактый баргач, аларның юлы сахрага керә. Сусызлыктан һәм ачлыктан Сөһәйл белән Гөлдерсен бик йончыйлар. Кызны коткару өчен, Сөһәйл су, азык эзләп китә. Ул әйләнеп килүгә, Гөлдерсен үлгән була. Кайгы белән дөньяда яшәгәнче, ярың белән үлү яхшырак дип, Сөһәйл үзүзенә хәнҗәр кадый. Шулай итеп, ике гашыйк һәлак була.

Аерым фактлар дастан сюжетының реаль җирлеге булу ихтималлыгына да ишарә ясыйлар. Беренчедән, автор үзе бу хәлнең «чын» икәнлеген кат-кат телгә ала. Икенчедән, халык телендә әсәр сюжетына охшашлы легендалар яши. Аларда егет Туктамыш хан улы, ә Гөлдерсен Аксак Тимер кызы дип

күрсәтелә. Чиләбе өлкәсендәге мәшһүр «Тамерлан манарасы» да бу легендаларга бәйләнешле. Риваятьтә сөйләнгәнчә, Аксак Тимер сугышчылары хәзерге Тамерлан станциясе тирәсендә егет белән кызны куып җитәләр. Тигезсез сугышта егет һәлак була. Кыз исә үз-үзен хәнҗәр белән кадап үтерә. Ахырдан, имеш, Аксак Тимер шул урынга манара кордыра. Кыскасы, Сәйф Сараиның үз әсәренә нигез итеп билгеле бер тормыш вакыйгасын алуы бик мөмкин.

«Сөһәйл вә Гөлдерсен» әсәренең сюжеты, бер яктан, Шәрык әдәбиятларында киң таралган Ләйлә — Мәҗнүн, Хөсрәү —Ширин, Гөл һәм Нәүрүз кебек парларның мәхәббәтен искә төшерсә, икенче яктан, поэмадагы егет белән кыз тарихы билгеле бер чорның, җирнең реаль атмосферасын сиземләргә дә мөмкинлек бирә. Әсәрнең тәүге юлларында ук:

> Әйтим аглабан (елап.— *Х. М.*) дәүрем җәфасын,
> Бер ирнең кыйссасын — әхчи (ачы.—*Х. М.*) вафасын,—

ди автор. Димәк, әдипнең игътибары беренче чиратта «дәүр җәфасы» на юнәлгән. Ә инде Сәйф Сараи чорында «җәфа» лар хәттин ашкан һәм аларның күпчелеге Аксак Тимернең яулап алу сугышлары нәтиҗәсе булып тора. Бу сугышлар шул дәвер кешеләре алдында гаять зур афәт булып баскан. Ул чорның алдынгы кешеләре Аксак Тимергә каршы фикер әйтүдән дә курыкмаганнар. Мәшһүр галим Мөхәммәд Бәззази (1344—1424) Аксак Тимергә каршы фәтвалар җибәргән. Әхмәд Үргәнчи сатира әсәре язган. Сәйф Сараи исә «Сөһәйл вә Гөлдерсен» дастанын иҗат иткән.

Дастаннарда тарихи үткәннәрне я булмаса хыялый вакыйгаларны гына укырга өйрәнгән Урта гасыр укучысына әсәрдә үз чоры вакыйгалары, күренешләре белән очрашу, әлбәттә, гаҗәбрәк тоелгандыр. Әмма шагыйрь моңа карамый, кыю рәвештә фикерен дәвам итә, аз сүзләр белән Аксак Тимер һөҗүменең аянычлы нәтиҗәсен укучы күз алдына китереп бастыра.

«Дәүр җәфасы» башта гомуми планда тасвирлана. Шагыйрьнең максаты — шул «җәфа» ны кеше язмышы аша бирү, үз сүзләре белән әйткәндә, «бер ирнең кыйссасын — әхчи вафасын» күрсәтү. Һәм автор үз максатына ирешә дә.

Сәйф Сараи Сөһәйл һәм Гөлдерсенне зур теләктәшлек белән тасвирлый. Шәрыкның күп кенә башка шагыйрьләре кебек үк, аны да гадәти матурлык кына канәгатьләндерми, аның каһарманнары гадәттән тыш матурлыкка ия булсын. Моңа

ирешү өчен, ул халык иҗатындагы һәм язма әдәбияттагы төрле сурәтләрдән, поэтик алымнардан иркен файдалана.

Сөһәйл хөсне (матурлыгы.— *Х. М.*) ирүр Йосыфдин
гали (өстен.—*Х. М.*),
Итәр мат алманы йөзенең алы,—

ди автор, үз каһарманын тасвирлап. Ул аны «көнәш»кә дә, «гөл»гә дә тиңли. Ә аның Гөлдерсене исә «дилкәш» (сокландыргыч), ай кебек, матурлыгы «гөл йөзе»ннән дә артык. Урта гасыр фарсы һәм төрки поэзиясендә хатын-кыз матурлыгын «пәри» белән чагыштыру киң таралган. Бу сурәт Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ында да очрый. Сәйф Сараи да Гөлдерсенгә карата пәри образын иркен куллана.

Автор каһарманнарга үзе характеристика бирү белән генә чикләнми, ә аларны бер-берсе аша тасвирлау алымына да мөрәҗәгать итә. Мәсәлән, зинданда ятучы Сөһәйлне Гөлдерсен җиргә ташланган «ал гөл» белән чагыштыра.

Дастан каһарманнары тышкы яктан гына түгел, ә рухи сыйфатлары, омтылыш-теләкләре, үзара мөнәсәбәтләре белән дә матур. Бер генә мисалга игътибар юнәлтик. Сөһәйлне күргәч, Гөлдерсендә мәхәббәт хисләре кабына. Кыз үзен «гөл», ә егетне читлектәге «былбыл» итеп тоя. Бу чагыштыру Сөһәйлнең хәленә карата укучыда ризасызлык тойгысы да уята: ни өчен шундый «кави» (көчле), матур кеше читлектәге былбыл кебек зинданда ята? Бу — хаксызлык; егет, һичшиксез, азат булырга тиеш!

Укучыда әсәр каһарманнарына карата теләктәшлек хисе уянуда Сөһәйл белән Гөлдерсен хәрәкәтләренең гуманистик юнәлештә булуы да зур роль уйный. Әсәрдә тасвирланган шартларда кызның егетне коткаруы — зур батырлык. Гөлдерсен үлгәч, Сөһәйлнең үз-үзен юк итүе кызның олы мәхәббәтенә егетнең конкрет җавабы булып тора. Бу күренеш, бер яктан, аларның вәгъдәләренә тугрыныклы калуларын күрсәтсә, икенче яктан, капма-каршы тарафтагы ике яшь йөрәкнең тормыш рәхимсезлегеннән һәлак булуы Сараи чорындагы гаделсезлекләргә, золым ияләренең башбаштаклыгына протест булып та яңгырый.

Сөһәйл белән Гөлдерсеннең фаҗигале язмышы шәхси бәхетнең иҗтимагый шартларга бәйле булуын да күрсәтә. Автор, мөгаен, шул хакыйкатьне аңлап, «киң сарай»ны, ягъни дөньяны, «золым»нардан азат кылырга чакыра. Бу — шагыйрь оптимизмының һәм иҗтимагый идеалының күркәм бер гәүдәләнеше.

Мәгълүм ки, борынгы төркиләрдә, аерым алганда, болгарларда һәм кыпчакларда, XIV йөзләрдә формалашып җиткән татарларда хатын-кызның җәмгыятьтәге урыны чагыштырмача югары булган. Сәйф Сараи, халыкның бу матур традициясенә тугрылыклы калып, Кол Галинең Зөләйхасы, Котбның Ширине шикелле актив, инициативалы, гүзәл хатын-кыз образын иҗат иткән. Бу очраклы хәл түгел. Әдип, гомумән, хатын-кызны ир-ат белән тиң күрергә, аны хөрмәт итәргә чакыра. Хатын-кызга мондый ихтирамлы мөнәсәбәт алга таба Мөхәммәдьяр, Утыз Имәни һәм башка әдипләрнең иҗатларында дәвам иттерелде.

«Сөһәйл вә Гөлдерсен»дә гыйльми яктан да гаять мөһим фикерләр бар. Шагыйрь кызның егетне күргәч борылып куюын Кояш тирәсендә Җирнең әйләнүе белән тиңли («Көнәш гәрдендә йөргән мисле йир тик»). Бу сурәт дөнья фәнендәге Николай Коперник (1473—1543) һәм Джордано Бруно (1548—1600) ачышларына яңача карауны да таләп итә.

Сәйф Сараи үз әсәрен «кыйсса» дип атаган. Кыйссалар шигъри дә («Кыйссаи Йосыф»), чәчмә дә булырга мөмкин. «Сөһәйл вә Гөлдерсен» үзенең характеры белән лиро-эпик рухтагы поэмаларны хәтерләтә. Биредә вакыйгаларны хикәяләү фәлсәфи-лирик уйланулар белән аралашып бара.

Гомумән, «Сөһәйл вә Гөлдерсен» дастаны, гәрчә анда романтик фикерләү, традицион әдәби ысуллар һәм чаралар өстенлек итсә дә, чынбарлык белән тыгыз бәйләнеше, гуманистик асылы, дөньяви мотивларны һәм тормышчан күренешләрне гәүдәләндерүе белән Урта гасыр төрки-татар әдәбиятында күренекле урынны били.

Нәзыйрәчелек. Моңа кадәр инде «нәзыйрә» сүзе берничә мәртәбә телгә алынды. Бу атама нинди төшенчәләрне белдерә соң?

Нәзыйрә — *гарәпчә-фарсыча*: өлге, үрнәк, әдәби җавап, охшатма. 1) Урта гасыр Шәрык, шул исәптән татар әдәбиятында киң таралган иҗат ысулы, поэтик форма; 2) башка бер авторның теге яки бу әсәре тәэсирендә туган, аңа охшатып язылган әсәр.

Әдип үзенә кадәрге яисә үз чорында иҗат ителгән нинди дә булса билгеле бер әсәрнең темасын, сюжет схемасын һәм төп каһарманнарын ала да башка әсәр иҗат итә. Кагыйдә буларак, эпик әсәрдә төп чыганакның темасы, еш кына исеме, сюжетының төп мотивлары саклана. Ә инде лирик парчаларда, әгәр дә алар чыганак белән бер үк телдә булсалар, темадан

һәм үлчәмнән тыш, рифманың, еш кына аерым сурәтләрнең дә саклануы шарт. Нәзыйрәдә әдип мәгълүм теманы ачуда һәм сюжетны эшкәртүдә үзе сайлаган автор белән ярышка чыга, шигъри җавабында ул үз көндәшенең яисә үз остазының әсәрендәге теге яки бу моментларны ныграк ачарга, я аларны кире кагарга, я булмаса бүтәнчәрәк яссылыкта яктыртырга омтыла. Ә инде мондый шигъри бәйгедәге җавапларның оригинальлеге, сыйфаты авторларның талантына һәм тәҗрибәсенә бәйле.

Шәрык әдәбиятының күп кенә классик әсәрләре нәзыйрә ысулы белән иҗат ителгән. Мәсәлән, Нәваиның (1441—1501) «Хәмсә» («Бишлек», «Биш поэма») циклы Низами (1141—1209) һәм Әмир Хөсрәү Дәһләвинең (1253—1325) шул циклдагы һәм сюжеттагы әсәрләренә нәзыйрә булып тора. Сүз уңаеннан шунысы да мәгълүм булсын: Шәрык әдәбиятында нәзыйрә әсәрләренең шактый өлеше Низами поэмалары белән бәйле. Мәсәлән, «Мәхзәнел-әсрар» («Серләр хәзинәсе») әсәренә төрле телләрдә 46, «Ләйлә белән Мәҗнүн»гә 100 дән артык нәзыйрә язылуы билгеле.

Нәзыйрә — милли, региональ әдәбиятларның эчке һәм тышкы бәйләнешләр формасы да; чор һәм җирлек ихтыяҗларыннан чыгып, ул башкаларның казанышларын үзләштерергә, әдипләрнең иҗат мөмкинлекләрен кузгатырга ярдәм итә, үзенә күрә бер поэтик мәктәп булып тора. Нәзыйрәләр, гадәттә, халыкның яңарыш, мәдәни җанлану чорларында активлашып китә.

Татар әдәбиятында нәзыйрә, иҗат ысулы һәм поэтик форма буларак, күптәннән үк кулланылып килә. Котб, Сәйф Сараи, Мөхәммәдьяр, Шәмседдин Зәки, Бабич һәм башкалар аңа еш мөрәҗәгать иткәннәр. Г. Тукай, үз элгәрләреннән аермалы буларак, нәзыйрә өчен Шәрык дөньясы авторларын гына түгел, ә рус һәм Көнбатыш Европа әдипләренең дә әсәрләрен сайлап ала. Ул кайбер элекке татар әдәби ядкярләрен дә нәзыйрә объектына әверелдерә. Мәсәлән, аның «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасы Урта гасырның «Кисекбаш» китабына пародик нәзыйрә рәвешендә язылган.

Сәйф Сараиның нәзыйрә әсәрләре. Лирикасы.

Үз чорының улы буларак, Сәйф Сараи да нәзыйрәчелек традицияләреннән читтә кала алмый. «Гөлестан бит-төрки»дәге аерым парчаларның нәзыйрә һәм аның төрдәше булган контаминация (ялгау) алымы белән иҗат ителүе турында инде югарыда әйтелгән иде. Биредә шуны искәртү урынлы булыр:

Сәйф Сараи фарсы «Гөлестан»ына аңлы рәвештә нәзыйрә язуны максат итеп куймый. «Гөлестан бит-төрки»дәге нәзыйрә алымы белән язылган юлларны тәрҗемә процессында туган иҗади дулкынлануларның ихтыярсыз бер гәүдәләнеше итеп карарга кирәк.

Сәйф Сараи нәзыйрә ысулына аңлы рәвештә махсус мөрәҗәгать итә. Безгә аның 8 төрки-татар шагыйренә (Мәүла Казый Мөхсин, Мәүлана Исхак, Мәүлана Гыймад Мәүләви, Әхмәд Хуҗа Сараи, Харәзми, Габделмәҗид, Туглы Хуҗа, Хәсән углы) җавап рәвешендә язган 7 газәле, 24 строфалы бер касыйдәсе мәгълүм. Бу әдипләр,— нигездә, XIV йөз Алтын Урда әдәбиятының вәкилләре. Алар арасында «мәүлана» титулына ия булган дәрәҗәле кешеләр дә бар.

Сәйф Сараи шигъри теле гаять нәфис һәм стиле камил әсәрләргә нәзыйрә язган. Мондый парчаларга югары сәнгатьле җаваплар язу автордан зур тәҗрибә, тырышлык, талант сорый. Сәйф Сараиның нәзыйрә әсәрләре аның бу сыйфатларга ия икәнен күрсәтә.

Сәйф Сараи төрки-татар әдипләренә язган барлык нәзыйрәләрендә дә төп текстлардагы шигъри үлчәмне һәм рифмаларны саклап кала. Әмма бу һич тә тулы тәңгәллек түгел. Мәсәлән, Сәйф Сараи Мәүлана Исхак әсәренә язган шигъри җавабында төп чыганакның рифмаларын саклый (рәүханы — солтаны —гөлестаны һ. б.); шуның белән бергә, ул нәзыйрә объектында булмаган эчке рифмалар да кертә.

Нәзыйрә әсәрләрендә Сәйф Сараи төп текстлардагы аерым сурәтләрне дә куллана. Әмма күпчелек очракта аларга башка мәгънә төсмере бирелә, үзгә эстетик вазифа йөкләнә.

Кыскасы, Сәйф Сараиның әдәби сәләте һәм темага иҗади мөнәсәбәте нәзыйрә кысалары эчендә дә аңа төп чыганак белән аерым урыннарда гына туры килүче югары сәнгатьле әсәрләр тудырырга мөмкинлек биргән.

* * *

Сәйф Сараиның нәзыйрә һәм мөстәкыйль лирик әсәрләрендә мәхәббәт темасы үзәк урынны алып тора. Шагыйрь кешелек яшәешенең мөһим сыйфаты булган сөю хисләрен җырлый, урыны белән сөйгән ярын илаһилаштыра, мәхәббәтне, Котб кебек, бөтен тереклекне иңләүче бөек күренеш итеп аңлый.

Үзенең лирикасында Сәйф Сараи тормышның башка мәсьәләләре турында да уйлана. «Замананың газабыннан бу күңелем кан белән тулы»,—ди ул фарсыча бер робагыенда. Шәрыкның бөек шагыйрьләре Рудаки, Йосыф Баласагунлы, Хәйям, Сәгъди кебек, Идел буе шагыйре дә дөньяның агышы, яшәү мәгънәсе шикелле мәсьәләләргә еш мөрәҗәгать итә. Аның уенча да кеше гомере «фани». Әмма вакыт агышының бу реаль фактыннан ул пессимистик нәтиҗә ясамый. «Бакчадагы гөлләр, ди ул бер шигырендә, әле ачылыр, әле йомылыр; агачлар да бер шәрәләнер, бер яшелләнер. Шуңа күрә син кайгы килсә дә борчылма, ул китәр, аның артыннан шатлык килер...»

Табигатьтәге мәңгелек хәрәкәт аркылы тереклекнең дәвам итүен күргән шагыйрь кеше үлемен дә яшәешнең табигый бер формасы итеп карый. Үлемнең зарури һәм котылгысыз бер күренеш икәнлеген ныграк төшенгән саен, аңарда гомернең кыйммәтен тою, яшәргә ашкыну хисе дә көчәя бара. Шуңа күрә дә Сараи кешене үзенә билгеләнгән вакытны «алтын колы», «бугаз әсире» булып түгел, ә «игү ат» калдырырлык итеп уздырырга чакыра. Моның шарты итеп автор белемле булу һәм һөнәргә өйрәнүне саный. Шагыйрь карашынча, «ирдәм иясе»,— белемле, һөнәрле булу белән бергә, гадел һәм кешелекле «ир» дә. Андый кеше үзгәләрнең «күңелен» дә «екмый», «чакмый» да, үз йөрәгендә кинәгә урын бирмичә, һәрвакыт олы җанлы, акыллы, башкаларга игелекле булып кала.

Сәйф Сараи лирикасында кешене чолгап алган табигать күренешләренә дә зур урын бирелгән. Бер касыйдәдә, мәсәлән, шагыйрь күзе аркылы укучы табигатьтә гаҗәеп бер җанлылык, гүзәллек һәм гармония күрә, бу күренешләр аның күңелендә куанычлы хисләр уята, аны рухи яктан сафландыра һәм баета. «Сөһәйл вә Гөлдерсен» дастанында пейзаж күренеше егетнең авыр хәлен тагын да көчәйтә. Геройлар һәлак булгач, сахрада «буран» кубу — моның ачык мисалы.

Сәйф Сараиның әдәби осталыгы.

Әдипнең сәнгатьчә фикерләве, сурәтләү алымнары һәм чаралары хакында инде алдарак конкрет әсәрләргә мөнәсәбәттә бераз сүз булды. Хәзер Сәйф Сараи поэтикасының кайбер якларына махсус тукталып китик.

Сурәтләү объектының үзенчәлегенә, уй-кичерешләрнең табигатенә, иҗади максатның асылына карап, әдип хикәят, нәсыйхәт, хикмәт, дастан, кыйсса, газәл, робагый, касыйдә, фәрд һәм башка жанрларда яза.

Аның хикәятләренә фәлсәфи һәм образлы фикерләү хәрәкәтчәнлеге, динамикалылыгы хас. Әдип беренче юлда ук вакыйганың яисә фактның үзегеннән тотып ала да аз сүзләр белән аның асылын ачарга керешә. Гадәттә, ул тәфсилле хикәяләүдән, сыйфатлаудан кача. Аның максаты — ситуацияләрнең характеры турында гомуми күзаллау тудыру.

«Гөлестан бит-төрки»дәге хикәятләр, алдарак әйтелгәнчә, чәчмә һәм тезмә юллар катнашмасыннан гыйбарәт. Күпчелек хикәятләрдәге шигъри текстлар, гадәттә, хикәят сюжеты белән турыдан-туры керешмиләр. Эчтәлекләре һәм рухлары белән алар сюжетка сөземтә, гыйбрәт, бәя, лирик чигенеш рәвешендә биреләләр.

Сәйф Сараи — татар әдәбиятында мәсәл жанрына нигез салучылардан берсе. Аның мәсәлләрендә сюжет диалог аркылы бирелә. Әхлакый нәтиҗә катнашучы исеменнән ясала.

Шагыйрьнең газәлләре 5—9 строфадан гыйбарәт. Жанрның кече күләмле булуын истә тотып, автор уй-кичерешләрен тыгыз, бизәкләрне куе бирергә омтыла. Сәйф Сараи газәлләренең күпчелеге рәдифле.

Үзенең касыйдә һәм мәдхия жанрларында Сәйф Сараи макталучы затның сыйфатларын, күпертеп, мөмкин булган югарылыкта бирергә тырыша. Мәсәлән, Шәрыкта юмартлыкның идеал образы — Хатәме Тай. Шагыйрь дә бу образдан файдалана. Әмма аңа ярдәмче рольне генә калдыра. «Хатәме замана кирәк булса чакәре»,— ди ул. Ягъни юмартлыкта Хатәме әсәрдә макталучы Искәндәрия мәлигенә үзе хезмәтче, өйрәнчек булырлык.

Классик поэтиканы яхшы үзләштергән Сәйф Сараи гарузның һәзәҗ, рәмәл, мөзаригъ һәм башка үлчәмнәрендә иҗат иткән. Автор рифмага җитди игътибар бирә. Аның әсәрләрендәге рифмалар төзелеше, аһәңе һәм мәгънәви вазифалары ягыннан гаять күптөрле. Әдип, классик поэтикадагы газәл *(аа ба...)*, мәснәви *(аа бб...)* рифмалары белән беррәттән, төрки сүз сәнгатендәге дүртьюллыклар өчен хас *абаб*, *аабб*, *ааба* кебек рифма төрләрен дә иркен куллана. Аңарда эчке, юлбаш рифмалар да очрый.

Рифмалаштыруда Сәйф Сараи еш кына телдәге омонимия һәм авазлар охшашлыгыннан да оста файдалана:

Тоз-икмәкне онытмас кәлб (эт.—*Х. М.*), гәр йөз
Куар булсаң, янә кайтармас ул йөз.

Бу юллардагы «йөз» сүзе беренче очракта сан төшенчәсендә, икенчесендә «бит»нең мәгънәдәше булып килгән.

Сәйф Сараи Шәрык әдәбиятларына хас булган традицион сурәтләү чараларыннан да иркен файдалана. Мәсәлән: гүзәлнең кашын — җәя, керфеген ук белән тиңләү, халык белән хөкемдар мөнәсәбәтләрен куй һәм көтүче образлары аша бирү, сәрв (кипарис) аркылы буйның зифалыгын күрсәтү, буйны тал белән янәшә кую һ. б.

* * *

Сәйф Сараи, Алтын Урда чорының башка әдипләре белән берлектә, төрки-татар әдәбиятын, язма телне үстерүгә зур өлеш кертте. Ул кулланган күп кенә мотивлар, жанрлар, рифма һәм строфа төрләре, шигъри үлчәмнәр һәм сурәтләү чаралары Өмми Кәмал, Мөхәммәдьяр, Г. Кандалый иҗатлары аша Г. Тукай һәм Дәрдмәндкә кадәр килеп җитте.

Кешеләргә яхшылык эшләү, алар күңелендә «игү ат» калдыру Сәйф Сараиның иҗат девизы, яшәү максаты булган. Шагыйрь моңа ирешкән дә. Ул замандашларының күңелендә генә түгел, хәзерге чор кешеләре өчен дә «игү ат»ы белән үз һәм якын.

Сораулар һәм биремнәр

1. Сәйф Сараиның тәрҗемәи хәлен сөйләгез.
2. «Мисырда мәмлүкләр дәүләте» дигәнне ничек аңлыйсыз?
3. «Китабе Гөлестан бит-төрки» һәм «Ядгярнамә» кулъязмаларының табылу, өйрәнелү тарихы, төзелеше хакында сөйләгез.
4. «Гөлестан бит-төрки» әсәре ничек төзелгән?
5. Сәгъди һәм Сәйф Сараи әсәрләре арасында нинди уртаклыклар һәм аерымлыклар күрәсез?
6. Әдипнең тәрҗемә принциплары хакында сөйләгез.
7. «Гөлестан бит-төрки» әсәренең идея-тематикасы.
8. Аксак Тимер һөҗүмнәре һәм «Сөһәйл вә Гөлдерсен» дастаны үзара нинди мөнәсәбәттә тора?
9. Сөһәйл һәм Гөлдерсен образларына нинди сыйфатлар хас?
10. Нәрсә ул нәзыйрәчелек, аның төп асылы?
11. Сәйф Сараиның нәзыйрә әсәрләренә нинди үзенчәлекләр хас?
12. Әдип нинди жанрлар куллана?
13. Шагыйрьнең әдәби осталыгы хакында сөйләгез.
14. «Игү ат» төшенчәсен Сәйф Сараи ничек аңлый?
15. «Татар әдәбиятында Сәйф Сараи традицияләре» темасына сөйләшү уздырыгыз.
16. Шагыйрь әсәрләреннән аерым үрнәкләрне ятлагыз.

ӘДӘБИЯТ ТЕОРИЯСЕ

Дидактик әдәбият. «Дидактик» сүзе грекча «гыйбрәтле», «сабак булырлык» мәгънәләрен белдерә. Бу атаманың үгет-нәсыйхәт, киңәш-өйрәтү төшенчәләре дә бар. Дидактик әдәбият — язма әдәбиятның һәм өлешчә фольклорның акыл-тәҗрибә, белем-тәрбия бирүне үзәккә куйган бер төре. Биредә уй-ният, кагыйдә буларак, турыдан-туры үгет-нәсыйхәт, өйрәтү рәвешендә бирелә, сәнгати як икенче планда кала, фикри башлангыч, публицистик аһәң өстенлек итә.

Дидактик башлангыч аеруча Борынгы һәм Урта гасыр әдәбиятында көчле. Йосыф Баласагунлы, Әхмәд Йүгнәки әсәрләренең үзәгендә — үгет-нәсыйхәт, киңәш бирү. Бу традиция Мәхмүд Болгари, Мөхәммәдьяр, Мәүла Колый иҗатларында да дәвам иттерелә. Сәйф Сараиның «нәсыйхәт»ләре дидактик әдәбият белән турыдан-туры керешеп китә.

XIX гасыр — XX йөз башы әдәбиятында да дидактизм күзәтелә. Һибәтулла Салихов, Акмулла, Каюм Насыйри, Муса Акъегетзадә, Мәҗит Гафури һәм башка күп кенә татар әдипләре укучыга турыдан-туры үгет-нәсыйхәт, акыл-тәҗрибә бирү алымын бик теләп файдаланалар. Хәзерге әдәбият өчен дә дидактизм чит түгел.

Әдәби багланышлар. Әдәби багланышлар — әдәби процесс өчен хас булган объектив күренеш.

Үзләренең эчтәлекләре, дәрәҗәләре һәм формалары белән әдәби багланышлар күптөрле була: милли әдәбиятның үз эчендәге бәйләнешләр; ике яки берничә әдәбият арасындагы багланышлар (рус-татар, гарәп-фарсы-төрек-татар һ. б.); шәхси элемтәләр (М. Горький һәм Р. Роллан, Г. Тукай һәм Ф. Әмирхан һ. б.); иҗат методлары, әдәби агымнар арасындагы мөнәсәбәтләр, тәрҗемәләр, адаптация, ияреп язулар, нәзыйрәләр һ. б. Әдәбият белән сәнгать төрләре арасындагы бәйләнешләргә дә фәндә нык игътибар ителә. Бер әдәби күренеш белән икенчесе арасындагы багланышлар турыдан-туры да, арадашчылар аркылы да булырга мөмкин. Мәсәлән, XVIII —XIX йөз рус укучылары Шәрык әсәрләре белән, нигездә, Көнбатыш Европа телләреннән тәрҗемәләр аркылы танышалар. Рус һәм татар әдәбиятлары арасында турыдан-туры бәйләнеш яши. Чынбарлыктагы әдәби багланышлар «әдәби йогынты» төшенчәсе белән керешкән.

Әдәби йогынты — бер әдәби күренешнең икенче бер әдәби күренешкә тәэсир итүе. Аның дәрәҗәләре һәм формалары гаять күптөрле (тәрҗемә, нәзыйрә, пародия, стилизация, иярү, бәхәскә керү, мавыгу; иҗади, турыдан-туры, башкалар аша, механик, уңай, тискәре һ. б.). Мәсәлән, инглиз шагыйре Байронның Пушкинга һәм Лермонтовка йогынтысы иҗади бәхәс характерында була. Үз чиратында бу өч әдиптән Г. Тукай да күп нәрсәгә өйрәнә. Әдәби йогынтының асылын социаль-иҗтимагый үсештәге, идеологиядәге, психологиядәге охшашлыклар, чорның, җирлекнең, халыкның эчке иҗтимагый-эстетик ихтыяҗлары билгели. Әдәби йогынты — әдәби бәйләнешләрнең мөһим бер өлеше.

Әдәбият фәнендә бәйләнешләрнең генетик, типологик, контактлы һәм башка төрләре күрсәтелә. Аларның һәрберсенең үз үзенчәлекләре бар. Генетик бәйләнешләрдә, мәсәлән, уртак бер чыганакка барып тоташкан әдәби күренешләр өйрәнелә. Типологик охшашлыкларда исә төп игътибар бер-берсенә бәйсез туган охшаш күренешләргә юнәлтелә. Бу бәйләнеш төрләре дә еш кына үзара керешеп китәләр. Мәсәлән, типологик охшашлыклар турыдан-туры мөнәсәбәтләр урнаштыруда мөһим алшарт булып торалар.

Урта гасыр һәм XIX йөз татар әдәбияты аеруча гарәп, фарсы, төрек, үзбәк әдәбиятлары белән күптөрле бәйләнешләрдә тора.

Әдәби тәрҗемә. Ул — әдәби бәйләнешләрнең, әдәби йогынтының мөһим бер төре. Тәрҗемә дип бер телдә язылган, иҗат ителгән әсәрләрне икенче телгә күчерүгә әйтәләр. Ягъни бер телдәге ядкярнең эчтәлеге икенче тел чаралары белән, кабат торгызыла. Әдәби тәрҗемәгә куелган төп таләп — әсәрнең идея байлыгын, поэтик үзенчәлеген мөмкин кадәр тулырак итеп икенче телгә күчерә алу.

Әдәбият тарихында тәрҗемәләрнең күп төрләре белән очрашасың: төгәл, «сүзгә-сүз» (хәрфи), иҗади, ирекле, сайлап, реалистик, якынча һ. б. Реализм әдәбиятына кадәр татар сүз сәнгатендә чагыштырмача ирекле, иҗади тәрҗемәләр өстенлек иткән. Нәкъ менә шуңа күрә дә Котбның «Хөсрәү вә Ширин», Сәйф Сараиның «Гөлестан бит-төрки» кебек әсәрләре фәндә ярым тәрҗемә, ярым оригиналь ядкярләр рәтендә карала.

Октябрь революциясенә кадәр күпчелек татар укымышлылары гарәпчә, фарсыча, төрекчә, үзбәкчә текстларны, нигездә, оригиналда укыганнар. Татар теленә тәрҗемәләрнең дә төп өлеше шушы телләрдән башкарылган. XIX йөз азакларыннан алып рус теленнән татарчага күп тәрҗемәләр эшләнә.

Тәрҗемә аша татарлар, күп кенә башка халыкларның рухи казанышларын иҗади үзләштереп, үз әдәбиятларының үсешен дә тәэмин иткәннәр. Үз чиратында татар авторларының да аерым әсәрләре башка телләргә күчерелгән.

Тәрҗемә иң беренче чиратта халыкның эчке ихтыяҗы, эчке таләбе белән башкарыла.

Әдәби тәрҗемәләр әдәбиятларның үзара баюына һәм төрле халыклар арасындагы дуслык элемтәләренең көчәюенә хезмәт итәләр.

Газәл. Ул —«мөселман Шәрык» поэзиясендә киң таралган лирик жанр атамасы. Газәл VII йөзләргә кадәр үк гарәп дөньясында барлыкка килә. Урта гасырларда гарәп, фарсы, төрек, татар, азәрбайҗан һәм кайбер башка халыкларның поэзиясендә киң тарала. Мәсәлән, Сәгъди, Хафиз, Сәйф Сараи, Нәсими, Нәваи газәл жанрының матур үрнәкләрен тудыралар.

Газәлнең традицион тематикасы — мәхәббәт. Шуңа күрә аны еш кына «мәхәббәт шигыре», «гыйшык җыры» дип тә йөртәләр. Шәрык халыкларында ул, музыка коралына кушылып, махсус көйләргә дә башкарыла. Фәлсәфи, дини-суфичыл, иҗтимагый-социаль темаларга язылган газәлләр дә очрый.

Газәлнең үзенә хас тышкы формасы бар. Ул чагыштырмача мөстәкыйльлеккә ия булган икеюллык строфалардан — бәетләрдән тора, гаруз белән языла. Рифмалашуы *аа ба ва...* рәвешендә. Еш кына рифмалардан соң рәдиф, ягъни аерым сүз яки сүзләр төркеме кабатланып килә. Рәдиф шигырьнең тематик һәм композицион бөтенлеген, көйлелеген тудыруга да булыша. Газәлләрнең уртача күләме 5—12 бәеттән гыйбарәт. Шактый гына газәлләрнең ахыргы яисә аннан алдагы бәетендә авторның исем-кушаматы кулланыла.

Төрки-татар поэзиясендә газәлләр күптәннән очрый. Әхмәд Ясәви, Сөләйман Бакырганый, Рабгузый, Харәзми, Сәйф Сараи, Өмми Кәмал, Колшәриф, Шәмседдин Зәки, Габделҗәббар Кандалый һ. б. бу жанрда уңышлы гына иҗат итәләр. Газәл аеруча XX йөз башы татар поэзиясендә активлашып китә. Бу чордагы газәлләрнең шактые иҗтимагый-социаль эчтәлектә (Г. Тукай — «Күңел», «Көзге җилләр», «Сайфия»...; М. Гафури —«Мәкъсуд», «Үзенчә», «Булмый»...). Соңгы чор татар шигъриятендә газәл Нури Арслан, Рәдиф Гаташ иҗатларында күзәтелә.

Касыйдә. Бу сүз гарәп телендә максат, теләк, ният, мактау шигыре мәгънәләрен белдерә. Касыйдә — Шәрык әдәбиятларында лирик жанр атамасы. Аның поэтик асылын кемне яисә нәрсәне дә булса гадәттән тыш күпертеп, иң чик дәрәҗәгә җиткереп мактау тәшкил итә. Күп кенә касыйдәләрнең нигезенә күренекле тарихи затларның эш-гамәлләре, чынбарлыкта булган тантаналы вакыйга-күренешләр салына. Мактау аркылы шагыйрьләр үзләренең теләк-омтылышларын, идеалларын да гәүдәләндергәннәр.

Касыйдә үзенең тышкы формасы белән газәлгә охшаш: ул чагыштырмача мөстәкыйль булган бәетләрдән төзелә, *аа, ба, ва...* рәвешендә рифмалаша, гаруз белән языла. Күп кенә касыйдәләрдә, нәкъ газәлдәге кебек, рәдиф һәм шагыйрьнең кушаматы кулланыла. Әмма ул, кагыйдә буларак, газәлдән зур: анда бәетләр саны 200 гә җитәргә мөмкин.

Касыйдә Борынгы һәм Урта гасырларда ук гарәп поэзиясенең иң популяр жанры була. Аннан ул, газәл кебек үк, фарсы, төрки һәм кайбер башка халыкларга тарала. Әл-Мөтәнәбби, Рудаки, Сәгъди, Нәваи кебек мәшһүр шагыйрьләрнең иҗатында касыйдә мөһим урынны били.

Татар поэзиясендә бу жанрга Харәзми, Сәйф Сараи, Өмми Кәмал, Әбелмәних Каргалый, Габделҗәббар Кандалый һәм кайбер башка әдипләр мөрәҗәгать итә. Әмма татар әдәбиятында еш кына касыйдә жанрының традицион таләпләре тулысынча сакланмый. Татар шагыйрьләре мактау формасының чагыштырмача иреклерәк жанры — мәдхияне (оданы) яратыбрак кулланганнар.

Гаруз — иң әүвәл гарәп, аннан фарсы, төрки, шул исәптән татар классик поэзиясендә кулланылган шигырь төзелеше. Аның өчен музыкальлек, аһәңлелек хас.

Силлабик шигырь төзелеше шигырь юлларында (тезмәләрдә) иҗекләрнең билгеле бер санда килүенә, әлеге юлларның билгеле бер зурлыктагы ритмик буыннарга бүленүенә нигезләнгән. Гарузның асылын исә озын һәм кыска иҗекләрнең ни рәвешле чиратлашуы билгели. Биредә, кагыйдә буларак, кыска иҗек ачыкка, озыны ябык иҗеккә туры килә. Әмма аерым очракларда, иҗекнең кайда урнашуына (бигрәк тә басымга, ритмик буын-афаил ахырында торуына) карап, ачык иҗекләр озын да булып китәргә мөмкин. Силлабик шигырьдә ритмик буын аралыгы, кагыйдә буларак, сүз аралыкларына туры килә. Гарузда исә, ритм һәм үлчәм таләбе белән, бер сүз ике афаилгә дә (ритмик буынга да) бүленергә мөмкин.

Гаруз шигырь төзелешендә озын һәм кыска иҗекләр, берләшеп, тезмәләрдә кимендә 3 ритмик буын (афаил) барлыкка китерәләр. Афаилнең үз эчендә озын һәм кыска иҗекләрнең урнаштырылышы төрлечә була (кыска — озын — озын — озын; озын — кыска — озын — озын; ... Схемасы: ∪ — — —; — ∪ — — ...). Һәр шигырь юлындагы афаилләр (ритмик буыннар), бер-бер артлы кабатланып, үзара берләшеп, төрле үлчәмнәрне барлыкка китерәләр: рәмәл, һәзәҗ, мөнсәрих, мөзаригъ... Бу төр 19 үлчәмнең (вәзеннең, бәхернең) гаять күптөрле вариантлары бар.

Татар шигъриятендә Октябрь революциясенә кадәр гаруз өстенлек иткән. Котб, Харәзми, Сәйф Сараи, Мөхәммәдьяр, Шәмседдин Зәки үз әсәрләрен, нигездә, гаруз белән иҗат итәләр. Г. Тукай, М. Гафури, Дәрдемәнд, Бабич кебек, XX гасыр башы шагыйрьләренең дә күпчелек шигырьләре гаруз үлчәмендә.

Татар поэзиясендә гарузның аеруча рәмәл (— ∪ — —/— ∪ — —...) һәм һәзәҗ (∪ — — —/∪ — — —...) үлчәмнәре, бигрәк тә аларның өчәр буынлы формалары актив.

Вәзен (үлчәм, бәхер) төрләрен белдерү өчен, еш кына шартлы сүзләр — махсус формулалар да кулланыла. Аларны авторлар кайвакыт үзләре дә шигырь юллары рәвешендә күрсәтәләр. Мәсәлән, «Кисекбаш» китабының соңгы бәете болай яңгырый:

> Фагиләтүн, фагиләтүн, фагиләт,
> Ахирәт кирәк исә — дөньяны сат.
> — ∪ — — / — ∪ — — / — ∪ —

Бу — рәмәлнең өч буынлы (кыскартылган) вариантына туры килә. Элеккеге татар мәктәп-мәдрәсәләрендә гаруз вәзеннәрен язылыш һәм әйтелеш ягыннан ныклап өйрәткәннәр. Бу эш бер үк вакытта шигъри текстларны сәнгатьле укуга әзерлек чарасы да булган. Шигырь үлчәмнәрен камил үзләштерү шагыйрьләр өчен зарури дип каралган.

Гарузда, кагыйдә буларак, икеюллык строфалар — бәетләр кулланылган. Газәл, касыйдә кебек жанрларда алар *аа, ба, ва* ... рәвешендә рифмалашса (кафияләшсә), калганнарында мәснәви (икеләтелгән, ягъни *аа, бб, вв* ...) формасы өстенлек иткән. Лирик парчаларда рифмалашу еш кына рәдиф белән баетылып барган.

Сораулар һәм биремнәр

1. Дидактик әдәбият төшенчәсен аңлатыгыз.

2. «Әдәби багланышлар» һәм «әдәби йогынты» төшенчәләре бер-берсенә нинди мөнәсәбәттә тора?

3. Типологик охшашлык нәрсә ул?

4. Әдәби тәрҗемә дип нәрсәгә әйтәбез?

5. Газәл, касыйдә жанрлары хакында сөйләгез. Аларның уртак яклары нәрсәләрдә күренә?

6. Татар шагыйрьләреннән кемнәрнең газәлләрен беләсез?

7. Моңа кадәр шигырь төзелеше турында өйрәнгәннәрегезне искә төшерегез.

8. Әдәбият белеме сүзлекләреннән (Казан, 1990, 2007) «силлабик шигырь төзелеше», «метрик шигырь», «гаруз» хакындагы мәкаләләрне укып, фикер алышыгыз.

9. Гарузның төп асылын аңлатыгыз.

КАЗАН ХАНЛЫГЫ ЧОРЫ ӘДӘБИЯТЫ

I

XV йөзнең урталарына таба төрле сәбәпләр аркасында Алтын Урда таркала. Аның җирлегендә Кырым, Казан, Себер, Олы Урда, Нугай, Әстерхан һәм башка татар ханлыклары барлыкка килә. (Шушы ук елларда Касыйм мәмләкәте дә төзелә.) Аларның халкын да, телен дә, нигездә, татар дип йөртәләр. Бу татар дәүләтләренең элеккеге Алтын Урда дәвамчылары булуы, этник, матди һәм мәдәни яктан Җучи улусы традицияләренә нигезләнеп яшәүләре тарих белән азмы-күпме хәбәрдар булган кешегә көн кебек ачык. Алтын Урда — XV йөзнең урталарында барлыкка килгән татар ханлыкларының төп йорты (ата-анасы һәм әби-бабасы).

Мәгълүм булганча, Казан һәм Әстерхан мәмләкәтләре Мәскәү тарафыннан 1552—1556 елларда юк ителә. Көнбатыш Себердәге татар ханлыгы шушындый ук язмышка 1585 елда дучар була. Кырым татарлары исә үз дәүләтчелегеннән 1783 елда мәхрүм ителәләр. «Курчак» дәүләт рәвешендә булса да, Касыйм ханлыгы 1682 елга кадәр яшәвен дәвам итә. Шактый халкын безнең әби-бабаларыбыз тәшкил иткән Нугай Урдасының да, Казан дәүләте бетерелгәннән соң, бер гасырдан артык яшәве мәгълүм. Шуңа күрә «Казан ханлыгы чоры әдәбияты» төшенчәсе вакыт һәм җирлек ягыннан киңрәк төшенчә итеп карала. Ул якынча XV йөзнең урталарыннан алып XVII гасырларга кадәрге татар мәмләкәтләрендәге әдәбиятны үз эченә ала. Әмма аның үзәгендә Казан ханлыгы тора. Чөнки бу дәүләт составына хәзерге татарлар яши торган күп кенә төбәкләр кергән: хәзерге Сембер, Пенза, Тамбов өлкәләре, Чувашия, Мари, Удмурт, Мордва Республикаларының җирләре, Нижгар, Сарытау, Самара, Вятка, Пермь өлкәләренең бер өлеше. Рус профессоры Михаил Худяков фикеренчә, Иделнең Сура һәм Ветлуга елгалары койган урыныннан алып Сарычин-

га (Волгоградка) кадәрге җирләр Казан ханлыгы карамагында булган. Бу дәүләт хәзерге Татарстанга караганда берничә мәртәбә зуррак була.

Тарих китапларында татар ханлыклары арасындагы үзара каршылыклар, сугышлар хакында күп языла. Чыннан да, бу хәл булган. Бердәмлек җитмәү, ызгыш-талаш, кыен вакытларда бер-берсенә тиешле ярдәм итмәү аларның берәм-берәм юкка чыгуына да китерә.

Әлбәттә, татар ханлыклары арасында гел каршылыклар гына булып тормаган. Алар үзара сәүдә итешеп, рухи байлыкларын уртаклашып, бер-берсенә кызлар бирешеп, кода-кодагый булып та яшәгәннәр. Бер үк кешеләр (Мамук, Сәхибгәрәй, Шаһгали һ. б.) хәтта аларның берничәсендә хан булып та торганнар. Бу чорда бер төбәктәге татарларның икенче җирләргә күпләп күчеп утырулары да тарихтан мәгълүм. XV йөздә, мәсәлән, Дон һәм Идел тамакларыннан, Азак (хәзерге Азов) шәһәреннән Урта Иделгә шактый гына татарлар килеп урнаша. Шушы ук гасырда Литвада һәм Польшада татарлар саны 100 меңнән артып китә.

Ислам диненең, язма һәм сөйләмә телнең, мәдәниятнең уртаклыгы, этник якынлык яисә тәңгәллек, Алтын Урда тарихының нигез булып торуы — Казан, Әстерхан, Кырым, Касыйм, Себер, Нугай, Олы Урда ханлыкларындагы татарларны үзара якынайтучы, берләштерүче төп факторлар.

Татар мәмләкәтләре, гәрчә Алтын Урда чорындагы кебек булмаса да, күп кенә илләр һәм халыклар белән төрле бәйләнешләрдә торалар. Мәсәлән, Әстерхан, Казан, Кафа (Кырымдагы шәһәр, хәзерге Феодосия), Сарайчык (Җаек буендагы кала) Евразиянең зур сәүдә үзәкләре булган. Казанда халыкара ярминкәләр эшләве дә мәгълүм.

Татар мәмләкәтләрендәге халыкның күпчелеге ислам динен тота. Шуңа мөнәсәбәттә күп кенә шәһәр-авылларда мәчетләр эшли. Алар янында исә мәктәп-мәдрәсәләр булган Касыйм шәһәрендә, мәсәлән, XV йөзнең урталарында зур мәчет төзелә. Галимнәр Казан Кремле эчендә сигез манаралы мәчет, аның янында зур китапханә булуын искәртәләр. Әстерхан каласы да үзенең уку йортлары белән дан тоткан. Аларда төрле төрки төбәкләрдән килгән шәкертләрнең укуы мәгълүм. Укытучылар арасында, татар мөгаллимнәре белән беррәттән, Мисыр, Һиндстан, Урта Азия, Иран, Госманлы укымышлылары да була.

Алтын Урдадагы кебек, татар мәмләкәтләрендә дә гарәп-фарсы телләрен, Шәрык әдипләренең китапларын өйрәнү киң тарала. Мәктәп-мәдрәсәләрдә, дин сабакларыннан тыш, математика, медицина, география, логика, тарих кебек дөньяви фәннәр дә укытылган.

II

Татар язма истәлекләренең зур өлеше ханлыклар бетерелү чорында һәм аннан соңгы авыр, караңгы елларда яндырыла, юкка чыгарыла. Кайберләре качып, күчеп киткән кешеләр аркылы чит мәмләкәтләргә, аеруча Төркиягә, Мисырга, Урта Азиягә, Иранга, Һиндстанга һәм өлешчә Европа илләренә эләгә.

Халык телендә бик борынгы күренешләргә карата «хан заманыннан калган» дип әйтү еш ишетелә. Ныклабрак уйлап караганда, безгә ул чордан килеп җиткән мирасның иң зурысы, иң кадерлесе ул — безнең газиз татар телебез. Аның төп лексик фонды, грамматикасы, фонетикасы шул «хан заманнары»нда — Алтын Урда, Казан ханлыгы чорларында ук тәмам оешып, камилләшеп җиткән. Моны шул дәвердән сакланып калган язма истәлекләрнең тел-стиле дә ачык күрсәтеп тора.

Тел ул — халыкның шифрга салынган хәтере. Әгәр дә ачкычын табып, аны укый белсәң, тарихи тормышның, дөньяның күп якларын ачыкларга була. Мөхәммәдьяр поэмасындагы «Заһид» хикәятендә бер хөкемдар «йөзигә кара сөртеп үлтереӊ» дигән әмер бирә. Баксаң, М. Гафури повестенда сурәтләнгән биткә кара сөртү җәзасы халыкта күптәннән кулланыла икән. «Төхфәи мәрдан» әсәрендә «Аның имен (дәвасын.— *Х. М.*) һич утачы белмәгәй» дигән юл бар. «Утачы» атамасының тамырын «ут» (үлән) сүзе тәшкил итә (хәзерге телебездәге «утлау», «утау», «утлавык» кебек сүзләр нәкъ әнә шуның белән бәйләнешле). «Утачы» исә «үлән белән дәвалаучы», «табиб» мәгънәсен белдерә. Элеккеге язма истәлекләрдә, аеруча эпитафик ядкярләрдә, «дарелбәка» (мәңгелек йорт, ягъни теге дөнья), «дарелфәна» (вакытлы йорт, ягъни бу дөнья), «рихләт кылды» (күчеп китте, үлде), «җаны кош булып очты» гыйбарәләре күзгә еш ташлана. Бу төр тәгъбирләр исә шул дәвер кешеләренең мифологик ышанулары, дөнья, яшәеш хакындагы күзаллаулары белән тыгыз бәйләнешле.

Телдә генә түгел, татар халык авыз иҗатының бүгенге мирасында да Казан ханлыгы чоры белән багланышлы истәлекләр шактый. Аларның бер өлеше теге яки бу дәрәҗәдә үзгәргән,

икенчеләре чагыштырмача бөтен, мөстәкыйль хәлендә сакланып калган. Алар арасында Иске һәм Яңа Казанның салынуы, Кабан күле, Елан тавы, Сөембикә, Җик Мәргән хакында риваятьләр, әкиятләр бар. XV— XVI йөзләргә мөнәсәбәтле фольклор истәлекләренең иң күренеклесе,— әлбәттә, «Идегәй» дастаны. Ул,— бер яктан, Алтын Урда җирлегенә, икенче яктан, фольклор һәм язма әдәби казанышларга нигезләнеп туган сирәк очрый торган (уникаль) күренеш. Анда халыкның күп гасырлык шигъри фикерләве, ватан, кеше, яшәеш хакындагы уйланулары, хикмәтле сүз әйтү осталыгы фокустагы кебек бергә тупланып бирелгән. Бу дастан — үзе генә дә элеккеге сүз сәнгатебезнең югары дәрәҗәдә торуын күрсәтүче мөһим бер дәлил.

Казан ханлыгы чорында язылган, укылган, шул дәвердән безгә килеп җиткән язма истәлекләр үзләренең табигатьләре белән гаять төрле. Алар арасында без татарча, гарәпчә, фарсыча текстларны да, әдәби әсәрләрне дә, гыйльми, дини китапларны да, каберташ язмаларын, ярлыкларны да, оригиналь һәм тәрҗемә ядкярләрне дә очратабыз.

Элеккеге төрки-татар язма истәлекләренең күпчелеге («Кыйссаи Йосыф», «Кыйссасел-әнбия», «Нәһҗел-фәрадис», «Җөмҗөмә солтан», «Кисекбаш» һ. б.) Казан ханлыгы чорында укылуын дәвам итә.

Йосыф Баласагунлы (XI йөз), Әхмәд Ясәви һәм Сөләйман Бакырганый (XII гасыр), Йуныс Әмрә (1250—1320), Гашыйк Паша (1271—1332), Лотфый (1366—1465) һәм кайбер башка төрки әдипләрнең әсәрләре дә татар мәмләкәтләрендә таралыш таба. Лотфый, мәсәлән, үзе дә Сарай, Казан калаларында була. Татар укучылары тарафыннан аның аеруча «Гөл вә Нәүрүз» дастаны (1411) яратып укыла. Төрки әдипләрнең олуг остазы Нәваи да (1441—1501) — үз чорында ук татар укымышлыларына үз һәм якын исем. Шагыйрь әсәрләренең XVI йөздә төзелгән бер кулъязмасы Казан белән бәйләнешле.

XV—XVI йөзләргә мөнәсәбәтле язма истәлекләрнең бер өлешен ярлыклар тәшкил итә. Табылган ярлыкларның икесе Казан (Ибраһим, Сәхибгәрәй), 56 сы Кырым (Хаҗигәрәй, Миңлегәрәй, Мөхәммәдгәрәй һ. б.) ханнарына карый. Татар телендә язылган бу ядкярләрнең күпчелеге оригиналда, ә бер өлеше төрле күчермәләрдә һәм тәрҗемәләрдә килеп җиткән.

Хан ярлыклары — татар тарихын, мәмләкәтләрен өйрәнүдә, аларның үзара һәм башка илләр, халыклар белән элемтәләрен ачыклауда гаять мөһим чыганак. Мәсәлән, Сәхибгәрәй хан

ярлыгында (1523) без Казан дәүләтендәге социаль һәм юридик атамалар, кеше исемнәре белән очрашабыз, аның ярдәмендә хакимият һәм халык мөнәсәбәтләре хакында билгеле бер күзаллау тудырабыз.

Казан ханы Мөхәммәд Әминнең Польша короле Александрга язган хат-бетегендә дә (1506) шул чор сәяси тормышына, аеруча Казан — Мәскәү мөнәсәбәтенә, кагылышлы мөһим мәгълүматлар бар.

Вафат булган кешеләрнең кабере өстенә язулы ташлар кую татар мәмләкәтләре дәверендә дәвам итә. Бизәкләре, язу рәвешләре, эчтәлекләре белән алар сәнгати һәм тарихи яктан игътибарга лаек. Сакланып калган кайбер каберташ язмаларында шигъри юллар да бар.

Сораулар һәм биремнәр

1. Алтын Урда җирлегендә барлыкка килгән татар мәмләкәтләрен атагыз, аларга кыскача сыйфатлама бирегез.

2. Татар ханлыклары арасында нинди бәйләнешләр яши? Мәгариф һәм мәдәниятнең торышы.

3. «Тел — элеккеге мирасның иң зурысы» дигән төшенчәне ничек аңлыйсыз?

4. Казан ханлыгы дәвереннән безгә нинди фольклор әсәрләре билгеле?

5. а) Телләрдән төшмәс Казан: Риваятьләр, бәетләр һәм тарихи ядкярләр (Төзүчесе — С. Гыйләҗетдинов // «Казан» журналы китапханәсе. —1992.— №2); ә) җыентыклар белән танышыгыз, аерым үрнәкләрне укыгыз. (Өстәмә яисә индивидуаль бирем.)

6. XV—XVI йөз татар укучылары арасында кайсы авторлар, нинди әсәрләр укыла?

7. Ярлыклар, бетекләр һәм каберташ язмалары хакында сөйләгез.

8. Илгаз Ваһап Нәүрүзхан. Сөембикә (роман); **Р. Батулла.** Сөембикә кыйссасы; **Ф. Латыйфи.** Хыянәт (повесть); **М. Хәбибуллин.** Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный (роман); **М.Әмирханов.** Үрбәт ханәкә гыйшкы (роман), Гәүһәршад (роман).— Кемнәрнең бу әсәрләрне укыганы бар? Дәрестән тыш вакытта уку, фикер алышу үткәрергә мөмкин. Аларның берсен алып, китап укучылар конференциясе дә уздырырга була (укытучы карамагында).

УРТА ГАСЫРНЫҢ АЕРЫМ ЯДКЯРЛӘРЕ

Элеккеге дәвернең аерым истәлекләрен, әдипләрен билгеле бер чорга, җирлеккә кертеп тикшерү шактый кыен, хәтта аерым очракларда мөмкин дә түгел. Ни өчен? Беренчедән, аларның туу вакыты, урыны тәмам ачыкланмаган, икенчедән, бу төр ядкярләрнең кайберләре Идел-йортта гына түгел, кайбер башка төрки төбәкләрдә дә таралыш тапканнар, соңгы

дәверләргә кадәр укылганнар, тыңланганнар. Андый әсәрләрнең берсе «Кисекбаш» хакында алдарак сүз булган иде. Хәзер исә шундыйларның берничәсе хакында кыскача гына белешмә биреп китик.

Идегәй. «Идегәй» — татар халык авыз иҗатының таҗы, күләмле фольклор әсәрләренең иң борынгыларыннан берсе. Ул Алтын Урда таркалу — татар мәмләкәтләре төзелү дәверендә, ягъни XV гасырның 40 нчы елларында барлыкка килгән дип карала. Яшәеш чорында дастанга теге яки бу дәрәҗәдә үзгәрешләр, өстәмәләр дә кертелгән, аның төрле вариантлары барлыкка килгән.

«Идегәй» — бөтен татар дөньясы өчен уртак хәзинә. Әмма ул аеруча Идел-Җаек, Көнбатыш Себер татарлары арасында киң таралган.

«Идегәй» инде менә биш гасырдан артык татар халкы белән бергә яши, аның шатлык-кайгылары да, уй-кичерешләре, теләк-өметләре дә уртак. Чөнки әсәрдә халыкның идеаллары, тормыш, кешеләр турындагы күзаллаулары, гореф-гадәтләре югары сәнгати дәрәҗәдә гәүдәләнеш тапкан.

«Идегәй» — иң беренче чиратта халкыбызның Алтын Урда чоры белән тыгыз бәйләнешле ядкяре. Дастанның каһарманнары Туктамыш, Идегәй, Норадын, Кадыйрбирде, Шаһ Тимер һ. б. — болар бар да диярлек XIV йөзнең азагына — XV гасыр башына мөнәсәбәтле шәхесләр. Аксак Тимер белән Алтын Урда арасындагы сугышлар да әсәрдә билгеле бер дәрәҗәдә гәүдәләнеш тапкан.

«Идегәй» — гадәти дастан гына түгел, ә Алтын Урданың җимерелү сәбәпләрен, фаҗигале елъязмасын гәүдәләндергән бөек мәрсия, моң-зар тулы сыктау да ул:

Идел-йортны дау алды,
Яу өстенә яу килде,
Идегәй әйткән көн килде.
Чыңгызның куйган хан тагы (тавы.— *Х. М.*)
Кан тагы булып әверелде,
Хан сарае камалды.
Кырым, Казан, Аждаркан (Әстерхан.— *Х. М.*)
Башлы-башлы ил булды,—
Алтын Урдааралды.

Чит патшалар көче белән үз иленә каршы көрәшкән кеше рәхәт күрми: ул үзенә дә, халкына да күп зыян китерә. Идегәй дә нәкъ әнә шундый язмышка дучар була.

Дастанда Туктамышны хурлау, төп каһарманны мактау өстенлек итә. Әмма бу — жанр таләбе белән генә шулай эшләнгән. Чынлыкта исә хәл катлаулырак. Алтын Урданың законлы ханы Туктамыш белән көрәшкә Идегәйне нинди эчке көч хәрәкәтләндерә соң? Ил язмышы, халык язмышымы? Юк, иң беренче чиратта шәхси үч алу, шәхси мәнфәгать. Күңелендәге шушы коткы аны иҗтимагый яктан әхлаксыз юлга этәрә: Аксак Тимер гаскәре белән ул Идел-йортка исәпсез-хисапсыз бәла-казалар китерә. Бу хакта әсәрдә Бодайби авызыннан Идегәйнең үзенә дә «Бу җиһанның фетнәсе Аксак Тимер дошманны Сарайга алып китердең», илне, «шәһре Болгарны» «көлгә-ташка» болгаттың дигән шелтәле сүзләр әйттерелә.

Туктамыш хан юк ителгәч, Идегәй Идел-йортның бөтенлеген, куәтен торгызырга омтыла. Әмма аның, гәрчә ул көчле, батыр булса да, бу изге максатка ирешә алмаячагы көн кебек ачык. Ни өчен? Чөнки дастанның төп каһарманы — илдәге таркалу процессына үзе нигез салучы. Өендә улы Норадын белән дә уртак тел таба алмаган хөкемдарның Идел-йортта иминлек урнаштыруына да ышаныч аз. Шунысы гыйбрәтле: Алтын Урда ханына каршы көрәшкән Идегәй ахырда үзе дә Туктамыш хәлендә кала, шулай итеп, әхлакый эш-гамәлләргә мөнәсәбәттә, шәхси язмышлар да кабатлана.

Дастанда Алтын Урда, Идел-йорт, Татар иле синоним төшенчәләр рәвешендә кулланыла. Идел-Җаек — аның үзәге, Сарай, Әстерхан, Болгар, Кырым — төп төбәкләре. Туктамыш әсәрдә үзен «татар» ханы дип саный, «сансыз татар урдам бар» дип мактана. Алтын Урдадан Урта Азиягә килгән Норадын Идегәйгә болай ди:

— Идел белән Җаектан,
Сарай белән Болгардан...
Татарның тулы йортыннан
Сиңа килдем, атаем.

Дастанда эчке бердәмлек җитмәү, үзара ызгыш-талаш, сугышлар илнең таралуында төп сәбәпләр итеп күрсәтелә. Боларның барысы да — «Идегәй»дә татар тарихының мөһим сәхифәләре гәүдәләнүенә дәлил. Әмма тарихи чынбарлык әсәрдә дастан кануннары, әдәби чаралар ярдәмендә үзенчәлекле чагылыш тапкан. Охшашлыклар, уртаклыклар күп булса да, әсәр белән аңа нигез булган вакыйга-хәлләрне тәңгәл куярга ярамый. Дастандагы аерым күренешләр, образлар хыялый,

әкияти характерда. Мәсәлән, Кара Тиен Алып, 195 яшьлек Субра карт — әнә шундыйлардан. Әсәрдә эпик идеаллаштыру, гадәттән тыш арттыру яисә киметү алымнары актив кулланыла. Идегәй «өч яшендә» китап укый башлый, «дүрт яшендә» дан ала, «уникегә җиткәндә, Алпамыштай ир була».

«Идегәй»,— нигездә, иң борынгы төрки шигыре калыпларының берсе — 7 иҗекле, ягъни җиделе үлчәмгә корылган. Күп кенә язма әдәби истәлекләрдән үзгә буларак, строфалар төрлелеге күзгә ташлана. Кайвакыт өзлексез агылып торучы тезмәләр саны строфада дистәдән артып китә. Строфа белән строфа арасы да еш кына шартлы рәвештә генә бер-берсеннән аерыла.

«Идегәй» өчен шигъри нәфислек, тел-сурәтләү чараларына байлык хас. «И Идел-йорт, Идел-йорт» дип җырлана торган мәдхиядә, мәсәлән, һәр юл диярлек «йорт» сүзенә тәгалләнә. Дастанның күпчелек юллары хикмәтле сүз, канатлы тәгъбир кебек яңгырый. Үзенә кадәрге төрки-татар сүз сәнгате казанышларын мул файдаланып туган «Идегәй» үзеннән соңгы фольклорга, язма әдәбиятка да зур йогынты ясый. Андагы сюжет-мотивлар, аерым юллар «Җәмигъ эт-тәварих» (1602), «Дәфтәре Чыңгызнамә» (XVII йөз) һәм башка истәлекләрдә күпләп очрый. Дастандагы образлы фикерләү казанышлары аеруча Акмулла, Дәрдемәнд тарафыннан иҗади дәвам иттерелде.

«Кыйссаи Сәйфелмөлек».

Сәйфелмөлек һәм Бәдигылҗәмалның мәхәббәт тарихы — Шәрык дөньясында киң таралган сюжетларның берсе. Ул «Мең дә бер кичә»дә дә урын алган. Бу сюжетка гарәп, фарсы, төрки телләрдә берничә әсәрнең иҗат ителүе мәгълүм. Шундыйларның берсе — Мәҗлисинең «Кыйссаи Сәйфелмөлек» поэмасы. Авторның тәрҗемәи хәле, яшәгән еллары төгәл билгеле түгел. Галимнәр аны XV гасыр азакларында — XVI йөзнең беренче яртысында яшәгән дип саныйлар. Кайберәүләр аны элек Алтын Урда составында булган Харәзем төбәгенә нисбәт итәләр. Шагыйрь Нугай Урдасында да яшәп алган булса кирәк. Аның әсәре якынча XVI йөзнең беренче чирегендә иҗат ителгән дип карала. «Кыйссаи Сәйфелмөлек» башка төрки төбәкләрдә дә мәгълүм. Әмма ул татарлар арасында аеруча киң таралыш тапкан. Аның күп санлы кулъязмалары, фольклор вариантлары бар.

Бу поэма тәүге мәртәбә 1807 елда Казанда нәшер ителә. Октябрь революциясенә кадәр аның Казанда ике дистәгә якын

басмасы дөнья күрүе мәгълүм. Әлеге китаплар төрле төрки халыклар арасында киң таралган[1].

Мәҗлиси әсәренең төп эчтәлеген Мисыр шаһзадәсе Сәйфелмөлекнең рәсемдә күргән гүзәлне — Бәдигылҗәмалны эзләү һәм табу маҗаралары тәшкил итә. Хыялга бай, мавыктыргыч сюжетлы бу поэмада олы мәхәббәткә, сөю хисләренең изгелегенә дан җырлана. Сәйфелмөлек белән бергә аның дусты Сәгыйть тә күп маҗараларны башыннан кичерә. Әсәр яшьләрнең үз максатларына ирешүе белән тәгәлләнә.

«Бабахан дастаны». «Бабахан дастаны» («Таһир — Зөһрә») әсәренең кайчан, кайда язылуы хакында мәгълүматлар сакланмаган. Берәүләр аны XVII гасырга, икенчеләр XV йөз башларына нисбәт итә. Фәндә поэманың иҗат ителү урынын Көнбатыш Себергә, Урта Азиягә мөнәсәбәттә караучылар да бар. Автор үзен «Сайяди» («Сайяд углы Кылыч», «Кол Сайяд») дип атый. Аның бераз вакыт Әфганстанның Бәлх шәһәрендә яшәп алуы да мәгълүм.

«Бабахан дастаны» төрки халыклар арасында, аеруча Көнбатыш Себер татарларында, гаять киң тарала. Аның төрле вариантлары, фольклор тәрдәшләре бар. Бер варианты, Көнбатыш Себер татарларыннан язып алынып, XIX йөздә В. Радлов тарафыннан нәшер дә ителә (1872 ел). Поэманың башка басмалары да бар. Кыскасы, «Бабахан дастаны»—күп кенә төрки халыклар тарафыннан яратып укылган, тыңланган уртак ядкяр.

Шәрык дөньясында Йосыф — Зөләйха, Ләйлә — Мәҗнүн, Хөсрәү — Ширин, Фәрһад — Ширин, Сәйфелмөлек һәм Бәдигылҗәмал кебек мәшһүр мәхәббәт тарихларын җырлаган күп санлы әсәрләр бар. Сайяди поэмасы да — әнә шундый ядкярләрнең берсе. Аның төп эчтәлеген Таһир — Зөһрә мәхәббәте тәшкил итә.

«Татар» дип йөртелгән шәһәрдә Бабахан исемле мәшһүр патша яши. Тормышы түгәрәк. Әмма бер кайгысы бар: баласы юк. Баһир исемле вәзирендә дә шундый ук кайгы. «Әгәр дә балаларыбыз булса, аларны һич тә бер-берсеннән аермаска!» — дип вәгъдә бирешәләр патша белән вәзир. Менә, ниһаять, Бабаханның кызы, Баһирның улы туа. Ике гаилә дә искиткеч шат.

---

[1] *Мәҗлиси.* Сәйфелмөлек: Дастан / Төзүче, хәзерге әдәби телгә күчерүче, кереш мәкалә авторы — Фәрит Яхин.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2007.— 374 б.

Таһир белән Зөһрә — икесе дә тиңсез гүзәлләр. Алар бергә уйнап, бергә укып үсәләр. Биш яшьтә вакытта Таһирның әтисе үлә.

Бабахан биргән вәгъдәсеннән баш тартырга карар кыла:

Ул үзедин әйтер: шаһ ирермән,
Ки бу татар илигә хан ирермән.

Вәзир Баһир ирде кара (кара халык.— *Х. М.*) углы,
Ки бу Таһир ирер һәм аның углы

Рәва ирмәс (әйбәт булмас.— *Х. М.*), вәзире берлә ханы
Кода булса, мәламәт тартса (борчылса.— *Х. М.*) җаны.

Патша Таһир белән кызы мәхәббәтен өзәргә уйлый: хатынының, Зөһрәнең, халыкның ай-ваена карамыйча, егетне, сандыкка салып, дәрьяга ташлата.

Сандык, агып, Багдад патшалыгына килеп җитә. Аны патшаның Маһым исемле кызы үзенең иптәшләре белән ярга чыгара. Сандыкны ачып җибәрүгә, егеткә гашыйк була. Таһир, Багдад патшасының сараенда яшәсә дә, һәрчак Зөһрәне уйлый, аңа атап җырлар чыгара. Бу вакытта Таһирның әнисе үлә, Зөһрәне Бабахан Кара баһадир дигән кешегә мәҗбүриләп кияүгә бирергә җыена. Кызның исә бөтен күңеле Таһирда. Кешеләр аркылы «Татар» шәһәрендәге хәлләрне ишетеп, егет туган ягына кайта. Бабаханнан янә кызны үзенә бирүен үтенә. Әмма патша Таһирны үлемгә хөкем итә. Егетнең үлемен ишетеп, Зөһрә үз-үзенә хәнҗәр белән кадый. Бу хәлне белеп, «Кара баһадир» да, Маһым да җаннарын фида кылалар...

Лиро-эпик характердагы «Бабахан дастаны»нда мәхәббәтнең бөеклегенә, табигыйлегенә дан җырлана, саф күңелле, олы җанлы, гүзәл Таһир — Зөһрә образлары тудырыла.

Әсәр әдәби яктан гаять камил, тәэсирле. Анда фольклорга, язма әдәбиятка хас булган күптөрле әдәби алымнар һәм чаралар уңышлы кулланылган. Вакыйга-хәлләрне бәян итүнең лирик чигенешләр, фәлсәфи уйланулар, каһарманнарның «газәл әйтүләре» белән үреп бирелүе әсәрнең укучыга тәэсир көчен тагын да арттыра. Поэмада хыялый, фантазиягә бай күренешләр күп.

Таһир — Зөһрә мәхәббәте, аларның бер-берсенә тугрылыгы өлге, үрнәк рәвешендә җырларга кереп калган.

Сайяди поэмасы күп кенә башка әсәрләр тууга этәргеч биргән. Шундыйларның берсе — Әхмәд Кормашиның «Таһир илә Зөһрә кыйссасы» (1874), икенчесе — Фәтхи Бурнашның атаклы «Таһир — Зөһрә» трагедиясе (1918).

Сораулар һәм биремнәр

1. «Идегәй» дастаны хакында VIII сыйныфта өйрәнгәннәрегезне искә төшерегез. Әсәрдән өзекләр укыгыз, тулы дастанның кыскача эчтәлеген сөйләгез.

2. «Идегәй» дастаны һәм тарихи чынбарлык үзара нинди мөнәсәбәттә?

3. Идегәй — «хәйләкәр, кыю, гайрәтле бер кеше...» «Аллаһы Тәгалә гафу итсен: Идегәй мирза шәхси мәнфәгате өчен гомуми мәнфәгатьне корбан итте. Тимерләнгне (Аксак Тимерне.—*Х. М.*) бу мәмләкәткә алып килеп, Дәшти-Кыпчак (Алтын Урда.—*Х. М.*) хөкүмәтен харап иттерде, һич вакыт җыелмас рәвештә мөселманнарның җәмгыятьләрен тараттырды, араларында булган мөнәсәбәтләрне өздерде. Хәзерге көндә бу җир мөселманнарының түбән һәм хур булып калуларының сәбәпчесе Тимерләнг булса, аның мондый һәлакәтне җиренә җиткерүче икенче сәбәпчесе Идегәй мирза булды». Тарихи Идегәй турында Ризаэддин Фәхреддин (1859—1936) әйткән бу сүзләргә сезнең мөнәсәбәтегез ничек?

4. «Кыйссаи Сәйфелмөлек» хакында нәрсәләр беләсез? Әсәрдән аерым өзекләр укыгыз, фикер алышыгыз. (Өстәмә бирем.)

5. Ни өчен без Сайяди әсәрен төрки халыкларның уртак ядкяре дип хисаплыйбыз?

6. Таһир — Зөһрә сюжетының халыкта популяр булу сәбәпләрен аңлатыгыз.

7. «Бабахан дастаны»ннан өзекләр укыгыз.

XV—XVI ЙӨЗЛӘРДӘ ИҖАТ ИТКӘН ӘДИПЛӘР

XVI йөзнең беренче яртысында иҗат иткән Мөхәммәдьяр, Казан каласын күздә тотып, болай яза:

Бер гаҗиб бу шәһәрнең эче тулуг:
Шагыйрь улмыш барча кечек һәм олуг.

Әмма шунысы кызганыч: Казан һәм башка татар мәмләкәтләренең бик аз санлы әдипләре генә безгә мәгълүм. Аларның да иҗат мираслары өлешчә генә сакланган.

Түбән Идел-Җаек төбәге шагыйрьләре.

Казтуган —чыгышы белән Әстерхан татары. Аның XV йөздә Идел тамагындагы хәзерге Кызылъяр төбәгендә аксөяк гаиләсендә туып үсүе мәгълүм. Ул батырлыгы, чичәнлеге белән дан тота. Казтуган Сөенеч углын еш кына «Казтуган батыр» дип тә йөртәләр.

XV йөздә иҗат иткән **Хәсән Кайгы** (Хәсән Сабит углы) Олуг Мөхәммәд хан даирәсендә әүвәл Сарайда, аннан Казан мәмләкәтендә яши. Хөрмәтле, дәрәҗәле кешеләрнең берсе була. Гомеренең ахырында Җаек буйларына — Нугай ханлыгына күчеп китә.

Дусмәмбәт XV гасырның соңгы чирегендә татарларның билгеле шәһәре Азакта (хәзерге Азовта) туып үсә. Гаскәри. XVI йөзнең 20 нче елларында сугышта алган ярасыннан үлеп китә.

Чалгиз Җырау (XV йөзнең соңгы чиреге—1560 еллар) — Казан ханбикәсе Сөембикәнең туганнан туганы. Яшәгән, иҗат иткән төбәге — Идел-Җаек арасы, Идел-йорт.

Бу шагыйрьләрнең әсәрләре элек-электән үк татарлар арасында укылган, Октябрь революциясенә кадәр Оренбург, Казан нәшриятларында басылып чыккан. Татарлардан тыш, алар казахлар арасында да укылган, тыңланган. Хәсән Кайгы, Казтуган, Дусмәмбәт, Чалгиз Җырау әсәрләренең, нигездә, татар телендә иҗат ителүе бәхәссез.

Өлешчә «казахлашып» киткән бу дүрт шагыйрь иҗатына нинди сыйфатлар хас соң? 1. Аксак Тимер тарафыннан Алтын Урда шәһәрләре җимерелгәч, Түбән Идел-Җаек төбәгендә утрак тормыш шактый дәрәҗәдә зәгыйфьләнеп китә. Шуның нәтиҗәсе буларак, язма һәм авыз иҗатын синтезлау (кушу) рәвешендәге сәнгати башлангыч көчәя. Чичәнлеккә тартым бу күренеш Хәсән Кайгы, Казтуган, Дусмәмбәт, Чалгиз Җырау әсәрләрендә дә күзәтелә. Шунысы мөһим: хикмәтле сүз әйтүгә, импровизациягә корылган бу традиция Акмулла һәм Дәрдемәнд иҗатларында аеруча нык дәвам иттерелде. 2. Һәр дүрт шагыйрьнең әсәрләре дә дастан жанры, аеруча «Идегәй» белән якын. Ул тел-стильдә дә, шигъри үлчәм, строфа, рифма төзелешендә дә, өлешчә эчтәлектә дә күзгә ташлана. Хәтта охшаш юллар да очрап куя. Мәсәлән, Казтуганның:

Атамыз безең бу Сөенеч
Кияү булып барган йорт,
Анамыз безең Бүзтуган
Киленчәк булып төшкән йорт,—

дигән юллары «Идегәй»нең хәзерге вакытта җыр итеп башкарыла торган өзеген искә төшерә. 3. Дүрт әдипнең дә шигырьләрендә туган җиргә, аеруча Идел-йортка, Идел-Җаекка мәхәббәт, дан җырлана. Дусмәмбәт өчен туган шәһәре Азак Истанбулдан ким түгел («Азаулының Истанбулдан нисе ким?»). Туган җиренә сокланып, Казтуган: «Хәйран минем Иделем!» — ди. 4. Хәсән Кайгы һәм аның чордашлары өчен дөньявилык, хөрлек, горурлык, яшәешне олылау хас. Авторлар шигъри чаралар ярдәмендә үз укучыларына һәм тыңлаучыларына гуманистик

сабак, әхлакый үгет-нәсыйхәт бирәләр: «Карендәшең яманлап, Үзеңә туган табылмас», «Киңәшсез сүз башлама», «Исәнең дә — тирән дә Бер булыгыз барыгыз» (Хәсән Кайгы), «Хан улыннан артык иде минем нәсәбем», «Ару сөйдем — үкенмәм, Бүген, соң да үкенмәм» (Казтуган) һ. б. 5. Дүрт әдипнең әсәрләрендә дә табигатькә якынлык, аңа янәшә яисә капма-каршы кую юлы белән кешенең рухи халәтен, әхлакый, иҗтимагый күренешләрне тасвирлау хас. Менә Хәсән Кайгының бер шигыре:

Күлдә йөргән кыңгыр каз
Кыр кадерен ни белсен?!
Кырда йөргән дуадак
Су кадерен ни белсен?!
Күчеп-кунып күрмәгән
(йөрмәгән.— *Х. М.*)
Ир кадерен ни белсен?!
Күчсә куна белмәгән,
Кунса күчә белмәгән,
Акылына күнмәгән,—
Йорт кадерен ни белсен?!

Өмми Кәмал. Ул XIV гасыр азакларында туа, 1475 елда вафат була. Өмми Кәмал — шагыйрьнең тәхәллүсе (кушаматы). Чын исеме — Исмәгыйль. Әсәрләреннән күренгәнчә, әдип бер генә урында яшәмәгән. Галимнәр аның Идел-Җаек буйларында, Кырымда һәм Кече Азиядә гомер кичерүен искәртәләр.

Өмми Кәмалнең әсәрләре татар укучылары арасында элек-электән гаять киң таралган. Кулъязмалары Идел-йортның төрле төбәкләрендә хәзер дә табылып тора. Әсәрләр җыентыгы XIX гасырда ук Казанда берничә мәртәбә нәшер ителә. Анда авторның 140 шигыре урнаштырылган. Аларның гомуми күләме 3255 строфадан гыйбарәт (күпчелеге — икеюллыклар, ягъни бәетләр; берничә шигырь дүртьюллыклар рәвешендә язылган). Җыентыктагы шигырьләрнең күпчелеге форма (шәкел) ягыннан газәл жанрында. Өмми Кәмал әсәрләренең бер өлешен мөнәҗәтләр, мәдхия-мәрсияләр тәшкил итә. Шагыйрь әсәрләренең барысы өчен дә диярлек тәхәллүс (кушамат) куллану хас.

Өмми Кәмалнең җыентыктагы әсәрләре, бер-ике сюжетлы күренешне исәпкә алмаганда, барысы да диярлек лирик характерда. Аларда уй-кичерешләр, хис-тойгылар гаять көчле һәм тирән бирелгән. Авторның лирик каһарманы — аллачыл, диндар кеше. Ул бөтен күңелен, бөтен барлыгын үзенең идеалы —олуг Тәңрегә юнәлткән, ул аны сөя, аңа омтыла, ахыр чиктә аның белән кушылырга тели. Моның өчен нәрсә эшләргә кирәк соң? Барыннан да бигрәк, дөньяның малына, рәхәт-ләззәтенә, тәхет-таҗларына кызыкмаска кирәк.

«Дөнья сүмәк һәр хатаның башыдыр»,—ди ул. Чөнки алар бар да вакытлы. Кеше, нәфес колы булудан туктап, үз күңелен пакьләргә, игелекле гамәлләр кылырга, булган гөнаһларыннан арынырга бурычлы. Шагыйрьнең күп кенә шигъри юллары лирик каһарманны битәрләүгә, аны гөнаһ кылуда, бозыклыкта гаепләүгә корылган. Өмми Кәмал иҗаты тулысы белән суфичылык рухында. Ул бу тәгълиматка мөнәсәбәтле тәшенчәләрне һәм символларны гаять мул һәм иркен куллана (тарикать, мәгърифәт, гафләт, мәгъшук, юл, мәнзил, бакый, фани, пәрванә, шәмгъ, бәхер, былбыл, гөл, кафәс, нәфес, шәраб, кәбаб һ. б.).

Өмми Кәмал иҗатындагы шактый гына юлларны пейзаж лирикасы дип атарга мөмкин. Шагыйрь табигатьне, андагы матурлыкны, җанлылыкны, гармонияне гаҗәеп оста итеп тасвирлый: «Галәм кара тунын чыкарып (салып.— *Х. М.*) киде яшелләр»; «Суларда йөзәр шад улубән үрдәк илә каз»; «Җиһане мисле җәнан итде яз йиле исәле» («Яз җиле исеп, җиһанны җәннәт кебек итте») һ. б.

Өмми Кәмал пейзаж лирикасында да суфичылыкның төп принципларына тугрылыклы кала. Аның фикеренчә, дөньядагы һәр җан иясе Аллага рәхмәт укый: «Камусы делле деленчә үгәрләр Аллаһи» («Һәммәсе үз теле белән Алланы мактар»); «кошлар Ходая тәсбих укыр». Кошлар булып кошлар да Алланы бу кадәр зурлагач, кешеләр инде Тәңрене тагын да ныграк хөрмәт итәргә, аңа иксез-чиксез рәхмәт укырга бурычлы!

Өмми Кәмал үзенең уй-кичерешләрен гәүдәләндерүдә башка сәнгати чаралардан да иркен файдалана. Ул еш кына эчке монолог формасын үз укучысына дәшү, мөрәҗәгать итү ысулы белән үреп бара. Шәрык дөньясындагы мәгълүм исемнәрне үзенең иҗади максатларына җигә. Мәсәлән, берничә бәеттә Йосыфның матурлыгы, Ягъкубның сабырлыгы, Рөстәмнең куәте телгә алына.

Өмми Кәмал иҗаты гаҗәеп күптөрле тропларга бай. Бер шигырендә ул дөньяны иске кәрвансарай, ә кешеләрне шул йортта кунып китүче кунаклар белән тиңли.

Төрки әдипләрнең олуг остазлары Әхмәд Ясәви һәм Сөләйман Бакырганый традицияләрен дәвам итеп, Өмми Кәмал да үз шигырьләренең интонацион яңгырашына, эстетик тәэсир көченә нык игътибар итә. Ул шигъри үлчәм һәм мәгънә таләбе белән синонимик вариантларга һәм формаларга мөрәҗәгать итәргә ярата: миһман — кунак, син — сән, шул — шу, сары —сару һ. б. Гомумән, шагыйрь әсәрләрендә гарәп, фарсы

сүзләре, формалары чагыштырмача күп кулланыла, архаик элементлар да очрый [тәлим (күп), яулак (начар) һ. б.].

Өмми Кәмал иҗаты — төрки-татар әдәбиятының төп юлында туган күренеш. Анда без традицияләр дәвамчанлыгын, үзенә кадәрге һәм үзеннән соңгы әдипләр белән күп санлы охшашлыклар күрәбез. Шагыйрь болай яза:

Сабыр илә һәр мөшкел эш асан улыр,
Сабыр илә һәм дәрдләрә (авыруларга.— *Х. М.*) дәрман улыр.

Шушыңа охшаш юлларны без Кол Гали, Мәүла Колый әсәрләрендә дә очратабыз.

Уд, су, йил, туфрак мохалифдер (капма-каршы, дошмандыр. — *Х. М.*)
бер-беренә,
Бонларыңла (болар белән.—*Х. М.*) тән бинасы өстөвар
(нык.—*Х. М.*) улмаз кеше,—

ди Өмми Кәмал. Мәүла Колый да күңел каршылыкларының сәбәбен кешенең физик табигате — капма-каршы дүрт элемент берлеге булу белән аңлата.

Өмми Кәмал китабында Әбелмәних Каргалыйның «Тәндә җаным ничә көн миһман икәндер, белмәдем» һәм Мәүла Колыйның «Килен кебек бизәнеп, алдагучы бу дөнья» юлларына аваздаш бәетләр дә бар.

Өмми Кәмал шигырьләрендә «үлемгә кадәр үлеп куй», «бәгъре башлы, күзе яшьле, бәңзе (йөзе) сары», «дөнья варлыгы бер көнлек», «күземез яшь йиренә кан түгәр», «һәр ки дугды улисәр», «гомреңчырагы... очды», «йөз карасын... күз яшилә (яше белән.—*Х. М.*) йу» кебек фразеологизмнар, сурәтләү чаралары очрый.

Гомумән, Өмми Кәмал иҗаты — Ясәви, Бакырганый, Хисам Кятибләрдән килә торган әдәби традицияләрне дәвам иттерүдә, үстерүдә һәм баетуда мөһим бер буын. Үз чиратында ул үзеннән соңгы татар әдипләренә, аеруча Колшәриф, Мәүла Колый, Шәмседдин Зәки, Дәрдемәнд кебек шагыйрьләргә, зур йогынты ясаган.

Мөхәммәд Әмин. Фәндә бу шагыйрьне 1487— 1496, 1502—1518 елларда Казан ханы булып торган Мөхәммәд Әмин белән бер үк зат дип хисаплыйлар. Бу хөкемдарның мәдәнияткә теләктәш булуы мәгълүм. Урта Азия һәм Һиндстан шагыйре, дәүләт эшлеклесе, галим Бабур (1483—1530) язуынча, Мөхәммәд Әмин үтенече белән Урта Азия ханы Шәйбани үзенең

берничә җырчы музыкантын һәм рәссамын Казанга җибәрә. Бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән бер савытка татарча һәм фарсыча шигъри юллар теркәлгән. Татарстан Дәүләт музеенда сакланучы бу матур, бизәкле комганны да Мөхәммәд Әминнең бакырчы остасы Насыйр ясаган. Бу хан вафат булгач, аның төрбәсендә Мөхәммәдьярның сакчы булып торуы да очраклы хәл булмаска тиеш. Кыскасы, Казан хөкемдарының әдәби иҗат белән шөгыльләнүе һич тә гайре табигый күренеш түгел.

Мөхәммәд Әминнең 12 юллык «Гыйкаб» («Үч») исемле шигыре билгеле. Бу парчада шагыйрь, үз әлгәрләре Сәйф Сараи, Әхмәд Үргәнчи, Бәззази традицияләрен дәвам итеп, Аксак Тимернең шәхесен («Үзе аксак, гаклы ахмак, фетнәдар»), эш-гамәлләрен кискен тәнкыйтьли, аның җиргә, «ислам йортына» «золым», «фетнә» китерүен күрсәтә һәм Алладан бу «залимгә» каты җәза бирүен үтенә.

Идел-Җаек буйларындагы татар мәмләкәтләре бетерелгәннән соң туган аерым ядкярләрдә («Җәмигъ эт-тәварих», «Әхвале Чыңгыз хан вә Аксак Тимер» һ. б.) Чыңгыз хан һәм Аксак Тимерне идеаллаштыру, әкияти, дастани каһарман рәвешендә гәүдәләндерү дә күзгә ташлана. Бу, күрәсең, Мәскәү хакимиятенең милли-колониаль сәясәтенә төрки-татарларның элеккеге тарихын, мөстәкыйль дәүләтчелеккә ия булган заманнарын каршы кую максатыннан эшләнгәндер.

Колшәриф. Ул — XV—XVI йөзләрдәге татар әдәбиятының Казан белән турыдан-туры бәйләнешле әдибе. Бу зат XVI гасырның беренче яртысында яшәгән, иҗат иткән, Казанның иҗтимагый һәм рухи тормышында кайнаган. Аның исеме, әсәрләре элек-электән татар укучыларына яхшы таныш.

Тарихи чыганакларда Колшәрифнең тәрбияле, укымышлы, затлы нәселдән булуы искәртелә. 1546 елда, әтисе Мансур үлгәч, Казан руханиларының җитәкчесе итеп сайлана. Бу — Казан мәмләкәтенең катлаулы, каршылыклы, һәлакәт алды еллары. Колшәриф илдә иминлекне торгызырга, Казан белән Мәскәү арасындагы мөнәсәбәтләрне тыныч, сәяси юл белән хәл итәргә омтыла. Әмма Явыз Иван хөкүмәте аның тәкъдимнәрен кире кага һәм Казанга каршы канкойгыч сугыш башлый. Башка чара калмагач, Колшәриф тә, бүтән ватандашлары белән берлектә, үз иленең, халкының бәйсезлеген саклап көрәшкә күтәрелә. Колшәриф һәм аның янындагы башка татар укымышлыларының батырларча һәлак булуын

бу күренешләрнең шаһиты кенәз А. Курбский да билгеләп китәргә мәҗбүр була. Шулай итеп, 1552 елның 2 октябрендә ил белән бергә аның рухи остазы Колшәрифнең дә гомере киселә.

Колшәриф — күренекле рухани, җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе, үз халкының фидакяр улы гына түгел, шагыйрь дә. Әмма, кызганыч ки, аның бик аз әсәрләре генә сакланып калган.

Татарлар арасында гаять киң таралган, Октябрь инкыйлабына кадәр Казанда күп мәртәбәләр нәшер ителгән «Бакырган китабы» үзенең төзелеше белән хрестоматияне хәтерләтә. Анда, Сөләйман Бакырганый (Кол Сөләйман), Әхмәд Ясәви (Кол Әхмәд), Нәсими, Фәкыйри, Мискини, Икани һәм кайбер башка төрки шагыйрьләрнең әсәрләре белән беррәттән, Колшәрифнең дә дүрт шигыре бар (барлыгы 35 бәет). Аларның барысы да төзелешләре, тышкы формалары белән газәл жанрында. Әмма шигырьләрнең берсен автор үзе «мөнәҗәт» дип атаган.

Колшәриф әсәрләре дини-суфичыл характерда. Аларда лирик каһарманның Алланы мактавы, аңа тартылуы сурәтләнә. Автор үз укучыларын «гафләт» (ваемсызлык) йокысыннан уянырга, күңелләрен пакьләргә, нәфескә бирелмәскә, Алланы һәрчак күңелдә тотарга чакыра. Шагыйрьнең аеруча «И күңел...» дип башланган газәле игътибарга лаек. Биредә автор кеше тормышының фанилыгын, әҗәлнең рәхимсезлеген аз сүзләр, гыйбрәтле сурәтләр ярдәмендә гаять оста тасвирлый:

И күңел, бил баглама, күпне кичергән дөньядыр,
Бу үлем ширбәтен халыкка эчергән дөньядыр...
...Углыны атадин айрып, кызны анадин тәкый,
Егълатып бер-бер ишекдә зари кыйлган дөньядыр...

Гомумән, Колшәрифнең «Бакырган китабы»нда теркәлгән шигырьләре үзләренең поэтик төзелешләре, интонацион яңгырашлары, сурәт-детальләргә бай булулары белән аерылып торалар. Мөгаен, шуңадыр алар укучылар тарафыннан яратып укыла.

Колшәрифнең янә бер әсәре мәгълүм. Ул 1899 елда Казанда аерым китап рәвешендә дә басылган. «Кыйссаи Хөбби Хуҗа» дип исемләнгән бу дастанның төп каһарманнары — тарихта билгеле затлар: Хәким ата Сөләйман, аның хатыны Ганбәр һәм уллары Хөбби Хуҗа. Әүвәл дастанда Сөләйман һәм Ганбәр тасвирлана, аларның изге эшләре сурәтләнә. Алга таба Хөбби Хуҗаның игелекле эш-гамәлләре, могҗизалары гәүдәләнә.

Шәрифи. Бу исем безгә иң беренче чиратта «Зафәрнамәи вилаяти Казан» («Казан мәмләкәтенең җиңүе», «Казан вилаятенең җиңү язмасы») әсәре аркылы мәгълүм. 1550 елда иҗат ителгән бу әсәрнең ахырында автор үзен «Шәриф Хаҗитархани» дип тә атый. Димәк, ул билгеле бер дәрәҗәдә Хаҗитархан (Әстерхан) шәһәре белән дә бәйләнешле: әдип яисә анда туган, яисә шул калада яшәп алган. Кайбер галимнәр бу затның Мөхәммәдшәриф (Мөхәммәд Шәриф) исемле булуын да искәртәләр. Галим Марсель Әхмәтҗанов фикеренчә, Колшәриф белән «Зафәрнамәи вилаяти Казан» авторы — икесе бер үк зат.

Шәрифи әсәренең нигезенә Мәскәү патшасы Иван IV нең 1550 елның февралендә Казанга ясаган һөҗүменә мөнәсәбәтле вакыйга-хәлләр салынган. Казанлылар дошман яуларына каршы искиткеч ныклык күрсәтеп көрәшәләр. Шуның нәтиҗәсендә шәһәр ике атнага сузылган камалыштан котыла, һәм Иван IV, чигенеп, Мәскәүгә кайтып китәргә мәҗбүр була.

Әсәрдә Сафагәрәй, Бибарс (Бәйбарс), Мамай, Нургали, Килдебәк һәм башка тарихи затлар телгә алына. Казан мәмләкәте белән рус гаскәрләре арасындагы каты сугыш шактый җентекле тасвирлана, мәскәүлеләр тарафыннан туплар кулланылуы, аларның кешеләргә ничек тәэсир итүе сурәтләнә.

Шәрифи, татар әдипләреннән беренчеләрдән булып, Казан каласы турында кызыклы язмалар калдыра. «Казан,— ди ул,—... искедән бер мөселман шәһәре булган. Казан мөселман өлкәләреннән еракта һәм кяфер өлкәсенә чиктәш урнашкан... Аңа һичбер җирдән ярдәм һәм таяныч ирешмәс, бары тик Тәңре — якын һәм фәрештәләр — ярдәмче». Автор Казан хакындагы уй-кичерешләрен шигъри юлларда да гәүдәләндерә: «Гаҗәйеб бер җай-гыйшрәттер (күңелле урындыр.—*Х. М.*) җиһанда бу Казан шәһәре», «Казан тик шәһри мәгъмүри бителмәс дөньяда һәргиз» [Казан кебек мәһабәт (төзек) шәһәр дөньяда һич булмас...]. Шәрифи фикеренчә, Казан — электән хан шәһәре. Шуңа күрә аңа Иванның дәгъва кылырга хакы юк: «Ничек килгән ушал мәлгунь?— Имәсдер бу Ибан шәһре!»

«Зафәрнамәи...» чәчмә һәм тезмә юллар катнашмасыннан гыйбарәт. Шигъри текстлар «газәл», «кыйтга», «бәет»... дип исемләнгән. Әсәрдә Коръәннән аерым өзекләр (аятьләр) дә бар. Алар сюжетка, язманың рухына туры килешле итеп ур-

наштырылган. Татарча текстлар кайвакыт гарәпчә, фарсыча юллар белән аралаштырылып бирелә.

«Зафәрнамәи...»нең тел-стиле, сурәтлелеге шактый камил. Автор үтемле генә чагыштырулар, тасвир чаралары куллана. Мәсәлән, ул «мәлгунь» Иван патшаны болай сурәтли: «Ул —денсез кяфер: тәкәббер, кинәле, ямьле көннәрне бозучы, дөньяга фетнә салучы, ике шайтанның берсе иде». Ике арадагы сугыш «мәхшәр» белән чагыштырыла. «Казан шәһәрендә,— ди Шәрифи,— Әму-Дәрьядай кан акты». Автор Казанны саклаучыларның каһарманлыгын Фирдәүси «Шаһнамә»сендәге Рөстәм, Искәндәр батырлыкларына тиңли.

«Зафәрнамәи...» ватанпәрвәрлек, азатлык рухы белән сугарылган. Әдип, бер урында үз-үзенә дәшеп: «Шәрифи, китмә бу йирдин, син — Казанның «сахибе» (хуҗасы)»,— ди. Әби-бабалары яшәгән җирне, татарның пайтәхете Казанны күздә тотып, бөек Тукай «кара йөзләргә» «Китмибез без!..» дип җавап бирә. Аның «Монда тудык, монда үстек, мондадыр безнең әҗәл» дигән юллары әби-бабаларыбыз рухына, Шәрифи мөрәҗәгатенә тугрылык анты булып та яңгырый.

«Зафәрнамәи...»дә авторның үзе күргән, кичергән вакыйгаһәлләр бәян ителә. Шуңа күрә бу әсәрнең тарихи чыганак буларак та әһәмияте зур. Жанры белән Шәрифи әсәре — әдәбитарихи-публицистик характердагы ядкяр.

Галимнәр күрсәтүенчә, «Зафәрнамәи вилаяти Казан»ның бер нөсхәсе XVI йөзнең урталарында төрек солтаны Сөләйман Канунига җибәрелә. Хәзер ул Төркиядә саклана.

* * *

XV—XVI йөзләрдә тагын башка әдипләрнең дә иҗат итүе мәгълүм. Мәсәлән, аерым хезмәтләрдә Гарифбәк исемле шагыйрьнең Сөембикәгә хезмәт итүе, Болгар-Казан тарихына мөнәсәбәтле әсәр язуы искәртелә. Әмма бу әдипнең китаплары безгә билгеле түгел. Кайбер әдәбиятчылар XVI йөздә иҗат иткән Максуди, Нух һәм Касыйми дигән төрки әдипләрнең дә Идел буенда яшәгәнлекләрен искәртәләр.

Казан ханлыгы чорының иң күренекле шагыйре,— әлбәттә, Мөхәммәдьяр.

Сораулар һәм биремнәр

1. Хәсән Кайгы, Казтуган, Дусмәмбәт, Чалгиз Җырау хакында сөйләгез. Аларның иҗатларына нинди сыйфатлар хас?

2. Өмми Кәмал әсәрләренең үзәгендә нинди уй-кичерешләр гәүдәләнеш тапкан? Аның суфичылыгы нәрсәләрдән күренә?

3. Өмми Кәмал иҗатына нинди поэтик үзенчәлекләр хас? Шагыйрьнең традицияләре татар әдәбиятында ничек дәвам иттерелә?

4. Мөхәммәд Әминне без ни өчен хөкемдар һәм шагыйрь дип әйтәбез?

5. «Колшәриф — күренекле рухани, җәмәгать эшлеклесе, үз халкының батыр улы» темасына әңгәмә оештырыгыз.

6. Колшәрифнең әдәби иҗатына нинди үзенчәлекләр хас?

7. Шәрифи әсәрендә тарихи вакыйгалар ничек гәүдәләнеш тапкан?

8. «Зафәрнамәи...»дә Казанның сурәтләнеше.

9. «Зафәрнамәи вилаяти Казан» әсәрен укып, фикер алышыгыз. Колшәриф һәм аның заманы — Кулшариф и его время.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2005.— 16—22 б. [Идел.— 1995, № 1.— 12—16 б.; Гасырлар авазы // Эхо веков.— 1995, № 1.— С. 83—92.] (Ирекле бирем.)

Мөхәммәдьяр

(1497—1549)

Бу әдипнең иҗаты һәм тормышы турында Шакир Абилов һәм кайбер башка галимнәрнең кызыклы гына хезмәтләре бар. Аның әсәрләре моңа кадәрге дәреслекләргә, «Татар поэзиясе антологиясе»нә кертелгән, 1966, 1997 елларда аерым китап рәвешендә басылып чыккан.

Тәрҗемәи хәле. Мөхәммәдьярның туган елы якынча XV йөз азагына — 1497 елга туры килә. Аның тормыш юлы Казан белән бәйләнешле. Рухани, хаҗи гаиләсеннән (Атамыз Мәхмүд догачы...). Автор «Төхфәи мәрдан» ахырында үз атының «Мәхмүд хаҗи углы фәкыйрь Мөхәммәдьяр» булуын искәртә. Ике урында шагыйрь үзен «Ярмөхәммәд» дип тә атый. Әсәрләреннән бу әдипнең шактый укымышлы булуы, гарәп, фарсы, төрки телләрне яхшы белүе аңлашыла.

Мөхәммәдьяр 1542 елда иҗат ителгән «Нуры содур» поэмасында «Мөхәммәд Әмин хан кабереңдә» «мөҗавир» (сакчы) булып торуын әйтеп китә. Әдип «Төхфәи мәрдан» әсәрендә үзенең күп мәшәкатьләргә, авырлыкларга дучар булуын да яза: «Чикдем әмма рәнҗ вә мәшәкъкать бихисаб»,— ди ул.

Аның гомер юлы да фаҗигале өзелә: Мөхәммәдьяр, Казан делегациясе составында тылмач булып, Мәскәүгә килә. Аны 1549 елның җәендә Явыз Иван гаскәрләре Муром тирәсендә вәхшиләрчә үтерә. Әмма шагыйрь үзе үлсә дә, аның ялкынлы сүзләре, әсәрләре исән калган. Бу,— әлбәттә, зур бәхет.

Безгә Мөхәммәдьярның өч әсәре — «Төхфәи мәрдан» («Егетләр бүләге», 1540), «Нуры содур» («Күкрәкләр нуры», 1542) поэмалары һәм «Нәсыйхәт» шигыре мәгълүм.

«Нәсыйхәт». Бу әсәр (ул 24 бәеттән гыйбарәт) тәүге мәртәбә 1842 елда М. Иванов хрестоматиясендә басылып чыккан. «Нәсыйхәт» дип аталган бу шигырьнең эчтәлеге символик характерда. Бер былбыл «күңел багына» очып килә.

Әмма анда караңгылык, «тикән» (тигәнәк), хәшәрәт. ...Озак очып йөргәч, ниһаять, былбыл бер «рәйхан гөле» таба һәм аңа үзенең «әр-теләк»ләрен белдерә: әгәр дә син, тикәннәрне бетереп, үз орлыгыңны чәчеп үстерсәң, бакча нурланыр, аның «иясе» дә сөйкемлегә әйләнер иде...

«Нәсыйхәт»нең төп мәгънәсе шунда: кеше үзенең күңелен пакь, нурлы, «тугры юлда» тотарга бурычлы. «Нәсыйхәт» әсәре үзенең символик образлары (былбыл, баг...), суфичылык рухы белән Шәрыкның Гаттар, Руми әсәрләренә аваздаш. Күңелне бакча белән тиңләве, «Коръән» сүзен тотарга чакыруы, лирик каһарманны бәндә, кол, «буш кул» дип битәрләве, түбәнсетүе белән бу шигырь Өмми Кәмал парчаларын да хәтерләтә.

Мөхәммәдьяр поэмалары. Бу ике әсәр үзләренең поэтик корылышлары (аларның һәр икесе дә — тартмалы композицион жанрда), әхлакый-фәлсәфи мәсьәләләрне үзәккә куюлары, лиро-эпик табигатьләре белән бер-берсенә охшаш. Һәр икесендә дә куелган мәсьәләләргә иллюстрация рәвешендә төрле шигъри хикәятләр китерелә. Хәтта сюжетлы өлешләрендә бердәй ситуацияләр дә очрый. Мәсәлән, «Төхфәи мәрдан»дагы «Җеп эрләп сатучы ир белән хатын» һәм «Нуры содур» поэмасындагы «хәммал» хикәятләре — әнә шундыйлардан. Аларның һәр икесендә дә төп каһарманнар, бурычын түли алмыйча, авыр хәлдә калган кешеләрне, актык акчаларын биреп, хәерчелектән йолып калалар. Икенче көнне берсе җебен, икенчесе утынын балыкка алыштыра. Кайтып, балыкны ярып карасалар, аның эчендә — кыйммәтле энҗе! Хикәятләрнең мәгънәсе: игелекле эш-гамәлләр һич тә юкка чыкмый, ә бәлки артыгы белән кире үзеңә кайта.

Поэмалардагы хикәят сюжетларын автор төрле чыганаклардан алган. Мәсәлән, Заһид турындагы сюжет генетик яктан «Кәлилә вә Димнә»гә һәм аның аркылы Борынгы Һиндстан ядкяре «Панчатантра»га барып тоташа. Мөхәммәдьяр поэмаларында Гаттар, Сәгъди әсәрләре, «Мең дә бер кичә» һәм Шәрыкның кайбер башка әсәрләре белән уртак сюжетлар да бар. Әмма Казан әдибе алынма материалларны теге яки бу дәрәҗәдә үзгәртә, аларны үзенең иҗади максатларына яраклаштырып эшкәртә. Нәтиҗәдә оригиналь яңгырашлы, мөстәкыйль кыйммәткә ия булган композицион берәмлекләр барлыкка килгән.

Мөхәммәдьяр поэмалары, идея-эстетик яктан традицион характерда булсалар да, үз чоры өчен дә гаять актуаль яңгырыйлар. Билгеле булганча, 30—40 нчы еллар — Казан мәмлә-

кәте өчен авыр, каршылыклы чор. Илнең эчке һәм тышкы сәяси, иҗтимагый тормышын яхшы белгән Мөхәммәдьяр, нәкъ Колшәриф кебек, дәүләтнең бөтенлеген, иминлеген саклау хакында уйлана, үз иҗаты белән тормышның зарури ихтыяҗларына җавап бирергә омтыла. Бөек остазлары Йосыф Баласагунлы, Кол Гали, Котб кебек, Мөхәммәдьяр да илнең имин, бәхетле тормышын мәгърифәтле, гадел хөкемдарга бәйләп карый. Аның фикеренчә, «падишаһ бер дәм (мизгел) гадел кыйлса», «ил-улус»ка ирек, рәхәтлек килер, хәтта «Бүре берлә куй бергә су эчәр, Үрдәк берлә карчыга бергә очар». Мөхәммәдьяр идеаль хөкемдар образын аеруча Нәүширван турындагы хикәятендә тулы гәүдәләндерә. Ни өчен бу патша вакытында ил төзек («мәгъмур»), бай, бәхетле була? Чөнки Нәүширван — укымышлы, гадел патша. Өстәвенә ул һәр эшен акыллы 70 вәзире белән киңәшеп башкара.

Шагыйрь фикеренчә, илне, җәмгыятьне төзек, имин, бәхетле итүнең мөһим бер шарты — кешеләр арасында табигый, гуманистик мөнәсәбәтләр булу. Автор үзара ызгыш-талашларны, гаугаларны, көнчелек, икейөзлелек, ялганчылык кебек сыйфатларны кискен гаепли. Әдип, зирәк һәм тәҗрибәле остаз кебек, гаделлек, рәхим-шәфкать, юмартлык, сабырлык, тугрылык кебек күркәм сыйфатларның асылын турыдан-туры да, төрле сюжетлар мисалында да укучыга җиткерергә омтыла, шулар ярдәмендә җәмгыятьне эчке яктан пакьләргә, камилләштерергә тели.

Үзеңә ни теләсәң, үзгәгә аны сакын (телә.— *Х. М.*),
Егълатып йийма үксезнең хакын.

Яманлык кыйлгучыга кыйлма яман,
Яхшылык кыйл, гәр булдырсаң, һәр заман...

Богдайдыр тиб илгә сатмагыл салам:
Яманлыкка яманлык килер һаман.

Кем егылганда, кулын тот моңлының,
Ул тәкый тоткай кулың бер көн сәнең һ. б.

Гуманистик эчтәлекле, кешегә хөрмәт белән сугарылган бу төр афористик юлларны Мөхәммәдьяр иҗатыннан күпләп китерергә мөмкин. Шагыйрь фикеренчә, бу тормыш — игелек, хезмәт күрсәтү урыны («Ингам вә ихсан йиредер бу җиһан»). Шуңа да кешеләр үз гомерләрен бу дөньяда бары изгелек һәм яхшылык кылып кына уздырырга бурычлылар.

Хәзәр, Болгар, Алтын Урда һәм XV—XVI йөзләрдәге татар мәмләкәтләрендә дин ирегә хөкем сөрүе мәгълүм. Төрки-татар чынбарлыгының шул гуманистик традицияләрендә тәрбияләнгән Мөхәммәдьяр да ил бөтенлеген саклауда үзәккә дини аерманы түгел, ә гаделлекне, кешелеклелекне куя. Аның түбәндәге сүзләре бүгенге көн өчен дә актуаль яңгырый:

Гадел булыр барча эш башы, белең,
Гадел берлә даимән бәс эш кыйлың...

...Көфер берлә мәмләкәт булмас хәраб,
Золым берлә екылыр улус йөдәб,

Көфер вә кяфир нәфсенә кыйлыр зийан,
Золым берлә булыр ил хале яман.

Шәрыкның мәшһүр философы, әдибе Газалига (1058—1111) кушылып, шагыйрь болай яза:

Бер сәгать гадел кыйлмак яхшырак,
Кем гыйбадәт алтмыш елдин озакрак.

Бездә кайвакыт «элек хатын-кыз хокуксыз булган» дигән сүзләрне ишетергә туры килә. Әмма татарлар мөстәкыйль вакытта мондый нәрсә күзәтелми, киресенчә, хатын-кызга тормышта зур хөрмәт, ихтирам булуы билгеле. Тайдула (Үзбәк ханның хатыны), Нурсолтан, Сөембикә кебек тарихи шәхесләрнең эш-гамәлләре үзләре генә дә күп нәрсә хакында сөйли. Әдипләр исә еш кына хатын-кыз образын күкләргә күтәреп мактаганнар. Харәзминең лирик герое үз сөйгәнен «пәри вә хурдан», «фәрештә»дән өстен куя, аны үзенең җаны белән тиңли «миңа дүзәх (тәмуг.—*Х. М.*) ирер оҗмах синсез», ди. Мөхәммәдьяр да үз укучысын хатын-кызны түбәнсетмәскә, аны ир-атлар белән тиң күрергә чакыра:

Тел вә күңлең игри (ялган, икейөзле.—*Х. М.*) кыйлма кешегә,
Йөзең бер кыйл кәрәк иркәк, тешигә (хатын-кызга.—*Х. М.*).

Борынгы һәм Урта гасырларның күп кенә әдипләре кебек, Мөхәммәдьяр да сүзгә, аның дәреслегенә, тәэсир көченә, шигъри телнең «тылсым ачкычы» булуына җитди игътибар итә, сүзне кешенең асылын күрсәтүче төп билге итеп саный:

...Бәс, ни килсә башка, бел, телдин килер,
Адәмигә нә ки кыйлса, тел кыйлыр...

...Ярмөхәммәд, сүзне тугры сүзләгел,
Игри тартып, укны тугры гизләгел...

Мөхәммәдьяр поэмаларына үгет-нәсыйхәт бирү, акыллы сүз әйтү хас. Автор, укучыга мөрәҗәгать итеп, фольклордан афористик фикерләр, канатлы сүзләр китерә. Аның әсәрләрендә мәкальләр күп очрый: «Иясен сыйласаң, этенә сөяк сал», «Асрама эт баласын — аслына тартыр», «Коюы казып, үзе төшкәй» һ. б.

Мөхәммәдьяр поэмаларында без татар халкының гореф-гадәтләре, образлы фикерләве өчен хас булган күп төрле күренешләр белән очрашабыз. Автор бозык, начар, мәкерле кешеләрне, халыкка зыян китерүчеләрне эт, елан-чаян белән тиңли. Шагыйрь әсәрләрендә кызыклы гына сурәтләр очрый. Мәсәлән, ул үзсүзле, тәкәббер кешеләрнең эш-гамәлен болай тасвирлый:

Мәнмәнлек кыйлыб, мәнмәнлек сатмаңыз,
Онга — кибәк, серкәгә су катмаңыз.

Мөхәммәдьяр исемнәрне символлаштыру алымына да мөрәҗәгать итә. Әсәрдәге аерым каһарманнарның исеме алардагы төп сыйфатны да белдерә: Заһид (изге), Зәргәр (ювелир), Гөлруй (гөлйөзле), Чынбел һ. б.

Өмми Кәмал, Колшәриф иҗатлары белән янәшә куйганда, Мөхәммәдьяр әсәрләренең теле гади һәм аңлаешлы. Аларда реаль тормыш белән кызыксыну, тарихи чынбарлык белән бәйләнеш көчле. Бу традицияне алга таба Мәүла Колый, Габди кебек шагыйрьләр дәвам итә.

Мөхәммәдьяр, Мәхмүд Болгари, Сәйф Сараи казанышларына таянып, үз әсәрләрендә утынчы, җеп эрләп сатучы, күчмә гарәп, ятимә кыз кебек гади кеше образларын тасвирлауга зур урын бирде, матур әхлакый сыйфатларны, гуманистик эш-гамәлләрне беренче чиратта гадәти хезмәт кешесендә күрде. Бу да — әдип иҗатының мөһим бер үзенчәлеге.

Мөхәммәдьяр поэмаларына Йосыф Баласагунлы, Котб, аеруча Кол Гали әсәрләренең тәэсире көчле. «Котадгу белек» белән «Төхфәи мәрдан», «Нуры содур» поэмалары арасында аваздаш якларны табу кыен түгел. Бу аңлашыла да, чөнки Йосыф Баласагунлы поэмасы төрки әдәбиятларның алга таба үсешен билгеләүдә катализатор вазифасын үтәгән. Мөхәммәдьяр Кол Гали әсәрендәге аерым идея-проблемаларны (язмыштан узмыш юк, мәгърифәтле, гадел хөкемдар һ. б.) уртаклаша. Мәсәлән, «Нуры содур»дагы «Сабыр кыйлмак сүзләрен бәян кыйлмак» бүлеге һәм фикри, һәм поэтик яктан «Кыйссаи Йосыф» белән аваздаш:

Сабыр берлә барча эш хасыйл булыр,
Сабыр кыйлган даимән гакыйл булыр...

Сабыр кыйлды ирсә Йагъкуб берзаман,
Булды Йосыф васлы берлә шадман...

Гуманистик рухлы, дөньяви эчтәлекле Мөхәммәдьяр поэмалары — күп гасырлык татар әдәбиятының үзенчәлекле бер сәхифәсе ул.

Казан ханлыгы чоры әдәбиятына йомгак.

XV—XVI йөзләрдәге татар мәмләкәтләрендә иҗат ителгән язма истәлекләрнең күбесе юкка чыккан. Бигрәк тә Себер, Әстерхан, Кырым ханлыкларының әдәби ядкярләре юньләп билгеле түгел.

Бу дәвердәге татар мәмләкәтләренең мәдәни якынлыгын этник берлек, язма һәм сөйләмә тел уртаклыгы, бер үк нигез —Алтын Урда мирасы тәэмин иткән. Җучи улусында туган язма һәм фольклор истәлекләренең күпчелеге («Нәһҗелфәрадис», «Җөмҗөмә солтан» һ. б.) татар мәмләкәтләрендә дә укыла. «Идегәй» — бөтен татар дөньясы өчен уртак хәзинә.

Татар укучылары Йосыф Баласагунлы, Әхмәд Йүгнәки, Ясәви һәм Бакырганый кебек борынгырак шагыйрьләр белән дә, Әхмәди, Лотфый, Нәваи, Язычуглы (Мөхәммәд Чәләби) кебек башка төрки төбәкләрдә иҗат иткән шул чор әдипләре белән дә шактый дәрәҗәдә таныш булалар. Аларның тәэсире, традицияләре XV—XVI йөзләрдәге татар әдәбиятында да үзен нык сиздерә.

XV—XVI гасырлардагы татар язма мәдәниятендә эстетик, гыйльми, гамәли башлангычлар еш кына үрелеп бара. Матур әдәбиятта газәл, дастан, хикәят, мәрсия, мәдхия, мөнәҗәт, тартмалы композиция һәм башка жанрлар, әдәби формалар актив. Гаруз хакимлек итә. Лирик, эпик һәм лиро-эпик әсәрләрнең барысы да очрый. Дөньяви һәм дини-суфичыл идеяләр еш кына бергә үрелеп бирелә. Бу дәвер әдәбиятында реаль тормыш, тарихи чынбарлык белән бәйләнеш көчәя төшә. Авторның уй-хисләре, шәхси язмышы да әдәби иҗатта зур урын ала. Эстетик идеалның мөһим өлешен матур әхлакый сыйфатлар, белем-мәгърифәт кебек төшенчәләр тәшкил итә...

Татар бәйсезлеген югалта. Дәүләтчелектән мәхрүм ителү, милли-колониаль коллыкка төшү, күп кенә матди һәм мәдәни байлыкларның юкка чыгуы татар язмышына, аның яшәешенә гаять тискәре йогынты ясый. Әстерхан, Себер, Касыйм төбәкләрендә милли-мәдәни яшәеш һәлакәт алды-

на куела. Әмма шуңа да карамастан элеккеге традицияләр, буыннар дәвамчанлыгы, тарихи хәтер билгеле бер дәрәҗәдә сакланып кала. Мәүла Колый, Утыз Имәни, Әбелмәних Каргалый, Кандалый, Акмулла һәм башка күп санлы әдипләрнең иҗатлары аша Алтын Урда, татар мәмләкәтләренең мәдәни традицияләре, аеруча язма әдәби теле Дәрдемәнд, Исхакый, Тукай, Такташларга килеп җитте. Элеккеге чор истәлекләрен бөртекләп туплау, җентекләп өйрәнү һәм халыкка җиткерү исә — бүгенге фәннең мөһим бурычы. Бары шунда гына без буыннар һәм чорлар аша асылыбызга кайта, тарихи хәтергә ия була алырбыз.

Сораулар һәм биремнәр

1. Мөхәммәдьярның тәрҗемәи хәле турында нәрсәләр мәгълүм?
2. «Нәсыйхәт» шигыренә күзәтү ясагыз.
3. Мөхәммәдьяр үзенең поэмаларында нинди мәсьәләләр күтәрә?
4. «Төхфәи мәрдан» һәм «Нуры содур» поэмаларындагы аерым хикәятләрнең эчтәлеген сөйләгез, мәгънәләрен аңлатыгыз.
5. Мөхәммәдьяр поэмаларына нинди поэтик үзенчәлекләр хас? Әхмәт Рәшитнең «Мөхәммәдьяр» поэмасын укып (Мирас.— 1996.— № 9.— 54—63 б.), фикер алышыгыз. (Ирекле бирем.)
6. Татар мәмләкәтләре арасындагы мәдәни берлекне нәрсәләр тәэмин иткән?
7. XV—XVI йөзләрдә иҗат иткән әдипләрне һәм аларның әсәрләрен искә төшерегез, кыскача белешмә бирегез.
8. Өмми Кәмал һәм Колшәриф иҗатында нинди охшашлыклар күрәсез?
9. XV—XVI гасыр татар әдәбиятында нинди жанрлар кулланыла?
10. Казан ханлыгы чоры әдәби традицияләре үзеннән соңгы татар әдәбиятында ничек дәвам иттерелә?
11. «Мөхәммәдьяр — гуманист шагыйрь» темасына инша языгыз. Шагыйрь әсәрләреннән аерым үрнәкләрне ятлагыз.

ӘДӘБИЯТ ТЕОРИЯСЕ

Лирик герой. Әдәбият өч төргә: эпос, драма, лирикага бүленә. Вакыйгалылык, эш-хәрәкәт, сюжетлылык белән бәйләгән эпик, драматик әсәрләрдән үзгә буларак, лириканың төп эчтәлеге — уй-кичерешләрне, рухи халәтне тасвирлау. Аның өчен эмоциональлек, шигъри стиль хас. Чәчмә рәвештә язылган лирик әсәрләр бик сирәк очрый. Лирикада гомумиләштерү, урын һәм вакыт шартлылыгы көчле, үзәктә —кеше, аның уй-кичереше. Мәсәлән, туган тел төшенчәсе һәр кеше, һәр халык өчен үз һәм якын. Г. Тукай

«Туган тел» шигырендә шушы гомуми изге хисне үзенчә, татар фикерләвенә хас чаралар ярдәмендә бирүгә ирешкән.

Лирик герой,— нигездә, әдәбиятның лирика белән бәйләнешле төшенчәсе. Мәгълүм булганча, лирикада кешенең эчке дөньясы, уй-хисләре, рухи халәте «мин» исеменнән сөйләнә яки нинди дә булса мәсьәлә хакында уйлану теге яисә бу күренешкә мөнәсәбәт беренче заттан шәхси кичереш рәвешендә бәян ителә.

Әдәби әсәрдәге вакыйга-хәлләр, факт-мәгълүматлар чынбарлыкның гадәти күчермәсе булмаган кебек, лирикадагы автор белән «мин»не дә тәңгәл куярга ярамый. Лирик каһарман ул —хыял, әдәби чаралар ярдәмендә тудырылган образ, сурәт. Әмма эпик, драматик әсәрләрдәге автор образыннан аермалы буларак, лирикадагы «мин» белән автор арасында эчке якынлык, бердәмлек чагыштырмача көчле. Нәкъ менә шуңа күрә дә әдәбият фәнендә лирик әсәрләр аркылы авторның тәрҗемәи хәлен, рухи халәтен, иҗтимагый һәм эстетик идеалларын өйрәнү киң таралган. Мәсәлән, Өмми Кәмал шигырьләре аркылы без әдипнең суфи булуын, күченеп йөрүен, диндар табигатьле кеше икәнлеген күрәбез.

Һәр әсәрдә лирик каһарман теге яки бу ягы белән ачыла. Шуңа күрә авторның «мин»ен ныграк аңлау, тулырак күзаллау өчен, шагыйрьнең мөмкин кадәр күбрәк әсәрләрен алу, аларны система рәвешендә карау шарт. Мәсәлән, Кандалыйның лирик герое өчен интонацион төрлелек, ихласлылык хас. Ул һәрвакыт диярлек мәхәббәттә яна, көя. Шәмседдин Зәки «мин»енә исә сагыш, уй-кичерешләр тирәнлеге, яшәү һәм үлем, кеше һәм Алла кебек мәңгелек темалар хакында уйлану хас.

Лирик каһарманның гәүдәләнеше жанр үзенчәлегенә дә бәйле. Мәсәлән, касыйдә һәм мәдхия жанрларында рухи күтәренкелек, мактау, үзең күрергә теләгән (идеаль) сыйфатларны бар дип тасвирлау күзгә ташлана. Мәрсиядә үлгән кешеләр мактала. Шуңа күрә анда үкенеч, моңсулык аһәңе өстенлек итә. Мөнәҗәтнең лирик герое, нигездә, Аллага мөрәҗәгать итеп, үзенең кайгы-хәсрәтен, аһ-зарын бәян итә. Газәлдәге каһарман — күп вакытта гашыйк кеше.

Лирик каһарман — шактый дәрәҗәдә тарихи төшенчә. Ул авторның шәхси үзенчәлегенә, талантына, чорга, җирлеккә дә бәйле. Әмма шуңа да карамастан аерым халык, дәвер әдәбиятының лирик героена хас гомуми сыйфатлар да бар. Мәсәлән, Октябрь инкыйлабыннан соң иҗат ителгән күп кенә

лирик әсәрләрнең «мин»е юлбашчыларны, партияне, СССРны, «интернационализм»ны мактады.

Кыскасы, лирик герой — әдәбиятны аңлауда һәм бәяләүдә мөһим төшенчә.

Сораулар һәм биремнәр

1. Эпос, драма төрләренең асылын аңлатыгыз. Аларга нинди жанрлар керә?

2. Лирикага нинди сыйфатлар хас?

3. Ни өчен лирик герой төшенчәсе беренче чиратта әдәбиятның лирика төре белән бәйле?

4. Автор һәм «мин» төшенчәләренең үзара мөнәсәбәтләрен аңлатыгыз.

5. Лирик герой бирелеше нәрсәләргә бәйле?

XVII ЙӨЗ ӘДӘБИЯТЫ

Тарихи-әдәби күзәтү.

Татар халкының төп өлеше яшәгән Казан, Әстерхан, Себер ханлыклары XVI йөзнең икенче яртысында Мәскәү хакимияте тарафыннан яулап алына. Явыз Иванның бу гайре табигый гамәле рәхимсез рәвештә, ут һәм кылыч ярдәмендә башкарыла. Үзенең туган җире, газиз ватаны өчен көрәшкән татар халкының яртысы диярлек юк ителә, шактые Урта Азия һәм Казахстан, Кавказ, Кырым, Төркия якларына күченә. Аларга шәһәрләрдә, зур елга буйларында яшәү тыела. Татар халкының гасырлар буена тупланган матди һәм мәдәни байлыгының күпчелеге илбасарлар тарафыннан талана, юк ителә. Казанда һәм Әстерханда мәчет-мәдрәсәләрнең, китапханәләрнең, күпләгән язма истәлекләрнең яндырылуы мәгълүм. Төп иҗат көчләре, галимнәр үтерелә. Исән калганнары да төрле якларга таралып бетә. Идел-Урал төбәгендә элек-электән татарлар белән ут күршеләр булып яшәгән чуваш, мари, удмурт һәм рус булмаган кайбер башка халыклар да Явыз Иван һөҗүмнәреннән искиткеч зур зыян күрәләр.

Мәгълүм булганча, Идел-Җаек буйларына рус патшаларының күзе элек-электән кызып йөргән. X—XII йөзләрдә үк рус кенәзләренең, юлбасарларының Хәзәр, Болгар дәүләтләренә һөҗүмнәр ясавы, аларны талау, яндырулары мәгълүм. Алтын Урда рус хакимиятенең яулап алу сугышларына берничә дистә ел буе чик куеп килә. Әмма Җучи улусы таралып, аерым татар мәмләкәтләре барлыкка килгәч, Мәскәү янә агрессив сәясәтен көчәйтә. Ул, мәсәлән, берничә мәртәбә Казанга һөҗүм итә, аның җирләрен талый, кешеләрен үтерә. Ниһаять, XVI йөзнең икенче яртысында Мәскәү хакимияте үзенең күптәннән хыялланган һәм омтылган максатына ирешә: Казан мәмләкәте юк ителә, аның халкы коллыкка төшерелә. Күп тә үтми, шундый ук язмышка башка татар мәмләкәтләре

дучар була. Әлбәттә, меңьеллык дәүләтчелек тарихына, бай матди һәм рухи культурага ия булган татар халкы үзенең милли-колониаль изелү астында калуына һич тә риза булмый: ирек, бәйсезлек өчен көрәшкә кат-кат күтәрелә. Әмма мондый кузгалышларның һәммәсе дә Мәскәү хакимияте тарафыннан рәхимсез рәвештә бастырыла.

Элек татарлар яшәгән төбәкләргә күпләп руслар күчеп утыра башлый. Чиркәүләр, монастырьлар төзелә. Уңдырышлы татар җирләре тартып алына. Халыкка зур салымнар салына. Татарның теле, гореф-гадәте, дине кысыла, төрлечә эзәрлекләнә. Көчләп чукындыру, руслаштыру башлана. Керәшен татарлары барлыкка килә.

Татар халкының милли дәүләтчелектән мәхрүм ителүе, колониаль коллыкка төшерелүе аның этник бөтенлегенә, теленә, аеруча мәдәниятенә тискәре йогынты ясады. Элеккеге рухи казанышларның күбесе юкка чыкты, яңаларын тудыру өчен, шартлар булмады. Шәрык белән традицион элемтәләр бик нык йомшара. Кыскасы, татар халкы торгынлыкка дучар ителде, иҗтимагый һәм мәдәни яктан берничә гасыр артта калды.

Әмма халкыбыз, Мәскәү, Петербург хакимияте тарафыннан никадәр изелеп, нинди зур югалтулар кичерсә дә, үзенең этник йөзен, телен, гореф-гадәтен, динен, мәдәниятен билгеле бер дәрәҗәдә саклый, бүгенге көнгә җиткерә алды.

XVI гасыр ахыры — XVII йөздә патша хөкүмәтенең милли-колониаль сәясәтенә каршылык йөзеннән татарлар арасында суфичылык тагын да көчәеп китә. Шуңа күрә дә Әхмәд Ясәви, Сөләйман Бакырганый, Өмми Кәмал кебек суфи шагыйрьләрнең әсәрләре халык арасында тагын да киңрәк тарала. Болардан тыш, Кол Гали, Рабгузый, Мөхәммәдьяр әсәрләренең яратып укылуы да мәгълүм.

Бу чор нинди ядкярләр тудыра соң? Кызганыч, аларның аз санда булулары, булганнарының да Алтын Урда, Казан ханлыгы чорында иҗат ителгәннәрдән күпкә кайтыш икәнлеге мәгълүм.

Фольклорда бәет жанры формалашып җитә. Бәетләр билгеле бер дәрәҗәдә тарихи хезмәтләр вазифасын да үз өстенә ала. Аларда халык тормышындагы, аерым кешеләр язмышындагы гыйбрәтле вакыйгалар, аянычлы хәлләр әдәби формада гәүдәләнеш таба. Мәсәлән, 1617 елда иҗат ителгән «Түкәл бәете»ндә нииндидер гаебе аркасында туган җиреннән, ата-

анасыннан аерылган кешенең авыр хәле, сагыну хисләре шактый тәэсирле итеп күрсәтелгән.

Татарның аянычлы тарихи язмышын шактый калку гәүдәләндергән «Казан алыну», «Сөембикә», «Манара» бәетләре кәгазьгә соңрак теркәлгән. Әмма аларның да тәүге вариантлары XVI гасырның икенче яртысы — XVII йөз башларында ук туган булса кирәк.

Галимнәр күрсәтүенчә, бәет жанры язма әдәбият йогынтысында, аның казанышларын мул файдалану нәтиҗәсендә туган һәм үскән. Мәсәлән, шул ук «Түкәл бәете»ндә без Өмми Кәмал, Колшәриф иҗатларында кулланылган «бәгъри башлы, күзе яшьле» гыйбарәләрен, «Кыйссаи Йосыф»тагы «газиз ирдем, зәлил улдым» тәгъбирләрен очратабыз.

Мәскәү хакимияте, гәрчә ул аны теләмәсә дә, татар телен дә билгеле бер дәрәҗәдә файдаланырга мәҗбүр булды. Рус патшаларына, түрәләренә, үзләренең колониаль сәясәтләрен тормышка ашыру, җирле халык белән идарә итү өчен, татар телен дә файдалану зарури иде. Шушы ихтыяҗны күздә тотып, XVI—XIX йөзләрдә русча-татарча, татарча-русча төрле сүзлекләр төзелә, рус уку йортларында татар телен өйрәнү өчен, уку-укыту әсбаплары, хрестоматияләр басыла. Гарәпчә-татарча, фарсыча-татарча сүзлекләрнең шул чорларда төзелүе мәгълүм.

XVII йөздә Йуныс Иванай (Йуныс бине Иванай... әл-Казани, 1619—1689) дигән күренекле шәхес яши. Ул Урта Азиядә белем алып, аннан Казан артындагы авылларда мөдәррис булып эшли. Аның Коръәнне күчерүе, фарсы китапларына шәрех язуы һәм гарәп теле грамматикасын татарча төзүе мәгълүм.

XVII йөздән безнең көннәргә берничә васыятьнамә килеп җиткән. Бу жанрның асылы — берәр кешенең икенче берәүгә үлем алдыннан язып калдырган киңәшләре яки васыяте. 1639 елда Галикәй Аталык, бераз соңрак Кишбикә Бикәч васыятьнамәләре теркәлә. Бу ядкярләр, юридик документ булу белән бергә, билгеле бер әдәби кыйммәткә дә ия. Алар намуслы, гадел яшәргә чакыралар, кешеләргә игътибарлы, ихтирамлы булырга өндиләр.

1630 елда татарчага гарәп теленнән «Мөнәббиһат» исемле китап тәрҗемә ителә. «Бу китапны,— диелә анда,— гарәп теленнән төрки теленә әвердек (күчердек.—*Х. М.*), мөселманнарга ядкяр булсын дип. Бу китапка «Мөнәббиһат» ат (исем.—*Х. М.*) бирделәр. «Мөнәббиһат» уятмакчы тимәк булыр, һәркем ирсә бу китапны укыса уяныр тиде». Тәрҗемәче үзеннән дә күп кенә

юллар, фикерләр өстәгән. Китапта дини-әхлакый мәсьәләләр, яшәеш кануннары, кыска-кыска сюжетлар гәүдәләнеш тапкан.

Тәрҗемәче «Мөнәббиһат»ка Йосыф Баласагунлының «Кутадгу белек» (1069) әсәреннән дә аерым юлларны бераз үзгәртеп керткән: «Кешенең күрке булыр йөз, йөзнең күрке — күз, авыз күрке тел булыр, телнең күрке яхшы сүз булыр». Гомумән, әсәр гуманизм, кешегә ихтирам, хөрмәт хисе белән сугарылган.

«Җәмигъ эт-тәварих».

XVII—XIX йөз татар укучылары арасында «Җәмигъ эт-тәварих», «Дәфтәре Чыңгызнамә», «Тәварихе Болгария» исемендәге әсәрләр киң таралыш таба. Аерым өлешләрен исәпкә алмаганда, алар проза белән язылган, тел-стильләре шактый камил, рифмалы проза үрнәкләре дә бар. Бу төр ядкярләр тоташ сюжетлы әсәрләр түгел: аларда фольклордан, язма чыганаклардан, тормыштан алынган төрле вакыйгалар, факт-мәгълүматлар бар. Әсәрләрдә, хыялый, уйдырма хәлләр белән бергә, күп кенә тарихи белешмәләр, вакыйгалар да урын алган. Шуңа күрә «Җәмигъ эт-тәварих», «Дәфтәре Чыңгызнамә» һәм «Тәварихе Болгария» ядкярләрен еш кына ярым тарихи, ярым әдәби әсәрләр дип тә йөртәләр. Хәзер шуларның кайберләре турында кыскача гына белешмәләр бирик.

«Җәмигъ эт-тәварих» — «Гомуми тарихлар» дигән сүз. Аны кайвакыт «Елъязмалар җыентыгы» дип тә йөртәләр. Ул 1602 елда Касыйм шәһәрендә төгәлләнгән. Китапның авторы — Кадыйр Галибәк (Галибик). Ул әүвәл Себер ханы Күчемгә хезмәт итә, аннан, русларга әсир төшеп, Мәскәүгә китерелә. Бераздан Борис Годунов тарафыннан Мәскәү кулындагы «курчак» Касыйм ханлыгына вәзир итеп билгеләнә.

«Җәмигъ эт-тәварих», — нигездә, төрки-татар ханнарының тормышын чагылдырган әсәр.

Ирандагы монгол хөкемдарлары сараенда Рәшидеддин (1247—1318) исемле дәүләт эшлеклесе һәм тарихчы эшли. Ул үзенең фарсы телендә язылган «Җәмигъ эт-тәварих» исемле атаклы хезмәте белән билгеле. Кадыйр Галибәк үз китабының беренче өлешен менә шушы Рәшидеддин тарихыннан файдаланып яза. Урыны белән тәрҗемә итә, кыскарта, өстәмәләр кертә. Ә инде татарча «Җәмигъ эт-тәварих»ның XIV—XVI гасырларны яктырткан икенче өлеше Кадыйр Галибәкнең үзе тарафыннан язылган. Биредә ул төрле язма һәм фольклор чыганаклардан файдаланган, тормыштан да күп кенә факт-мәгълүматлар кертеп җибәргән.

«Җәмигъ эт-тәварих» кереш һәм Борис Годуновны мактау белән башланып китә. Аннан соң монгол һәм төрки кабиләләрнең тарихы сөйләнә. Тәрҗемә өлешендә Чыңгызның әбибабаларын, үзен, нәселен яктыртуга зур урын бирелә. Биредә хыялый һәм тарихи мәгълүматлар үреп барыла.

«Җәмигъ эт-тәварих»ның икенче өлеше чагыштырмача мөстәкыйль берничә кисәктән — «дастан»нан гыйбарәт. Аларның үзәгендә Алтын Урда, татар мәмләкәтләренең ханнары: Ырыс, Туктамыш, Тимер Котлуг, Хаҗи Гәрәй, Хаҗи Мөхәммәд, Ядкяр... Дастаннарның берсе Идегәй турында. Бу өлештә татар тарихына, мәдәниятенә мөнәсәбәтле мәгълүматлар бар. Алар арасында «Идегәй» дастанына аваздаш юллар да очрый. Мәсәлән:

Идел туңса, кем кичмәс,
Идегәй үлсә, кем бармас.
Идел туңмасдин борын,
Идегәй үлмәсдин борын...

«Җәмигъ эт-тәварих» китабының ахыргы һәм төп «дастаны» Ураз Мөхәммәд хан турында. Бу кешенең язмышы Кадыйр Галибәк язмышына охшаш. Әүвәл ул — Көнбатыш Себердәге хөкемдарларның берсе. Русларга әсирлеккә төшә. Бераз Мәскәүдә яши. Борис Годуновның ышанычын казанып, XVI гасыр азагында Касыйм тәхетенә утыртыла.

Автор Ураз Мөхәммәднең Чыңгыз нәселеннән булуына, Касыйм ханлыгының законлы хөкемдары икәнлегенә кат-кат басым ясый. Бу «дастан»да Кадыйр Галибәк Касыйм патшалыгының эчке тормышына, гореф-гадәтләренә, Мәскәү белән элемтәләренә мөнәсәбәтле мөһим генә мәгълүматлар бирә. «Ураз Мөхәммәд хан,— ди автор,— падишаһ Борис Федоровичның теләгән теләде, даим, кичә-көндез бер касә мәй эчсә, аны яд кылмай эчмәс ирде...» Бу юллар үзе үк Касыйм мәмләкәтенең Мәскәүгә ни дәрәҗәдә бәйле булуын ачык күрсәтеп тора.

Китапта Ураз Мөхәммәднең тәхеткә утыру тантанасы аеруча җентекләп сурәтләнгән. Анда бик күп кешеләр, шул исәптән Мәскәү хакимияте вәкилләре дә катнаша.

«Җәмигъ эт-тәварих»та әдәби, тарихи яктан аеруча мөһим бер өлеш бар. Ул — «Тәгърифе Борис», ягъни Борис Годуновны мактау өлеше. Бу мадхия нәфис стиль, купшы сурәтләр, рифмалы проза белән язылган. Автор, Мәскәү хакимиятенә ярар өчен икейөзлеләнеп, рус патшасын күкләргә күтәреп мактый, аны гаделлекнең, хаклыкның өлгесе итеп тәкъдим

итә. Чынлыкта исә рус патшаларының ниндилеге, татарларга карата рәхимсез сәясәт үткәрүе тарих белән азмы-күпме хәбәрдар кешеләргә көн кебек ачык.

«Дәфтәре Чыңгызнамә». Бу җыентык та үзенең төзелеше, рухы, стиле белән «Җәмигъ эт-тәварих»ка якын. Чыңгыз хан, Идегәй турындагы текстларда хәтта эчтәлек ягыннан аерым уртаклыклар да бар. «Дәфтәре Чыңгызнамә» төрле исемнәрдә йөртелә: «Әхвале Чыңгыз хан вә Аксак Тимер...», «Дастаннар мәҗмугасы», «Дастаннар китабы» һ. б. Ул беренче тапкыр, аерым кыскартулар белән, 1819 елда Ибраһим Хәлфин хрестоматиясендә нәшер ителә. Җыентыкның башка басмалары, шул исәптән русчага тәрҗемәләре дә бар.

«Дәфтәре Чыңгызнамә»нең язылу вакытын якынча XVII йөзнең 80 нче елларына (кайберәүләр 1679 елга) нисбәт итәләр. Авторы билгеле түгел. Ул Мәскәү хакимиятенең колониаль сәясәтенә каршы кеше булса кирәк. Чөнки җыентыкта төрки-татарның бәйсез вакытын, данлы һәм гыйбрәтле тарихи язмышын сурәтләүгә төп урын бирелә, Җангали җитәкчелегендә татарлар күтәрелеше (1615 ел) хакында да мәгълүмат бар. Касыйм мәмләкәтенең соңгы ханнарыннан берсе Сәйд Борһан, 1653 елда Василий исемен алып, христиан динен кабул итә. (Ул 1679 елга кадәр Касыйм ханлыгы белән идарә итә. Ул үлгәч, 1681 елга кадәр әнисе Фатыйма солтан идарә итә. Ул вафат булгач, Касыйм ханлыгы яшәүдән туктый.) Билгесез автор Сәйд Борһанга тискәре мөнәсәбәтен белдерә, аны диненнән язучы дип атый.

«Дәфтәре Чыңгызнамә»нең төп өлеше, нәкъ Кадыйр Галибәк китабындагыча, чагыштырмача мөстәкыйль булган берничә дастаннан гыйбарәт.

Тәүге ике дастанда Чыңгыз хан һәм Аксак Тимернең әбибабалары, ата-аналары, нәсел-нәсәбе хакында сөйләнә. Биредә төгәл тарихи мәгълүматлар риваять-легендалар, хыялый, әкияти материаллар белән үреп бирелә. Мәсәлән, Алангу кояш нурыннан йөкле була, шуннан Чыңгыз туа. Турагай дигән кешенең йөкле хатынын Чыгытай хан әмере белән кыйнап үтерәләр. Әмма аның карындагы баласы исән кала. Гарип булып дөньяга килгән бу балага Аксак Тимер исемен бирәләр...

Китапта Чыңгыз хан һәм Аксак Тимер, реаль прототипларыннан үзгә буларак, әкият, дастан каһарманнары рәвешендә тасвирланалар. Һәр ике зат та гаделлекне яклаучы, хаклык өчен көрәшүче идеал хөкемдар рәвешендә күзаллана. Гомумән,

әсәрдә хөкемдар һәм халык мөнәсәбәтләре проблемасы үзәктә тора. Мәмләкәттәге бәхетсезлекне автор хакимият ияләренең гаделсезлегендә, җәбер-золымында күрә.

Беренче ике дастанда да шигъри сөйләмгә тартым, гыйбрәтле фикер-киңәшләрне үз эченә алган юллар бар. Мәсәлән: «Белеңләр кем, уңмас йортның нишаны (билгесе.— *Х. М.*) бу торыр: Үз йортын яманлар, кеше йортын мактар; үз агасын яманлар, кеше агасын мактар; үз ыругын яманлар, кеше ыругын мактар. Олысы торыр, кечесе сүзләр; атасы торыр, углы сүзләр...» Яисә: «Ил улмаган ил улса, ул ил ил улмас. Мал көтмәгән мал көтсә, кешене күзгә элмәс...»

Икенче дастанда Аксак Тимернең Идел-Җаек буйларын, Болгарны яулап алуы хакында да вакыйгалар бәян ителә. Әмма биредә дә әкияти башлангыч, хыялый күренешләр өстенлек итә.

«Гыйса углы Амәт».

Бу әсәр — җыентыктагы иң кызыклы, халык арасында киң таралган дастаннарның берсе. Ул тәүге мәртәбә 1859 елда С. Кукляшев хрестоматиясендә нәшер ителә, аннан соң да берничә тапкыр дөнья күрә. Дастанның сюжеты түбәндәгечә: Җанибәк хан, ауга китәр алдыннан, «ае-көне йиткән» хатыны Тайдулага кыз бала туса — үтерергә, ир бала булса, сөенечен хәбәр итәргә куша. «Кыз углан» дөньяга килә. Аны Тайдула углы Бирдебәк янына җибәрә. Фәрманының үтәлмәвен белеп, Җанибәк бик ачулана, янә кызны үтерергә боера. Әмма Бирдебәк бу турыда алдан ук хәбәрдар була, ул сеңелесен алып кача.

Вакыт уза. Җанибәк берчак болай ди: «Кем мәнем углымны кәлтерсә, кызымны аңа бирермен».

Гыйса углы Амәт бу эшкә алына. Ул Бирдебәк янына килә. Аны үгетләп, өчәүләп Җанибәк янына кайталар. Мәҗлестә бергә булалар. Әмма Җанибәк, әйткән сүзен бозып, кызын Мәнгәл углы Тимергә бирергә ниятли. Моны белеп, Гыйса углы Амәт, кызны алып, Идел янындагы «Зөя тагы»на кача. Ике елдан соң хатыны бала таба. Шушы вакытта Җанибәк гаскәр җибәрә. Амәт аны җиңә. Әмма яу вакытында агач ботагына асылган бишектәге баланы югалталар. Амәт, Җанибәк үлгәч, Бирдебәккә кушыла. Баланы Иделдәге салчылар үзләре белән ала да Әстерхан ханы Тимер Котлугка бирәләр. Салчы исемен алган бу бала үсә, төрле тәртипсезлекләр кыла.

«Гыйса углы Амәт» проза һәм шигырь кушылмасыннан гыйбарәт. Тезмә юллар каһарманның монологы, төп сюжетка мөнәсәбәте рәвешендә бирелә.

Үзләренең табигате һәм төзелеше белән әсәрдәге шигъри юллар «Идегәй» дастанына бик якын тора. Гыйса углы Амәт хакында да заманында күләмлерәк шигъри дастан туган булса кирәк. Хәзерге әсәр аның югалудан сакланып калган өлеше, прозаик нөсхәсе генә бугай.

«Гыйса углы Амәт»не кайчак тарихи повесть, тарихи әсәр дип тә атыйлар. Мондый караш өчен, әлбәттә, нигез бар. Дастандагы вакыйга-хәлләр XIV гасыр Алтын Урда җирлегендә, Идел буе тирәсендә (Зөя буенда хәзер дә «Кыз тавы» дигән урын бар) бара. Җанибәк, Тайдула, Бирдебәк, Тимер Котлуг кебек исемнәр дә безгә Җучи улусы тарихы аша яхшы таныш. Амәт тә тарихи шәхес булырга охшый. Хәтта Салчының да реаль нигезе бар: аның хакында Никонов елъязмасында (XIV гасыр) искә алына. Гомумән, дастан билгеле бер дәрәҗәдә шул чор рухын, атмосферасын чагылдырган.

Әмма «Гыйса углы Амәт» хәзерге төшенчәдәге тарихи әсәр түгел. Анда әдәби башлангыч, дастан логикасы өстенлек итә. Моны әсәрнең тел-стилендә, композициясендә һәм башка компонентларында күрергә була. Әсәрдә тарихи вакыйгалар, фактлар әдәби эшкәртелеп, үзгәртелеп сурәтләнгән. Мәсәлән, әсәрдәге Тайдула — Җанибәкнең хатыны. Чынлыкта исә ул —аның әнисе. Тарихи чыганакларда Тайдуланың тугыз улы түгел, ә Тәнибәк, Җанибәк, Хызырбәк исемле өч улы гына булуы мәгълүм. Әсәрдә аның кызы, әкияттәгечә, бик тиз үсеп буйга җитә. Дастанда Җанибәкнең үз кызын үтерергә боеруы әйтелә. Тарихта исә мондый нәрсә күзгә ташланмый. Киресенчә, Алтын Урда ханнарының хатыннары һәм кызлары сарайда бик дәрәҗәле булганнар.

Кыскасы, «Гыйса углы Амәт» дастаны,— гәрчә анда тарихи фактлар гәүдәләнеш табуга да карамастан, әдәби иҗат, фольклор кануннары нигезендә туган сәнгать әсәре. Шуңа күрә аны тарихи эзләнүләрдә ярдәмчел чыганак итеп кенә файдаланырга мөмкин.

«Дәфтәре Чыңгызнамә»нең дүртенче дастанында Идегәйнең шәҗәрәсе, «Җәмигъ эт-тәварих»тагы күп кенә факт-мәгълүматлар кабатлана.

Соңгы ике дастанда монголларга каршы көрәшкән кыпчак кешесе Бачман турында хикәят, болгар-татар тарихына мөнәсәбәтле риваятьләр һәм башка сюжетлар бар.

* * *

XVII йөз әдәбияты шигъри әсәрләргә дә ярлы. Бу дәвернең төп шагыйрьләре — Мәүла Колый һәм Габди.

Сораулар һәм биремнәр

1. Татар мәмләкәтләренең ни сәбәпле бетерелүе һәм таркалуы турында сөйләгез.

2. XVI йөзнең икенче яртысы һәм XVII йөз башы татар тормышына күзәтү ясагыз.

3. М. Худяковның «Казан ханлыгы тарихыннан очерклар» китабыннан аерым өзекләр укыгыз, фикер алышыгыз. (Ирекле бирем.)

4. XVII йөздә безнең әби-бабаларыбыз нинди китаплар укыган?

5. Бәет жанры һәм халык тарихы үзара нинди мөнәсәбәттә?

6. XVII йөздә төзелгән сүзлекләр, васыятьнâмәләр.

7. «Мөнәббиһат» нинди китап ул?

8. Ярым тарихи, ярым әдәби ядкярләргә нинди үзенчәлекләр хас?

9. Кадыйр Галибәк хакында без нәрсәләр беләбез?

10. «Җәмигъ эт-тәварих» китабының төзелеше, төп эчтәлеге.

11. «Дәфтәре Чыңгызнамә»нең язылу вакыты, төзелеше.

12. Җыентыкта Чыңгыз һәм Аксак Тимер образлары ничек бирелгән?

13.«Гыйса углы Амәт» дастаны: төп эчтәлеге, тарихи чынбарлык белән мөнәсәбәте. Дастаннан өзекләр укыгыз.

Мәүла Колый

Тормыш юлы. Урта гасырның күп кенә әдипләре кебек үк, Мәүла Колыйның да яшәгән еллары төгәл билгеле түгел. Бер шигырендә ул болай ди:

> Мөхиб (якын.—*Х. М.*) дуслар, бу хикмәтне әймеш көндә
> Сиксән сигез ирде тарих ул көн мең дә,
> Әйтелде шәһри Болгар кәндләрендә (авылларында.—*Х. М.*).
> Гасый (гөнаһлы.—*Х. М.*) җани Мелла Колый сүзли, дуслар.

Һиҗричә 1088 ел милади белән 1677 елга туры килә. Димәк, XVII йөзнең 70 нче елларында шагыйрь Болгар тирәләрендә яшәгән булып чыга.

«Мәүла Колый» — әдипнең кушаматы. Бер кульязмадагы шигырендә автор үзен «Меллагол» дип тә атый.

Шагыйрь мәрсия эчтәлегендәге бер хикмәтен остазы Мелла Мамайга багышлый. Шигырьдә авторның бу олуг затка карата хөрмәт хисләре белдерелә, мәрхүмнең кылган кайбер эш-гамәлләре мактала. Әсәрдән Мелла Мамайның гаять диндар, укымышлы булуы («Гыйлем, хикмәт мәктүпханә»ләр, астанәләр, ягъни гыйбадәтханәләр төзетүе) аңлашыла. «Аның туган йире шәһре Казан мәкам ирде»,— ди автор. Мелла Мамай —үз дәверенең күренекле суфие, күп дәрвишләрнең, шул исәптән Мәүла Колыйның да, рухи җитәкчесе булган. Автор бу хөрмәтле затның хаҗга баруын, кайтышлый вафат булуын искәртә.

Мелла Мамайның мөхтәрәм кеше булуы башка чыганаклар белән дә раслана. Степан Разин Казан татарларына мөрәҗәгатендә аның исемен дә телгә ала. Димәк, әле 1670 елларда Мелла Мамай исән булган. Бу факт та Мәүла Колыйның XVII йөзнең икенче яртысында иҗат итүен раслый.

Аерым исбатлаулар буенча, Мәүла Колыйның чын исеме — Бәйрәмгали Колыев (Бимкә суфи). Ул тумышы белән хәзерге Питрәч районындагы Чыты авылыннан. Казан төбәгендә укый. 70 нче елларда шагыйрь бер төркем татар крестьяннары белән Биләр тирәләренә күчеп утыра. Әмма Пётр I фәрманы белән 1699 елда аларны яшәгән җирләреннән куып җибәрәләр. Би-

регә рус стрелецлары (укчылары) китереп утыртыла. Мәүла Колый исә Шушма буендагы Иске Иштирәк авылына (хәзерге Лениногорск районы) күченеп килә. Димәк, шагыйрь XVII гасыр азакларында — XVIII йөз башларында исән була.

Мәүла Колый хикмәтләре.

Шагыйрь үз әсәрләренең күпчелеген «хикмәт» дип атаган. Аларның саны йөзгә якын. Инде без, Әхмәд Ясәви, Сөләйман Бакырганый, Сәйф Сараи, Өмми Кәмал иҗатларын өйрәнгәндә, бу жанрдагы ядкярләр белән очрашкан идек. Алда әйтелгәнчә, хикмәт — фәлсәфи-дидактик характердагы, афористик яңгырашлы лирик жанр атамасы. Хикмәтләр, нигездә, шигырь формасында язылалар. Төрки әдәбиятта бу жанр күптәннән кулланылган. Мәүла Колый Сөләйман Бакырганыйны, Кол Габидине хикмәт язуда үзенең остазлары дип саный һәм аларның исемнәрен дә үз шигырьләрендә телгә ала. Һәм, гомумән, бу шагыйрьләр арасында якынлык жанрда гына түгел, ә идея-тематикада, образлар системасында да күзәтелә. Суфичылык —аларны берләштерүче төп сыйфат.

Мәүла Колый хикмәтләре күбесенчә дүртьюллык строфалар белән язылган. Алар уртача 9 строфадан гыйбарәт. Арада 16 шар, 7 шәр дүртьюллык хикмәтләр дә очрый. Аларның иң зур күпчелеге *аааб вввб...* рәвешендә рифмалашкан. Еш кына һәр строфаның ахырында бер үк сүз кабатланып килә. Мәсәлән, карендәш турындагы хикмәттә — «булсаң», гариблек хакындагы шигырьдә — «иркән» һ. б. Берничә хикмәттәге һәр строфа бердәй юллар белән тәгалләнә. Мәсәлән, «Нишлим, ни кылыйм,— гыйлем юктыр» мәгънәсен белдергән юл 10 строфалык хикмәтнең һәр дүртьюллыгыннан соң кабатланып килә. Бер үк сүзләрнең яисә юлларның кабатланып килүе шигырьгә композицион һәм интонацион бөтенлек, сәнгати нәфислек бирә.

Үз элгәрләре Ясәви, Бакырганый, Өмми Кәмал кебек, Мәүла Колый да, нинди мәсьәлә хакында язса, шуны үтәүне үзе өчен мәҗбүри саный. Мәүла Колый шигырьләренең күбесе аның үз-үзенә мөрәҗәгате, эндәше белән тәгалләнә. Мәсәлән:

Мәүла Колый, атаң-анаң белдең микән?
Хушнуд кыйлып изгү дога алдың микән?
Юкса хушнуд булмай анлар үтте (үлде.— *Х. М.*) микән,—
Кани (кайда.—*Х. М.*) бу көн? Кулдин китде, нитмәк кирәк?

Лирик геройның уй-кичерешләрен турыдан-туры авторга бәйләү шигъри сөйләмнең үтемлелеген, ышандыру көчен арттыра.

Мәүла Колыйның күпчелек шигырьләре 12 ле иҗек үлчәме белән язылган, ягъни һәр шигырь юлындагы иҗекләр саны 12 гә тигез. Берничә хикмәте фольклорга хас булган җиделе үлчәмдә. Мәсәлән:

Карый (карт.—*Х. М.*) дөнья төзәнеп, 7
Килен кебек бизәнеп, 7
Алдамага ясанып. 7
Кач, качкынай, качсана. 7

Мәүла Колый хикмәтләре тел һәм стильләре, эчтәлек, формалары белән чагыштырмача тормышчан, үтемле.

Хикмәтләрнең идея эчтәлеге.

Мәүла Колый шигырьләрендә тормыш һәм яшәешнең аерым мәсьәләләре гәүдәләнеш тапкан. Шагыйрьнең лирик герое төп игътибарын кешегә, аның рухи дөньясына юнәлтә. Мәүла Колыйның идеалы — диндар, Аллага чын күңелдән бирелгән, аңа буйсынган зат; ул — ихлас, гадел, инсафлы, итагатьле, ярдәмчел шәхес. Андый кеше, нәфесенә бирелеп, дөнья малына, җиһан ләззәтләренә кызыкмый: рухын пакьләү, үзен эчке яктан камилләштерү белән шөгыльләнә.

Шагыйрь үз идеалын еш кына лирик каһарманны тәнкыйтьләү, аны битәрләү аша гәүдәләндерә. Ягъни аның герое ваемсызлыкка, гөнаһка чумган, нәфескә бирелгән, дөнья белән мавыгып, Алланы хәтереннән чыгарган:

Бу җиһанда (һич) тугмады мәндин яман,
Нәфсе илә шайтан мәңа бирде яман.

Автор үзенең лирик каһарманын уянырга, тәүбә кылырга, хак юлга басарга өнди:

Күңлем эчрә корылмыштыр гөнаһ туе,
Уд кабар дип хәүфлемен, белең моны.
Ул удларны сүндерер ирмеш тәүбә суы,—
Андин үзгә һәргиз (һич тә.— *Х. М.*) дәва юкдыр анда.

Мәүла Колый — тормышта гына түгел, иҗатында да суфи. Аерым шигырьләрендә ул илаһи мәхәббәт хакында, Аллага бөтен барлыгы белән тартылуы турында яза:

Сөйгән ярның мәхәббәте күңел тулды,
Күрмәгә барур булсам — бакмас мәңа.
Эчем-тышым кабну янган хәсрәт уты,—
Сүндермәгә су теләсәм, бирмәс мәңа.

Урыны белән тормышны түбәнсетеп каравы да авторның суфичылык карашлары белән аңлатыла.

Әмма Мәүла Колыйның суфичылыгы шактый үзенчәлекле. Бер хикмәтендә ул, бер яктан, суфичылыкны кәсепкә әйләндерүчеләрне кискен тәнкыйтьли. Икенче яктан, аның фикеренчә, чын суфи халыктан алмыйча, аңа үзе бирә, дөнья малы белән мавыкмый, «Хак гыйшкында баш-җаныдин кичә». Кыскасы, шигырьдә суфи идеаль кеше, камил инсан рәвешендә күзаллана.

Күп кенә суфи шагыйрьләрдән үзгә буларак, Мәүла Колый хикмәтләрендә дөньявилык шактый көчле. Автор кешелек яшәешенең игенчелек, гаилә кору, гыйлем туплау, карендәшлек кебек мәсьәләләренә җитди игътибар итә. Түбәндәге хикмәтендә автор, үз элгәрләре Котб, Сәйф Сараи традицияләрен дәвам итеп, игенчелекнең гыйззәтле-хөрмәтле «хуш һөнәр» булуы хакында яза. Хикмәт авторның үзен һәм укучыларны, иген игеп, юмарт кеше булырга өндәү белән тәмамлана.

Мәүла Колый тигез мәхәббәткә корылган гаилә тормышын мактый, бала тәрбияләүне ата-ана өчен зарури эш дип саный.

Шагыйрьнең аеруча галимнәр, гыйлемлек турындагы юллары тормышчан, кызыклы:

> Гыйлемлек Хак рәхмәтедер, бер нур торыр,
> Кемне галим кыйлса Изем (Аллам. — *Х. М.*), газиз кыйлыр.
> Углан икән, төн-көн гыйлем тәхсыйль кыйлыр
> (өйрәнер.— *Х. М.*),
> Хак рәхмәте ул колына булыр булгай...

Әмма Мәүла Колый әсәрләрендә каршылыклы фикерләр дә очрый. Мәсәлән, бер хикмәтендә ул туганнары белән аралашып, үзара ярдәмләшеп яшәүне мактый. Икенче урында исә үз укучысын хәлвәттә, ягъни аулакта, ялгыз гомер кичерергә чакыра.

Мәүла Колый хикмәтләре кешеләргә хөрмәт-ихтирам, шәфкать, ярдәмчеллек рухы белән сугарылган. Бер шигырендә автор ата-ана белән бала арасындагы мөнәсәбәтләрнең ничек булырга тиешлеген гаҗәеп матур, үтемле итеп тасвирлый. Ата-ананы хөрмәтләү, аларга ярдәм итү — баланың изге бурычы. Әгәр дә киресе икән, ул — Аллага каршы килү дигән сүз.

Шагыйрьнең гарибләр (туган-үскән җиреннән аерылган кешеләр) турындагы хикмәте дә тирән гуманистик фикергә бай. Аларның,— ди автор:

> Башында ултырмага атасы юк,
> Өстендә хәсрәт йотар анасы юк.
> Уңлы-суллы хәлен сорар иясе юк,
> Бер үлмәке мең үлмәкдин яман иркән.

Шагыйрьнең үз-үзенә эндәшеп язган шигырьләре гаҗәеп мәгънәле, кешелекле яңгырый:

Мәүла Колый, гарибләрнең хәлен сорсаң,
Хәлен сорап, гарибләргә шәфкать кыйлсаң,
Кулда барын биреп, күңлен хушнуд кыйлсаң,
Изем рәхман сәндин хушнуд (риза.— *Х. М.*)
булыр иркән.

Өмми Кәмал кебек, Мәүла Колый да табигатьтәге үзгәрешләр аша вакыт, гомер агышын тасвирлый:

Кыш көнендә үләннәр йирдә черер,
Яз булдисә, нәбат (үсемлек.—*Х. М.*), нигъмәт үсә
торыр.
Барча адәм үлеп барып, гүргә керер,
Кыямәт көн кайра (кабат.— *Х. М.*) терлер кодрәт
берлә...

Шагыйрь фикеренчә, кеше гомере дә фани. Шуңа күрә үзеңә бирелгән вакытны бушка уздырма:

Бу тереклек кулдин китәр, кайра (кабат. — *Х. М.*) килмәс,
Гомрең заигъ кичәр, сәңа әсигъ (файда.— *Х. М.*) кыйлмас,
Нәчә кусаң, үткән гомер янә булмас,—
Тереклекдә Хак зикрендә торгым микән?

Мәүла Колый хикмәтләрендәге лирик герой, әйткәнебезчә, каршылыклы, аның күңелендә һәрчак көрәш, тартыш бара. Автор исә моның сәбәбен, Котб, Өмми Кәмал һәм Урта гасырның кайбер башка әдипләре кебек, кешенең каршылыклы табигатендә күрә. Аның фикеренчә, кеше ут, су, һава, туфрак берлегеннән гыйбарәт. Бу элементлар капма-каршы сыйфатлы, алар арасында һәрчак көрәш бара. Шуңа күрә кешенең күңеле дә каршылыклы.

Мәүла Колыйның илаһи мәхәббәт хакында гына түгел, дөньяви гыйшык турында да шигъри юллары бар. Алар өчен тормышчанлык, самимилек хас:

Былбыл кошның артар гыйшкы кызыл гөлдин,
Нәүмид кыйлса (өметсез итсә.—*Х. М.*) сүнмәз яр (и) күңел сәндин,

Бу чыкар җан ахыр бер көн чыкар тәндин,—
Сән гүзәл яр айрылмаен торгыл мәндин...

Гомумән, Мәүла Колый хикмәтләрендә авторның рухи халәте, тормыш һәм яшәеш хакында уйланулары, хис-кичерешләре шактый тулы һәм үтемле тасвирланган.

Шагыйрьнең яңа табылган әсәрләре. Без моңа кадәр Мәүла Колыйны хикмәтләр авторы буларак кына беләидек. Баксаң, ул күләмлерәк әсәрләр дә язган икән. Узган гасырның 90 нчы еллар башында Татарстан Республикасының Милли китапханәсе хезмәткәре Раиф Мәрданов Әгерҗе районы Яңа Аккужа авылыннан шагыйрьнең ике поэмасын табып кайтты һәм аларны бастырып та чыгарды (Казан утлары.— 1996.— № 10.— 159—171 б.).

Әсәрләрнең беренчесе «Береккәннәр сыйфаты» (ул 238 шигъри юлдан — мисрагтан гыйбарәт. Уртада берничә бите юк), ә икенчесе «Хәлял нәфкъә эстәгәнләр (хәләл ризык теләүчеләр.—*Х. М.*) сыйфаты» (монысының тәүге 66 мисрагы гына бар). «Береккәннәр сыйфаты»нда автор үз исемен дә телгә ала:

> Әй Ходая, гасый җафи Мәүла Колый,
> Рәхмәтеңлә (рәхмәтең белән.—*Х. М.*) биргел коллык йулый.

Беренче поэмада «60 ел» гыйбадәт белән генә шөгыльләнгән ир белән хатынның, Иблис котыртуы белән, сәфәргә чыгулары, маҗаралы хәлләргә дучар булулары сурәтләнә. Патша кызына гашыйк булган ир хатынының тугрылыгы, кыюлыгы аркасында гына үлемнән котылып кала. Әсәрдә киң күңеллелек, бердәмлек («береккәнлек») мактала.

Икенче поэма гади бер «тиречe»нең көнкүрешен тасвирлау белән башлана. «Бу зат хәләл дип тапкан «тәңкә»сен хакына һәр нә тигәр алыб килгел!» — дип, бер сәүдәгәргә бирә... Әмма, кызганычка каршы, шушы урында кульязманың битләре төшкән.

Һәр ике поэма да лиро-эпик характерда. Сюжетлары традицион. Суфичылык рухы сизелеп тора. Һәр ике әсәр өчен дә вакыт һәм урын шартлылыгы хас. Әкияти һәм реаль күренешләр, детальләр еш кына кушылып, үрелеп бара. Поэмаларның тел-стилендә, шагыйрьнең хикмәтләре белән чагыштырганда, архаик сүзләр һәм формалар күбрәк. Ритмик төгәлсезлекләр дә очрый. Мәүла Колый бу әсәрләрен, күрәсең, яшьрәк чакта, әдәби тәҗрибәсе азрак вакытта иҗат иткәндер дигән фикер кала.

Мәүла Колый шигырьләренең поэтикасы. Ә соң шагыйрь үзенең теләк-омтылышларын, эстетик идеалын гәүдәләндерүдә нинди әдәби чаралар кулланган? Бу сорауга инде хикмәтләр бүлекчәсендә өлешчә җавап бирелде. Хәзер исә Мәүла Колый поэтикасының янә берничә үзенчәлеген билгеләп китәрбез.

Шагыйрь кулланган сурәтләрнең һәм төшенчәләрнең шактые реаль чынбарлыктан, тормыштан алынган. Әмма бер өлеше дини-мифологик характерда: оҗмах, тәмуг, Әйүб, Мөнкир-Нәнкир (кабердә сорау алучы ике фәрештәнең исеме), Иблис һ. б.

Мәүла Колый да, Урта гасырның кайбер башка шагыйрьләре кебек үк, капма-каршы куюу, ягъни антитеза алымын ярата кулланa: яшьлек — картлык, яз — кыш, оҗмах — тәмуг, юмартлык — саранлык, фани дөнья — бакый дөнья һ. б. Бер шигырендә ул «гыйлем» төшенчәсен наданлык белән капма-каршы куеп сурәтли:

Галимнәр күк йөзендә көнәш яңлигъ (кояш кебек.— *Х. М.*),
Шәкердләр тулып торган айга яңлигъ,
Мөэминләр күк йөзендә йолдыз яңлигъ,
Наданлар коңгыз-кортка охшар булгай.

Икенче бер урында шагыйрь яз — кыш антитезасы аша «яшьлек — картлык» төшенчәләрен ачып сала:

Яз көнендә болыт аз, чуак (аяз.— *Х. М.*) ула,
Егет кеше кайгусы юк,— даим көлә.
Карый (карт.— *Х. М.*) кеше мисле һаман кыш тик була,
Шул сыйфатлы гомре кәчәр кодрәт берлә.

Мәүла Колый хикмәтләре күптөрле метафораларга, чагыштыруларга, символларга бай. Шагыйрь күңел тынычсызлыгын дулкын, диңгез белән тиңләргә ярата: «Мәвеҗ орыр бу күңел», «Мәвеҗ кылса (дулкынланса.— *Х. М.*) бу күңелнең бәхре (диңгезе.— *Х. М.*) кайнап...» Бер хикмәтендә автор дөньяны — зиндан, тәнне шуның эчендәге «бостан» (бакча), ә җанны бостандагы «миһман» (кунак) белән чагыштыра, күңел каршылыгын «гөнаһ туе»на охшата.

Мәүла Колый нәфескә бирелеп, хәрәм мал җыеп, тәкәбберләнеп йөргән кешенең ахыргы язмышын болай тасвирлый:

Туным бар,— тиб, дөнья тунын кигән кеше,
Хак кашында ябынурга туны юкдыр.

Автор көндәлек тормыш өчен хас булган детальләрне дә шигырьдә бик оста файдаланган. Мәсәлән, бер хикмәтендә ул, үз укучысын дөнья белән мавыкмаска чакырып, болай ди:

Бу дөньяны үләксә ит кебектер бел,
Дөнья өчен талашканлар — этләрдер, бел.
Талашканлар китәр, дөнья калыр, күргел,—
Гыйбрәт алып, тәүбә-тәүфикъ итәйен мән.

Икенче бер парчасында автор тәмәке тартучыларны пычрак дуңгыз белән тиңли.

Мәүла Колый поэтикасында төрле стилистик фигуралар мөһим урынны алып тора. Автор, кичерешләрнең тирәнлеген, хәрәкәтнең дәвамчанлыгын белдерү өчен, бер сүзне янәшә куеп кабатларга ярата. Автор кайвакыт, бер тамырдан булган сүзләрне кабатлап, шигырьнең интонациоч һәм фикри яңгырашын көчәйтүгә ирешә. Хәтта ул бу алымны композицион чара буларак та куллана.

Ирүр дөнья бер сәгать,
Нә ятурсән, кыйл тәгать (буйсыну.—*Х. М.*),
Бу җан — тәндә әманәт,
Белгел, беләй (бел әй), белсәнә.

Алдагы строфаларның һәр соңгы юлы, үзара рифмалашып, шундый кабатланулы, көчәйтүле сүзләр төркеменнән гыйбарәт: «Ян-ян, янгай, янсана», «Тән-тән, тәнәй, тәнсәнә», «Кач, качкынай, качсана» һ. б. Бу төр кабатлаулар соңрак Бабич иҗатында актив кулланыла. Мәүла Колый урыны белән анафораларга да мөрәҗәгать итә:

Сабыр берлә Әйүб тапты сыйххәт үзен,
Сабыр берлә Йагъкуб ачды күрмәс күзен.
Сабыр берлә Йосыф табды дәүләт йөзен,—
Сабыр берлә телдин җөда (мәхрүм.—*Х. М.*) итсә булмас.

(Бу юллар — «Кыйссаи Йосыф» традицияләренең дәвам ителешенә дә бер дәлил.)

Мәүла Колый телдәге аерым авазларның гармоник кабатлануын да шигъри максатка җигә:

Йөз юмага акның агы күздә яшьтер,
Йөзем ике күз яшилә югым кәлер.

Күрәсез: биредәге *з, а, г...* авазларының кабатлануы бу юлларның интонацион яңгырашын көчәйтүгә ярдәм иткән.

Мәүла Колый хикмәтләренең теле, нигездә, бүгенге укучыларга шактый аңлаешлы. Арада «бал-шәкәрдин ләззәтле», «йөрәк-бәгърем кайный», «килен кебек бизәнеп», «колагыңны сала күрмә һәр сүзенә» кебек киң кулланылыштагы тәгъбирләр дә күпләп очрый. Шагыйрь кайвакыт борынгырак сүзләр һәм формалар да кулланып ала. Мәсәлән: иркәк-теши (ир-ат, хатын-кыз төшенчәсен белдерүче бу тезмә борынгы төрки телдә үк очрый), күкес (күксе) — күкрәк, үгәр — мактар, әл-

азак — аяк-кул. Шигырьләрдә халыкка аз аңлаешлы гарәп-фарсы сүзләре күп түгел. Автор урыны белән аларны синонимнар рәвешендә дә кертеп җибәрә.

* * *

Мәүла Колый иҗаты — үзенә кадәрге төрки-татар әдәбиятындагы аерым сәнгати казанышларның билгеле бер дәрәҗәдә кабат торгызылуы һәм дәвамы да ул. Бу хәл хикмәтләрнең идея-эчтәлегендә дә, поэтикасында да, тел-стилендә дә ачык күзәтелә. Мәсәлән, Йосыф Баласагунлы, Өмми Кәмал дөньяны тугрылыксыз, килен кебек бизәнеп кешеләрне алдаучы зат рәвешендә карыйлар. Мәүла Колыйда да шуңа охшаш юллар бар:

Кадим заман узынып, төрлүк рәңгә (төскә.—*Х. М.*) төренеп,
Килен кебек бизәнеп, алдагучы бу дөнья.

Яисә:

Бу җиһанны күреп белдем вафасы юк.

Сәйф Сараи «Гөлестан бит-төрки» әсәрендә болай ди:

Икейөзле кеше синең мәҗлесеңдә нигъмәтеңне ашар,
Аннан чыгып, дошманнарыңа гайбәтеңне чәчәр. *(Тәрҗемә)*

Мәүла Колый да бу мотивны үз сүзләре белән гәүдәләндерә:

Дошман улдыр: өйүгә керер, ашың йийр,
Андин чыкып, хәлаекга гайебең дийр.

Үз чиратында Мәүла Колый традицияләре дә үзеннән соңгы әдәбиятта дәвам иттерелде. Мәсәлән, Сәйф Сараи һәм Мәүла Колый иҗатларында эшкәртелгән мотивлар Утыз Имәни, Габдулла Тукай шигъриятендә дә гәүдәләнеш тапкан.

Сораулар һәм биремнәр

1. Мәүла Колыйның тормыш юлы.
2. Әдәбият белеме сүзлекләреннән хикмәт хакындагы мәкаләләрнең эчтәлеген үзләштерегез.
3. Мәүла Колый хикмәтләренең жанр үзенчәлекләрен атагыз.
4. Шагыйрь хикмәтләренең идея эчтәлеге нәрсәдән гыйбарәт?
5. Мәүла Колыйның суфилыгы нәрсәләрдә күренә?
6. Шагыйрь хикмәтләренең поэтикасына нинди сыйфатлар хас?
7. Мәүла Колый поэмалары нәрсә турында?
8. Татар әдәбияты тарихында Мәүла Колыйның урыны.
9. Шагыйрьнең бер хикмәтен ятлагыз.

Габди
(*1679 —XVIII йөзнең беренче чиреге*)

Габди — XVII һәм XVIII йөз әдәбиятларын тоташтыручы, Мәүла Колыйдан алган шигъри эстафетаны үзеннән соң килгән әдипләргә, иң беренче чиратта Габдессәламгә, Утыз Имәнигә җиткерүче шагыйрь.

«Габди»— әдипнең тәхәллусе. Аерым шигырьләрендә ул үзен «Мескен Габди» дип атый.

Шагыйрьнең тормыш юлы хакында мәгълүматлар бөтенләй юк диярлек. Шуңа күрә без аның кемлеге хакында әсәрләренә таянып кына фикер йөртәбез. Бер шигырендә ул болай яза:

Мескин Габди, яраг әйлә,
Яшең утыз булды төз.
Тарих ирде мең дә йөз дә
Екерме бередә төз.

Димәк, авторга 30 яшь тулган була. Шуңа карап аның туган елы 1679 дип билгеләнә. Ә үлгән елы билгеле түгел.

Әсәрләреннән Габдинең Казан белән бәйләнешле булуы аңлашыла: «Шәһрең булгай һәм Казан», «Шәһре — Казан, теле — төрки» һ. б. Шагыйрь — үз чорының укымышлы, билгеле кешесе.

Габдинең безгә билгеле иҗат мирасы зур түгел: 60 тан артык кыска-кыска лирик шигырьләр. Жанр ягыннан алар төрле: хикмәт, робагый, мәдхия, мөнәҗәт һ. б. Бу шигырьләр «Тәгърифнамә» исеме астында бирелгәннәр.

Габди дә, нәкъ Мәүла Колый кебек, үзенең уй-кичерешләрен ислам дине белән тыгыз бәйләнештә белдерә. Чор күренешләрен, кешеләрнең холык-фигыльләрен, эш-гамәлләрен дә ул нәкъ әнә шул тәгълиматка, дини әхлакка таянып бәяли.

Шагыйрь яшәгән чор — татар тормышының иң авыр, иң катлаулы еллары. Габди дә кыенлыкны күрә, җәбер-золымда яшәгән халыкка кызгану, теләктәшлек тойгысын белдерә, әмма сабыр итәргә, түзәргә чакыра. Шагыйрь өчен кешеләрнең үзара тату булып, килешеп яшәве мөһим:

Бер-берецез арасында
Кылмагыл золым, җәвер.
Үз гайебең үкеш (күп.— *Х. М.*) күргел,
Кеше гайебен һәргиз (һич тә.— *Х. М.*) күрмә.

Габди, үз элгәрләре Мөхәммәдьяр, Мәүла Колый традицияләрен дәвам итеп, кешеләрдә булырга тиешле матур әхлакый сыйфатларны, күркәм эш-гамәлләрне тасвирлауга зур урын бирә. Кешене бизи торган сыйфатларның иң изгесе —«сәхилек», ягъни юмартлык, ди ул.

Шагыйрь, тәкәбберлек, масаю, хәрәм мал җыю, кешене рәнҗетү, саранлык кебек күренешләрне кискен тәнкыйтьләп, аларга тыйнаклык, әдәплелек, юмартлык кебек матур сыйфатларны каршы куя.

Габди галимнәрне хөрмәт кылырга, алар белән аралашырга чакыра:

Йыракдин күрсәң анларны,
Катына килеп кул алыш.
Күңлен алып, көн дә кил —
Бервакыт булма чалыш.

Габди ата-анага мөнәсәбәт, бала тәрбияләү, дуслык һәм башка мәсьәләләрне яктыртуда да Мәүла Колыйга тугрылыклы кала. Хәтта ул рифмалашуда да үзенең өлкән каләмдәшенә аваздаш:

Атаң берлә анаңа
Хезмәт иткел күп-күп,
Иртә торып, һәр көндә
Аякларын үп-үп.
Һәр нә әйтә, анларның
Сүзләрен күр йөп-йөп (җөплә.—*Х. М.*).
Сабыр кылгыл, һәр нәчә
Кыйнасалар дөп-дөп.

Шагыйрь фикеренчә, һәрбер кешенең барыр җире — бер («Барыр йиреңез — бер йирдер, йарлы-бай, хатын-ир кеше»), яшәүнең ахыры — үлем, шуңа күрә кешеләргә тигез карау шарт.

Мәгълүм булганча, патша хөкүмәте үзенә каршы килүчеләргә, аеруча рус булмаган халыкларга карата колак, борын кисү, телне өзү кебек рәхимсез җәзалар кулланган. Бу детальләрнең кайберләре Габди шигырьләрендә дә очрый. Автор мондый гамәл кылучыларны гаепли, аларны тәмуг җәзасы белән куркыта.

Габди шигырьләре тел-стиль ягыннан Мәүла Колый хикмәтләренә караганда да аңлаешлырак.

Габди кулланган чагыштырулар, метафоралар чынбарлыкка якын булулары белән сыйфатланалар:

Бу дөньяның бары кырау —
Малың тормас ошбу көнчә.

Яхшы атың чыгарубән
Үзең өчен ат казан.
Бу йигетлек чиллә бикин (кебек.— *X. M.*),
Карыйлык мисле хәзан (картлык көз кебек.—*X. M.*).

Дөнья малын «кырау» белән чагыштыру, яшьлекне «чиллә» белән янәшә куюю моңа кадәрге әдәбиятта күзгә бик ташланмый. Соңгы шигырьдәге «яхшы ат», «ат казану» детальләре борынгы төрки ядкярләрендәге, Сәйф Сараидагы сурәтләргә аваздаш.

Габди иҗатында Урта гасыр әдәбиятына хас булган афористик фикерләү, хикмәтле сүз әйтүнең дә матур гына үрнәкләре бар:

Үз кавемең арасында мең гаебең бер күренер,
Ят кавемнең арасында бер гаебең мең күренер.

Габди шигырьләрендә татар халкының аерым гореф-гадәтләре дә чагылыш тапкан. Мәсәлән, «Кунакка хөрмәт күрсәт» парчасында без моның бер үрнәген күрәбез.

Габди иҗатында Мәүла Колый белән чагыштырганда дөньявилык көчле, ә суфичылык зәгыйфь.

XVII йөздәге язма мәдәният, башка чорлар белән чагыштырганда, шактый ярлы. Әмма, объектив шартларны искә алганда, бу дәвер мәдәниятендә дә уңай яклар булуын күрергә кирәк. Анда элеккеге рухи казанышларны яңа тарихи шартларга нисбәтән торгызырга, хәтта үстерергә омтылыш бар. Әдәбият һәм фольклор, әдәбият һәм тарих үзара тагын да якыная төшә. Язмаларның тел-стилендә халыкның сөйләм теленә борылу үзен сиздерә. Шигъри фольклордагы аерым сурәтләр, формалар язма әдәбиятка күбрәк керә башлыйлар. Суфичылык үзен нык сиздерә. Мәүла Колый һәм Габди кебек шагыйрьләрнең әсәрләрендә әхлакый-фәлсәфи мәсьәләләр, кеше турында карашлар үзәккә куела, аларны сәнгати хәл итүдә уңышлы гына адымнар ясала.

XVII йөз әдәбияты — күп гасырлык татар әдәбияты тарихының мөһим бер сәхифәсе ул. Элеккеге күп кенә традицияләр шушы дәвер аша XVIII—XIX гасырларга тапшырылды.

Сораулар һәм биремнәр

1. Габдинең тәрҗемәи хәле хакында сез нәрсәләр белдегез?
2. Шагыйрь әсәрләрендә нинди мәсьәләләр гәүдәләнеш таба?
3. Габди шигырьләренең сәнгатьчә эшләнеше.
4. Ни өчен без Габдине Мәүла Колый традицияләрен дәвам иттерүче дибез?
5. XVII йөз әдәбиятына нинди сыйфатлар хас? Аның әдәбият тарихындагы тоткан урыны турында сөйләгез.

ӘДӘБИЯТ ТЕОРИЯСЕ

1. Шигырь төзелеше (белгәннәрне искә төшерү, тирәнәйтү)

Укучылар, сез инде моңа кадәр төрле жанрдагы поэтик әсәрләр белән очраштыгыз, тезмә сөйләм, шигырь төзелеше турында күп кенә мәгълүматлар алдыгыз. Алга таба да бу юнәлештә белемнәрегезне тирәнәйтерсез, яңадан-яңа текстлар белән очрашып, төрле күзәтүләр ясарсыз, гамәли күнекмәләр алырсыз.

Мәгълүм булганча, поэзия ул — шигъри формадагы әдәби әсәр. Аның өчен ритмлылык, тезмә сөйләм хас. Поэтик әсәрләр лирик яисә лиро-эпик характерда булалар. Шигъри текстларда уй-кичереш, рухи халәт, эчке дөнья, эмоциональ мөнәсәбәтләр, тәэсирләр үзәктә. Шигъри сөйләм ритмик буын, үлчәм, строфа, рифма, басым һәм башка төрле сыйфатлар, элементлар белән характерлана. Инде сез татар шигыренең гаруз һәм силлабик төзелешле системалары белән очрашкан идегез. Гарузның нигезендә озын һәм кыска иҗекләр чиратлашуы ята. Ә инде силлабик система шигырь юлларындагы иҗекләрнең билгеле бер санда кулланылуына, ритмик буыннарның ни рәвешле булуына нигезләнгән. Йосыф Баласагунлы, Котб, Харәзми, Өмми Кәмал, Мөхәммәдьяр, Г. Тукай һәм кайбер башка шагыйрьләрнең күпчелек әсәрләре гарузның төрле үлчәмнәре белән язылган. Ә инде Кол Гали поэмасы, Мәүла Колый, Габдинең аерым шигырьләре силлабик үлчәмдә. Фольклорда да шигырьнең силлабик төзелештәгесе өстенлек итә. Соңгы вакытта татар шагыйрьләре, нигездә, силлабик үлчәм белән яздылар һәм язалар.

Шигърият өчен, кагыйдә буларак, газәл, касыйдә, мәдхия, робагый, фәрд, дастан, мөнәҗәт һәм башка жанрлар хас.

Сез инде, укучылар, Сәйф Сараида, «Идегәй»дә, Мәүла Колый һәм Габди иҗатларында шигъри үлчәмнең, строфаның, рифмалашуның төрле рәвешләре белән очраштыгыз. (Алар хакында хәтерегезне яңартырга киңәш итәбез.)

2. Шигърияттә стилистик фигуралар

Шигырьне шигырь итүдә, башка чаралар, элементлар белән беррәттән, поэтик фигуралар да мөһим роль уйный. Әдәбият белемендә аларны синтаксик яисә стилистик фигуралар дип тә йөртәләр. Алар,— гомумән, әдәбиятка хас күренеш. Әмма шигърияттәге бу төр элементларны поэтик фигуралар, кайвакыт поэтик синтаксис дип атау да очрый.

Фигура — *латинча* сурәт, образ, күренеш дигән сүз. Мәгънә, уй-кичереш таләбе белән сөйләмдәге сүзләр, тәгъбирләр, җөмләләр төрлечә урнашырга, төрле мөнәсәбәтләргә керергә мөмкин. Сөйләм телендәге шушы үзенчәлекне әдәби иҗат тагын да тулырак, тагын да мулрак файдалана. Стилистик фигуралар нәкъ шул күренешкә нигезләнгәннәр дә. Аларны куллану мәгънәне ныграк ачуга, сөйләмнең эмоциональлеген, аһәңлелеген, тәэсир көчен арттыруга, стильне нәфисләүгә ярдәм итә.

Шигърияттәге стилистик фигураларның төрләре гаять күптөрле. Шуларның кайберләрен атап китик.

Инверсия — гадәти булмаган сүз тәртибе.

Риторик эндәш, сорау, мөрәҗәгать.

Анафора — шигырь юлларының бер үк сүзләргә башлануы (юлбаш рифмалар).

Рәдиф — рифмадан соң кабатланып килүче сүз яки сүзләр төркеме (аны эпифора дип атау да бар).

Антитеза — капма-каршы мәгънәдәге сүзләрне бергә куллану.

Ялгау — мисрагларны яисә строфаларны бәйләү өчен, бер үк сүзләрнең кабатлануы.

Иллә, ишет кем, соңында **киттеләр,**
Киттеләр, бер парә бәзгә (кәфенлек
күздә тотыла.—*Х. М.*) чолганып...

(Хисам Кятиб)

Градация — көчәйтүгә нигезләнгән аерым сүзләрнең, формаларның кабатланып килүе.

Мәүла Колый, нәсыйхәт,
Сиңа тийәр гакыйбәт (ахырда.—*Х. М.*).
Гүргә табан киткәнне,
Күргел, күрәй, күрсәнә.

(Мәүла Колый)

Парлы сүзләр, синонимик вариантлар:

Һич күңлемдин китмәйдер
Бал-шикәр тик сүзләрең.
(Габдессәлам)

Атаң берлә анаңа
Хезмәт иткел күп-күп.
(Габди)

Поэтик фигураларның **синтаксик янәшәлек, санау, кыскарту** һәм башка бик күп төрләре бар. Алар кайвакыт аерым-аерым түгел, ә берничәсе берьюлы да кулланылырга мөмкин.

Көч белән бетмәс эшең, акча кирәктер, акча!
Акчалы кеше мохтаҗ дәгелдер көчкә!
(Сәйф Сараи)

Сәйф Сараиның бу бәетендә градация, кабатлау, риторик эндәш кебек стилистик фигуралар берьюлы кулланылган.

Сораулар һәм биремнәр

1. Шигъри сөйләмгә нинди үзенчәлекләр хас? Чәчмә сөйләмнән ул кайсы яклары белән аерылып тора?

2. Мисраг (шигырь юлы), кафия, бәхер, бәет атамаларының мәгънәсен аңлатыгыз.

3. Гаруз дип нинди шигырь системасына әйтәләр? Аңа хас сыйфатлар нәрсәдән гыйбарәт?

4. Силлабик шигырь хакында сөйләгез.

5. Газәл, касыйдә жанрларында строфа төзелеше, рифмалашу ничек?

6. Стилистик фигуралар, синтаксис фигуралар, поэтик синтаксис, поэтик фигура — болар арасында нинди уртак яки үзгә яклар бар?

7. Синтаксик фигура нәрсәгә нигезләнеп туа? Аның вазифасы?

8. Поэтик фигураларның нинди төрләре бар? Мәгънәләрен, вазифаларын аңлатыгыз. Мисаллар китерегез.

9. Мөхәммәдьяр, Мәүла Колый, Габди әсәрләренә хас булган аерым шигъри үзенчәлекләрне, поэтик фигураларны күрсәтегез.

XVIII ЙӨЗ ӘДӘБИЯТЫ

ТАРИХИ-МӘДӘНИ КҮЗӘТҮ

XVII гасыр кебек үк, XVIII йөз дә — татар тарихында гаять катлаулы һәм каршылыклы чор. Россия хакимиятенең яңадан-яңа җирләр басып алуы, халыкларны буйсындыруы дәвам итә. Россия чын мәгънәсендә империягә, халыклар төрмәсенә әверелә. Пётр I реформалары, капиталистик мөнәсәбәтләрнең әкренләп керә баруы империядәге милли-социаль изүне тагын да көчәйтеп җибәрә. Коточкыч зур салымнар, көчләп чукындыру, хокуксызлык күп татар кешеләрен Себер, Урал якларына, башка төбәкләргә күчәргә мәҗбүр итә.

Бу чорда татарларны төрле мәҗбүри эшләргә тарту көчәя. Мәсәлән, 1708 елда Петербург төзелешендә 5 меңгә якын татар катнаша. Аларның күпчелеге авыр хезмәттән, ачлыктан, төрле чирләрдән шунда ятып та кала. Аннан соң озатылган татарларның да шактыен шундый язмыш көтә.

Пётр патшаның әмере белән 1718 елда Казанда, кораблар төзү өчен, махсус верфь — Адмиралтейство оеша. Аны агач белән тәэмин итү татарларга йөкләнә. Аларны икенче төрле лашманнар дип йөртәләр. XVIII йөз азагында лашманчылыкта 112,3 мең татарның эшләве мәгълүм. Болай да авыр хәлдә яшәгән татар гаиләләренең төп эш көчләрен берничәшәр айга урман кисәргә җибәрү халыкның бәгыренә төшкән. Бу мәҗбүри хезмәт хакында халык бәетләр чыгарган («Ылашман бәете», «Лашман бәете»). Аларда татар кешеләренең бәхетсез язмышы, фаҗигасе шактый тулы гәүдәләнеш тапкан.

...Сибирия урманында аю, бүре күп була,
Бәхетсезгә, вакытсыз үлүчеләр күп була.

Ылашманга киткәндә, җылый-җылый баралар,
Бәхетсезгә, җеназасыз шунда үлеп калалар...

...Ылашманга киткәндә утырабыз олауга,
Аяз көнне томанлы ясый гаиләбез җылауга.

Урал заводларына, Азовка, Азәрбайҗанга мәҗбүри рәвештә эшкә җибәрелгән татарларның да күпчелеге туган җирләренә әйләнеп кайта алмый. Мәсәлән, 1723 елда Иран походына озатылган 5 мең татардан бары 40 кеше генә исән кала.

XVIII йөздә руслаштыру, чукындыру сәясәте тагын да көчәеп китә. 1713 елда Пётр I указы белән мөселман динендәге татар морзаларының хокуклары бик нык чикләнә. Шуңа күрә татар морзаларының бер өлеше чукынырга, руслашырга мәҗбүр була, икенчеләре гадәти крестьян, һөнәрчегә — «чабаталы морза»га әверелә. Алар арасыннан күп кенә сәүдәгәрләр дә чыга.

1740 елда хөкүмәт әмере белән Казанда «Чукындыру конторасы» төзелә. Аның башында татар халкының кан дошманы, карагруһчыл Лука Канашевич (Аксак Каратун) тора. Ул халыкны, куркытып, мәҗбүри чукындыра, буйсынмаган очракта яшәгән җирләреннән куа, мәдрәсә-мәчетләрне, зиратларны җимерә. Аларның ташларыннан монастырь-чиркәүләр төзетә. Бары 1742—1744 елларда гына да Казан тирәсендәге 536 мәчетнең 418 е юк ителә.

Хокуксызлыкка, милли һәм иҗтимагый-социаль изүгә түзә алмыйча, татар халкы Идел-Җаек төбәгендәге башка халыклар белән берлектә берничә мәртәбә баш күтәрә. Алдар-Күчем (1704—1708), Акай (1735—1741), башкорт (1705—1711, 1735—1740), Тирсә (1744), Батырша (1755) һ. б. күтәрелешләр — әнә шундыйлар. Әмма аларның һәммәсе дә рус хакимияте тарафыннан рәхимсез рәвештә бастырыла: күпләгән кешеләр үтерелә, төрмәләргә утыртыла, Себергә сөрелә.

Пугачёв хәрәкәте — XVIII йөздәге халык күтәрелешләренең иң югары ноктасы. Анда катнашучыларның яртысын диярлек татарлар тәшкил итә (100 меңгә якынын). Башында Канкаев, Мостафин, Гомәров, Алиев кебек мәшһүр татар уллары торган махсус полклар төзелә. Башкорт халкының каһарман улы Салават Юлаев кул астында күп кенә татарлар көрәшә. Шуңа күрә ул башкортлар өчен генә түгел, безнең халык өчен дә үз һәм якын. Аның турында иҗат ителгән әсәрләр татарлар күңеленә дә нык кереп калган.

Пугачёв хәрәкәтенә кушылып, татар халкы үзенә ирек, тиешле хокуклар таләп итә. Бу кузгалыш вакытында татар теле үзенең иҗтимагый вазифасын, халыкара аралашу функциясен тагын да арттыра: татар телендә күп санлы өндәмәләр, рапортлар, документлар языла. Алар өчен фактик байлык,

аңлаешлылык, халык теленә якынлык хас. Шуңа күрә бу төр язмалар галимнәр тарафыннан мөһим чыганак буларак өйрәнеләләр. Пугачёв хәрәкәте татар тормышына, аның рухи дөньясына зур йогынты ясый. Бу көрәштә татар халкы үзенең җитди бер көч икәнлеген, әчке мөмкинлекләрен күрде һәм башкаларга да күрсәтте. Пугачёв һәм аның көрәштәшләре хакында җырлар, бәетләр, риваятьләр, әдәби әсәрләр туа. Аларда еш кына Пугачёв әкият герое, гаделлек өчен көрәшче рәвешендә тасвирлана. Бер шигырьдә Пугачёв сафларында көрәшү дан, хөрмәт эше итеп карала:

...Пугачёв патшаны күрсә идең,
Алларыннан буй бөгеп узса идең;
Аргамак менеп, дан тотып,
Җаек яуларында йөрсә идең.

Салават Юлаев хакындагы җырларда һәм бәетләрдә дә бу каһарманга ихтирам, аның фидакярлегенә соклану сизелеп тора.

...Салават менгән күк атның
Күкрәк түшкәйләре киң икән;
Яу башлыгы булып чыккан кеше
Салават та дигән ир икән...

1773—1775 еллардагы халык хәрәкәте канга батырыла. Әмма ул патша хакимиятен татар-башкортларга карата билгеле бер ташламалар ясарга мәҗбүр итте. Көчләп чукындыру, руслаштыру сәясәте бераз йомшартылды. Мәктәп-мәдрәсәләр, мәчетләр ачудагы тоткарлыклар да өлешчә киметелде. Дин эшләре белән идарә итү өчен, 1789 елда Уфада Дини идарә ачыла. Патша хөкүмәте тарафыннан аның башына Мөхәммәдҗан дигән кеше куела. XVIII йөзнең соңгы чирегендә Мөхәммәдҗанга багышлап бер мәдхия язылуы да билгеле.

XVIII йөздә татарлар арасында төрле социаль катламнарның яшәве мәгълүм. Әлбәттә, халыкның төп өлешен крестьяннар тәшкил итә. Шәһәрләрдә һәм авылларда һөнәрчеләр дә шактый була. Патша хакимиятенә тылмач, чиновник, гаскәри булып хезмәт итүче «йомышлы татарлар» катламы да арта бара.

Безнең милләт — элек-электән сәүдәгә һәвәс халык. Әмма татар мәмләкәтләре бетерелгәч, сәүдә белән шөгыльләнүче татарларның саны бик азая. Булганнарының да мөмкинлеге чикләнә. XVIII—XIX гасырларда бу эш кабат җанланып китә. Моның тарихи сәбәпләре бар.

Патша хакимияте Шәрык илләре һәм халыклары белән багланышлар урнаштырырга, сәүдә итәргә омтыла. Әмма тел һәм дин ягыннан чит булган русларга мөселман дөньясына керү бик кыен була. Хөкүмәт, үзенең сәяси мәнфәгатьләрен күздә тотып, бу эшкә татарларны тарта башлый. XVIII гасыр урталарында корылган Оренбург, Сәгыйть бистәсе, Троицк һәм башка төбәкләр тиз арада Шәрык белән сәүдә итүнең мөһим үзәкләренә әвереләләр. Бу эштә татарлар төп көчне тәшкил итә. Урта Азия, Иран, Кавказ арты илләре белән сәүдә мөнәсәбәтләренә керү Шәрык дөньясы белән татарлар арасындагы элеккеге традицион мәдәни багланышларны өлешчә торгызырга мөмкинлек бирә. Идел-Урал буйларына гарәп, фарсы, төрки телләрдәге күпләгән китаплар кайта башлый.

XVIII гасыр азагында Казан губернасындагы 2876 сәүдәгәрнең 861 ен татарлар тәшкил итә.

XVII йөз белән чагыштырганда XVIII гасыр татар мәдәни һәм рухи тормышында билгеле бер хәрәкәт, җанлану күзгә ташлана. Патша хакимияте татар мәгарифен үстерүгә һич тә ярдәм итми, киресенчә, төрле тоткарлыклар тудырып тора. Әмма шуңа да карамастан халык үз хисабына мәктәп-мәдрәсәләр ача. (Бу эштә аеруча сәүдәгәрләр, хәлле катлам вәкилләре актив катнаша.) Шул сәбәпле татарларның шактый өлеше укый-яза белә. XVIII йөздә Эстәрлебашта, Кышкарда, Казанда һәм кайбер башка төбәкләрдә зур мәдрәсәләрнең эшләве мәгълүм. Бер өлеш татарлар Урта Азиядә, Төркиядә белем алалар. Хөкүмәт, ягъни рус уку йортларында укучылар да була.

Патша хакимияте, татарлар белән мөнәсәбәтләр булдыру, алар белән идарә итү, шулай ук руслаштыру максатын күздә тотып, аерым уку йортларында (Казан гимназиясендә, Оренбургта, Әстерханда, Самарада, Тубылда һ. б.) татар телен өйрәнүне оештыра. Педагогик ихтыяҗларны күздә тотып, аерым сүзлекләр төзелә, дәреслекләр языла. XVIII йөздә, төгәлрәк әйткәндә 1723 елдан, татарча китап басу да гамәлгә керә башлый. XIX гасыр исә — татар китапларының күпләп нәшер ителү дәвере.

XVIII йөз татар мәктәп-мәдрәсәләрендә, «төрки» (татар) теле белән беррәттән, гарәп, фарсы телләре дә ныклап өйрәнелә. Татар укучылары арасында Ибне Сина, Газали, Гаттар, Сәгъди, Руми кебек Шәрык классикларының әсәрләре укылу мәгълүм. Ясәви, Бакырганый, Суфи Аллаһияр да — бу дәвер кешеләренә бик билгеле исемнәр. Гарәп, фарсы, төрек, үзбәк телләрендә

язылган дәреслекләр, фәнни һәм әдәби ядкярләр Идел-Җаек буйларында шактый нык таралыш таба.

XVIII йөз әдәбиятында фольклорга мөрәҗәгать итү көчәя, татар җирлегенә, шул чор кешеләренең тормышына игътибар арта. Идея-тематикада, жанрлар системасында да билгеле бер киңәю, төрлелек күзгә ташлана. Элеккеге ядкярләр, тәрҗемә китаплар белән берлектә, татар укучыларына үз әдипләренең дә оригиналь әсәрләре ирешә. Татар рухи дөньясына янә Шәрык тәэсире көчәя башлый.

XVIII йөз — элекке дәверләр белән чагыштырганда, безгә якынрак чор. Әмма шуңа да карамастан бу гасырның да күп кенә ядкярләре юкка чыккан, билгелеләре дә әле тиешенчә барланып, өйрәнелеп җитмәгән.

Сораулар һәм биремнәр

1. XVIII йөз татар тарихында нинди вакыйгалар була?
2. Лашманнар дип кемнәргә әйткәннәр? Алар турында нинди бәетләрне беләсез?
3. XVIII гасырда нинди күтәрелешләр була?
4. Пугачёв хәрәкәте һәм татарлар.
5. Шәрык һәм татар мәдәнияте. Сәүдә элемтәләренең бәйләнеше.
6. Бу чор әдәбиятына нинди гомуми сыйфатлар хас? Әйтегез.
7. Туфан Миңнуллинның «Канкай углы Бәхтияр» драмасы хакында нәрсәләр беләсез?

XVIII ГАСЫР ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА ЖАНРЛАР

Казан, Әстерхан ханлыклары бетерелеп, әби-бабаларыбыз дәүләтчелектән мәхрүм ителгәннән соң, татар әдәбиятында элеккеге казанышларны югалту, торгынлык башлана. Бу бер гасырдан артык вакытка сузыла. Әмма Мәүла Колый, Габди иҗатларыннан соң безнең әдәбиятта бераз хәрәкәт, җанлану күзәтелә. XVIII йөздә исә бу процесс тагын да көчәеп, киңәеп китә. Без моны әдәби жанрлар мисалында ачык күрәбез.

Сәяхәтнамәләр. Дөнья әдәбиятында элек тә, хәзер дә киң таралган бу жанр XVIII йөз татар әдәбияты өчен дә чит түгел. Шундыйларның берсе — «Исмәгыйль сәяхәтнамәсе». Бу язма кат-кат басылган, галимнәр тарафыннан ныклап өйрәнелгән.

Сәяхәтнамәнең авторы — Исмәгыйль Бикмөхәммәд углы —чыгышы белән Казан артыннан булса кирәк. XVIII гасыр урталарында ул Оренбург янындагы Сәгыйть бистәсендә, ягъни Каргалыда яши, сәүдә эшләре белән шөгыльләнә. 1751 елда ул

һәм шушы бистәнең биш кешесе сәүдә эшләре белән Бохарага юнәләләр. Аларга патша әмере белән Һиндстанга бару бурычы йөкләнә. Сәяхәтчеләрнең юлы хәзерге Әфганстан, Пакистан аша үтә. Аннан бераз диңгездә корабта баралар. Юлда диңгез караклары һөҗүменнән өч иптәшләре һәлак була. Мең газаплар күреп, Исмәгыйль Ягъкуб исемле иптәше белән Һиндстан җиренә килеп җитә. Әмма сугыш аркасында алар куелган максатка ирешә алмыйлар. Коры җир, диңгез аркылы Гарәбстанга — изге җирләргә юнәләләр. Хаҗ кылгач, Исмәгыйль үзе генә Истанбулга килә һәм анда егерме биш еллап яши. 1783 елда туган якларына әйләнеп кайта.

Сәяхәтнамәнең төп эчтәлеген авторның Истанбулга кадәрге вакыт эчендә күргән, кичергән, ишеткәннәре тәшкил итә. Язмалардан Исмәгыйльнең шактый күзәтүчән, гамәли табигатьле кеше булуы күренә. Корабта йөзүләр, пиратлар белән сугышлар шактый киеренке, мавыктыргыч итеп тасвирлана.

Сәяхәтнамәдә аеруча Һиндстанның табигатенә, гореф-гадәтләренә кагылышлы мәгълүматлар кызыклы. Автор бирәдәге кешеләрнең «сыгыр»га (сыерга) изге хайван дип карауларын, аңа табынуларын, үлгән кешеләрне яндыру кебек гореф-гадәтләр турында яза.

Исмәгыйль Бикмөхәммәд углының Гарәбстандагы Мәккә, Мәдинә һәм башка изге җирләр хакындагы мәгълүматлары да мавыктыргыч. Ул шулар арасына риваять-легендалар да кертеп җибәрә.

Исмәгыйль бу сәяхәтнамәсен хат рәвешендә яза. Аның телендә госманлы сүзләре һәм формалары шактый. Бу — авторның озак еллар буе Төркиядә яшәве белән аңлатыла. Авторның теле шактый шома.

Исмәгыйль язмасы тарихи чыганак буларак та игътибарга лаек. Шуңа күрә аңардан тарихчылар да бик теләп файдаланалар. Шунысын да әйтик: безнең әби-бабаларыбыз Хәзәр, Болгар, Алтын Урда, Казан мәмләкәтләре чорында Һиндстан белән багланышларда торганнар. XVII йөздә Әстерхан татары Мөхәммәд Йосыф Касыймов җитәкчелегендәге Мәскәү илчелегенең дә Һиндстанга барып кайтуы билгеле. Рус хакимиятенең Һиндстан «шаһиншаһы»на адресланган рәсми ярлыгы русча, татарча, латинча язылган була.

XVIII йөзгә мөнәсәбәтле икенче сәяхәтнамә Мөхәммәд Әмин тарафыннан язылган. Бу кеше 1783 елда, «Арча округы Алат юлындагы Яңа Кишет авылы»ннан чыгып, Казанга килә,

аннан Идел буйлап Әстерханга юл тота. Төньяк Кавказда өч ел имам булып тора, балалар укыта. Аннан Кара диңгез аркылы хаҗга юнәлә. Истанбул, Каһирә, Искәндәрия, Иерусалим (Кодес Шәриф), Мәккә, Мәдинә калаларында була. Бераздан туган якларына әйләнеп кайта.

Гомәр углы Мөхәммәд Әмин сәяхәтнамәсе дә кызыклы күзәтүләргә, факт-мәгълүматларга бай. Анда Исмәгыйль язмасына охшаш урыннар да бар. Күрәсең, Мөхәммәд Әмин Исмәгыйль сәяхәтнамәсе белән таныш булгандыр.

XIX йөздә, аеруча XX гасыр башында татар әдәбиятында күпләгән сәяхәтнамәләр туа (Г. Чокрый, Ш. Мәрҗани, З. Бигиев, Ф. Кәрими һ. б. ның язмалары).

«Батырша хаты».

Бу ядкяр (аның икенче исеме — «Гарызнамә»), бер яктан, хат жанрында булса, икенче яктан, ул автобиографик характердагы документаль повестьны хәтерләтә.

«Батырша» — Габдулла Баһадиршаһ Гали углы Галиевнең кушаматы. Ул 1710—1713 еллар тирәсендә хәзерге Башкортстанның Балтач районы Карыш авылында татар (мишәр) мулласы гаиләсендә туган. Әүвәл үз авылында, аннан Әлмәт тирәсендәге Тайсуган мәдрәсәсендә белем ала. Бераз вакыт Казан артындагы Ташкичүдә укый. Аның биредәге остазы мәшһүр Габдессәлам була. Алар Оренбург ягында да очрашкалап торалар (Габдессәлам 1746 елда Сәгыйть бистәсенә күчеп киткән була).

Батырша — үзенең зирәклеге, укымышлылыгы, оештыру сәләтенә ия булуы белән аерылып торган күренекле шәхес. Ул Урал якларында («Гайнә», «Исет» һ. б. төбәкләрдә) имамлык кыла, мәдрәсәләрдә укыта. 1754 елда ул ахун булып эшли башлый.

Батырша, татар һәм башкортларның хокуксыз, авыр хәлдә яшәвен күреп, аларны баш күтәрергә чакыра, Уралны иңләп-буйлап халык арасында агарту һәм оештыру эшләре алып бара. 1755 елның маенда башланган күтәрелеш Уралның күп төбәкләрен биләп ала, ләкин озак дәвам итми. Ирек, хокук таләп иткән татар һәм башкорт халкы рәхимсез бастырыла. Батырша, бераз качып йөргәннән соң, 1756 елның 8 августында кулга алына. Ул Уфадан Мәскәүгә, аннан Петербургка озатыла, Шлиссельбург зинданына ябыла. Биредә аның биш елга якын ятуы мәгълүм. 1762 елның 24 июлендә богаулы Батырша төрмә сакчылары белән бәрелештә үтерелә. «Патша төрмәсе тарихы»

дигән мәшһүр хезмәт авторы, профессор М. Н. Гернет Батыршаның соңгы бәрелешен романнарга лаек адым дип бәяли.

1992 елда Җәмит Рәхимовның «Батырша» исемле романы дөнья күрде. Анда бу кыю, фидакяр көрәшченең эш-гамәлләре, олуг шәхесе шактый тулы һәм җанлы гәүдәләнеш тапкан. Шагыйрь Эдуард Мостафин да 1991 елда «Батырша» исемле поэма иҗат итте.

Батырша язмасы — халыкның 1755 елгы күтәрелешкә килү сәбәпләрен һәм бу хәрәкәтнең асылын аңлаткан җанлы елъязма ул. Автор патша түрәләренең комсызлыгын, явызлыгын, җирле халыкның хокуксызлыгын, көннән-көн хәерчеләнә, җиренең, мал-мөлкәтенең талана баруын җанлы, үтемле тел белән бәян итә. Урыны белән гыйбрәтле мисаллар, кечкенә сюжетлар да кертеп җибәрә. Язма трибунадан сөйләнгән гаепләү нотыгын хәтерләтә. Аңа публицистик аһәң, ораторлык яңгырашы хас.

Батырша фикеренчә, бу хәлнең тууына халык түгел, ә хакимият гаепле. Шуңа күрә ул үзен һәм башка баш күтәрүчеләрне ярлыкауны сорый. Дөрес, автор үзе мөрәҗәгать иткән патшаны гаепләмәскә, аны гадел, мәрхәмәтле итеп күрсәтергә тырыша. Имеш, ул бу хәлләрне белми, чын хакыйкатьне аннан яшерәләр. Әмма кайвакыт Батырша, киная белән булса да, патшаның гаделлеген шик астына ала. «Падишаһымыз гаделдер,— ди ул бер урында,— вәләкин үз куеныннан китмәгән, безгә килеп җитмәгән гаделлектән ни файда?!..»

Исмәгыйль сәяхәтнамәсе кебек, Батырша язмасы да — әдәби ядкяр генә түгел, ә тарихи чыганак та. Аның аркылы без халкыбыз тарихын, аның ирек өчен көрәш сәхифәләрен һәм Батырша кебек олуг шәхесләрен күзаллыйбыз.

«Мәҗмугыл хикаят». Хикәят — татар әдәбиятында киң таралган жанр төре. Аның өчен эпиклык, вакыйгалылык, хикәяләү хас. Күпчелек хикәятләр чәчмә формада язылган. Шигырь белән аралаштырып яисә тезмә формада язылган хикәятләр дә бар. Мондыйларны инде без Сәйф Сараиның «Гөлестан бит-төрки» әсәрендә күргән идек.

Күп кенә хикәятләр үзләренең эчтәлекләре, жанр табигатьләре белән хәзерге хикәя, новелла, мәзәкләргә якын торалар. Повесть, роман, мәсәл, әкият, кыйсса, дастан, легенда кебек жанр төрләренә туры килгән яисә якын торган әсәрләрне дә еш кына хикәят дип атаганнар.

Хикәятнең үзәгендә — кеше, аның эш-гамәле, үз-үзен тотышы. Ул еш кына тормышчан шартларда һәм бәйләнештә

күрсәтелә. Кайбер хикәятләрдә хайваннар, кош-кортлар, фантастик көчләр дә хәрәкәт итәләр, экияти ситуацияләр дә очрый.

Татар әдәбиятында Мәхмүд Болгари, Сәйф Сараи, Мөхәммәдьяр, К. Насыйри һәм башка әдипләрнең хикәят язулары мәгълүм. Соңгы гасырда «хикәят» термины урынына «хикәя», «повесть» атамаларын куллану гадәткә кергән.

Хикәятләр еш кына аерым-аерым түгел, ә тематикасы һәм эчтәлегенә карап яисә авторга мөнәсәбәттә, төрле җыентыкларга тупланып йөртелгәннәр. «Мәҗмугыл хикаят» — әнә шундый тупламнарның берсе. 305 битлек бу җыентыкта 33 хикәят бар. XVIII йөзгә мөнәсәбәтле бу ядкяр татар укучыларына яхшы таныш.

«Мәҗмугыл хикаят» безнең көннәргә Мөхәммәд Рәхим төзегән кулъязмада килеп җиткән. Бу кеше чыгышы белән Казан артындагы Ташкичү авылыннан. Ул, Пугачёв хәрәкәте бастырылганнан соң, Тубыл ягына, Себер татарлары янына китәргә мәҗбүр була. Кулъязма да шунда төзелә.

«Мәҗмугыл хикаят» — фарсычадан тәрҗемә ителгән җыентык. Аның бер өлешен Нурмөхәммәд бине Галим дигән кеше тәрҗемә иткән, ә калган өлешен тәрҗемә итүче билгесез. Тәрҗемә шактый ирекле. Анда өстәмәләр, кыскартулар, татар тормышы белән яраклаштырулар бар.

Җыентыктагы хикәятләр шактый кызыклы, мавыктыргыч, маҗаралы. Аларда тормышчан һәм хыялый күренешләр, вакыйгалар еш кына үрелеп, кушылып бара. Үзәктә — актив каһарман. Ул эзләнә, хәрәкәт итә, төрле кыенлыкларга тап була, әмма аларны җиңеп чыга, максатына ирешә. Әбелфәварис дигән герой — әнә шундыйларның берсе. Ул «Мең дә бер кичә»дәге атаклы Синбад-Дәрьяви кебек күп сәяхәтләр кыла, диңгез һәлакәтләренә очрый, кыен хәлләрдә үзенең ихласлыгы, зирәклеге белән исән кала. Аның өчен оптимизм, күңел күтәренкелеге, тормышны ярату хас.

Хикәятләрдә хатын-кыз, ир-ат тугрылыгы мәсьәләләренә зур урын бирелә, мәхәббәттә тигезлек, үзара хөрмәт яклана.

Җыентык үзенең төзелеше, тематикасы, образлары, поэтикасы белән «Мең дә бер кичә»гә охшаш.

XVIII гасыр башларында Парижда француз телендә, фарсы чыганакларыннан файдаланып, «Мең дә бер көн» исемле берничә томлык китап дөнья күрә. Ул тиз арада инглиз, немец, итальян, рус һәм башка телләргә тәрҗемә ителә, күп кенә сәнгать әсәрләрен иҗат итүдә материал рәвешендә файдаланыла.

Мәсәлән, итальян драматургы Карло Гоццины (1720—1806) «Турандот» драмасы — шундыйлардан. Дж. Пуччини да шушы әсәргә мөнәсәбәттә үзенең атаклы операсын иҗат итә.

«Мең дә бер көн»дәге күп кенә сюжетлар «Мәҗмугыл хикаят»тә дә бар. Аларның шактые, Шиһабеддин Рәхмәтуллин тарафыннан әдәби эшкәртелеп, XX гасыр башларында укучыларга аерым китап булып тәкъдим ителде («Кылаф белән Диләрә», «Кылаф белән Турандук», «Малик», «Сәйфелмөлек» һ. б.).

«Мәҗмугыл хикаят» — күп гасырлык татар-фарсы әдәби багланышларын күрсәтүче мөһим бер сәхифә дә ул.

«Хикәяте сычкан». Бу ядкяр — «хикәят» атамасының төрлечә кулланылуына бер дәлил. Әмма ул үзенең эчтәлеге, рухы белән мәсәл жанрына туры килә.

«Хикәяте сычкан»— 39 бәетлек шигъри әсәр. Ул фарсы шагыйре Гобәйдулла Закани (XIV гасыр) поэмасына нигезләнеп иҗат ителгән. Аның авторы да, язылган вакыты да билгеле түгел. Әсәрнең XVIII һәм XIX гасырларда татар укучылары арасында киң таралуы мәгълүм. Ул М. Иванов һәм С. Кукляшев хрестоматияләрендә XIX гасыр урталарында ук басылып та чыккан.

Әсәрнең кыскача эчтәлеге болай: бер сычкан (тычкан) йөрергә чыга. Савыттагы эчемлекне татып карый. Баксаң, ул исерткеч була. Куркып кына йөргән сычкан батыраеп китә, мактана. «Баһадурлыкда бән Рөстәмдин артык, миннән мәчеләр гаскәре өркеп тора»,— ди ул. Шунда бу сычканны «карыны ач» бер мәче эләктереп ала. Теге бичара сычкан айнып китеп ялвара башлый, үзен азат итүен үтенә. Әмма мәче: «Сәнең тик фетнәне азад кыйлмак — ул мәзлумларга гаделсезлек кылу булыр иде»,— ди һәм сычканны ашый.

Вакыйгалылыгы, кинаяле һәм динамик табигате белән бу әсәр тулысынча мәсәл жанрына туры килә.

Автор тычканның җиңел акыллылыгыннан, тотнаксызлыгыннан көлә; «герой» авыр хәлгә төшкәч, аңа карата кызгану, теләктәшлек хисләрен дә сиздереп куя. Мәченең гамәле, хәйләкәрлеге сатирик планда күрсәтелә. Игътибар итегез: ул тычкан баласын явызлыкны бетерәм, башкаларга яхшылык эшлим дип юк итә.

Гомумән, «Хикәяте сычкан» хикәятендә дә тормыш, кешеләр өчен хас хәлләр гәүдәләнеш тапкан.

Илаһи бәетләр. Элеккеге әдәбиятта, аеруча XVIII—XIX гасырлар шигъриятендә «илаһи бәет» исеме астында язылган әсәрләр күпләп очрый. Алар өчен лиризм (кайчак

лиро-эпиклылык) хас. Бу төр шигырьләрнең күпчелеге икеюллык строфалар белән язылган, һәм «бәет» атамасы шуңа мөнәсәбәттә алынган да. Дүртьюллык строфалар белән иҗат ителгән илаһи бәетләр дә бар.

Илаһи бәетләрнең бер өлешендә илаһи, дини уй-кичерешләр, Алланы зурлау, аңа сыгыну үзәктә тора. Бу ягы белән алар еш кына мөнәҗәтләр белән керешеп китәләр. Әмма күпчелек илаһи бәетләр дөньяви характерда. Аларның төп эчтәлеге уй-тойгыларны, рухи халәтне тасвирлаудан гыйбарәт. Илаһи бәетләрнең идея-тематикасы төрле: иҗтимагый-социаль, дини-фәлсәфи, сөю-мәхәббәт; туган илне, туган җирне сагыну; яшәү һәм үлем; тормыштагы фаҗигале хәлләр һ. б. Мәсәлән, «Казан да Тубол арасы» әсәрендә[1] Себергә сөрелгән татар кешесенең авыр шартларда яшәве, газаплы рухи халәте, Казанын, гаиләсен сагынуы тасвирлана. XVIII йөздә төзелгән Габделкәрим дәфтәрендәге шигырьләрдә сөю-мәхәббәт хисләре халык җырларына, аеруча шаян җырларга хас сурәтләр, аһәңнәр ярдәмендә гәүдәләндерелә.

Күпчелек илаһи бәетләр, шәкертләр тарафыннан язылып, халыклашып киткәннәр. Сирәк кенә булса да, авторлары билгеле булган илаһи бәетләр дә очрый. Мәсәлән, XVIII йөз шагыйре Габдессәламнең бу жанрда язып калдырган шигырьләре бар.

Мәдхия-мәрсияләр.

Татар әдәбиятында элек-электән популяр булган бу жанрлар XVIII йөздә янә активлашып китә. Алар өчен мактау, үзең күрергә теләгәнне бар дип сыйфатлау хас. Мәрсия — шул ук мәдхия ул. Әмма анда вафат булган кешеләр мактала.

XVIII йөздәге мәдхия-мәрсияләрнең үзәгендә — шул чорның конкрет кешеләре. Хөсәен бине Локманга нисбәт ителүче бер мәдхиядә соңыннан мөфти булган Мөхәммәдҗан хәзрәтләре идеал итеп куела. Шунысы үзенчәлекле: шигырьдәге һәр бәеттән соң «Мөхәммәдҗан ирүр котбе заман» юлы кабатланып килә. Рәхимкол Әбүбәкер углы язган икенче бер мәдхиядә патша старшинасы — Габделмәннан (Мәндан) Мөслим углы мактала. Әсәр каһарманның тәрҗемәи хәлен, эшчәнлеген тасвирлау рәвешендә төзелгән. Мәдхия аркылы без Мәнданның унике ел гомерен авырлыкта уздыруын, аннан баш күтәрүчеләр (Пугачёвчылар) кулына төшүен, азат ителүен күрәбез. Каһарман, патша гаскәрләре ягында торып, «фетнәче»ләрне бастыруда

[1] Бу шигырьне кайберәүләр Хөсәен бине Локманга нисбәт итәләр.

зур батырлыклар күрсәтә, бүләкләргә лаек була. Автор, үз героен юмартлык үрнәге, зирәк, акыллы, оста, күркәм телле дип атап, аның батырлыкларын Иран халыкларының дастани каһарманы Рөстәм гамәлләре белән тиңли. Бу мәдхия Пугачёв хәрәкәтенә каршы кеше тарафыннан язылган. Әсәрдә Дон казагы залим, «ләгыйнь», «җан кыючы» рәвешендә тасвирлана.

XVIII йөздә иҗат ителгән мәрсияләрнең берсе — патша генералы, Оренбург хөкемдары Котлуг Мөхәммәд турында (бу шигырь Бәшир бине Габдулла дәфтәренә урнаштырылган). Автор бу затның гадел, гыйззәтле булуын күрсәтә. «Әмма,— ди ул,— без аның кадерен белмәдек, шуңа күрә Алла аны кире алды». Чынлыкта, Котлуг Мөхәммәд Тәфкилев, рус патшаларына сатылып, татар-башкортларга гаять зур зыян китергән, хәйләкәр, икейөзле кеше булган. Батырша аны үзенең хатында «ялганчы карт дуңгыз» дип атый.

XVIII гасырда иҗат ителгән мәрсияләрнең иң күренеклесе Утыз Имәни тарафыннан язылган. Алар шагыйрьнең хатыны Хәмидәгә багышланган. Аның үлеме — зур югалту, олы кайгы булуы һәм хатынына, ягъни балаларының анасына, тирән хөрмәте поэтик яктан гаять көчле итеп тасвирланган.

* * *

XVIII йөздә дастан, газәл, васыятьнамә, мөнәҗәт, хикмәт, фәрд, робагый, риваять һәм кайбер башка жанрлардагы әсәрләрнең дә язылуы мәгълүм. Мәсәлән, бу гасырда Таһир — Зөһрә сюжетына дастан языла.

XVIII йөз азакларында «Каһарман китабы» исемле күләмле эпик әсәрнең (романның) иҗат ителүе хакында да аерым мәгълүматлар бар. Бу чорда тарихи шәхесләр, изгеләр, пәйгамбәрләр тормышына, географик атамаларга мөнәсәбәтле риваятьләр дә киң тарала. Аларның кайберләре «Тәварихе Болгария» китапларына, күләмлерәк әдәби әсәрләргә дә кертелгән. Әхмәдбик тарафыннан иҗат ителгән фәрдләр — мөстәкыйль икеюллыклар да кызыклы гына:

Хурмы сән? Мәләкме сән? Йә фәрештә?—
Гаклымны алдың (мәнем) бер күрештә.

Яисә:

Аһ идәрсәм, яндырырым галәми,
Сабыр идәрсәм, кемсә белмәс хәлеми.

Сораулар һәм биремнәр

1. Әдәбият белеме сүзлекләреннән сәяхәтнамә, риваять, тартмалы композиция, кысалы кыйсса, фәрд хакындагы мәкаләләрне укыгыз, фикер алышыгыз.

2. Исмәгыйль сәяхәтнамәсенең төп эчтәлеген нәрсә тәшкил итә?

3. XVIII—XIX йөзләрдә язылган тагын нинди сәяхәтнамәләрне беләсез?

4. Батырша кем ул? Җ. Рәхимовның «Батырша» романын һәм Э. Мостафинның шул исемдәге поэмасын кемнәрнең укыганы бар? Аларда бу тарихи шәхес ничек бирелә? (Ирекле бирем.)

5. Батырша язмасы нинди жанрда? Аңа нинди сыйфатлар хас?

6. Хикәят дип нәрсәгә әйтәбез? «Мәҗмугыл хикаят»нең төзелеше, идея-эстетик үзенчәлекләре.

7. «Мәҗмугыл хикаят»нең аерым өлешләрен укыгыз. (Ирекле бирем.)

8. «Хикәяте сычкан»ны без ни өчен мәсәл дип атыйбыз?

9. «Илаһи бәет» жанрының үзенчәлекләре.

10. XVIII йөздә иҗат ителгән мәдхия-мәрсияләргә нинди сыйфатлар хас?

11. XVIII гасырда тагын нинди жанрлар кулланылган?

XVIII ЙӨЗДӘ ИҖАТ ИТКӘН ӘДИПЛӘР

Мәүла Колыйлар яшәгән гасырдан безгә бик аз санлы әдипләр мәгълүм: Кадыйр Галибәк, Габди... Аларның да соңгысы ике гасыр аралыгына туры килә. Габдинең иҗатын хәтта XVIII йөзгә кертеп тә карарга мөмкин.

XVIII гасырда иҗат иткән әдипләрнең саны шактый. Бу үзе үк әлеге чор әдәбиятындагы җанлылыкны, билгеле бер үсеш-хәрәкәтне раслап тора. Дөрес, XVIII йөз әдипләренең әле тулы исемлеге барланмаган, билгеле авторларның да әдәби мираслары тәмам ачыкланып, өйрәнелеп җитмәгән. Күбесенең хәтта туган, үлгән еллары да билгеле түгел. Бу чор әдипләренең кайберләре (Утыз Имәни, Ялчыгол, Әхмәдбик, Мәнди Котыш һ. б.) XIX йөздә дә яшәүләрен дәвам итәләр. Шуңа күрә алар иҗат иткән әсәрләрне дә бер чорга гына кертеп карау шартлырак. Дөресрәге, бу әдипләрнең иҗат мираслары ике гасырны тоташтыручы күпер вазифасын үтиләр.

Габдессәлам. Габдессәлам — үз чорының күренекле рухание, педагогы, шагыйре. Аның тулы исеме — Габдессәлам бине Урай (Уразмөхәммәд) бине Колмөхәммәд бине Колчура. Ул Казан артындагы Олы Мәңгәр авылында 1700 елда туган. 1746 елга кадәр күршедәге «Ташкичүнең таш мәчетендә имам һәм хатыйп булып, мәдрәсә тотып, дәрес әйткән» (Мәрҗани). Аның шәкертләре арасында атаклы Батыршаның булуы да күп нәрсә хакында сөйли.

1746 елда Габдессәлам Сәгыйть бистәсенә (Оренбург Каргалысына) күчеп китә, анда ахун (өлкән рухани) булып, мәдрәсә тота. Үлеме — 1766 еллардан соң.

Габдессәлам — күп кенә лирик парчалар авторы. Алар өчен самимилек, уй-кичерешләрнең табигыйлеге хас. Автор үз шигырьләрен халык җырлары үрнәгендә, аларга ияреп яза, фольклор казанышларыннан мул файдалана. Бу күренеш бигрәк тә мәхәббәт турындагы парчаларында күзәтелә:

...Байның кызы бай кебек, йөзе тулган ай кебек.
Күз өстендә кашлары корып куйган йай (җәя. — *Х. М.*)
кебек...

...Кашың берлә күзеңә, йөз мең алтын үзеңә,
Җаным фида кыйлырмын, бер кәлимә сүзеңә...

...Күңлем төште үзеңә, коңгыр(т)-кара күзеңә,
Йөрәк кенәем янадыр, кермәйсең лә сүземә.

Шагыйрь аерым строфаларында халык җырларына хас интонацион яңгырашны, шаяру, юмор алымнарын да файдалана.

Су акар гөлдүр-гөлдүр,
Сәүгәнем кызыл гөлдүр.
Сәндин үзгәне дуст тотсам,
Пычак ал, бәне үлдүр.

...Чыгып китдең йортыңдин,
Карап калдым артыңдин.
Бер көн хәстә, бер көн сау,
Үлә яздым дәртеңдин...

Шагыйрь әсәрләре арасында аеруча «Меллагол бәете» игътибарга лаек. Ул, фольклордагы бәет кануннарын саклап, үлгән кеше авызыннан ата-анасына, туган-тумачаларына мөрәҗәгать рәвешендә язылган. Меллагол дигән кеше 1757 елда, Россия-Пруссия сугышында катнашып, Польша җирендә һәлак була.

...Әткәй-әнкәй, карендәшләр, бәндин бәхил улыңыз!
Гариблекдә җан бирүбән изге дога кыйлыңыз!..

Габдессәлам үз шигырьләренең күбесен «илаһи бәет» дип атаган. Эчтәлеге, поэтикасы белән шагыйрьнең әсәрләре фольклорга якын. Мөгаен, шуңа күрәдер аларның күпчелеге халыклашып киткән, укылган, җырланган. Чыгышы белән татар булган Г. Державин да заманында Габдессәлам шигырь-

ләре белән кызыксынган: ул, аларның тугыз бәетен рус хәрефләре белән язып, аннан русчага тәрҗемә иткән.

Габдессәламнең нәсел-нәсәбе мәшһүр кешеләргә бай. Шуларның берсе — XIX йөзнең күренекле шагыйре Әбелмәних Каргалый.

Габделмәннан Мөслим углы (Мәндан). Ул XVIII гасырның 30 нчы елларында Урал аръягында яшәүче татар (мишәр) гаиләсендә дөньяга килә. Үз чоры өчен шактый төпле белем ала. Тарихи мәгълүматлар аның зирәк табигатьле, акыллы, хәйләкәр булуын искәртәләр. Габделмәннанның оештыру сәләтенә ия булган көчле шәхес икәнлеге дә мәгълүм. Аның хакында Рәхимкол Әбүбәкер углының мәдхия язуы да юкка гына түгел. Габделмәннанның нәсел-нәсәбен, эшчәнлеген махсус яктырткан бер кулъязма да сакланган. Ул шагыйрьнең углы Габделҗәлил тарафыннан төзелгән.

Алдарак әйтелгәнчә, Габделмәннан Мөслим углы Пугачёв яклылар кулында әсирлектә дә була. Аннан аларны бастыруда батырлыклар күрсәтә. «Бөек» патша аның хезмәтләрен югары бәяли. Габделмәннанның Уралдагы Исәт провинциясендә старшина булып эшләве дә мәгълүм.

Татар-башкорт дөньясында Пугачёв хәрәкәтен яклаучылар гына түгел, аңа каршылар да була. Соңгыларын, нигездә, йомышлы татарлар, морзалар, башкорт-татар казакларының җитәкчеләре тәшкил итә. Мондый капма-каршылык әдәбиятта да гәүдәләнеш таба. Габделмәннанны мактаган мәдхия дә — шуның бер мисалы.

Габделмәннан Мөслим углы үзе дә әдәби иҗат белән шөгыльләнә. Аның безгә мәгълүм шигырьләре, күрәсең, 1773—1775 елгы Пугачёв кузгалышыннан шактый соң язылган. Аларда авторның авыр рухи халәте, үлем турында уйланулары, элеккеге гөнаһлы эш-гамәлләренә үкенү хисләре чагылыш тапкан. Шагыйрь, гомумән, кара йөз, бозык эшләр, гөнаһка чуму, күңел карасы, тәүбә кылуларны еш телгә ала.

Яшь вакытта, көчле чагында тормышның үзәгендә кайнаган җитәкче кешенең картайгач, зәгыйфьләнгәч язган шигъри юллары түбәндәге фаразга да этәрә: мөгаен, халык хәрәкәтенә каршы кылган эш-гамәлләре өчен таныш-белешләре Габделмәннанга, кырын карап, тәнкыйть сүзләре әйткәннәрдер?! Бәлкем, ул үзе дә, элеккеге эш-гамәлләрен күңеленнән кичереп, хаталы, гөнаһлы эшләрен аңлагандыр, тәүбә кылып, алардан котылырга, әхлакый яктан күңелен

пакьләргә омтылгандыр?! Шигъри юллар нәкъ әнә шундый фикергә ишарә ясый:

Габделмәннан Мөслим углының моңы,
Эшендә һич улмаган уңы-сулы.
Гөнаһларын хак үзе кичермәсә,
Эшенең ахырында нә ула соңы?

Әхмәдбик. Шагыйрьнең яшәү елларын XVIII гасырның икенче яртысына һәм XIX йөз башына нисбәт итәләр. Бер шигырендә ул үзен «Болгари» дип тә атый. Аның шигырьләре халыкта шактый киң таралган, басылып та чыккан. Татар-башкорт кешеләре арасында дини (ритуаль) җырга әйләнгән «Әлвидаг» текстын да Әхмәдбиккә нисбәт итәләр.

Мөселман дөньясында Вәйс әл-Карани исемле мәшһүр изге зат билгеле. Әйтүләренә караганда, ул Йәмәндә көтүчелек кыла, Мөхәммәд пәйгамбәрнең дә дусты була. Әхмәдбикнең «Вәйс әл-Карани» исемле мәдхиясе әнә шул зат хакында. Шигырьнең әдәби яктан камил, интонацион яктан аһәңле булуына аның төзелеше дә нык тәэсир иткән.

...Йәмән илләрендә Вәйс әл-Карани,
Гарәб чүлләрендә Вәйс әс-солтани.

Әхмәдбикнең берничә шигыре дини-суфичыл характерда. Аларда илаһи мәхәббәт хакында да юллар бар.

Таҗеддин Ялчыгол (1768—1838). Ул — табиб, әдип, педагог һәм галим. Хәзерге вакытка аның унбишләп китабы билгеле. Алар мөселман хокукы (фикъһе), тарих, медицина, әдәбият, әхлак, педагогика һәм башка тармакларга карый. Кайбер хезмәтләре гарәпчә яисә катнаш телдә (татарча һәм гарәпчә) язылган. Үзенең күпкырлы эшчәнлеге белән Таҗеддин Ялчыгол татар тормышында һәм язма мәдәниятендә билгеле бер эз калдырган.

Таҗеддин Ялчыголның тәрҗемәи хәле шактый катлаулы. Табиб һәм укытучы буларак, ул күченеп йөргән, төрле урыннарда эшләгән.

Әдипнең үзе язуынча, аны кече яшьтә вакытта ук әтисе хаҗга алып китә. Әмма анда барып җитми, ул Төркиянең Диярбәкер шәһәрендә кала. Әтисе, хаҗдан кайтканда, аны үзе белән туган якларына алып кайта. 1785 елда Мамадыш ягындагы Кече Сон авылында аның әтисе кинәт үлеп китә. Алга

таба Таҗеддин Ялчыголның күпкырлы эшчәнлеге башлана: ул Кече Сон, Тымытык, Кызыл Чапчак, Җирекле (Түбән Кама төбәге), Мәлем (Югары Налим хәзерге Зәй районында) авылларында табиблык кыла, балалар укыта, әдәби-гыйльми эшләр белән шөгыльләнә. Мәлем авылында яшәгәндә, Таҗеддин хәзрәтне авыруларны карау өчен, хәзерге Зәй белән Түбән Кама арасында урнашкан Имәнлебаш авылына чакыралар. Хөрмәтле табиб анда килә. Әмма кинәт авырый һәм шунда вафат та була. Аны зурлап Имәнлебашта күмәләр. Имәнле халкы һәм ул тирәдәге татар кешеләре өчен Таҗеддин хәзрәт кабере изге урынга әверелә. Аның кабер ташы сакланган, үзен исә зурлап, олылап, «әүлия», «изге хәзрәт» дип искә алу гадәте хәзер дә яши.

Таҗеддин Ялчыгол әдәбият тарихында үзенең «Рисаләи Газизә» исемле китабы белән билгеле. Ул бу әсәрен 1806 елда төгәлли. «Рисаләи Газизә» тәүге мәртәбә 1847 елда Петербургта, аннан 1850 елда Казанда нәшер ителә. Болардан тыш та күп мәртәбәләр басыла (соңгысы 2001 елда), кулъязма рәвешендә дә киң тарала. «Рисаләи Газизә» — XIX йөз татар уку йортларында иң күп укылган китапларның берсе.

XVII—XVIII йөзләрдә Урта Азиядә Суфи Аллаһияр (1616—1713) дигән мәшһүр суфи, төрки шагыйрь яши. Ул — чыгышы белән Әстерхан татары. Идел буе, Казан белән тыгыз бәйләнештә тора. Бу төбәкләрдә аның бераз вакыт яшәп алуы да мәгълүм. Аның «Сөбател гаҗизин» («Гаҗизләрнең ныклыгы») исемле шигъри әсәре Урта Азия укучылары арасында гына түгел, Идел-Җаек буйларында да киң тарала. Әмма аны татар шәкертләренә аңлау, төшенү кыенрак була. Әйтүләренә караганда, Таҗеддин Ялчыгол, сабак өйрәнүче кызының үтенече белән, Суфи Аллаһияр әсәренә (татар әдибе бу әсәрне энҗе белән тиңли) шәрех (комментарий) яза һәм үз китабын кызы хөрмәтенә «Рисаләи Газизә» дип атый.

Таҗеддин Ялчыгол, бу әсәрендә Суфи Аллаһияр шигырьләрен дә китереп, аларга аңлатмалар биреп бара, арага төрле сюжетлар, үзенең дә оригиналь юлларын өстәп җибәрә.

«Рисаләи Газизә» — дини-суфичыл характердагы әсәр. Анда кешеләрнең эшчәнлеге, әхлагы, яшәү рәвеше белән бәйләнешле мәсьәләләр гәүдәләнеш тапкан. Мәсәлән, автор наданлыкны, ялган суфилыкны, комсызлыкны кискен тәнкыйтьли. Гаделлек, юмартлык, эчкерсезлек кебек матур сыйфатларны зурлый. Китапта Урта гасыр өчен хас булган хөкемдар — ха-

лык (рәгыйять) мәсьәләсе дә гәүдәләнеш тапкан. Автор фикеренчә, солтан җәмгыятьнең әхлагы өчен дә җаваплы:

Әгәр солтан үзе кылса яманлык,—
Качан булгай рәгыйятьтә әманлык (иминлек.—*Х. М.*)?

«Рисаләи Газизә» — әхлакый, фәлсәфи, тарихи, иҗтимагый фикерләрне туплаган мөһим бер чыганак та.

Таҗеддин Ялчыголның халыкта киң таралган икенче китабы — «Тәварихе Болгария» (1805). Ул — Кадыйр Галибәк, Мөслими традицияләре рухында язылган ярым әдәби, ярым тарихи характердагы әсәр. Аның үзәген авторның нәсел шәҗәрәсе тәшкил итә.

«Тәварихе Болгария»дә болгар-татарларга мөнәсәбәтле төрле легенда-риваятьләр, топонимик аңлатмалар, аерым тарихи факт-мәгълүматлар урнаштырылган. Әмма аларда тарихи төгәлсезлекләр, уйдырмалар да очрый. Мәсәлән, Таҗеддин Ялчыголның «Кыйссаи Йосыф» авторы хакында биргән мәгълүматларын күп кенә галимнәр нигезсез, уйдырма дип санныйлар.

* * *

Бу чорда, Габдессәлам, Ялчыголлар белән беррәттән, кайбер башка авторлар да әдәби иҗат белән шөгыльләнә. Шулардан без Хөсәен бине Локман, Рәхимкол Әбүбәкер углы исемнәрен һәм әсәрләрен алдарак телгә алган идек. Аларның һәр икесе дә XVIII йөзнең икенче яртысында иҗат иткәннәр. Шушы ук вакытта Сәгъдеддин Габделмәҗид углы, Габделгафур бине Габделмәннан исемле зыялыларның да яшәве, илаһи бәетләр иҗат итүе мәгълүм. Аларның әсәрләреннән аерым өзекләр:

Кашкайыңның карасына каткыл бәне,
Буйкайыңның зифасына кушкыл бәне;
Хезмәт итеб, хезмәтеңә йарамасам,
Гыйшыклык базарына саткыл бәне!

(Габделмәҗид углы)

Акар су кебидер гомрең карарe,
Исәр йилдер йегетлек рузгяре (вакыты.— *Х. М.*).

XVIII йөзнең икенче яртысында Нигъмәтулла Бәшир углы исемле әдип тә яши. Аның Казан тирәсендәге авылларның берсендә тууы, 60—70 нче елларда Бәрәскә мәдрәсәсендә укуы мәгълүм. Аның бер шигырендә мондый юллар бар:

Ничә еллар, ничә көннәр, ничә ай
Йөгердем-йилдем, әмма булмадым җай.

XVIII йөзнең икенче яртысына мөнәсәбәтле Вәлид Каргалый исеме дә элеккеге чыганакларда еш очрый. Ул — чыгышы белән Кайбыч төбәгеннән. Туган ягында һәм Урта Азиядә укый. Ахырда Сәгыйть бистәсенә (Оренбург Каргалысына) кайтып урнаша. Мөритләр җыя, ишан (Вәлид ишан), мөдәррис буларак таныла. Анда Утыз Имәнинең дә укуы мәгълүм. Хаҗга барганда, күп кыенлыкларга очрый. Ул 1803 елда Мәдинә шәһәрендә вафат була. Вәлид Каргалый аеруча мөфти Мөхәммәдҗанны тәнкыйтьләп язган шигыре белән мәшһүр. Ул бу кешене «гыйлем, куәт, шәүкәт» белән алданып горурланмаска чакыра, гомернең фани булуын искәртә (Сөләйман һәм Мөхәммәд пәйгамбәрләр дә «фани җиһандин киттеләр», ди автор, «бәс, болардан гыйбрәт ал»). Гомерләре белән ике гасырны ялгаучы Колмөхәммәд, Мәнди Котыш һәм кайбер башка әдипләрнең дә иҗатлары теге яки бу дәрәҗәдә XVIII йөз белән бәйләнешле.

Бу дәвердә иҗат иткән әдипләрнең иң күренеклесе — Габдерәхим Утыз Имәни. Аның әдәби иҗаты һәм, гомумән, эшчәнлеге Урта гасыр әдәбиятыннан XIX йөз мәгърифәтчелек әдәбиятына күчештә мөһим баскыч булып тора.

Сораулар һәм биремнәр

1. Габдессәламнең тормышы һәм иҗаты турында сөйләгез.
2. Рәхимкол Әбүбәкер углының мәдхиясен искә төшерегез, аның Габделмәннан Мөслим углына мөнәсәбәтен ачыклагыз.
3. Габделмәннан Мөслим углы шигырьләренә нинди сыйфатлар хас?
4. Әхмәдбикнең тормышы һәм иҗаты хакында белешмә бирегез.
5. Таҗеддин Ялчыголның тәрҗемәи хәле турында сөйләгез.
6. «Рисаләи Газизә» нинди әсәр ул?
7. XVIII йөз әдәбиятының тагын нинди әдипләрен беләсез?

Габдерәхим Утыз Имәни
(1754—1834)

Утыз Имәнинең исеме, эшчәнлеге, китаплары үзе исән вакытта да, аннан соң да укучыларга һәм галимнәргә яхшы таныш. Октябрь революциясенә кадәр үк әдип хакында К. Насыйри, Ш. Мәрҗани, Р. Фәхреддин кебек мәшһүр кешеләр мөһим мәгълүматлар биреп калдырганнар. Совет чорында да Утыз Имәни күз уңында торды: аның әсәрләре мәктәпләрдә, югары уку йортларында өйрәнелде, дәреслекләрдә, «Татар поэзиясе антология»ләрендә нәшер ителде. Г. Газиз һәм Г. Рәхим, Ү. Беляева, М. Гайнуллин, М. Госманов, Ә. Шәрипов хезмәтләрендә әдипнең эшчәнлеге төрле яктан тикшерелде.

Утыз Имәнинең тормыш юлы.

Утыз Имәни 1754 елда хәзерге Чирмешән районы (элеккеге Чистай өязе) Утыз Имән авылында игенче гаиләсендә дөньяга килгән. Аның кушаматы туган авылына мөнәсәбәтле. Элеккеге традицияләргә хөрмәт йөзеннән, шагыйрь үзен кайвакыт «әл-Болгари» тәхәллүсе белән дә йөрткән.

Габдерәхимнең балачагы билгеле бер дәрәҗәдә Мөхәммәд пәйгамбәрнең һәм Тукайның сабый чагын хәтерләтә. Чөнки боларның өчесе дә бик яшьли ата-анасыз калалар.

Габдерәхимнең әтисе — Госман бине (углы) Сәрмәки — тумышы белән элеккеге Бөгелмә өязенең Тимәш авылы кешесе. Ул булачак шагыйрь дөньяга килгәнче үк үлеп китә. Шуннан соң Габдерәхимнең әнисе үзенең туган авылы Утыз Имәнгә кайтып яши башлый. Әмма, улы туып, ике-өч ел да үтми, ул да вафат була. Ата-анасыз калган Габдерәхим җиңгәсе кулында тәрбияләнгән. Уку яшенә җиткәч, үз авылларындагы Вилдан мулла мәдрәсәсендә белем ала, берничә ел күрше авылга йөреп укый. Ятим бала бик фәкыйрьлектә яши. Җиңгәсе өенә кайтмыйча, күп вакытын мәдрәсәдә уздыра: бай шәкертләргә хезмәт итеп, үзен үзе карый. Габдерәхим иптәшләре арасында зирәклеге, сәләтлелеге белән аерылып торган. Аның турын-

дагы истәлек һәм риваятьләрнең берсендә Габдерәхимнең кечкенәдән тиз уйлаучан, җитез табигатьле булуы, үзенең зирәк һәм шаянлыгы белән күзгә ташланып торуы язылган. Дәресне ул бик игътибар белән тыңлаган, тиз отып алган һәм соңыннан үз иптәшләренә аңлатып бирә алырлык зиһенле шәкерт булган. Шуңа күрә дә аны «укымый белә торган шәкерт» дип йөрткәннәр.

Габдерәхим, үз туган төбәгендә укыганнан соң, Оренбург янындагы атаклы Каргалы мәдрәсәсенә белем алырга килә. Биредә ул шагыйрь, атаклы ишан Вәлид Каргалыйдан дәресләр ала.

Габдерәхим, хатыны Фәтхия үлгәч, Утыз Имән авылындагы Габдеразак исемле кешенең кызы Хәмидәгә өйләнә. Балалары туа. 1788 елда Утыз Имәни гаиләсе белән Үзәк Азиягә юнәлә. Биредә аның Бохара, Үргәнеч, Сәмәрканд, Акча, Бәлех, Һират, Кабул һәм башка шәһәрләрдә булуы һәм эшләве мәгълүм. Утыз Имәни Урта Азиянең, Иран һәм Әфганстанның күп галимнәре белән очраша, дуслаша. Бу елларда аның гаиләсе ишәя: берничә баласы дөньяга килә. Әмма 1798 елда Утыз Имәнигә зур кайгы килә: сөйгән хатыны Хәмидә Әфганстандагы Каурмач төбәгендә үлеп китә. Кайгыдан Утыз Имәни хатынына багышлап мәрсияләр яза.

1798 елда шагыйрь үзенең гаиләсе белән туган якларына юнәлә. Кайтышлый Эстәрлетамак өязе Мерәс авылында туктالып ала. Аннан туган авылына кайта. Беренче хатыны Фәтхиянең сеңелесенә өйләнә һәм үз гомеренең ахырына кадәр аның белән яши. Шагыйрьнең 20 баласы булуы мәгълүм.

Утыз Имәни туган авылында төпләнеп калырга ниятли. Әмма аңа, «синең атаң Тимәш кешесе иде» дип, җир бирмиләр. Шуннан соң шагыйрь, Чистай өязенең Исләй авылына китеп, анда шәкертләр укыта башлый. Анда бер ел эшләгәч, хәзерге Лениногорск районындагы Сарабиккол авылына күчә һәм өч ел янә мөгаллимлек итә. Аннан Куакбаш авылына килеп, мәдрәсә салдыра, төрле төбәкләрдән җыелган шәкертләрне укыта. Утыз Имәни гомеренең ахырын Тимәштә уздыра. 1834 елның апрель башларында шунда ук вафат та була. Кабере — Тимәштә.

Утыз Имәни үз дәверенең гаять укымышлы кешесе була. Ул, туган теленнән тыш, гарәп, фарсы, таҗик, үзбәк, төрек телләрен камил белә. Үзенең аерым хезмәтләрен, шигъри юлларын гарәп, фарсы телләрендә дә яза.

Утыз Имәни туры һәм тапкыр сүзле, көчле характерлы

шәхес булган. «Габдерәхим хәзрәт сүз сөйләргә гаять тә сәләтле улып, кулында чукмары вә агызында чукмарыннан да куәтле теле улып, нә дөнья вә нә дин тугрысында бәхәс иткәндә җиңелеп калмамыштыр»,— ди аның турында Ризаэддин Фәхреддин. Утыз Имәни хакимият ияләре, Уфадагы Дини идарә белән дә каршылыкка керә. Габдерәхим хәзрәт ислам диненең сафлыгы өчен көрәшүчеләр хәрәкәтенең башында торган. Феодаль-колониаль изүгә, чукындыруга каршы юнәлтелгән бу хәрәкәтне халыкта «Утыз Имәни мәсләге» дип тә йөрткәннәр. Габдерәхим хәзрәт, тормыш авырлыкларына да, гаилә мәшәкатьләренә дә, дошманнарының яла-тәнкыйтьләренә дә карамыйча, мал-байлыкка кызыкмыйча, үзенең гомер юлыннан горур рәвештә алга атлый, төрле тармакларда армый-талмый эшли. Мөгаен, шуңа күрәдер дә ул халык күңеленә туры сүзле, мөхтәрәм Габдерәхим хәзрәт буларак кереп кала. Аның хакында күп санлы легенда-риваятьләр туа. Аларда шагыйрьнең үзенчәлегенә, тапкырлыгына, зирәклегенә басым ясала. Менә шундый риваятьләрнең бер-икесе:

«Өлкән улына кече малаеның исеме белән эндәшкәнен ишеткәч, берәү:

— Габдерәхим, ул егермеләп баланың исемен дә онытып бетерәсеңдер инде,— дип әйткән, ди.

— Хикмәт балаларның исемен онытуда түгел, ата икәнеңне онытмауда,— дип җавап биргән Утыз Имәни».

«Бервакыт Габдерәхим хәзрәт кырдан кайтып килә икән, юлда аны ат белән баручы бер кеше куып җиткән. Габдерәхим аның арбасына утырган. Икесе дә бик гади киенгән, аякларында чабата икән. Бераз сөйләшми барганнар. Бервакыт теге кеше, аны-моны уйлап тормыйча, кычкырып җырлап җибәргән. Аның җырлавы Габдерәхимгә бик ошаган, һәм ул үзе дә аңа кушылып җырлый башлаган. Теге кеше, бик кызыксынып: «Син кем буласың, кайсы авылныкы син?»— дип сораган. Габдерәхим аңа: «Үзең дә ишетә-беләсеңдер инде, Габдерәхим хәзрәт дигән кеше булам мин»,— дип җавап биргән. Теге кеше, моны ишетеп: «Ай хәзрәт, бик оятлы булдым, зинһар гафу ит. Тышкы килешең, гадилегең белән без аңлаган хәзрәткә бер дә охшамагансың бит»,— дип, гафу үтенә башлаган. Габдерәхим аңа: «Чү-чү, тавышланма! Кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырларсың, дигәннәр. Менә җырлавың миңа бик ошады, мин сиңа иярдем. Инде син дә минем фикерләремә ияр»,— дип, шуннан танышып киткәннәр».

Талантлы шәхес. Утыз Имәни — озын һәм катлаулы гомере белән генә түгел, ә күпкырлы һәм нәтиҗәле эшчәнлеге, бай иҗат мирасы белән дә хөрмәткә һәм ихтирамга лаек шәхес. Ул, — барыннан да элек, укытучы (мөгаллим, педагог). Шагыйрь ярты гасырдан артык гомерен яшь буынга белем һәм тәрбия бирүгә багышлый. Үзенең туган якларында да, Урта Азиянең мәшһүр мәдрәсәләрендә дә мөгаллимлек кыла. Аның шәкертләре арасыннан халыкка хезмәт итүче гаҗәеп күп санлы фидакяр кешеләр чыга.

Утыз Имәнинең гыйльми һәм әдәби мирасы да аның педагогик эшчәнлеге белән тыгыз бәйләнгән. Чөнки аның күп кенә китаплары белем-тәрбия бирүне, уку-укыту ихтыяҗларын күздә тотып язылган.

Галимнәр күрсәтүенчә, Утыз Имәни тудырган йөзләп китапның яртысын диярлек педагогик, гыйльми хезмәтләр, сүзлекләр, төрле шәрехләр һәм белешмәләр алып тора. Алар татарча, гарәпчә, фарсыча яисә катнаш телләрдә язылган.

Мәгълүм булганча, Урта гасырларда язылган әсәрләр кулдан-кулга күчерелеп таралганнар. Бу эш вакытында аларга теге яки бу дәрәҗәдә үзгәрешләр, өстәмә-төзәтмәләр дә кертелгән, ялгышлар да җибәрелгән. Китап басу башлангач, язма текстларның дөрес нөсхәсен төзү мөһим мәсьәләгә әйләнгән. Утыз Имәни, бу ихтыяҗны тоеп, күп кенә күренекле әсәрләрнең чагыштырмача дөрес, җыйнама текстын булдырган. Болар арасында Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ы да бар.

«Кыйссаи Йосыф»ның 1839 елда дөнья күргән тәүге басмасы нәкъ менә Утыз Имәнинең тәнкыйди текстына нигезләнгән. Бу үзе үк күп нәрсә хакында сөйли.

Шунысы да билгеле булсын: Утыз Имәни, гомумән, Кол Гали китабын бик яраткан. Бу хакта хәтта төрле мәзәкләр дә бар. «Сере бик гади» исемле мәзәкнең эчтәлеге болай: «Утыз Имәнидән бер танышы:

— «Йосыф китабы»на шулкадәр гашыйк булуыңның сере нәрсәдә? — дип сораган.

— Бик гади,— дигән шагыйрь.— «Йосыф китабы» миннән башка яшәгән һәм яшәячәк, ә мин аннан башка яши алмыйм...»

Утыз Имәни фарсы әдәбияты классигы, бөтен дөньяга мәгълүм шагыйрь Җәләледдин Руминың (XIII йөз) зур күләмле «Мәснәви» әсәрен дә күчереп чыга. Ул төзегән фарсыча тәнкыйди текстта 26 мең 936 бәет (икеюллык строфа) бар. Шулай ук Утыз Имәнинең Имам Газали, Фәридеддин Гаттар, Сәгъди,

Габдрахман Җами кебек Шәрык классикларының гарәпчә, фарсыча язган әсәрләрен дә күчерүе мәгълүм. Белгечләр раславынча, Утыз Имәни төзегән тәнкыйди текстлар чагыштырмача дөрес, тулы булулары белән сыйфатланалар.

Утыз Имәни эшчәнлегенең мөһим бер тармагын сүзлекләр төзү тәшкил итә. Мәсәлән, ул гарәп философы Мөхәммәд әл-Газалиның «Дин гыйлемен тергезү» исемле гарәпчә хезмәтендәге авыр аңлаешлы сүзләргә һәм төшенчәләргә гарәпчә-фарсыча сүзлек төзи. Аның Җәләледдин Руминың «Мәснәви»енә төзелгән сүзлеге дә нәкъ әнә шундый характерда.

Утыз Имәни — күренекле шәрехче (комментатор) һәм тәрҗемәче дә. Ул берничә күренекле хезмәтнең эчтәлеген аңлатып, шәрехләп бирә. Болар арасында үзе хөрмәт иткән Суфи Аллаһиярның «Сөбател гаҗизин» (1782 елларда, ягъни Таҗеддин Ялчыголдан 20 еллап алда), «Морадел-гарифин» («Укымышлыларның максаты») әсәрләре дә бар. Утыз Имәни бу шәрехләрен гарәпчә яза. Аларда татар авторының иҗтимагый, фәлсәфи, әхлакый фикерләре дә урын алган.

Татар әдибе ислам дөньясының аерым күренекле кешеләре хакында (биобиблиографик, энциклопедик) белешмәләр дә төзи. Мәсәлән, Урта Азия галиме Мөхәммәд Хорасанигә мөнәсәбәттә төзелгән китабында Утыз Имәни 227 зыялы хакында кыскача мәгълүматлар бирә. Аның бу юнәлештәге эшчәнлеген алга таба Ш. Мәрҗани, Р. Фәхреддин дәвам итәләр.

Утыз Имәнинең тарих, фәлсәфә, тел белеме, мөселман юриспруденциясе (хокук фәне) буенча да хезмәтләре бар.

Халыкка гыйльми белемнәр җиткерүне күздә тотып, Утыз Имәни медицина, астрономия, сәүдә, икътисад хакында да хезмәтләр яза. Мәсәлән, аның астрономия буенча язылган китабында галәм системасы, планеталарның хәрәкәте хакында фикерләр әйтелә. Тыйб гыйлеме (медицина) турындагы хезмәте, нигездә, чисталык, гигиена мәсьәләләренә багышланган.

Урта гасырның күп кенә башка ядкярләре кебек, Утыз Имәнинең аерым әдәби әсәрләре дә синкретик характерда, ягъни аларда әдәби тел һәм чаралар ярдәмендә гыйльми фикерләр дә бәян ителә. Бу әсәрләрдән без шул дәвернең фәлсәфәсе, эстетикасы, педагогикасы, хокукы, тарихы, психологиясе хакында күптөрле мәгълүматлар таба алабыз.

Утыз Имәни — табигате белән, әлбәттә, шагыйрь. Ә ни өчен соң ул, әдәби иҗаттан тыш, башка тармакларда да эшли? Моның билгеле бер тарихи, иҗтимагый сәбәпләре бар. Пугачёв

хәрәкәтеннән соң татарлар мәктәп-мәдрәсәләр, мәчетләр ачуда, дин һәм мәдәни эшләрне оештыруда билгеле бер хокуклар алуга ирешәләр. Элек-электән гыйлем-мәгърифәтне хөрмәт иткән татарларда педагогик кадрларга, дин белгечләренә, китап-әсбапларга гаять зур ихтыяҗ туа. Утыз Имәни, шушы ихтыяҗны тоеп, әдәби иҗат белән генә чикләнмичә, бик күп төрле тармакларда эшләргә мәҗбүр була. Үзенең энциклопедик мирасы, күпкырлы эш-гамәлләре белән ул руслардагы Ломоносов эшчәнлеген хәтерләтә.

Әдип бер шигырен (бәянын): «Егет булсаң, егетлек күрсәт илгә»,— дип башлый. Бу сүзләренә ул үзе дә тугрылыклы калды. Аның хезмәтләре — илгә күрсәтелгән «егетлек»нең күркәм бер галәмәте.

Һәр сүзнең «аслы бардыр, фаслы бар».

Утыз Имәни мирасында төп урынны, әлбәттә, әдәби әсәрләр алып тора. Алар арасында «Гавариф-эз-заман» («Замана укымышлылары»), «Мөһиммәтэз-заман» («Замананың мөһим хәлләре»), «Төхфәтел-гораба...» («Читтә йөрүчеләргә —гарибләргә бүләк...»), «Горбәтнамә», «Тәнзиһел-әфкяр...» («Фикерләрне пакьләндерүче...»),(«Бурыч — дуслыкны кисү кайчысы») «Әл-карзи микъразел-мәхәббәт» кебек күләмле әсәрләр (поэмалар) дә, чагыштырмача кечерәк мәдхия-мәрсияләр, мөнәҗәтләр, шигъри хикәятләр һәм башка жанрдагы әсәрләр дә бар.

Утыз Имәнинең әдәби әсәрләре әдип гомеренең төрле елларында, төрле вакытларда язылган. Бу аларның тел-стилендә, образлар системасында ачык күренә. Бер өлеш әсәрләренең теле шактый авыр. Арада хәтта фарсыча, гарәпчә юллар да очрый. Болар, мөгаен, аның башлангыч чор иҗатында һәм Урта Азиядә яшәгән елларында язылгандыр. Икенче төркем әсәрләренең тел-стиле чагыштырмача гади һәм бүгенге көн укучысы өчен дә, нигездә, аңлаешлы. Мәсәлән:

Кичәләрне йите бүлгән,
Мәнем өчен уйагъ торган,
Кечелекдә сөтен биргән
Шәфикамдин җөда булдым (аерылдым.— *Х. М.*).

(Хатыны Хәмидәгә багышланган мәрсиядән)

...Егетлеккә егетлек һәркем эшләр,
Яманлыкка егетлек ир кем эшләр.
Егет булсаң, егетлек күргәз илгә,
Атаңдик гомреңи үткәрмә җилгә.

(«Мөһиммәтэз-заман»нан)

Утыз Имәни үзенең әсәрләрендә дә укытучы булып кала. Аның иҗатында акыл, үгет-нәсыйхәт бирү, киңәш итү өстенлек итә. Хис-кичерешләр фикри якка буйсынулы. Автор шигърияттә Йосыф Баласагунлы һәм Әхмәд Йүгнәкидән, Мөхәммәдьяр һәм Мәүла Колыйдан, «Идегәй» дастаныннан килүче афористик фикерләү, хикмәтле сүз әйтү традициясен дәвам иттерә.

Шагыйрь үз иҗатында төп игътибарын белем, мәгърифәт мәсьәләләренә юнәлтә. «Гавариф-эз-заман» поэмасы, мәсәлән, тулысы белән шул проблемаларны яктыртуга багышланган. Утыз Имәни дә белемле, укымышлы кешеләрне мактый, наданнарны тәнкыйтьли. Ул күптөрле чаралар һәм сурәтләр ярдәмендә гыйлем, белем төшенчәләренең эчтәлеген, кеше өчен әһәмиятен, тормыштагы урынын гәүдәләндерә. Менә аның «Гыйлемнең өстенлеге турында төркичә бәетләр» әсәреннән өзекләр (алар Әхмәт Исхак тәрҗемәсендә бирелә):

Мәңге яшәргә теләсәң, и угыл,
Ал гыйлем, чөнки тереклек суы ул.

Белмәде һөнәрне гыйлемсез кеше,
Булмады аңарда бәхетнең эзе.

Чын бәхетне бирә тик гыйлем генә,
Баш иярләр һәрвакыт белемлегә.

Ал гыйлем, чөнки яшәүнең аслы шул,
Хәл итә барлык кыенлыкны тик ул.

Кем гыйлемле, бел асылташ дип аны,
Һич җиңалмас угры яки дошманы.

Гыйлемлек — яшьрен хәзинә, кем таба,
Ике дөнья байлыгы булыр аңа.

Шундый байлык ул — гел өстәп тор аны,
Ул сарыф иткән саен арта бары;

Дөньяның малы кими тоткан саен,
Өстәлә белем — сарыф иткән саен.

Күп гыйлемле булса адәм — байдыр ул,
Башкалар йолдыз кебектер,— айдыр ул...

...Килсә дә үлем, галим үлми һаман,
Үлеме килгәнче үк үлә надан.

Бел наданнар төркемен үлек диеп,
Үлсә галим, бел аны терек диеп...

Шагыйрь фикеренчә, белем — кеше идеалының зарури сыйфаты, бәхет ачкычы. Кеше никадәр укымышлы, белемле икән, ул шулкадәр үзе өчен дә, җәмгыять өчен дә файдалы. Утыз Имәни белем төшенчәсен һөнәр, эш-гамәл белән тыгыз бәйләнештә карый. Шагыйрь карашынча, хакимият ияләренең, кеше белән эш итүчеләрнең белемле, һөнәрле булулары зарури.

Урта гасырның күп кенә әдипләре кебек үк, Утыз Имәни өчен дә белем-мәгърифәт төшенчәсе кешеләрдәге әхлакый як белән тыгыз бәйләнешле. Шуңа күрә дә аның әсәрләрендә гаделлек, сабырлык, юмартлык, шәфкатьлелек кебек күркәм сыйфатлар, матур эш-гамәлләр мактала, икейөзлелек, комсызлык, хәрәм мал җыю, саранлык, тәкәбберлек төрлечә хурлана. Автор байлыкка, акчага, бурычка корылган дуслыкның начарлыгын, икейөзлелеген тасвирлауга да зур урын бирә. Тикмәгә генә аның бер әсәре «Бурыч — дуслыкны кисү кайчысы» дип исемләнмәгән.

Утыз Имәни дә традиция нигезендә сүз сөйләү, сөйләшә белү турында шактый күп яза. Аның фикеренчә, һәр сүзнең мәгънәсе, сөйләү вакыты бар. Шуңа күрә фикереңне уйлап, ачык, дөрес итеп сөйләү шарт. Чөнки «Хакыйкать — ул еланның агуы кук, Ачы булса да үзе, файдасы күп».

Авыр хәлдә калган кешеләрне яклавы белән Утыз Имәни Мәүла Колый хикмәтләренә аваздаш эш итә.

Шагыйрь иҗаты катлаулы, каршылыклы. Бу билгеле бер дәрәҗәдә шул дәвердәге иҗтимагый тормыш шартлары белән дә аңлатыла. Әйткәнебезчә, шагыйрь әсәрләре төрле елларда иҗат ителгән. Шуңа күрә авторның иҗтимагый һәм эстетик карашларында үзгәрешләр булып тору да — табигый хәл.

Утыз Имәни иҗаты үзенең идея-тематикасы, куелган мәсьәләләре белән традицион характерда. Әмма анда тормышка якынлык, үз дәверенең проблемаларына, шәхеснең эчке дөньясына игътибар чагыштырмача көчлерәк. Мәсәлән, ул икейөзле руханиларны, суфиларны кискен тәнкыйтьли. Татар җирлеге өчен хас булган мөселман-христиан мөнәсәбәтләрен яктырта. Кузьма углы Гришканың дини ышануын автор тәрбия җимеше, күнегү нәтиҗәсе дип саный («Кечкенәдән бер нәрсәгә күнегелсә, аңардан аерыла алмассың, гәрчә ул эчемлек булса да»).

Әйтүләренә караганда, Утыз Имәни, нахак бәла аркасында, бераз вакыт Бөгелмә төрмәсендә утырып чыга. «Горбәтнамә» поэмасын ул шунда иҗат итә. Анда авторның тоткынлыктагы авыр рухи халәте, азат, ирекле чакларын сагыну хисләре

шактый тулы гәүдәләндерелә. Менә аның хәзерге телгә тәрҗемәсеннән бер өзек:

Көтмәгәндә дошман кеше пәйда булды,
Хур итеп, мине төрмәгә яптырды...
...Ятамын ялгызым бер аулак өйдә,
Дусларымның берсе-бер юк янымда.
Кеше белән сөйләшү тыелды.
Дүрт ягымны сакчылар чорнап алды...
...Гаҗәп-хәйран булдым күреп үз хәлемне,
Белә алмадым нидән бу хәлгә төшүемне,
Кайда ул шат булып йөргән көннәрем?
Матур тормыш эчендә үткән көннәрем?
Кайда ул мул ризыгым, хуш күңелем?..

(Ә. Исхак тәрҗемәсендә)

Шагыйрь иҗатының реаль тормыш белән бәйләнеше аеруча аның мәрсияләрендә ачык күренә. Аларда гадәти татар хатыны, гадәти шартларда һәм мөнәсәбәтләрдә сөеп, хөрмәт белән тасвирлана.

Әдип бер шигырендә үз туган теле — төрки-татар телен яклап, мактап чыга. Бу башлангыч бераздан мәгърифәтче язучылар тарафыннан дәвам иттерелде.

Утыз Имәни шигырьләре поэтик яктан да, нигездә, традицион характерда. Аның күпчелек әсәрләре гаруз, икеюллык строфалар белән язылган. Утыз Имәни үз шигырьләренә мәкаль-әйтемнәр, кайбер күренекле әдипләрнең канатлы юлларын кертеп җибәрә. Сөйләмгә иллюстрация рәвешендә аерым сюжетлар китерү дә бар. Стилистик фигуралардан антитеза, риторик эндәш һәм сорау чараларын еш куллана. Аның шигырьләрендә чагыштыру, метафора бик актив.

* * *

Утыз Имәни мирасы — татар мәмләкәтләре вакытындагы рухи хәзинәләрне кабат торгыза башлауда, таралган, сибелгән әдәби казанышларны җыйнауда мөһим бер күренеш. Әдипнең гарәп, фарсы, төрки телләрен камил белүе, Урта Азиядә яшәп алуы аңа Шәрык гыйлемен һәм әдәбиятларын да ныклап үзләштерергә, мөселман дөньясындагы казанышларны татар мәдәниятенә дә күпләп кертергә мөмкинлек биргән.

Утыз Имәни иҗатында, гәрчә ул, гомумән, традицион идея-эстетик кысаларда, норматив поэтикада калса да, тормышчанлык, шул дәвер кешеләренең эчке дөньяларына, иҗтимагый мөнәсәбәтләренә игътибар көчәя төшә. Бу башлангыч

XIX йөз татар мәгърифәтчелек әдәбиятында тагын да үстерелде.

Утыз Имәни иҗаты Урта гасыр, Шәрык рухи казанышларын Ш. Зәкигә, Г. Кандалыйга, Акмуллага, К. Насыйрига җиткерүдә арадашчы вазифасын да үтәде. Шагыйрьнең гыйльми, педагогик хезмәтләре халыкның аң-белемен күтәрүдә, зиһенен баетуда мөһим роль уйнады.

Утыз Имәнинең бай һәм күпкырлы мирасы — халкыбызның үткәнен, рухи дөньясын, иҗтимагый һәм фәлсәфи карашларын өйрәнүдә, Шәрык мәдәниятләре белән бәйләнешләрен тикшерүдә дә мөһим чыганак.

Сораулар һәм биремнәр

1. Әдипнең тәрҗемәи хәлен сөйләгез.
2. Утыз Имәни хакында нинди риваятьләр, мәзәкләр бар?
3. Әдипнең гыйльми-педагогик эшчәнлеге кайсы тармакларда барган?
4. Утыз Имәни иҗат иткән аерым әсәрләрнең исемнәрен әйтегез.
5. Шагыйрьнең белем-мәгърифәт турындагы карашлары.
6. Әдип иҗатына нинди поэтик үзенчәлекләр хас?
7. «Утыз Имәни — талантлы шәхес» темасына инша языгыз.
8. Шагыйрьнең «Мәңге яшәргә теләсәң, и угыл...» әсәрен яттан өйрәнегез.

ӘДӘБИЯТ ТЕОРИЯСЕ

Урта гасыр әдәбиятында жанрлар системасы.

Әдәбият тарихын өйрәнү барышында инде без күп кенә жанрлардагы әсәрләр белән очраштык, аларга хас аерым үзенчәлекләрне күзәттек. Дистәдән артык жанрга махсус рәвештә билгеләмәләр дә бирелде.

Урта гасыр татар әдәбиятындагы жанрларга нинди сыйфатлар, үзенчәлекләр хас соң? Табигатьләре белән алар эпик (хикәят, кыйсса, сәяхәтнамә, әкият, мәсәл, дастан, мәзәк, кысалы кыйсса, риваять һ. б.) һәм лирик (газәл, касыйдә, мәдхия, кыйтга, мәрсия, илаһи бәет, робагый, мөнәҗәт, хикмәт, фәрд һ. б.) төрләргә аерылалар. Әмма бу ике төр арасында кискен чик юк. Аларның кайберләре еш кына лиро-эпик эчтәлектә була (дастан, кыйсса, васыятьнамә һ. б.).

Элеккеге жанрларны, сөйләмнең оешу формасына, стиленә карап, шигъри һәм чәчмә төрләргә аерырга мөмкин. Лирик жанрларның күпчелеге (газәл, касыйдә, робагый, мөнәҗәт, фәрд, кыйтга һ. б.) шигъри формада була. Әмма бу катгый таләп түгел. Аерым эпик жанрлар (кыйсса, дастан, хикәят

һ. б.) чәчмә формада да, шигырь белән дә язылырга мөмкин. Тезмә һәм чәчмә юллар катнашмасыннан төзелгән әсәрләр дә еш очрый («Гөлестан бит-төрки», «Гыйса углы Амәт», «Зафәрнамәи вилаяти Казан» һ. б.).

Жанрларның бер өлешендә тышкы форма таләпләре катгый саклана. Мәсәлән, газәл, касыйдә жанрлары гаруз, икеюллык строфалар (бәетләр) белән языла, рифмалашулары *аа ба ва*... рәвешендә. Робагый гадәти дүртьюллык строфадан тәмамланган уй-кичерешне белдерүе, мөстәкыйль әсәр булуы белән аерыла. Аерым жанрлар үзләренең табигатьләре, рухлары белән бер-берсенә якын торалар. Мәсәлән, касыйдә, мәдхия, мәрсия — мактау рухындагы әсәрләр. Кысалы кыйссалар һәм тартмалы композицион әсәрләр өчен чагыштырмача мөстәкыйль сюжетларның бер әсәр (җыентык, туплам) кысасында бирелүе хас («Мең дә бер кичә», «Мәҗмугыл хикаят», «Төхфәи мәрдан» һ. б.). Тарихи һәм уйдырма (легенда, хыялый) материалларның кушылмасы ярым тарихи, ярым әдәби әсәрләрне тәшкил итә («Җәмигъ эт-тәварих», «Дәфтәре Чыңгызнамә», «Тәварихе Болгария» һ. б.).

Аерым жанр атамалары еш кына төрле эчтәлектәге әсәрләргә карата кулланыла. Мәсәлән, хикәят исеме белән хикәя, әкият, мәзәк, кыйсса, дастан, мәсәл эчтәлегендәге әсәрләр дә атап йөртелгән. Кайвакыт терминнарны синоним рәвешендә дә куллану бар. Мәсәлән, Кол Гали әсәрен дастан да, кыйсса да дип атыйлар.

Урта гасыр язма әдәбиятындагы жанрларның бер өлеше фольклор белән охшаш яисә бик якын (дастан, илаһи бәет, бәет, мөнәҗәт, кыйсса, риваять һ. б.). Аерым жанрлар Шәрык әдәбиятларының күбесе өчен уртак (газәл, касыйдә, фәрд, робагый, дастан һ. б.).

Борынгы һәм Урта гасыр язма мәдәниятендә фәнни, публицистик һәм матур әдәбият арасында кискен чик юк: алар, еш кына үзара керешеп, синкретик берлек тәшкил итәләр.

Элеккеге әсәрләрне жанр ягыннан исемләүдә дә хәзерге әдәбият белемендә төрлелекләр бар. Мәсәлән, шигъри дастаннарны еш кына поэма дип атыйлар. Күләмле хикәятләрне повесть дип исемләү дә бар. Риваять һәм легенда атамаларын синоним рәвешендә дә куллану еш очрый. Хәзерге мәсәлне элек «ләтыйфә», «хикәят» дип, ә мәкальне «мәсәл» дип тә атаганнар.

Кыскасы, Урта гасыр әдәбиятында жанрлар системасында күптөрле үзенчәлекләр күзәтелә. Гомумән, жанрлар арасында

кытай дивары юк: алар еш кына үзара керешәләр; атамаларны куллануда да төрлелекләр яши.

Мәдхия. *Гарәпчә:* мактау, мактау шигыре, мәдех; Шәрык, шул исәптән татар әдәбиятында мактау әчтәлегендәге лирик жанр. Ул аерым кешеләрнең (гадәттә, күренекле шәхесләрнең, пәйгамбәрләрнең, хөкемдарларның) эш-гамәлләрен данлый, тантаналы, шатлыклы вакыйгалар, мөһим күренешләр уңае белән иҗат ителә. Аерым шәһәр-авылларга, предметларга багышланган мәдхияләр дә бар.

Традицион мәдхия өчен гайре арттыру, күрергә теләгәнне бар дип күрсәтү, күтәренке рух, чагыштырмача купшы стиль хас. Үзенең төп вазифасы һәм жанр табигате белән мәдхия рус һәм Көнбатыш Европа әдәбиятларындагы одага якын тора; еш кына алар татар әдәбияты фәнендә синоним рәвешендә дә кулланылалар.

Мактау шигырьләренең төп жанры булган касыйдәдән аермалы буларак, мәдхиянең тотрыклы тышкы формасы юк. Анда рифмалашу, строфа төзелеше күптөрле. Хәтта ритмлы проза белән язылган мәдхияләр дә очрый («Тәгърифе Борис»). Касыйдәләр, кагыйдә буларак, мөстәкыйль рәвештә кулланылалар. Мәдхияләр исә зуррак күләмле әсәрләр составында да иҗат ителәләр (Рабгузый, Котб, Харәзми, Кадыйр Галибәк мәдхияләре). Бу ике жанр күләм ягыннан да бердәй түгел.

Мактау әчтәлегендә әсәрләр иҗат итү бик күптәннән килә. Аның аерым үрнәкләрен дә инде без Йосыф Баласагунлы һәм Мәхмүд Кашгарый китапларында очраткан идек. Аннан соңгы әдәбиятта да мәдхия жанры яшәвен дәвам итә: «Мәдхе Мөхәммәдҗан» (Рәхимкол Әбүбәкер углы, XVIII йөз), «Вәйс әл-Карани» (Әхмәдбик, XVIII—XIX), «Мәдхе Казан» (Гали Чокрый, XIX), «Мәдхия» (Тукай) һ. б.

Мәрсия. *Гарәпчә*: елау, сыктау; некролог. Шәрык, шул җөмләдән татар әдәбиятында вафат булган кешеләрне, гадәттә, күренекле затларны мактау, олылап искә алу әсәре. Аның аерым үрнәкләре борынгы төрки (Күлтәгин, Билгә-каган ядкярләре) һәм Урта гасыр әдәбиятында очрый (Өмми Кәмал һәм Мәүла Колыйның остазлары истәлегенә язган шигырьләре һ.б.). Утыз Имәни мәрсияләрендә гадәти татар хатын-кызының реалистик сыйфатларга бай булган олы, якты образы тудырыла. Акмулланың «Дамелла Шиһабеддин хәзрәтләре», Тукайның «Хөрмәтле Хөсәен ядкяре» мәрсияләре жанр камиллекләре, көчле иҗтимагый яңгырашлары белән сыйфатланалар.

Мәрсия үзенең мактау рухы, поэтик тел-стиле белән мәдхиягә бик якын. Әмма аларның берсендә исән кешеләр, икенчесендә вафат булганнар тасвирлана. Мәрсияләргә, кагыйдә буларак, элегик, кайгылы аһәң хас. Бу жанрның конкрет әдәби формасы юк. Әмма күп кенә классик мәрсияләр гаруз белән язылган, касыйдә, газәл шәкелләрендә рифмалашкан.

Сораулар һәм биремнәр

1. Моңа кадәр өйрәнелгән жанрларны санап чыгыгыз. Әдәбият белеме сүзлекләреннән, дәреслектән файдаланып, аларның төп эчтәлеген билгеләгез.
2. Урта гасыр әдәбиятындагы жанрлар системасына нинди үзенчәлекләр хас? Бу жанрларны ни рәвешле төркемлиләр?
3. Мәдхия дип без нинди жанрга әйтәбез? Мәдхия һәм касыйдә арасында нинди уртаклыклар һәм аерымлыклар бар?
4. Мәрсия жанрының төп эчтәлеге нәрсәдән гыйбарәт? Аның мәдхия белән мөнәсәбәте.
5. Мәдхия һәм мәрсия жанрында нинди әсәрләр язылган?

ЙОМГАК

Борынгы һәм Урта гасыр әдәбияты — татар әдәбияты тарихының беренче баскычы, бай һәм катлаулы чоры. Ул мең елдан артык вакытны үз эченә ала.

Иҗтимагый тормыш (реаль чынбарлык, тарих), фольклор, борынгы төрки әдәбият, Шәрык классикасы — Урта гасыр татар әдәбиятының төп чыганаклары.

Хәзерге төрки халыклар этник кавем буларак формалашканчы туган, ягъни XII—XIII йөзләргә кадәрге борынгы төрки мәдәният фәндә уртак мирас, гомумтөрки әдәбият итеп карала. Бу рухи хәзинә татар әдәбиятының һәм фольклорының, аеруча татар язма әдәби теленең нигезендә ята. VI—VIII гасырларда язылган рун истәлекләренең, XI—XII йөзләрдә иҗат иткән Йосыф Баласагунлы, Әхмәд Йүгнәки, Әхмәд Ясәви, Сөләйман Бакырганый әсәрләренең традицияләре бөтен татар әдәбиятын ярып бара, хәтта Дәрдемәнд, Тукай иҗатларында да дәвам иттерелә. Төрки халыклар арасында үзара керешүләр, мәдәни уртаклык яисә якынлык XII—XIII йөзләрдән соң да әле билгеле бер дәрәҗәдә дәвам итә. Аларның әдәби ядкярләре, нигездә, бер-берсендә тәрҗемәсез, оригиналда укыла.

Әдәбият тарихы халык тарихы белән тыгыз бәйләнешле. Безнең әби-бабаларыбызны тәшкил иткән болгарлар, хәзәрләр, кыпчаклар, татарлар һәм кайбер башка төрки кавемнәр Көнчыгыш Европаның, Көнбатыш һәм Үзәк Азиянең, Себер һәм

Алтайның зур мәйданнарында яшәгәннәр; төрле көчешләр, керешүләр булган, берничә дәүләт төзелгән. Әмма Идел-Җаек моннан мең еллар элек үк инде төрки-татарларның төп йорты булган. Болгар, Хәзәр, Кыпчак, Алтын Урда, Казан, Әстерхан, Кырым, Нугай, Касыйм, Себер мәмләкәтләре — болар бар да безнең әби-бабаларыбыз төзегән, алар яшәгән дәүләтләр. Төрки-татарлар бу илләрнең төп халкын, ә төрки-татар теле ул мәмләкәтләрнең дәүләт телен тәшкил иткән. XVI— XVII йөзләрдән безнең халык, үз дәүләтчелегеннән мәхрүм ителеп, милли-колониаль изелүгә дучар була.

Ислам — Урта гасыр татар дөньясында төп дин, төп идеология. Шуңа мөнәсәбәттә бу чор әдәбияты да мөселман дине, Коръән рухы белән сугарылган. Татарлар арасында гарәп, фарсы телләрен өйрәнү, бу телләрдәге әсәрләрне уку киң тарала. Гомумән, Шәрык әдәбиятлары татар әдәбиятының формалашуында һәм үсешендә зур роль уйный.

Борынгы һәм Урта гасырларда фольклор һәм язма әдәбият арасында тыгыз бәйләнеш яши. Күп кенә ядкярләрдәге сюжетлар, мотивлар, сурәтләр генетик яктан халык авыз иҗатына барып тоташа. Үз чиратында язма әдәби истәлекләр дә фольклорга зур йогынты ясый. Халыклашып киткән әдәби ядкярләр дә бар.

Хәзерге чор әдәбиятындагы кебек, элекке дәвер әдәбиятының да үзәгендә — кеше, аның эчке дөньясы, табигать һәм җәмгыять белән бәйләнеше. Әмма кеше образының бирелешендә үзенчәлекләр дә бар. Урта гасыр әдәбиятында кеше гомумирәк, чагыштырмача абстракт пландарак тасвирлана. Аның индивидуаль ягына, төс-кыяфәтенә тиешенчә игътибар ителми. Ул, кагыйдә буларак, я бик уңай, я бик тискәре. Кешене сурәтләүдә экияти, дастани чаралар иркен кулланыла. Аның асылын, эш-гамәлләрен Аллага, илаһи көчкә мөнәсәбәттә тикшерү, бәяләү өстенлек итә. Еш кына Алла абсолют хакыйкать, куәт, матурлык өлгесе рәвешендә алына. Тәңренең берлегенә һәм барлыгына ышану — кеше турындагы идеалның мөһим өлеше.

Мәгърифәтле, гадел хөкемдар, яшәү мәгънәсе, мәхәббәт, гыйлемлелек, әхлак — Урта гасыр әдәбиятының төп проблемалары. Матур әхлакый сыйфатларга һәм эш-гамәлләргә ия булган белемле, һөнәрле, диндар шәхес — әдипләрнең кеше турындагы идеалы менә шул.

Хисам Кятиб поэмасында (1369) «Һәр кем ирсә нә иксә —ургай аны» дигән юл бар. Бу — без күнеккән «Ни чәчсәң, шуны

урырсың» мәкаленең бер төре, Урта гасыр әдәбиятында кешеләрне бәяләүнең төп әхлакый маддәсе (статьясы). Ягъни кеше үзенең сүз-фикере, эш-гамәле өчен үзе җаваплы. Яхшылыгың да, яманлыгың да, иртәме-соңмы, кире үзеңә кайтачак. Шуңа күрә авторлар үз укучыларын игелекле булырга, үзгәләргә ярдәм итәргә чакыралар. Кеше үз гомерен үзеннән соң «игү ат», яхшы исем калдырырлык итеп уздырырга тиеш! Андый зат кешелек хәтерендә мәңге сакланачак.

Шунысы мөһим: Урта гасыр әдипләре кешеләрне, аеруча хатын-кызларны, төрле юллар белән зурларга, дәрәҗәсен сакларга омтылганнар, аларны кимсетүгә, түбәнсетүгә кискен каршы чыкканнар. Суфи шагыйрьләр өчен Алла алдында һәр кеше тигез. Табигый тигезлек идеясе иҗтимагый, социаль тигезлек өчен дә нигез итеп алынган.

Урта гасыр әдәбияты теге яки бу дәрәҗәдә сүз сәнгатендә эшкәртелгән материаллар белән мөгамәлә кылуны, хәзергечә әйткәндә, интертекстуаль ысулны өстен күрә. Әмма авторлар андый материаллар белән иҗади эш итәләр, билгеле сюжетларны өстәмә факт-мәгълүматлар, шигъри детальләр белән баеталар. Нәтиҗәдә гомуми танышлык эчендә гаҗәеп күптөрле үзгәлекләр, яңа идея-эстетик күренешләр барлыкка килә.

Урта гасыр поэтикасында антитеза, гайре гиперболизм, эндәш, мөрәҗәгать, риторик сорау, сыйфатны сан аша бирү алымнары еш кулланыла. Төш күрүләр — сюжетны коруда һәм каһарманнарның сыйфатларын ачуда бик актив чара.

Урта гасыр әдәбияты өчен жанрлар төрлелеге, шигъри формаларның һәм чараларның байлыгы хас. Авторлар сүзләрдәге күпмәгънәлелек күренешен, сөйләмдәге фонетик һәм синтаксик мөмкинлекләрне әдәби максатларга оста җигәләр. Хикмәтле сүз әйтү традициясе уңышлы дәвам itelә. Шигърияттә гаруз актив кулланыла. Хәзерге әдәби тел белән чагыштырганда, Урта гасыр әдәбиятының теле сөйләмә телдән ераграк. Анда гарәп, фарсы сүзләре дә күп очрый. Бу борынгы төрки традицияләрнең дәвам итүлеше, Шәрык мәдәниятенең көчле йогынтысы, әдәби ядкярләрнең башка төрки төбәкләрдә дә тәрҗемәсез укылу ихтималлыгын күздә тоту һәм башка факторлар белән аңлатыла. Әмма шуңа да карамастан әдәби әсәрләрдә җанлы сөйләм, фольклор теленә хас булган элементларның, сурәтләрнең матур гына кулланылу үрнәкләре бар. Бу яктан аеруча Кол Гали, Котб, Хисам Кятиб, Сәйф Сараи, Мөхәммәдьяр әсәрләре игътибарга лаек. Мәүла Колый, Габди,

Габдессәлам иҗатларында язма һәм сөйләмә телләр тагын да якынаеп, урыны белән керешеп тә китәләр.

Урта гасыр әдәбияты өчен, гомумән, традиционлык, ягъни дәвамчанлык, чагыштырмача тотрыклылык, охшашлык хас. Бу — әсәрләрнең идея-тематикасында да, образлар системасында да, поэтикасында һәм телендә дә ачык күренә. Әдәбияттагы традиционлык, нормативлык исә чынбарлыкның үзенчәлеге белән билгеләнә. Чөнки Урта гасыр тормышында үсеш-үзгәреш шактый акрын, салмак бара.

Элеккеге әдәби ядкярләрнең бик аз өлеше генә сакланып, безгә килеп җиткән. Әмма билгелеләре дә Урта гасыр татар әдәбиятының идея-тематик яктан шактый бай, сәнгати яктан камил булуын күрсәтеп торалар.

* * *

Сүзнең кеше тормышында гаять зур роль уйнавын Урта гасыр әдипләре бик яхшы белгәннәр һәм бу хакта шигырьләр дә язганнар. Хәзер шуларның берсенә — Мөхәммәдьярга сүз бирик:

> ...Гәнҗ (хәзинә.— *Х. М.*), дәүләт, рәнҗ михнәт —
> камугы (барысы.— *Х. М.*).
> Ул (ягъни тел.—*Х. М.*) тылсым ачкычы берлә ачелер.
> ...Бәс, ни килсә башка, бел, телдин килер,
> Адәмигә нә ки кыйлса, тел кыйлыр.

Икенче бер урында шагыйрь болай ди:

> ...Нәчәләр сүзләб бу җиһандин кәчтеләр,
> Сүзләмәкдин парча дөрләр (энҗеләр.—*Х. М.*) сачтеләр...

Әйе, кешеләр дөньяга килгән һәм киткән, киләчәк һәм китәчәк. Әмма элеккеге дәвернең әдипләре фани дөньядан китсәләр дә, алар калдырган энҗедәй кыйммәтле сүзләр һаман да яши, һаман да безне дулкынландыра. Шулай итеп, буыннар бәйләнеше, кешелек хәтере дәвам итә.

Сораулар һәм бирем

1. Татар әдәбияты тарихы нинди чорларга бүлеп өйрәнелә?

2. Борынгы һәм Урта гасыр әдәбиятының үз эчендә вакыт ягыннан нинди бүленешләр бар?

3. Татар халкын барлыкка китерүдә нинди этник кавемнәр катнашкан? Безнең әби-бабаларыбыз төзегән һәм алар яшәгән дәүләтләрне атагыз.

4. Татар әдәбиятының нинди төп чыганаклары бар?

5. Ни өчен без борынгы төрки мәдәни хәзинәне бүгенге төрки халыкларның уртак мирасы дип әйтәбез?

6. Татар әдәбияты үсешендә Шәрык классикасы нинди роль уйнаган?
7. Урта гасыр әдәбиятында нинди мәсьәләләр гәүдәләнеш тапкан?
8. Элеккеге чор ядкярләрендә кеше образы ничек бирелгән?
9. Элеккеге һәм хәзерге әдәби тел арасында нинди гомуми уртаклыклар һәм аермалыклар бар?
10. Өйрәнелә торган чорга мөнәсәбәтле нинди фольклор әсәрләрен беләсез?
11. Урта гасыр әдәби традицияләренең үзеннән соңгы әдәбиятта дәвам ителешен нәрсәләрдә күрәсез?

ӘДӘБИЯТ ТЕОРИЯСЕ

Тарихи-әдәби процесста әдәби бәйләнешләрнең роле.

Укучылар, инде без, Алтын Урда чоры әдәбиятын өйрәнгәннән соң, «әдәби бәгланышлар», «әдәби йогынты» мәсьәләләренә махсус тукталып, аларның асылы, эчтәлеге хакында мәгълүматлар биргән идек. Кайбер әсәрләрне тикшерү, аерым темаларны өйрәнү барышында да әдәби элемтәләр турында күп кенә фикерләр әйтелде.

Әдәби бәйләнешләрне тормыштагы реаль бәгланышлар тәэмин итә. Татар халкы да үзенең тарихи яшәешендә бик күп илләр һәм халыклар белән төрле бәгланышларга керә. Гомумтөрки чорда безнең әби-бабаларыбызның Иран, Кытай, Һиндстан, Византия кебек мәмләкәтләр белән элемтәләре көчле булган. Ислам дине кабул ителгәч, төрки-татарларның мөселман дөньясы белән бәгланышлары арта. Шәрык белән бәйләнеш тарихыбызның мең елдан артык вакытын үз эченә ала һәм үзенең дәвамлылыгы, күпкырлылыгы, тирәнлеге белән сыйфатлана. Ә инде руслар, угро-фин, Кавказ һәм Урта Азия халыклары белән безнең күп гасырлык традицион, тыгыз мөнәсәбәтләр урнашкан.

Кыскасы, башка илләр һәм халыклар белән элемтәләр —тарихи процессның закончалыклы күренеше ул. Чөнки бер генә халык та үз кысаларында гына бикләнеп яши алмый. Тормыш ихтыяҗлары аны башка мәмләкәтләр һәм кавемнәр белән теге яки бу дәрәҗәдә бәгланышларга керергә, алардагы казанышларны, тәҗрибәне үзләштерергә, үзеннән дә бирергә мәҗбүр итә.

Әдәби бәйләнешләрдә иң мөһиме — халыкның эчке ихтыяҗы, эчке үсеше. Шуның таләбе нигезендә ул башкаларның рухи мәдәниятенә мөрәҗәгать итә, аннан тиешлесен файдалана, үзләштерә. Әгәр дә халыкның эчке рухи ихтыяҗлары, образлы фикерләве, традицияләре исәпкә алынмый икән, ул вакыт-

та читтән кергән казанышлар, ядкярләр этник бердәмлеккә, милли үсешкә зыян да китерәләр.

Урта гасыр һәм, гомумән, Тукайгача чор татар әдәби бәйләнешләренең хәлиткеч өлешен Шәрык әдәбиятлары белән бәйләнеш тәшкил итә. Дини берлек — бу бәйләнешләрне тәэмин итүче төп фактор. Бездә гарәп, фарсы, төрки (үзбәк, уйгур, төрек һ. б.) телләрен өйрәнү, ул халыклардагы ядкярләрне оригиналда һәм төрле тәрҗемә-шәрехләрдә уку элек-электән киң таралган. Татар әдәбиятындагы күп кенә сюжетлар, мотивлар, образлар, әдәби формалар генетик яктан Шәрык дөньясына барып тоташа. Мәсәлән, гаруз, аерым жанрлар (газәл, касыйдә, фәрд һ. б.) килеп чыгышлары ягыннан гарәп-фарсыларга мөнәсәбәтле.

Мәгълүм булганча, Урта гасыр Шәрык мәдәнияте — дөньядагы иң бай мәдәниятләрнең берсе. Шуңа күрә формалашып һәм үсеп килүче татар әдәбиятының күп гасырлар буе Шәрык классикасы белән тыгыз бәйләнешләрдә торуы, аның казанышларын иҗади үзләштерүе — тарихи яктан уңай һәм игътибарга лаеклы күренеш.

XIX гасыр азакларыннан башлап, татар әдәбиятының рус һәм Көнбатыш Европа әдәбиятлары белән бәйләнешләре арта. Әмма бу процесста татар тормышының эчке ихтыяҗларын, гореф-гадәтләрен тиешенчә исәпкә алмау, берьяклылык та күзгә ташлана. Шуның нәтиҗәсендә халкыбызның рухы өчен ят, кирәксез нәрсәләр дә, татар җирлегенә күчерелеп, татар укучылары арасында пропагандалана. Бу исә татарның теленә, этник бөтенлегенә, гореф-гадәтләренә, тарихи хәтеренә шактый зыян да китерде. Аерым халыкларның әдәби бәйләнешләре үз чиратында дөнья әдәби процессының чагыштырма бердәмлеген дә тудыра.

Әдәби иҗатта күчемлелек.

Иҗтимагый эшчәнлекнең башка өлкәләрендәге кебек, әдәби иҗат та буш урында гына барлыкка килми. Ул, табигый талант өстенә, билгеле бер шартлар, тәҗрибә, дәвамчанлык булуны да таләп итә.

Сүз сәнгате кешеләрнең яшәеш һәм хезмәт процессында барлыкка килә, үсә. Әүвәл ул, мифология белән кушылып, синкретик рәвештә яши. Бераздан фольклорда чагыштырмача мөстәкыйль төс ала. Утрак тормыш, шәһәрләр һәм сәүдә үзәкләре барлыкка килү, хезмәт бүленеше, дәүләтләр туу язуга ихтыяҗны китереп чыгара. Моңа тикле сөйләмә (фольклор) формасын-

да яшәгән сүз сәнгате язма рәвештә дә яшәү, үсү, таралу мөмкинчелеге ала. Язма сүз сәнгате белән махсус шөгыльләнүчеләр — әдипләр барлыкка килә. Аларның тырышлыгы белән язма мәдәният буыннан-буынга тулылана, байый, үзенә хас үзенчәлекләргә, төшенчәләргә, чагыштырмача мөстәкыйльлеккә ия була бара. Инде бераздан фольклор һәм чынбарлык материалларын, моңа кадәрге язма мирасны, андагы казанышларны белмичә, үзләштермичә, гәүдәләндерү мөмкин булмый башлый. Бу хәл үзеннән-үзе әдипләрнең, табигый талант өстенә, сүз сәнгатендә тупланган казанышларны, «техника»ны да белүне шарт итеп куя. Мисалга телне һәм жанрларны гына алып карыйк. Тел — сүз сәнгатенең төп коралы, төзү материалы ул. Һәр буын язучысы аны баетуга, камилләштерүгә үзеннән өлеш керткән. Нәтиҗәдә язма телнең бай хәзинәсе барлыкка килгән. Бу мирасны һәм халыкның җанлы телен тиешенчә үзләштерми торып, бер генә язучы да әдәби иҗатта уңышлы адымнар ясый алмый. Әдипләрнең үзенә кадәрге кулланылган жанрларны белүе дә кирәк. Чөнки аларда әдәби иҗат өчен хас булган үзенчәлекләр аеруча ачык гәүдәләнеш тапкан.

Кыскасы, һәр язучыга үзенә кадәрге милли, эстетик казанышларны, әдәби мирасны өйрәнү, белү зарури. (Әлбәттә, башка халыкларның да файдалы эстетик тәҗрибәләренә игътибарлы булу шарт.) Бары шунда гына әдәби процесс нормаль үсеш ала, традицияләр һәм новаторлыкның нормаль берлеге туа.

Урта гасыр әдәбиятында күчемлелек аеруча көчле. Бу процессның дәвамчанлыгын тәэмин итүдә аеруча мөселман диненең роле зур була. Чөнки әдипләр, күп кенә проблемаларны Коръәнгә мөнәсәбәттә алып, аларны ислам дине рухында эшкәртәләр.

Бер үк мәсьәләләрне (хөкемдар һәм халык, кеше һәм Алла, яшәү мәгънәсе һ. б.) охшаш әдәби чаралар һәм формалар белән яктыртуда да күчемлелек, дәвамчанлык ачык күренә.

Йосыф — Зөләйха, Хөсрәү — Ширин, Сөһәйл һәм Гөлдерсен, Таһир — Зөһрә, Сәйфелмөлек һәм Бәдигылҗәмал — болар бар да мөстәкыйль язмышлы мәхәббәт тарихлары. Әмма авторлар еш кына, бу гыйбрәтле сюжетларны яктыртканда, охшаш формалар, сурәтләү алымнары, шигъри детальләр кулланалар. Бу да шул чор поэтикасындагы традиционлыкны, әдәби иҗаттагы буыннар бәйләнешен күрсәтеп тора.

Әдәбиятта күчемлелек билгеле бер дәрәҗәдә чынбарлык тәэсире белән дә билгеләнә. Чөнки әдәбиятның нигезендә

кеше язмышы, халык, җәмгыять тормышы ята. Алар өчен исә һәр чорда актуаль булган проблемалар да җитәрлек. Туу һәм үлү, яшәү, гыйлем-һөнәр үзләштерү, мәхәббәт, гаилә кору, кеше һәм табигать, хөкемдар һәм халык, ата-ана һәм бала мөнәсәбәтләре — әнә шундыйлардан. Бу мәсьәләләргә һәр чор язучысы үзенчә, үз дәвере һәм җирлеге таләбенчә җавап бирергә омтыла.

Урта гасыр әдәбиятының бай иҗади мирасы, образлар системасы, поэтикасы һәм бигрәк тә тел-стиле үзеннән соңгы татар әдәбияты, аның әдипләре өчен нигез, осталыкка өйрәнү мәктәбе булып хезмәт итте.

Үткәне юкның — киләчәге юк, диелә халык мәкалендә. Безнең халыкның озын тарихы, бай мәдәнияте бар. Без аны никадәр ныграк, төплерәк өйрәнсәк, безнең киләчәгебез дә шулкадәр өметлерәк, аңа баруыбыз да шулкадәр ышанычлырак булыр.

Сораулар һәм биремнәр

1. Дәреслекнең алдагы өлешеннән «Әдәби багланышлар» һәм «Әдәби йогынты» мәкаләләрен укыгыз, аларның төп эчтәлекләрен сөйләп бирегез.
2. Әдәби бәйләнешләрне нәрсә тәэмин итә?
3. Әдәби багланышларда халыкның эчке ихтыяҗын исәпкә алу ни өчен бик мөһим?
4. Татар әдәбиятының Шәрык белән дәвамлы бәйләнеш сәбәпләре нәрсәләрдә күренә?
5. Дәреслектә «Кыйссаи Йосыф» әсәреннән соң бирелгән «Традиция һәм новаторлык» мәкаләсен укыгыз, төп мәгънәсен аңлатыгыз. Традиция, новаторлык, күчемлелек төшенчәләре бер-берсе белән нинди мөнәсәбәттә?
6. Язма сүз сәнгате ничек барлыкка килә?
7. Урта гасыр әдәби процессында күчемлелек, дәвамчанлык нәрсәләрдә ачык күренә?
8. Ни өчен без: «Урта гасыр әдәбияты үзеннән соңгы әдәбият, язучылар өчен нигез, осталыкка өйрәнү мәктәбе булды»,— дип әйтәбез?

XIX ЙӨЗ ӘДӘБИЯТЫ

XIX ЙӨЗНЕҢ БЕРЕНЧЕ ЯРТЫСЫНДА ӘДӘБИЯТ

XIX йөз — татар әдәбиятының күп гасырлык үсеш юлында бик әһәмиятле зур бер этап. Бу гасырны яңа татар әдәбиятының формалашу чоры дип тә атыйлар. Бу әдәбиятның яңалыгы нидән гыйбарәт? Аның яңаруына нинди тарихи-иҗтимагый факторлар йогынты ясаган? Алга таба без күп кенә шундый сорауларга бергәләп җавап табарга тырышырбыз. Ә хәзергә бу гасырда барган процессларга, әдәбият үсешенә гомуми күзәтү ясыйк.

XIX гасырда, бигрәк тә аның икенче яртысында (1861 елгы реформадан соң), Россиядә феодаль тәртипләр таркала барып, капиталистик, буржуаз мөнәсәбәтләр үсә. Бу үзгәрешләр, акрынлап булса да, татар халкы арасында да бара. Шуның нәтиҗәсендә иске феодаль-патриархаль тәртипләргә, торгынлыкка каршы буржуаз-демократик хәрәкәт буларак, татарлар арасында **мәгърифәтчелек хәрәкәте** формалаша.

Бу хәрәкәт татар тормышының **эчке,** үз җирлегендә, яңа тарихи шартлар нигезендә барлыкка килә. Шул ук вакытта **тышкы бәйләнешләр** дә әһәмиятле роль уйный. Бер яктан, татар мәгърифәтчеләре Көнчыгыш (Шәрык) әдәбияты һәм мәдәниятенең гуманистик традицияләренә таяндылар. Икенче яктан, фән-техника, прогрессив фикер алга киткән — рус, алга табарак Европа мәдәнияте белән уңай багланышлар урнаша барды.

Үсеп-оешып килгән милләтне агарту, аң-белемле, һөнәрле итү, әхлакый тәрбияләү, уку-укыту системасын үзгәртеп кору һәм, гомумән, татар тормышын һәрьяклап яңарту идеяләре белән сугарылган мәгърифәтчелек идеологиясе, матур әдәбиятны үзенә көчле, үтемле корал итеп алып, аның үсешенә гаять зур этәргеч ясый. Татар халкының үз тормышын чагылдырган,

мәгърифәтчелек идеяләре гәүдәләнгән **реалистик** әдәбият мәйданга чыга. Көнчыгыш әдәбиятының гуманистик традицияләре дәвам итү белән беррәттән, рус һәм Европа әдәбиятларына тәрәзәләр ачыла. Поэзиянең эчтәлеге һәм сәнгатьчә сурәтләү чаралары яңара бару белән бергә, реалистик проза, драматургия беренче адымнарын атлый. Матур әдәбиятның халык тормышы белән бәйләнеше ныгый бара. Әдәби тел татар халкының үз җанлы сөйләменә нигезләнергә омтыла.

* * *

Татар әдәбиятының яңа сыйфатка күчә бару билгеләре XIX гасырның беренче яртысында ук (1800—1860)[1] күренә башлый. Бу чорда товар җитештерү, сәүдә эшләренең киңәюе белән бергә, татар халкының аңына, җәмгыять тормышына, мәгърифәт үсешенә уңай тәэсир ясаган тарихи вакыйгалар, факторлар була. Аларның иң әһәмиятлеләре түбәндәгеләр:

1. 1812 елгы Ватан сугышы.
2. 1825 елгы Декабристлар восстаниесе.
3. XIX гасырның беренче елларыннан Казанда татарча китаплар басыла башлау.
4. 1804 елда Казанда университет ачылу һәм аның Көнчыгыш телләре бүлегендә татар телен укыту.

Наполеонга каршы көрәштә һәм 1825 елгы Декабристлар восстаниесендә, руслар һ. б. милләт кешеләре белән бергә, татарлар да актив катнаша.

Дөрес, Россия империясе халыклар төрмәсе иде. Бу империядә күп халыклар, шул исәптән татар халкы да, милли-колониаль һәм социаль изелү астында иде. 1552 елда Казан дәүләте Иван Грозный гаскәрләре тарафыннан басып алынганнан соң, ватаныннан мәхрүм ителгән татар кешесе үз илендә эчтән сыкрап яшәде. Әмма берничә гасырлар буена руслар һ. б. халыклар белән бергә тормыш алып бару, аралашу, алыш-биреш итү, бигрәк тә Степан Разин, Емельян Пугачёв восстаниеләрендә азатлык өчен иңгә-иң торып бергәләп көрәшүләр күп халык-

[1] Әдәбият үсешендәге этаплар, сыйфат сикерешләре календарь, еллар исәбе белән үзара тәңгәл килеп җитми. Татар халкының иҗтимагый фикер һәм әдәбият тарихын өйрәнгәндә, XIX йөзнең беренче яртысы итеп бу гасырның урталай бүленеше, ягъни 1850 елга кадәр түгел, ә 1860—1861 елларга кадәрге чорны алу кабул ителгән. Чөнки халык тормышындагы зур үзгәрешләр Россиядә 1861 елның 19 февраль реформасы белән крепостное право бетерелгәннән соң тизләтелгән үсеш ала.

ларны үзара якынайтты. 1812 елгы Ватан сугышы да моңа зур этәргеч ясады.

Татарлар сугышта зур батырлыклар күрсәтәләр. Ватан сугышы герое Денис Давыдов[1] болай дип язган: «Генерал Ермолов татарлардан гаскәр төзеде. Бу гаскәр көчлелектә, батырлыкта һәм осталыкта алардан (чик буе казакларыннан. — *Ред.*) өстен булмаса да, һәрхәлдә, һич тә калышмый». Татар-башкорт улларының ил язмышын хәл иткән бу тарихи вакыйгаларда катнашуы, батырлыклар күрсәтүе халыкның рухи тормышында тирән эз калдырган, милли горурлык, патриотизм, халыклар дуслыгы тойгысын үстергән. Болар халыкның җыр-бәетләрендә чагылыш тапкан. «Рус-француз сугышы» бәетендә туган җиргә басып кергән дошманны тар-мар итү, җиңеп кайту шатлыгы, ил һәм аның халкы өчен горурлык тойгысы бөркелеп тора.

Татар-башкорт атлыларының яратып җырлый торган «Икенче әрме[2] җыры» гадел сугышка баручы ир-егетләрне кыюлыкка, батырлыкка дәртләндерә. Туган ил һәм аның батыр уллары бербөтен итеп күрсәтелә.

Йомры гына тояк, ай, елкының
Юлкайларын кисәр лә җәнлек юк.
Һай илкәем, егет
Беленер тезген тотканда.
Ир-егеткәй өчен, ай, яуларда
Күкрәккәен тишәр лә ядрә юк.
Һай илкәем, ир
Сыналыр угын тартканда.

Сугыш истәлекләре, җыр-бәетләр халык күңелендә озак сакланган. Шуны да әйтергә кирәк: ул замандагы җыр-бәетләрдән килә торган традицияләрне, образлы гыйбарәләрне әле халкыбыз иҗатында безнең көннәрдә дә очратырга мөмкин.

1913 елда Г. Тукай татар халкының тарихта эзле, «бер дә тапсыз көзге» булганлыгын күрсәтеп, әмма аның хокуксыз хәлдә булуына тирәнтен ачынып, милли хокукларын таләп итеп, болай дип язган иде:

Без сугышта юлбарыстан көчлебез,
Без тынычта аттан артык эшлибез.
Шул халыкныңмы хокукка хаккы юк?—
Хаклыбыз уртак ватанда шактый ук!

---

[1] Денис Давыдов үзе дә борынгы татар нәселеннән.

[2] Әрме — армия.

Ә соң әле без өйрәнә торган дәвердә —1812 елгы сугыш һәм аннан соңгы чорда, гомумән XIX гасырда — халыкларның хокуклары иркен идеме? Һич юк. Киресенчә, бу хокуклар юк дәрәҗәсендә иде. 1812 елгы сугыш халык массаларының чикләнмәгән көчен, ә крепостной тормышның, самодержавие хакимиятенең череклеген күрсәтте. Бөтен авырлыкны үз җилкәсендә күтәреп, җиңүдә хәлиткеч роль уйнаган халыкның кол хәлендә булуы, рәхимсез изелүе патша хакимиятенә каршы Декабристлар хәрәкәтен китереп чыгара. Бу хәрәкәткә иреккә сусаган башка милләт вәкилләре дә (латыш, эстон, чуваш һ. б.), шул исәптән татарлар да катнаша.

Мәсәлән, подпоручик, «Төньяк җәмгыяте» әгъзасы А. А. Бурнашев, башка полкларның вәкилләре белән бергә, восстание алдыннан К. Рылеевта үткәрелгән киңәшмәдә була. Декабрист А. А. Арбузов капитан-лейтенант Җанбулатовны үзенең акыл бирүче остазы дип саный. Сенат мәйданында восстаниедә барабанчы татар Рамазан Семёнов та була. Ул яралана, Петропавел крепостена ябыла. «Көньяк җәмгыяте» әгъзасы майор Спиридонов подпоручик Казанлы белән дустанә мөнәсәбәттә булуын белдерә. Тикшерү һәм суд эшләре материалларында тагын күп кенә татар исем-фамилияләре (офицерлар, рядовойлар) күрсәтелгән.

* * *

Хәзер без татар мәгърифәте, мәдәнияте һәм әдәбияты үсешенә турыдан-туры зур этәргеч биргән әһәмиятле факторларга тукталыйк.

Кульъязма һәм беренче басма китаплар. 1800 елда Казанда «Азия» типографиясе ачыла. Анда гарәп хәрефләре белән татарча китаплар басыла башлый.

Элекке заманнарда китаплар кулдан күчерелгән һәм төпләнгән. Уку-язуга әүвәлдән һәвәс булган безнең халыкта кульъязма китапның Болгар чорыннан ук килгән күп гасырлык бай тарихы бар. Китап язу-күчерү эшләрен мәктәп-мәдрәсәләрдә шәкертләр һәм аларның укытучы-остазлары башкарган. Матур, пөхтә язуга сәләтле, бу эш белән даими шөгыльләнүче укымышлыларны хәттатлар (каллиграфия осталары) дип атаганнар. Мәсәлән, 1720 елда ачылган һәм тиз арада танылып өлгергән Эстәрлебаш (хәзер Башкортстанның Эстәрлетамак районы) мәдрәсәсендә бик бай китапханә тупланган була. Үз гомерендә, зур тырышлык куеп, дистәләгән, хәтта йөзләгән китап

күчергән кешеләр билгеле. Мәгърифәтче Каюм Насыйриның бабасы шундый осталардан саналган.

Кулдан язылган китаплар арасында тышлыгы, бит кырыйлары, бүлек башлары чәчәкле орнаментлар белән нәфис итеп бизәп эшләнгәннәре дә булган. Борынгы әдәби әсәрләрнең төрле күчермәләре әле дә табылып тора. Болар халкыбызның китап сүзенә, аң-белемгә элек-электән олы ихтирам һәм тирән мәхәббәт саклап яшәве турында сөйли.

Кешеләр китапны басма юл белән аз вакыт эчендә йөзләрчәмеңнәрчә данә итеп күбәйтү турында күптәннән хыялланганнар. Хәреф җыеп китап басу омтылышлары иң элек Кытайда (Би Шэн) 1041—1048 елларда ясалган. Европада (Германия) бу эшне XV гасырның 40 нчы елларында немец уйлап табучысы Иоһанн Гутенберг башлап җибәрә. Славян халыклары тарихында беренче типографиягә 1491 елда Польшаның Краков шәһәрендә нигез салына. XVI гасырның 20 нче елларында Вильнюста типография ачыла. Россиядә һәм Украинада китап басу эшләренең башлануы Иван Фёдоров (1510 тирәсе — 1583) эшчәнлеге белән бәйле. Төгәл датасы куелган беренче рус басма китабы — «Апостол» — аның тарафыннан Мәскәүдә 1564 елда чыгарыла.

Россия империясенең колониаль изүе астында яшәгән күп халыкларда, шул исәптән татар халкында да, үз телендә китап басу гасырлар буе тыелып, тоткарланып килгән. Шулай да хөкүмәт даирәләре, төрки халыклар арасында беренче буларак, татарча китап басу эшләренә керешергә мәҗбүр булганнар. Чөнки татар теле элек-электән Россиянең эчке эшләрендә, Көнчыгыш илләре белән бәйләнешләрендә арадашчы ролен уйнаган. Татар укымышлылары дәүләт учреждениеләрендә, илчелекләрдә тылмач, киңәшче, илче һ. б. булып хезмәт иткәннәр.

Пётр I патшалык иткән елларда татар теленнән файдалану тагын да киңәя. Татар зыялылары катнашында тел өйрәткечләр, сүзлекләр төзелә башлый, гарәп хәрефләре булдырыла. Кайбер указлар татар теленә тәрҗемә ителеп (1711 елдан) басыла башлый. Беренче татар китабы Пётр I кушуы буенча 1722 елда Әстерхан типографиясендә басыла. Шушы елның җәендә Пётр I Иранга каршы зур поход оештыра. Бу походка барганда, ул Казанда һәм Болгарда да була. Походта татарлар да катнаша. Патша, Каспий буе, Кавказ, Кырым халыкларына бу походның сәбәбен аңлатып, «Манифест» яздыра. «Манифест»ны татарча бастырып чыгару эшләрен Дмитрий Канте-

мирга[1] тапшыра. Аңа патша даирәсендә булган өлкән тылмач Тәфкилев[2] һ. б. татарлар ярдәм итәләр. Типографиядә җыелган беренче татар басма китабының тарихы шушы брошюрадан башлана.

XVIII һәм XIX йөзләрдә төрки халыклар яшәгән күп территорияләрнең Россия составына кертелүе, Көнчыгыш илләре белән бәйләнешләрнең активлашуы нәтиҗәсендә, бу халыкларның телләрен белүче кадрларга ихтыяҗ арта бара. Руслар арасыннан шундый белгечләрне (шул исәптән христиан миссионерларын да) әзерләү өчен, Казан, Оренбург, Әстерхан, Түбән Новгород, Тобол, Пенза һ. б. шәһәрләрдәге гимназия, хәрби мәктәп, духовное училище кебек уку йортларында төрки, татар телләре укытыла. XVIII йөз азакларында татар теле Мәскәү университеты, XIX йөз башларында Казан, Харьков университетлары, төрле институтлар программаларына кертелә.

Татар телен укыту өчен, әлбәттә, дәреслекләр, кулланмалар кирәк була.

Казанда гимназия 1759 елда ачыла. Бу уку йортына башлап кабул ителгән ундүрт малай арасында яшүсмер **Гаврила Романович Державин** да (1743—1816) була. Бик тере һәм җитез табигатьле, рәсем һәм сызымга оста, музыка һәм әдәбиятны яратучы бу яшүсмергә, дөрес, гимназияне тәмамлау насыйп булмый. 1762 елда ул Петербургка солдат хезмәтенә алына. Киләчәктә ул рус поэзиясенең бөек шагыйре һәм күренекле дәүләт эшлеклесе сыйфатында таныла.

Г. Р. Державин чыгышы белән татар морзалары нәселеннән. Аның борынгы бабасы Бәһрам морза XV гасырданиндидер низаг аркасында Алтын Урда дәүләтеннән Руська хезмәткә күчкән була.

Гимназиядә укыганда, Державин 1761 елның җәен берничә иптәше белән борынгы Болгарда үткәрә. Шагыйрь үзе язганча, ул анда Хан сарае хәрабәләрен, мунча, манара кебек корыл-

---

[1] Дмитрий Кантемир (1673—1723) — чыгышы белән Кырым татары. Озак еллар Төркиядә хезмәт итә, ул заманда Төркия кул астында булган Молдавия идарәчесе итеп билгеләнә. 1711 елда, үзе теләп, Пётр I ягына чыга. Күп телләр белгән зур укымышлы. Әстерханда поход типографиясе өчен гарәп хәрефләренең рәсемен үзе ясап койдыра.

[2] Тәфкилев (1674—1766) — морза Котлымөхәммәд (христиан диненә күчкәннән соң Алексей Иванович) Тәфкилев. Җаек буенда Оренбург һ.б. шәһәр-крепостьларны салуда, Казахстанның Россиягә кушылуында зур роль уйный. Алга таба генерал-майор дәрәҗәсенә күтәрелә.

маларны, җир асты юлларын тасвирлап яза, күп кенә башка биналарның рәсемнәрен ясый, кабер ташларындагы язуларны кәгазьгә төшерә, борынгы акчалар, алтын һәм көмеш әйберләр таба. Боларның барысын да ул Казанга, гимназиягә алып кайта. Гимназист Державинның бу сәяхәте борынгы Болгарга оештырылган беренче экспедицияләрдән була.

Татарларның килеп чыгышы турындагы мәгълүматларны шагыйрь үзенең әсәрләрендә яраткан поэтик бизәкләр итеп куллана. Шигырьләрендә ул үзен «Атилла токымы, Ра[1] елгасы кешесе», «Болгар җирләреннән, Ай илләреннән» дип белдерә. Ул үзе һәм замандашлары аны еш кына «морза» дип тә атаганнар. «Морзаның күзаллавы» дигән шигыренең азагында ул болай ди:

> Мин җырладым, җырлыйм һәм җырлармын,
> Хакыйкатьне төреп шаяруга;
> Томаланган татар җырын тапшырырмын,
> Якты нур сипкәндәй, яшь буынга.
>
> *(Ш. Садретдинов тәрҗемәсе)*

Державинның тормышы һәм иҗаты Казан шәһәре, Мишә, Кама һәм Идел буйлары белән тыгыз бәйләнгән. Картайган көннәрендә дә шагыйрь туган якларын сагынып җырлый. «Арфа[2]» шигырендә арфаның моңлы чыңлавы, «тылсымлы авазы» аңа «кадерле ватаны», «Казандагы алтын вакытлар» турында сөйли. Хискә бирелгән карт шагыйрь әсәрен болай тәмамлый:

> Чыңла, сазым, моңлы сазым, эчем ялкын!
> Казаннарда ниләр барын тынмый сөйлә!
> Үз ягымның җилләре дә җанга якын:
> Тәмле, татлы туган җирнең төтене дә.
>
> *(Ш. Садретдинов тәрҗемәсе)*

Шигырьнең соңгы юлындагы гыйбарә («Отечества и дым нам сладок и приятен»), халык теленә кереп, канатлы сүз, әйтем булып әверелгән.

1816 елның көзендә, Г. Р. Державинның вафат булуы турында хәбәр алынгач, Казан университеты укытучысы Нигъмәт Ибраһимов җитәкчелегендәге Туган тел һәм әдәбиятны сөючеләр җәмгыятенең махсус утырышы үткәрелә. Н. Ибраһимов Казанда бөек шагыйрьгә һәйкәл салу мәсьәләсен күтәрә. Бу тәкъдим халык арасында киң яклау таба, акча җыела.

---

[1] Ра — Иделнең борынгы исеме.
[2] Арфа — чиертеп уйный торган кыллы музыка коралы.

1847 елның 23 августында университет ишегалдындагы мәйданда Державинга һәйкәл ачу тантанасы була. 1870 елда бу һәйкәл Казанның мәдәни үзәге булган Театр мәйданына (хәзерге Ирек мәйданы) күчерелә. Бу тирәләр халыкның яратып ял итеп йөри торган урыны була. Бирегә татарлар да күп киләләр, һәйкәлне «Бакыр бабай», «Алтын бабай», аның тирәсендәге бакчаны «Бакыр бабай бакчасы» дип атый торган булганнар.

1769 елда Казан гимназиясендә татар теле укытыла башлый. Екатерина II нең махсус указы белән мөгаллим итеп татар укымышлысы Сәгыйть Хәлфин билгеләнә. С. Хәлфин гимназиядә уналты ел укыта. Аңа губернаның баш тылмачы дигән дәрәҗә дә бирелә. 1778 елда аның «Татар теле әлифбасы» («Азбука татарского языка») дигән грамматикасы Мәскәү университеты типографиясендә басыла. Бу грамматика 20 елдан артык рус уку йортларында татар телен өйрәнүдә бердәнбер кулланма булып килә. Татар басма әлифбасының бай тарихы шушы дәреслектән башлана. С. Хәлфин 20 меңгә якын сүзне туплаган «Татарча-русча сүзлек» тә төзегән.

1800 елда Казан Духовный академиясе янында да татар теле сыйныфы ачыла. XVIII йөз азагы —XIX йөзнең беренче яртысында Казан Россиядәге тюркология фәненең (төрки халыкларның телен, тарихын, фольклорын, әдәбиятын һ. б. өйрәнү) үзәгенә әверелә.

Казанда «Азия басмаханәсе».

XVIII йөзнең азакларына таба Казан, Уфа, Оренбург һ. б. губерналарда яшәүче татарлар, Коръән, догалыклар, мәктәп-мәдрәсәләр өчен уку китаплары җитмәвен әйтеп, кулдан күчерелгән һәм Төркиядән кайтарылган китапларның кыйммәт торуын искәртеп, басмаханә ачарга рөхсәт сорап, үтенечләр яудыралар. Шуларның нәтиҗәсе буларак, 1785 елда Петербургтагы фәннәр академиясе янында «Азия типографиясе» эшли башлый. 1787 еллар тирәсендә казна хисабына гарәп хәрефләре белән Коръән басыла. Бу басмаханәдә чыгарылган беренче татарча китаплар — С. Хәлфиннең улы, гимназия укытучысы Исхак Хәлфин тәрҗемә иткән закон җыентыклары була (1785).

Император Павел I, 1799 елда «дини китаплар һәм догалыклар» бастыру өчен, Казанда татар типографиясе ачарга рөхсәт бирергә мәҗбүр була. Бер елдан соң бу хакта Сенат указы да чыга.

1800 елның көзендә Петербургтагы «Азия типографиясе»ннән Казан гимназиясенә ике станок һәм хәрефләр кайтарыла. Бу эшләрне озак еллар патша армиясендә хезмәт итеп,

прапорщик дәрәҗәсендә отставкага чыккан Габделгазиз Туктамыш улы Бурашев башкара. Ул Казандагы беренче татар типографиясенең эшен оештырып җибәрүдә зур тырышлык куя.

Сенат указы белән Петербургтан Казанга китап басу остадлары — наборщик Гали Рәхмәтуллин һәм корректор Хәмзә Мамышев та җибәрелә. Басмаханә 1800 елның декабрендә эшли башлый. Традиция буенча, аны да «Азия типографиясе» дип атыйлар. 1801—1802 елларда анда басылып чыккан беренче китаплар, мәктәптә укырга өйрәтү өчен, әлифбалар һәм «Һәфтияк» була. «Һәфтияк» — Коръәннең җидедән бер өлеше — әлифбадан соң укыла торган дәреслек рәвешендә файдаланылган һәм шулай ук еш басылган.

Төрки-татар телендә нәшер ителгән беренче матур әдәбият әсәре сезгә таныш — «Сәйфелмөлек кыйссасы» (1807 елда басыла). Шигырь белән язылган, «Мең дә бер кичә» әкиятләрен хәтерләткән фантастик бу поэмада чын мәхәббәт идеалы хакына төрле кыенлыкларны җиңеп чыккан каһарманнар сурәтләнә. Бу кыйсса халыкта күп таралып, яратып укылган дөньяви эчтәлекле әсәрләрдән була.

1809 елда Казан университетында да типография ачыла. Анда шулай ук татар китаплары басыла. Бу типографиядә басылган беренче китап гимназия укытучысы Ибраһим Хәлфиннең татар теле дәреслеге була. 1829 елда «Азия басмаханәсе» университет типографиясе белән берләштерелә. Шушы вакыттан башлап гасырның 80 нче елларына хәтле татар китапларының күпчелеге университет типографиясендә чыгарыла.

Казанда XIX гасыр башында эшли башлаган татар типографиясе безнең халыкта гына түгел, гомумән, барлык төрки халыклар арасында, төрекләрдән кала, беренчеләрдән була. Ул башка төрки халыкларга аң-белем бирүдә дә зур роль уйный. Университет типографиясендә «Хуҗа Насреддин мәзәкләре» (1845), «Кисекбаш кыйссасы» (1846), Таҗеддин Ялчыголның «Рисаләи Газизә» (1850), татар әдәбиятыннан беренче хрестоматияләр, XIX йөз татар әдипләренең күп кенә әсәрләре дөнья күрә. Гасыр урталарында инде татар китапларын басучы берничә хосусый типография дә ачыла.

Шул рәвешле, бу гасырның беренче яртысында ук әдәбият үсү өчен бик әһәмиятле мөмкинлекләр ала. Электәге әдәби ядкярләр һәм бу гасырда иҗат ителгән күренекле әсәрләр халык арасында басма рәвештә күпләп тарала. Димәк, XIX йөз татар әдәбияты, Борынгы һәм Урта гасырлар әдәбиятыннан

аермалы буларак, инде кульязма әдәбият тугел, ә басма әдәбият буларак үсә. Шул ук вакытта әсәрләрне кулдан күчерү традициясе дә дәвам иткән.

Казан университеты һәм татар укымышлылары. Мәскәү һәм Тарту университетларыннан кала, Россиядә өченче булып ачылган Казан университеты Идел буе-Урал-Себер төбәкләрендә яшәгән халыклар тормышына якты бер нур булып керә. Казан уку-укыту округына җитәкчелек итү, халык мәгарифен җәелдерү эшләре дә яшь университетка йөкләнә. Ул чакта бу округ Идел буйларыннан Ерак Көнчыгышка кадәр зур территорияне били торган була.

Дөнья фәненә зур өлеш керткән галимнәр — бөек математик Н. И. Лобачевский, астроном И. М. Симонов, химиклар Н. Н. Зинин һәм А. М. Бутлеров — бу университетта тәрбияләнеп, соңыннан шунда ук гыйльми-педагогик эш алып баралар. Биредә күренекле язучы С. Т. Аксаков һәм даһи сүз рәссамы Л. Н. Толстой укый. Кара реакционер М. И. Магницкий кебек кайбер чиновникларның университетта казарма тәртипләре урнаштырырга тырышуларына карамастан, бу уку йортында хөр фикер һәм ирек атмосферасы хөкем сөргән.

Университетның беренче укытучыларыннан татар кешесе Нигъмәт Ибраһимов (1778—1818) Н. И. Лобачевский, С. Т. Аксаков һ. б. күренекле кешеләрнең остазы була. Ул, Казанда беренчеләрдән булып, Туган тел һәм әдәбиятны сөючеләр җәмгыятен оештыра, аны җитәкли, үзе дә шигырьләр яза.

Университетта Көнчыгыш телләре бүлеге ачыла һәм анда татар телен укыту кертелә. Профессорлар И. Н. Березин, А. К. Казембек, Х. Д. Френ, Карл Фукс һ. б. галимнәр Идел буе халыкларының, шул исәптән татар халкының, тарихына, этнографиясенә, фольклорына, язма әдәбиятына караган материалларны җыя, өйрәнә, бастырып чыгара башлыйлар. Университетка эшкә тартылган прогрессив карашлы татар укымышлылары үсеп чыга.

Шундыйлардан без иң элек **Ибраһим Хәлфин** (1778—1829) исемен зур хөрмәт белән искә алабыз. Алдынгы карашлы Ибраһим Хәлфин, туган теленнән тыш, гарәп, фарсы, рус, төрек, латин телләрен яхшы белгән. 22 яшендә I Казан гимназиясенең татар классына укытырга билгеләнә. 1805 елда ул, Казанда беренче буларак, шушы ук гимназиядә гарәп һәм төрек телләреннән дә дәресләр бирә башлый. Университетта татар теле буенча лекцияләр укый. 1823 елда аңа, татарлардан

беренче буларак, адъюнкт-профессор (профессор ярдәмчесе) дигән гыйльми-педагогик дәрәҗә бирелә. Укыту белән бергә, ул зур фәнни эшләр дә алып бара.

И. Хәлфин, халыкта сакланган кульязма тарихи-әдәби әсәрләрне табып, редакцияләп, аңлатмалар белән бастырып чыгаруга зур тырышлык куя. Ул төзегән «Әхвале Чыңгыз хан вә Аксак Тимер» дигән тарихи-әдәби хрестоматия 1822 елда басыла, университетта дәреслек итеп кулланыла. И. Хәлфин, шулай ук Урта Азия тарихчысы Әбелгази Баһадур ханның «Шәҗәрәрә әт-төрек» («Төрки халыкларның нәсел-ыру шәҗәрәсе», 1824) китабын бастырып чыгара. Соңгысы рус, немец, француз телләренә дә тәрҗемә ителә. И. Хәлфиннең бу һәм башка хезмәтләре рус галимнәре арасында гына түгел, Европада да зур кызыксыну тудыра.

И. Хәлфин татар халкын мәгърифәтле итү хакында борчылып уйланган, бу эштә университет студентларын файдалану мөмкинлеген күргән. 1819 елда ул «Татарларны мәгърифәтле итү» проектын эшли. Университет советы бу башлангычны хуплый. Ләкин Казан уку-укыту округы башлыгы Магницкий аны кире кага. Әмма җәмәгатьчелектә татар яшьләренә дөньяви белем бирү, мәктәпләр ачу, мәгърифәт тарату фикере сүнми.

Сәгыйть Исхак, Ибраһим исемнәре «мәгърифәтче Хәлфиннәр династиясе» дип тарихка керде.

Университетта укыткан татар галимнәреннән **Мөхәммәдгали Мәхмүдов** (1824—1891) эшчәнлеге —мәгърифәт һәм мәдәниятебез тарихында шулай ук якты бер сәхифә. Ул Казан өязе Мәмдәл волосте (хәзер Татарстанның Арча районы) Сөләнгер авылында крестьян гаиләсендә туа. Казан мәдрәсәсендә укыганда, аны университет профессоры А. Казембек һ. б. галимнәр күреп алалар һәм, гарәпчә искиткеч матур язуына, каллиграфия осталыгына, белеменә сокланып, университетка укытучы итеп урнаштыралар. Шул рәвешле, күп тырышлык куеп, крепостной коллыктан азат ителүенә ирешәләр.

Мөхәммәдгали Мәхмүдов университетта гарәп каллиграфиясенә өйрәтү белән бергә, татар, төрек, гарәп телләрен дә укыта. 1857 елда «Татар телен өйрәнүгә практик кулланма» дигән грамматика дәреслеге басыла. Халыкны агартуны күздә тотып, ул, русчадан тәрҗемә итеп, фәнни-популяр брошюралар да чыгара.

М. Мәхмүдов әдәбият, мәдәният, мәгърифәт үсеше өчен принципиаль әһәмияте булган зур мәсьәләне күтәрә. Аның фикеренчә, язма әдәби тел татар халык массаларына аңлаешлы

булырга, халыкның җанлы сөйләм теленә нигезләнергә тиеш. И. Хәлфин хыялланган дөньяви мәктәпләр булдыру, татарларга рус телен өйрәтү турында эзлекле кайгыртып, М. Мәхмүдов Казанда «Татар учительләр мәктәбе»н оештыру һәм ачуда (1876) актив катнаша, аның беренче инспекторы була.

Казан гимназиясендә һәм университетында белем алган **Габдүш Ваһапов** та (1814—1876) төп игътибарын халыкның сөйләм телен өйрәнүгә, фольклор әсәрләрен җыюга биргән. 1852 елда университет типографиясендә басылган «Русско-татарская азбука» дигән китабына кушымта итеп ул күп кенә хикәятләр һәм 30 җыр урнаштыра. Бу кулланма русча өйрәнүче татарларга, татарча өйрәнүче русларга «Үз-үзидән өйрәткеч» («Самоучитель татарского языка») дип исемләнгән.

1855 елда Казан университетының Көнчыгыш телләре бүлеге укытучы-профессорлары һәм студентлары белән Петербург университетына күчерелә. Әмма җирле халыкларның телен өйрәнү тукталмый, бу эшне тарих-филология факультеты галимнәре дәвам иттерә. 1878 елда Казан университеты каршында «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте» төзелеп, аның эшендә А. Соловьёв, И. Готвальд, Н. Катанов кебек күренекле тюркологлар, татарлардан К. Насыйри, Ш. Мәрҗани, Г. Ильяси, Ш. Әхмәров һ. б. мәгърифәтче галим һәм әдипләр актив катнашалар, шушы җәмгыятькә әгъза итеп сайланалар.

Бу традицияләр Казан университетында 1944 елда ачылган татар теле һәм әдәбияты бүлегендә, 1989 елдан татар филологиясе, тарихы һәм Көнчыгыш телләре факультетында, Шәрык институтында (2000) дәвам иттерелә.

Иҗтимагый-фәлсәфи фикердә яңалыклар.

Патша хөкүмәтенең көчләп чукындыру, руслаштыру, милли-колониаль изү сәясәте нәтиҗәсендә татарларда мәдәни-рухи, әдәби үсеш авыр шартларда барды. Әмма XVIII гасыр азаклары — XIX йөз башларындагы феодаль йомыклык шартларында да татар җәмәгатьчелегендә яктылык чаткылары бар иде. Прогрессив карашлы мөселман укымышлылары, әдипләр иҗади эзләнү, яшәү, алга таба хәрәкәт итү фәлсәфәсен алга сөрделәр, дөньяви прогрессив идеологиягә йөз тоттылар. Кешенең белемле, һөнәрле, иҗади фикерле булуын якладылар.

Мәсәлән, тормышы һәм иҗаты XIX гасырда дәвам иткән **Габдерәхим Утыз Имәнинең** (1754—1834) идеалы — мәгърифәтле, һөнәрле, күңелендә иман нуры булган галим кеше. Г. Утыз Имәни, татарлар өчен рус телен өйрәнүнең әһәмиятен

ассызыклап: «Русиядә тереклек кылучы мөселманнар өстенә йөкләнә торган фарызлар кырык бер, кырык беренчесе — русча белмәктер»,— дип әйтә торган булган.

Г. Утыз Имәнинең замандашы **Габденнасыйр Курсави (1776—1812)** акылга, иҗади фикергә ирек таләп итеп чыга. Ул Казан өязендәге Курса авылында дөньяга килә, үз якларында мәдрәсәдә укыгач, Бохарага китә. Көнчыгыш телләрен, дини тәгълиматны өйрәнә. Күп нәрсәне үзлегеннән укый. Мәдрәсә тәртипләре, андагы укыту белән килешә алмый. «Туры юлга өндәү» («Әл-иршаде лил-гыйбад») дигән гарәпчә китабында ул үзләрен галим санап йөргән туң фикерле руханиларны кискен тәнкыйть итә. Кешенең үз акылы белән ирекле фикер йөртү хокукын яклый. Аның кыю, мөстәкыйль фикерләре консерватив руханиларны тәмам ярсыта. Алар аны динсезлектә гаеплиләр. Бохара әмире Хәйдәр хозурында диспут, хөкем мәҗлесе оештыралар. Әмир үлем җәзасы белән яный. Бу җәзадан Г. Курсави туган иленә качып кайтып котыла. Зур мәдрәсә ачып, шәкертләр җыеп укыта башлый. Ләкин аерым реакцион руханилар аңа монда да тынгы бирмиләр, өстеннән язып торалар. Г. Курсави 1812 елда хаҗ сәфәре вакытында Төркиянең Искедар шәһәрендә ваба (чума) авыруыннан үлә.

Курсавиның рационализмны яклаган карашларын гасырның икенче яртысында Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Р. Фәхреддин кебек мәгърифәтчеләр үстерәләр. Мәгърифәтче шагыйрь Мифтахеддин Акмулла Г. Курсавины зур хөрмәт белән искә ала.

Әдәбияттан хрестоматияләр.

XIX йөздә мәгърифәтчелек әдәбияты формалашу юлында яңа бер баскыч буларак, әдәби хрестоматияләр басыла башлый. Шундыйларның берсен Оренбургтагы Неплюев хәрби училищесында татар теле укытучысы Мартиниан Иванов төзи (1812 елда туган). Аның «Татар грамматикасы» һәм «Татар хрестоматиясе» дигән китаплары 1842 елда Казан университеты типографиясендә дөнья күрә.

М. Иванов, гади халыкка аңлаешлы әдәби телне алга сөреп, татар телен кирәкмәгәнгә гарәп-фарсы сүзләре белән чуарлауга каршы чыга. Хрестоматиянең 1 нче кисәгендә халык иҗаты әсәрләренә зур урын бирелә: анда 127 мәкаль, 70 җыр, 34 табышмак, күп кенә хикәятләр һәм әкиятләр урнаштырыла. Мәкальләр тәрбия һәм акыл бирү характерында. Арада социаль эчтәлеклеләре дә бар. Төзүче мәкальләрнең шигъриятле яңгырашына да игътибар иткән.

Сылу сылу күренмәс,
Сөйгән сылу күренер.

Яхшы белән юлдаш булсаң, җитәрсең морадка,
Яман белән юлдаш булсаң, калырсың оятка.

Сүз токымы — колактан, су токымы — болактан...

Җырлар бик нечкә әдәби-эстетик зәвык белән сайланганнар. Төзүче иң элек туган илгә багышланган җырларны урнаштырган, аннан соң гыйшык-мәхәббәт һ. б. темаларга караган җырлар тезелеп китә. Җаек, Сакмар, Агыйдел сулары бу җырларга үзенчәлекле җирле төсмер бирә.

М. Иванов татар әдәбияты өчен яңа бер тәрәзә ача: рус әдәбияты әсәрләрен татарчага тәрҗемә итү тәҗрибәсен башлый. Проза белән тәрҗемә итеп, 17 мәсәл урнаштыра. Аларның күпчелеге И. А. Крыловтан алынган. Беренче тәрҗемәләр арасында **И. И. Панаевның** (1812—1862) «Иван Костин» повесте гади халык тормышын чагылдырган реалистик әсәр буларак аерым әһәмияткә ия. Повестьта авыл кешеләренең тормышы, хезмәте, шатлык-кайгылары сурәтләнә. Башкалада ташчы булып эшләгән крестьян егете Иван тырышлыгы, уңганлыгы, әхлакый сафлыгы, ярдәмчеллеге кебек күркәм сыйфатлары белән ачыла. Аның сөйгән кызы Дуня да шундый сыйфатларга ия. Бәхеткә иң элек алар хаклы. Ләкин ул замандагы реаль шартлар, акча хакимлеге, җирле түрәләрнең башбаштаклыгы аларның кавышуына киртә булып төшә, фаҗигале язмышка китерә.

Икенче бер хрестоматияне Оренбургтагы Неплюев кадет корпусында укытучы **Салихҗан Кукляшев** (1811—1864) төзи. Ул әлеге хәрби мәктәптә укый һәм Казан университетын тәмамлый. «Диване хикәяте татар» («Татар хикәятләре җыентыгы») исемле 124 битле хрестоматиясе 1859 елда Казан университеты типографиясендә басыла.

Кереш мәкаләсендә ул татар язма телен өчкә бүлеп карый: гади тел, эш теле һәм гыйльми тел. Гади тел сөйләүгә бик якын һәм укый-яза белүче һәр татарга җиңел аңлашыла. Эш теле гади тел белән гыйльми тел арасында урта урынны алып тора. Гыйльми тел гарәп телен яхшы белүчеләргә генә аңлаешлы. Шул нигездә ул хрестоматиясендәге материалларны да өч өлешкә бүлеп урнаштыра: I — мәкаль сүзләр, хикәятләр һәм әкиятләр; II — эш кәгазьләре, язышу үрнәкләре; III — шигъри текстлар; Ә. Каргалый, Һ. Салихов һ. б. шагыйрьләрнең әсәрләре, төрек шагыйре Әхмәдинең «Искәндәрнамә» поэмасыннан аерым бүлекләр.

Бу хрестоматияләрдә татар мәгърифәтчелек әдәбиятында үсеп китәчәк сыйфат һәм үзенчәлекләр — тарихка һәм фольклорга, халыкның җанлы сөйләменә игътибар, Шәрык һәм рус әдәбиятлары белән бәйләнеш ачык күренә.

Сораулар һәм биремнәр

1. XIX йөзнең беренче яртысында Россиядә булган тарихи вакыйгалар һәм аларда татарларның катнашуы.
2. 1812 елгы Ватан сугышының халык иҗатында чагылышы.
3. Татарча китаплар басыла башлауның һәм Казанда университет ачылуның әһәмиятен ничек аңлыйсыз?
4. Мәгърифәтче Хәлфиннәр династиясе хакында сөйләгез.
5. Г. Курсави эшчәнлеге кайсы ягы белән игътибарга лаек?
6. М. Иванов һәм С. Кукляшев хрестоматияләре ничек төзелгән? Аларның татар мәдәниятендә тоткан урыны нәрсәдән гыйбарәт?

ПОЭЗИЯ

XIX йөзнең беренче яртысы татар әдәбияты, бер яктан, Урта гасырлар әдәбияты, икенче яктан, капиталистик үсеш, яңарыш белән бәйле. Әби-бабаларыбыз яратып укыган, каткат басылган «Мәликә китабы» (1845), «Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз» (1856) һ. б. хикәят китапларында белемле һәм һөнәрле булуның файдасы, сәүдә итүнең дә мөһим бер шөгыль икәнлеге, яхшы ният белән эшләнгән гамәлләрнең саваплы булуы күрсәтелә.

Бу чор поэзиясендә дә төп ике юнәлеш күзгә ташлана. Берсе — дини-суфичылык йогынтысындагы тармак. Бу юнәлешнең күренекле вәкилләре — Әбелмәних Каргалый, Һибәтулла Салихов, Шәмседдин Зәки. Икенче юнәлеш исә дөньяви-реалистик характерда. Бу тармакның иң күренекле шагыйре — Габделҗәббар Кандалый.

Әбелмәних Каргалый (1783—1833).

Әбелмәних Әбелфәиз углы Габдессәлам Каргалый Оренбург Каргалысында (Сәгыйть бистәсендә) туа. Башта Каргалы мәдрәсәсендә, аннан соң Бохарада укый. 1816—1817 елларда Бохара әмиренең илчелеге составында Төркиягә бара, Мисырда, Гарәбстанда хаҗ сәфәрендә була. «Әбелмәних хаҗи тәрҗемәләре» дигән китабында борынгы изгеләр, күренекле суфилар тормышыннан алынган, шигырь белән язылган хикәятләр, сәяхәтнамә һәм лирик мөнәҗәтләр урнаштырылган. Бу әсәрләрендә шагыйрь комсызлыкка, мал-мөлкәт туплауга, кешене иманыннан яздыручы начар гамәлләргә каршы чыга,

фәкыйрьләргә ярдәм итәргә, юмарт һәм кешелекле булырга чакыра. Мөнәҗәтләрдә дөньяның ышанычсызлыгы, кешене өметләндереп һаман алдавы, гөнаһка батыруы турында сөйләнә. Мал һәм дәрәҗәләргә кызыкмаска өнди.

«Мөхәммәд байга», «Кибай байга» язган шигъри хатларында автор дөнья малына масаеп кәпрәйгән байларны тәнкыйть итә. Аны җәмгыятьтәге гаделсезлекләр, кешеләр арасындагы тигезсезлек борчый. Мөхәммәд пәйгамбәргә багышланган мәдхиясендә шагыйрь Рәсүлнең ролен халыкны әдәплелеккә өйрәтүдә, мәрхәмәтлелек, изге күңеллелек чыганагы булуда күрә. Азакта үзенең Алладан һәм пәйгамбәрдән үтенеп сораган теләген белдерә: «Бу гарипне коллары (ягъни кешеләр) капкасын кагарга мохтаҗ итмәсә иде». Әмма шагыйрьнең иң зур үтенече — «барча өммәт», халык турында. Аның идеалы — кешеләр тигез тормышта яшәгән гадел җәмгыять.

Бер үк вакытта ул дөньядан кул селтәгән шагыйрь түгел. Сәяхәтнамәсендә җир йөзенең киңлегенә, хозурлыгына сокլана.

Үкенмә үткәнгә, киләчәк өчен хәсрәт чикмә син:
Йөреп җирнең күп илләрен, тамашасын күрдең син[1]! —

ди ул үз-үзенә тирән канәгатьләнү белән.

Шагыйрь, ватанын сагынып, туган иленә кайта. Ватанны ярату тойгысын иман белән бергә куя:

Туган илне сагыну һич китми икән,
Кайтам илемә, аңа җитми икән,
Ватан мәхәббәте иманнан ул...

Автор сәяхәтнамәсенең азагында гыйлемгә дан җырлый:

Бер көе генә тормас дөньяның эше:
Бер югары, бер түбән булыр кеше.
Бетмәс дәүләт булыр камил гыйлем генә,
Мал-дәрәҗә бер килер дә бер китәр.

Әбелмәних Каргалый иҗатында гыйшык-мәхәббәт һәм туган ил табигатен яратып сурәтләгән пейзаж лирикасы да урын ала.

Һибәтулла Салихов (1794—1867). Һибәтулла Сәетбаттал углы Салихов Оренбург губернасы Чебенле авылында мулла гаиләсендә туа. Бабасы бу якларга Чистай өязеннән күчеп килгән була. Һибәтулла, мәдрәсәдә укыгач, Чебенледә, аннан соң Каргалыда мулла һәм мөдәррис

[1] Шигырьләрдән өзекләр хәзерге әдәби телгә күчерелеп бирелә.

булып тора, ишанлык дәрәҗәсе ала. Ризаэддин Фәхреддин аны: «Матур сүзле, туры җаваплы, түбәнчелекле, йомшак вәгазьле, нәсыйхәте тәэсирле бер кеше булган»,— дип тасвирлый.

Декабристлар восстаниесеннән соң илдә урнашкан реакция шартларында шагыйрьне җәмгыятьтәге гаделсезлекләр, кешеләрнең бозык эш-гамәлләре борчый. Рухани җитәкче буларак, ул халык алдында зур җаваплылык тоя. «Ничә төрле теләкомтылышларым бар, тормышка ашырырга мөмкинлек юк»,— дип әрни. Күңелен ялгызлык, ризасызлык һәм хәсрәт тойгылары били: «Кайда кулдаш?.. Кайда юлдаш?Моңа әвәрә булып баш, күңел гамь, хәсрәт белән тулы»,— дип белдерә. Реакция заманын тасвирлауда шагыйрь зәһәрле елан образын куллана.

Урта гасырларда бер шагыйрьнең популяр әсәренә, аның рифма-ритм калыбына салып, идея-тематикасын үзенчә үстереп, икенче бер шагыйрьнең нәзыйрә язу гадәте булганлыгын сез инде беләсез. Бу традицияне дәвам иттереп, Һибәтулла Салихов та Әбелмәних Каргалыйның «Җиһанның җаһ-малы...», «Тәндә җаным ничә көн миһман[1] икәндер, белмәдем» кебек мөнәҗәтләренә нәзыйрәләр иҗат иткән. Бу мөнәҗәтләрдә дөнья эшләре һәм чын иман, рухани тормыш белән яшәү берберсенә каршы куеп сурәтләнә, дөнья эшләренә артык бирелеп китүгә үкенү белдерелә. Иң кирәге — укымышлылар, мәгърифәтле кешеләр мәҗлесе, изге гамәлләр кылу, ди шагыйрь. Бу әсәрләр бик популяр булганнар, мәдрәсә шәкертләре аларны яттан көйләп йөргәннәр.

Һ. Салиховның зур күләмле төп әсәре —1839 елда язылган «Мәҗмәгыл-адаб» китабы («Әдәпләр турындагы җыентык»). Заманы өчен шактый калын (144 бит) бу китап беренче мәртәбә 1856 елда чыгарыла, шуннан соң күп тапкырлар басыла. Кереш өлешендәге мөнәҗәтләрдән күренгәнчә, дини һәм дөньяви тойгылар конфликты шәхес буларак уянган лирик геройның йөрәген телгәли. Шагыйрь күңеле белән, үзе дә сизмәстән, дөнья эшләренә, аның ләззәтләренә тартылуын, хәтта гыйбадәт вакытында да бөтен барлыгы белән Аллага бирелә алмавын, догаларының да тышкы бер мәҗбүрият төсендә үтәлүен, тыштан гына «төзек» булып күренүен ачынып сөйли.

Китапның төп өлешендә шагыйрь күбесенчә дини этикага өйрәтә. Иллюстрация рәвешендә шигъри хикәятләр урнаштыра. Кешене тәрбияләү, аны туры, изге юлга күндерү мәсьәлә-

[1] Миһман — кунак.

сендә бик сак килергә, шәхесне кимсетмәскә, хәтта крепостной колга да кеше итеп карарга чакыра:

Улдыр Габдулла[1], гәрчә булса мөлля[2],
Үзене күрмәя һичкемнән әүля[3],
Әгәр ул кол исә, бу булса азат,
Кәрәк мөлля, кәрәк бәк яки мир[4] зат.

«Кеше йөзен ертып» хурлау, мәсхәрәләү кире нәтиҗәгә генә китерергә мөмкин. Кешенең асылы, рухы нурлы җәүһәр кебек. Шушы җәүһәр пычракка буялган икән, аны игътибарсыз калдырмыйча, рәхимлек күрсәтеп, йомшаклык белән сак кына алып, ягымлылык кулъяулыгы белән сөртсәң, ул янә ялтырап, балкып китәр.

Кеше тумыштан бозык булып тумый икән, каян килә соң аңа начар сыйфатлар?Аны чолгап алган тормыштан, җәмгыятьтән йога, ди автор. Шул рәвешле, шагыйрь әхлак, тәрбия хакында фикер йөртүдән **шәхес** һәм **тирәлек мәсьәләсенә** килеп чыга. Ә бу исә үзе зур яңалык — **әдәбиятта реализм принцибының аваз бирүе иде.**

«Сүз монда бик мөһим» дип искәртеп, шагыйрь кешенең иҗтимагый бәйләнешләрен, конкрет-тарихи шартларны, үз заманы җәмгыятен анализлый. «Замана халкын» сыйнфыйсоциаль яктан өч катлауга бүлә: 1) патша чиновниклары, аристократ түрәләр —«әмирләр»; 2) «төлке толыплылар» — малмөлкәтле урта катлау; 3) фәкыйрьләр.

Автор гади халыкның, крестьяннарның авыр хезмәт белән мохтаҗлыкта көн күрүен, залим түрәләр тарафыннан җәберләнүен ачынып тасвирлый. Фәкыйрь кешенең теңкәсенә тигән яман якларны нәфрәт белән фаш итә.

Халык массаларын, башлыча крестьяннарны буйсындырып тоту өчен, илдәге зур бюрократик идарә аппараты чиновниктүрәләр хакимиятен урнаштырган иде. Патша чиновниклары халыкны, бигрәк тә рус булмаган халыкларны талап баюда бернинди чик-чаманы белмәгәннәр. Һәркайда башбаштаклык, ришвәтчелек тамыр җәйгән.

Халыкның патша түрәләреннән ризасызлыгы беренче нәүбәттә фольклорда, җыр-бәетләрдә яңгыраш тапкан. Һәм

[1] Габдулла — Алла колы, чын изге кеше.
[2] Мөлля — укымышлы кеше, мулла.
[3] Әүля — өстенрәк, артыграк.
[4] Мир — әмир.

бу, бик гомуми төстә булса да, Г. Утыз Имәни, Ә. Каргалый әсәрләрендә дә күренә. Түрәләрнең явызлыгын тәфсиллерәк итеп тасвирлау алга таба нәкъ менә Һибәтулла Салихов китабында зур урын ала.

Ул үзе күпмедер вакытлар тоткынлыкта — Тозтүбәдә — тоз кисү эшләрендә була. Оренбург шәһәренә якын яшәгән шагыйрь хакимият башлыкларының явызлыкларын күреп тә, үз җилкәсендә татып та, ишетеп тә торган. Ул аларны астыртын чагучы агулы еланга охшата.

Бер-бер хатаңны күрсәләр, аны алдан уйлап эшләгәнгә санарлар, тузаннан чебен, чебеннән каракош ясарлар, төпченүләреннән максат — акча җыю, һич тә мәзлумнарга ярдәм итү түгел, ди автор. Кулларына алтын-көмеш тамса, җинаятьчене аклап чыгаралар.

Һ. Салихов авылларга килгән түрәләрнең халыкны деспотларча куркытып торуы, кычкыртып талавы турында сөйли.

«Замана әфәнделәре» — хәлле катлау кешеләре — «биреп ришвәт, симертәләр әмирне». Аларның бу явыз түрәләр белән якыннан аралашуы да реалистик планда сурәтләнә. Зур рухани буларак, шагыйрь мондый кешеләрне: «Залим — Ходаның дошманыдыр, залимне сөйгән мөселманның динендә, һичшиксез, кимчелек булыр, ул залимнәрне ут кебек күрергә кирәк, якын барсаң, үзең дә янарсың»,— дип кисәтә. Әмма моның капма-каршысы буларак: «Аларга дуслык итми ни чара? Көн саен эшең-йомышың төшеп тора, дөнья кирәкләре мәҗбүр итә»,— диләр.

Һ. Салихов иҗатында җәбер-золымга, хокуксызлыкка каршы халык күңелендәге нәфрәт, чын иманлы камил кеше, тигезлек, гадел җәмгыять, әдәп һәм иман берлеге идеяләре ачык чагыла. Шагыйрьнең үгет-нәсыйхәтләре хикмәтле сүз рәвешендә күңелгә уелып керә. Мәсәлән:

...Аяксызга аяк бул,
Олуг юлдан адашканга маяк бул.

...Гомердә күрмәсәң аш,
Кешегә салма ризыгың, кыйлма сер фаш.

Олуг димә, кечек димә, би кибар[1],
Нә кем гаҗизне[2] күрсәң, әйләгел яр[3].

---

[1] Би кибар — горурланмыйча, кәпрәймичә.
[2] Гаҗиз — көчсез, зәгыйфь, фәкыйрь.
[3] Яр — сөекле кеше, якын дус.

Әдәпсезлеклә[1] иман бергә тормас,
Әдәп берлә имансыз һәм бакый[2] калмас.

Шәмседдин Зәки (1821—1865). Шәмседдин Ярмөхәммәд углы Зәки (Гобәйдуллин) көчле рухлы лирик шагыйрь һәм газәл остасы буларак билгеле. Аның шәхси тормыш юлы да үзенчәлекле. Ул Оренбург өязендә Зәк суы буендагы Зәк-Ишмәт авылында (хәзерге Башкортстан) дөньяга килә. «Зәки» дигән әдәби псевдонимы да шуңа бәйле. Әдәбият тарихында аны Зәки Суфи дип тә атыйлар.

Тумыштан ике күзе дә сукыр булуга карамастан, Шәмседдин зирәклеге, хәрәкәтчән һәм көчле ихтыярлы булуы, белемгә омтылуы белән аерылып торган. Үз якларындагы авыл мәдрәсәләрен тәмамлагач, ул Казанда укый, укытучы дәрәҗәсенә күтәрелә. Белеме, сәләте, мөстәкыйль фикер йөртүе, бәхәскә осталыгы белән таныла. Хәтта үзен мәдрәсәдән куалар. Шәмседдин аптырап калмый, туган авылына кайтып, мәдрәсә ачып укыта башлый. Монда да аңа каршы чыгучылар табыла. Шәмседдин, шәкертләрен ияртеп, атаклы Эстәрлебаш мәдрәсәсенә күчеп китә. Тиз арада күп шәкертләрнең яраткан остазына әверелә. Алар арасыннан Гали Чокрый, Мифтахеддин Акмулла кебек күренекле шагыйрьләр чыга. Акмулла белән Ш. Зәки еш кына бергәләп сахрага чыга торган булалар. «Нәүбәтләшеп,— дип искә ала Акмулла,— һәртөрле әдәби шигырьләрне әйтеп, эчләребезне бушатып, күңелләребезне күтәреп, сорур[3] хасыйл кылып кайтадыр идек». Гали Чокрый остазы турында болай дип яза:

Үзе тома сукыр күзгә,
Зирәклеге чыккан йөзгә,
Галим һәм оста сүзгә.

Эстәрлебашта дүрт ел укыткач, авылдашларының үтенечен тыңлап, гаиләсе һәм шәкертләре белән шагыйрь янә Зәккә кайта. 1865 елның сентябрендә хаҗ сәфәренә барганда, Таганрог шәһәрендә үлеп кала.

Ишеткәнне истә тоту, укыганны яттан белү җәһәтеннән Ш. Зәки сирәк кешеләрнең берсе була. Коръәнне, гарәп һәм фарсы телләрендә мәдрәсәләрдә укыла торган китапларның күпчелеген ул яттан белгән, бу телләрдә үзе дә шигырьләр

---

[1] Әдәпсезлеклә — әдәпсезлек белән.
[2] Бакый — мәңгелек.
[3] Сорур — шатлык, күңеллелек.

иҗат иткән. Шәрык классик поэзиясе — Низами, Руми, Хафиз, Нәваи кебек шагыйрьләрнең әсәрләре белән яхшы таныш булган. Шигырьләрен телдән иҗат итеп, әйтеп яздырган. Төрле кул эшләрен дә оста башкарган, хәтта ватык сәгатьләрне сүтеп җыя, төзәтә икән.

Ш. Зәки классик суфичылык традицияләрен Идел-Урал буе татар поэзиясендә яңарта. Аның әсәрләрендә җәмгыятьтәге гаделсез тәртипләр белән килешә алмаган, үз юлында нык торучы, мөстәкыйль фикерле шәхес уянуы сизелә. Шагыйрь дөньяны яхшырта алмавына ачына:

Ничек күңел бирим соң бу дөньяга? —
Никадәр төзесәм дә, һаман хәрабә хәлендә.

Аны дөньядан бизү һәм Аллага омтылу тойгылары били. Дөньяви тормыш кешене аздыручы, нәфес коллыгына этәрүче булса, Алла үзендә рухи сафлык, хаклык, гаделлек, рәхим-шәфкатьлелек кебек гүзәл сыйфатларны туплаган зат, өлге, шагыйрь ирешергә омтылган абсолют идеал рәвешен ала.

Кинаяле гыйшык — Аллага карата кайнар мәхәббәт тойгыларын гүяки җир кызына булган сөю хисе кебек итеп тасвирлау — суфи шагыйрьләрнең яраткан поэтик алымы. Бу үзенчәлек Ш. Зәкинең «Тәкать, сабырым калмады...» дип башланган газәлендә дә ачык чагыла. Илаһи мәхәббәт авторның бөтен барлыгын тулысынча биләп алган гаять көчле һәм кайнар тойгы буларак тасвирлана. Шагыйрь: «Җан сөйгәнем ул гына, үзгә яр белән нишлим мин..., гүзәллегең күңелемә тәэсир иткәннән бирле..., аны уйлау дәрьясына баткан күңел..., калмады һичбер өметем синнән бүтән кемсәдә..., зарыгып көтәм, канлы күңелемә бер караш ташла, бер сине генә беләм мин, синнән гайре ярым калмады», — ди. Беренче карашка, бу сүзгыйбарәләр гадәттәге мәхәббәт шигырен хәтерләтә. Әмма алар бер сылу кызга карата түгел, ә фәкать Алланы күздә тотып әйтелгән. Әсәрнең гомуми рухы һәм фикер агышыннан моңа төшенү кыен түгел.

Шагыйрьнең «сөйгәне, яры» белән кавышуга киртә булып торучы дошман — күңел азгынлыгы, нәфес. Сугышып, шул нәфесемне үтерсәм, сиңа бару юлыма каршы төшкән башка дошманым юк минем, ди.

Кешедәге кимчелекләр, җәмгыятьтәге бозык һәм начар яклар якты идеалга кискен каршы куелып тәнкыйтьләнә. Бәхеткә ирешү җиңел түгел. Кеше тынгысыз, хәрәкәттә булырга

тиеш. Шагыйрь, боларны сурәтләгәндә, табигать образларына да мөрәҗәгать итә:

Сафа[1] вә нигъмәтә ирмәклек өчен,
Җәфа вә михнәтә түзмәк кирәкдер...
Исеп җил дик, агып су дик, тәмамәт,
Бу юлда ут кеби кызмак кирәкдер.

Кеше үз гомерен ничек уздыруы, кылган эш-гамәлләре өчен үзе җаваплы:

Нә кылса — аны күрер адәм углы,
Нә иксә — аны урыр...

Гомер чикле, вакытлы:

Чөн бу тормакның соңы — китмәк дорыр,
Һәм бу барлыкның соңы — бетмәк дорыр.

Ваемсызлык йокысында изрәп ятмаска чакырып, шагыйрь риторик эндәш, сорау, өндәү кебек интонация чараларын куллана:

Һай, нә оерсән[2]?!— Уян! Йөз мең хәтәр җаныңдадыр!
Күңлеңе гыйшык илә дөргез кем, үлем — яныңдадыр.

Шуңа күрә, изге гамәлләр, яхшы эшләр кылып, явызлыкка бирелмичә, үзара ярдәмләшеп яшәргә кирәк. Фәлсәфи характердагы мондый фикерләү яшәү һәм үлем темасына багышланган «Булгай-булмагай» шигырендә дә гәүдәләнә. Шагыйрь кешеләрне кул кушырып утырмаска, дөнья гизәргә, актив эшчәнлеккә, бер-береңә ярдәм итешеп, матур итеп яшәргә чакыра:

Бу җиһанның шәһренең базарының сәүдәсе күп,
Кыл бу сәүдәне, янә базары булгай-булмагай.

Ат сәнең астыңдадыр, йөргел, бу җирнең хәдден ал[3],
Нагяһан[4] ул ат сәнең астыңда булгай-булмагай.

Та терек[5] сез, дусларым, бер-береңә гыйззәт[6] кылың,
Ваһ, бу үлем! Үзгә дәм[7] нагяһ булгай-булмагай.

---

[1] Сафа — рәхәтлек, яхшы кәеф.
[2] Нә оерсән?! — Ник йоклыйсың?!
[3] Хәдден ал — чигенә чык.
[4] Нагяһан — кинәт, көтмәгәндә, берчак.
[5] Та терек — исән чакта.
[6] Гыйззәт — кадер-хөрмәт.
[7] Үзгә дәм — үзгә мизгелдә, тиз вакытта.

Шигырьгә килеп кергән карчыга образы да тирән мәгънәле. Сине тыңлаучы карчыга кулыңда чакта, ягъни тазалыгың, ихтыяр көчең бар вакытта күңелеңне аздыргыч нәрсәләрдән гел тазартып тор, иң элек нәфесеңне аула.

Автор үз-үзенә: «Хафиза!» (китапларны яттан белүче шагыйрь) дип эндәшеп, исән чакта нәфис-татлы сүзләреңне әйтеп калырга ашык, дигән мәгънәдәге строфаларны да бирә:

Хафиза! Ширин кәлам[1] сүзлә телең(нең) барында,
Нагяһан килсә әҗәл, тел сүзгә килгәй-килмәгәй!

Г. Тукай Ш. Зәкине борынгы шагыйрьләребез тәсбих тезмәсенең «Мәрьям анасы» (ягъни иң зур төймәсе) дип атаган. Әдәбият белгече Гали Рәхим дә: «Даһилык дәрәҗәсендә истигъдадлы[2] лирик булганлыгын бер дә тартынмыйча әйтергә мөмкин»,— дип яза.

Күргәнебезчә, Ә. Каргалый, Һ. Салихов, Ш. Зәки үзләренең чыгышлары, яшәгән урыннары белән бер тирәдән. Аларны Көньяк Урал-Оренбург төбәге шагыйрьләре дип атарга мөмкин. Шигырь белән бер-берсенә хатлар, нәзыйрәләр язышканнар. Иҗатларында уртак яклар да байтак: дөньядан бизү, Аллага мәхәббәт кебек мотивлар зур урын ала. Яшәү — үлем, яхшылык кылу — гөнаһка бату, изгелек — явызлык кебек капма-каршы төшенчәләр актив кулланыла. Үлем образы яхшы, гадел яшәүгә өндәү вазифасын үти. Әҗәл кылычы һәрвакыт баш өстендә тора, гомереңне кинәт, искәртмәстән өзеп ташлавы мөмкин, шуңа күрә яшәүнең һәр мизгелен изге, яхшы эш-гамәлләргә бирергә кирәк. Шул ук вакытта мондый мәсьәләләрне яктыртуда шагыйрьләрнең һәркайсы үзенә хас образлар белән эш итә.

Бу шагыйрьләрнең теле шактый чуар, хәзерге укучыга авыр аңлаешлы.

Феодализм торгынлыгыннан акрынлап булса да ояну, яңару чорында яшәгән әлеге шагыйрьләрнең иҗаты катлаулы, каршылыклы. Бер яктан, аларның иҗаты борынгы Көнчыгыштан, Урта гасырлардан килә торган дини-суфичылык әдәби традицияләре белән бәйләнгән булса, икенче яктан, мәгърифәтчелек әдәбиятына йөз тота, шуңа килеп ялгана. Аларның әсәрләрендә **кешенең шәхес буларак уянуы, замана хәлләре**

---

[1] Ширин кәлам — татлы сүз.
[2] Истигъдадлы — талантлы, сәләтле.

белән актив кызыксынуы, феодаль тәртипләрне тәнкыйть итүе, тигезлек идеяләрен алга сөрүе ачык сизелә. Уянган шәхеснең дөньяви уй-хисләр белән януы XIX йөзнең урталарына таба аеручa Г. Кандалый әсәрләрендә күренде.

Сораулар һәм биремнәр

1. Ә. Каргалый иҗатындагы төп жанрлар. Әсәрләрендәге яңалыклар нидән гыйбарәт?

2. Мөнәҗәт жанры. Ә. Каргалый һәм Һ. Салихов мөнәҗәтләрендә дөнья куу һәм рухи пакьлеккә омтылышның бирелеше.

3. Һ. Салиховның «Мәҗмәгыл-адаб» китабында әхлакый тәрбия, шәхес һәм тирәлек мәсьәләләре, патша түрәләрен тасвирлау.

4. Ш. Зәки лирикасында төп мотивлар.

5. Газәл жанры турында белгәннәрегезне искә төшерегез. Ш. Зәкинең үзенчәлекле образлары.

6. «Кинаяле гыйшык» төшенчәсен ничек аңлыйсыз? Ш. Зәкинең «Тәкать, сабырым калмады...», «Булгай-булмагай» шигырьләрен идея-эстетик яктан анализлагыз.

7. Ә. Каргалый, Һ. Салихов, Ш. Зәки иҗатларындагы уртак һәм аермалы якларны күрсәтегез.

Габделҗәббар Кандалый
(1797—1860)

Тормыш юлы. Татар поэзиясенең дини-суфичылык йогынтысыннан дөньяви-реалистик юнәлешкә, халыкчанлыкка таба борылышында Г. Кандалый иҗаты зур роль уйнады. Габделҗәббар Габделмәҗид улы Кандалый элекке Самара губернасы (хәзерге Ульяновск өлкәсе Иске Майна районы) Иртуган авылында мулла гаиләсендә туа. Бу авылны әүвәл Иске Кандал дип тә йөрткәннәр. Шагыйрьне Кандалый дип атау шуннан килә.

Габделҗәббарның бабалары Сембер шәһәреннән 80—90 чакрым ераклыктагы Каракитә авылыннан (хәзер Татарстанның Чүпрәле районы). Каракитәдән җиде генә чакрымда — Бизнә, аның янәшәсендә Чокал авыллары. Бөек мәгърифәтче галим Шиһабеддин Мәрҗанинең бабалары да (әнисенең әтисе һәм бабасы) шушы авылларда яшәгәннәр, мулла булып торганнар. Күрәсез, Г. Кандалый белән Ш. Мәрҗанине билгеле бер дәрәҗәдә якташлар дип тә әйтергә мөмкин. Шагыйрь үзе дә бер шигырендә: «Безнең мелла җиде бабадан бирле бер дә өзелмичә килгән»,— дип яза. Әтисе гадәти авыл мулласы гына түгел, ә «Габделмәҗид Болгари» исеме белән китаплар да язган шактый зур укымышлы, абруйлы кеше була.

Халык хәтерендә сакланган истәлекләргә караганда, Габделҗәббар урта буйлы, җиңел сөякле, хәрәкәтчән, бик зиһенле, сүзгә тапкыр, үткен, ачы телле, туры сүзне кемнең кем булуына карамастан кистереп әйтүчән була. Шуңа күрә ул иске фикерле мулла һәм ишаннар белән тыныша алмаган.

Габделҗәббар башта үз авылында әтисеннән укый. Аннан соң Мораса (Чистай якларындагы), Кизләү, Кышкар, Оры, Шонталы һ. б. мәдрәсәләрдә белем ала. Шигырьләрен дә мәд-

рәсәдә укыганда яза башлый. Тынгысыз табигатьле, мөстәкыйль фикерле, иске тәртипләр белән килешә алмаган яшь егет кайбер мәдрәсәне үзе ташлап китә, кайсыберләреннән аның үзен куып чыгаралар. Шулай да табигый сәләте, тырышлыгы нәтиҗәсендә ул күп нәрсәне үзләштерә. Мәдрәсәдә алган белемен, гарәп, фарсы телләренә осталыгын күреп, аны шәкертләргә дәрес бирергә куйганнар. Бу телләрне яхшы белү Габделҗәббарга бай Көнчыгыш әдәбияты хәзинәләренә дә юл ачкан. Ул шулай ук классик төрки әдәбиятны, «Кыйссаи Йосыф», «Кыйссаи Сәйфелмөлек» кебек әсәрләрне тәэсирләнеп укыган. Мондый дастан-поэмалардагы образларны алга таба үзенең иҗатында яратып куллана.

Авылда үсеп, халык белән аралашып торган мәдрәсә шәкертләре авыз иҗаты әсәрләрен, җыр-бәетләрне куен дәфтәренә теркәп, җыеп барганнар, үзләре дә чыгарганнар. Мондый дәфтәрләр белән Габделҗәббар да таныш була, җыр-бәет, мөнәҗәтләр үрнәгендә үзе дә шигырьләр яза.

Шул рәвешле, шагыйрь өйрәнгән чыганакларның берсе — гарәп, фарсы, төрки телләрдәге әдәбият — классик язма поэзия булса, икенчесе — халыкның үз иҗат чишмәсе — мәкаль-әйтем, образлы гыйбарәләргә бай җанлы сөйләм теле, җырлары, бәетләре.

Шагыйрь шулай ук рус, чуваш, мордва халыклары белән аралашып яшәгән һәм аларның телләрендә дә җиңел аңлашкан. Мәҗлесләрдә үтенсәләр, берничә тел сүзләрен катнаштырып шигырь әйтеп бирә торган булган.

Габделҗәббар да 1824 елда, Иртуганга кайтып, муллалык итә башлый. Гөлстан исемле кызга өйләнә, бер-бер артлы биш баласы була. Муллалык вазифасын үтәү, балалар укыту белән бергә, ул игенчелек, бакчачылык, умартачылык белән дә шөгыльләнгән.

Иген икмәк бирер икмәк,
Белеп иксәң бирер күпләп,—

дип әйтә торган булган. Җирнең күңелен, хәтерен таба белергә, яхшылап ашларга, эшкәртергә киңәш иткән.

Шагыйрь табигать кочагына, урман, болын, кырларга чыгарга яраткан. Күршедәге Олы һәм Кече Кандал дигән рус авылларына да еш барып йөргән. Иртуган белән бу авыллар арасындагы сукмакны әле дә «Габделҗәббар сукмагы» дип атыйлар.

Байлар, түрәләр алдында тәлинкә тотмаган Габделҗәббар хәзрәт иске фикерле муллалар белән дә тыныша алмаган. Бик дәрәҗәле кешеләр булган мәҗлесләрдә дә үзен иркен, бәйсез тоткан, бер дә тартынмыйча, чәнечкеле шигырьләрен әйтә торган булган.

Дошманнары: «Ул динсез, тәүфыйксыз, халыкны шәригать юлыннан яздыра, әллә нинди шигырьләр яза»,—дип каныкканнар, аның абруен төшерергә тырышканнар. Хәтта волостьтагы рус түрәләренә әйтү, язып бирү белән янаганнар, бәлки шулай эшләгәннәрдер дә. Шагыйрь түрәләргә карата да кыю сүзләрен ярып әйткән:

Килсен җөмлә, берәр түрә волостьтан,
Курыкмыйм мин вә дәхи ки урыстан.

Әтисе үлгәч, Габделҗәббарның дошманнары тагын да кыюланалар, 1841 елда аны муллалыгыннан алалар. Әмма авылда шагыйрь яклы кешеләр дә күп була. 1843 елда, яңа мәхәллә ачып, аны янә мулла итәләр.

1848—1849 елларда улы Садреддин солдатка алына. Солдатта 25 ел хезмәт иткәннәр. Инде картаеп барган ата кеше бу аерылуны бик авыр кичерә, сагыну һәм сагыш тулы шигырьләр яза. Улы да әтисенә шигырь белән хатлар язган.

Дошманнарының өстән язуы аркасында, шагыйрьгә тоткынлыкта да булырга туры килә. Бер китапның азагында ул: «Зур авырлыклар күрергә, ике ел буена төрмәләрдә утырырга туры килде, шулвакыт менә бу китапны яздым»,— дип теркәп куйган.

Г. Кандалый 1860 елның май аенда 63 яшендә вафат була. Соңгы елларда аның каберенә зур гранит таш куелды.

Башлангыч иҗаты.

Г. Кандалыйның иҗат эшчәнлеге шәкертлек чорында башлана. Яшь егет авыл кызларына шигъри хатлар юллый. Мәдрәсәләрдә дини-дидактик әдәбият һәм суфичылык рухындагы әсәрләр күп укылган. Кандалый да шушы традицияләрдә тәрбияләнгән. Шуның нәтиҗәсе буларак, үзе дә дини-әхлакый юнәлештә үгет-нәсыйхәт бирүче поэма язган. Әсәренең исемен «Рисаләи-л-иршад», ягъни «Тугры юлга күндерүче китап» дип атаган. Поэма керештән, 28 бүлектән һәм йомгак рәвешендә урнаштырылган «мөнәҗәт»тән гыйбарәт.

Керештә автор «вәгазьләр бабын» ачуын, бу вәгазьләргә игътибар белән колак салырга кирәклеген төшендерә, нәрсәнең

яхшы, нәрсәнең начар икәнлеген аңлау өчен, гыйлемле булырга чакыра:

Җәһаләтлек — яманлыкдыр,
Бере аның наданлыкдыр...

Гыйлемле булып бәхеткә ирешү надан крестьянның кул хезмәте белән михнәт чигүенә каршы куела:

Иген икмәк вирер икмәк,
Мәшәкькать-лә михән[1] чикмәк;
Гыйлемлек мәкъсудә[2] йитмәк,
Һәр ике дөньяда әйкан[3].

Кара эш белән җәфа чигүче крестьян («мажик») һәм укымышлы мулла тормышын капма-каршы куеп сурәтләү Кандалыйның җитлеккән чор иҗатында да урын алачак.

Поэманың беренче бүлегендә автор сабыйларга, икенчесендә исә яшь җилкенчәкләргә үгет-нәсыйхәтләр бирә. Сабыйлык көннәреңдә гел уенга-шаяруга мавыгып, егет чакларыңда азып-тузып, исереп йөрсәң, гомерең бозыклыкта үтәр, картлыгың үкенечле булыр, ди. Күңелеңне югары тотма, явызлык эшләмә, шайтан коткысына бирелмә, гөнаһлы эшләрне ташла, кече яшьтән Аллага буйсынып, гыйбадәт һәм яхшы гамәлләр кыл, олысы-кечесенә хөрмәтле, шәфкатьле бул, шул чакта Хода рәхмәтенә лаек булырсың, дип өнди.

Шагыйрь, үзенең балачагында шуклык һәм шаяруга артык бирелгәнлеген әйтеп, моңа үкенеп, минем кебек булмагыз, ди.

Өченче бүлек кызларга нәсыйхәтләрдән тора. Автор аларга әдәпле һәм саф булырга, азгыннардан ерак торырга, үз кадерен үзе белергә, юк-барга кызыгып алданмаска киңәшләр бирә.

Дүртенче бүлек матур, күркәм телле булу, хәзергечә әйтсәк, сөйләм культурасы хакында. Сүзне ачык, матур итеп сөйлә, энҗе чәчелгән кебек булсын, күңелең мәхәббәте, миһербанлыгы — ул телең (сүзең) нәфислеге; тел сөяксез, йомшак булса да, сөңгедән дә яман җәрәхәт ясарга сәләтле, ди шагыйрь:

Яман тел һич кемгә бирмә,
Дәхи гайбәт кылып йөрмә.

Бишенче — сигезенче бүлекләрдә ирләргә һәм хатыннарга вәгазьләр сөйләнә, булдыксыз ирләр һәм ирләрен рәнҗетүче

---

[1] Михән — михнәтләр.
[2] Мәкъсудә — омтылган теләкләргә.
[3] Әйкан — ап-ачык.

яман хатыннар тәнкыйтьләнә. Автор тормыштагы әхлаксызлык күренешләренә борчыла.

Алдагы бүлекләрдә дини-суфичылык китапларында күп әйтелгән фикерләр кабатлана: фани дөнья бик тиз үтә, аның кызыкларына алданмаска, ахирәткә якты йөз белән бару өчен, юлга «азык», ягъни изге эш-гамәлләр булдырырга кирәк, әҗәл угы гомерне кинәт өзәргә мөмкин.

Шайтан («иблис ләгыйнь») коткысына бирелмәү турында автор һәр бүлектә диярлек кабатлап тора. Унынчы бүлектә аның аздыргыч сыйфатларына махсус туктала. Бу образ электә язма әдәбиятта шактый еш кулланылган. Г. Кандалый иҗатында без аның белән янә очрашачакбыз. Ә хәзер кыска гына төшенчә бирик. Коръәндә язылганча, Алла беренче кешене — Адәмне — туфрактан яраткач (барлыкка китергәч), барлык фәрештәләргә дә аның алдында баш иярга боера. Фәрештәләрнең һәммәсе, Адәмгә хөрмәт күрсәтеп, баш ияләр. Тик Иблис (Газазил) кенә, мин аңардан затлырак, дип, Адәм алдында сәҗдә кылудан баш тарта. Тәкәбберлеге өчен каргалып, күктән җиргә сөрелә, тәмуг газапларына хөкем ителә. Ул — кешеләрне аздырып, изге юлдан яздырып, Аллага каршы котыртып йөрүче, җеннәр, шайтаннар башлыгы, имеш.

Гомерен шайтан коткысына бирелеп уздырган кешенең үкенечле картлык көннәрен тасвирлагач, автор «теге дөнья» хәлләрен бәян итә: үлем, ахырзаман җиту, сират күперен кичү, оҗмахтагы рәхәт-ләззәтләр, тәмуг газабы.

Ахырда китерелгән мөнәҗәттә шагыйрь, янә җир тормышына кайтып, җәмгыятьтәге реаль тәртипләргә, гаделсезлеккә ризасызлыгын белдерә.

Күргәнебезчә, поэмада дөнья һәм ахирәт хәлләре бергә үрелә, дини дидактика дөньяви рух белән өртелеп бирелә.

Дини-суфичылык карашларында торган әдипләр үрнәк булырлык уңай идеалны күп очракта борынгы изгеләр тормышында күргәннәр. Көнчыгыш әдәбиятларында аеруча киң таралган һәм популяр булган образларның берсе — Ибраһим Әдһәм. Риваятьләргә караганда, ул VIII гасырда Ирандагы Бәлех[1] патшасы булган. Таҗын-тәхетен ташлап, суфи-дәрвиш булып китә, бөтен гомерен Аллага табынуга багышлый. Аның турында төрле поэмалар, дастаннар иҗат ителгән.

---

[1] Бәлех — Әфганстанның төньягындагы шәһәр.

XIX йөз татар поэзиясендә бу образга Әбелмәних Каргалый мөрәҗәгать итә. Хикәятендә ул төп игътибарны Ибраһимның суфилык юлына кергәндә кичергән михнәт-газапларына юнәлтә. Тәхетен ташлап киткән патша унҗиде ел буена, аркасы белән күтәреп, урманнан утын ташый — шәехкә хезмәт итә, аны куалар, кыйныйлар һ. б. Ниһаять, изгелек юлына ихлас күңелдән бирелгәнлеген күреп, шәех аны мөритлеккә кабул итә. Әнә бит чын изгелек нинди булган, дип Әбелмәних үз заманының ялган суфи һәм руханиларын кискен тәнкыйтьли.

«Ибраһим Әдһәм кыйссасы»нда[1] Г. Кандалый бу образны үзәккә куя, баштагы биш бүлектә аның белән бәйле вакыйгаларны бәян итә. Әмма Кандалый тудырган образ икенче төрлерәк. Ибраһим инде «җитлеккән» суфи-дәрвиш кыяфәтендә, илләр гизеп йөргән хәлләрдә сурәтләнә. Беркөнне Ибраһим мәгърифәтле һәм гадел булуы белән танылган Һарун әр-Рәшид иленә килеп чыга. Караңгы төшеп, шәһәр капкасы ябылганга күрә, тышта кунарга кала. Төнге сакчылар сәләмә киемле бу кешене, карак дип тотып, падишаһ каршына китерәләр. Сораша-сөйләшә торгач, патша, бу дәрвишнең акылына һәм тапкырлыгына сокланып, табынга чакыра, үз янында калырга кыстый. Әмма Ибраһим патша тәкъдим иткән ризыктан да, патша янында калудан да баш тарта, иректе, мөстәкыйль булып, юлын дәвам итә. Бәйсезлек идеясен Г. Кандалый поэманың ахырында да искә ала, «солтанга якынлык — җанга бәла» дип кисәтә.

Илләр гизеп йөргәндә, Ибраһим төрле маҗараларга очрый. Шундыйлардан янә берсенә тукталыйк. Бер мәҗлескә туры килеп, ул казый янына ук менеп утыра. Начар киемле бу йолкыш картны, хурлап, орышып, түбән дәрәҗәлеләр, ярлылар янына казый куып төшерә. Ул арада мәҗлестә көчле бәхәс куба, телләренә нәрсә килсә, шуны әйтешәләр, әтәчләр кебек сугышыр дәрәҗәгә җитәләр. Бәхәсне казый да чишә алмый. Бу низагны, «энҗе-гәүһәр чәчкәндәй» акыллы сүзләре белән, арткы рәттә утырган Ибраһим хәл итә. Барысы да мактап алкышлыйлар. Оятлы булган казый, хәтта башыннан затлы чалмасын салып, аңа кидерә. Дәрвиш карт исә: «Башыма куйма аяк чолгавын!» — дип җавап кайтара. Кешенең кадере мал-мөлкәттә, олуг дәрәҗәләрдә түгел; һичнәрсәгә кызыкмаган күңел генә

[1] Табылган кулъязмада әсәр тулы түгел, баштагы, уртадагы һәм азактагы күп кенә битләре югалган. Поэманың исеме шартлы рәвештә алына.

җәннәткә юл таба, алтын-көмеш, затлы киемнәр бик шәп булса да, алар берни тормый, дип сөйли. Янә үз юлына китә.

Ибраһим Әдһәмне автор үз-үзен хакимнәрдән бәйсез хис итүче, иманында нык торучы, гадел һәм хикмәт иясе итеп тасвирлый.

Шуннан соң шагыйрь, мәдрәсәдән мәдрәсәгә күчеп йөргәндә, үзе белән булган төрле маҗаралы хәлләрне сурәтләүгә күчә.

Ничек уйлыйсыз, бәлки ул Ибраһим Әдһәм белән үзе арасында билгеле бер охшашлык, уртаклык та күргәндер? Икесенең дә, хакыйкать эзләп, белем эстәп, ил гизүләре, үз-үзләрен бәйсез, мөстәкыйль тотулары кебек охшаш сыйфатлары шундый уйларга да этәрә.

Яшь Кандалый иҗатында тормышта үзе күзәткән күренешләрне реаль сурәтләү киң чагылыш таба. Бу ул кулланган тел-сурәтләү чараларында да ярылып ята. Гарәп-фарсы сүзләре белән бик нык чуарланган язма телдән шагыйрь фразеологизмнарга гаҗәп бай халыкчан телгә йөз тота.

Бу үзгәреш аның мәдрәсәдә язган «Мулла белән абыстай» шигырендә үк бик ачык күренә.

Ул заманда татар халкының укымышлы катлавын, нигездә, руханилар, муллалар тәшкил иткән. Аларның күпчелеге яшь буынга белем һәм халыкка әхлакый тәрбия бирү юлында зур тырышлык куйганнар. Бу укымышлыларның аң-белем таратудагы фидакяр эшчәнлеге күтәрелеп-оешып килүче татар мәгърифәтчелегенең бер үзенчәлеге булып тора. Шул ук вакытта муллалыкны, суфилык һәм ишанлыкны кәсепкә әверелдергән, денем өчен түгел, көнем өчен дигән принцип белән яшәгән руханилар да булган. Мондый руханиларны Г. Утыз Имәни, Ә. Каргалый, Һ. Салихов, Ш. Зәки кебек шагыйрьләр кискен тәнкыйтьләгәннәр. Ләкин әле аларның әсәрләрендә бу тәнкыйть гомуми рәвештәрәк булып, конкрет, индивидуаль сыйфатлары белән сурәтләнгән образлар бик күренми иде. Мәдрәсә җанлы Габделҗәббар авыл муллаларының яшәү рәвешләрен якыннан күзәтә һәм, алда әйтелгән шагыйрьләрдән аермалы буларак, халык җилкәсен кимереп ятучы дин әһеленең җанлы сатирик образын тормышчан детальләр белән күз алдына бастыра. Авторның үзе сурәтләгән героена иронияле мөнәсәбәте бик ачык сизелә. Ягъни ул аңа үз итеп, дустанә дәшкән кебек, асылда исә бөтенләй шуның киресе күздә тотыла:

Тотынышып кулың кулга,
Үзең кергән сары тунга,
Кая киттең болай, хәзрәт,
Абыстайны салып уңга?

Хәзрәт уку-укыту эшләре яисә җәмгыять мәнфәгатьләре белән кызыксынып йөрми икән, аның крестьян өенә аш мәҗлесенә барышы:

Үзең түргә утыргансың,
Авызыңны тутыргансың,
Тәгәл кәефне коргансың,
Абыстай утырып уңга.

Шагыйрь мондый мәҗлесләрне муллаларның алдан әйттереп куюлары буенча, авыл агаеның «егермесен сатып унга» чакырырга мәҗбүр булуын да искәртә:

Синең өчен тавык чалган,
Суган, балтырганын салган,
Син әйткәч чакырып алган,
Егермесен сатып унга.

Намазларын да ашык-пошык кына башкаручы, үз вазифаларына кул селтәгән, бар уе ашау-эчүдә булган мондый муллаларның эчке дөньясын да шагыйрь зур осталык белән ача:

Торып иртә битең югач,
Ашык-пошык намаз кылгач,
Берәр ашка баруны сән
Үзеңә зур бәхет сандың[1].

Абыстай берлә икәүләп,
Мужикның сыртын игәүләп,
Тавык, күркә, казын ашап,
Ки кайтып йокыга талдың.

Бу очракта автор төш күрү алымын уңышлы куллана:

Тавык төштә тары күрә,
Синең дә ашларың керә,
Йокыңда сөйлисең нигә:
«Абыстай, чык, кеше керә!»

Муллалыкның һәм яшәүнең бөтен мәгънәсен мәҗлесләргә йөрүдә күргән затны сурәтләүдә, шагыйрьнең икониясе сарказм дәрәҗәсенә күтәрелә:

[1] Сандың — санадың.

Чакыручы түгел икән,
Бу бары төш кенә икән,
Күп ашап, саташып шулай
Төшеңдә сөйлисең икән.

Күп кенә шундый муллаларга хас булган сыйфатларны бер кешегә җыеп, Г. Кандалый сорыкорт руханиларның типик образын тудыра. Крестьяннарда аларга карата ризасызлык туачагын да кисәтә:

Ләкин, мулла, онытма син,
Бу ашларга кызыкма син,
Ки алдыңа сызыкла син,
Мужиклар да бизәр соңра.

Сатирик үткенлеге, реалистик характеры һәм халыкчан тел-сурәтләү чаралары белән бу әсәр Кандалый иҗатында гына түгел, бәлки шул чор татар поэзиясе өчен дә күренекле яңалык булды. Шуңа күрә әлеге шигырь, кулдан-кулга, телдән-телгә күчеп, халык арасында киң тарала да.

Яшь шагыйрь өчен моның нәтиҗәсе дә булмый калмый. Аны мәдрәсәдән куалар. Шул уңайдан язган шигыре яшь кешенең үз язмышы турында борчылып уйланулары характерында талгын һәм салмак рәвештә башлана:

Бу илләрдә[1] торып калсам,
Ярамас кызга күз салсам,
Атамның каргышын алсам...
Качыйм тизрәк бу илләрдин!

Туган илем ерак калды,
Җәяү йөреп сыйрак талды,
Тагы бигрәк йөрәк янды...
Әзәлдәген[2] ник азсындың?

Моңланып уйлана торгач, аның хисләре кайнарлана бара, иске тәртипләр һәм фанатизмга карата ялкынлы протест тойгысы дөрләп кабына; шигъри сөйләм кискен, каты төс ала:

Тарсынма бер дә, китәрмен:
Җен, Иблистән дә битәрмен,
Үз белгәнемне итәрмен,
Ки әгъля-гаршә[3] ашкындым!

---

[1] Илләрдә — бу урында билгеле бер як, төбәк, авыл мәгънәсендә.

[2] Әзәл — башы һәм ахыры булмаган мәңгелек, *монда*: яратылыш, тәкъдир.

[3] Әгъля-гаршә — иң югарыга, күкнең түбәсенә (дини өйрәтмә буенча Алланың тәхете урнашкан иң югары тугызынчы кат — күк).

«Рисаләи-л-иршад» поэмасында ике сүзнең берендә шайтан, Иблис коткысына бирелмәскә өндәгән Кандалый инде бу шигырендә фанатиклар урнаштырган тәртипләргә буйсынмауда үзен җенгә, Иблискә тиңли, хәтта алардан да уздырып җибәрәчәге белән яный.

Ничек уйлыйсыз, бу аның, гомумән, дингә, Аллага каршы чыгуы идеме? Юк, әлбәттә. Бу аның борынгы тәртипләргә, надан фанатикларга буйсынмавы, мөстәкыйль, бәйсез ихтыяр көчен күрсәтүе иде. Ул гаршә әгъляга ашкынуын, ягъни иң биеккә, күкнең түбәсенә, Алланың тәхете урнашкан югарылыкка омтылуын белдерә.

Үзенең кешелек кыйммәтен тойган, **шәхес буларак уянган** яшь кеше, горур кыяфәттә калып, һич тә күңелен төшерми, иҗат дәрте белән яна:

Кусагыз да, һич уфтанмам,
Язуымнан да тукталмам,
Котылмассыз барыбер сез,
Әле болай гына калмам!

Төреп чалма-чапаннарны,
Йөресәм кыр-япаннарны,
Онытмам сез наданнарны,—
Элеп салмыйча һич калмам!

Бу көр тавыш татар поэзиясенең алга таба үсешендә хөр шәхеснең горур авазы, кара көчләргә каршы көрәш, бунтарьлык мотивлары булып яңгырады.

«Сахибҗәмал» һ. б. поэмалары.

Мәдрәсәләрдә укыган вакытларында ук авыл кызларына атап шигырьләр яза башлаган Г. Кандалый иҗатында дөньяви мәхәббәт төп темага әверелә.

Илдә булып узган тарихи вакыйгалар һәм буржуаз мөнәсәбәтләр үсеше белән бәйле иҗтимагый үзгәрешләр кешенең үзенә, аның бу дөньядагы тормышына игътибарны арттыра, дөньявилык белән кызыксыну көчәя бара. Иҗтимагый аң үсеше белән бәйле бу үзгәрешләрне без Г. Кандалыйның үз иҗатында да күрәбез.

Кандалый татар язма поэзиясендә XVII—XVIII гасырларда йомылыбрак калган дөньяви традицияләрне яңарта. Аның шигырьләрендә, «Шәфгый», «Фәрхи», «Сахибҗәмал» поэмаларында кайнар сөю хисе кешенең җанын-тәнен биләп алган табигый олы бер тойгы буларак тасвирлана; сөйгән ярың белән уртак мәхәббәткә корылган гаиләдә тигез һәм бәхетле

гомер итү омтылышы идеал рәвешендә җырлана. Бу теманы эшкәртүдә шагыйрь әдәби традицияләргә дә таяна, Йосыф һәм Зөләйха, Сәйфелмөлек һәм Бәдигыйлҗәмал, Ләйлә — Мәҗнүн, Фәрһад — Ширин кебек образларны мисалга ала, еш кына үзен дә шуларга охшата.

Бер үк вакытта Кандалый, традицияләр кысасында гына калмыйча, новатор буларак эш итә, ягъни ул, классик поэзиянең романтик геройларын үрнәк итеп алса да, аларны кабатламый, ниндидер хыялый дөньяны, патша кызларын, билгесез географик урыннарны, гадәттән тыш хәлләрне сурәтләми, ә реаль тормышның үзеннән алып (Борнай, Парау һ. б.), гади татар авылы кызларын, хезмәт иясе крестьян кызларын тасвирлый. Бу — аның татар поэзиясенә алып килгән зур яңалыгы.

Кандалый — мәхәббәт җырчысы. Аның иң күп язганы — кеше матурлыгы, табигать кочагында үскән, эшчән, сәламәт җир кызы матурлыгы. Күпчелек очракта әле ул — тышкы матурлык. Шагыйрь сөйгәнен, мәсәлән, болай тасвирлый:

Тулган ай дик йөзең матур икәндер,
Ике битең кояш дик нур икәндер.
Кашың кара сызылган күз өстендә,
Яңа ай дик һавада — күк йөзендә.

Татар крестьян кызы, тиңсез биеклеккә күтәрелеп, алдында сәҗдә итәрлек, табынырлык гүзәл зат буларак сурәтләнә.

Кандалыйның лирик герое тышкы матурлык белән мавыкса да, ул сөйгәне белән рухи якынлык, тиңлек эзли. Кызның эчке дөньясы, уйлары нинди? Шагыйрь аны шушы яктан да танып белергә тели, шуңа омтыла:

Күреп ирдем сәнең гөл йөзләреңне,
Ишеттем бал-шикәр дик сүзләреңне.

Дәхи күрдем мөбарәк буйларыңны,
Белалмадым вәләкин уйларыңны!..

Автор кызның укымышлы булуын аның иң гүзәл сыйфатларыннан саный. «Фәрхи» поэмасында мулла өенә сабакка килгән яшь кызлар:

Диделәр: без ишеттек: бер матур кыз,
Үзе галим, укырга бик батыр кыз.

Кандалый үз иҗатында сыйнфый-социаль һәм иҗтимагый-сәяси мәсьәләләрне турыдан-туры күтәрмәсә дә, аның мәхәббәт җырларында тормыш чынлыгы бар. Ул авыл кызлары яшәгән

мохитне, аларны чолгап алган тормыш шартларын реаль сурәтли. «Кара кол тик» шигырендә, «Сахибҗәмал» поэмасында һ. б. әсәрләрендә гүзәл кызның ачы язмышы ышандырырлык итеп тасвирлана. Беренчедән, күпчелек крестьян хатын-кызлары гомер буе мохтаҗлыкта яши. Аларның киемнәре начар, ямалып беткән. Икенчедән, алар, «Камыл эчендә лапырдап, Юеш балчыкта чапырдап», урак урып, көлтә җыеп, авыр хезмәт белән интегәләр. Аларның сәламәтлеге какшый, аяк-куллары яргалана, кышкы салкыннарда туңып-өшеп, бит-борыннары шешеп, тавышлары карлыгып бетә.

Эш эшләп унике аең,
Гомер буең, кышын-җәен,
Сызып бетеп йөрәк маең,
Каның да калмый кашыкка...

Кыскасы, гади татар крестьян кызларының гүзәллеген җырлау, бигрәк тә хатын-кызларның авыр язмышын реаль планда тасвирлаган әсәрләр татар язма поэзиясендә Кандалыйга кадәр юк дәрәҗәсендә иде.

Крестьян агайларның да гомере авыр физик хезмәттә үтүен шагыйрь җыйнак һәм ышандырырлык итеп әйтеп бирә:

Ки көз көне дә кыш көне—
Мажикның бар да эш көне;
Буламы елда биш көне
Тыныч, эшсез, Җәмиләкәй?

Крестьян дәүләт тарафыннан изелә, аның бар тапканы салым түләүгә китә:

Гүяки бер бояр колы,
Боярның әмере аркылы
Эш эшләп, кабарып кулы,
Саладыр акча оброкка.

Шул рәвешле, чынбарлыкка турыдан-туры якын килергә омтылу, крестьяннар яшәгән социаль һәм тарихи шартларны тормышның үзендәгечә дөрес сурәтләү Кандалый реализмының уңышларын тәшкил итә. Ләкин әлегә бу реализмның беркатлырак, башлангыч адымнар гына булуын, бигрәк тә крестьян образын тудыруда шагыйрь-мулланың карашлары каршылыклы һәм чикләнгән булуын да әйтергә кирәк.

Укымышлы аерым муллалар арасында гади крестьянга, аның кышын-җәен кара тиргә батып, тузан-туфракта

казынуына, томаналыгына түбәнсетеп, кимсетеп карау табигый саналган. Кандалый да үзенең муллалыгы, тормышы җитешле, укымышлы, затлы катлаудан булуы белән һавалана. Крестьян, «мажик» образын да ул, нигездә, шушы муллалар позициясеннән торып, көндәше сыйфатында сурәтли. Вакыт-вакыт тупас сүзләр дә куллана. Ләкин, икенче яктан, объектив рәвештә ул крестьянның тиргә һәм кергә батуын да, иске чабата, ертык киемнәрен дә, ашаганы кара икмәк һәм суган, торма булуын да, төтенле «ызба»да яшәвен дә сәнгатьчә конкрет детальләр ярдәмендә күрсәтә.

Крепостной тәртипләр хөкем сөргән ул заманда күп кенә крестьяннарның ярлы булуы гына түгел, надан булуы да хак иде. Дөрес, татарлар арасында укый-яза белү, грамоталылык чагыштырмача югары булган. Әмма яшьлегендә, берике ел муллага сабакка йөреп, азмы-күпме укырга-язарга өйрәнү — ул бит әле укымышлылык түгел. Кандалый төп игътибарын «мажик»ның наданлыгына юнәлтә, наданлыкны кешедәге иң яман сыйфат рәвешендә тасвирлый. «Рисаләи-лиршад» поэмасында ук наданлык һәм гыйлемлелекне кискен каршы куйган шагыйрьнең «Мәгъшукнамә», «Сахибҗәмал» һ. б. әсәрләрендә дә бу антитеза еш кабатланып тора. Наданлык һәм мәдәниятсезлекнең социаль сәбәпләренә төшенеп җитмәгән автор кызларны надан иргә бармаска, яхшы тормышлы муллага, укыган кешегә кияүгә чыгарга үгетли:

Наданга бармагыз, кызлар,
Бу сүзем тыңлагыз, зинһар,
Галим булса да ярыңыз,—
        Моны фәһем итсәнә (уйласана.— *Ш. С.*), җаный!
Наданларга күңел салма,
Аның сүзене дә алма;
Гомерлек хәсрәттә калма,—
        Моны фәһем итсәнә, җаный!

Надан ирне галим муллага каршы куюы, кияү сайлауда акыл белән уйлап эш итәргә өндәве Кандалый иҗатында мәгърифәтчелек идеяләренең аваз бирүе, үзенчәлекле чагылышы иде. Шагыйрь мәгърифәтчелегенең төп үзенчәлеге дә шунда: әлегә ул башлангыч хәлдә, эчтәлеге дә тар һәм чикләнгән. Белемле булу дигәндә, нигездә, дини гыйлем, дин кагыйдәләрен, дога һ. б. ны яхшы белү күздә тотыла.

Шагыйрь иҗатына хас гомуми үзенчәлекләр: җир кешесенең табигый хисләрен җырлау, крестьян кызларын һәм алар-

ны чолгап алган тормышны реаль сурәтләүдәге казанышлар «Сахибҗәмал» поэмасында аеруча калку гәүдәләнә. Башка күп кенә әсәрләре кебек, бу поэма да авторның лирик кичерешләре белән сугарылган хатлар рәвешендә язылган. Ягъни ул — лирик-эпистоляр әсәр.

Баш героинясы — Парау авылының (хәзерге Ульяновск өлкәсе, Мәләкәс районы) гади крестьян кызы Сахибҗәмал. Кандалый үзенең сөйгән кызын, бик югары күтәреп, чын йөрәктән чыккан тирән кичерешләр, кайнар тойгылар белән тасвирлый. Бу кызның чибәрлеге, сылулыгы, исеме-шөһрәте «җәелеп беткән илләрдә». Үзе уку-язуга да бик оста, сөйләшүләре «былбылдай». Шул ук вакытта бу кыз — горур, көчле характерга ия, үз сүзендә нык торучан.

Икенче герой — шагыйрь үзе (мин). Бу образда да гашыйк булган кешенең эчке кичерешләре гаять калку итеп бирелә:

Гөлем бул, гөл егачым[1] бул,
Йә былбыл-сандугачым бул,
Бу дәрдемгә гыйлаҗым[2] бул,
Сахибҗәмал абыстай ла!
Сәнең илә аем-көнем,
Сәнең илә көнем-төнем,
Сәнең илә төшем-өнем
Үтәдер, и абыстай ла!

Бу герой Парау авылына, озын юлларда «елап-сыктап», барып-килеп йөри, ашау-эчүдән кала, ялварып хатлар яза.

Парау илендә төш күрдем,
Ки бер кош тоттым, ук аттым,—
Парау илендә бер матур
Өчен уйкумны[3] югалттым.
Ничә кемсә, ничәләр дә,
Ашыйлар да, эчәләр дә;
Ки бән шул көн-кичәләрдә
Аш үтмичә елап яттым.

Ул үзенең хыялында, сөйгәне белән күрешкән кебек, татлы уйларга бирелә, төшләрендә күреп саташа. Боларны сурәтләгәндә, әсәрдә ягымлы юмор да балкып китә. Төшендә, имеш, кызның авылына очып барып, аның белән кавышып, үзен

[1] Егач — агач.
[2] Гыйлаҗ — чара, дәва.
[3] Уйку — йокы.

оҗмахта шикелле итеп күрә, уянып китсә, почмактагы сәкедә ялгызы ята икән:

> Йөзеңә йөземи сөрдем,
> Синең лә күп сафа сөрдем...
> Уяндым — үземи күрдем:
> Ятамын өйдә почмакда!..

Кызга ул үпкәсен дә белдерә, каргышы белән дә яный, яшь вакытларның тиз үтәчәген искәртә, надан мужикка барудан кисәтә, укымышлы мулла тормышы белән кызыктыра. Әсәрнең аерым-аерым бүлекчәләрендә автор бу ике тормышны, хатын-кыз хәлендә ничек чагылуына карап, капма-каршы итеп сурәтли. Без аларны бергә җыеп, янәшә куеп карыйк.

1. Надан мужикның хатыны көне-төне авыр эш белән интегә, чиргә сабыша.	1. Укымышлы муллада уракка чыгу да юк, киенү, бизәнү-ясану гына. Сәламәтлегенә зыян килми.
2. Аның тамагы ач, киеме начар.	2. Тук, тәэмин ителгән тормыш. Яхшы өй, әйбәт киемнәр.
3. Крестьян басудан арып кайтып йоклый, иркәли-сөя белми.	3. Мулла үзенең хатынына бик тә игътибарлы, кулында гына йөртә, сөюдән һич ялыкмый.
4. Ул бик тупас, хатынын кыйнап та ташлый.	4. Хатынының хәтерен калдырмый, аның турында төрлечә кайгыртып, иркәләп тора.
5. «Кара мажик» намаздан бизгән, язымкка баткан, дин тотуы бөтен түгел. Аңардан туган балалар да бозык, азгын була, гомере җир тырнап я урлашып үтә, «динендә булмый кайгысы».	5. Галимнән туган балалар белемле, динле һәм әхлаклы булып үсәләр, үзең кабердә ятсаң да, догачы булалар.
6. Мондый гаиләне — ирне дә, хатынны да, балаларны да — теге дөньяда мәңгелек ут газабы көтә.	6. Гыйлемлек һәр ике дөньяда максатка ирештерә. Гыйлем иясенең урыны түрдә. Ул, үлсә дә, гүрдә черемәс. Урыны җәннәттә булыр дип аңларга кирәк.

Ике төрле тормышны, шул рәвешле, гомуми планда сурәтләгәннән соң, автор, Сахибҗәмалга гыйбрәт булсын өчен, наданга кияүгә чыккан Борнай авылы кызының ачы язмышын кон-

крет картиналарда тасвирлый. Күз алдына патриархаль гаилә, хатынын теләсә ничек җәберләүче ир, барлык хокуклардан мәхрүм булган, бер кешедән дә ярдәм көтә алмаган хатын образы килеп баса:

Ире бик әйләде каһри, елан кеби сачып зәһри,
Ки тәгъзиб әйләде[1] дәһри[2], булып агъзы тулук кына.
Көне-төне дә сугышты, яла ябып, ләкаб[3] кушты...
Кыйныйдыр иде фәрманга, түзалмый монча дәрманга,
Качып китәрде[4] урманга, йөгерүбән турук[5] кына.

Ире аны, пүнәтәйләр белән барып табып, сүгеп-хурлап кыйный-кыйный, өенә кайтарып яба.

Тотып, чормап сач үрмәсен, ашатты камчы җөрмәсен,
Ки дошманың да күрмәсен,— ки ул икән шул ук кына.
Тәнендин яра китмәде, күзендин кара бетмәде...

Хатын кыйналган саен, күз яшьләрен агызып, авыл старостасына зарланып елый. Әмма боларның берсе дә ярдәм итми. «Сөяген тоз кеби уып, ки борнын кан илә юып», ире аны, аерып, Борнайга куып җибәрә.

Тәмам имгәтелеп ташланган, йөзләре саргайган ана шул авыр хәлендә дә үзеннән бигрәк баласы өчен кайгыра:

И бәбкәм, бала син, диеп, ятим лә каласың, диеп,
Бәне утка саласың, диеп, гомергә, и сынык кына!

Сахибҗәмал — Парау авылының умартачы Сәйфетдин кызы. Кандалый үзенә хатынлыкка алырга күпме генә өндәсә дә, аңа бармаган. Ул күп кенә башка егетләрнең дә йөрәген яндырган. Шуннан соң атасы бу горур кызны үз авылларындагы Пәскә исемле тол иргә хатынлыкка биргән. Сахибҗәмалның андагы тормышы авыр булган дип уйларга кала. Беренче баласы Ногман тугач озак та үтмәстән, Сахибҗәмал 25 яшьтә дөнья куйган.

Шагыйрь, күрәсең, Сахибҗәмалга булган ихлас (мөгаен, бердәнбер!) мәхәббәтен берәүдән дә яшермәгән. Шигъри хатлары, кулдан-кулга күчерелеп, ерак тарафларга таралган. Поэманың азагында китерелгән «кыйтга»ларда (өзек, кисәк,

---

[1] Тәгъзиб әйләде — газаплады.
[2] Дәһри — динсез.
[3] Ләкаб — кушамат.
[4] Китәрде — китәр иде.
[5] Турук — туры ук.

кыска шигырь) Уфа, Казан, Сембер, Сарытау, Түбән Новгород, Оренбург төбәкләре, Чистай, Тәтеш, Буа, Мамадыш, Малмыж, Бәләбәй яклары, Чирмешән буйлары һ. б. урыннар күрсәтелә. Бу очракта шунысы кызыклы: Кандалый, татарлар яшәгән төбәкләрне санап, бергә җыеп, бу халыкны бербөтен итеп күзаллый.

Авторның гади крестьянга карата кимсетүле, кәпрәюле мөнәсәбәте дә яшьрәк чакларындагы иҗаты өчен хас дип уйларга кирәк. Олыгайган, тормышның ачысын-төчесен үзе дә күп татыган, инде «әгъзалары кипкән», «хәлләре китеп, куллары тала» торган шагыйрьнең лирикасында кайгы-хәсрәт мотивлары урын ала:

Каләмем дә тая инде
Ки яза алмый турыдан;
Яна бәгърем, сула йөзем
Авырлыклардин, гуредан[1].

Шагыйрь күңелен кеше язмышы, нинди генә авыр хәлләрдә дә яшәргә омтылу турында фәлсәфи уйланулар били:

Бу тәкъдир дигәнең нидер? —
Изеп, йәнчеп, орыр йиргә;
Бары тыкмасын ук гүргә, —
Китермәсен әҗәлләргә.
Кеше дигән дә мәзлумдыр[2]:
Йөгерер, егылыр, торыр,
Башыны ташлара орыр,
Сөренмим дип әҗәлләргә.

Тел һәм сәнгатьчә сурәтләү үзенчәлекләре.

Дини-суфичылык рухындагы поэмалардан дөньяви-реалистик юнәлешкә юл ярган Кандалый тел-сурәтләү чараларын куллануда да өлгерлек күрсәтте. Ул гарәп-фарсы сүзләре һәм гыйбарәләре белән бик нык чуарланган язма телдән гомумхалык теленә күчүдә зур борылыш ясады. Бу безнең поэзия өчен үзе әһәмиятле казаныш иде.

Шагыйрь, бер яктан, классик поэзиядә гасырлар буе эшкәртелә килгән традицион сурәтләү чараларыннан киң файдаланса, икенче яктан, татар халкының җанлы сөйләм телендәге, җыр-бәетләрендәге, мәкаль-әйтемнәрендәге образлы гыйбарәләрне мул кулланды. Саекмас шушы ике чишмә-

[1] Гуре — (*русча:* горе) кайгы.
[2] Мәзлум — золымланган, изелгән, җәбер ителгән.

чыганак, Кандалый лирикасында бергә кушылып, куәтле ташкын булып агыла.

Бигрәк тә башлангыч чор әсәрләрендә классик поэзиядәге сурәтләрне турыдан-туры күчереп алу («Назме Йосыф»), китапчылык шактый сизелә. Сөйгәненә: **әй нигарем** (гүзәлем, чибәрем) дип эндәшүләр, ләбең (иренең) — **якут, дешең энҗү дезелмеш, тулун ай, көнәш** (кояш), **Ирәм багы** (риваятьләрдә сөйләнгән, Шәрык поэзиясендә еш телгә алынган, гүзәллектә тиңе булмаган бакча) һ. б. традицион образлар күп кулланыла. Шагыйрьнең:

Сачың кара ирер-төндик,
Сачың ара йөзең-көндик,
Улып мән имди Мәҗнүндик,
Идеп гыйшык хыяләти[1],—

дип сурәтләүләре дә классик поэзия хәзинәсеннән алынган.

Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасында, кырым-татар әдибе Гашыйк Гомәр газәлләрендә һ. б. шагыйрьләр иҗатында кулланылган **сәба (таң) җиле** — Кандалыйның иң яраткан образларыннан берсе, һәм ул төрле функцияләрдә килә. Илләр-җирләр гизеп йөрүче, хәбәрләр китерүче, ике арада хат йөртүче, сәламнәр ирештерүче йомшак җил ул.

Сәба йиле, исәр булсаң,
Параү атлыйг нәфис җайга[2],
Сәламемне тикергәйсән
Сахибҗәмал абыстайга!

Шагыйрь сөйгән кызын да иртәнге җилгә охшата; үзе дә таң җиленә утырып очарга хыяллана. Бу образга шагыйрь олыгайган көннәрендә дә мөрәҗәгать итә, улын, туганнарын сагынып, һәр таңда укыган догаларын тапшыруын үтенә.

Табигатьне лирик герой, гомумән, бик тә үз итә. «Йөрәге уттай янганда» ул сахраларга чыгып китә, су буйларында «гаҗаиб яфрагы баллы» талларга карап юана, җан сердәше итеп, кошлар, агачлар белән сөйләшә:

— Әйа агач, яшең күпме?
Түгелгән йимешең күкме?
Минем күк сагышың күпме?—
Диеп сорыйм ки анлардин...

---

[1] Хыяләти — хыялыйларча.
[2] Нәфис җайга — матур, гүзәл урынга.

Яфраклар яшь гомер икән,
Ботаклары бала икән;
Фираклык[1] бер бәла икән,—
Бәгырь өзгән туганлардин.

Ай, кояш, гөл, чәчәк, былбыл, сандугач кебек образлар классик поэзиядә дә, халык җырларында да күп кулланыла. Бу Кандалыйда да шулай. Сөйгәненең матурлыгын, аңа булган мәхәббәтен күңелендә ташып торган хисләр муллыгы белән сурәтләүдә мондый образлар ташкын булып агылып тора:

Ай гынам ла, көн генәм лә, гөл генәм,
Җан гынам ла, тән генәм лә, көн генәм!
Җәүһәрем лә, гәүһәрем лә, нур гынам,
Сәрвием лә, җәннәтем лә, хур гынам!
Ташламачы, ай йөзем лә, гөл йөзем,
Тыңласана, кич Ходайчөн, бер сүзем!..

Сак-Сок, шүрәле, Агыйдел камышлары сурәтләре, әлбәттә, татар халык бәетләре, әкиятләре, җырларыннан килә. Шагыйрь халыкның мәкаль-әйтемнәрен, җанлы сөйләм телендәге фразеологизмнарны-образлы гыйбарәләрне бик яратып куллана. **Уңга ишкәнне сулга сүтү** гыйбарәсен иҗади файдаланып, шагыйрь каршылыклы ситуациягә корылган строфа тудыра:

Бу үзсүзле мишәр, диеп,
Ки бер сүзне бишәр, диеп,
Уңга таба ишәр, диеп,
Ки сан сулга сүтәрмүсән?

Синонимнардан оста файдаланган кебек, ул омоним, ягъни әйтелешләре бердәй, ә мәгънәләре төрлечә булган сүзләрне матур итеп рифмалаштыра:

Бу нидән булды **чи генә**?
Эшем дә җитте **чигенә**,
Сахибем кире **чигенә**,
Исем китәр, и җанкәй лә!

Халык мәкальләре рәвешендә канатлы сүз булып әверелгән, җыйнак һәм акыллы әйтелгән икеюллыкларны да күрәбез. Мәсәлән:

Якутлар табыладыр вакыт берлән,
Вакытлар табылмыйдыр якут берлән.

---

[1] Фираклык — аерым тору.

Кояш образы символик мәгънәдә — өмет, бәхет төшенчәсе буларак та кулланыла:

И кояшым, чыгармусән болытдин?
Алырмусән бәне бу ялкын-утдин?

Алга таба бу образ Г. Тукай лирикасында үстерелә. «Өмид» шигырендә ул болай ди:

Чыкчы, и фикрем кояшы! Китсен өстеңнән болыт;
Бу үлек вөҗданны җанландыр, җылың берлән җылыт!..
Юк, кояшым, мин беләм: син батмагансың мәңгегә;
Син дә вөҗдан, бер торырсың: ятмагансың мәңгегә.

Г. Кандалый татар **шигырь техникасын** баетуга да үзеннән сизелерлек өлеш кертте.

Г. Кандалый әсәрләре халык арасында телдән-телгә ятланып, кулдан-кулга күчерелеп таралган. Кайбер шигырьләре, авторы күрсәтелмичә, аерым җыентыкларда (мәсәлән, С. Кукляшевның «Диване хикәяте татар» хрестоматиясендә, 1859) басылган. Беренче мәртәбә, шагыйрьнең исемен атап, әсәрләрен бастырып чыгаручы мәгърифәтче Каюм Насыйри була. «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият» (1884) китабында ул «Сахибҗәмал», «Фәрхи» поэмаларын һ. б. шигырь текстларын урнаштыра, шагыйрь иҗатына кыскача булса да бәя бирә: «Бу мәзкүр әбъятның (шигырьләрнең.— *Ш. С.)* имля иншасы байтак яхшы төзелгәндер. Шул җәһәтдән игътибар кылынды. Мәрхүм Габделҗәббар — шагыйрь адәм имеш».

Г. Тукайның «Исемдә калганнар»ында язылганча, Кырлайдан Уральскига барганда, Габдуллага беркадәр вакыт Кушлавычта Бәдри абзыйлар өендә торырга туры килә. «Кич белә китаплар актарганда,— дип искә ала Тукай,— кулыма «Фәвакиһел-җөләса...» китабы төшеп, шуны укырга тотындым. Актыктагы шигырьләрен бик яратып укыйм вә аңларга тырышам, фәкать... бу китаптагы оят сүзләргә гаҗәпләнәм вә китапта шундый сүзләр дә була микәнни, дип, үземә сөаль бирә идем». Күрәсез, Габдулла К. Насыйри китабының соңгы бүлегенә урнаштырылган Кандалый шигырьләренә аеруча игътибар итә, яратып, аңларга тырышып укый, әмма «оят сүзләргә» гаҗәпләнә, сәерсенә.

Җамал Вәлиди «Татар әдәбиятының барышы» китабында (1912) Г. Кандалый иҗатын анализлауга махсус бүлек багышлый. Егерменче елларда шагыйрь мирасын барлау эшләре

беркадәр җанлана. Әдәбият белгече Бәкер Яфаров 1947 елда аның җыентыгын әзерли, ләкин бу китап чыкмый кала. Илленче еллар азагында Казан университеты профессоры Хатип Госман шагыйрь яшәгән төбәккә студентлар катнашында экспедиция оештырды. Нәтиҗәдә Г. Кандалыйның шактый әсәрләре тупланган беренче җыентыгы дөнья күрде (*Г. Кандалый.* Шигырьләр, 1960). Казан университеты һәм Татарстан Фәннәр академиясе оештырган экспедицияләрдә шагыйрь әсәрләре теркәлгән байтак кулъязма тупланды. Университет профессоры Миркасыйм Госманов «Рисаләи-л-иршад» һәм «Кыйссаи Ибраһим Әдһәм» поэмаларын, табып, кулланылышка кертте. Аның тарафыннан әзерләнеп, тирән анализ ясалган кереш мәкалә һәм аңлатмалар белән шагыйрьнең беренче зур җыентыгы чыгарылды (*Г. Кандалый.* Шигырьләр һәм поэмалар, 1988). Профессор Мөхәммәт Гайнуллин тарафыннан мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен чыгарылган дәреслекләрдә һәм хрестоматияләрдә шагыйрьнең тормышына һәм иҗатына лаеклы урын бирелде. Шагыйрь мирасын барлау һәм өйрәнү әле дә дәвам итә.

Сораулар һәм биремнәр

1. Г. Кандалыйның тормыш юлы, шәхесенең үзенчәлекле яклары.

2. Шагыйрь иҗатын нинди төп этапларга бүләргә мөмкин?

3. «Рисаләи-л-иршад» поэмасының идея-тематикасы.

4. Ибраһим Әдһәм образын сурәтләүдә Ә. Каргалый һәм Г. Кандалый әсәрләрендәге охшаш һәм аермалы якларны нәрсәләрдә күрәсез?

5. Дөньяви тематикага борылыш Г. Кандалыйның кайсы әсәрләреннән башлана?

6. «Мулла белән абыстай» шигырендәге мулла образына, иске тәртипләргә протест белдергән, шәхес буларак уянган геройга характеристика бирегез.

7. «Сахибҗамал» һ. б. поэмаларының жанр үзенчәлеге.

8. Феодализм дәвере крестьяннарының һәм татар хатын-кызларының авыр тормышы шагыйрь әсәрләрендә ничек гәүдәләнә?

9. Шагыйрьнең сурәтләү чараларын кулланудагы үзенчәлекле яңалыклары.

10. Г. Кандалыйның иҗат мирасын кемнәр өйрәнгән?

11. «Татар поэзиясе үсешендә Г. Кандалый иҗатының әһәмияте» дигән темага инша языгыз.

12. Г. Кандалый әсәрләреннән үзегезгә ошаган шигырьне ятлагыз.

XIX ЙӨЗНЕҢ ИКЕНЧЕ ЯРТЫСЫНДА ӘДӘБИЯТ

(Яңа әдәбиятка күчеш чоры)

Россиядәге феодаль-крепостнойлык тәртипләре XIX йөзнең урталарында тирән кризиска килеп керде. Бу тәртипләр икътисади (экономик) һәм иҗтимагый-социаль үсешне, җитештерү көчләренең алга китешен тоткарлап, буып тора иде. Изелү һәм хәерчелекнең соңгы чигенә җиткән халыкның күтәрелүеннән куркып, патша хөкүмәте реформалар үткәрергә мәҗбүр булды. 1861 елда крепостное право бетерелде, крестьяннар алпавыттан азат ителде. Илдә капитализм кызурак темплар белән үсә башлады.

Халык тормышында икътисади-социаль үзгәрешләр.

Татар халкы да, төрки халыклар арасында беренчеләрдән булып, капиталистик үсеш процессына торган саен, ныграк тартыла. Царизмның милли-колониаль изү сәясәте татар халкының икътисади-мәдәни үсешен тоткарлап килде. Татарларга, сәүдә белән шөгыльләнүгә төрле чикләүләр, киртәләр куелып, завод-фабрика салу, сатып алу, тимерчелек кебек эшләр, гомумән, тыелган иде (рус хөкүмәте татарлар корал ясарлар дип курыккан).

XIX йөз урталарыннан инде татар сәүдәгәрләре сату-алу эшләре белән генә чикләнеп калмыйлар. Алар эреле-ваклы фабрикалар, күн эшкәртү, сабын кайнату кебек эшләр белән шөгыльләнүче предприятиеләр булдыра башлыйлар. Ягъни татар сәүдә капиталы әкренләп сәнәгатькә үтеп керә. Сембер губернасында фабрикант Акчуриннар, Оренбургта сәүдәгәр Гани һәм Әхмәт бай Хөсәеновлар, Көньяк Уралда алтын прискылары хуҗалары Шакир һәм Закир Рәмиевләр (Закир Рәмиев — шагыйрь Дәрдемәнд) гасыр азакларына күренекле милли миллионерлар булып танылалар. Шулай ук Казан, Уфа, Сарытау, Самара h. б. шәһәрләрдә Агишевләр, Дибирдиевләр

кебек фабрикантларны, Үтәгәновлар, Апанаевлар кебек зур сәүдәгәрләрне атарга мөмкин. «Татар сәүдә капиталы... Башкортстан белән Себерне каплады,— дип язды соңыннан Г. Ибраһимов,— һәм Урта Азия белән Европа арасында көньяктан төньякка һәм көнчыгышка таба озын бер буй булып тезелгән шәһәрләрдә сәүдә эшләре бөтенләй диярлек татарга күчте: Әстерхан, Уральск, Оренбург, Орск, Троицк, Кызылъяр (Петропавел), Семипалатинск шәһәрләре менә шул җөмләдән иде».

Авылда да социаль катлаулану көчәя, кулак катлавы күтәрелеп чыга. Авыл кулагы урып-җыю эшләрендә машина куллана, кечкенә булса да кибет ачып, шәһәрдән төрле товарлар кайтара, шәһәр белән авыл арасында элемтә урнаштыра. Элек аерым хуҗалык булып, йомылып яшәгән авыл кешесе үзенә кирәк һәммә нәрсәне диярлек үзе җитештергән, ә хәзер инде әкренләп көнкүрешкә завод-фабрикаларда эшләнгән әйберләр керә бара. Крестьянның яшәү рәвеше дә үзгәрә башлый. Ярлы крестьяннар, бәхет эзләп, тимер юл, завод-фабрика төзелешләренә, Донбасс, Урал, Себер шахталарына китәләр. Мәсәлән, Донбасс шахталарында татарлар 1850 еллардан ук күренә башлый. Авылдан чыккан кешеләрнең белеме, профессиясе булмаганга күрә, алар забойда кәйлә белән күмер чабу, пристаньнарда йөк төяү-бушату, балык промыселларында эшләү, тимер юлда таш ташу кебек иң авыр, кара эшләрдә эшлиләр. Аларның бер өлеше эшләгән җирендә урнашып кала, икенчеләре исә, дөнья күреп, күп нәрсәгә күзләре ачылып, авылга яңа рух, яңа уй-фикерләр белән кайта.

Татар җәмәгатьчелегендә электән яшәп килгән иске тәртипләрдән ризасызлык, демократик уй-фикерләр, аң-белемгә, һөнәр үзләштерүгә омтылыш көчәя.

Татарларда мәгърифәтчелек хәрәкәтенең формалашуы.

Татарлар арасында капиталистик үсеш, Россия һәм чит ил базарларында рус һәм Европа мәдәнияте һәм капиталы белән йөзгә-йөз очрашу, көчле конкуренция эшләрне заманча алып баруны таләп итә. Кайда нинди чимал бар, кайда нинди товар үтә, нәрсә файдалы, нәрсә файдасыз, әйберләрнең сыйфатын ничек күтәрергә — боларны уңышлы башкарыр өчен исәп-хисап эшләрен, рус телен, экономик географияне, химия, физика һ. б. фәннәрне белергә кирәк. Кыскасы, практик эшкә сәләтле белгечләргә зур мохтаҗлык туа. Моңа, икенче яктан, фәкыйрьлектә, караңгы тормышта яшәгән халык массаларының аң-белемгә, һөнәргә омтылышы килеп кушыла.

Ә ул вакыттагы иске тип мәктәп-мәдрәсәләр мондый белгечләрне әзерлиләр идеме?Юк. Схоластикага корылган мәдрәсәләр, нигездә, дин-шәригать йолаларын башкаручы руханиларны, муллаларны гына әзерлиләр иде.

Халыкка көчле йогынты ясап торган руханилар катлавының шактые дини фанатизм һәм феодаль идеология тарафдары иде. Алар тормыш-көнкүрештә, уку-укыту эшләрендә һәртөрле яңалыкка каршы булдылар, иске тәртипләрне сакларга тырыштылар, рус һәм Европа мәдәниятен үзләштерүне, хәрәм дип, кискен кире кактылар. Патша хөкүмәте мондый консерватив көчләрне яклап килде. Чөнки аларның халыклар арасында милли дошманлыкны кабартуы, фанатизмны сакларга омтылуы царизмның «бүлгәлә һәм хакимлек ит» дигән сәясәтенә бик туры килә иде.

Ләкин бу иске кысалар татар халкының икътисади-мәдәни үсеше өчен бик тар иде инде. Яңа тормыш иске феодаль идеологиядәге бозны чатнатты. Яңа фикерләр, идеяләр кайдандыр күктән төшмәде, әлбәттә. Халык тормышындагы икътисади-социаль үзгәрешләр кешеләрнең аң үсешенә, үзгәрүенә китерде.

Мәктәп-мәдрәсәләрне реформалаштыру хәрәкәте башланды. Яшь буынны үз ана телендә укыту, дин белән бергә дөньяви фәннәрне дә өйрәтү, укытуның метод-ысулларын да үзгәртү (иҗек ысулын ташлап, аваз методына күчү, башлангыч сыйныфтан ук язу өйрәтү һ. б.) өчен көрәш җәелде. Бу хәрәкәтне «ысулы җәдит» (яңа нигезләр, яңача ысул) дип атадылар.

Бу хәрәкәт уяну, яңару юнәлешенең бер тармагы — яңалыкларны тормышка ашыра башлау этабы иде. Фанатизмга ябышып, иске тәртипләрне сакларга тырышучыларны —«кадимчеләр» («иске» дигән сүздән), мәктәп-мәдрәсә белән генә чикләнмичә, гомумән, халыкны агарту, аның тормыш-көнкүрешен һәрьяклап яңарту, мәдәниятле итү тарафдарларын «җәдитчеләр» дип йөртә башладылар.

Татарлар һәм, гомумән, төрки халыклар арасында барган уяну, яңару хәрәкәте, асылда, **мәгърифәтчелек хәрәкәте** иде. Мәгърифәтчелек дәверен капиталистик үсеш этабына кергән барлык халыклар да үтә. Көнбатыш Европа илләрендә бу дәвер XVIII гасырда, Россиядә XVIII—XIX йөзләрдә булды. Мәгърифәтчеләр феодаль-крепостнойлык тәртипләрен кискен тәнкыйть иттеләр, халык массаларын бәхетле, таза тормышка чыгарырга омтылдылар, моның өчен халыкны агартырга,

җәмгыятьне акыл, белем һәм югары әхлак нигезендә үзгәртеп корырга тырыштылар.

Сез инде беләсез: татар мәгърифәтчелегенең яралгылары XVIII гасыр азакларында — XIX йөзнең беренче яртысында ук күренә башлый. Феодаль-патриархаль тәртипләргә каршы буржуаз-демократик хәрәкәт буларак, ул әлеге гасырның икенче яртысында, бигрәк тә соңгы чирегендә формалашып җитә. Аның күренекле эшлеклеләре — Ш. Мәрҗани, Х. Фәезханов, К. Насыйри, Р. Фәхреддин кебек галимнәр, фикер ияләре, М. Акъегетзадә, З. Бигиев, Г. Ильяси, М. Акмулла, Ф. Кәрими һ. б. әдипләр үсеп чыга. Мәгърифәтчелек идеяләре башка төрки халыкларда да кузгала. Азәрбайҗанда Мирза Фатали Ахундов, Казахстанда Чокан Вәлиханов, Абай Кунанбаев, Кырымда Исмәгыйль бәк Гаспралы (Гаспринский) аның күренекле вәкилләре иде.

Исмәгыйль Гаспралы эшчәнлеге (1851—1914).

Исмәгыйль Мостафа улы Гаспралы — Кырым татарларының гына түгел, бәлки төрки-татар һәм, гомумән, мөселман халыкларының яңару хәрәкәтенә зур өлеш керткән мәгърифәтче әдип, педагог, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе. Яшьлегендә ул татар һәм рус мәктәпләрендә белем ала. Милләтенә хезмәт итү теләге белән, Мәскәүдәге хәрби училищеда укуын ташлап, 1866 елда Бакчасарайга кайта, берничә ел мәдрәсәдә укыта. Белемен арттыру нияте белән Истанбулга китә, аннан Парижга барып чыга, бабалары татар нәселеннән булган язучы И. С. Тургеневның шәхси секретаре булып тора, газета-журналларда мәкаләләр белән катнаша. Алжир, Тунис, Греция, Төркиядә була. Бу вакытларда инде ул татар, төрек, гарәп, фарсы, рус, француз телләрендә укый-яза һәм сөйләшә белә.

1875 елда Бакчасарайга кайтып, җәдитчелек идеяләрен тормышка ашыруда практик эш җәелдерә: яңа тип мәктәпләр ача, ана телендә яңача укыта, дәреслекләр бастырып тарата. 1878 елда аны шәһәр башлыгы итеп сайлыйлар.

Зур кыенлыкларны җиңеп, ул рус хөкүмәтеннән газета чыгарырга рөхсәт алуга ирешә. Бу башлангычны Ш. Мәрҗани хуплый, миллионер Рәмиевләр, фабрикант Акчуриннар матди ярдәм күрсәтәләр. 1883 елда «Тәрҗеман»[1] газетасы чыга башлый. Исмәгыйль бәкнең хатыны — татар байлары Акчуриннар

[1] Тәрҗеман — 1. Кемнең дә булса (бу очракта халыкның, милләтнең) теләк-омтылышларын бәян итүче, белдерүче. 2. Тәрҗемәче.

кызы Зөһрә — аның бу эшләрендә иң якын фикердәше, ярдәмчесе һәм таянычы була. Ул барлык бирнәсен басмаханә ачу, типография эшләрен оештыруга тота, үзе көне-төне редакциядә эшли. Р. Фәхреддин аның хезмәтләрен «Мәшһүр хатыннар» китабында (1903) зур хөрмәт белән искә ала.

Әле бездә вакытлы матбугат бөтенләй булмаган заманда чыга башлаган «Тәрҗеман» 1918 елга кадәр яши, төрки-татар дөньясында иң дәвамлы газета була. Ул Кырымда гына түгел, бәлки татарлар яшәгән күп төбәкләрдә, Идел-Урал буйларында, шулай ук Кавказда, Урта Азиядә, Төркиядә һ. б. мөселман илләрендә тарала. Бу газета битләрендә И. Гаспралы колониаль изелүдә булган төрки халыкларны уяту, мәгърифәтле һәм мәдәниятле итү, аларны үзара якынайту идеяләрен пропагандалый, «телдә, уй-фикердә, эштә бердәмлек» лозунгын алга сөрә. Шул ук вакытта ул алга киткән рус һәм Европа фәне, мәдәнияте һәм әдәбияты казанышларын үзләштерүне, алардан үрнәк алуны кайнар яклый. И. Гаспралы XX гасыр башында да төрки-татар милли хәрәкәтенең күренекле эшлеклеләреннән, юлбашчыларыннан берсе була.

«Таңыбызның Чулпаны».

Татарлар яшәгән төрле төбәкләр арасында икътисади-мәдәни бәйләнешләрнең үсеше нәтиҗәсендә халыкның милләт булып оешу процессы бара. Милли үзаң формалаша. Бу исә халыкның үз тарихы, теле, мәдәнияте белән кызыксынуын көчәйтә. Ш. Мәрҗани, Х. Фәезханов кебек галимнәр милли тарихны өйрәнүнең нигез ташларын салырга керешәләр. Алар, Г. Ибраһимов сүзләре белән әйткәндә, халыкның уяну хәрәкәтенә тарихны корал итәләр.

Мәгърифәтче галим, педагог, тарихчы, философ **Шиһабеддин Баһаведдин улы Мәрҗани** (1818—1889) Татарстанның хәзерге Әтнә районы Ябынчы авылында туа. Бабаларының төп чыгышы Мәрҗән авылыннан булганга, Шиһабеддиннең да кушаматы Мәрҗани булып йөри. Булачак галим Ташкичү авылында әтисе мәдрәсәсендә укый, 17 яшьтән үзе дә шәкертләргә дәресләр бирә башлый. 1838 елда аны, белемен арттырыр өчен, Урта Азиягә озаталар. Бохара, Сәмәрканд мәдрәсәләрендә укыганда ул, аларда хөкем сөргән иске тәртипләрдән, фикер торгынлыгыннан риза булмыйча, күбрәк вакытын китапханәләрдә мөстәкыйль рәвештә үзлегеннән укуга бирә. Борынгы Көнчыгышның мәшһүр галимнәре һәм фикер ияләре әл-Фәрәби, Бируни, Ибне Сина һ. б. ның әсәрләрен өйрәнә. Гарәп

һәм фарсы телләрен ныклап үзләштерә, соңыннан үзе дә күп кенә хезмәтләрен гарәп телендә яза. Мәрҗани Көнчыгыш әдәбиятының Сәгъди, Фирдәуси, Хәйям, Нәваи кебек классиклары мирасы белән якыннан таныша. Аңа бигрәк тә якташы, татар укымышлысы Габденнасыйр Курсавиның акылга ирек таләп иткән фикерләре зур йогынты ясый.

1849 елда ул, Казанга кайтып, беренче мәчеткә имам һәм аның каршындагы мәдрәсәгә мөдәррис итеп билгеләнә. Мәрҗани үз мәдрәсәсендә эчке тәртип кагыйдәләрен булдыра, шәкертләргә, дин белемнәре белән бергә, тарих, география, математика кебек фәннәрдән дә белем бирә, Көнчыгышның мәшһүр әдипләре һәм фикер ияләренең әсәрләре белән таныштыра. Гыйльми-фәлсәфи хезмәтләрендә ул схоластикага каршы чыга, иске китапларда язылганнарга сукырларча иярүне кискен тәнкыйть итә, остазы Г. Курсави фикерләрен үстереп, кешенең ирекле уй-фикер йөртергә, ягъни иҗтиһад итәргә хокукын яклый. Шәкертләреннән дә ул еш кына: «Бу мәсьәләдә син үзең ничек уйлыйсың?» — дип сорый торган була.

Ш. Мәрҗанинең яңача фикерләве кадимче руханиларның һәм иске карашлы байларның зур каршылыгына очрый. Аны ике мәртәбә муллалыгыннан алалар, динсезлектә, көферлектә гаеплиләр. Ләкин Мәрҗани кузгаткан фикер хәрәкәте үсә, аның тарафдарлары да ишәя бара. «Мәрҗани әсәрләрендә,— дип яза соңыннан Г. Ибраһимов,— сез ислам дөньясын каплап, акылларны богаулап яткан барлык туңлыкларга, барлык тәгассыб[1] вә караңгылыкларга каршы гайрәтле протест кылучы көчле фикер иясе, фикердә вә икътикадта[2] хөр булмак — һәркемнең табигый хокукы, дип игълан кылу дәрәҗәсендә бер каһарманны күрәчәксез».

Мәрҗанинең 30 дан артык хезмәт язганлыгы мәгълүм. Аларның шактый өлешен тарихка караган әсәрләр тәшкил итә. Фәлсәфи характердагы «Назурәтелхак» («Хакыйкатьне күзаллау...», 1870), халык тарихын тикшерүгә багышланган «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» («Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр», I том — 1885, 1897; II том —1900) кебек хезмәтләре аеруча игътибар казана. Мәшһүр галимнең исеме һәм әсәрләре чит илләрдә дә танылa, югары бәя ала.

[1] Тәгассыб — фанатизм.
[2] Икътикад — инану, ышану.

Ш. Мәрҗани татар халкын, тар милли кабык эчендә бикләнеп, йомылып калмыйча, фән-мәдәният эшләрендә башка милләтләрдән дә өйрәнергә чакыра. «Үз милләтебезнең яшәргә тырышуы, үз эшен үзе эшли алуы, хәят[1] мәйданында изелеп калмавы өчен,— дип яза ул,— Европаның гыйлем вә мәгарифенә, һөнәр вә сәнәгатенә[2] зур ихтыяҗыбыз бар. Европа мәктәпләрендә укымак безнең өчен файдалы. Һөнәр вә мәгариф кайда булса, шунда барып тәхсил итәргә[3] кирәк. Гыйлем белән мәгарифнең хас ватаннары, хас лисаннары[4] юк».

Ул Шәрыкны өйрәнүче рус галимнәре белән якыннан аралаша, К. Насыйри белән бергәләп, университетта докладлар укый. Мөселман галимнәреннән беренче булып, Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенә әгъза итеп сайлана. 1876 елда Казанда ачылган Укытучылар мәктәбен оештыруда актив катнашып, үзе дә шунда дәресләр алып бара.

Ш. Мәрҗанинең мәгърифәтчелек өчен көрәше, олуг фикер иясенең мәһабәт образы үз заманында ук инде матур әдәбиятта чагылыш таба. Гали Чокрый, Мифтахеддин Акмулла кебек шагыйрьләр иҗатында ул халыкны туры юлга салучы галим, көрәшче каһарман рәвешендә сурәтләнә. Аның эшчәнлегенә Ф. Әмирхан югары бәя бирә. Г. Ибраһимов аны «бөек остазыбыз», «безнең таңыбызның Чулпаныдыр» дип атый. «Шиһаб хәзрәт» шигырендә Г. Тукай мәгърифәтче галимне балкып чыккан тулган айга охшата:

Мәгарифкә әүвәл башлап адым салган,
Милләт өчен бәһа җитмәс кыйбат хәзрәт,—

дип яза.

«Төп максат — халыкның күзен ачу...»

Ш. Мәрҗанинең шәкерте һәм фикердәше **Хөсәен Фәезханов** (1828—1866) элекке Сембер губернасының Сафаҗай авылында («матур урын» дигән мәгънәдә, соңыннан русча кулланылышта Сабачай булып йөри башлаган, хәзерге Түбән Новгород өлкәсенең Пилнә районы) крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Башлангыч белемне авыл мәктәбендә ала, соңрак Бәрәскә, Казан мәдрәсәләрендә укый. Белемен үзлегеннән

---

[1] Хәят — тормыш.
[2] Сәнәгать — промышленность.
[3] Тәхсил итү — белем алу.
[4] Лисан — тел.

күтәрү белән шөгыльләнә, татар, төрек, гарәп, фарсы, рус телләрен, әдәбиятын һәм тарихын өйрәнә. Казанда Мәрҗани укыта башлагач, биш ел буена аның дәресләрен тыңлый. Шул ук вакытта ул университетка А. К. Казембек, И. Н. Березин кебек күренекле галимнәрнең лекцияләренә йөри, алар белән якыннан таныша.

1855 елда Казан университетының Шәрык факультеты Петербург университетына күчерелгәч, башкалада яңа ачылган факультетның беренче деканы А. Казембек һәм профессор И. Березин тырышлыгы белән Х. Фәезханов шунда төрек-татар теле укытучысы итеп алына. Биш елдан соң, 1862 елда, Көнчыгыш телләре факультеты лекторы итеп билгеләнә.

Укыту эшләре белән бергә, Х. Фәезханов киң колачлы фәнни тикшеренүләр алып бара. Күренекле галимнәр һәм Россия Фәннәр академиясе белән тыгыз бәйләнештә торып, ул Мәскәү архивларында Кырым һәм Касыйм ханлыкларына караган бик күп документларны өйрәнә, фәнни экспедицияләргә чыга, борынгы Болгар кабер ташларын укып, алардагы язуларга анализ ясый, татар халкының килеп чыгышы мәсьәләләрен яктырта. 1860 елда ул, татарлардан беренче буларак, Император археология җәмгыятенең әгъза-корреспонденты булып сайлана. Фән эшлеклеләре арасында аны «төпле ориенталист» (Көнчыгыш халыкларының телләрен һәм мәдәниятен белүче) буларак югары бәялиләр.

Х. Фәезханов татар телендә газета чыгару мәсьәләләре белән якыннан кызыксынган. 1862 елда Казанга язган бер хатында ул газета чыгарудан «төп максат — халыкның күзен ачып, мәгърифәт тарату» дип билгели. П. И. Пашиноның Н. Г. Чернышевский, Н. А. Некрасов җитәкчелегендә чыгучы «Современник» журналында басылган «Идел буе татарлары» дигән очерклар язуы мәгълүм. Х. Фәезханов белән П. И. Пашино якын дуслар булганнар, Петербургта бергәләп «Чулпан» исемле татарча газета чыгару уе белән йөргәннәр. Пашино архивында аларның икесе исеменнән язылган гариза һәм газетаның программасы саклана. Программадан күренгәнчә, газетада, эчке һәм тышкы хәбәрләр бүлекләреннән тыш, фән бүлеге булдыру, тарихка, географиягә, өй медицинасына һ. б. фәннәргә караган мәкаләләр урнаштыру, «Әдәбият» дигән махсус бүлектә этнографик очерклар, сәяхәтнамәләр, повестьлар һәм хикәяләр бастыру күздә тотылган. Соңгы бишенче бүлектә тел һәм фольклор материалларын (мәкаль-әйтемнәр, табышмаклар,

халык җырлары һ. б.) биреп барырга уйлаганнар. Кызганычка каршы, аларның бу ниятләре тормышка ашмый калган.

Х. Фәезхановның татар иҗтимагый фикере һәм мәгърифәтчелек хәрәкәтенә тирән эз салган хезмәте — укыту системасына реформа проекты. Иске мәдрәсәләрне яраксыз табып, ул алтмышынчы еллар башында ук Казанда яңа типта зур мәдрәсә ачу, анда дин белән бергә дөньяви фәннәрне, шулай ук татар, рус һәм Европа телләрен укыту, белем һәм тәрбия бирү тәртипләрен гимназия тибында үзгәртеп кору фикерләре белән чыга. Мондый уку йортын тәмамлаган яшьләр университетка керү хокукы алырга тиеш була.

Ул заман өчен бу фикерләр бик кыю булганга, шау-шулы бәхәсләр кузгата. Фанатизм дөньясы ишетергә дә теләми. Ләкин фикер сүнми. 70—80 нче елларда ул, көчәя барып, 90 нчы елларда яңалык яклы байлар ярдәме белән гамәлгә ашырыла башлый. Оренбургта миллионер Хөсәеновлар «Хөсәения» мәдрәсәсен ачалар. Иж-Бубый авылында — «Буби», Казанда — «Мөхәммәдия», соңрак Уфада эшли башлаган «Галия» мәдрәсәләре шундый яңарак типтагы уку йортлары була.

Кырау сугып иртә сулган чәчәк кебек, Х. Фәезханов нибары 38 ел яши. Үпкә авыруы белән каты чирләп, 1866 елның җәендә туган авылына кайтып вафат була. «Гыйльми гамәл, үткен акыл, хакимлек... җәһәтләреннән аның тиңен хәзер кайдан табарга? — дип язган бу уңайдан тирән кайгы белән Ш. Мәрҗани.— Табылса да бик сирәк табылыр. Шулай ук гаҗәеп һәйбәт кеше иде ул. Гавамның юк-бар сүзләренә, шаушуларына исе китми торган олы җанлы кеше иде».

Әдәби үсеш. Матур әдәбият яңа идеяләрне кешеләрнең күңеленә һәм аңына сеңдерүдә бик үтемле чара булганлыктан, мәгърифәтчелек хәрәкәте аны үзенә көчле бер корал итеп ала. Мәгърифәтче язучылар әдәби чаралар, образлар ярдәмендә мәгърифәтчелек идеяләрен үткәрәләр. Иске тәртипләрне тәнкыйть итәләр, яңача яшәүгә өндиләр.

Аң-белемле, яңа фикерле герой әдәбиятның төп фигурасы булып әверелә. Иске тәртипләрне яклаучылар тискәре образларда сурәтләнә.

Гасырның беренче яртысындагы әдәбиятта без кешенең **шәхес буларак уянуын,** искелеккә, фанатизмга протестын, дөньяви уй-хис, теләк-омтылышларын күргән идек. Гасырның соңгы чирегендә инде татар әдәбияты, шәхесне сурәтләү белән бергә, яңа бер баскычка күтәрелә: анда үзәк урынны **милләт**

мәсьәләсе ала. Татар халкын уяту, милләтне аң-белемле итү, мәдәни яктан алга киткән милләтләр белән бер сафка чыгару идеясе әдәбият үсешен алга әйдәп баручы үзәк идеягә әверелә. М. Акъегетзадәнең «Хисамеддин менла» романында (1886) сурәтләнгән Хисамеддин, Әбүзәр Дәүләтгилдиев, Гайса Зурколаков кебек геройларны милләтне сөю тойгылары үзара берләштерә, дуслаштыра, фикердәш һәм хезмәттәш итә. Алар, шәхес ирегеи яклау белән бергә, беренче чиратта милләтне мәгърифәтле итү уе белән яналар. Без моны алга таба З. Бигиев, М. Акмулла, Р. Фәхреддин, Ф. Кәрими, З. Һади һ. б. әдипләр иҗатында да күрәчәкбез.

Халыкны фәкыйрьлектән йолып алу өчен, аны белем, һөнәр белән коралландырырга, анда югары әхлакый сыйфатлар тәрбияләргә кирәк. Ә моны ничек эшләргә? Милләт аерым кешеләрдән тора. Әгәр һәркем фән һәм мәдәният казанышларын үзләштерерлек белемгә, тормышын җитешле итәрлек һөнәргә ия булса, бар тапканын җилгә очырып, азып-тузып йөрмәсә, даими тырышлык күрсәтсә, ул үзен һәм гаиләсен яхшы тәэмин итә алачак. Матур әдәбият моңа һәрьяклап булышырга, кешеләрдә югары әхлакый сыйфатлар тәрбияләргә тиеш. Һәркем җитешле тормышка ирешкәч, гомуммилләт тә бәхетле, мул һәм культуралы тормышка чыгачак. Җыеп кына әйткәндә, мәгърифәтче язучыларның әдәби карашлары шуннан гыйбарәт иде.

Бу карашлар язучыларның иҗат практикасында тормышка ашырыла. Әсәрләрдәге персонажлар, гадәттә, әхлаклы һәм культуралы булу-булмау ягыннан капма-каршы рәвештә ике төркемгә бүленә. Язучының уңай идеалын гәүдәләндергән геройлар бар яктан да килгән, сөттән ак, судан пакь итеп сурәтләнә. Тискәреләр исә кара буяуларны мул кулланып тасвирлана. Конфликтта, кагыйдә буларак, уңай геройлар өстен чыга, тискәреләр җиңелә, хурлыкка кала, мәкерле эшләренең җәзасын ала. Автор укучыга, уңай геройларыма охшарга тырыш, алардан үрнәк, ә тискәреләрдән гыйбрәт ал, алар кебек булма, дип әйтергә тели. Әсәрләрдәге публицистик чигенешләрдә һәм фикер йөртүләрдә яхшы булырга, яманлыктан-явызлыктан сакланырга өндәүләр дә еш очрый. «Адәмнең башка хайваннардан аермасы шундадыр ки,— дип яза, мәсәлән, К. Насыйри,— адәмнең гакылы бар, фикерли белә, теле бар, сөйләшә белә». Укып, белем алып, бу сыйфатларны нык үстерергә, камилләштерергә мөмкин. Әмма, мәгърифәтче галим һәм әдип фикеренчә, камил кеше булыр өчен, бу сыйфатлар гына

җитми. «Камил адәмилек,—ди ул,— дәхи изге холыклы булмак вә явыз холыктан сакланмак белән хасил булыр».

Яхшылык һәм явызлык көрәшендә яхшылык җиңгән, камил, күркәм кешене идеал иткән, үгет-нәсыйхәтчелек белән сугарылган әсәрләр элекке әдәбиятта да шактый күп иде. Алар,— нигездә, Көнчыгыш әдәбиятыннан килгән әкият, легенда характерындагы хыялый-фантастик хикәятләр, кыйссалар.

Татар мәгърифәтчелек әдәбиятында бу традицияләр дә яңа сулыш алып, тернәкләнеп китә. К. Насыйри, Ф. Халиди, Г. Фәезханов (Х. Фәезхановның бертуган энесе) һ. б. күп кенә әдипләр Көнчыгыш, шул исәптән төрек әдәбиятындагы әсәрләрне тәрҗемә итә, аларга ияреп яза башлыйлар. Мондый әсәрләрдә гәүдәләнгән яхшылык, инсафлык, юмартлык, гаделлек, белемлелек һәм зирәк акыл кебек гуманистик идеяләрне халыкка җиткерергә омтылалар. Укучыларның игътибарын фантастик кыйссаларның маҗаралы булуы да җәлеп иткән.

Мәгърифәтчелек реализмы формалашу.

Шул ук вакытта яңа заман тудырган актуаль идеяләрне, милләт алдында торган бурычларны татар кешесенең күңеленә һәм аңына үтемлерәк итеп сеңдерү өчен, күп кенә язучыларны иске китаплардагы хыялый сюжетлар, фантастик геройлар канәгатьләндерә алмый инде. Мәгърифәтче әдипләр, рус, Европа әдәбиятлары үрнәгендә, вакыйгаларны һәм геройларны татар тормышының үзеннән алып сурәтли башлыйлар. М. Акъегетзадә, З. Бигиев, М. Акмулла һ. б. әдипләр әсәрнең беренче юлларында ук вакыйгаларның Казанда яисә Идел буендагы татар авылында баруын ассызыклап әйтәләр.

Кадимче руханилар, иске фикерле сәүдәгәрләр, схоластик уку-укыту системасы тарихи конкрет **татар тормышы материалында** тәнкыйть ителә. Белемле, күркәм кеше идеалы да яңа сыйфатлар белән байый. Ул, Ш. Мәрҗани образы шикелле, тормышның үзеннән алынган актив кеше, көрәшче герой буларак сурәтләнә.

Персонажлар арасындагы конфликт, нигездә, мораль яссылыкта калса да, ул инде яңалыкны яклаучылар белән искелек тарафдарлары арасындагы каршылык итеп сурәтләнә. Прогрессив карашлы геройлар югары әхлакый сыйфатларга ия, төскә-биткә дә чибәр; торгынлык яклылар исә — еш кынаямьсез, аңгыра, әхлаксыз кешеләр.

Мәгърифәтче язучылар, бер яктан, кешенең бәхетле яки бәхетсез булуы аның үзеннән, белем һәм әхлакый сыйфат-

ларыннан тора дип күрсәтәләр. Димәк, барлык җаваплылык кешенең үз өстенә төшә. Кешегә мондый мөнәсәбәт язучыларны үгет-нәсыйхәтчелеккә, дидактизмга этәрә иде.

Әмма, икенче яктан, бу чордагы мәгърифәтче әдипләр, үз геройларын сурәтләгәндә, аларны чолгап алган тормыш шартларына да игътибар итә башладылар, персонажларны тирәлек, мохит белән бәйләнештә күрсәтергә керештеләр. Бу исә әдәбиятны реализмга таба әйди иде. Кеше надан, азгын, бозык икән, ул тумыштан шундый булганмы, моңа үзе генә гаепле-ме, әллә башка сәбәпләре дә бармы?Нинди шартларда ул шундый булып формалашкан?

Кешене үзе яшәгән шартлар, тирәлек белән тыгыз бәйләнештә сурәтләү бу инде иҗатта реализм принципларын үзләштерү иде. Бу уңайдан татар мәгърифәтчелек философиясенең ролен дә искә алырга кирәк. Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Р. Фәхреддин кебек галимнәр дөньяда бер генә күренеш тә сәбәпсез барлыкка килми дип өйрәттеләр, бу дөнья сәбәпләр дөньясы дип аңлаттылар.

Мәгърифәтче язучылар кешене тәрбия җимеше итеп сурәтлиләр. Бу иң элек — гаилә тәрбиясе. Уңай геройларның әти-әниләре дә,— гадәттә, ачык фикерле, белемле, кешелекле кешеләр — балаларына яхшы тәрбия биргәннәр. Тискәреләрнең ата-аналары да бик үк әйбәт түгел. Икенче баскыч — мәктәп-мәдрәсә тәрбиясе. Геройларның аянычлы язмышы аша схоластик, иске тип мәдрәсәләр тәнкыйть ителә. Мәсәлән, З. Бигиев «Гөнаһе кәбаир» («Зур гөнаһлар») романында Габделгафур исемле яшүсмернең әтисен, исемен дә әйтеп тормыйча, «Нәкәс мулла» дип кенә атый (начар, әшәке дигән мәгънәдә). Димәк, Габделгафур гаиләдә тиешле тәрбия күрмәгән дип нәтиҗә ясый алабыз. Егет, авылдан Казанга килеп, схоластик мәдрәсә шартларында бозылып, эчкечелеккә бирелеп, тормыш төбенә тәгәри.

Шәхес һәм тирәлек мәсьәләсенә З. Һади повестьларында һ. б. әдипләрнең әсәрләрендә шулай ук зур игътибар бирелә. Тирәлек, мохит дигәндә, кагыйдә буларак, әлегә гаилә һәм мәктәп-мәдрәсә, укыту-тәрбия сферасы, әхлакый мөнәсәбәтләр күздә тотыла.

Кыскасы, бу чор татар әдәбиятында инде реализмның нигез принцибы — кешене аны чолгап алган иҗтимагый мөнәсәбәтләр белән тыгыз бәйләнештә күрсәтү, тирәлек җимеше итеп тасвирлау — мәгълүм бер дәрәҗәдә тормышка ашырыла. Әмма бу — үзенчәлекле реализм. Анда үгет-нәсыйхәтчелек

шактый зур урын тота. Геройларны сурәтләгәндә, мораль принцип өстенлек итә. Иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең аеруча әһәмиятлеләре —икътисади һәм социаль мөнәсәбәтләр — игътибардан читтәрәк кала. Мәгърифәтчелек идеяләре белән сугарылган мондый реализмны **мәгърифәтчелек реализмы** диләр.

Шул рәвешле, XIX йөзнең икенче яртысы татар әдәбиятында төп иҗат методы буларак, мәгърифәтчелек реализмы формалаша.

Җыеп кына әйткәндә, бу чор татар әдәбияты борынгы хыялый сюжетлардан һәм фантастик геройларны сурәтләүдән татар халкының үз тормышын реаль сурәтләүгә күчә бара. Милли яңарыш идеяләре белән сугарылган реалистик әдәбият мәйданга килә.

Сораулар һәм биремнәр

1. Татарларда мәгърифәтчелек хәрәкәте нинди тарихи сәбәпләр нәтиҗәсендә барлыкка килгән?

2. Җәдитчеләр дип кемнәргә әйткәннәр? Алар нинди фикерләр белән чыкканнар, нәрсә өчен көрәшкәннәр?

3. И. Гаспралы эшчәнлегенә кыскача характеристика бирегез.

4. Ш. Мәрҗани эшчәнлегенең әһәмияте нәрсәдә?

5. Х. Фәезханов эшчәнлегенең төп тармаклары.

6. XIX йөзнең икенче яртысы татар әдәбиятындагы үсешне, төп яңалыкларны нәрсәләрдә күрәсез?

7. Мәгърифәтчелек реализмында шәхес һәм мохит проблемасы ничек хәл ителә?

Каюм Насыйри
(1825—1902)

Күренекле галим, укытучы-педагог һәм әдип К. Насыйри татар мәгърифәтчелек хәрәкәте һәм әдәбияты үсешендә зур роль уйнады. Аның ярты гасырга сузылган күптармаклы һәм нәтиҗәле эшчәнлеге халыкка хезмәт итү, милләтнең аң-белем дәрәҗәсен күтәрү, киң күпчелеккә аңлаешлы татар әдәби телен гамәлгә ашыру теләге, демократик караш һәм халыкчанлык рухы белән сугарылган иде.

Бу исем сезгә инде күптән таныш. Балачакта сез аның мавыктыргыч әкиятләрен укып үстегез, «Иске мәдрәсәдә», «Патша белән карт», «Надан мөәзин белән надан мулла», «Аңгыралык бәласе» кебек гыйбрәтле кыска-кыска хикәятләрен укып танышкан идегез. 7 нче сыйныфта «Әбүгалисина» әсәрен өйрәндегез.

Инде хәзер без бергәләп Каюм Насыйриның тормыш юлы, карашлары, төрле юнәлештәге эшчәнлеге һәм әдәби әсәрләре белән танышырбыз.

Хезмәттә узган гомер.

Габделкаюм Габденнасыйр улы Насыйров (Каюм Насыйри) 1825 елның 14 (2) февралендә элекке Казан губернасы Зөя өязе (хәзер Татарстанның Яшел Үзән районы) Югары Шырдан авылында мулла гаиләсендә дөньяга килә. Бабасы Хөсәен һәм әтисе үз дәверендә шактый танылган укымышлы кешеләр булалар. Алар гарәп, фарсы, рус телләрен белгәннәр, китап күчерүгә оста булганнар, төрле темаларга үзләре дә әсәрләр язганнар. Әтисе, «иҗтиһад[1] — һәркемгә кирәк эш», ягъни кеше һәрнәрсәдә үзе

[1] Иҗтиһад — иске карашларга сукырларча иярмичә, тырышлык куеп, акыл белән эш итү, фикер йөртү мәгънәсендә.

тырышырга, акыл белән эш итәргә тиеш, дип өйрәтә торган булган.

Башлангыч белемне Каюм үз атасыннан ала. 1841 елда аны Казандагы бер мәдрәсәгә бирәләр. Бу мәдрәсәдә ул 1855 елга кадәр унбиш ел укый. Гарәп, фарсы телләрен өйрәнә. Күп нәрсәне үзлегеннән үзләштерә. Төрек телендәге китаплар белән дә таныша. Нәтиҗәдә ул киң белемле, мөстәкыйль фикер һәм эш йөртә алырлык кеше булып җитешә.

1855 елда аны Казандагы Духовное училищега татар теле укытырга чакыралар. К. Насыйриның мөгаллимлек хезмәте шунда башлана. Соңрак ул әлеге училищеның югарырак баскычы булган семинариядә татар теле дәресләре алып бара. Казан университетына ул ирекле тыңлаучы булып керә, күренекле галимнәрнең лекцияләрен тыңлый.

К. Насыйри семинария чарлагындагы бер бүлмәдә яши. Матди яктан көнкүреше бик үк җитешле булмый. Семинариядә ул 15 ел эшли. 1873 елда Казан мәдрәсәләрендә рус теле укытыла башлый. К. Насыйри да бер мәдрәсәгә мөгаллим итеп билгеләнә. Әмма мәктәпләр инспекторы белән икесе арасында чыккан каршылык нәтиҗәсендә 1876 елда К. Насыйри бу хезмәтеннән туктый.

Мәгърифәтче галимне халыкның шәһәрдә дә, авылда да мохтаҗлыкта яшәве борчый. Мәскәүдәге агасы Габделхәйгә язган бер хатында ул: «Ят хәбәр юк. Ләкин халык бик ябык, зарланмаган кеше юк»,— дип хәбәр итә.

Яз, җәй айларында ул Югары Шырданга еш кайта торган була. Кыр эшләрендә катнаша, гади халык, крестьяннар белән якыннан аралаша. Зөя ягындагы авылларга да чыгып, борынгы кабер ташларын укый, картлардан авыл тарихларын, тарихи истәлекләрне язып ала, халыкның җанлы сөйләм телен, гореф-гадәтләрен, йолаларын өйрәнә, җырлар, бәетләр, әкиятләр, риваятьләр һ. б. материаллар җыя. Күп кенә авылларның тарихы борынгы Болгар белән бәйле булуын ачыклый.

1879 елдан К. Насыйри, рәсми рәвештә бер җирдә дә хезмәт итмәстән, калган гомерен бары фән һәм язучылык эшенә багышлый. Зуррак күләмле әсәрләре шушы чорга туры килә. Ш. Мәрҗани, Г. Ильяси кебек укымышлылар белән бергә, Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте утырышларына йөри, докладлар ясый. Галимнәр аның хезмәтләрен югары бәялиләр.

Барлык көчен дәреслекләр һәм китаплар язуга, тапкан акчасын аларны бастыруга тоткан галимнең килере аерым кешеләрнең балаларын укытудан, гаризалар язып бирүдән, тәрҗемә итү, китапларын сатудан гыйбарәт була.

Язу-сызу, акыл хезмәте белән бергә, К. Насыйри физик эш белән дә шөгыльләнгән. «Һаман утырып язу ялыктыра, каннар оеша, мин, һәр көн бер-ике сәгать эшләп, бу кораллар белән үземә кирәкле әйберләрне ясыйм»,— дип әйтә торган була. Аның бүлмәсендә кыру станогы һ. б. кирәк-яраклар тора. Дәреслекләренә карталар сызу, басылган китапларын төпләү, рәсемнәр төшерү эшләрен дә үзе башкара. Ул бигрәк тә агачтан төрле әйберләр ясарга яраткан, кирәк булган әйберләрнең барысын да үзе эшләгән.

К. Насыйри даими рәвештә диярлек Казанда яши. Берничә мәртәбә Мәскәүдә — агасы Габделхәй янында булып кайта, Мәкәрҗә ярминкәсенә һәм, имтихан тапшыру өчен, Уфага бара. 1893 елның җәендә ул татар мәдәнияте һәм әдәбиятының зур үзәкләреннән берсе булган Оренбург төбәгенә сәяхәт ясый. Ләкин Казандагы муллалар һәм сәүдәгәр-мещаннар арасындагы кебек үк, мәгърифәтче галимгә монда да бик үк игътибар итүче булмый.

Каюм Насыйри халык медицинасыннан файдаланган, төрле үләннәр белән дәваланган, физик хезмәт белән шөгыльләнгән. Шуның нәтиҗәсе буларак, бөтенләй диярлек ятып авырмаган. Бары тик гомеренең соңгы елларында гына аякларын җиңелчә паралич суга, һәм ул үзен үзе электр белән дәвалый, гел хәрәкәттә булырга тырыша. Нәтиҗәдә, аяклары яңадан язылып, йөрерлек хәлгә килә.

К. Насыйри 1902 елның 20 августында (2 сентябрьдә) 77 яшендә вафат була. Кабере — Казанда Яңа Бистәдәге татар зиратында.

Туган телнең пар канаты. Каюм Насыйриның гыйльми-мәгърифәтчелек эшчәнлеге XIX гасыр урталарында яшь буынга төрле уку китаплары һәм дәреслекләр язудан башлана. Аның иң беренче хезмәте — «Кыскача татар нәхүе», ягъни татар теле синтаксисы. Бу китап 1860 елда басыла. Русча өйрәнүче татарларны, татарча өйрәнүче русларны күздә тотып, бу дәреслек рус телендә язылган һәм «Краткая татарская грамматика» дип аталган. Текстларда татарча һәм русча китерелгән сүзлек бирелгән.

Шул ук елда аның «Буш вакыт» исемле китабы да басылып чыга. Бу хезмәтендә автор балаларны һәм дөньяви фәннәрдән

башлангыч белем алучыларны анатомия, табигать белемнәреннән кыскача мәгълүматлар белән таныштыра. 1868 елда әлеге китапның тулыландырылган икенче басмасы дөнья күрә.

Бу хезмәтнең беренче бүлеге кешенең анатомиясенә багышланган. Автор кайбер ышану-ырымнарның нигезсез булуын да төшендерә. Мәсәлән, кан йөреше, йөрәк тибеше турында аңлатып килә дә албасты басты дип сөйләүләрнең юк-барга ышану икәнлеген искәртә: «Йөрәкнең тибүе шуның өчен дә: әгәр йөрәк шулай типмәсә, тәндә кан агып йөрмәс иде... Кешенең кайчагында йоклар-йокламастан бастырылуына убыр басты яисә албасты басты дип әйтәләр. Төбендә убыр түгел, бары шул тәндә кан йөреше кысылыбрак тору гына»,— ди.

Китапның калган бүлекләрендә Җир һәм аның әйләнүе, һава, кыш, яз, җәй һәм көз, җылылык үлчәве, яңгыр, чык, кырау кебек табигать күренешләре, төрле металлар һ. б. турында кызыклы мәгълүматлар тупланган. Бу китапны 1909 елда «Балалар көтепханәсе» сериясеннән, биш кисәккә бүлеп, кабат бастырып чыгаралар.

Инде бергәләп уйлап карыйк: галимнең күпкырлы мәгърифәтчелек эшчәнлеге нәкъ менә татар теле дәреслеген һәм туган телдә фәнни-популяр китап бастырудан башланып китүе очраклы хәл идеме? Юк, әлбәттә. К. Насыйриның тел өлкәсендә башкарган эшләре — аның гомере буена дәвам иткән иң зур хезмәтләреннән берсе.

Халыкта милли үзаңның формалаша баруы туган телгә игътибарны арттыра, нәтиҗәдә аның К. Насыйри шикелле эшлеклеләре дә мәйданга килә. Ш. Мәрҗани һәм Х. Фәезхановлар уяну хәрәкәтенә тарихны корал итсәләр, К. Насыйри туган телне корал итә, татар телен күтәреп чыга. «Ул заманның яңару омтылышларына беренче аяк атлаучы Насыйрилар,— дип язды Г. Ибраһимов,— аңарчы исәпкә дә алынмаган татар телен бер гыйлем итеп тикшерә башладылар».

«Татар теле ул — урам теле, ломовойлар теле, әдәби-гыйльми тел булырга сәләте юк аның» дигән карашлар яшәгән заманда К. Насыйри халкыбызның туган телен кайнар яклап чыкты. «Ялган, яла бу! Без — татарлар, телебез — татар теле, мөстәкыйль һәм төзек кагыйдәле камил тел ул. Бүтән телләрдән бер дә ким түгел, эшләнмәгәнлек сәбәпле генә ул шулай артта калган»,—дигән ялкынлы фикерләре белән эш алып барды. Татар теленең фәнни тел була алуын, моңа аның тулы хакы һәм мөмкинлекләре барлыгын исбат итте.

«Телебезгә игътибар итеп, яхшы тикшереп карасак,— дип яза ул,— билгеле ки, телебездә булган бәетләр, шигырьләр, мәкальләр, идиоматик әйтемнәр бик уңышлы рәвештә ритм һәм рифмага салынып төзелгәннәр... Мәгънәне тулы һәм матур итеп бирүдә башка телләрдән һич тә ким түгел, бәлки кайбер яктан үзенчәлекләре күбрәк булган урыннары да бардыр, бигрәк тә фигыльләрдә. Ләкин шуны да әйтеп китәргә кирәк: телебез, бер дә кузгалмыйча, бер урында утырып калган. Хәзерге заманда яшәүче башка милләт халкының теләге —телне эшкәртү, төзәтү һәм яхшырту... Кайвакытта кайбер кешеләрнең татар телен телгә санамаулары турында ишетергә туры килә. Аларның хәтта тарих гыйлемен белмәүләре сәбәпле, татарча сөйләшергә, татар сүзен ишетергә дә чыдамлыклары җитми».

Татар телен гамәлгә кертүдә, К. Насыйри эшчәнлегенең бер тармагы телнең үзен өйрәнү, кагыйдәләрен аңлату, сүзлекләр төзү була. 1892 елда аның «Кавагыйде китабәт» («Язу кагыйдәләре») дигән кулланмасы басылып чыга. «Әнмүзәҗ» (1895) исемле хезмәте (үрнәк, мисал дигән мәгънәдә) белән К. Насыйри татар теленең фәнни грамматикасына нигез сала. Татар теленең беренче аңлатмалы сүзлеген төзеп бастыра («Ләһҗәи татар», ике томда, 1895, 1896). Аның әлеге хезмәтләре гыйльми җәмәгатьчелек тарафыннан югары бәяләнә.

Хәлбуки бер канаты белән талпынып, оча алмаган кош кебек, татар теле дә шушы бер тармагы, бер канаты белән генә югары күтәрелә алмас иде. К. Насыйри туган телнең ике канатын да үстерү һәм ныгытуны бергә алып бара. Икенче канат исә төрле фәннәрдән дәреслекләрне татар телендә язу, терминнарны татарча эшләү, орфографияне яңарту була. Математика фәне буенча ул «Хисаплык» (1873, тулыландырылган икенче басмасы —1899), «Гыйльме һәндәсә» («Геометрия фәне», 1895) дәреслекләрен бастыра. Географиягә караган «Истыйляхате җәгърафия» («География терминнары», 1890), «Җәгърафияи кәбир» («Зур география», I, II һәм III кисәкләр, 1894, 1898, 1899) китаплары чыга. К. Насыйри үзе төзегән календарьларда да географиягә бәйләнешле мәкаләләр, үзе сызган карталар урнаштырган. Ул шулай ук татар телендә игенчелек һәм бакчачылыкка, ботаникага караган, Россия тарихын бәян иткән һ. б. китаплар чыгара.

Гарәпчә атамалар урынына К. Насыйри керткән татарча терминнар (мәсәлән, арифметикада: сан, бүлү, калдык

һ. б.) хәзер дә кулланыла. Мәгърифәтче галим бүтән телләргә иярмәскә, «дәгел» язмаска, «түгел» язарга, «ичүн» язмаска, «өчен» дип язарга өйрәтә.

К. Насыйри башка телләрне өйрәнү өчен дә иң элек үз телеңне һәм аның кагыйдәләрен белергә кирәклеген аңлата. «Башка телне өйрәнәсе булсаң, ул вакытта үз телеңнең кагыйдәләрен белү бик кирәк,— дип яза ул.— Чөнки кеше үзенең телен яхшы белмәсә, башка телгә төшенә алмас, тик бик озак вакытлардан соң гына аңа күнегә алыр».

Татарларда рус телен белүнең әһәмиятен яхшы аңлаган мәгърифәтче, бу телне өйрәнү өчен, уку китабын («Кыйраәте рус», 1889), рус теле грамматикасын («Нәмүнә, яки Әнмүзәҗ», 1891), татарча-русча һәм русча-татарча сүзлекләр (1878, 1892) төзеп бастыра. Укыту процессында һәм тәрҗемә иткәндә, ике телне чагыштыру алымын куллана. Бу — хәзерге көндә дә уңышлы кулланыла торган метод.

«Ләһҗәи татар» сүзлегенең керешендә К. Насыйри үзен бик хаклы рәвештә «татар теленең хезмәтчесе» дип атый. Бу юлда күп кыенлыклар күрергә, каршылыкларны җиңәргә туры килүен ачынып искә ала: «Татар телебезгә хезмәтчеләр була килмәгәнлек сәбәпле, татар телебез артта, бик еракта йоклап калган. Әмма татар телебезгә хезмәтче мин булыйм дип, утыз биш ел уздырдым... Төн-көн никадәр тырышсам, шулкадәр җәфа чиктем. Милләтебез халкын татар дип атасам яратмадылар, татар теле дисәм яратмадылар».

Дөрес, К. Насыйри хезмәтләренең һәм әдәби әсәрләренең телендә хәзерге заман укучысына авыр аңлаешлы урыннар да шактый. Үз дәверендәге гадәт буенча, ул күп кенә китапларының исемнәрен дә гарәп-фарсы сүзләре һәм гыйбарәләре белән атаган. Әмма бу хәл язма телдә гасырлар буе урнаша, ныгый килгән гадәт-традицияләрнең ул заманда әле көчле булуы белән аңлатыла. К. Насыйри да, замана улы буларак, үзенең язу практикасында ул йогынтыдан бөтенләй үк арына алмаган, традицияләр киртәсен кинәт кенә сикереп чыгу кыен булган.

Әдәби тел күп язучылар һәм галимнәр тырышлыгы белән дәвамлы рәвештә формалаша. К. Насыйри бу юнәлештә юллар сызган. «Һәрбер нәрсә әүвәл чыкканда, бәгъзе җирләре җитешмәгән кебек булса да,— дип яза ул,— бара-бара төзәлә, яхшыга әйләнә, елдан-ел арттыралар, төзәтәләр... Өмет бар — табылмасмы икән йокысын кызганмаган егетләр. Бездән бары тик юл күрсәтү булсын...»

К. Насыйри хезмәтләренең тарихи әһәмияте туган телебезгә, татарча укытуга игътибар бермә-бер арткан безнең заманда тагын да ачыграк күренә.

Халык җәүһәрләрен балкытып. Тел байлыгының мул чыганагы халыкның җанлы сөйләмендә, авыз иҗатында икәнлеген яхшы аңлаган К. Насыйри фольклор әсәрләрен җыю һәм гыйльми нигездә бастырып чыгаруда зур тырышлык куя. Бу — аның фольклор өлкәсендәге эшчәнлегенең мөһим бер тармагы. Икенчедән, К. Насыйри татар халкының тарихи риваятьләре, борынгы мифологик ышанулары, гореф-гадәтләре, дөньяга карашлары һ. б. белән башка халыкларны, фән дөньясын таныштыру буенча эш алып бара, рус телендә хезмәтләр чыгара. Өченчедән, галим Көнчыгыш халыклары фольклорын өйрәнә, аның үрнәкләрен татарчага тәрҗемә итеп, бастырып чыгара.

Шул рәвешле, К. Насыйриның фольклор фәнендәге эшчәнлеге төп өч юнәлештә бара.

Үзе чыгарган календарьларда, сүзлекләрдә һәм җыентыкларда К. Насыйри халык иҗаты үрнәкләрен урнаштыруга зур игътибар бирә. **Халык тәҗрибәләре,** төрле **сынамышлар** еш кына ритм һәм рифмага салынган. Мәсәлән: «гыйнвар аеның 6 сында тулы ай — язгы ташу суга бай», «6 сында көн җылы — кырда икмәк бик куе», «Март берендә аяз — аяз булыр бөтен яз», «Марттагы кар бакча җимешенә бик ярар» һ. б.

1881 елгы календаренда ул «Казан бәете», «Шаһгали бәете» кебек әсәрләрне, Казан шәһәренең салынуы, Кабан күле һ. б. турында халыктан язып алган күп кенә **риваятьләрне** урнаштыра. 1883 елгы календарьда «Алып адәмнәр» турында риваятьләргә кыскача тукталып, аларның халыкта киң таралган булуын күрсәтә: «Безнең Болгар йортында, кайсы авылга барсаң да, Алып хакында бер хикәят бар. Күп авылларда мәшһүрдер. Кырларында бер күркәмрәк тау булса, Алып чабатасын каккан дип хикәя кылалар. Бу дәлилдер ки, Болгар йортында бер зур кеше булгандыр. 800 елдан бирле бу сүз онытылмагандыр».

1880 елда басылган «Кырык бакча» исемле китабының һәр бүлегендә диярлек **мәкальләр** һәм **әйтемнәр** урнаштырыла. Мәкальләр, аз сүз белән тирән мәгънә аңлатып, халык тәҗрибәсен җыйнак һәм образлы итеп белдерәләр. Акыл һәм тәрбия бирү максатларында чыгарылган бу китапта К. Насыйри халыкның «хикмәт энҗеләре»ннән киң файдалана.

Аерым бер бүлектә 296 мәкаль һәм әйтем, шулай ук 116 җыр (китап авторы аларны шигырьләр дип атаган), «Чәй бәете», «Уңмаган килен» бәетләрен, «Фикер сынашмак» дигән исем астында 3 экият-табышмак урнаштыра.

К. Насыйри төзегән «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият» дигән (Әдәбият турындагы мәҗлесләрнең җимешләре, 1884) зур хрестоматиянең соңгы 40 нчы бүлеге татар халык иҗаты әсәрләренә багышланган. Бүлек халыкның зирәк акылы, образлы һәм тапкыр фикер йөртүе тудырган табышмаклар белән башлана (27 табышмак китерелә). Галим, бу жанрга кыскача аңлатма биреп, табышмакларның җавапларын да әйтеп бара. Мәсәлән:

Мич тулы пәрәмәч, уртасында — бер калач. *(Күктә йолдызлар арасында — ай.)*

Табышмаклардан соң халык җырлары, берничә бәет һәм 309 мәкаль һәм әйтем китерелә. Бу хезмәтләрендә К. Насыйри фольклор әсәрләрен төрләргә һәм жанрларга бүлеп карый, аларга аңлатмалар бирә. Җырларны да ул, татар фольклористикасында беренче буларак, эмоциональ-мәгънәви эчтәлегенә карап, алты төркемгә бүлә. Сөйгән кешенең буй-сынын, күркәм сыйфатларын мактаган җырлар беренче төркемдә китерелә. Болардан кала, махсус исем бирелгән төркемнәрдә —аерылышу һәм ачыну, күрәсе-кавышасы килү, сагыну, зарлану һәм үпкә, өмет җырлары.

К. Насыйри татар халык җырларының төзелеше, табигате турында да фикерләр әйтә, күп кенә җырларда теләкне соңгы юллар аңлатуын, бер үк җырны төрле көйләргә җырларга мөмкин икәнлеген күрсәтә. Кайбер җырларга кыскача аңлатмалар да бирә.

Күп кенә мәкаль һәм әйтемнәрнең дә мәгънәләре әйтеп барыла. Мәсәлән:

Атасы болан атмаганның углы колан атмас. Күбрәк һөнәрсез атадан һөнәрсез бала туа, димәктер.

Өрә белмәгән эт өенә кунак китерер. Җайсыз сөйләшеп, үзенә зарар сөйләгән кемсәнә хакында.

Узган болытны тотып булмый. Эш үткәч, үкенмәктә файда юк, димәк.

Гыйльми хезмәтләрендә һәм сүзлекләрендә теге яки бу сүзләрнең мәгънәләрен тулырак аңлатканда да К. Насыйри халык җырларына, мәкаль һәм әйтемнәргә еш кына мөрәҗәгать иткән. Мәсәлән, «шикәр» сүзенең мәгънәсен аңлатканда:

Шикәрдин ширин[1], балдин татлы
Тел тибрәтеп әйткән сүзләрең,—

дигән юлларны китерә.

Мәгърифәтче галим халыкның **иң борынгы ышануларын, мифларын, мифик образларын, әкиятләрен** җыйнап бастырып чыгаруга һәм гыйльми тикшерүгә зур әһәмият биргән. 1880 елда аның «Казан татарларының ышанулары һәм гореф-гадәтләре» дигән зур хезмәте Петербургта рус телендә басылып чыга («Поверья и обряды казанских татар»). Китапның кереш өлешендә автор мифик ышануларны ничек җыюы һәм өйрәнүе турында да кыскача мәгълүмат биреп уза: «...тикшерену һәм күзәтүләремне, бер яктан, балачакта ук ишеткән хикәяләремә һәм, икенче яктан, бу мәсьәләгә фәнни күзлектән карый башлавымнан соң, татарлардан сорашып белүләремә нигезләнеп яздым».

Татар мифологиясендәге образларны ул ике төркемгә бүлә: 1) су астында торучы әкәмәтләр — су бабасы, су иясе, су анасы, юха елан; 2) җир өстендә яшәүче әкәмәтләр — убыр, албасты, өрәк, бичура, өй иясе, абзар иясе, чәчәк анасы, чәчәк иясе, Шүрәле, җен һәм дию пәрие.

Аларның һәркайсына характеристика бирелә. Мәсәлән, су анасы татарга су буенда чәчен тарап утыручы хатын кыяфәтендә күренә.

Шүрәләләр урманда яши, татар очраса, алар аны кети-кети уйнарга чакыралар, әгәр ул күнсә, үтергәнче кытыклыйлар. Ләкин татар Шүрәләне алдалый ала: балта белән ярган агачка кулын тыгып уйната да аның бармакларын бүрәнә ярыгына кыстыра. Шүрәле, бармакларының авыртуына чыдый алмыйча, бик каты акыра башлый, иптәшләрен чакыра. Әгәр дә татар Шүрәләнең: «Син кем?» — дип соравына: «Мин Былтыр атлы»,— дип әйтергә башына килсә, Шүрәләнең: «Былтыр кысты, Былтыр кысты!» — дип кычкыруына җыелган иптәшләре хәйләкәр татар артыннан чабу түгел, бәлки: «Былтыргы елны каян эзлисең, табып буламыни аны!» — дип, Шүрәледән кычкырып көләләр генә, имеш. «Күрәсең, шүрәләләр бик аңгыра булалар икән»,— дип тәмамлый бу өлешне К. Насыйри. Шүрәле образын матур әдәбиятта беренче булып кулланучы да К. Насыйри була. «Әбүгалисина кыйссасы»нда бу

[1] Ширин — татлы.

образны берничә урында китерә. Соңыннан Г. Тукайның «Су анасы» һәм «Шүрәле» дигән матур-матур поэмалар язганлыгын беләбез. Композиторлар Ф. Яруллин һәм Ә. Бакиров бу темаларга халык яраткан балетлар иҗат иттеләр.

1896 елда К. Насыйриның «Казан татарларының халык әдәбияты үрнәкләре» дигән хезмәте Казанда рус телендә басыла («Образцы народной литературы казанских татар»). Бу хезмәттә 28 табышмак, 243 мәкаль һәм 145 җырның татарча текстлары һәм аларның русчага тәрҗемәләре дә бирелә.

Галимнең халык иҗатын өйрәнүдәге эшчәнлеге гомеренең соңгы елларында да тукталмаган. 1900 елда аның «Казан татарларының әкиятләре» дигән хезмәтендә татарча һәм русчага тәрҗемәдә 11 әкияте басыла («Сказки казанских татар и сопоставление их со сказками других народов»). Бу хезмәттә татар әкиятләрен рус һ. б. халыкларның әкиятләре белән чагыштырып тикшерү омтылышы ясала.

Шул рәвешле, мәгърифәтче галим, татар фольклорының күп кенә жанрларында да эшләп, халыкның рухи байлыгын, акыл һәм күңел җәүһәрләрен барлап, бергә туплап, халыкның үзенә кайтару юлында армый-талмый хезмәт иткән.

«Таң йолдызы» калыкмаса да...

Халык арасында аңлату эшләрен системалы рәвештә алып бару максатында, К. Насыйри алтмышынчы еллар башында ук татар телендә газета чыгару омтылышы белән йөргән, үзенә хезмәттәшләр тапкан. 1862 елның декабрендә литография[1] хуҗасы Мөхәммәтвәли Яхин белән Каюм Насыйри бергәләп икесе исеменнән Казан губернаторына үтенеч бирәләр. Алар кул куйган гаризадан күренгәнчә, «Таң йолдызы» дип аталачак газетада, төрле хәбәрләр белән бергә, «көнкүрештә кирәкле өлкәләргә караган популяр мәкаләләр, этнографик язмалар, ял сәгатьләрендә уку өчен хикәяләр» бастыру күздә тотылган.

Казан губернаторы бу үтенечне Эчке эшләр министрлыгына җибәрә.

Нәкъ шушы елларда Петербургта Х. Фәезхановның П. И. Пашино белән бергәләп «Чулпан» газетасын чыгару ниятендә булганлыгын без инде беләбез. Х. Фәезханов К. Насыйриның татарча газета чыгару омтылышлары белән дә якыннан кызыксынган. Бу хакта ул М. Мәхмүдов һ. б. кайбер кешеләр белән

---

[1] Литография — яссы таш өслегенә төшерелгән хәрефләрдән, рәсемнәрдән басма алу. Татарларда ташбасма дип тә аталган.

хәбәрләшеп торган. «Күп вакыттан бирле,— дип яза ул 1862 елда Казанга җибәргән бер хатында,— бу уй минем вә дәхи ничә кешеләрнең күңелләрендә уйный иде». Хатларында ул, Казандагы башлангычка сөенүе белән бергә, әледән-әле: «Начальство рөхсәт бирерме?» — дип, тирәнтен борчылуын да белдерә.

Ләкин мәгърифәт күгебездә балкып янарга тиешле «Таң йолдызы» калка алмый кала. Патша хөкүмәте аны чыгарырга рөхсәт бирми.

1871 елдан К. Насыйри ярымжурнал рәвешендә еллык өстәл календарьлары чыгара башлый. Шуның белән бергә, ул газета чыгару уеннан бу елларда да кайтмаган. Газета чыгару теләге тормышка ашмаса да, еллык өстәл календарьларын К. Насыйри чирек гасыр дәвамында (1897 елга кадәр) бастырып килә. Аларда ул әдәби-фәнни темаларга мәкаләләр, яңа чыккан китапларга күзәтүләр, халык иҗаты әсәрләрен, сынамышларны һәм тарихи материалларны биреп бара.

1877 елгы календаренда, мәсәлән, Габденнасыйр Курсавиның тормышы, эшчәнлеге, акылга ирек таләп иткән идеяләре белән таныштыра. «Имам вә мөдәррис, заманының чын мәгънәсендә дикъкатькә лаек зур галимнәреннән» булганлыгын, «яңача иҗат итүче» атаклы фикер иясе икәнлеген күрсәтә. Курсави әсәрләренең төп эчтәлеге бу мәгънәдә, ди ул, кеше үз фикеренчә иҗтиһад кылырга, тырышлык күрсәтергә тиеш. «Иҗтиһад, эшчәнлек заманы узмаган, бетмәгән» («Заманы иҗтиһад мөнкарыйз түгел»). Шул ук елгы календаренда ул шагыйрь Г. Утыз Имәнинең тормышы һәм иҗаты турында матбугатта беренче мәгълүматларны бирә. Календарьларда шулай ук Әбелмәних Каргалый, Һибәтулла Салихов кебек шагыйрьләр хакында, Шиһабеддин Мәрҗани әсәрләре һ. б. турында фикерләр әйтелә. Көнчыгышның бөек галимнәре һәм фикер ияләре әл-Фәраби, Ибне Сина (Әбүгалисина) хакында белешмәләр урнаштырыла.

Яшь буынны укыту һәм тәрбия итүгә багышланган мәкаләләрендә К. Насыйри бу эшләрдәге җитешсезлекләрне тәнкыйть итә (1887, 1891 еллардагы календарьлар).

15 бүлектән торган «Казан халкына мөрәҗәгать» дип исемләнгән кулъязмасы, күрәсең, «Таң йолдызы» газетасы өчен әзерләнеп, үз заманында басылмый калган. «Беренче мөрәҗәгать», «Икенче мөрәҗәгать»... дип тәртип саннары белән күрсәтелгән бу мәкаләләр сериясендә автор, уку-укыту эшләрендәге иске тәртипләрне кире кагып, мәгърифәтне, ба-

лаларга дөньяви белемнәр бирүне кайнар яклаучы публицист буларак күренә.

Халыкның наданлыгы, аеруча яшь буынның язмышы турында ул тирәнтен борчылып, ачынып яза. «Бөтен дөнья халкы гыйлем арттыруга омтылып торганда,— ди ул,— сез киресенчә эш итәсез. «Ул нигә кирәк, бу нигә кирәк?» — дисез. Гыйлем кирәк булмый икән, ишәк бул, гыйлем кирәк булмаса, китабын да язмаслар иде». Автор мәктәп-мәдрәсәләрдә, балаларга фән нигезләреннән белем биреләсе урында, дини эчтәлекле иске китаплар гына укытылуын тәнкыйть итә. «Хисаптан, географиядән, геометриядән, табигатьтән, тарихтан, химиядән, һөнәр һәм сәнгатьтән — һәркайсыннан балаларыгызга бераз-бераз белем бирү тиеш иде»,— ди ул.

Укыту-тәрбия мәсьәләләренә багышлап, К. Насыйри «Әхлак рисаләсе», «Тәрбия китабы» кебек кечкенә-кечкенә китаплар да бастырып тарата. Әхлак төзәтү, тәрбия — бу заман татар матур әдәбиятының да төп мәсьәләләре.

Мәгърифәтченең тормышын һәм эшчәнлеген озак еллар җентекләп өйрәнгән күренекле галим Мөхәммәт Гайнуллин, К. Насыйри татарларда беренче журналист-энциклопедист та булган, дип нәтиҗә ясавы белән бик тә хаклы иде.

1905 елгы революция елларында татар вакытлы матбугаты кинәт җәелеп, күтәрелеп киткән икән, аның чишмәләрен башлап К. Насыйри кебек мәгърифәтчеләр ачканлыгын искә алырга тиешбез.

Көнчыгышның гыйбрәтле хикәятләре.

К. Насыйри эшчәнлегенең зур бер мөстәкыйль тармагы — матур әдәбият өлкәсендәге хезмәтләре. 1868 елда аның тәрҗемәсендә «Кырык вәзир кыйссасы» басылып чыга. Үзенең төп чыгышы белән «Мең дә бер кичә» әкиятләренә барып тоташкан мәшһүр бу әсәр XIV йөздә гарәп телендә «Кырык иртә вә кырык кичә» исеме белән төзелгән. XV гасырда төрек язучысы Шәехзадә Әхмәт Мисрый тарафыннан «Кырык вәзир» исемендә эшләнә. К. Насыйри, шушы вариантны бераз кыскартып, төрекчәдән тәрҗемә итә.

Әсәр халык әкиятләрендәгечә, ләкин инде язма әдәбиятка хас булганчарак башланып китә: «Тарих китапларында риваять кылып язалар ки, гаҗәм[1] йортында Ханкыйн исемле бер олуг патша бар иде». Күрәсезме, әкиятләр, гадәттә, «Борын-

[1] Гаҗәм — гарәп булмаган халыклар; иранлылар.

борын заманда бар иде бер патша...» дип башланса, монда вакыйгаларның тарих китапларында язылганлыгы әйтелә, патшаның исеме атала, яшәгән урыны да «гаҗәм йортында» дип конкретлаштырыла. Бу патша улының «анасы Хытай мәмләкәтенең кызларыннан иде» дип күрсәтелә.

Патшаның бик сөекле һәм гаять күркәм улы була. Егет төрле һөнәрләргә дә чиксез оста. Уку-язу, ук ату һ. б. сугыш һөнәрләрендә аңа тиңнәр юк. Ләкин берзаман аның әнисе үлеп китә. Әтисе яшь хатынга өйләнә. Бу хатын патшаның улына гашыйк булып яна-көя, шулай да сабыр итә. Әмма тора-бара мәхәббәте көчәя барып, ул көне-төне бер-бер хәйләсен табу уенда була.

Атасы егетне астрономия фәне белән шөгыльләнүче бер остазга укырга бирә. Көннәрдән бер көнне остазы, йолдызлар хәрәкәтен күзәтеп, егетнең язмышын юрый, аңа бик зур куркыныч янавын — башы киселәчәген күрә: бу хакта егеткә әйтә һәм моның чарасы бар, кырык көн буена һич бер сүз сөйләшмәскә дип кисәтә.

Бик үз итеп, яратып сорашкан сорауларына җавап бирмәгән, бер сүз сөйләшмәгән улын әтисе, аптырап, «бәлки хафасын әнисенә сөйләр» дип, яшь хатын янына җибәрә.

Үги улы белән ялгыз күрешеп, мәхәббәтен белдерергә хәйлә эзләп йөргән хатынга, ниһаять, бик яхшы җай чыга. Хезмәтчеләрен чыгарып җибәреп, егетнең муенына кулын салып, әтиең инде карт, үзең патша булырсың дип, ярату тойгыларын белдерә, әтисен ни рәвешле агулап үтерү, соңыннан өйләнешү хәйләләрен сөйли. Егетнең бер сүз дә дәшми торуын күреп, тәмам сабырсызлана, кочаклап үпмәкче була. Әсәрнең шушы урынында вакыйганы сурәтләү бик тыгыз һәм хәрәкәтчел итеп бирелә:

«Углан, ачуланып, кулының аркасы белән хатынның авызына шулкадәр каты чапты, хатынның күзеннән утлар күренеп, авызы туп-тулы кан булды. Хатын, бу хәлне күргәч, ачу уты күкрәген яндырып, миенең төтененнән күңеленә корым утырып, угланга явызлык касд[1] кылды». Бу эпизод әсәр сюжетының төенләнешен дә тәшкил итә. Шуннан соң вакыйгалар үстерелеше башлана.

Хатын, авызыннан аккан канга киемнәрен буяп, елый-елый патшага зарлана. «Улың, миңа кул озайтып, мәсхәрә итәргә

---

[1] Касд — уй-ният, явыз ният.

теләде, мин риза булмагач, сиңа фаш булмасын өчен, мине үтерергә ташланды,— дип сөйли.— Ул сине дә һәлак итмәкче була»,— дип ялганлый. «Тизрәк ул сине үтермәс борын, син аны элгәре үтер, явызлыгыннан имин булырсың!» — дип котырта.

Патшаның, ачуы кабарып, төне буе күзенә йокы керми. Иртән, җәлладны чакыртып, улының башын кисәргә боера. Әмма аның якын кешеләре, җәлладны бераз тоткарлап, вәзирләргә хәбәр итәләр. Бик ашыгып-кабаланып килеп җиткән яхшы күңелле вәзирләр егетне яклыйлар. Көн саен иртә-кич вәзирләр һәм хатын хикәятләр сөйли. Кырык көн дәвамында сөйләнгән хикәятләр китапның «уртадагы» эчтәлеген хасил итә. Ягъни төп сюжет эчендә кечкенә-кечкенә бүтән сюжетларга корылган хикәятләр тезелеп китә. Бу хикәятләр төп вакыйга белән тыгыз бәйләнештә китерелә. Көнчыгыш әдәбиятларында киң таралган мондый төзелешле әсәрләрне «кысалы кыйсса» дип атыйлар.

Хатын сөйләгән хикәятләрдә сүз балаларның инсафсызлыгы, аталарына хыянәте, гомумән, явызлыкның җиңүе турында бара. Вәзирләр сөйләгән хикәятләрдә болар инкяр ителә, яхшылык, гаделлек, намуслылык, тугрылык өстен чыга. Кырык көн буена егетнең язмышы кыл өстендә тора. Хатын хикәятләреннән ачуы кабарып ярсыган, әмма вәзирләр сөйләвеннән күңеле йомшарып киткән ата кеше улын җәзалауны кичектерә килә.

Ниһаять, вакыйга үстерелеше кульминациягә җитә, ягъни иң югары ноктага күтәрелә: егетне генә түгел, инде вәзирләрне дә хыянәттә гаепләгән мәкерле хатынның хәйләле сүзләренә ышанып, патша, улы белән бергә аларны да җәза мәйданына чыгарып, башларын кисәргә боера. Җәллад, ялангач кылычын күтәреп, мәйдан әйләнгәндә, егетнең остазы күренә. Аны да, шунда ук тотып алып, «аягын җиргә тидермичә», патша каршына китерәләр.

Шуннан инде — бәхетле чишелеш: гаделлек җиңеп чыга, явызлык, мәкер гаепләнә. Остаз һәм шаһзадә эшнең асылда ничек булганлыгын сөйләп бирәләр. Хатын исә җәзасын ала.

Күргәнебезчә, әсәрнең үзәгенә әхлак мәсьәләсе куелган. Мәгърифәтче язучылар, кешеләрне белемле һәм һөнәрле итү белән бергә, югары әхлакый сыйфатлар тәрбияләүгә зур игътибар бирделәр. К. Насыйри да мавыгып укыла торган, тәэсирле бу әсәр белән кешеләрне явызлык кылудан качарга, яхшы, гадел булырга өйрәтә. Әсәрдән чыга торган идеяне көчәйтеп,

ул болай ди: «Изгелек теләсәң, башыңа булсын. Гайре (башка.— *Ш. С.*) кешегә кое казысаң, тирән казы, ихтимал, үзең төшәрсең».

Әсәрдә язма тел үзенчәлекләре халыкның җанлы сөйләменнән алынган гыйбарәләр белән үрелеп-үрелеп китә. К. Насыйри саф татарча диалогларны, мәкаль-әйтем, чагыштыру һ. б. чараларны еш куллана. Мәсәлән: «Хатын ... шаһзадәне күргәч, мең җан белән гашыйк булды. Гаять гүзәл сөлек шикелле егет. Хатыннар әйтә торган сүз: кашыклы су белән йотарсың». «Бер һәйбәт гүзәл кыз, айның ундүртенче кичәсе кебек». «Кайда бал булса, анда чебен җыела» һ. б.

Бу китап укучылар тарафыннан яратып кабул ителә, һәм ул 1910 елга кадәр 8 мәртәбә басыла. 1911 елда казахчага тәрҗемә ителеп чыга.

Әбүгалисина хикмәтләре. 1872 елда К. Насыйри төрекчәдән янә бер әсәрне — «Әбүгалисина» әсәрен тәрҗемә итә. 980—1037 елларда яшәгән атаклы таҗик галиме Әбүгалисина (Ибне Сина) турында Көнчыгыш халыкларында күп санлы фантастик хикәятләр, риваятьләр барлыкка килгән. Төрек язучылары аларны бергә җыеп, эшкәртеп, аерым китап итеп төзегәннәр. Зыяддин Сәед Яхъя язган вариант татарлар арасында кулъязмада да укылып йөргән. 1864 елда ул Казанда басылып чыга. Ләкин К. Насыйрины әсәрнең гарәп-фарсы гыйбарәләре белән чуарланган теле, сәнгатьчә эшләнеше канәгатьләндерми. Ул аны «халык аңларлык итеп» яза.

Бу әсәр, андагы төп образлар белән сез инде 7 нче сыйныфта танышкан идегез. Бу юлы аларны кабат искә төшереп, әсәрнең идея эчтәлеген, сәнгатьчә эшләнешен тирәнрәк өйрәнергә тырышырбыз.

К. Насыйриның, әлеге китапны киң күпчелеккә аңлаешлы рәвештә үзенчә эшкәртеп, тәрҗемә итәргә алынуы очраклы хәл идеме? Юк. Ул аның мәгърифәтчелек уй-теләкләренә һәм демократик карашларына җавап биргән.

Беренчедән, әсәрнең үзәгенә, баш герой буларак, мәгърифәтле зур галим кеше алынган. Мәгърифәтнең, төрле фәннәрне яхшы белүнең көч-куәте, могҗизалар тудыру сәләте, халык әкиятләрендәгечә, фантастик вакыйгаларда сурәтләнә. Әйтик, Әбүгалисинага табигать көчләре, җилләр дә буйсына. Бу образ укучыда мәгърифәткә, аң-белемгә, һөнәргә омтылыш, мәхәббәт тәрбияли.

Икенчедән, татарлар арасында мәгърифәт чаралары үсеп барган шартларда мондый сорау да тумый калмагандыр: мәгърифәт һәм гыйлем кемнәргә һәм нәрсәгә хезмәт итәргә тиеш? Өстен катлауларга, патшалар һәм түрәләргәме? Яисә гади халыккамы? Фән казанышларын явызлык өчен файдаланырлармы, әллә яхшылык максатындамы? Әсәр моңа үзенчә ачык җавап бирә: мәгърифәт һәм гыйлем хаклык яклы булырга, гади кешеләргә ярдәм итәргә тиеш.

Бу идеяләр укучыга, нигездә, Әбүгалисина һәм Әбелхарис образлары ярдәмендә җиткерелә. Бер ата, бер анадан туган игезәк ике бала бер мәктәптә укыйлар. Әбелхарис «бераз авыррак зиһенле» була. Әбүгалисина исә «үткенлеге белән кылны кырыкка ярыр иде» диелә. Аны сурәтләүдә гиперболик алымнар кулланыла. Мәктәптәге иптәшләре аның киезе астына бер бит кәгазь салып куйгач, Әбүгалисина аны да сизә. Әбелхарис белән икәүләп алар гыйлем арттыру теләге белән дөнья гизәргә чыгып китәләр. Көнбатыш илендәге бер шәһәрдә елга бер мәртәбә ачыла торган, Фисагурис (Пифагор) дигән борынгы галимнең әсәрләре сакланган мәгарәгә кереп, белем алалар. Хәтта симия гыйльме серләренә ия булалар. Бу белеме булган кеше теләсә нинди кечкә каршы тора, аны җиңә ала икән.

Мәгарәдән чыккач, аларның юллары аерыла. Әбелхарис, Багдад шәһәренә барып, әфсен көче белән гаҗәеп гүзәл мунча салдыра. Аннан соң аның эш-гамәлләре патшаларга хезмәт итү белән бәйле булып китә. Әбүгалисина, Мисырга барып чыгып, фәкыйрь хәлвәфрүшкә (хәлвә пешереп сатучыга.— *Ш. С.)* ярдәм итә башлый, патшалар белән конфликтка керә. Төрле маҗаралы вакыйгаларда ул алардан өстен чыга. Әбүгалисина белән Әбелхарис әхлакый сыйфатлары белән дә аерылалар, гыйлем көчен төрле максатларда файдаланалар. Әбүгалисина кешелекле, ярдәмчел; ул саран байларны, явыз патшаларны мәсхәрәгә калдыра, гади халыкка ярдәм итә. Мин-минлеге көчле булган Әбелхарис исә, хуҗаларына ярарга тырышып, туганына каршы көрәш алып бара. Еш кына аның үзен дә кимсетәләр, булдыксыз дип хурлыйлар. Ахыр чиктә ул Әбүгалисинаның патшага дип җибәргән агулы чәчәген иснәп һәлак була.

«Кырык вәзир кыйссасы»ннан аермалы буларак, «Әбүгалисина» әсәре фантастик планда иҗат ителгән. Анда, реаль тормыш эпизодларын сурәтләгән кайбер урыннар булу белән бергә, нигездә, фантастик әкиятләр стиле өстенлек итә (Әбүгали-

сина белән Әбелхарисның, айга бер мәртәбә су кабып, берничә бавырсак белән тукланып, ел буе мәгарәдә белем алуы, күз ачып йомганчы бик ерак җирләргә барып җитүләр, юктан бар ителгән сарайларны, бакчаларны, шәһәрләрне, мәҗлесләрне әкиятләрдәгечә бик арттырып сурәтләүләр һ. б.).

Тел-сурәтләү чараларына килсәк, «Кырык вәзир кыйссасы» белән чагыштырганда, бу әсәрдә К. Насыйри халык тудырган образларга, җанлы сөйләмдәге тәгъбирләргә күбрәк мөрәҗәгать итә. Мәсәлән, Әбүгалисинаның мәгарәдән чыккандагы кыяфәтен (чәч-сакаллары үсеп укмашкан, тырнаклары озаеп беткән) сурәтләгәндә, **«урмандагы Шүрәле кебек булган иде»**, ди. Берзаман патша сараена китерелгән Әбүгалисина вәзирләрне һәм патшаны, сулы таска каратып, төрле җирләрдә итеп күрсәтә. Сарайның бер әһеле үзен сусыз сахрада күрә. «Гаять эссе коры комлык сахрадыр. Асла яшел үлән әсәре юк. **Урман шүрәлесе юлыкса, сусызлыктан җан бирер»**.

Әдип әлеге әсәрендә рифмалар кулланып, кайчагында ритмга салып язарга ярата. Мәсәлән: «Агачлары һавага **киткән**, алмалары үсеп **җиткән**, җимешләре тәмам **пешкән»**. «Агачның астына барып **яттылар**. Бераз яткач, йокы дәрьясына **баттылар»**. «Өйдә утырса — **курка**, тышка чыкса — **бака**: торырларына шәһәр тар булды» һ. б.

Хикәяләүне болай бизәкле һәм эмоциональ итү алымы соңрак З. Һади прозасында кулланыла.

«Әбүгалисина» әсәренең шактый өлешен персонажларның үзара сөйләшүләре — диалоглар алып тора. Геройларның үзара нинди мөнәсәбәттә булуларына карап, сөйләшү я бик ягымлы, я бик кискен, дорфа характерда. Әйтик, Әбүгалисинаның, хәлвә пешерүче егет һәм аның әнисенең үзара сөйләшүләре ягымлы, йомшак итеп бирелә. Әсәрдә шулай ук хат белән мөрәҗәгать итүләр дә кулланыла. «Әбүгалисина» әсәре күп мәртәбәләр басыла.

Кырык бакчаның җимешләре.

1880 елда әдипнең «Кырык бакча» дигән җыентыгы дөнья күрә. Кырык бүлектән торган бу китапта кешенең яхшы һәм яман яклары турында сүз бара. Һәр бүлек (бакча) билгеле бер сыйфатка багышланган. Кереш өлешендә баланың ана карынында ничек яралуын, үсүен сөйләгәч, беренче бүлектә — акыл, икенчесендә — гыйлем, ә өченче бүлектә — әдәп, бишенчедә — зирәклек, җиденчедә тугрылык кебек төшенчәләр аңлатыла. Күп кенә бүлекләрдә аңгыралык,

куркаклык, наданлык һ. б. кебек тискәре сыйфатлар тәнкыйть ителә. Боларны язганда, автор күп кенә фикерләрне, мисалларны Көнчыгыш галимнәре китапларыннан тәрҗемә итеп ала, үзлегеннән дә иҗат итә. Фикерләрне раслау өчен, кыска-кыска хикәятләр китерә.

Бу хикәятләрдә үз заманының социаль күренешләре тәнкыйтьләнә («Бай һәм хезмәтче», «Мөәзин», «Ишанланучылар бәянында» һ. б.). Афористик характердагы бик күп хикмәтле сүзләр әйтелә («Һәрбер нәрсәнең чиге бар, акылның чиге юк». «Әгәр берәүгә гыйлем үгрәтергә теләсәң, әүвәл үзеңне үзең үгрәт» һ. б.).

«Кырык бакча» китабы — К. Насыйриның җитмешенче еллар азагында ук төзи башлаган иң зур хрестоматиясе — «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият» («Әдәбият турындагы мәҗлесләрнең җимешләре») дигән җыентыкның кыскартылган варианты. «Фәвакиһел-җөләса...» үзе 1884 елда басылып чыга. Ул шулай ук кырык бүлектән тора. Күп кенә кыска хикәят мәзәкләрне халыктан К. Насыйри үзе язып алганга охшый. Мәсәлән, бер хикәяттә сүзнең гомер буе җир налогы (имана) түләп җәфа чиккән татар крестьяны турында барганлыгын шактый анык чамаларга мөмкин: «Бер фәкыйрь үлем сырхавы хәлендә. Якыннарыннан янына җыелган адәмнәр: «И фәлән, хәлең начар, иманыңны әйт», — дигәч, ул бичара: «Һай шул үлем хәлендә дә имана белән аптыраталар ла!» — димеш».

«Патша белән карт» хикәятендә патша һәм аның түрәләре иң явыз кешеләр итеп сурәтләнә, халыкны җәберләүләре күрсәтелә.

Шул рәвешле, әдәби әсәрләрдә дә К. Насыйриның гади халыкка теләктәшлеге, демократик карашлары гәүдәләнә. Иҗтимагый мәсьәләләрне сәнгатьчә сурәтләгәндә, үзенчәлекле юллар таба.

К. Насыйриның иҗаты, эшчәнлеге халыкчанлык белән сугарылган. Бу аның халык өчен әһәмиятле мәсьәләләрне күтәрүендә, халык мәнфәгатьләрен яклавында һәм китапларында халык иҗатына киң урын бирүендә күренә.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: К. Насыйриның гаять күпкырлы эшчәнлеге төп ике зур тармакка бүленә: гыйльмимәгърифәтчелек һәм әдәби-тәрҗемәчелек юнәлешләре. Яңа татар әдәбияты үсеп китәр өчен, гүяки ул туфрак йомшарта, түтәлләр әзерли, үзе дә беренче гөлләр үстерә башлый. Шуңа күрә без аны зур галим генә түгел, зур әдип дип тә атыйбыз.

Әдәбиятның халыкчанлыгы

Халыкчанлык — әдәбият һәм сәнгатьнең иң әһәмиятле төшенчәләреннән берсе. Заманнар үзгәрү белән, бу төшенчә дә үзгәрә, байый килгән. Халыкчанлык термины әдәбиятта халык авыз иҗатына игътибар арту, фольклор әсәрләрен җыеп бастыру, алардагы образларны, сюжетларны, алымнарны файдалану, охшатып, ияреп язу белән бәйләнештә кулланыла башлый. Мәсәлән, Г. Тукайның «Шүрәле», «Су анасы», «Кәҗә белән Сарык» әсәрләре, А. С. Пушкинның әкият-поэмалары. Шушы мәгънәдә ул еш кына хәзер дә кулланыла.

Тора-бара гади халык тормышыннан алып әсәрләр язуны, халык тормышын дөрес һәм теләктәш булып гәүдәләндерүне халыкчанлык дип атый башлыйлар. Теге яки бу әсәрдә гади халык тормышы турыдан-туры чагылмаса да, халыкны борчыган мәсьәләләр күтәрелүе әһәмиятле санала. «Әдәбият, әгәр дә ул какшамас һәм мәңгелек буласы килсә, һичшиксез, халыкчан булырга тиеш»,— дип яза В. Г. Белинский.

Халыкчанлыкның нигезендә, асылда, язучының, әдәбиятның халык белән бердәмлеге ята. Шуннан чыгып, гадәттә, халыкчанлыкның төп өч шартын күрсәтәләр.

Беренчедән, язучының әсәрендә, гомумән иҗат эшчәнлегендә, халыкны борчыган, гомумхалык өчен әһәмиятле булган проблемаларны күтәрү чагылырга тиеш. Әмма кайбер язучы мондый мәсьәләләрне куеп та, аларны халык мәнфәгатьләреннән чыгып хәл итмәскә мөмкин. Шулай булгач, икенче шартның булуы сорала.

Димәк, икенчедән, халыкны борчыган әһәмиятле мәсьәләләрне язучы, халык карашына нигезләнеп, халык мәнфәгатьләренә аваздаш рәвештә хәл итәргә тиеш.

Өченчедән, бу шартлар үтәлеп тә, әсәрләрне киң халык массасы аңламаса, укый алмаса, аларны чын халыкчан әсәрләр дип әйтеп булмый. Димәк, халыкчанлыкның әһәмиятле өченче шарты — әсәрләрнең, язучы иҗатының халыкка аңлаешлы телдә язылуы, аңа якын, үз булган сурәтләү чараларын куллану. Бу юнәлештә Г. Кандалый һәм К. Насыйриның зур адымнар ясаганын күрдек. Әйтик, «Әбүгалисина» әсәрен эчтәлеге белән дә, халыкка якын сурәтләү чаралары белән дә, заманына, шартларына карап, халыкчан әсәр дип атый алабыз. Гомумән,

К. Насыйриның иҗаты да, эшчәнлеге дә халыкчанлык рухы белән сугарылган иде.

XX йөз башы әдипләреннән Г. Исхакый, Г. Тукай, Г. Ибраһимов һ. б. иҗат эшчәнлегендә бу сыйфатлар тагы да баеды, ныгыды.

Сораулар һәм биремнәр

1. Ни өчен без К. Насыйрины күпкырлы эшчәнлек күрсәткән мәгърифәтче галим дип атыйбыз? Аның эшчәнлегенең төп тармакларын күрсәтеп чыгыгыз, мисаллар китерегез.
2. К. Насыйри тәрҗемә иткән яки файдаланып язган әсәрләрнең әһәмиятен ничек аңлыйсыз?
3. «Кырык вәзир кыйссасы» һәм «Әбүгалисина» әсәрләреннән халыкчан тел-сурәтләү чараларын табып, дәфтәрләрегезгә язып алыгыз.
4. К. Насыйриның «Кырык бакча» һәм «Фәвакиһел-җөләсә...» китапларында китерелгән хикәятләрдә иҗтимагый мәсьәләләрнең чагылышы.
5. «К. Насыйри һәм татар халык авыз иҗаты» дигән темага инша языгыз.

РЕАЛИСТИК ПРОЗА ҮСЕШЕ

Алда күреп үткәнебезчә, XIX йөзнең икенче яртысында әдәбият, мәгърифәтчелек идеяләре белән сугарылып, татар халкының үз тормышына, үз теленә, заман алга куйган реаль, актуаль мәсьәләләргә йөз белән борыла бара. Бу борылыш әдәби төрләр һәм жанрлар системасына да зур үзгәрешләр кертә. Тезмә, шигъри әсәрләр язылу белән бергә, чәчмә әсәрләр, ягъни проза активлаша. Татар прозасы реализм нигезләрендә үсеш чорына керә.

Кыйссалардан — романга.

Реалистик хикәя, повесть һәм романнар буш урында барлыкка килмәделәр, әлбәттә. Элекке әдәбиятта геройларны һәм алар катнашкан вакыйгаларны хикәяләп язуның бай традициясе бар иде (хикәятләр, кыйссалар, дастаннар). Әкиятләргә, Көнчыгыш кыйссаларына нигезләнеп, заманча художестволы проза әсәрләре тудыру омтылышлары да арта. Гасыр урталарында «Мәликә китабы», «Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз» дигән кечкенә-кечкенә хикәят китаплары чыга. Бу китапларда белемле һәм һөнәрле булу идеяләре алга сөрелә. Татар телендә Хуҗа Насреддин мәзәкләре дөнья күрә һәм алга таба мондый җыентыклар еш чыгарыла. М. Ивановның «Татар хрестоматиясе»ндә «Иван Костин» повесте, Крылов мәсәлләре русчадан проза белән тәрҗемә итеп бастырыла. С. Кукляшев «Диване хикәяте татар» җыентыгында чәчмә хикәятләр урнаштыра.

Гасырның икенче яртысында Көнчыгыш (гарәп, фарсы,

төрек һ. б.) әдәбиятларыннан күп кенә проза әсәрләре тәрҗемә ителә. Бу юнәлештә К. Насыйриның актив эшчәнлеген күреп уздык. Татар реалистик романнары һәм повестьлары туудa, халык иҗаты һәм язма әдәбият белән бергә, бөтенләй яңа өченче фактор — рус һәм Европа әдәбиятларыннан өйрәнү, үрнәк алу булды. Безнең әдәбиятта беренче реалистик романнарның авторлары Муса Акъегетзадә һәм Заһир Бигиев татарча да, русча да белем алган, рус һәм Европа әдәбиятлары, мәдәниятләре белән яхшы таныш булган әдипләр иде. Иҗат эшенә алардан бераз соңрак, гасыр азакларында керешкән Фатих Кәрими исә француз телен дә әйбәт белгән.

Язма прозага күчә бару билгеләрен без «Кырык вәзир кыйссасы»ның башламы мисалында күреп узган идек. Ул персонажларны һәм вакыйгаларны азмы-күпме тормышка якынайту юнәлешендә иде. М. Акъегетзадәнең «Хисамеддин менла» романы (1886) вакыйганың урыны, вакыты турында тагын да конкретрак, реаль мәгълүматлар бирүдән башлана: Россиянең уртасында Идел елгасыннан ерак түгел бер татар авылы бар...

«Өлүф (меңнәр), яки Гүзәл кыз Хәдичә» әсәрен (1887) З. Бигиев шулай ук вакыйганың берничә ел элек Казан шәһәрендә булганлыгын әйтеп башлый.

Ризаэддин Фәхреддин «Сәлимә, яки Гыйффәт» романына (1898) кереш сүзендә болай ди: «Хикәятемез, Казан шәһәреннән башлап, Итил өстеннән Самарга вә аннан Әстерхан шәһәрене кичеп, Бакуга кадәр озанмыштыр». Автор шунда ук «хикәятемез үз халемезгә мөнәсәбәтле вә үз тормышыбызга бәйләнешле» дип ассызыклап үтә.

Кыскасы, бу чор әдипләре үзләренең әсәрләрен, элекке әдәбияттан аермалы буларак, нәкъ менә татар тормышының реаль җирлеген күрсәтүдән башлыйлар. Мондый башламнар үзләре генә дә татар прозасының реалистик нигездә үсә башлау ноктасы булып тора, милли тормышны чагылдыруга йөз белән борылуны раслый.

Күп кенә әсәрләрдә авыл, шәһәр, губерна исемнәре еш кына хәреф белән белдерелә. Бу алым рус һәм Европа әдәбиятларыннан килә иде. Соңга таба Ф. Кәрими, З. Һади кебек язучылар авылларны да исеме белән атый башлыйлар (Торналы, Юкәле һ. б.).

Тормыш күренешләрен, халыкның хәлен бер әсәрдә киңрәк колачлау, геройларны төрле вакыйгаларда һәм бәйләнешләрдә сурәтләү, мәгърифәт мәсьәләләре хакында укучы белән

иркенләбрәк сөйләшү максатларында, мәгърифәтче язучылар роман, повесть кебек зуррак күләмле жанрларны кулай күрәләр. Бер генә вакыйганы сурәтләгән кечкенә күләмле реалистик хикәя бик очрамый.

«Роман» дигән термин, жанр атамасы ул вакыттагы татар укучысы өчен бөтенләй яңа, ят, ияләшмәгән сүз була. Бәлки шуңа күрәдер, мәгърифәтче прозаиклар бу термин белән янәшә «хикәя» сүзен кулланалар. М. Акъегетзадә үз әсәрен «милли роман яки хикәя» дип атаган. З. Бигиев, «Меңнәр, яки Гүзәл кыз Хәдичә», «Зур гөнаһлар» әсәрләрен «роман» дип бер сүз белән атаса да, әсәрләрнең эчке текстында «хикәямез» дип яза. Күп кенә әсәрләрнең жанр атамасы бөтенләй күрсәтелми. Текст эчендә авторлар «хикәя» сүзен телгә алгалыйлар. Кыскасы, әле бу вакытларда «хикәя» атамасы, гомумән, берәр вакыйганы бәян итү, хикәяләү мәгънәсендә киң төшенчә булып йөри. Русча «повествование» (хикәяләү) сүзеннән ясалган «повесть» термины бөтенләй кулланылмый. Ул әле XX йөз башы татар әдәбиятында да очрамый. Безнең әдәбиятка жанр атамасы буларак соңыннан керә. Ул замандагы әсәрләрнең кайсын роман, кайсын повесть, кайсын хикәя дип, аларның жанрын без хәзерге күзлектән карап билгелибез.

Шуны да әйтергә кирәк: мәгърифәтче язучыларны, әсәрләренең нинди жанрда булуына карамастан, халык өчен мөһим, актуаль мәсьәләләр күбрәк кызыксындырган. Төп игътибарлары әһәмиятле тема һәм проблемаларга юнәлгән.

Үзәктә — кеше һәм милләт язмышы.

Мәгърифәтче язучыларны нинди мәсьәләләр борчый иде соң? Алар күбрәк нәрсә турында язалар? Әлбәттә инде, халыкны агарту, милләтне мәгърифәтле һәм мәдәниятле итү турында. Бу мәсьәләләр иң башлап М. Акъегетзадәнең «Хисамеддин менла» романында күтәрелә. Әсәрнең баш герое укытучы Хисамеддин һәм аның фикердәшләре Әбүзәр Дәүләтгилдиев, Гайса Зурколаков шушы уй-теләкләр белән яналар. Аларны милләтне сөю берләштерә. Бу егетләр, сүздән эшкә күчеп, халык арасында китаплар тарату эшен башлап җибәрәләр.

«Әбүгалисина кыйссасы»ндагы кебек, әсәрнең баш герое итеп гыйлем иясе, укымышлы кеше алына. Әбүгалисина кебек, Хисамеддин дә гади кешеләргә, авыл халкына ярдәм итә. Әмма ул инде — әфсен белән могҗизалар тудыручы фантастик галим түгел, ә татар җирлегенең үзендә җитешкән, шушы тормышта хәрәкәт итүче реаль шәхес.

Яңа фикерле, халык өчен тырышкан укымышлы кеше образларын без алга таба башка язучыларның әсәрләрендә дә күрәбез.

Гомумән, мәгърифәткә һәм мәдәнияткә мөнәсәбәтле рәвештә образлар ике төркемгә аерыла: мәгърифәтлеләр, ягъни белемле, эшлекле, яхшы кешеләр һәм аларга аяк чалучы надан, иске карашлы, яман затлар. Мәгърифәтле уңай геройлар тышкы кыяфәтләре, эчке уй-теләкләре белән дә күркәм итеп тасвирлана. Ә инде тискәре персонажлар мондый сыйфатлардан мәхрүм. Алар күбрәк кара буяулар белән сурәтләнә, каты тәнкыйть ителә. Шул рәвешле, бу чор татар прозасында уңай һәм тәнкыйди юнәлешләр ачык төс ала. З. Бигиев, Ф. Кәрими, З. Һади, Ш. Мөхәммәдев иҗатында тәнкыйди башлангыч көчәя.

Мәгърифәтче әдипләр, уңай һәм тискәре персонажлар җитешкән тирәлеккә, шартларга, мохиткә игътибар итеп, шәхесне тәрбия, тирәлек җимеше итеп күрсәтә башлыйлар. Төп игътибар гаилә тәрбиясенә һәм мәктәп-мәдрәсәләрне яңарту мәсьәләләренә юнәлтелә. Образлар, нигездә, муллалар, мөгаллимнәр, шәкертләр, сәүдәгәрләр даирәсеннән алына.

Күп кенә әсәрләрдә хатын-кыз образларына зур урын бирелә. Тормышчан проблемалар еш кына очракта хатын-кыз язмышына бәйле рәвештә куела, конкрет образларда сурәтләнә һәм хәл ителә.

Бу чор прозасының күзгә күренеп торган янә бер үзенчәлеге шунда: мәгърифәтче язучылар хикәяләүгә үзләре актив катнашалар. Геройларга һәм вакыйгаларга мөнәсәбәтләрен ачык белдерәләр, укучыларга мөрәҗәгать итеп, публицистик чигенешләр ясыйлар. Татар телендә газета-журналлар булмаган шартларда халыкка җиткерәсе килгән фикерләрен әдәби әсәрдә турыдан-туры да белдерәләр. Күренекле рус язучысы А. И. Герцен болай дигән иде: «Иҗтимагый иректән мәхрүм ителгән халыкта әдәбият, үзенең вөҗдан һәм ачу авазын ишеттерү өчен, бердәнбер трибуна булып тора». Безнең бу чордагы әдәбият та үз өстенә күптөрле вазифаларны алды. Әдипләргә бер үк вакытта образлар тудыручы художник та, милләт кайгысын кайгыртучы публицист та, укучыга белем һәм тәрбия бирүче мөгаллим дә булырга туры килде. Мәсәлән, Р. Фәхреддин «Сәлимә, яки Гыйффәт» романында Идел елгасы, Болгар дәүләте, Казан шәһәре, төрки халыклар турында тарихи-географик мәгълүматлар китерә, укыту-тәрбия мәсьәләләре хакында фикер йөртә. Мондый фикер йөртүләрне без башка язучыларда да күрәбез.

Мәгърифәтчелек прозасы, геройларны тирәлек белән тыгыз бәйләнештә сурәтләү, ягъни реализм принципларын ныграк үзләштерә бару белән бергә, тел-тасвир чаралары ягыннан да камилләшә, байый төшә. Беренчедән, М. Акъегетзадә, З. Бигиев әсәрләре төрек теле йогынтысындарак булса, ике гасыр чигендә һәм XX йөзнең беренче елларында иҗат иткән Р. Фәхреддин, Ф. Кәрими, З. Һади, Ш. Мөхәммәдев һ. б. язучылар халыкның җанлы сөйләм телен ныклап гамәлгә кертә баралар. Икенчедән, коры хикәяләү, геройлар һәм аларның эш-хәрәкәтләрен сөйләп аңлату урынына тасвирлап язу зуррак урын тота башлый. Мәсәлән, З. Һади үзенең повестьларына пейзаж күренешләрен күп кертә, геройларның эчке кичерешләрен табигать күренешләренә параллель яисә контраст итеп сурәтли. Персонажларның портретын, өй җиһазларын һ. б. ны тасвирлауга игътибар арта. Өченчедән, искелек тарафдарларын, тискәре персонажларны сурәтләгәндә, аларны, көлкеле итеп, ирония һ. б. чаралар кулланып, сатирик планда күрсәтә башлыйлар.

«Чит илләрдә йөреп, гыйбрәт ал...»

Бабайлар шулай җырлаган. Борын-борыннан зур сәүдә юлы булып килгән Идел буенда яшәгән, төрле илләр белән сәүдә һәм мәдәни мөнәсәбәтләргә кергән, хаҗга барган, дипломатия эшләре белән йөргән татарлар чит илләрдә күргәннәрен кәгазьгә дә төшергәннәр, сәяхәтнамәләр язганнар. Сез XVIII гасырдан калган Исмәгыйль һәм Мөхәммәд Әмин сәяхәтнамәләрен инде беләсез.

XIX йөзнең беренче чирегендә Ә. Каргалыйның шигырь белән язылган сәяхәтнамәсендә дә Көнчыгышны идеаллаштыру күзгә ташлана. Автор үзе укыган «Бохараи шәриф»не, бик мактап, «исламның гөмбәзе» дип атый; Истанбул да — «җиһанда мәһабәтлелек урыны»; хаҗ кылган җирләре дә,— әлбәттә, изге, «мөбарәк» җирләр; Мәккә, Мәдинә шәһәрләре дә «хөрмәтле», «нурлы». Шул ук вакытта шагыйрь бу жанрга зур гына яңалыклар да кертә. Беренчедән, сәяхәтнамәне шигырь белән яза, бу жанрда лирик-публицистик агым көчәя. Икенчедән, автор Көнчыгыш илләрендә, мәсәлән Мисырда, күренгән уңай яңалыкларны, реформаларны сокланып телгә ала, әсәрнең азагында мәгърифәткә, «камил гыйлемгә» дан җырлый.

Бу тенденцияләр алга таба Гали Чокрыйның «Хаҗнамә» әсәрендә (кулъязма китап, 1873—1874 еллар) үстерелә. Әлеге китапта, беренчедән, татар укучысына киң географик

мәгълүматлар бирү, аның белемен арттыру максаты куелса, икенчедән, феодаль Көнчыгыш, гарәп илләрендәге артталыкны, үзе әйткәнчә, төрле «юньсезлекләр»не тәнкыйть итү, фән-техника ягыннан алга киткән Россия, Европа мәдәниятенә йөз тоту юнәлеше ачык төсмерләнә.

Конкрет тормыш материалы, автор үзе күзәткән күренешләр белән тыгыз бәйләнештә язылган мондый әсәрләр, гадәттә, берничә катламнан тора: хикәяләү, әдәби тасвирлар, тарихи-географик мәгълүматлар бирү һәм лирик-публицистик уйланулар, иҗтимагый әһәмиятле мәсьәләләр хакында фикер йөртүләр. Алга таба язылган сәяхәтнамәләрдә мәгълүмат бирү һәм публицистик фикер йөртү арта бара. «Мавәраэннәһердә сәяхәт» әсәрендә (1893) З. Бигиев феодаль Урта Азиядәге иҗтимагый тәртипләрне, уку-укыту системасындагы схоластика һәм наданлыкны кискен тәнкыйть итә. «Европа сәяхәтнамәсе» (1902) һәм «Кырымга сәяхәт» (1903) китапларында Ф. Кәрими татар укучысын рус һәм Европа фәне, мәдәнияте белән таныштыра, татар тормышын һәрьяклап үзгәртү, европалаштыруны яклый. Шул рәвешле, сәяхәтнамә жанры татар әдәбиятында мәгърифәтне пропагандалауның аеруча кулай бер чарасына әверелә.

Ф. Әмирхан сүзләре белән әйткәндә, «әдәбиятымыз, күп гасырлар Шәрык тәэсире белән килгәннән соң, акрын гына Гареп тәэсире астына керә башлый». Гасырның икенче яртысында әдәбият сыйфат сикереше ясый, яңа баскычка күтәрелә. Чын мәгънәсендә милли характердагы реалистик татар прозасы формалаша.

Сораулар

1. XIX йөзнең икенче яртысындагы татар прозасына нинди сыйфатлар хас?

2. XIX гасырда нинди сәяхәтнамәләр языла?

Муса Акъегетзадә
(1864—1923)

Татар тормышыннан алып язылган беренче реалистик роман авторы Муса Мөхәммәтҗан улы Акъегетзадә Пенза губернасы Чембар (хәзерге Белинский) шәһәрендә хезмәткәр гаиләсендә дөньяга килә. Бабасы Алтынбай Акъегет 25 ел солдатта хезмәт иткән, 1812 елгы Ватан сугышында зур батырлыклар күрсәткән була. Шуның өчен аңа прапорщик дәрәҗәсе һәм дворянлык титулы бирелә.

Мусаны башта әтисенең туган авылы Мачалида татарча укыталар, аннан соң Чембардагы рус мәктәбенә бирәләр. Бу мәктәпне тәмамлаганнан соң, Муса Пенза гимназиясендә белем ала, рус, француз телләрен өйрәнә, әдәбият белән кызыксына, рус һәм Көнбатыш Европа әдипләренең әсәрләрен күп укый. Шул ук вакытта татар әдәбияты һәм мәдәнияте белән якыннан кызыксына. Гимназияне барлык фәннәрдән дә «яхшы» билгесенә тәмамлагач, башта Мәскәү, аннан соң Казан университетына керергә омтылып карый, ләкин кабул ителми. Патша хөкүмәте рус булмаган милләтләргә, бигрәк тә христиан динендә булмаганнарга, югары уку йортлары ишеген ачмый.

Мусаның иҗат эшчәнлеге шушы елларда башлана. Аның «Хисамеддин менла[1]» романы Казанда университет типографиясендә 1886 елда басылып чыга.

1887 елда М. Акъегетзадә, Кырымга Бакчасарай шәһәренә китеп, И. Гаспралының «Тәрҗеман» газетасы редакциясендә эшли. Югары белем алу теләге белән 1888 елда Төркиягә китә, Истанбулда дәүләт учреждениеләре өчен белгечләр әзерләүче Мөлкия мәктәбендә укый, шунда ук рус теле укытучысы бу-

[1] Менла — укымышлы, белемле дигән мәгънәдә.

лып эшләп, яшәп кала. 1908 елда «Мәтин» («Чынлык») газетасын чыгара. Төркиядә ул күренекле икътисадчы буларак та танылa. 1914 елдан Истанбул китапханәсендә эшли, профессор Н. Ф. Катановның Казан университетыннан алынган бай китапханәсен, архивын тәртипкә сала (шул нигездә соңыннан Истанбулда Шәрыкны гыйльми өйрәнү институты оештырыла). Гомеренең соңгы көннәренә кадәр шушы китапханәдә эшләп, 1923 елның 24 сентябрендә вафат була.

Яңа геройлар. Безнең әдәбиятыбызга М. Акъегетзадә «Хисамеддин менла» романы белән кереп калды. Роман татар милләтен мәгърифәтле итү, алга җибәрү идеяләре белән сугарылган.

Романның беренче битләрендә үк автор әсәрнең баш герое Хисамеддин белән таныштыра. Аның тырыш, уңган кеше икәнлеген белдерер өчен, иң элек йорт-җирен тасвирлый: авыл уртасында мәчеттән ерак түгел кечкенә, җыйнак өй бар. Бу өй үзе кечкенә булса да, такта түбәле, амбар һәм сарайлары да бик төзек булып, хуҗасының тырыш һәм хезмәт сөюче адәм икәнлеген күрсәтеп торалар. Әлеге өйдә мулла хатыны тол Зөлхәя абыстай белән аның улы Хисамеддин яшиләр. «Хәрәкәт вә кәсеп сөйгән» укымышлы бу егет гади крестьян хезмәте, игенчелек белән дә шөгыльләнә. Мәрхүм атасы указлы мулла булса да, улы башка юлны сайлый. Төркиядә белем алып кайтып, инде берничә ел авылда үз өендә балалар укыта. Яңача укыта. Балалар тиз вакыт эчендә укырга-язарга өйрәнәләр, хисап һ. б. фәннәрне үзләштерәләр.

Шушы мәсьәләдә — яңача уку-укыту эшләрендә — авылның карт мулласы Бикбулат хәзрәт белән ике арада конфликт төенләнә. Моңарчы искечә укытып көн күргән, иске тәртипләр сакчысы булган хәзрәт: «Ни өчен балаларыгызны ул тиле наданга бирәсез, китерегез үз мәдрәсәмә»,— дип, Хисамеддинне хурлый, абруен төшерергә тырыша. Автор, мондый муллаларның тагын да булуын күрсәтеп, гомумиләштерү ясый. Ягъни Бикбулат хәзрәтне надан һәм иске карашлы, көнче руханиларның типик бер вәкиле итеп күрсәтә. Халык карт хәзрәт сүзенә шәригать сүзе кебек ышанса да, күп кенә кешеләр, Хисамеддиннең яңача укыту нәтиҗәләрен күреп, аны ихтирам итәләр, теләктәшлек күрсәтәләр, балаларын аңа бирәләр. Шулай итеп, бу мәсьәләдә карт хәзрәт җиңелә бара. Уку-укыту эшләрендә искелек һәм яңалык тарафдарларының көрәшен тасвирлау алга таба башка әсәрләрдә дә зур урын алды.

Хисамеддиннең тышкы портреты да, эчке уй-хисләр дөньясы да бик күркәм итеп бирелә. Егерме биш яшьлек бу егетнең «йөзе гүзәл, ачык». Яңарак чыккан коңгырт төстәге сакалмыеклары, кыска чәче йөзенең матурлыгын тагын да арттыралар.

Ул — эчкерсез, олы җанлы, саф күңелле кеше. Күңел түрендә яткан иң зур изге тойгысы — үз халкын, милләтне, татарларны ярату. Үзен дошман күргәнлеген белсә дә, ул Бикбулат хәзрәткә ачу, үпкә сакламый. Чөнки бу дошманлык көнчелектән дип белә. Ә мондый авыруга дучар булганнарны ул кызгана. Көрәсез: конфликт, искелек һәм яңалык арасында булу белән бергә, әхлакый яктан да алына.

Милләтне сөю (милләтпәрвәрлек), аны мәгърифәтле итү теләге Хисамеддинне гимназист Әбүзәр бәк Дәүләтгилдиев, шәһәрдә бакыр мастерское хуҗасы Гайса Зурколаков һәм сәүдәгәр Мохтар белән дуслаштыра, фикердәш итә. Алар еш кына бергә очрашып сөйләшәләр, киңәшләшәләр. Милләтпәрвәрлек турында автор үзе дә, укучыларга мөрәҗәгать итеп, публицистик пафос белән сөйли.

Фән һәм белемгә әһәмият бирмәгән, халыкның рухи мөмкинлекләренә шикләнеп караган татарларга, «ачыйгланып», Әбүзәр болай ди: «Татарда ярты гакыл түгел, зиһен бик камил. Мәдәниятле булырга сәләтле халык. Уяныгыз, кардәшләр! Уйланыгыз, моның кебек гакылсыз дәлилләрегез белән үзегездән көлдермәгез! Карагыз башка милләтләргә, менә французларга, менә немецларга; болар суда көймәдә балык кебек йөзү түгел, һавада кош кебек очу машинасы төзи беләләр. Әмма безнең сукаламак илә вак сәүдәдән башка һөнәребез юк кебек».

Милләт, халык кайгысы белән яшәгән бу егетләрнең һәркайсын автор индивидуаль сыйфатлары, портретлары белән күз алдына бастырырга омтыла. 18 яшьлек Әбүзәр Дәүләтгилдиев ак йөзле, назлы һәм нечкә табигатьле. Гимназиянең 7 нче сыйныфында укый. «Бик бәһале кара сукно сюртук, чалбар кимеш, алтын ука белән чигелгән такыясы вә алтын сәгатьләре малдар вә олуг бәкләрдән идекенә бер дәлил кеби күренерләр иде».

Мастерской хуҗасы Гайса Зурколаковны үсеп килүче яшь капиталист дип карарга мөмкин. Мәрхүм атасы Гайсаны мөселманча һәм бераз русча укыткан. Гайса яшь чагыннан ук «ислам вә рус, гыйлем вә һөнәр китапларын укымага һәвәскәр» була. Әнисе Гайниҗамал абыстай — «гаять диндар, яхшы вә хакыйкатьле» хатын. Үзен бөтен шәһәр халкы хөрмәт итә.

Беренче мәртәбә без Гайса белән тимер юл вокзалында, мөфти хәзрәтне каршы алырга килгән кешеләрне сурәтләгән урында танышабыз. Гайса — эш кешесе. Вакыты белән ул фикердәшләрен дә битәрләп ала:

— Дуслар! — ди ул.— Милләт файдасы, милләт файдасы дип сөйләнәсез, сүз белән файда хасил булмас, эш кирәк, җил куганнар!

Егетләр, акча җыеп, китаплар кайтаруны оештыралар. «Буш эш белән йөрисез, безгә фән нәрсәгә кирәк»,— дип, акча кызганучылар да була. Мондый кешеләргә Гайса бик «ачы вә яман сүзләр» әйтә, «ишәкләр» дип атаудан да тартынмый. Хисамеддин белән Әбүзәр йомшак күңелле, әдәп саклаучан булсалар, Гайса кискен характерлы, фәнгә каршы килүчеләргә карата усал итеп сурәтләнә.

Хисамеддин, төрле фән китаплары төяп, авылларга чыгып китә. Ул әйләнеп кайткач, аның озаграк йөрүен ошатмыйча, Гайса вакытның кадерен белү кирәклеге турында сөйли, инглиз мәкален китерә: «Вакыт сәрмаядыр[1], сәрмаяны бушка сарыф хәрәмдер». Иптәшләре белән ул шук, шаян да була белә.

Кыскасы, яңа геройларның берсе булган Гайса Зурколаков та үзенә генә хас индивидуаль сыйфатлары, характеры белән сурәтләнә.

Тырышлык куеп, байлык табу һәм шушы байлыкны милләт файдасына тоту идеясе Мохтар образында гәүдәләнә. Үз авылларының ятим малае Мохтарның шәһәрдә теләнеп йөрүен күреп, Хисамеддин аны берничә мәртәбә кисәтә. Ләкин Мохтар теләнеп йөрүен дәвам итә. Шуннан соң Хисамеддин белән Әбүзәр аны полиция участогына яптыралар. Участоктан чыккач, дуслар җыелып киңәшәләр.

— Кәсеп ит, бай булырсың,— ди Әбүзәр, «кем иҗтиһад итә, ул таба» дип, пәйгамбәр сүзләрен дә китерә. Мохтар сәүдә эшенә керешсен өчен, акча да биреп тормакчы була. Ләкин Хисамеддин: «Кеше акчасы белән эш итү егетлек түгел, акчаның кадрен белмәссең»,— дип каршы төшә.

Мохтар, акча туплау турында ныклы карарга килеп, извозчикка яллана. Хезмәт хакы айга 6 сум булса да, ул көндез генә түгел, төннәрен дә эшли, көн саен җыелган акчаның 1—2 сумын, ат хуҗасына биреп бетермичә, яшереп калдыра бара.

— Эшлә, эшлә, әүвәл җәфа, соңра сафа,— диләр дуслары.

[1] Сәрмая — байлык, капитал.

Шул рәвешле, җитәрлек мая туплап, сәүдә эшенә керешеп, Мохтар бай сәүдәгәр булып китә. Милләт өчен файдалы эшләр башкара: үз хисабына зур мәдрәсә салдыра, шәкертләргә кирәкле чыгымнарны да үз кесәсеннән тота.

Шул рәвешле, яңа геройларны гәүдәләндергән образларның һәркайсына автор билгеле бер мәгънә йөкли. Милләт алга китсен өчен, аны кайгырткан яңа фикерле укытучылары (Хисамеддин), дәүләт хезмәткәрләре (Әбүзәр бәк, ул заманда юрист, судья һ. б. булып югары белемле дворяннар эшләгән), матди ярдәм күрсәтүче эшкуарлары, капиталистлары (Гайса) һәм сәүдәгәрләре (Мохтар) булырга тиеш. Мохтар үткән юл тырышлык нәтиҗәсендә уңышка ирешү үрнәге дә булып тора.

Теләнче Мохтарның участокка ябылуы Бикбулат хәзрәткә, Хисамеддиннән үч алу, аны халык алдында мәсхәрә итү өчен, җайлы бер сылтау була. Тирә-якларда дан тоткан Гали бай Җаватов өендә зур мәҗлес җыялар. Авылда ике катлы, калай түбәле зур таш йорты, йон юу мастерское, шәһәрдә агач склады булган, Мәскәү фабрикантлары белән эш йөрткән бу байга авыл халкы ярты чакрымнан сәлам бирә. Һичкем аңа каршы сүз әйтә алмый. «Ул ни диде, шул булды». Тик Хисамеддин, барлык кешеләрне тигез күргәнгә, Гали байны аерым олыламый. Тәкәббер Гали бай, тыштан сиздермәсә дә, эчтән аңа дошманлык саклый. Байның улы Сибгатулла белән автор, Хисамеддин кебек яшь булса да, «күркәмлеге юк иде» дип кенә таныштыра.

Мәҗлескә Бикбулат хәзрәт үзе кебек үк надан һәм иске карашлы шәкертләрен ияртеп килә. Бу шәкертләр индивидуаль йөзләре булмаган соры бер масса рәвешендә күрсәтелә. Алар, ятим Мохтарны син яптыргансың, «бу — кяфер эше», дип Хисамеддингә ташланалар, гауга куптаралар. Ләкин Хисамеддин, Мөхәммәд пәйгамбәрнең сүзләрен татарча һәм гарәпчә китереп, барысын да тынып калырга мәҗбүр итә. «Үзе өчен бер кемсә соранмактан бер капка ачса, Алла хәзрәтләре аңа фәкыйрьлектән җитмеш капка ачар»,— диелә ул хәдистә. Бикбулат хәзрәт бу очракта да җиңелә.

Хәнифә образы. Бикбулат белән Хисамеддин арасында өченче зур каршылык Хәнифә тирәсендә куера. Хәнифә — шәһәрдә мосафирханә (кунак йорты, гостиница) хуҗасы Габбас агай кызы. Хисамеддин шәһәргә килгәндә, гадәттә, шушы йортта туктала. Хәнифәне дә шунда күрә. Язучы бу кызны шулай ук бик күркәм итеп сурәтли. Кыз урта буй-

лы, башына яхшы Казан калфагы кигән, өстендәге йон, күк камзулы нәзек һәм зифа буена килешеп тора. Муенына саф көмеш тәңкәләр таккан, вак-вак атлап барган вакытта, бу акчалар, аның йомры күкрәкләренә бәрелеп, челтер-челтер итә. «Аягында тамбурлы читек-башмак, чәче, күзләре һәм кашлары ялтыравык кара, йөзе нурлы, кызгылт ак, борыны кечкенә вә гүзәл». Кыз да сарай янында ат тирәсендә кайнашкан егетне күреп кала.

Шәһәргә төрле эш белән килгән кешеләр кичләрен мосафирханә бүлмәсендә Хисамеддин белән сөйләшеп утыралар. Такта белән бүленгән күрше бүлмәдә Хәнифә оек бәйли. Моңарчы егетләргә бик карамаган Хәнифә, пычак белән шпалерны (обойны) кисеп, ике такта арасында ярык ясап, Хисамеддинне күзәтә. Бу уңайдан автор, «татар бәете хакыйкать бәет икән» дип, халык җырын да китерә:

Ак эшләпә мамыктан, кызлар карый ярыктан,
Карамас иде ярыктан, бер күрергә зарыккан.

Хисамеддиннең чибәрлеге генә түгел, халыкка сөйләгән сүзләре дә кызның күңеленә хуш килә. Укымышлы кыз Хәнифә Хисамеддин фикерләрен, шул исәптән хатын-кызларны яклап сөйләгән сүзләрен, йотылып тыңлый.

Егет белән кыз хатлар да алышалар. Хәнифә тәрәзәсенә Хисамеддин вак-төяк сатып йөрүче венгр кыяфәтендә дә килә, кызга йөзек бүләк итә. Алар бер-берсен яратып сөйләшәләр, аңлашалар.

Муллага сәдака бирү кирәклеге турында халыкның исенә төшереп, яңа никахлар көтеп йөргән Бикбулат хәзрәт шушы вакытларда Хәнифәне Гали бай Җаватовның улы Сибгатуллага димләп йөри башлый. Кызларын бай кияүгә бирергә Габбас агай белән Шәмси абыстай, әлбәттә, шатланып риза булалар.

Хәнифә Сибгатуллага барудан катгый рәвештә баш тарта. Ата-анасы: «Бармасаң, ирексезләп бирербез»,— дип, үз сүзләрендә нык торалар. Хисамеддин ягыннан яучы булып килгән Гайниҗамал абыстайны кире боралар. Илле чакрым ераклыктагы бер авылдан ишан хәзрәтне китереп, Хәнифәнең күңелен Хисамеддиннән суытырга тырышалар. Бу уңайдан М. Акъегетзадә ишаннарның им-том, өшкерү-төкерүләр белән халыкны төрлечә алдап яшәүче сорыкортлар икәнлеген күрсәтә.

Романда шәхес ирекге идеясе, кешенең феодаль-патриархаль богаулардан азат булу, шәхес буларак үзенең кыйммәтен аңлау тойгысы бик югары куела. «Безем ихтыяр вә хөрриятемезне ала алмаслар,— ди кискен, нык фикергә килгән Хисамеддин.— Җаным! Инсан мәгыйшәтендә бер бәһале вә яхшы шәй хөрриятләр. Без үз хөрриятемезне саклый белермез.

— Хөрриятсез яшәмәк көч вә зәхмәт идекене бән дә белермен,— диде Хәнифә туташ».

Геройлар язмышка, тәкъдиргә буйсынырга һич тә теләмиләр. Тиздән Сибгатулла белән Хәнифәнең туе булачагын белгәч, Хисамеддингә әнисе: «Углым, сабыр ит, язылмаган!» — ди. «Дәшмә, анай,— дип җавап кайтара улы,— нинди язылмаган? Язылган».

Хисамеддиннең милләткә хезмәт итү теләге аның бу вакыттагы шәхси максаты белән каршылыкка да керә. Үзе һәм сөйгәне өчен шундый борчулы, хәлиткеч көннәр булуга карамастан, егет, бу хәлләрне белмәгән иптәшләренең тапшыруы буенча, китаплар төяп, авылларга чыгып китә. Иҗтимагый мәнфәгатьләрне шәхси мәнфәгатьтән өстен куя.

Борчулы кичерешләре белән газапланган Хәнифә, туй алдыннан, зур тәвәккәллек эшли, ныклы бер карарга килеп, төн уртасында тәрәзәдән чыгып кача. Гайниҗамал абыстайларга килә. Гайниҗамал абыстайның кыз белән үз-үзен тотышы әсәрдә бик кызыклы һәм реаль бирелгән. Ачык фикерле, кыз белән егетнең яратышуларын белгән, үзе яучы да булып барган карчык Хәнифәнең мәҗбүри никахтан качып котылуын хупларга, кызны кочак җәеп каршы алырга тиеш иде кебек. Ләкин Гайниҗамал абыстай, эшнең нәрсәдә икәнлеген белгәч, кызны:

— Ай кызым, әстәгъфирулла! Ата-анаңа итагать кирәк. Юк, юк, өйгә кайт! — дип куа.— Бу ни хәл, ярабби! Ничек яшьләр бозылдылар!

Хәнифә «үз-үземне үтерүгә кадәр барырмын... җанымны коткар!» дип ялваргач, абыстай аны өч көнгә өендә калдыра. Бу турыда улы Гайсага да, Хәнифә турында борчылып сорашкан Хисамеддингә дә әйтми. Бала ата-ана ихтыярыннан читкә чыгарга тиеш түгел дигән караш татар карчыгының канына сеңгән.

Шау-гөр килеп, мылтыклар атып, шәһәргә туй китү, җәйге матур табигать күренешләрен автор җанлы картиналарда сурәтли.

Туйга килүчеләрнең юлына атлы бер егет, каршы чыгып, кызның югалуын хәбәр итә. Гали байның ачуы йөзенә чыга. Кәпрәеп барган Сибгатулла, «үлек кеби агарып», башкода Бикбулат хәзрәт «телсез калып, нишләргә, нәрсә дияргә белмичә» аптырап калалар.

Габбас агай өенә Гали бай белән Бикбулат хәзрәт килеп кергәч, төрле хурлаулар һәм дәгъва белдерүләр башлана. Әсәрдә Мохтар, Хәнифә кебек, Шәмси абыстай да рухи үсештә бирелә. Өйдә купкан дәгъвалы сөйләшүгә ул да катнаша.

— Алла, Алла, байлыгыңызга ианып, кызымны көчләдем, харап улдым, йөрәк бәгърем баламнан аердың. Кайдадыр, белмибез,— дип, инде үкенеп, Гали байга үпкәләп сөйли Шәмси абыстай. Җаватов белән Бикбулат мулла бу юлы да җиңеләләр. Хисамеддин белән Хәнифә очрашып кавышалар, өйләнешеп, бәхетле гаилә коралар. Хәнифә язмышында автор, шәхес азатлыгы мәсьәләсенең мөһим бер өлеше буларак, хатын-кыз ирекге проблемасын да куя һәм мәгърифәтчелек рухында хәл итә.

«Хисамеддин менла» романының әһәмияте.

Бу романның тарихи әһәмияте,— барыннан да бигрәк, татар прозасының, милли тормышны сурәтләүгә йөз белән борылып, мәгърифәтчелек реализмы баскычына күтәрелүен күрсәткән беренче әсәр булуында. Роман үз заманының актуаль, прогрессив идеяләрен чагылдыра, феодаль-патриархаль яшәешкә, тормыш-көнкүрештәге, уку-укытудагы иске тәртипләргә каршы күтәрелеп килгән хәрәкәтне әдәби образларда гәүдәләндерә. Моңа үз вакытында рус матбугаты да игътибар иткән.

«Хисамеддин менла» романы үзенең геройлары, идеяләре белән дә, сәнгатьчә эшләнеше белән дә игътибарны җәлеп итә. Образларны сурәтләүдә, персонажларның психологик кичерешләрен ачуда автор портрет, пейзаж күренешләрен, газета мәкаләсен һәм хат язышу алымнарын, сөйләм үзенчәлекләрен, җыр һәм мәкаль-әйтемнәрне куллана. Уңай һәм тискәре персонажларны гомуми һәм индивидуаль сыйфатлары белән күрсәтергә омтыла.

Г. Ибраһимов билгеләп үткәнчә, «Хисамеддин менла» җәдитчелек әдәбиятының төп мәсьәләләрен һәммәсен диярлек эченә ала. «Татар әдәбияты тарихы» китабында (1926) профессор Габдрахман Сәгъди бу романга шулай ук югары бәя бирә. «Хисамеддин менла»,— дип яза ул,— үзенең тарихи әһәмиятен бервакытта да югалтмый торган әсәр. Монда без

татарлар арасында башланган уяну, җәдитләнү, европалашу хәрәкәтен дә, җанлы тормыш картиналарын да күрәбез».

Татар мәгърифәтчелек прозасы үсешенә, язучылар иҗатына М. Акъегетзадә романының йогынтысы зур булды. Күп кенә әсәрләр өчен ул үрнәк, өлге булып хезмәт итте. Мәгърифәтче әдипләр әлеге романда күтәрелгән мәсьәләләрне, идеяләрне уртаклаштылар, дәвам иттерделәр, образларны һәм аларны сурәтләү чараларын камилләштерделәр һәм үстерделәр.

Романның үзәгенә куелган халык язмышы мәсьәләсе, милли прогресс идеяләре хәзерге заман проблемалары белән дә бик аваздаш.

Сорау һәм биремнәр

1. М.Акъегетзаденең тормыш юлы.
2. «Хисамеддин менла» әсәренең эчтәлеген сөйләгез.
3. Хисамеддин, Әбүзәр Дәүләтгилдиев, Гайса Зурколаков, Мохтар образларын нәрсә берләштерә?
4. Романда Хисамеддин һәм Хәнифә мәхәббәтенең бирелеше.
5. М. Акъегетзадә әсәренең татар әдәбиятындагы яңалыгы һәм әһәмияте.



Ризаэддин Фәхреддин (Риза Фәхреддин)

(1858—1936)

Күренекле фикер иясе, мәгърифәтче галим, язучы, журналист, дин әһеле Ризаэддин Фәхреддин элекке Самар губернасы Бөгелмә өязе (хәзерге Татарстанның Әлмәт районы) Кичүчат авылында мулла гаиләсендә дөньяга килә. Мәдрәсәдә укыган елларында ук аңа Ш. Мәрҗани хезмәтләре зур йогынты ясый. Мәдрәсәне тәмамлагач, мөгаллим булып эшли, фән, иҗат эше белән шөгыльләнә башлый. Мәктәп-мәдрәсәләрне яңарту идеяләре белән сугарылган «Мәгариф мәдрәсәсе» дигән беренче зур хезмәте цензурада тоткарлана.

1898 елда аны Уфадагы Диния нәзарәтенә казый, ягъни дин эшләре буенча хөкем итүче, судья итеп сайлыйлар. Р. Фәхреддин, Уфага күчеп, Диния нәзарәте архивындагы бик күп кулъязмаларны, тикшереп, тәртипкә сала, татар укымышлылары, мулла һәм мөдәррисләре, әдип һәм шагыйрьләре турында гаять бай мәгълүматлар тупланган күп томлы «Асарь» (әсәр сүзенең күплек саны; эзләр, ядкярләр дигән мәгънәдә дә) дигән хезмәтен яза башлый. Бу тарихи хезмәтнең I кисәге — 1900 елда Казанда, II кисәге —1901, III кисәге—1903, IV—VIII кисәкләре 1904 елда Оренбургта басылып чыга. Бу хезмәт, татар мәгарифе, әдәбияты тарихын өйрәнү өчен, бай чыганак булып тора. Анда Әбелмәних Каргалый, Һибәтулла Салихов, Шәмседдин Зәки һ. б. бик күп укымышлыларның биографияләренә һәм әсәрләренә караган мәгълүматлар китерелә. Мифтахеддин Акмулла, Шиһабеддин Мәрҗани, Каюм Насыйри турында да башлап язучы Р. Фәхреддин була.

Мәгърифәтчелек идеяләре белән рухланып, Р. Фәхреддин үзе дә әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә. Аның «Сәлимә, яки

Гыйффәт» романы 1899 елда — Казанда, «Әсма, яки Гамәл вә җәза» романы 1903 елда Оренбургта басыла.

1905 ел революциясе чорында ул, казыйлык эшен ташлап (1906), иҗади хезмәткә күчә. Оренбургта урнашып, «Вакыт» газетасында языша, 1908—1918 елларда аена ике мәртәбә чыгып килгән иҗтимагый-педагогик, әдәби-публицистик «Шура» («Киңәш») журналының баш мөхәррире (редакторы) булып эшли. Иҗтимагый-фәлсәфи фикер, әдәбият, мәдәният, мәгариф һ. б. темаларга караган бик күп мәкаләләре шушы журналда басыла. Галим «Мәшһүр ирләр», «Мәшһүр хатыннар» исеме белән атаклы кешеләрнең тормышы һәм эшчәнлеге турындагы китапларын, педагогика һ. б. өлкәләргә караган хезмәтләрен чыгарып бара. «Асарь» томнарын язуны дәвам итә.

«Сез болай күп эшләргә ничек өлгерәсез?»— дигән сорауга Р. Фәхреддин: «Мин, үз-үземне белә башлаганнан бирле, өстемә кояш чыгармадым»,—дип әйтә торган булган.

Курсави, Мәрҗани һ. б. мәгърифәтчеләрнең идеяләрен үстергән бу галимне шагыйрь Акмулла: «Ризаэддин — бер камил зат»,— дип атый.

1922 елда Р. Фәхреддин мөфти итеп сайлана, Уфага күчә. Гыйльми хезмәтләр язуын да дәвам итә. Бай мирас калдыра. Соңгы көннәренә кадәр гыйльми иҗади эшләр белән шөгыльләнеп, 1936 елда Уфада вафат була.

Әдәби иҗаты. Р. Фәхреддин үзенең әсәрләрендә, милләтне аң-белемле һәм һөнәрле итү белән бергә, әдәп-әхлак ягыннан тәрбияләүгә зур игътибар бирә. «Сәлимә» романына өстәмә исем итеп «яки Гыйффәт» дип тә куелган. Гыйффәт — кызлык намусы, сафлык, абруй дигән мәгънәне белдерә.

Бу әсәрдә әдәпле татар шәкертенең, Идел буйлап пароходта барганда, Иран баеның кызы Сәлимә белән танышып дуслашуы хикәя ителә. Сәлимә белән әнисе Петербургтан үз илләренә кайтып баралар. Яшьләр, фән, әдәбият, тарих, мәгърифәт турында сөйләшеп бара торгач, бер-берсенә гашыйк булып, Бакуга җиткәч өйләнешәләр. Кыз егетне үзенең гүзәллеге һәм тирән белемле булуы белән җәлеп итә. Сәлимәгә егетнең бик әдәпле булуы, күпне белергә тырышуы ошый.

Шәкерт ун ел буе Казанда мәдрәсәдә укыган, әнисенең үгет-нәсыйхәтләрен күңелендә йөрткән, шуның нәтиҗәсе буларак, беркадәр күзе ачыла башлаган. Әмма ләкин дөньяви фәннәрдән шактый артта калган. «Артта калуның соңы, әлбәттә, харап»,— дип, автор аны укымышлы Сәлимә белән

таныштыра. Сәлимә Мисырда университет тәмамлаган, үзенең фарсы теле шикелле үк, гарәп, француз, инглиз телләрен белә. Тарихтан, хәтта төрки-татар тарихыннан да мәгълүматлы. Автор аны «гыйлем диңгезе булган идеаль бер кыз» итеп тасвирлый. «Май кебек йомшак, сандугач мисаллы моңлы вә мөлаем тавышлары таң җиле рәвешендә җанны рәхәтләндерә».

Автор, хикәяләүгә үзе дә актив катнашып, борынгы Болгар, Казан дәүләтләре, төрки халыклар турында мәгълүматлар бирә, әхлакый-иҗтимагый мәсьәләләр хакында публицистик фикер йөртә. Дини белемнәр белән бергә, фәнни белемнәрне үзләштерү, укыту-тәрбия ысулларын үзгәртеп кору, күркәм холыклы булу, рус телендәге фәннәрне өйрәнеп, халыкка хезмәт итү идеяләрен алга сөрә.

«Әсма» романына да автор «яки Гамәл вә җәза» дип өстәмә исем куйган. Әсәрнең эчтәлегенә ишарә иткән мондый алымны рус һәм Европа язучылары да кулланганнар. Романда яхшылык һәм явызлык, әдәплелек һәм әдәпсезлек, белемлелек һәм наданлык бәрелеше әдәби образларда сурәтләнә. Ни чәчсәң, шуны урырсың, дигән карашта торып, Р. Фәхреддин яхшылыкның нәтиҗәсе — бәхет, мәкер һәм явызлыкның, начар эшләрнең җәзасы — түбәнлек, хурлык дигән идеяне персонажлар язмышында тәэсирле итеп гәүдәләндерә.

Романның үзәгенә Әсма исемле ятим кызның маҗаралы язмышы алынган. Аның әтисе — Габбас мулла — заманының ачык фикерле, прогрессив карашлы кешесе итеп сурәтләнә. Ул үзе белемле һәм яхшы холыклы. Халыкны да шул рухта тәрбияли, вәгазьләрен йомшак сөйли, ислам дине кагыйдәләрен ачык аңлата. Мәктәп ачып, авыл балаларын яңача укыта башлый. Автор аның бу хезмәтен «бер олуг эше» дип бәяли.

Яшьлегендә Габбас бик зирәк һәм сәләтле булса да, укуда әллә ни тырышлык күрсәтмичә, камиллеккә ирешмичә, мәдрәсәдән чыгып имам булган. Аның белем һәм әхлак ягыннан үсешендә хәлиткеч рольне хатыны Гайшә абыстай уйный. Тирә-якларга атаклы, әмма уртача тормышлы бер мөдәрриснең кызы булган Гайшә «гыйлемлек хөрмәтене белер, укыр һәм язар, иркәлек нәдер белмәс, тәкәбберлекне күңеленә китермәс, кешедән асла көлмәс иде», ди автор. «Бер байгура баласына әсир дөшмәдекеннән шатланып», Гайшә абыстай, көн-төн тырышып, Габбас мулланың холкын тәрбия итәргә керешә һәм теләгенә ирешә дә. Алар бергәләп төрле китаплар, рус, төрки, гарәп телләрендәге газета һәм журналларны укыйлар.

Әдәби, фәнни әсәрләр дә Габбас мулланың холкын төзәтүгә күп ярдәм итә.

Әсма әнә шундый дус гаиләдә әти-әнисеннән яхшы тәрбия алып үсә. Габбас мулла кызын укытуга бик җаваплы карый. Зирәклеге, тырышлыгы белән Әсма да укуында көннән-көн алга бара. Бәхетле ата-ана, Әсманың киләчәгенә зур өметләр баглап, якты хыял белән яшиләр.

Бу гаилә белән бәйләнештә әдип гади халыкның бер вәкиле булган Сәлим бабай образын да ялатып сурәтли. Умарта каравылчысы алтмыш яшьлек бу карт халыкның үзе төсле: күпне күргән, күпне кичергән. Халык тарихыннан булган хәбәрләрне, ата-баба мәкальләрен, мәсәл һәм хикәятләрне, шигырьләрне бик күп белә, тәэсирле итеп сөйли. Бу карт бик моңлы җырлый һәм курайда уйный. Җәйге кичләрдә Сәлим бабай уйнаган курай моңы һәммә кешене дулкынландыра. Сызланып яткан картлар, урыннарыннан сикереп торып, «һай, үзәкләрем өзелә!..» диләр. Усал каенаналар «май кеби йомшарып» китә. Мәгърифәтче әдип бу уңайдан кешенең күңелен сафландырып, рухын баетуда музыканың әһәмиятен аңлата. Милли җырларны, ата-баба мәсәлләрен язып алу, хикәя һәм романнар иҗат итү галимнәргә лаек түгел дигән карашны тәнкыйть итә. «Мондый әсәрләрне галимнәр язмас исә, җаһилләрме[1] язачак?! Алар язмаганда, милли әдәбиятыбыз ни рәвешле төзеләчәк?!» — ди ул.

Уңай образларга контраст итеп, автор тискәре персонажларны сурәтли. Яңалыкка каршы торган, әхлакый бозык мондый кешеләрне «тәрәккый тормозлары» дип атый. Шундыйлардан беренче урында зур сәүдәгәр Хикмәт хаҗи тора. Автор аны чиксез надан, икейөзле, тәкәббер зат дип тәкъдим итә. Бу сәүдәгәр, «беренче дәрәҗәдә залим» булган хәлдә, үзен изге хаҗи итеп күрсәтә. Ерактан торып сәлам бирмәгәннәрдән, хөрмәт итмәүчеләрдән үч ала. Бу сыйфатлары белән ул «Хисамеддин менла» романындагы Гали бай Җаватовны хәтерләтә. Хикмәт хаҗиның сәүдәсе дә, бай булып китүе дә мәкергә һәм алдашуга корылган. Яшьлегендә үзе хезмәт иткән байның ике улын төрле бозыклыкка өйрәтеп, йөзәр тәңкә акча биреп, алардан егермешәр мең тәңкәлек вексельләр ала. Бай үлгәч, аның хатынына өйләнеп, улларын өйдән куып чыгара.

Хикмәт хаҗи «агачтан да надан» кызларының дүртесен дүрт муллага бирә. Бу муллалар аның һәрбер эшен хуплап

[1] Җаһил — надан.

торалар. «Меллаларның нәфес коллары идекене» яхшы белгән сәүдәгәр бишенче кызын яңарак указ алган Габбас мулла соратачагына һич тә шикләнми. Әмма Габбас, Сәлим бабайның: «Хатынсыз мал кирәк улса—Хикмәт хаҗи кызыны вә малсыз хатын кирәк улса, Сөләйман хәзрәт кызыны алырсың!»— дигән киңәшен тотып, Гайшәгә өйләнә. Хикмәт хаҗи икенче хатынлыкка алыр дип өметләнә, әмма үз хатынын якын дус һәм сердәш итеп күргән Габбас икенче мәртәбә өйләнергә уйламый да. Шуннан соң Хикмәт хаҗи яңа фикерле бу мулланың кан дошманы булып әверелә: аның эшләренә аяк чала, бөтенләй аударып ташлау, базга төшереп батыру өчен чаралар эзли. Бу дошманлык ундүрт-унбиш ел дәвам итеп, икенче хаҗ сәфәреннән Хикмәт хаҗи тагын да тәкәбберләнеп, мин-минлеге артып кайта. Габбас мулла ачкан мәктәпне, хәленнән килсә, ваттырып, урынында булган туфракны суга салдырыр иде, ди автор.

Хикмәт хаҗиның фикердәшләре булган иске карашлы муллаларны әдип ирония белән сурәтли. Бер авылдагы мулла, нинди хайван мае икәнлеге безгә мәгълүм түгел, дип, керосин лампаларын мәчеттән чыгарткан. Икенчесе, шәм эзләтеп, намаз вакытын бушка уздырган. Шундый муллаларның дүрт-биш тибын күрсәтеп, автор аларның кайсы «мантыйкка (логикага) оста», кайсы астрономиягә оста дип көлә.

Шундый надан муллаларның берсе, ишан мөрите, «бозык әхлаклы» Муса, мәчет салырга дип дәфтәр ачып, Габбас мулла исеменнән халыкка үтенеч-мөрәҗәгать язып, акча җыярга чыгып китә. Шәһәр байларыннан бер мең сумнар акча җыеп, күңел ачу йортына керә һәм шунда барлык акчасын югалта. Тикшерү эшләре башланып, Мусаны кулга алалар. Хикмәт хаҗи, бу форсаттан файдаланып, Габбасны төрмәгә яптыру чараларына керешә. Бу хәлләрдән борчылып калган Габбас мулла хаҗ сәфәренә чыгып китә. Тиздән аның үлгән хәбәре килә. Кайгы-хәсрәт эчендә бер ел узгач, Гайшә абыстай да вафат була. Күршедә чыккан янгыннан йортлары да янып китә.

Ятим Әсманы мәрхәмәтле кешеләр — кымыз остазы Йосыф бабай белән карчыгы сыендыралар. Әсма монда дәваланырга килгән «гүзәл йөзле, инсафлы, гаять мөлаем», үзе кебек үк ятим бер шәкерт белән дуслаша. Алар бергәләп китаплар укыйлар. Күңелләрендә саф мәхәббәт тойгысы уяна. Казанга киткәндә, шәкерт әнисенең истәлеге булып калган, бик кадерләп саклаган алтын тәңкәсен кызга бүләк итә. Әсма егеткә әнисеннән калган балдакны бирә.

Бервакыт Әсманы, әнисе минем якын дустым иде, дип, Хәмидә исемле бер хатын кунакка алып китә. Озакламый, Әсма тиф авыруыннан үлде, дигән хәбәр килә. «Шайтан ялчысы» бу хатын шундый ятим кызларны, алдап алып китеп, сатып йөри икән. Әсманы да ул кызлар белән сату итүче Зәйнүш исемле бер хатынга бирә. Әсма өчен куркыныч һәм авыр көннәр башлана. Әдип капиталистик шәһәр тормышына хас булган төрле бозыклыкларны, караңгы һәм һәлакәтле якларны җанлы картиналарда сурәтли. Зәйнүш Әсманы, исемен «Зәйнәп» дип үзгәртеп, теләндереп йөртеп, фәхешханә тотучы бер хатынга сата. Әлегә «Зәйнәп»нең яше җитмәгәнгә, аны йорт эшләрендә эшләтәләр. Баскычтан егылып, «Зәйнәп» аягын сындыра, шифаханәгә эләгә. Дәваланучы хатыннарга китаплар укып, алар өчен хатлар язган күркәм бу кызны гади бер авыл хатыны үзе белән алып китә, фаҗигале язмыштан коткара. Алар, аналы-кызлы булып, авылда үз хезмәтләре белән көн күрәләр.

Исеме бөтен Азиягә мәгълүм булган Салих бай, шәһәрдә ятим балалар өчен тәрбия йорты ачып, аларның җәмгыятькә файдалы кешеләр булып җитешүенә ярдәм итә. «Зәйнәп», шушы тәрбия йортында укып, укытучы-мөгаллимә булып җитешә. Монда ул үзенең әтисе белән дә очраша. Габбас үлмәгән, исемен «Юныс хәзрәт» дип үзгәртеп, әлеге тәрбия йортында хезмәт итә икән. Әсманы кияүгә сораган һәм ризалыгын алган мөгаллим дә яшьлегендә дуслашкан шәкерт булып чыга. Шәкерт биргән алтын тәңкәне Әсма чәч толымына тагып йөрткән була. Яшьләр тигез һәм бәхетле гаилә коралар. Шул рәвешле, яшьлегендә ата-анадан яхшы тәрбия алган Әсма, саф килеш калып, бәхеткә ирешә. Явызларның һәркайсы үз җәзасын ала.

Маҗаралы сюжетка һәм кискен конфликтларга корылган бу әсәрендә Р. Фәхреддин, милләтне мәгърифәтле итү идеяләре белән бергә, намуслы хезмәт, югары әхлакый сыйфатлар, мәрхәмәтлелек кебек гомумкешелек кыйммәтләрен раслый, мәкер һәм явызлыкларны кире кага. Г. Тукай Риза Фәхреддинне «Әсма...», «Сәлимә...» кебек китаплары белән язу куәтен, хәтта шигъриятен күрсәткән һәм, гомумән, хикәяләве ачык, язу стиле җиңел «вә гүзәл бер язучыдыр» дип югары бәяли.

Биремнәр

1. Р. Фәхреддиннең тормыш юлы турында сөйләгез.
2. Автор ни өчен Сәлимәне «гыйлем диңгезе булган идеаль бер кыз» дип саный.

Фатих Кәрими

(1870—1937)

Фатих Кәрими (Фатих Гыйльман улы Кәримов) татар әдәбиятына үзенең мәгърифәтчелек рухындагы хикәяләре белән килә һәм реалистик проза үсешенә зур өлеш кертә, соңрак очерклар, төрле китаплар авторы, журналист-публицист буларак та танылa. Ул 1870 елның 30 (18) нчы мартында хәзерге Татарстан Республикасының Әлмәт районы Миңлебай авылында мулла-ахун гаиләсендә туа. Аның этисе Гыйльман ахун Ш. Мәрҗани шәкерте һәм заманының прогрессив карашлы кешесе була, балаларына дөньяви белем бирергә омтыла.

Фатих 11 ел Чистай мәдрәсәсендә укый һәм шунда ук ике сыйныфлы рус мәктәбен тәмамлый. 1891 елда Төркиягә китеп, Истанбул университетында белем ала. 1896 елда Кырымга кайтып, Исмәгыйль Гаспралы оештырган яңа методлы мәктәптә укыта. 1898 елда Бакчасарайда ачылган яңача укытучылар әзерләү курсларына җитәкчелек итә, әдәбият һәм педагогика дәресләрен алып бара.

1899 елда этисе, муллалыгын ташлап, Оренбургка күчә, типография сатып алып, 1901 елда бу шәһәрдә татарча китап басу эшләрен башлап җибәрә. Фатих Мәскәүдә бухгалтерия курсларында укып кайта. Петербургта китап басу һөнәренә дә өйрәнә, этисенең эшен дәвам иттерә. Ул рус, гарәп, фарсы, төрек, француз телләрен һәм күп кенә фәннәрне яхшы белгән мәгърифәтче булып җитешә.

Шул сыйфатларын истә тотып, алтын приискы хуҗасы Шакир Рәмиев Европа илләренә сәяхәткә аны үзенә киңәшче һәм тәрҗемәче итеп ала. 1899 елда алар бу илләрдә дүрт ай йөреп кайталар. Ф. Кәриминең «Европа сәяхәтнамәсе» дигән китабы 1902 елда Петербургта басыла. 1903 елда, «Тәрҗеман»

газетасының чыга башлавына 20 ел тулу бәйрәменә, Ф. Кәрими Оренбургтан Бакчасарайга вәкил булып бара һәм шул ук елда «Кырымга сәяхәт» китабын чыгара. Бу сәяхәтнамәләрендә автор татар укучыларын рус һәм Көнбатыш Европа әдәбияты, сәнгате, белем һәм мәдәният казанышлары белән таныштыра, татар милләтен мәгърифәтле һәм мәдәниятле иту идеяләрен алга сөрә.

1906—1917 елларда Ф. Кәрими Оренбургта Шакир һәм Закир Рәмиевләр чыгарган «Вакыт» газетасының баш мөхәррире булып эшли. 1912—1913 елларда, Балкан сугышлары барган чорда, шушы газетаның Төркиядәге хәбәрчесе сыйфатында «Истанбул мәктүпләре» дигән публицистик очеркларын бастыра. Бу очерклар 1913 елда аерым китап булып та чыга. Дөнья халыклары турында Ф. Кәрими күп кенә брошюралар бастыра.

Октябрь революциясеннән соң Ф. Кәрими төрле газеталарда языша, мәгариф институтында, татар, башкорт, казах мәктәпләренә мөгаллимнәр әзерләү курсларында укыта, әдәбият түгәрәге оештырып, аңа җитәкчелек итә. Шушы түгәрәкнең юлламасы белән 1922 елда Муса Җәлил Казанга укырга килә.

1925 елда Ф. Кәрими, Мәскәүгә күчеп, СССР халыкларының Үзәк нәшриятында эшли, Көнчыгыш университетында укыта. Шушы елда аның «Фатих Кәрими әсәрләре» дигән җыентыгы басыла.

Татар әдәбияты, мәдәнияте һәм журналистикасы үсешенә зур өлеш керткән әдип, шәхес культы корбаны буларак гаепләнеп, 1937 елның 27 сентябрендә үлә.

Хикәяләре. Ф. Кәриминең хикәяләре ике гасыр чигендә — XIX гасырның соңгы — XX йөзнең беренче елларында басылып чыга. «Җиһангир мәхдүмнең[1] авыл мәктәбендә укуы» хикәясендә (1898 дә язылып, 1900 елда Петербургта басыла) автор иске тип мәктәпләрнең эчке тормышын реаль күренешләрдә сурәтли. Мәктәп бинасы бик иске, тишек почмагына зур таш тыгып, туфрак белән күмеп куелган. Черек матчасын терәүләр тотып тора. Күпер төбендәге мәктәп янына мужиклар тирес түгәләр, яз көннәрендә бозык, сасы исләр таралып, балалар авыруга сабыша. Бина эчендә алар: «Әлеп, би, ти, си!»— дип көйләп иҗек ятлыйлар.

Авыл мулласы Әхмәтша хәзрәт үзе «мәдрәсәдә егерме биш сәнә[2] гомер кичермеш исә дә, ялгыз тәһарәт алу вә кычкырып-

[1] Мәхдүм — мулла, хәзрәт улы.
[2] Сәнә — ел.

кычкырып» бәхәсләшүдән башкага өйрәнмәгән. Авыл агайлары, малайларын аңа китереп: «Балабызның ите синә, тиресе безгә, каты тота күрегез, хәзрәт»,— диләр. Әхмәтша хәзрәт тә: «Шулай тиеш шул, остаз суккан җир җәһәннәмдә янмас»,— дип җавап бирә. Әдип Әхмәтша хәзрәтнең халык җилкәсендә яшәвен, барлык эшләрен авыл кешеләреннән эшләтүен дә күрсәтеп үтә.

Халык вәкиле булган Биктимер агайны әдип яратып сурәтли. Авыл кешеләре ачык фикерле бу картны «гомуми ата кебек белеп хөрмәт итәләр». Әхмәтша хәзрәткә дә аның сүзе үтә.

Шул рәвешле, язучы, тискәре образларны ирония һәм сатира чаралары кулланып сурәтләү белән бергә, уңай персонажларны да күрсәтергә омтыла.

«Бер шәкерт белән бер студент» хикәясендә (1899) Ф. Кәрими унбиш-егерме ел мәдрәсәдә укыган татар шәкерте белән Мәскәү университетының Көнчыгыш телләре факультетында гарәп, фарсы, төрек һәм татар телләрен өйрәнүче студентны чагыштырып сурәтли. Пароходта алар арасында барган сөйләшүдә татар шәкертләренең үз халкының тарихын, мәдәниятен белмәүләре, дөньяви белемнәрдән мәхрүм булулары күренә. «Хәзер дөнья гыйлем дөньясыдыр. Гыйлемсез кеше канатсыз кош кебектер»,— ди студент. Ул киң карашлы, тирән белемле, тәрбияле егет итеп күрсәтелә.

Зур чалмалы ишан һәм аның мөритләрен, аларның өс-башларын, кыяфәтләрен, үз-үзләрен тәртипсез, әдәпсез тотуларын әдип нечкә ирония һәм юмор белән тасвирлый.

«Салих бабайның өйләнүе» хикәясендә (1897) гади халык вәкиле булган Салих карт Р. Фәхреддиннең «Әсма...» романындагы Сәлим бабайны хәтерләтә. Икесе дә, тормышның ачысын-төчесен татып, күпне күргәннәр, күпне кичергәннәр. Гомерләре хезмәттә, күбрәк ялчылыкта узган. Картаймыш көннәрендә икесе дә кыяр, умарта каравыллыйлар, кызыклы бик күп хикәятләр, мәсәлләр беләләр. Ләкин шуны искә алырга кирәк: Салих бабай образын Ф. Кәрими алданрак иҗат итә. «Әсма...» романы бераз соңрак языла.

«Салих бабайның өйләнүе» хикәясендәге егет белән кыз икесе дә гади крестьян, авыл яшьләре итеп бирелсә, «Морза кызы Фатыйма» әсәрендә (1901) социаль хәлләрендә кискен аерма булган морза кызы һәм хезмәтче егет арасындагы саф мәхәббәт тасвирлана. Морза Туганскийлар гаиләсендә үскән Фатыйма — русча да, татарча да укыган, белемле һәм фикерле

кыз. Ул морзалык, затлы нәсел белән мактануны, башкаларга түбәнсетеп карауны кире кага. Кеше үзенең эш-гамәлләре белән танылырга тиеш дип саный. Ул үзләрендә хезмәттә торучы бакчачы һәм каравылчы Мостафаны ярата, әти-әниләренең риза булмаячагын уйлап борчыла, газаплана.

Чибәр, мөлаем, намуслы, укымышлы кыз Мостафаның да күңелен биләп ала. Ләкин Мостафа аксөякләр гаиләсеннән булган бу кызга күңелендәге серен ачарга тартына. Алар бакчада очрашып аңлашалар.

Фатыйманы атаклы нәселдән булган бай морза улы Габделгәрәйгә яучылыйлар. Кыз баш тарта. Атасы аны Габделгәрәйгә кияүгә бирергә карар иткәч, Фатыйма кыю адым ясый, малмөлкәт һәм дәрәҗәдән ваз кичеп, Мостафа белән чит якларга кача. Беркадәр михнәт чигеп йөргәннән соң, алар туган төбәкләренә кайталар, бәхетле гаилә коралар.

Шул рәвешле, Ф. Кәрими бу ике хикәясендә мәхәббәт һәм гаилә мәсьәләләрен кешелекле, гуманлы идеаллар ноктасыннан торып яклый. Үз бәхетләре, мәхәббәтләре өчен көрәштә геройлар ныклык һәм тәвәккәллек күрсәтәләр.

Ф. Кәрими хикәяләренең теле шактый аңлаешлы, халыкчан. Аларда без геройларны, персонажларның эш-гамәлләрен, эчке кичерешләрен төрле чагыштырулар, портрет, табигать күренешләре ярдәмендә тасвирлап бирүләрне күрәбез.

Сорау һәм бирем

1. Ф. Кәриминең тормыш юлын сөйләгез.
2. Ф. Кәрими әсәрендәге геройларга нинди сыйфатлар хас?

Закир Һади

(1863—1933)

Закир Һади — бөтен гомерен, иҗатын яшь буынга белем, тәрбия бирүгә багышлаган әдип һәм педагог. Ул әдәбиятка XX йөзнең беренче елларында мәгърифәтчелек идеяләре белән сугарылган, киң күпчелеккә аңлаешлы телдә язылган повестьлары белән килә. Үз чорының кимчелекләрен тәнкыйть иткән бу повестьларда авыл тормышының реаль күренешләре сурәтләнә.

З. Һади 1863 елда Уфа губернасы Бәләбәй өязе (хәзерге Башкортстанның Шаран районы) Ярмәкәй дигән татар авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. Әтисе игенчелек, умартачылык белән шөгыльләнгән, кыш көннәрендә балалар укыткан. Закир авыл тормышын якыннан белеп, өйрәнеп үсә. Башлангыч белемне атасыннан алган Закирны 12—13 яшьләрендә Тымытык мәдрәсәсенә җибәрәләр. Иске типтагы бу мәдрәсәдә ун ел уку, шәкертләрнең авыр тормышы аң-белемгә омтылган Закир күңелендә тирән ризасызлык уята.

1885 елда З. Һади, бәхет эзләп, Түбән Новгород шәһәренә бара, бер байның тире эшкәртү эшләрендә хезмәт итә. Күпмедер вакыт узгач, Касыйм шәһәрендә яңачарак укыта башлаган мәдрәсә ачылуын ишетеп, шунда китә. Шәһәр мәдрәсәсендә уку аңа русча өйрәнергә, үзлегеннән белемен күтәрергә дә ярдәм итә. Касыйм шәһәреннән 5—6 чакрымдагы Татар Бае авылында җәдитчә укытучы мөгаллимнәр курсы ачылгач, шунда укый башлый, аны тәмамлап, Мулта авылында мөгаллим булып эшли. Шуннан соңгы бөтен гомерен балалар укытуга багышлый. Ул төрле шәһәрләрдә (Одесса, 1905; Харьков, 1914—1918), туган якларында, Касыйм төбәгендә укытучылык итә. 1933 елда Касыйм районының Бимсала авылында үлә.

Иҗаты. З. Һадиның «Бәхетле кыз» һәм «Бәхетсез кыз» исемле беренче повестьлары 1904 һәм 1905 елларда басылып чыга. Бу әсәрләрдә автор, барӗачак вакыйгаларга керешкәнче, авылларның гомуми күренеше, төрле катлау кешеләренең көнкүреше белән таныштыра. Халыкның ярлы һәм караңгы тормышы бу авылларның бай табигатенә каршы куеп сурәтләнә. Ташлар арасыннан чылтырап аккан чишмәләре саф сулы, урман «өсләренә авып» тора, җирләре дә бик уңдырышлы, кара туфраклы. Надан һәм мәгърифәтсез булу сәбәпле, крестьяннар бу байлыклардан файдалана белмиләр. Авылларда мәктәп, мәчет, хәтта мулла да юк.

«Бәхетле кыз» повестенда сурәтләнгән авылда балалар укытуны үзе дә надан һәм дорфа Ибәт абызагай башкара. «Искечә торыңыз, йорт вә абзарларны бик мәхкәм (нык.— *Ш. С.*) эшләмәңез, аннан-моннан сөяштереп куйсаң да ярар, бу дөнья мәңгелек түгел»,—дип, акыл бирә ул халыкка, изге юлга кертәм, яманлыктан саклыйм, дип, юашрак мужикларны таяклап та җибәргәли. Ибәт абызагай фикеренчә, ирләр хатыннарын күпме җәберләсәләр дә ярый. Үзенең хатыны Хәдичә абыстайны да бик җәберли. Староста Муллагали белән Тимербулат та — шундыйрак кешеләр. «Мужик баласы, никадәр укыса да, гыйлем вә һөнәр иясе буласы түгел» дигән караш нык таралган. Авыл ярлы, надан, ялкау, караңгы.

Шушы караңгы тормышка каршы куеп, автор үзенең мәгърифәтчелек идеалын гәүдәләндергән якты һәм эшлекле шәхесләрне дә тасвирлый. Ибәтнең хатыны Хәдичә абыстайны әтисе өенә остабикә чакыртып укыткан. Хәдичә, төрки, гарәп, фарсы китапларын укып, язуга да өйрәнгән. Гаять гүзәл һәм күркәм холыклы, бик ягымлы һәм ачык йөзле. «Бәхетле кыз» — Гайшә — шушы гаиләдә үсә. Атасы Ибәт холыксыз һәм иске карашлы булса да, анасы Хәдичә абыстай — фәрештә кебек изге хатын — кызына яхшы тәрбия бирә.

Әти-әнисеннән яхшы тәрбия алып үскән, яшьтән үк тырышлыгы, белемгә омтылышы белән аерылып торган Габбас, Казандагы атаклы бер мәдрәсәдә укып кайтып, авылда мулла була, мәчет һәм мәдрәсә салдыра, үзенең вәгазьләре белән дә, шәхси үрнәге белән дә крестьяннарны яңача эшләргә һәм яшәргә өйрәтә. Габбас мулланың тырышлыгы белән авыл халкы мәдәниятле мул тормышка ирешә.

Гайшә Габбаска кияүгә чыга, кыз балаларны укыта башлый. Әдип аның бәхетле булуын, гаиләдәге тигезлеккә ирешү

белән бергә, халыкка файдалы кеше булып җитешүендә дип күрсәтә.

«Бәхетсез кыз» повестендагы төп герой — Хәнифә — бай табигатьле, әмма караңгы авылда туып үсә. Юкәле авылы кешеләренең төп кәсебе — чабата ясау. Җәй көннәрендә чит авылларга китеп эшлиләр. Автор Юкәле авылын Кирлемар дигән чуваш авылына капма-каршы итеп сурәтли. Кирлемарда мәктәп бар, көз җиткәч, балалар укырга бара, Юкәледә мәктәпнең нәрсә икәнен дә белмиләр. Мулла-мәзиннәр яшьләрне укыту турында уйлап та бирмиләр, киресенчә: «Мужикны әлифтән үткәрмә, бага («б» хәрефенә.— *Ш. С.*) йиткермә, күп укыса, күп белә, мулланың хәйләсенә төшенә, хатын-кызны укыту бозыклыкка сәбәп була, егетләр белән хат язышa»,— диләр.

Хәнифәнең ата-анасын да әдип әхлаксыз кешеләр итеп сурәтли. Әхтәри агай яшь чакларында үзен бик әдәпле тотмаган. Олыгайган көннәрендә дә төрле мәкерле уйлар белән эш йөртә.

Гамәлдән чыккан акчаны сәдака итеп бирә, сукалаганда, бер буразна булса да, кеше җиренә керә, хезмәтчеләргә түләүне кыса, авырып үлә башлаган хайванын суеп, кунак чакыра һ. б. Хатыны Шәрифәнең дә үз-үзен тотышы әдәп кагыйдәләренә сыешмый.

Ата-ананың дөрес тәрбия бирә алмавы кызларына тискәре йогынты ясый. Намусын югалткан, ирләре тарафыннан туктаусыз кыйналып җәфа чиккән Хәнифәнең язмышы фаҗига белән тәмамлана. Ул урманга барып асылына. Язучы Хәнифәнең фаҗигале язмышын гаиләдә тиешле тәрбия булмаудан һәм аны чолгап алган мәгърифәтсез, караңгы тормыш нәтиҗәсе итеп күрсәтә. Икенче яктан, әдип яшьләргә әхлакый тәрбия бирү максатын да куйган. «Яшь егетләр вә кызлар, шушы хикәяне укып, гыйбрәт алырлар, холыклары төзәлер дип өмет иделер», — дип яза ул.

«Мәгъсүм» (1906) һәм «Яңа әсхабе кәһәф» («Яңа тау куышы ияләре» мәгънәсендә, 1908) повестьларында язучының осталыгы һәм реализмы тагын да үскәнлеге күренә. Мулла баласы гөнаһсыз Мәгъсүм, авыл егетләре Сәфәргали, Миңлешаһ һәм Тимербай язмышында автор мулла һәм ишаннар кулындагы иске тип мәдрәсәләрне тәнкыйть итә.

«Җиһанша хәзрәт» повесте.

Бу повесть (1908) З. Һади әсәрләре арасында күләм ягыннан зур булуы белән генә түгел, ә тасвирланган вакыйгаларның күплеге, әһәмиятле мәсьәләләре, образларның тулырак эшләнүе белән дә

аерым урын тота. Автор, шәхесне тирәлек белән бәйләнештә реалистик сурәтләүне үзәккә алып, татар тормышында сорыкорт ишаннарның җитлегү юлын күрсәтә. Шуларны искә алып, Фатих Әмирхан 1908 елда «Әл-ислах» газетасында басылган мәкаләсендә болай дип яза: «Чын татар тормышыннан алынып язылган әсәр... Ишанлык мәсьәләсе татар матбугатында бик күптәннән бирле язылып килсә дә, ул тугрыда мөкәммәл әсәр барлыкка килгәне юк иде әле».

Башка әсәрләрендәге кебек, бу повестьта да автор баш геройны үзе яшәгән тирәлекне, гомумән, ул замандагы авыл тормышын киң планда алып сурәтли.

Җиһаншаның әтисе Дәүләтша — үз хезмәте белән көн күрүче урта хәлле крестьян. Сабый чактан ук зирәк, белемгә омтылган улын атасы: «Минем улым мулла булыр, яшел чапан, ак чалма киеп йөрер, ул ишектән килеп кергәндә, халык аягүрә торып каршы алыр, кунак итәр», — дип сөйләнеп, муллалыкка әзерли. Чөнки авылда иң яхшы яшәүче кешенең мулла икәнлеген күреп тора. Алга куйган максатына омтылучан яшүсмердә, укып, мулла булу теләге ныгый бара. Күрше авылда мәдрәсәдә укыганда, Җиһанша инде үзләренең авыл мулласы үше түгел, ә зуррак укымышлы мөдәррисләрне күрә, авылга кайтып, «Дәүләтша малае» булып йөрисе килми, зур бер мөдәррис булырга карар итә. Мәдрәсәдәге «укытучылары» һәм «тәрбиячеләре»нең үз мәнфәгатьләре белән генә яшәүчеләр, байлык, шөһрәт өчен төрле кыек юлларга керүдән дә тартынмаучылар икәнлеген Җиһанша якыннан танып белә. Аның характерында элек үк булган үзсүзлелек, үзен сөючәнлек (эгоистлык) сыйфатлары тагын да үсә.

Бохарада укып кайткан муллалар бик тә «белемле», абруйлы саналганга, Җиһанша да шунда китеп, берничә ел торып кайта, атаклы ишан булып әверелә, мөрит җыя, зур байлык туплый. Җиһанша ишан «үзенең йорт-җирләренә бик нечкәләп караса да, мәдрәсә эшләрен бик өстән йөртә... Аның шәкерт җыйнавы, мәдрәсә каравы җигәр өчен ат, савар өчен сыер, йон өчен куй асраудан аермасы» булмый.

Әсәрдә Җиһанша хәзрәткә һәм аның тарафдарларына яңа фикерле Хәсән мулла образы каршы куела. Хәсән, Җиһанша мәдрәсәсендәге иске тәртипләрне күреп, шәһәргә китеп укый, рус мәдәнияте белән дә таныша. Авылга кайтып, балаларга белем бирә, дөньяви фәннәр укыта, китапханә ачып, халык

арасында агарту-аңлату эшләре алып бара. Бу образ мәгърифәтче язучының уңай идеалын гәүдәләндерә.

Фәхрелбәнат образында язучы, хатын-кыз иреге мәсьәләсен куеп, ишаннар тозагына төшмәгән ачык фикерле кызны сурәтли. Белемле һәм әдәпле бу кыз белән Хәсән мулла, чын дус һәм фикердәш булып, тигез, бәхетле гаилә коралар.

Закир Һади иҗаты мәгърифәтчелек реализмы әдәбиятын XX йөз башларында тәнкыйди реализм баскычына китереп ялгый.

Биремнәр

1. З. Һадиның катлаулы тормыш юлы.
2. З. Һади әсәрләрендә табигатьнең һәм тирә-юньнең бирелеше, идея-эстетик вазифалары.

ӘДӘБИЯТ ТЕОРИЯСЕ

Мәгърифәтчелек реализмы

Мәгърифәтчелек реализмы — реализм үсешендә бер этап, феодаль-монархия системасының кризисы шартларында, мәгърифәтчелек идеологиясе нигезендә мәйданга килгән әдәби юнәлеш һәм иҗат методы. Ул Көнбатыш Европа әдәбиятларында XVIII йөздә, рус әдәбиятында бу гасырның икенче яртысында, татар әдәбиятында XIX гасырда, бигрәк тә аның икенче яртысында формалаша. Мәгърифәтче язучылар халыкның фәкыйрьлектә һәм томаналыкта изелеп яшәвен күрсәтәләр, әсәрләрен феодализм тәртипләренә каршы көрәш рухы, аң-белемгә нигезләнгән яңа тормыш, яңа әхлак нормалары урнаштыру идеяләре белән сугаралар. Әдәбият һәм сәнгатьтә реалистик принципларны теоретик нигезләүгә зур урын бирелә (Көнбатыш Европада Лессинг, Дидро һ. б. хезмәтләре). Мәгърифәтчелек реализмы әдәби төр һәм жанрларның, бигрәк тә повесть, роман һәм драманың, сатираның, үсешендә зур роль уйный.

Мәгърифәтче язучылар җәмгыятьне үзгәртеп коруның төп чарасы итеп кешеләрнең аңын һәм әхлагын үстерүне санныйлар. Әдәбиятның иҗтимагый ролен дә иске тәртипләрне тәнкыйть итүдә һәм аң-белемне, югары әхлак нормаларын пропагандалауда күрәләр. Әдәбият, тәнкыйть һәм мәгърифәтчелек вазифаларын үтәп, иске тормышның каршылыкларын ачып кына калмый, бәлки яшәешне үзгәртү юлларын да күрсәтә. Шушы сыйфат язучыларның иҗат принципларын билгели,

мәгърифәтчелек реализмын ике катламлы итә, ягъни ике башлангыч — реаль һәм идеаль башлангычлар — үзара тыгыз үрелә. Беренчедән, әдәби әсәр өчен материал тарихи конкрет милли тормыштан, заман чынбарлыгыннан алына, персонажларның үз-үзен тотышы, психологиясе, эш-гамәлләре аларны чолгап алган шартлар белән тыгыз бәйләнештә күрсәтелә, кеше тирәлек (мохит) җимеше итеп тасвирлана, ягъни реализм принциплары теге яки бу дәрәҗәдә тормышка ашырыла. Икенче яктан исә, язучының уй-теләкләрен, хыялларын гәүдәләндергән идеаль образлар сурәтләнә. «Әдәбиятка педагогик күзлектән карау, аны әхлак төзәтү, кеше тәрбияләү чарасы итеп күрү» (М. Горький) язучыларны үгет-нәсыйхәтчелеккә, дидактизмга этәрә. Укучыга үрнәк яки гыйбрәт булсын өчен, персонажлар, гадәттә, капма-каршы ике төркемгә — бик тә уңай һәм үтә тискәреләргә бүленә. Бу бүленеш, персонажларның искелек һәм яңалык тарафдарлары булуы белән бергә, мораль принципка, ягъни әхлаклы һәм культуралы булу-булмауга нигезләнә. Конфликтта, кагыйдә буларак, уңай геройлар өстен чыга, тискәреләр җиңелә, бәхетсезлеккә дучар була.

Мәгърифәтчелек реализмында тәрбия проблемасы зур урын тота. Кеше конкрет тарихи-социаль шартлар белән тыгыз бәйләнештә күрсәтелсә дә, тирәлек (мохит) төшенчәсе күбрәк гаилә һәм мәктәп-мәдрәсә даирәсе, ягъни өскорма, күренешләрен эченә ала.

Г. Кандалый, М. Акмулла, М. Акъегетзадә һәм З. Бигиев, Г. Ильяси, Ф. Халиди, алга таба Г. Исхакый, Р. Фәхреддин һәм Ф. Кәрими, З. Һади һәм Ш. Мөхәммәдев иҗатларында реалистик милли әдәбият зур үсеш алды. Татар мәгърифәтчелек реалистик әдәбияты капиталистик мөнәсәбәтләр үсеп барган чорда формалашу сәбәпле, күп кенә әсәрләрдә инде буржуаз җәмгыятькә хас бозыклыклар, каршылыклар күрсәтелә башлый, ягъни аның үз эчендә тәнкыйди реализм элементлары ярала.

Мәгърифәтчелек реализмы татар әдәбиятының XX йөз башында тизләтелгән үсеш процессына, тәнкыйди реализм һәм романтизм формалашуга җирлек әзерләде.

Сораулар һәм биремнәр

1. XIX гасырның икенче яртысында проза үсешенең сәбәпләрен ничек аңлыйсыз?

2. Роман һәм повесть, хикәя жанрындагы әсәрләрдә татар әдәбиятының реализм баскычына күтәрелүе нәрсәләрдә күренә?

3. Сәяхәтнамә жанры нинди үзгәрешләр кичерә?

4. «М. Акъегетзадәнең «Хисамеддин менла» романында яңа геройлар» дигән темага инша языгыз.

5. Р. Фәхреддиннең «Әсма, яки Гамәл вә җәза» романындагы уңай һәм тискәре образларга характеристика бирегез.

6. Ф. Кәриминең «Салих бабайның өйләнүе» хикәясендәге Салих һәм Р. Фәхреддиннең «Әсма...» романындагы Сәлим бабай арасындагы уртак һәм аермалы якларны күрсәтегез.

7. З. Һади повестьларында нинди төп темалар күтәрелә? Андагы образларга характеристика бирегез.

8. Җиһанша хәзрәт образы, аның характеры формалашуга тәэсир иткән шартлар.

9. Мәгърифәтчелек реализмының төп билгеләре.

Заһир Бигиев
(1870—1902)

Мәгърифәтчелек дәвере татар әдәбиятының күренекле вәкиле, роман һәм сәяхәтнамә жанрларын үстерүгә зур өлеш керткән Заһир Бигиевнең иҗат эшчәнлеге әдәбиятыбыз һәм мәдәниятебез тарихында әһәмиятле урын алып тора. М. Акъегетзадә кебек, З. Бигиев, бер яктан, татар һәм Көнчыгыш әдәби-мәдәни хәзинәләрен үзләштерсә, икенче яктан, рус, төрек һәм Европа әдәбиятларыннан үрнәк ала, үз заманы кимчелекләрен, иҗтимагый зарарлы якларын тәнкыйть итә.

Заһир Бигиев 1870 елда Ростов-Дон шәһәрендә мулла гаиләсендә туа. Әтисе Ярулла Пенза губернасы Чембар өязе Кикин авылыннан күчеп килгән. Шуңа күрә З. Бигиев үзен Чембарныкы (хәзерге Белинский шәһәре) дип атый торган була. М. Акъегетзадә белән аны якташлар дип әйтергә мөмкин. Белинский шәһәреннән ерак булмаган Мачали һәм Кикин авылларының арасы җиде чакрым гына.

Булачак язучы башта әтисеннән укый, рус мәктәбендә белем ала, рус телен һәм әдәбиятын өйрәнеп үсә. Әтисе үлеп, әнисе тәрбиясендә калгач, аны, рус мәктәбеннән алып, татар мәдрәсәсенә бирәләр. Монда ул гарәп, фарсы телләрен өйрәнә. Заһир яшьтән үк матур әдәбият белән кызыксына, бигрәк тә рус, француз, төрек язучыларының әсәрләрен мавыгып укый. Шулар үрнәгендә үзе дә бик яшьли, 15—16 яшьләрендә, әсәрләр яза башлый. «Меңнәр, яки Гүзәл кыз Хәдичә» романын бастыру теләге белән Казанга килеп, Күл буе мәдрәсәсендә укырга кала. Роман 1887 елда басылып чыга. Казанда Заһир шәһәр тормышы, иске тип мәдрәсә тәртипләре белән якыннан таныша. Шундый мәдрәсәләр тормышын һәм Казан байлары

арасындагы бозык һәм җинаятьле хәлләрне сурәтләп, «Гөнаһе кәбаир» («Зур гөнаһлар») романын яза. Әсәр 1890 елда басылып чыга.

1891 елда мәдрәсәне тәмамлап, З. Бигиев Ростов-Донга кайта. Рәсми рәвештә мулла булып торса да, күбрәк вакытын китапханәдә әдәби-фәнни китаплар укуга бирә, «Гөнаһе кәбаир»нең дәвамын — «Мөртәд» романын яза. Ләкин бу әсәр үз вакытында басылмый калган һәм аның кулъязмасы әлегәчә табылганы юк. Әдипнең бу елларда «Катыйлә» («Үтерүче хатын») романын язганлыгы турында да кайбер мәгълүматлар бар. Хәлбуки соңгы елларда галимнәрнең цензура архивларында тикшеренүләре «Катыйлә хатын» романы «Гөнаһе кәбаир»нең 1889 елда Петербургка цензурага җибәрелгән, тик басарга рөхсәт бирелмәгән беренче варианты булганлыгын күрсәтте. Бәлки, автор шул ук исемдәге мөстәкыйль яңа бер әсәр язган булгандыр,— монысы әлегә ачыкланмаган.

1893 елның җәендә З. Бигиев Бохара һәм Сәмәрканд якларына сәфәргә чыга, элек-электән мөселман мәдәнияте һәм белем үзәкләреннән саналган бу төбәкләрне үзе күреп кайтырга тели. Әдип бу елларда газета чыгару уе белән яши, Россиядә бу мөмкин булмаганга, газета чыгаруны Бохарада оештырып булмасмы дип тә өметләнә. 1892 елның ахырында Бохара әмире Петербургка барышлый Ростов-Дон аша уза, З. Бигиев, шунда аның белән танышып, ике басма романын һәм «Мөртәд» белән «Катыйлә» әсәрләренең кулъязмаларын бүләк итә, газета чыгару турында рөхсәт сорап гариза да бирә. Әгәр дә Бохара мәдрәсәләрендә белем бирү тәртипләре ошаса, анда укырга калу нияте дә була.

Ике ай ярым дәвам иткән бу сәяхәттә күргәннәре һәм уйкичерешләре турында әдип «Мавәраэннәһердә сәяхәт» очеркларын яза. Әсәр 1908 елда гына басыла.

Бу сәяхәттән З. Бигиев күп өмет-ниятләре җимерелеп, төшенке тойгыларга бирелеп кайта. Ул 1902 елда вафат була.

«МЕҢНӘР, ЯКИ ГҮЗӘЛ КЫЗ ХӘДИЧӘ»

Бу әсәр — детектив роман. Детектив әсәрләр, җинаять һәм шуңа бәйләнешле серле хәлләрне тикшереп, чәбәләнгән төеннең җеп очын табуга, җинаятьне ачуга, гаепләне эзләүгә

корылган була. Шуңа күрә мондый әсәрләрдә мавыктыргыч, маҗаралы сюжет өстенлек итә. «Мең̧нәр, яки Гүзәл кыз Хәдичә» романы да Казан мосафирханәләренең берсендә номерда атып үтерелгән Зөләйханың гәүдәсе табылу белән башланып китә. Зөләйха бүлмәсеннән Муса исемле кешегә язылган записка, сыңар перчатка, тәрәзә арасына ертып ташланган фоторәсем табыла. Җинаятьчене эзләү башлана. Ул кешене эзләп табуны атаклы шымчы Шубинга тапшыралар. Шик Казанның яшь байларыннан берсе Муса Салиховка төшә.

Муса образы. Казандагы бер бай улы Муса Салихов, Петербургта университет тәмамлаган булса да, этисе вафатыннан соң сәүдә эшләре белән мәшгуль. Үзенә зур куркыныч янаганда, Муса Петербургта бергә укыган дусты адвокат Андреевка түбәндәгеләрне сөйли. Бер ел элек ул, университетта укыганда, эти-әнисе белән Кырымнан Петербургка килгән морза кызы Зөләйха белән таныша. Зөләйха — гимназия тәмамлаган «гаять тә гүзәл кыз». Аның этисе, морза булса да, артык бай кеше түгел, башкалага күзен дәваларга килгән. Кыз белән студент егет бер-берсенә гашыйк булалар. Муса Зөләйханы этисеннән үзенә кияүгә бирүләрен сорый. Ләкин кызның этисе Мусаны яхшы белмәве сәбәпле риза булмый. Тиздән алар Кырымга кайтып китәләр. Шулай да Зөләйха Мусаның исем-фамилиясен, кайдан икәнлеген язып ала. Ләкин алар хәбәрләшмиләр.

Атасы үлгәч, сәүдә һәм фабрика эшләре, тормыш мәшәкатьләре Муса өстенә төшә. «Инде менә Казан байлары арасында һәркемгә билгеле мәшһүр бай Әхмәди Хәмитов үзенең Хәдичә исемле кызын йөз мең сум көмеш акча белән кияүгә биргәнлектән,— дип яза автор,— Муса Салихов шул туташны кәләшлеккә ярәшеп йөри, һәм тагы бер айдан аларның никах мәҗлесләре булырга тиеш».

Шул көннәрдә Казанга Зөләйха килеп төшә, хат язып, Мусаны мосафирханәдәге номерына чакыра. Күрешеп, хәлләр белешкәч, елмаеп, егетнең йөзенә туры карап: «Сезгә килдем. Шаять, Петербургта биргән вәгъдәгезне онытмагансыздыр бит?» — ди. Муса бик кыен хәлдә кала. Ләкин бер дә бorгаланмыйча, дөресен сөйләп бирә. Максаты Әхмәди бай кызын йөз мең сум көмеш акчасы белән кәләшлеккә алу булганлыктан, Зөләйхага өйләнә алмавын белдерә. Зөләйха, тыела алмыйча еласа да, Мусага ялынмый. Киресенчә, сөйгән кешесенә бәхетле, мәхәббәтле тормыш теләп, хәер-дога укый. «Бүген-

иртәгә мең сум акча китерермен, өегезгә кайтырсыз»,— дип, Муса аны тынычландырырга тырыша, төнге уникеләргә кадәр сөйләшеп утыргач, «икенче көнне килермен» дип кайтып китә.

Газетадан Зөләйханың үтерелү хәбәрен укыганда, елау дәрәҗәсенә җиткән Мусаның күзләреннән тамчы-тамчы яшь тәгәри.

Шымчы Шубин суд тикшерүчесен «Зөләйханы үтерүче — Муса», дип ышандыра. Шәһәрдә Муса Салихов Төркиягә качарга җыена, имеш, дигән хәбәрләр тарала. Тикшерүчене бу турыда кисәтеп, «Чынны әйтүче» дип кул куйган кешедән хат та килә. Шуннан соң Мусаны кулга алалар. Суд аны ун елга каторгага сөрә.

Автор Мусаны укымышлы, туры сүзле, йомшак күңелле итеп сурәтли, кызганып та куя. «Сизгер укучым! Мин дә Муса әфәндегә бернәрсә дә булмас, ул төрмәдән тиз котылып чыгар дип өмет итәм. Сезнең дә уегыз шулай булса иде!» — ди. Хикәяләвендә Муса белән аның абыйсы Нигъмәтулланың намаз укуларын да әледән-әле әйтә тора.

Габденнасыйр образы.

Әхлак ягыннан һәм шәхси интереслары белән Мусага капма-каршы итеп, З. Бигиев Габденнасыйр образын сурәтли. Автор аларның икесен дә бер үк социаль катлау вәкилләре итеп ала. Габденнасыйр, Муса кебек үк, Казандагы бер бай улы. Аларның гаилә хәлләре дә охшаш: икесенең дә этиләре вафат булган, икесе дә өйләнмәгән. Муса яше һәм белем дәрәҗәсе белән югарырак: ул 25—26 яшьләрдә, университет тәмамлаган. Габденнасыйр 24 яшьләрдә, гимназия бетергән. Алар арасында бүтән аермалар да бар. Муса этисенең бертуган кардәше Нигъмәтулла белән бер өйдә тора, сәүдә һәм фабрика эшләре белән шөгыльләнә. Габденнасыйрның Казанда өч-дүрт җирдә ташпулат өйләре булса да, үзе мосафирханәдә тора. Аның нинди эш белән шөгыльләнүе әйтелми. Мосафирханәдәге швейцар сүзләре белән Мусаның портреты бирелә: «Нечкә адәм, озын буйлы, ак йөзле, кечек сары сакаллы». Габденнасыйрның тышкы кыяфәте бөтенләй сурәтләнми.

Әмма алар арасындагы иң зур аерма — мораль, әхлакый сыйфатларында. Ул, якын сердәш сыйфатында Мусаны ничек коткару турында адвокат Андреев һәм башкалар белән киңәшеп йөргән булса да, аны тизрәк кулга алдыру, хөкем иттереп, каторгага җибәрү өчен, астыртын рәвештә кулыннан

килгәннең барысын да эшли. Муса турында ялган хәбәрләр таратучы да, тикшерүчегә «Чынны әйтүче» имзасы белән хат җибәрүче дә ул була. Габденнасыйр судта, Зөләйха үтерелгән кичтә Муса әфәнде минем номерыма килгән иде, дип сөйләргә ризалык бирә, шулай сөйли дә. Әмма алдан номерлар хуҗасы Габдуллин белән килешеп, ул кичне үзенең Кышкарга китүе турында записка язып бирә. Хөкем барышында Габдуллин: «Ул кичне Габденнасыйр әфәнде өйдә юк иде. Өйдә булмау гына түгел, ул, гомумән, Казанда юк иде»,— дип, әлеге записканы күрсәтә. Хәлиткеч моментта Муса үзе дә:

— Мосафирә хатын үтерелгән кичне мин Габденнасыйр әфәнде янында булмадым!..— дип кычкырып әйтә. Залдагы халык гаҗәпләнүдән аһ итә.

Шул рәвешле, гүзәл Хәдичәнең үзеннән бигрәк «меңнәр»енә хуҗа булу, көндәшен юлдан алып ташлау өчен, астыртын көрәш Габденнасыйр ягыннан алып барыла. Муса Габденнасыйрга карата бернинди дә начарлык эшләми. Романда Габденнасыйрның үзенә көндәш икәнлеген Мусаның белү-белмәве турында да әйтелми. Муса Габденнасыйрны үзенең якын дусты дип белә.

Муса каторгага хөкем ителгәч, Габденнасыйр өчен «меңнәр»гә хуҗа булу мөмкинлеге ачыла. Муса хәсрәтеннән Хәдичә туташта күкрәк авыруы башлангач, докторлар киңәше буенча, аны кымыз белән дәвалау өчен, Әхмәди бай гаиләсе Самара ягындагы дачага китә. Алар артыннан Габденнасыйр да китеп бара. Әхмәди бай дачасына кунакка баргалап йөри, әкренләп-иплэп кенә, «үзеннән дә ялганнар кушып», Мусаның Зөләйха янында булганлыгын сөйли, Әхмәди байны борчуга салып, шөбһәле уйларга батыра. Көннәрдән бер көнне:

— Муса әфәнде акылдан язган, имеш,— дип әйтеп куя.— Казаннан бер мөселман сөйләде,— ди. Габденнасыйр, Казаннан Әхмәди байга килгән хатларны, ачып укып, иясенә бирмичә, үзендә калдыра. Ниһаять, беркөнне, җаен туры китереп, Әхмәди байдан кызын үзенә кәләшлеккә бирүен сорый. Әхмәди бай, хатыны белән киңәш-табыш иткәч, Хәдичәне Габденнасыйрга бирергә риза була. Габденнасыйр тантана итә. Аны кызның кайгы-хәсрәт эчендә калуы да кызыксындырмый. «Ниһаять, морадына иреште: йөз мең сум көмеш акча белән гүзәл кыз ала! Тагы унбиш-егерме көннән Самара шәһәрендә аларның никах мәҗлесе булырга тиеш».

Ләкин Казанда Мусаның туганнары һәм дуслары да тик

ятмыйлар. Нигъмәтулланың, Мусаны коткарырга бирәр юл юкмыни, дигән соравына адвокат Андреев болай ди:

— Нишләп булмасын, бар андый юл. Тик аның өчен күп акча кирәк.

Мусаның гаепсез икәнлеген ул яхшы белә һәм чын үтерүчене эзләп табу чарасына керешә. Инде рәсми рәвештә тикшерү, суд эшләре тәмамланган. Акча исә хосусый рәвештә тикшерү, эзләнү чыгымнарына кирәк була. Судтан соң «Царьград» чәйханәсендә Габденнасыйр белән Габдуллинның әңгәмәсен исерек кыяфәтендә тыңлап утырган Шубин «үтерүче — Габденнасыйр» дигән уйга килә, үзенә тәкъдим дә булгач, бу эшне ахыргача ачыкларга алына. Самарага китәргә җыенган Габденнасыйр номерына бер сәүдәгәр кыяфәтендә килеп, бүлмәдәге җиһазларны сатып ала, өстәлдә яткан револьверның көпшә очын балавызга төшереп, соңыннан номердагы кәгазьләрне бик җентекләп тикшерә. Кырым адресын күрсәткән бер кәгазь кисәге табып ала. «Бүлмә җиһазларын мосафирханә хуҗасы Габдуллинга арзан бәһагә генә сатып һәм юл чыгымнары өчен кирәкле акчаны Нигъмәтулла әфәндедән алып», Бакчасарай шәһәренә чыгып китә, Зөләйханың әнисен эзләп таба. Шушы кульминацион ноктадан чишелеш башлана. Әнисенә язган хаттан күренгәнчә, Зөләйха үзен үзе үтергән икән.

Мусаны төрмәдән чыгаралар. Тиздән аның Хәдичә белән туе була. Алар «кичерелгән кайгы-хәсрәтләрдән соң», «тәмам теләкләренә ирешеп, бәхетле булып, кәеф-сафада» яши башлыйлар.

Габденнасыйрга килсәк, ул Зөләйха белән күрше бүлмәдә яшәгән, ату тавышын ишеткәч, кыз номерына кереп, «Зөләйханың үлемендә Муса Салиховны гаепләсеннәр» дип, револьверны һәм Зөләйханың «үз-үземне үтерәмен» дигән язуын урлап чыккан булган. Мәкерле теләкләренә ирешә алмаган Габденнасыйр кылган гөнаһларыннан тәүбә итеп, агу эчеп үлә.

Шул рәвешле, явызлык белән гаделлек бәрелешендә гаделлек җиңеп чыга, Габденнасыйр җәзасын ала.

З. Бигиевнең Муса Салиховка теләктәшлеге, Андреев һәм Шубинга уңай карашы, Габденнасыйрга тискәре мөнәсәбәте сизелеп торса да, ул үзенең уңай геройларын, М. Акъегетзадә кебек, артык идеаллаштырмый. Төп игътибарын вакыйгаларны тормышның табигый агышына хикәяләүгә юнәлдерә. Мусаны да ул җәмәгать эшләре белән кызыксынмаган, үзен генә кайгыртып яшәүче, байлар, сәүдәгәрләр даирәсенең бер кешесе

итеп тасвирлый. Безнең күзлектән караганда, Муса — үз чорының, үз җәмгыятенең кешесе, яшь татар буржуазиясенең бер вәкиле. Ләкин, Габденнасыйр кебек, кешелек сыйфатларын югалткан мәкерле тип түгел. Шуңа күрә, Муса белән Габденнасыйрның икесен дә бер яссылыкка куеп, меңнәр өчен көрәш ике комсыз арасында бара; Муса да — меңнәр артыннан гына куучы акча колы, кешелексез түбән җан, җинаятьче, дип искечә карау берьяклылык булыр иде. Зөләйханың акчасы булмаса да, бирсәләр, Муса аңа өйләнер иде, әлбәттә. Дөрес, тормыш арбасына үзе җигелгәч, аның карашлары үзгәргән булуы мөмкин. Ләкин әсәрдә бу хакта әйтелми. Конфликт мораль планда алына.

Адвокат Андреев, шымчы Шубин һ. б. тикшерүчеләр капитал хезмәтчеләре итеп күрсәтелә, алар белем һәм осталыкларын дөреслеккә түгел, бәлки акчага буйсындыралар, дигән фикер белән дә килешеп булмый. Күреп үткәнебезчә, алар барлык тырышлыкларын хаклыкны эзләүгә бирәләр. Нигъмәтулладан алынган акча исә төрле чыгымнарга тотыла.

Зөләйха һәм Хәдичә образлары.

Күреп үткәнебезчә, романда ике кыз образы бирелгән. Икесе дә бик гүзәл. Зөләйха (затлы нәселдән) — морза кызы. Хәдичә,— атасы бик бай булса да, гади сәүдәгәр кызы. Зөләйха гимназия тәмамлаган, хатларын да русча яза. Мусага язган хатыннан күренгәнчә, Хәдичә дә татарча белем алган шактый укымышлы кыз булып күз алдына килә. Алар арасында зур аерма шунда: Зөләйханың әтисе, морза булса да, артык бай кеше түгел, ә Хәдичәне йөз мең сум белән бирәләр. Романда Зөләйханың саф мәхәббәте белән байлык арасында каршылык тудырган хәлләр реаль, тормышчан итеп тасвирлана.

Ләкин Зөләйханы фаҗигагә китергән төп сәбәп бу түгел. Әтисе үлгәч, карт анасын япа-ялгыз калдырып, хәсрәткә салып, Зөләйха өйдән качып китә. Мәгърифәтчеләр, гаилә тәрбиясенә зур әһәмият биреп, яхшы ата-ана тәрбиясендә үскән бала алар күрсәткән юлдан барырга тиеш, дип карыйлар. Бала, читкә тайпылып, бу тәртипне боза икән, димәк, ул әхлакны да боза. Зөләйха да үзенең гаебен шунда күрә. Үләр алдыннан әнисенә язган хатында үзен аның алдында җинаятьче дип саный. «Мәхәббәтле әткәемнең дөнья куюыннан болай да җәрәхәтле күңелегезгә минем сезне ташлап, качып китүем аеруча зур зәһәр булгандыр...—дип язган ул.—Сезнең рөхсәтләрегездән башка качып китүем сәбәпле, минем Казанга сәфәрем дә хәерле булмады. Мәгъшукым Муса әфәнде... миңа өйләнүдән

баш тартты... Шәфкатьле әнкәем! Әгәр сез хәзер бу номерда, минем янымда булсагыз иде, мин, бәлкем, үз-үземә кул салмыйча, әүвәлгечә, дөньяда торып калыр идем. Ниләр кылыйм соң?! Син дә, сөекле әнкәем, минем янымда юк! Гөнаһларым өчен минем хөкемем тәмам: үз-үземә кул саламын».

Зөләйханың үкенүле бу хаты Габденнасыйрның гөнаһларыннан тәүбә итеп язып калдырган хатын хәтерләтә. Романда ике үлем була: берсе — ата-ана сүзеннән чыгып, карт әнисен ялгыз калдырып, качып киткән Зөләйха, икенчесе — комсызланып кешегә баз казыган Габденнасыйр.

Автор безне Хәдичә белән берничә урында кыска-кыска сурәтләп таныштыра. М. Акъегетзадә романындагы Хәнифә кебек, Хәдичә дә үзенең булачак кияве Мусаны күрше бүлмәдән такта ярыгы аша күзәтә. Муса хөкем ителгәч, хәсрәтеннән кыз тәмам авыруга сабыша. Дачада дәваланып ятканда, инде Габденнасыйрга бирәчәкләрен ишеткәч, моны бик авыр кичерә, хәсрәте көннән-көн арта, тирәнәя бара. Кыз борчулы уйларга бата. Шул ук вакытта аның чарасыз калуы да күренә: «Ләкин нәрсә генә уйласа да, ни кылсын? Ата-ана теләгенә каршы барсынмыни?!»

Шул рәвешле, Хәдичә образында нечкә күңелле, сөю тойгысын тирәнтен кичерүче, әмма язмышы тулысынча ата-ана ихтыярына бәйле татар кызы сурәтләнә. Ахыр чиктә, сөйгәне белән кавышып, ул бәхетле була.

«ГӨНАҺЕ КӘБАИР»

«Зур гөнаһлар» романында язучының мәгърифәтчелек карашлары, иске тип мәдрәсәләргә һәм байлар арасындагы төрле җинаятьләргә тәнкыйте активлаша, геройларга мөнәсәбәте ачыклана төшә. Бу әсәрендә инде З. Бигиев, шәхес һәм тирәлек мәсьәләсен үзәккә куеп, реализм принципларын эзлеклерәк һәм ачыграк итеп тормышка ашыра. Романның керешендә үк, әхлак төзәтү максатыннан, төрле бозыклыкларны һәм җинаятьләрне фаш итү теләген белдерә. Әсәрдә катнашучыларның күпчелеге гөнаһлы бәндәләр булып, әгәр ярлыкаучы-рәхимле Алланың рәхмәтенә ирешмәсәләр, мәхшәр көнендә җәһәннәм кисәүләренә әйләнәчәкләр, ди ул.

Роман янәшә барган һәм үзара үрелеп тә киткән ике сюжет сызыгыннан гыйбарәт. Берсе — авылдан килгән Габделгафурның, иске мәдрәсәдә бозылып, тормыш төбенә тәгәрәве.

Икенчесе — сәүдәгәр хатыны Маһруйның, иренә хыянәт итеп, бозыклык, җинаять юлына басуы. Икесендә дә тәрбия һәм тирәлекнең шәхескә йогынтысы мәсьәләсе үзәккә куела.

Габделгафур образы. Башта З. Бигиев Габделгафур туып үскән авыл (Нижгород губернасы Сергач өязендәге бер татар авылы) һәм аның әтисе турында кайбер мәгълүматлар биреп уза. Әтисенең исемен дә әйтеп тормыйча, «Нәкәс мулла» дип кенә атый. Ягъни кешелексез, әшәке дигән исем бирә. Нәкәс мулла, байтак заманнардан авылда имам булып, шәригать һәм дин исеме астында төрлечә алдашып, хәйләләп, ришвәт алып, күп мал-мөлкәт туплаган. Мохтаҗ кешеләргә бурычка акча биреп торып, арттырып түләтә, ягъни процент ала. Бу исә — шәригать буенча тыелган эш. Нәкәс ике хатын белән тора (моны мәгърифәтчеләр шулай ук хупламыйлар).

Казанга белем алырга килгән Габделгафур иске тип мәдрәсәгә урнаша, аның зарарлы йогынтысына бик тиз бирелә. Мәдрәсәдән куылып, карак Мәмәт белән аралашып китеп, тормыш төбенә тәгәри. Хезмәтче Әхмәдине үтерүдә, чиркәү басуда катнаша, тотылып төрмәгә ябыла.

Габделгафурның мәдрәсәдә укуын тасвирлаган чакта, әдип, публицистик чигенеш ясап, иске уку йортларындагы тәртипләрне тәнкыйть итә. Яшь буынга тиешле белем һәм тәрбия бирү өчен, мәдрәсәләрне үзгәртеп кору таләпләрен куя.

Шул рәвешле, Габделгафур язмышында шәхес һәм тирәлек мәсьәләсе (гаилә, мәдрәсә һәм җинаятьчелек белән тулы буржуаз җәмгыятьтәге тискәре күренешләр) реалистик планда хәл ителә.

Маһруй образы. Сәүдәгәр Җиһангир Агиев хатыны Маһруй элегрәк бер дә бозык кеше булмаган. Аның әтисе Гали Ваһабов Нәкәс мулланың киресе рәвешендә бирелә. Ул — алыш-биреш, сәүдә итеп күп кенә байлык туплаган алтмыш биш яшьлек юмарт һәм динле карт. Укымышлы, кешеләргә һәм шәкертләргә ярдәмчел. Хатыны Мәрьям абыстай да, — яхшы ата баласы булып, изге күңелле, намазчы ханым. Шундый кешелекле һәм мәгърифәтле кешеләр гаиләсендә Маһруйның яхшы тәрбия алып үсүенә шикләнмәскә мөмкин. Автор үзе дә, аңа сокланып, исемен Маһруй (ай йөзле мәгънәсендә) дип атый.

Шундый ук күркәм һәм кешелекле гаиләдә үскән Җиһангир Агиев та Маһруйның «аңлы, тәрбияле булуына хәйран, матурлыгына гашыйк» була. Тиздән алар өйләнешәләр, тату, матур гаилә коралар.

Ләкин феодаль-буржуаз җәмгыять яхшы, күркәм тормыш алып барган Маһруйны үзенең бозыклыклар сазлыгына тартып кертә. Маһруйның ире Җиһангир сәүдә эшләре белән айлар буе ерак сәфәрләрдә йөри. Тук тормышта яшәгән мондый чибәр, ялгыз хатыннарны бозык бай егетләр белән таныштырып, кавыштырып йөрүче карчыклар шәһәрдә тулып ята. Алар шуның хисабына яшиләр.

Бер карчык Маһруйны да бозык яшь сәүдәгәр Ягъкуб Галиев белән таныштыра. «Яшь гомерне бушка уздырырга ярамый дип, бер карчык,— ди автор,— бу ике яшь кеше арасында элемтәче булып, яшьләрнең яшь гомерен күңелле һәм кирәк эштә уздырта башлады». Мондый хатыннар һәм ирләр бер Маһруй белән Ягъкуб кына түгеллеген искәртеп, әдип җәяләр эчендә болай дип тә өсти: «Яшь гомерне бушка уздырырга ярамый диюче мондый карчыклар һәм яшь гомерләрен бушка үткәрмәгән мондый яшьләр Казанда аз түгел». Шулай итеп, язучы Маһруйның юлдан язуын һәм фаҗигасен тышкы тәэсирләр, тирәлек йогынтысы итеп күрсәтә.

Ягъкуб Галиевтән балага узган Маһруй, аның тарафыннан алданып, мәсхәрәләнүен күргәч, Ягъкубны үтерә һәм төрмәгә эләгә.

Автор Маһруйның кешелекле сыйфатларын да сурәтли. Ул яңа туган баласын ничек булса да саклап калырга тырыша, вакытлыча акушерка карчыкта калдырып торып, соңыннан «тәрбиягә алырга» ниятли. Төрмә тәрәзәсенә янгын шәүләсе төшкәндә, аңа үз өйләре янадыр кебек тоела. Янгын эчендә калган карт әнисе һәм кызы күз алдына килә. Алар, Маһруйга кулларын сузып, «кызым!», «әнкәй!» дип ярдәмгә чакыралар кебек тоела. Маһруй, үз хатасын аңлап, вөҗдан газаплары кичереп, асылынып үлмәкче була. Ләкин аны ярым үлек хәлендә ире Җиһангир кереп коткара.

Хатынының хыянәтен гафу иткән, аны төрмәдән коткарырга йөргән Җиһангирны автор бик кешелекле, идеаль герой итеп сурәтли. Җиһангир мәгърифәтче әдипнең гуманистик идеалын гәүдәләндерә. Моңа үз заманында Фатих Әмирхан да игътибар иткән. Ул болай дип яза: «Бу әсәрдәге типларны Заһир Бигиев, булачак мәгыйшәтне[1] алдан сизенеп чыгарган шикелле, вөҗүдкә чыгарадыр[2]... Хатынына җинаяте соңында

[1] Мәгыйшәт — тормыш.
[2] Вөҗүдкә чыгара — барлыкка китерә.

да гуманлы мөгамәлә итеп гафу итә алырлык хөр табигатьле татар менә бу көннәрдә генә вөҗүдкә килә башларга мөмкиндер» (1908).

Бертуган Галиевләр. Җиһангир Агиев белән бер үк социаль катлау вәкилләре — сәүдәгәрләр булган ике бертуган — Ибраһим һәм Ягъкуб Галиевләр әхлакый яктан гаять бозык кешеләр итеп сурәтләнә. Ягъкуб Галиев —27 яшьтәге бозык, тәүфыйксыз, өйләнмәгән егет. Шәхси зәвыклары өчен, чибәр хатыннар белән танышып, аларны кыен хәлдә калдырып, эзне суытырга остарып беткән. Әсәрдә Ягъкуб Галиев әхлак-мораль ягыннан череп таркалган, намуссыз бер тип буларак күрсәтелә.

Ягъкубның абыйсы Ибраһим Галиевне автор «олуг юрист, мәкерле һәм фетнәчел кеше» дип тәкъдим итә. «Олуг юрист» кушаматы да бу сәүдәгәрнең белеменә карап түгел, ә мыскыл итеп ирония белән бирелгән. Автор аның наданлыгын, байлыктан башка нәрсә белән кызыксынмавын берничә эпизодта күрсәтә.

Әхмерский, иң мөһим соңгы яңалык итеп, муллаларны имтиханга тарту турында патша указын укырга керешә. Шулчакны, приказчик кереп, ат һәм сыер тиреләре, аларны нинди хакка җибәрүләре турында әйтә. «Ибраһим Галиев, «тире» сүзен ишеткәч,— ди автор,— бөтен игътибарын приказчикка юнәлтеп, падишаһ фәрманын бөтенләй онытты».

Маһруйдан туган баланың әтисе Ягъкуб икәнлеге исбат ителсә, Ягъкубтан калган мал-мөлкәт бу балага булачак һәм халык арасында Галиевләрнең яманаты да чыгачак. Шуңа күрә, Маһруйның тикшерүчегә сөйләгәннәрен белү белән, Ибраһим Галиев кичекмәстән акушерка карчыкны эзләп таба. Баланы тәрбияләргә дип, аңа ике йөз сум акча бирә, бу турыда карчыктан расписка яздыра. Хәйләләп яздырган бу кәгазьне, «арыслан гайрәте белән сузылып алып», кесәсенә яшергәч: «Кардәшем Ягъкубны, бер киңәштә булып, икәү бергә үтергәнсез икән!» — дип, карчыкның котын ала. Себер җибәрәчәкләре белән куркыта. Тикшерүчегә баргач, Маһруй сөйләгәннәрне кире кагарга, ә аңарчы баланы бик тиз «тәмам» итәргә куша.

Ибраһим, жулик Мәмәт белән Габделгафурны биш йөз сумга яллап, бу эшләрне сизенгән хезмәтче Әхмәдине дә үтертә.

Шул рәвешле, Ибраһим Галиевнең теләк-омтылышлары, эш-гамәлләре икътисади исәп-хисап белән билгеләнә. Ягъкуб-

тан калган байлыкны кулыннан ычкындырмас өчен, ул теләсә нинди мәкерле җинаятькә бара. Җинаятьләрне ул турыдан-туры үзе эшләми, моны аның акчасына «хезмәт» күрсәтүчеләр башкара. Ибраһим исә, читтә калып, судан коры чыга белә. Аның бу гадәтләрен үз җилкәсендә татыган Мәмәт болай ди:

— Син үткән юлы теге эштә дә, бернәрсә дә булмас, дип ышандырган идең. Ләкин ахырда вәгъдәңне үтәмәдең дә, мин алты ай төрмәдә яттым. Әгәр язу бирсәң — мөмкин, булмаса, икенче кеше тап.

Ахыр чиктә, Мәмәт һәм Габделгафур белән бергә, Ибраһим Галиев тә төрмәгә эләгә. Ләкин алар төрмәдән качалар. Әсәрдәге бу персонажлар турында сөйләүгә нокта куелмый. Автор, аларның киләчәк хәлләрен «Мөртәд» исемле романымда сөйләрмен, дип вәгъдә итә. Әмма соңыннан ул әсәр, язылган булса да, үз вакытында басылмый калган, һәм кулъязмасы әлегә табылганы юк.

«Гөнаһе кәбаир» романында сурәтләнгәнчә, Ибраһим Галиев кебекләр җинаятьләрне үзләре генә эшләмиләр. Буржуаз җәмгыятьтә аларның «йомыш»ларын үтәүчеләр тулып ята. Мондый «хезмәтче»ләрне җәмгыять үзе тудыра. Шундый кешеләр сыйфатында әсәрдә акушерка карчык һәм Мәмәт образлары бирелгән. Акушерка карчык яшьрәк чакларында балаларга белем бирү белән шөгыльләнгән, гарәп һәм фарсы телендәге китапларны да укыткан. Маһруйны да укырга-язарга ул өйрәткән. Картайгач, күрәсең, бүтән килере булмагач, фатирында яшереп бала табучы хатын-кызларга «яхшылык эшләп» көн күрә башлаган. Яңа туган балаларның кайсын ишек төбенә ташлап китә, кайсын кеше кулына биреп кача. Куркытып, Ибраһим Галиев кушкач, шул ук кичне Маһруйның баласын, ике кирпеч белән капчыкка салып, Кабан күленә бәкегә ташлый. Тыштан бик динле булып күренгән, намазын калдырмаган бу карчык, тикшерүчегә чакырылгач: «Йа Алла, әстәгъфирулла,— дип чәчрәп чыга.— Мин бу эшләрне һич тә белмимен»,— дип ялганлый. Хезмәтче Әхмәдинең үтерелүенә дә сәбәпче була.

Мәмәт — утны-суны кичкән, «җиңел кәсепләр» белән тәмам шомарып беткән тип. Аның милләте дә мәгълүм түгел, башта Россия кешесе булып, соңыннан Иранга качкан, ике-өч елдан Төркиягә күчеп, анда паспорт алган. Паспортында дине мөселман дип язылса да, «Мәмәт әфәнде бик шөбһәле адәм

булып, аның мөселман баласы, мөселман булуына шаһәдәт[1] бирмибез»,— ди автор.

Җинаятьче булуы белән бергә, Мәмәт образы икенче яктан да игътибарга лаек. Ул безнең хәзерге замандагы «манкортлык» күренеше белән бәйле. Мәмәт кебек «шөбһәле затлар Русиядә аз түгелдер» ди автор.

Романда эпизодик образлардан үзенең гадилеге, эчкерсезлеге, туры сөйләве белән хезмәтче Әхмәди хәтердә уелып кала. Ул үзенең бергә гомер иткән хатынын ихтирам белән күңелендә саклый. Аның турында гел сагынып кына сөйли. Автор Әхмәдине идеаллаштырмый, тормыштагыча итеп сурәтли.

Романда тормыш күренешләре шактый киң эпик планда алынган. Вакыйгалар авылда да, шәһәрдә дә бара, төрле холыклы, төрле идеаллы кешеләр сурәтләнә. М. Акъегетзадә әсәрендә алгы планда идеаль башлангыч — идеаллаштырылган уңай геройлар торса, З. Бигиев әсәрләрендә, шул исәптән әлеге романда да, образлар реаль мөнәсәбәтләрдә, тормышта булганчарак күрсәтелә. Туып килә торган буржуаз җәмгыять алып килгән бозыклыклар, җинаятьләр гомумкешелек кыйммәтләренә, яшәеш нормаларына капма-каршы килә. Әсәрдә бу бозыклыклар хөкем ителә.

Язучының реалистик хикәяләү стиле ныгый бара. Геройларны сурәтләгәндә, ул инде кара һәм ак төсләр белән генә эш итми, ә төрле буяулар куллана. Мәгърифәтче язучыларга хас булганча, публицистик чигенешләр дә ясый, теге яки бу уңай белән үз фикерләрен, җәяләр эченә алып, кыска гына белдереп үтә.

Әсәрдә вакыйгаларны сөйләү, гади хикәяләү өстенлек итсә дә, әдип геройларның психологик кичерешләренә дә урын бирә. Җиһангир, Маһруйның хәлләре белән танышкач, икеләнеп кала: «Инде нишләргә? Маһруйны хөкемнән коткару өчен, көченнән килгән кадәр гайрәт-тырышлык күрсәтеп, берәр төрле ярдәм чарасына керешергәме? Әллә иренә хыянәте өчен, «эзләгәнен үзе тапты» дип, мөмкин булган ярдәмне дә күрсәтмәскәме? «Юк,— ди ул.— Минем никахлы хатыным буларак, аның миннән ярдәм һәм булышлык көтәргә хакы бар». Акушерка карчык сорау алуда дөреслекне инкяр иткәч, Маһруй «шашкан кеше кебек» нишләргә дә белми:

[1] Шаһәдәт — таныклык, шаһитлык.

— И Алла! Кайда мин?Балам, балаларым, анам, кайда сез?! Сез кемнәрсез?! Минем белән ни кыласыз?! Ни өчен баламны бирмисез?! Ни өчен дөресен сөйләмисез?! Ярабби! Юкса әллә өнем түгел, төшемме бу?Йа Алла! Йа Алла!..— дип ачыргалана.

Габделгафур, бер яман юлга баскач, гел түбәнгә тәгәрәсә, Маһруй, тирән газаплар кичереп, хәтта «үлеп», физик һәм рухи терелү халәтен кичерә. Автор гаиләдә яхшы тәрбия алган кешенең бөтенләй үк бозыла алмавына ишарә ясый. Әхлаклы яшәү идеалы җиңеп чыга.

Романда матур-матур чагыштырулар очрый. Мәсәлән: «Ибраһим Галиевнең сүзләреннән акушерка карчыкның күзләре, чынаяктай зураеп, дүрт булды». «Биш сәгать үлгән кеше кебек йоклагач ... өстенә кайнар су коелган кеше сыман, Маһруй яткан җиреннән янә сикереп торды».

Әсәрдәге образлар һәм вакыйгалар, гаилә һәм мәдрәсә даирәсе белән генә чикләнмичә, буржуаз җәмгыятьтәге тәртипләр белән тыгыз бәйләнештә сурәтләнә. Ягъни роман, мәгърифәтчелек реализмы кысаларыннан чыгып, үз эченә тәнкыйди реализм элементларын да ала.

«Мавәраэннәһердә[1] сәяхәт».

З. Бигиевнең бу әсәре, иҗтимагый-сәяси һәм мәгърифәтчелек карашларын өйрәнү, халкыбызның башка милләтләр белән мәдәни бәйләнешләрен барлау, татар әдәбиятында сәяхәтнамә жанрының идея-эстетик үсеш юнәлешен күзаллау өчен, әһәмиятле чыганак булып тора. Язучы 1893 елның җәендә Урта Азия, Бохара, Сәмәрканд якларына сәфәр чыга. Әсәрдә сүз шул сәфәр турында бара.

Бу жанрдагы әсәрләргә хас булганча, әлеге очеркларда үзара тыгыз үрелгән берничә катламны күрергә мөмкин:

1. Хикәяләү. Ягъни автор үзенең сәяхәте, булган, күргән илләр, җирләр, халыклар турында хәбәр итеп, мәгълүмат биреп, хикәяләп яза.

2. Тасвир. З. Бигиевнең хикәяләвендә төрле чагыштырулар һ. б. сурәтләү чаралары кулланып, тасвирлап язу да очрый. Дөрес, алар бик күп түгел.

---

[1] Мавәраэннәһер — елга аръягы дигән мәгънәдә. Гарәпләр Урта Азия якларын шулай атаганнар. Бу гыйбарә укымышлы татарлар арасында да кулланылган.

3. Автор үзе булган урыннар, шәһәрләр һ. б. турында тарихи-географик мәгълүматлар белән таныштыра (Идел елгасы, Волга-Дон каналы, Бохара, Сәмәрканд һ. б. шәһәрләр, аларда яшәгән галимнәр).

4. Лирик-публицистик уйланулар, фикер йөртүләр. Автор гади бер күзәтеп йөрүче булып кына калмый, теге яки бу уңай белән һәрнәрсәгә үзенең мөнәсәбәтен белдерә, иҗтимагый әһәмиятле мәсьәләләрне күтәреп, публицистик фикерләре белән уртаклаша. Болар әсәрдә шактый зур урын тота.

Әдип татарларда мәктәп-мәдрәсәләрнең торышы, хатын-кыз хәле турында борчылып яза, яшь буынга дөньяви белем бирүне яклый.

З. Бигиев, Бохарадагы руханилар һәм уку-укыту тәртипләре белән якыннан танышкач, монда хөкем сөргән наданлык һәм артталыкны күрә.

Әдип Бохарадан күңеле кайгы белән тулган хәлдә китә. Зур өметләр белән башланган сәяхәтнең «ахыры соң дәрәҗәдә һәлакәтле» була. «Кулыма каләм тотмас бер хәлгә килдем. Тормыш ләззәтләреннән өмет өздем»,—ди ул.

Бу әсәр 1908 елда аерым китап булып дөнья күргәч, Ф. Әмирхан, аның әһәмиятен күрсәтеп, махсус мәкалә белән чыга.

Икенче бер мәкаләсендә Ф. Әмирхан З. Бигиев иҗатына, аның романнарына югары бәя бирә, бу язучыны татар әдәбиятына яңалык алып килүчеләрнең берсе итеп саный. «З. Бигиев романнары,— дип яза ул,— татар телендә язылып, миңа укырга тугры килгән роман диярлек әсәрләрнең әүвәлгеләредер... Бу романнар ... безгә яз якынлашканын күрсәтә торган кышкы якты кояшлы көннәр булып хезмәт иткәннәрдер».

Халык шагыйре Г. Тукай беренче мәртәбә «Мавәраэннәһердә сәяхәт» китабының тышлыгында басылган «Мәрхүм Мөхәммәдзаһир әфәндегә» дигән шигырендә болай дип яза:

...Иртәрәк милләтне сәүкъ әйләр идең[1] чын эзгә син!
Нинди гали[2], нинди зур эш эшләр идең безгә син!
Шунда да исмең синең милләт яшәдекчә яшәр,
Милләт үсдекчә үсәр һәм милләт ашдыкча ашар!

[1] Сәүкъ әйләр идең — алга әйдәр идең.
[2] Гали — бөек.

Роман жанры. Сюжет һәм композиция

Хикәяләүгә, образларны тасвирлауга, вакыйгаларны сөйләүгә корылган әсәрләр матур әдәбиятның эпик төрен тәшкил итә. Мәсәл, әкият, хикәя, повесть, роман, эпик поэма кебек жанрлар шушы төргә карый. Жанрлар үзләре исә вакыйга һәм образларның азлыгы яисә күплеге, әсәрләрнең күләме һ. б. үзенчәлекләре белән аерыла. Аларның барысына да сюжетлылык хас.

Хикәядә, гадәттә, бер яки ике вакыйга сөйләнә, катнашучылар аз, күләме кечкенә була. **Повестьта**, кагыйдә буларак, бер үзәк герой тормышындагы вакыйгалар, эпизодлар тезмәсе бирелә, аның инде күләме дә зуррак була. Мәсәлән, З. Һадиның «Җиһанша хәзрәт» повесте һ. б.

Катлаулы вакыйгаларны һәм күп образларны эченә алган, шәхси һәм иҗтимагый тормыш күренешләрен киң планда алып сурәтләгән эпик әсәрләр **роман** жанрына карый. Мондый әсәрләрнең күләме тагын да зуррак була, кайбер романнар берничә кисәктән, томнардан тора.

Повесть белән романны бер-берсеннән аерганда, кайчагында күләм мәсьәләсе зур роль уйнамый. Мәсәлән, З. Һадиның «Җиһанша хәзрәт» повесте белән З. Бигиевнең «Гөнаһе кәбаир» романы күләм ягыннан бер чамадарак. Персонажлар санында да әллә ни аерма юк дияргә мөмкин. Әмма «Җиһанша хәзрәт» повестенда геройның малай чагыннан башлап үлгәнчегә кадәр булган тормыш юлы күзәтелә, вакыйгалар һәм эпизодлар шушы образ тирәсенә туплана. «Гөнаһе кәбаир» әсәрендә исә вакыйгалар Габделгафур һәм Маһруй язмышы белән бәйләнештә үзара үрелеп киткән ике сюжет сызыгы буенча үстерелә, шәхси һәм иҗтимагый тормыш күренешләре дә киң һәм катлаулырак алына. Аерым кешеләрнең гаилә-көнкүреш хәлләре җәмгыять тормышы белән тыгыз бәйләнештә сурәтләнә.

Шуңа күрә М. Акъегетзадәнең «Хисамеддин менла», З. Бигиевнең «Меңнәр, яки Гүзәл кыз Хәдичә», «Зур гөнаһлар», Р. Фәхреддиннең «Әсма...» әсәрләре күләм ягыннан хәзерге романнар кебек артык зур булмасалар да, без аларны татар әдәбиятында беренче реалистик романнар дип карыйбыз.

Романнарның сюжет һәм композициясе дә, гадәттә, катлаулы була.

Сюжет («әйбер», «әчтәлек» мәгънәсендәге француз сүзеннән) — әдәби әсәрдә геройлар белән таныштыру, вакыйгалар барышында, үзара мөнәсәбәтләрендә аларның үсү-үзгәрү тарихы. Һәркайсы үз теләк-омтылышлары белән яшәгән персонажлар, гадәттә, үзара төрле каршылыкларга, конфликтларга керәләр. Конфликт билгеле бер якка хәл ителә.

Сюжетта вакыйгалар, үзара тыгыз үрелеп, хәрәкәттә сурәтләнә. Шуңа күрә сюжет төрле кисәкләрдән, элементлардан оеша. **Экспозициядә** («аңлатма» дигән латин сүзеннән) автор, кагыйдә буларак, әсәрдә катнашачак кешеләр, аларның тормышы, характерларының формалашуы турында мәгълүматлар бирә, вакыйга барачак урын-хәлләр белән таныштыра.

Геройларның үзара конфликтка керүе **төенләнеш** булып, **вакыйгаларның үстерелеше** башлана. Вакыйгаларның, көрәшнең иң киеренке, хәлиткеч моменты **кульминацион нокта** була (латинча «биеклек» дигән сүздән). Шуннан соң **чишелеш** китә. Сюжетның бу элементлары әдәби әсәрләрдә эзлекле рәвештә, шушы тәртиптә дә, урыннары алыштырылып та бирелергә мөмкин.

Монда инде без **композиция** төшенчәсенә киләбез. Композиция (латинча «төзү», «тәртипкә китерү» мәгънәсендә) — әдәби әсәрнең барлык өлешләрен сәнгатьчә оештыру, образларны бер-берсенә бәйләү, вакыйгаларны урнаштыру тәртибе, аның төзелеше. Моны һәр автор үзенчәрәк эшли. Мәсәлән, М. Акъегетзадә «Хисамеддин менла» романында композицияне геройлар белән таныштырудан (экспозиция) башлап чишелешкә кадәр (Хисамеддин белән Хәнифәнең өйләнешүе) эзлекле тәртиптә төзи. З. Бигиев «Меңнәр, яки Гүзәл кыз Хәдичә» романын вакыйгалар үстерелешеннән башлап китә (Зөләйханың үле гәүдәсе табылу). Экспозиция өлеше, ягъни төп персонажлар белән таныштыру, вакыйгалар барышында бирелә. Конфликтның төенләнүе исә (Габденнасыйр, үзенең көндәше Муса Салиховны төрмәгә утыртып, юлыннан алып ташлау өчен, Зөләйханың үләр алдыннан язып калдырган хатын һәм револьверын алып яшергән) әсәрнең азагында гына мәгълүм була. Шымчы Шубинның, Кырымга китеп, Зөләйханың әнисен эзләп табуы вакыйгалар үстерелешенең кульминациясен тәшкил итә. Зөләйханың хаты белән танышудан, бу турыда Казанга телеграмма бирүдән чишелеш башлана. Муса төрмәдән азат ителә, Габденнасыйр агу эчеп үлә.

Сораулар һәм биремнәр

1. З. Бигиевнең рус һәм Европа әдәбиятлары үрнәгендә реалистик романнар язуы нәрсә белән аңлатыла?

2. «Меңнәр, яки Гүзәл кыз Хәдичә» романы ни өчен «Меңнәр...» дип аталган?

3. Дәфтәр битенең бер ягына — Муса Салиховны, икенче ягына Габденнасыйрны характерлый торган мәгълүматларны язып чыгыгыз, охшаш һәм аермалы якларны күрсәтегез. Авторның аларга мөнәсәбәтен искә алыгыз. Шундый ук алым белән Зөләйха һәм Хәдичә образларына характеристика бирегез.

4. «Зур гөнаһлар» романындагы Габделгафур һәм Маһруй образларына нинди сыйфатлар хас?

5. З. Бигиев романнарының жанр һәм сюжет-композиция үзенчәлекләрен күрсәтегез.

6. «Роман», «сюжет», «композиция» төшенчәләрен аңлатыгыз.

XIX ЙӨЗНЕҢ ИКЕНЧЕ ЯРТЫСЫНДА ТАТАР ПОЭЗИЯСЕ

Гомуми күзәтү. Татар әдәбиятында проза әсәрләре элек-электән үк туып торган. «Кыйссасел-әнбия» (1310), «Нәһҗел-фәрадис» (1358), «Гөлестан бит-төрки» (1391), «Җәмигъ эт-тәварих» (1602) һ. б. — әнә шундыйлардан. Бу традиция XIX йөзнең икенче яртысында да дәвам итә. Каюм Насыйри, Муса Акъегетзадә, Заһир Бигиев кебек әдипләрнең тырышлыгы белән проза тагын да үсеп, киңәеп китә. Әмма ничек кенә булмасын, Гаяз Исхакый һәм Галимҗан Ибраһимовларга кадәрге татар әдәбиятында поэзия хакимлек итте.

Бу дәвер шигъриятенең күләм ягыннан шактый артуы, идея-тематик һәм жанр җәһәтеннән баюы, төрләнүе, халык арасында киң таралуы күзгә ташлана. Поэзиядә, бер яктан, Урта гасыр әдәби традицияләрен дәвам итү, Шәрык мәдәни казанышларын ныклап үзләштерү бара. Фольклор белән элемтәләр көчәя. Икенче яктан, шагыйрьләрнең реаль тормыш, иҗтимагый-социаль мәсьәләләр белән кызыксынуы арта.

XIX йөз татар шигъриятендәге җанлану һәм эзләнүләр иң беренче чиратта халыкның тормышындагы һәм үзаңындагы үзгәрешләргә бәйле. Татар нинди халык ул? Ул кайдан кая бара? Башка халыклар арасында аның тоткан урыны ничек? Дөрес, бу төр мәсьәләләр әле, XX йөз башы белән чагыштырганда, тоныграк, зәгыйфьрәк куела. Халкыбызның үзаңы «мөселман», «төрки», «болгар» төшенчәләре белән тыгыз бәйләнештә карала.

Татар халкы алдына иҗтимагый тормыш куйган сорауларга, Шиһабеддин Мәрҗани, Каюм Насыйри кебек акыл ияләре белән беррәттән, шагыйрьләр дә җавап бирергә омтылалар. Мәсәлән, Гали Чокрый Болгарның шанлы үткәненә, үз халкының данлы улларына мәдхия укый. Күп кенә шагыйрьләр, шул исәптән Акмулла да, Мәрҗанине зурлап шигырьләр яза. Бу һич тә очраклы хәл түгел. Чөнки «Шиһаб

хәзрәт»,— бер яктан, мөстәкыйль фикерле, тәрбияле, укымышлы шәхес; икенче яктан, ул,— үз халкының гыйльми тарихын тудырып, аның үткән һәм барыр юлларын яктырткан олуг галим. Авторлар фикеренчә, халыкны алга әйдәп бару өчен, Мәрҗани рухлы кешеләр кирәк.

Галим булса, милләт өчен зарлы булсын,
Кирәк ул — бай, кирәк ул ярлы булсын! —

дип язганда, Акмулла иң беренче чиратта Мәрҗани кебек олуг затларны күз алдында тота.

Милләт һәм шәхес — үзара аерылгысыз төшенчәләр. Бу чор шагыйрьләре халыкны үстерүнең төп юлын кешене тәрбияләүдә күрәләр. Һәм шуңа күрә дә аларның әсәрләрендә шәхес, аның уй-кичерешләре, иҗтимагый бәйләнешләре үзәккә куела, белемлелек, матур әхлакый сыйфатлар мактала, тискәре яклар кискен тәнкыйть ителә. Әлбәттә, шәхесне, аның эчке дөньясын тасвирлау төрле шагыйрьләрдә төрлечә. Мәсәлән, Кандалыйның лирик каһарманы өчен ихласлылык, тормышка якынлык хас. Гали Чокрый исә төп игътибарын кешенең тышкы сыйфатларына һәм иҗтимагый бәйләнешләренә юнәлтә.

Бу дәвер авторлары өчен гаилә — кешене, халыкны тәрбияләүнең иң мөһим урыны. Нәкъ менә шуңа күрә дә алар саф мәхәббәткә нигезләнгән гаилә коруга, яшь буынны белемле, тәрбияле итүгә, ата-ана һәм бала мөнәсәбәтләрен яктыртуга зур урын бирәләр. Бу эштә, башка чорлардан үзгә буларак, шагыйрәләрнең (Газизә Сәмитова, Хәнифә Гыйсмәтуллина, Галимә Рәхмәтуллина h. б.) актив катнашуы шигъри сүзнең самимилеген, үтемле яңгырашын тагын да көчәйтә төшкән.

Бу чор поэзиясенә янә нинди үзенчәлекләр хас соң?Акмулла, Әбелхәер, Баһаведдин Вәисев (1804—1893), Яков Емельянов (1848—1893) иҗатларында социаль мотивлар, тормышка тәнкыйть аша карау, публицистик аһәң көчле. Залим түрәләрне, ялган суфиларны, надан һәм әхлаксыз руханиларны тәнкыйтьләү дә шигъриятә зур урынны алып тора. Элеккеге чор белән чагыштырганда, дини-суфичылык мотивларын җырлау кими төшә, тормыш мәсьәләләре, дөньявилык белән кызыксыну арта.

Мәгълүм булганча, Урта гасыр Шәрык, шул исәптән татар әдәбиятында әкияти, билгеле сюжетларга язылган, романтик рухлы кыйсса-дастаннар күп. Хыялый күренешләргә бай булган бу төр әсәрләр иҗат итү XIX йөздә тагын да көчәеп китә.

Бу юнәлештә аеруча Баһави, Мәүлекәй Йомачиков, Әхмәт Уразаев-Кормаши, Лотфулла Галиулла улы (Сабир) кебек шагыйрьләр актив эшли. Аларның романтик поэмаларында еш кына яшьләрнең мәхәббәте илаһилаштырыла, иҗтимагый мәсьәләләр белән тыгыз бәйләнештә яктыртыла. Бу чор авторларын бигрәк тә Таһир — Зөһрә, Сәйфелмөлек — Бәдигыйлҗәмал сюжетлары җәлеп итә. Шунысын да искәртик: XIX йөз татар кыйсса-дастаннарының шактые Урта гасыр фарсы, төрки әдәбиятлар, фольклор белән бәйләнешле. Мәсәлән, Йосыфбик Шәйхелислам углы үзенең «Кыйссаи Сәйфелмөлек —Бәдигылҗәмал» поэмасын (1876) Мәҗлисинең «Сәйфелмөлек» әсәренә нигезләнеп иҗат иткән.

XIX йөз татар поэзиясе лирик һәм лиро-эпик формаларда үсә. Чәчмә һәм тезмә юлларны катнаштырып язган ядкярләр дә очрый. Лиро-эпик жанрлардан аеруча дастаннар актив. Лириканың газәл, мөнәҗәт, робагый, фәрд, хат кебек жанрлары иркен кулланыла. Халыкның үзаңы җанлануга, тарих, чынбарлык белән кызыксынуга мөнәсәбәттә күп санлы мәдхияләр һәм мәрсияләр иҗат ителә. Аларның үзәгендә, кагыйдә буларак, шул дәвернең күренекле кешеләре, мөһим вакыйга-хәлләре. Тел-стиль, сурәтлелек һәм, гомумән, поэтик яктан бу дәвер шигъриятендә әле Урта гасыр әдәбиятына хас сыйфатлар өстенлек итә.

XIX йөзнең беренче яртысы кысаларында өйрәнелгән Һибәтулла Салихов, Габделҗәббар Кандалый, Шәмседдин Зәки үзләренең иҗади эшчәнлекләрен әле гасыр уртасыннан соң да дәвам итәләр. Ә инде XIX йөзнең икенче яртысына кертеп өйрәнелә торган Гали Чокрый иҗат эшенә 40 нчы елларда ук керешә. Шуңа күрә әдәбият фәнендә аерым чорларга бүлү —билгеле бер дәрәҗәдә шартлы күренеш тә. Чынбарлыкта исә әдәбиятның яшәеше һәм үсеше — чагыштырмача бердәм һәм тоташ процесс.

XIX йөз поэзиясе, Урта гасыр әдәби традицияләрен дәвам итеп, баетып, яңа дәвер шигъриятен, Тукай, Дәрдемәнд, Сәгыйть Рәмиев, Бабич әсәрләрен тудыруда мөһим чор, баскыч булды.

Хәзер XIX гасырның икенче яртысында иҗат иткән аерым шагыйрьләргә кыскача гына тукталып китик.

Гали Чокрый (1826—1889).

Мөхәммәдгали Габдессалих углы Көеков — үз чорының күренекле шагыйре, педагогы һәм рухание. Ул хәзерге Башкортстанның Тәтешле районы Иске Чокыр авылында мулла гаиләсендә дөнья-

га килә (кушаматы туган авылына мөнәсәбәттә алынган). Яшьтән үк әтисеннән укырга-язарга, игенчелек, умартачылык кебек һөнәрләргә өйрәнә. Пермь төбәгендәге атаклы Танып мәдрәсәсендә, Минзәлә, Сарман якларында укый. Эстәрлебаш мәдрәсәсендә Шәмседдин Зәки белән бергә эшләп ала.

Гали Чокрый 50 нче еллардан башлап гомеренең соңгы көннәренә кадәр туган ягында уку-укыту, дин, иҗат эшләре, игенчелек белән шөгыльләнә. Аның өч мәртәбә хаҗга баруы мәгълүм.

Гали Чокрый, Утыз Имәни кебек, гаять үзенчәлекле, туры сүзле, бәйсез холыклы шәхес була. Шуңа күрә аңа шактый кыенлыклар да күрергә туры килә. Шагыйрь туган авылында ук вафат та була.

Гали Чокрый традицияләрен аның якташлары уңышлы дәвам итә. Болар арасында шагыйрьнең улы Гарифулла Чокрый (ягъни Гарифулла хәзрәт), татар-башкорт әдәбиятының күренекле вәкиле Әнгам Атнабаев һ. б. бар.

Гали Чокрый — күп санлы әдәби, гыйльми, педагогик китаплар авторы. Арада гарәп һәм фарсы телләрендә язылган ядкярләр дә бар. Күпчелеге шигъри формада. Гали Чокрый әсәрләренең кайберләре шагыйрь исән вакытта ук нәшер ителгән.

Әдип иҗат иткән китапларның, әдәби әсәрләрнең аеруча күренеклеләре түбәндәгеләр: «Шәм нуры» («Шәмгыз-зыя»), «Казанны мактау» («Мәдхе Казан»), «Елның дүрт фасылы» («Фосуле әрбага»), «Хаҗнамә» һ. б. Боларның шактые мәдхия һәм мәрсия жанрларында.

Гали Чокрый тематик һәм поэтик яктан, нигездә, традицион рухта эш итә. Әсәрләренең теле дә чагыштырмача авыр: гарәп, фарсы сүзләре белән чуарланган. Әмма әдип иҗатында чынбарлык, татар иҗтимагый тормышы һәм тарихы, заман белән бәйләнеш шактый көчле. Аның мәдхия һәм мәрсияләренең үзәгендә, мәсәлән, татар тормышының, мәдәниятенең мәгълүм затлары мактала. Алар арасында Вәлид Каргалый һәм Шәмседдин Зәки кебек шагыйрьләр дә, Мәрҗани кебек мәшһүр галимнәр дә, Сәлимгәрәй Тәфкилев шикелле билгеле мөфтиләр дә бар. Автор бу төр затларны күтәренке рухта, купшы сурәтләр ярдәмендә тасвирлый. Арага кызыклы гына тормышчан детальләр, күренешләр кертеп җибәрә. «Мәдхе Казан»да үткән һәм хәзерге заман, чынбарлык һәм идеал үзара үрелеп, конкрет күренешләрне сурәтләү аша бирелә. Әсәрдән

авторның белем-мәгърифәтне чын күңелдән яклавы, үз халкын алга җибәрергә омтылуы ачык күренә. Казан,— шагыйрь фикеренчә, тиңсез шәһәр, халыкның, «ислам йорты»ның үзәге. Автор бу каланы «саф ирләре», «саф җырлары» өчен дә мактый.

Гали Чокрыйның «Хаҗнамә» әсәрендә сәфәр кылу, дөнья күрү хуплана, фән-техника казанышлары, кеше хезмәте, иминлек, тәртип мактала. Шулай ук язмада туган илнең газизлеге, ватанның якынлыгы да образлы гәүдәләнеш таба. Ходаның хөкеме белән, көтмәгәндә иленнән аерылып калган кешенең, ди автор, сөекле ватаны үлгәнче исеннән чыкмас. Икенче бер урында ул «Зәй буендагы тауларны», «бакчаларны» дөньяның иң ямьле җире рәвешендә тасвирлый.

Гомумән, Гали Чокрый табигать күренешләрен сурәтләүгә, пейзаж аркылы кеше гомерен, рухи халәтне, тереклекне гәүдәләндерүгә зур урын бирә. Бу яктан аның бигрәк тә «Елның дүрт фасылы» циклы һәм кайбер башка әсәрләре игътибарга лаек. Бер шигырендә ул болай яза:

Яз әйямы — егет улмак,
Көз әйямы — карый улмак,
Кыш әйямы — вафат улмак,—
Гомернең гыйшрәте аздыр.
(Язгы көннәр — егет булу,
Көзге көннәр — карт булу,
Кыш көннәре — вафат булу,—
Гомернең рәхәт чагы аз.)

Шагыйрь фикеренчә, кеше яз көнендә үк кышка хәстәрлеген күрергә, ягъни яшь чакта ук алдагы гомерен уйлап яшәргә бурычлы.

Гали Чокрый, Сәйф Сараи, Әхмәт Үргәнчи, Мөхәммәд Әмин традицияләрен дәвам итеп, Болгарга, Идел-йортка зыян китергән Аксак Тимергә дә тискәре мөнәсәбәтен белдерә.

Гали Чокрый әсәрләрендә лирик каһарманның рухи халәтен, күңел каршылыкларын шактый үтемле тасвирлаган юллар бар. Бер мөнәҗәтендә шагыйрь, мәсәлән, болай яза:

Йанар бәгърем бәнем сүнмәс,—
Кеше хәлен кеше белмәс.
Ки кайгыдин кеше үлмәс,—
Ирешмәсә әҗәлләрдән.

Яков Емельянов («Җырчы Җәкәү») (1848—1893).

Мәгълүм сәбәпләр, иң беренче чиратта патша хакимиятенең колониаль сәясәте аркасында татарларның бер өлеше христиан динен кабул итәргә мәҗбүр була (Гаяз Исхакыйның «Зөләйха» трагедиясендә бу процесс шактый тулы гәүдәләнеш тапкан). Динен алыштыручыларның бер төркеме, бигрәк тә аксөяк катламы, әкренләп руслашып китә, ә инде күпчелеге үз әби-бабаларының телен, моңын саклап кала. Чукынган татарларны «керәшеннәр» дип йөртү гадәткә керә. Шунысын да әйтик: чукынган татарларның элеккеге диннәренә — мөселманлыкка — кабат кайту очраклары да тарихта күп.

Христиан диненә күчү керәшен татарларының дөньяга карашларында, гореф-гадәтләрендә кайбер үзгәрешләр дә тудыра (руска хас исем-атамалар алу, христиан дине йолаларын, бәйрәмнәрен тоту, рус язуын куллану һ. б.). Мөселман һәм чукынган татарлар арасында иҗтимагый һәм социаль тормышта да билгеле бер аерымлану башлана. Христианлаштыруны, руслаштыруны рәсми сәясәте иткән Россия хакимияте, әлбәттә, керәшеннәргә аерым өстенлекләр дә бирә, аларны мөселман татарларына каршы көрәштә үзенә таяныч итеп тә файдалана һәм билгеле бер дәрәҗәдә үз максатына ирешә дә...

Дини аерымлык керәшеннәрне татарның төп массасыннан, ислам дине белән сугарылган күп гасырлык бай мәдәнияттән өлешчә читләштерүгә дә китерә. Шуңа күрә аларның сөйләмендә гарәп-фарсы алынмалары чагыштырмача азрак очрый, борынгырак сүзләр, формалар, фольклор ядкярләре күбрәк сакланып калган. Әмма ничек кенә булмасын, бер хакыйкатьне онытырга ярамый: мөселман һәм керәшен татарлары — бер үк халыкның, ягъни татарның газиз балалары; аларның гомуми тарихи язмышлары, көй-моңнары һәм, иң мөһиме, теле уртак! Яков Емельянов — татар халкының менә шул керәшен төркеменнән чыккан күренекле шагыйрь. «Җырчы Җәкәү»гә кадәр (халык аны үз итеп, яратып, шулай атый) безгә христиан динендәге татар әдипләре булуы хәзергә билгеле түгел. Соңгы дәвердә исә керәшен татарларыннан чыккан Гурий Тавлин, Гәрәй Рәхим (Григорий Родионов) һ. б. әдәбиятыбызда уңышлы гына иҗат итәләр.

Яков Емельянов хәзерге Балык Бистәсе районы (элеккеге Лаеш өязе) Алан авылында урта хәлле игенче гаиләсендә дөньяга килә. Әүвәл Мамадыш өязенең Җүкәче авылындагы писарьлар әзерләү училищесында, аннан 1864—1869 елларда Казандагы «Үзәк керәшен татар мәктәбе»ндә укый. Мәктәпне

тәмамлагач, туган ягындагы Үрәй-Чаллы авылында балалар укыта. Кайбер галимнәр фикеренчә, 1874—1880 елларда Яков Емельянов Казан Духовная академиясендә белем ала. Аннан ул Вятка, Мамадыш якларындагы төрле төбәкләрдә поп булып тора. Әмма, күрәсең, ул үз вазифасын үтәүдән рухи канәгатьләнү алмый: әләк-шикаятьләргә дучар була, «каһәрләнгән поплар» исемлегенә кертелә, өметсезлеккә төшә.

Көн дә ызгыш, ялан әр
Җебектерде инде җанымны!
Каты кылмыш, тиешсез тормыш
Киптерә минем санымны!

Бу юлларда шагыйрьнең шәхси рухи халәте гәүдәләнүе дә бәхәссез.

Яков Емельянов 1892 елда, балалар укытам дип, элек үзе эшләгән Үрәй-Чаллы авылына әйләнеп кайта. Әмма берничә айдан үлеп китә.

Яков Емельяновның беренче китабы («Стихи на крещёно-татарском языке. Дьякон Я. Емельянов стихлары») 1879, икенчесе 1888 елда басылып чыга.

Шагыйрь әсәрләрендә тормыштагы, кешеләр табигатендәге аерым күренешләр гәүдәләнеш тапкан. Автор бигрәк тә ярлылыкка, бәхетсезлеккә игътибар итә. «Ярлы тормыш» шигырендә ул, мәсәлән, фәкыйрьлектән аптыраган, йөдәгән карт белән карчыкның аяныч көнкүрешен реалистик детальләр ярдәмендә тасвирлый. «Кайгы» әсәре дә тормышчан, оригиналь сурәтләргә бай (Кеше җаны «теш кебек ныгып утырсын», «үлән күк ... сыгылмас» һ.б.). Автор «кайгы»ны конкрет зат рәвешендә җанландыра, аңа кешегә дәшкән кебек мөрәҗәгать итә:

Сүрелдең инде, бөкре кайгы,
Ялкының һич тә кыздырмый,
Эчкә кереп кайнатсаң да,
Куәтең мине сыздырмый.

Әсәрдә кешенең ихтыяр көче мактала, кайгының, җиңелеп, «хурлык»ка калып, тормыштан куылачагына һәм «җан»га «сөенеч», «куаныч» киләчәгенә ышаныч белдерелә. Авторның тереклекне зурлаган «Кояш» шигыре дә яшәешкә өмет, ышаныч кебек яңгырый:

Яшьнә, кояш, ялтыра,
Яктың җирдә уйнасын!
Иртәнге кырау, соңгы суык
Яңа орлыкны коймасын!..

Әңгәмә формасына корылган «Күремчене хөрмәтләү» шигырендә Яков Емельянов күрәзәче карчыкны кискен тәнкыйтьли, кешеләрнең юк-барга ышануларын сатира уты астына ала. Шушындый ук сатирик башлангыч шагыйрьнең «Саран бай» парчасы өчен дә хас. Автор саранлыкның гайре табигый күренеш булуын, бу сыйфатка ия кешеләрнең ахырда барыбер җәзага тартылачагын күрсәтә:

...Күзенең туймас ялкыны
Яндырыр аның саннарын;
Ярлыдан кызганган саранннарның
Шайтан эчәр каннарын.

Яков Емельянов — христиан дине тәрбиясендә үскән гадәти керәшен татары гына түгел, ә югары рухани белемле чиркәү әһеле дә. Әмма шуңа да карамастан аның иҗатында ислам динен тәнкыйтьләү, христиан динен мактау азчылык урынны алып тора. Шагыйрь төп игътибарын гуманистик мәсьәләләргә, татар иҗтимагый тормышы куйган проблемаларга юнәлтә. Шуңа күрә Яков Емельянов иҗаты, гәрчә ул татар әдәбиятында үзенчәлекле урын алып торса да, күп гасырлык татар язма мәдәнияте һәм фольклоры белән шактый тыгыз бәйләнешле, аларга аваздаш.

Матур әхлакый сыйфатларны, күркәм эш-гамәлләрне мактау, аларның капма-каршыларын тәнкыйтьләү — Урта гасыр һәм XIX йөз татар әдәбияты өчен, гомумән, хас күренеш. Бу хәлне без «Җырчы Җәкәү» иҗатында да күзәтәбез. Мәсәлән, авторның «Улым» шигырендә юмарт, гадел, яхшы кешеләр сөеп, ә инде яман, усал, оятсыз, саран затлар нәфрәт белән тасвирлана.

Ярлы-мескеннәргә шәфкать, ярдәмчеллек, теләктәшлек рухы белән сугарылган «Балам» парчасындагы юллар үзләренең төп рухы, эчтәлеге белән Мөхәммәдьяр, Габди, Акмулла әсәрләренә аваздаш яңгырый.

Ата-ананы, олыларны зурларга, хөрмәт итәргә чакыру — татар әдәбиятындагы төп мотивларның берсе. Яков Емельянов та «Санлау» шигырендә, балаларга мөрәҗәгать итеп, карт кешеләрне хөрмәт кылырга, аларның киңәш-үгетләрен тотарга өнди.

Калыгыз сыгылып, баш орышып,
Йөзенә ягымлы карагыз;
Картка санлау кылсагыз,
Сезне дә санлар балагыз.

Картны, олыны санлаучы
Соңгы көндә сөенер;
Картны, олыны санламаган
Гомере буена көенер.

«Җырчы Җәкәү» иҗатына нинди поэтик үзенчәлекләр хас соң? Үзенә кадәрге һәм үз чорындагы күпчелек татар шагыйрьләреннән аермалы буларак, Яков Емельянов, кагыйдә буларак, гаруз формасына да, газәл, робагый, фәрд кебек классик жанрларга да мөрәҗәгать итми. Аның әсәрләрендә Шәрык поэзиясе белән бәйләнешле тел-сурәтләү чаралары да, тасвир алымнары да күзгә бик ташланмый. Шагыйрь иҗаты өчен ритмик чатаклыклар, шигъриятсез тезмә юллар куллану да чит түгел. Шулай да «Җырчы Җәкәү» шигырьләрендә аның үзенә хас яклар, хәтта татар әдәбияты өчен кыйммәте булган поэтик табышлар да бар.

Мәүла Колый, Габди, Габдессәлам, Кандалый һәм кайбер башка әдипләрнең иҗатларында халыкка аңлаешлы телдә язуның матур гына аерым үрнәкләре бар. Яков Емельянов исә барлык әсәрләрен дә гади халык телендә иҗат итә.

Урта гасыр һәм XIX йөз татар язма поэзиясендә гаруз — хакимлек итүче шигырь системасы. Силлабик шигырь исә Кол Гали, Габди, Габдессәлам кебек берничә шагыйрь иҗатында гына күзәтелә. «Җырчы Җәкәү» исә, нигездә, халык җырлары өчен хас булган дүртьюллык строфа формасын яратып файдалана.

Яков Емельянов поэзиядә җанлы сөйләм формаларын һәм интонациясен куллануда да уңышлы гына адымнар ясый. Аның шигырьләрендә эпик башлангыч, сюжетлылык үзенчәлеген сиздерә, эндәш, диалог формалары да актив. Поэтик яктан авторның аеруча «Әләк» шигыре игътибарга лаек. Шагыйрь фикеренчә, әләк шундый нәрсә ки, син ничек кенә булып, кайда гына йөрсәң дә, ул сине барыбер эзләп таба.

...Каладан илгә,
Җирдән суга,
Суыктан утка,
Төшлектән төнгә,
Таудан атауга
Күч, кач,—
Табар әләк!..

Шигырь җидешәр юллы 5 строфадан гыйбарәт. Һәр строфа (соңгысыннан кала) бер үк сүзгә («әләк») — рәдифкә төгәлләнә.

Әсәрдә шигъри үлчәм һәм рифма куллануда төрлелек күзгә ташлана.

Строфа ахырындагы сүз белән алдагы строфаны башлап җибәрү, ягъни ялгау, шигъри фольклорда еш очраса да, элеккеге язма поэзиядә бик сирәк күренә. Яков Емельянов исә — бу алымны куллануның чын остасы. Мәсәлән, «Санлау» шигырендәге строфаларның барысы да диярлек үзара ялгау ысулы белән бәйләнгән: «...Һәрберегез **аңлагыз. Аңлагыз** картның гыйбрәтен...»; «...Һәрберегез **отыгыз. Отыгыз** аның сүзләрен...» һ. б. Авторның башка күп кенә шигырьләрендә дә янәшә ике строфаның ахырында һәм башында бер үк сүзләрне кабатлау еш очрый: «...Аннан оялып **качма. Качма** аның йөзеннән...» («Саран бай»); «...Тамырын җәеп **калмасын. Калмасын** монда яман шәүлә...» («Олысыманлык») һ. б.

Яков Емельянов иҗаты, беренче карашка, Тукайгача чор татар язма поэзиясендә утрау кебек үзенчәлекле урынны алып тора. Әмма чынлыкта исә ул татар чынбарлыгы, татар фольклоры һәм язма мәдәнияте белән шактый бәйләнешле. «Җырчы Җәкәү» татар шигъриятен халык теленә якынайтуга, аның поэтикасын баетуга үзеннән билгеле бер өлеш кертте. Аның иҗатындагы аерым казанышлар: шигырьдә сөйләм стилен һәм интонациясен мул файдалану, ялгау алымын куллану С. Рәмиев, Һ. Такташ, Г. Кутуй һәм кайбер башка шагыйрьләр тарафыннан дәвам иттерелде. Мәсәлән:

Таң вакыты... Татар йоклый...
Мин, йокысыз, **уянам**,
Уянам да, тиле кебек,
Тик бер үзем **уйланам**.
Уйланам, уема батамын,
Тормыймын үзем, ятам...

(С. Рәмиев. «Таң вакыты»)

XIX йөздә рус һәм татар әдәбиятлары арасында багланышлар көчәя төшә. Бу процесста Яков Емельяновның да билгеле бер катнашы бар. Галимнәр күрсәтүенчә, аның «Әләк» шигыре рус шагыйре И. С. Никитинның (1824—1861) «Сплетня» әсәренә мөнәсәбәттә туган.

XIX гасырның икенче яртысында иҗат иткән шагыйрьләрдән, әлбәттә, иң күренеклесе — Акмулла.

Сораулар һәм биремнәр

1. XIX йөзнең икенче яртысындагы татар поэзиясе шул чор тормышы белән нинди мөнәсәбәттә?

2. Бу дәвер шигъриятенә нинди үзенчәлекләр хас?

3. Урта гасыр әдәбиятында Таһир — Зөһрә, Сәйфелмөлек — Бәдигылҗәмал сюжетларына язылган нинди әсәрләрне беләсез?

4. Гали Чокрыйның тәрҗемәи хәле хакында сөйләгез.

5. Гали Чокрый нинди китаплар, әсәрләр язган?

6. Шагыйрь әсәрләренең идея-тематикасын, автор кулланган жанрларны әйтегез.

7. Яков Емельяновның тормыш юлы һәм иҗаты хакында сөйләгез.

8. «Җырчы Җәкәү» шигырьләренә нинди үзенчәлекләр хас?

9. Яков Емельянов иҗатының татар поэзиясендә тоткан урыны.

10. «Әләк» әсәренең шигъри үзенчәлекләрен күзәтегез.

11. Әхмәт Уразаев-Кормашиның «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» әсәрен мөстәкыйль рәвештә укыгыз, аның Сайяди поэмасына мөнәсәбәтен ачыклагыз. (Ирекле бирем.)

Мифтахеддин Акмулла
(1831—1895)

«Котадгу белек» һәм «Идегәй» кебек ядкярләрдән, Мөхәммәдьяр һәм Утыз Имәни шикелле әдипләрдән килә торган шигъри эстафетаны Дәрдемәнд һәм Тукайларга тапшыруда Акмулла иҗаты хәлиткеч роль уйный. Шагыйрьнең шәхесе һәм әсәрләре инде менә йөз елдан артык татар, казах, башкорт укучыларының, әдипләренең һәм галимнәренең игътибар үзәгендә. Г. Ибраһимов, мәсәлән, Акмулланы «беренче яңа уйгану хәбәрчесе» дип атый, аның «мәшһүр» шагыйрь икәнлеген искәртә. Г. Тукай Акмулла шигырьләрен яттан белгән.

Акмулланың тормыш юлын һәм иҗат мирасын өйрәнүгә аеруча Ризаэддин Фәхреддин зур өлеш керткән. Галим шагыйрьне күреп тә белгән. Ул Акмулланың «зирәк вә үткен табигатьле һәм дә игътибарлы» кеше булуын әйтеп калдырган.

«Һәркемне артык сөйсә — артык кыйнар».

Мифтахеддин Акмулланың тормыш юлы шактый катлаулы, гыйбрәтле. Булачак шагыйрь 1831 елның 14 декабрендә элеккеге Бәләбәй өязендәге авылларның берсендә дөньяга килгән. Аның әтисе Мөхәммәдьяр хәлфәне берәүләр казах, икенчеләре татар дип күрсәтәләр. Әнисе Бибиөммегөлсем исә — татар кызы.

Мифтахеддин кечкенә вакытта ук, әтисе үлеп китә. Шуннан әнисе Камаледдин исемле бер башкорт мулласына кияүгә чыга. Әмма бераздан Акмулланың әнисе дә вафат була. Шулай итеп, Акмулла, нәкъ Утыз Имәни кебек, бик яшьли атаанасыз кала һәм ятимлекнең бөтен авырлыгын күреп үсә.

Үгәй ана кулында ятим калдым,
Андан да бик эрәтем китеп калды.
Өстемдә керле күлмәк, йыртык дамбал (ыштан.— *Х. М.*),

Кайда мелла (укымышлы.— *Х. М.*) бар дисә,—
йитеп бардым.
Фәкыйрьлекдән артык фән күрә алмадык... —

ди ул бер әсәрендә үзе хакында.

Шагыйрьнең мәдрәсәдә уку еллары да шактый авыр уза. Бу хакта Ризаэддин Фәхреддин менә ничек яза: «Йортыннан азык биреп тормаганлык вә атасы да моның хәленә артык игътибар итмәгәнлек сәбәбеннән, мәдрәсәдәге гомере ачлы-туклы үткән. Бераздан ул үги әтисе йортыннан, тынышмыйча, бөтенләй чыгып китә».

Акмулла әүвәл үз тирәләрендәге, аннан Эстәрлебаштагы һәм Троицкидагы мәдрәсәләрдә белем ала. Эстәрлебашта аның укытучысы атаклы шагыйрь Шәмседдин Зәки була.

Казах далаларына китеп муллалык кылу, анда мәгариф эшләре белән шөгыльләнү — Октябрьгә кадәрге татар дөньясында киң таралган күренеш. Акмулла да үз гомеренең зур өлешен казах балаларын укытуга, дала халкын белемле, мәгърифәтле итүгә бирә. Казах телен, фольклорын, гореф-гадәтләрен бик яхшы үзләштерә.

Акмулла төрле урыннарда яши, эшли. Уку-язу, белем бирүдән тыш, балта остасы, тимерчелек һөнәре белән дә шөгыльләнә; матур, моңлы тавыш белән җырлый да; тыңлаучыларны мавыктырырлык итеп сөйли дә, шигырьләр дә укый. Акмулла үз аты белән Урал тауларын, Казахстан далаларын, Көнбатыш Себер киңлекләрен кат-кат ураган, төрле кешеләр белән очрашып, дөнья хәлләреннән, бигрәк тә татар иҗтимагый һәм мәдәни тормышыннан хәбәрдар торган. Әйтүләренә караганда, аның өч бүлемле арбасы булган. Шуларның берсенә Акмулла үзенең китап-дәфтәрләрен, икенчесенә балта, чүкеч, пычкы, борау кебек эш коралларын салган. Ә инде өченче бүлемтегенә үзе утырып йөргән.

Акмулла бер шигырен: «Минем кебек булыр микән бәхетсез»,— дип башлап җибәрә. Чыннан да, шагыйрь өстенә бәлаләр болыт-болыт өелеп кенә тора. Ятимлек, ачлы-туклы яшәү, бер урыннан икенче урынга күченүләр... Акмулла ике мәртәбә гаилә корып карый. Әмма икесе дә уңышсыз чыга. Истәлекләрдә шагыйрьнең туры һәм үткен телле, кыю фикерле, гаделлекне яклаучы шәхес булуы искәртелә. Бәлкем шуңадыр, аның дошманнары да күп була. Нахак бәла аркасында Акмулла берничә ел төрмәдә дә утырып чыга.

Акмулланың гомер юлы да фаҗигале рәвештә өзелә. Шагыйрь Златоусттан Миасска барырга чыга. Юлда ял итәргә туктый: учак яга, ут яктысында китаплар карап утыра. Шунда аңа ике явыз зат, сиздермичә, пычак белән кадыйлар, гәүдәсен суга ташлыйлар. Бу аянычлы вакыйга 1895 елның 27 октябренә каршы төндә була. Бераздан шагыйрьне Миасс зиратына җирлиләр. Каберенә Зәйнулла Рәсүли тарафыннан язулы таш куела.

Акмулла,— шәхси яктан күп бәла-казаларга, бәхетсезлекләргә тарыса да, шагыйрь буларак бәхетле кеше. Аны исән вакытта да, вафат булгач та, татарлар гына түгел, казахлар һәм башкортлар да үз җырчылары итеп хисаплыйлар. Өч халыкның яраткан шагыйре булу — иҗат кешесе өчен, әлбәттә, зур бәхет һәм олы дәрәҗә.

«Түрә димә, кара димә — фигълен кара!»

Акмулланың безгә билгеле иҗат мирасы әллә ни зур түгел, кечерәк бер китапка сыеп бетә. Ул, нигездә, шигъри әсәрләрдән гыйбарәт. Шагыйрьнең җыентыклары Казанда берничә мәртәбә (1892, 1904, 1907) нәшер ителгән. Соңгысы — чагыштырмача тулысы —1981 елда дөнья күрде. Аны басмага Миркасыйм Госманов әзерләгән[1].

Акмулла әсәрләре, нигездә, мәрсия, мәдхия, робагый, шигъри хат, газәл, мөнәҗәт жанрларында иҗат ителгән. Болар арасында күләмлеләре — «Дамелла Шиһабеддин хәзрәтнең мәрсиясе», «Нургали хәзрәткә...» һ. б.

Акмулла әсәрләрен идея-тематик яктан, гадәттә, өч төркемгә бүлеп йөртәләр: 1) Мәрҗанигә мөнәсәбәтле һәм, гомумән, мәгърифәтчелекне, тәрәккыятне (прогрессны) яклап язган әсәрләре. Моңа шагыйрьнең «Нургали хәзрәткә...» дип аталган мәрсиясе һәм кайбер башка ядкярләре керә; 2) әдипнең тоткынлыкта иҗат ителгән һәм иҗтимагый гаделсезлеккә ризасызлык белдергән әсәрләре; 3) фәлсәфи, әхлакый, дини мәсьәләләр хакында төрле уйлануларны үз эченә алган парчалары. Әлбәттә, мондый бүленеш чагыштырмача шартлы. Чөнки андагы әсәрләр идея-тематик һәм поэтик яктан, жанр җәһәтеннән еш кына үзара керешеп, хәтта өлешчә кабатланып та китәләр.

Ни өчен соң Акмулла Мәрҗани тематикасына еш мөрәҗәгать итә? Моңа шагыйрь үзе болай җавап бирә:

---

[1] *Акмулла.* Шигырьләр.— Казан : Татар. кит. нәшр., 1981.— 271 б. (Өзекләр, мисаллар, нигездә, шушы китап аша китерелә.)

Ул минем атам имәс, остаз имәс,
Алыстан (еракган, читтән.— *Х. М.*) гашыйк булдык, эшен күргәч.

Димәк, автор өчен Мәрҗани иң беренче чиратта эше белән якын. Шулай ук олуг галим образына мөрәҗәгать итү — Акмулла өчен уй-кичерешләрен, кеше идеалын гәүдәләндерүдә билгеле бер сылтау, мөһим әдәби чара да.

Мәгълүм булганча, Мәрҗани — фикердә, эш-гамәлдә хөрлек, мөстәкыйльлек тарафдары, татар мәгърифәтчелек хәрәкәтенең юлбашчысы. Кыю рәвештә алга таба хәрәкәт итүче олуг затның эшчәнлеге, хезмәтләре, аеруча «Назурә» (1870) китабы, көчле иҗтимагый яңгыраш, шау-шулы бәхәсләр тудыра. Акмулла да, шигырьләреннән күренгәнчә, бу процесстан, Мәрҗани хезмәтләреннән хәбәрдар була.

Унбиш ел «Назурә»сен алганыма,
Карай-карай баш очыма салганыма,
Шифаи садр (күңелгә шифа.— *Х. М.*) анда хасил итдек,
Эленмәй хасидләрнең (көнчеләрнең.— *Х. М.*) кармагына,—

ди ул бер урында. Шагыйрь олуг галимнең дусларын да, дошманнарын да ярыйсы белгән һәм үзе, һич икеләнүсез, Мәрҗани ягында торып көрәшкән, аның карашларын халыкка җиткерүдә күп көч куйган.

«Дамелла Шиһабеддин хәзрәт...» әүвәл мәдхия рәвешендә язылган. Әмма автор, Мәрҗанинең үлем хәбәрен ишетеп, әсәрнең ахырына 13 дүртьюллыктан торган матәм шигыре — мәрсия өстәгән. Анда галимнең бөеклеге, үлеменең зур югалту булуы шактый үтемле тасвирлана (тәрҗемәдә): «Ул кояшның зуры иде, якты яшен нуры иде», «Кайчан ул зат китеп барды, Казан күрке китеп калды...» Һәр строфаның ахырында кабатланып килүче бер үк «Җөда булдык, дәрига, аһ!» («Аерылдык, үкенеч, аһ!» — *Х. М.*) юлы, музыкаль әсәрдәге кебек, хис-кичерешләрне көчәйтүгә, кайгы аһәңен арттыруга ярдәм итә. Шунысын да искәртик: бу парча үзенең строфа төзелеше, рифмалашуы, кабатланып килүче соңгы юлы белән Утыз Иманинең атаклы «Мәрсияи Хәмидә» шигырен хәтерләтә.

Акмулланың «Дамелла Шиһабеддин хәзрәтнең мәрсиясе», Мәрҗанигә мөнәсәбәтле башка әсәрләре жанр таләбе һәм Урта гасыр әдәби традицияләре йогынтысында төп образны, аның сыйфатларын, эш-гамәлләрен гадәттән тыш арттырып, күпертеп сурәтләүгә нигезләнгән. Мәсәлән:

Күзең сал: Мәрҗани ул — Тимер казык (йолдыз.— *Х. М.*)!
Булмаса, кыйбла тапмай адашырсың...

* * *

Исламбул (Истанбул), Мисыр, Шамда (Сүриядә.— *Х. М.*)
нәзыйре (тиңе.— *Х. М.*) юк.

* * *

Кай эше ул фазыйльнең таң калмастай,
Кай сүзе ул кямилнең сүз салмастай?!

Дәрденә дәрдемәндләр (авырулар.— *Х. М.*) шифа тапты,
Сукырлар күзен ачды карманмастай!

* * *

Хикмәтдә бу заманның Локманы[1] бу.

Имам Газали (1058—1111) — бөтендөньяга мәгълүм философ, хикмәт иясе. Ул татар укымышлылары тарафыннан аеруча хөрмәт ителә, өйрәнелә. Утыз Имәнинең, мәсәлән, бу олуг затка мөнәсәбәттә туган хезмәтләре, шигъри юллары бар. Акмулла берничә урында Мәрҗанине Газали белән тиңли (башка галимнәр чагыштыру өчен бөтенләй диярлек алынмый!).

Акмулла кулланган күп кенә сурәтләр тормышчанлыгы, яңалыгы, үтемлелеге белән сыйфатланалар:

Караңгыда фанусны (маякны, яктырткычны.— *Х. М.*)
кабызган ул,
Кайнар сөткә сары майны тамызган ул.

* * *

Болагы саф, чәйгә һәркем су алгандай...

* * *

Мондый гали (өстен, бөек.— *Х. М.*) галимгә тел оза(й)ткан,—
Ул үзе дүрт аяклы малдай икән!

* * *

Һавада ул бер шоңкар әйләнә очкан...

* * *

Дошманга пәйгамбәр дә ярамаган,
Сары май эт карнына онамаган
(килешмәгән, өнәмәгән.— *Х. М.*)!..

Акмулланың төрмәдә язылган шигырьләренә тирән лиризм, хис-кичерешләрнең табигыйлеге, ихласлылыгы хас.

[1] Локман — акыллылыгы белән мәшһүр легендар зат.

Автор тоткынлыкның авыр газапларын, лирик каһарманның кайнап торган рухи халәтен күрсәтү аша ирек, хаклык, шәхес хөрлеге идеалларын алга сөрә. Биредә ул Утыз Имәнинең «Горбәтнамә» поэмасындагы традицияләрне дәвам итә.

Акмулла — тормышның үзәгендә кайнаган, һәрвакыт хәрәкәттә, эш-гамәлдә булган тынгысыз зат. Мөгаен, шуңадыр да яшәешнең, заманның күп мәсьәләләре, фокустагы кебек, аның иҗатында образлы гәүдәләнеш тапкан. Шагыйрьне иң әүвәл, үзенең күп элгәрләре кебек, кеше проблемасы борчый. «Ат та булыр, тун да булыр — без булмабыз»,— ди ул бер шигырендә. Димәк, байлык, бер булмаса, бер булыр. Ә кеше гомере чикле. Аңа исән вакытта ук бәхет, тулы канлы тормыш кирәк. Моның өчен кеше, шагыйрь фикеренчә, белем-мәгърифәт тупларга, һөнәр үзләштерергә, тынмыйча, акыл белән эш итәргә, даими хәрәкәт итәргә бурычлы: «Карамас гыйлем кадрен кара надан»; «Надан дуст — бер айлык дуст, төбе — дошман»; «Кемнең хәле беленер мөбһәм (тик.— *Х. М.*) ятса?!» Акмулла белем, һөнәр төшенчәләрен гакыл, әхлак, әдәп һәм, гомумән, кешелеклелек төшенчәләре белән тыгыз бәйләнештә карый, хәтта соңгыларына өстенлек тә бирә. Авторның күп кенә шигъри юллары матур әхлакый сыйфатларны, кешелекле эш-гамәлләрне мактауга, аларның капма-каршыларын кискен тәнкыйтьләүгә юнәлтелгән. Шагыйрь үз укучыларын эчке яктан пакьләнергә, сафлыкка, иманга өнди:

Иң әүвәл пакьләү кирәк эчнең керен,
Эчтә тулып җатмасын сасык эрен.
Аһ, дәрига! Эч тазарсын, эч тазарсын,—
Булмаса, файда бирмәс коры белем!

* * *

...Әдәб дигән — мәхәббәткә сәбәб дигән;
Көферлек әдәбендә тормагандай,
Әдәбсездә иман тору гаҗәб дигән...

Акмулла өчен кеше иң беренче чиратта кешелеклелеге, әхлагы белән кыйммәт. Шуңа күрә ул кешеләрне байлыгына, дәрәҗәсенә карап бәяләүне тәнкыйть итә. «Гаҗәп,— ди ул бер шигырендә,— һәркем, бай булса, аңа якты йөз белән карый, ә фәкыйрь-мескенгә хөрмәт юк, (ул) кимсетелүдән зар итәр». Икенче бер урында автор үз укучысына болай дип эндәшә: «Түрә димә, кара димә — фигълен кара!»

Акмулла кешене белемле, һөнәрле, тәрбияле, саф һәм пакь күңелле итү аша халыкны, җәмгыятьне имин, бәхетле итәргә

тырыша. Әмма, шуның белән бергә, ул шәхес язмышының иҗтимагый һәм социаль шартларга бәйле булуын да күрә. Чөнки тормыш шартлары ярсу «аргамаклар»ны да туктата, «сандугачтай телләр»не дә кисә:

Арыкны аркылы атлаган аргамак идем,
Тәрәлеп туктап калдым текә ярга.

* * *

Дөньяда тулып яткан газизләр бар,
Телләрен сандугачтай — акча кискән!..

Акмулла — социаль гаделлек җырчысы, оптимист шагыйрь. Ул тормыштагы ямьсез, бозык күренешләрнең вакытлы булуына, хаклыкның өстен чыгачагына ышана:

Хаклыкны күрәм дисәң, бездә күз бар,
Арыслан айга сикереп аягы сынар...

* * *

...Саф алтынны нәҗескә буяу илән
Нәҗес китәр, алтынның заты китмәс!..

* * *

Залимнәргә әзерләнгән җәһәннәм бар...

Акмулла бер шигырендә болай яза:

Әһле ислам йоклабрак калыр булды,
Башка милләт алга таба барыр булды...
...Һиндстан галәмендәй мәхкәм (нык.— *Х. М.*) торып,
Исламга каршыларны каһир булсын (җиңеп чыксын.— *Х. М.*).

Ислам дөньясындагы, шул исәптән төрки-татар тормышындагы, артталыкның төп сәбәбе — колониаль коллык. Автор «Һиндстан галәмендәге» көчле антиколониаль хәрәкәткә теләктәшлек белдерүе, аны яклавы белән объектив рәвештә Россиядәге империячел көчләргә дә каршы чыга. Халыкның «йокыдан» уянуы, үз иркенә үзе хуҗа булуы, алга баруы өчен, шагыйрь фикеренчә, бердәмлек («Кабергә талаш берлә керәсезме?»; «Һай, кардәшләр, талашмаек булып бак-бак»), тәрбиялелек, белем-мәгърифәтле булу кирәк. Дошманнарыңа каршы тору өчен, ди ул, яңа гыйлемнәр, төрле фәннәр үзләштерү, «камилләр» рәтенә керү, телләрне белү шарт.

Урысча укып кына түгел белмәк,—
Халь килсә, фыравсузча белгән яхшы!

Акмулла төрки-татар дөньясында халыкны агартуда руханиларның мөһим роль уйнавын яхшы аңлый. Әмма алар арасында төрлесе бар. Бер өлеш руханилар, нәфескә бирелеп, тәкәбберләнеп, үз мәнфәгатьләрен генә кайгырту юлына басканнар. Андый затларны Акмулла, Мәүла Колый, Утыз Имәни, Кандалый традицияләрен дәвам итеп, сатира уты астына ала. Автор карашынча, чын мулла — ихлас табигатьле, бөтен күңеле белән дингә бирелгән кеше («Диндә — зирәк, дөньясына чукрак булсын»; «Дин юлында... юртак булсын...»).

Акмулла иҗатында кайбер башка фикерләр дә гәүдәләнеш тапкан. Мәсәлән, ул, Урта гасыр әдәби традицияләрен дәвам итеп, тугрылык, тел, шигъри сүз, язмыш кебек мәсьәләләр хакында да яза:

Тугрылык бу заманда корып калган,—
Туры әйтүче арт җакда торып калган...

* * *

Фетнәнең күбе чыгар телемездән...

* * *

Дөньяда сүземез бар — үземез юк!

* * *

Һәр бәндә күрәсене күрмәй калмас —
Кирәк солтан булсын, кирәк — император!

Күп кенә каләмдәшләреннән үзгә буларак, Акмулла иҗатында хатын-кызны сөю, мәхәббәт хисләрен җырлаган әсәрләр юк дәрәҗәдә. Әмма шагыйрь хатын-кыз һәм ир-атның тигез хокуклылыгын яклый, хәтта бер шигырендә «яулыклы дөрест хатын»ны ялган сатучы, чалмалы ирдән өстен дә куя.

«Сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт берлән».

Акмулла, нигездә, үзе тирән кичергәннәр хакында яза. Аның иҗатында заман сулышы, авторның шәхси язмышы нык сизелә. Поэтик интонациясендә публицистик аһәң көчле. Шагыйрь еш кына үз чорының конкрет затлары белән бәхәскә керә, нәрсәнедер раслый, кире кага. Бу процесс вакытында ул эндәш, сорау, өндәү чараларына мөрәҗәгать итә, телдәге образлы тәгъбирләрне, мәкаль-әйтемнәрне дә кулланып җибәрә («Батыр үлеме — марҗадан...»; «Иясе — серен белер биясенең»; «Башыңнан гакыл китәр — бәла килсә»; «Җаман дуст — кара җылан...»). Урыны белән бырат (брат),

наград, карман, паруд (порода) кебек рус алынмаларын, хәтта сөйләм телендәге аерым тупас сүзләрне дә файдаланудан тартынмый. Чичән табигатьле Акмулла, үз укучыларының һәм тыңлаучыларының, ягъни аудиториянең, нинди булуына карап, саф татар әдәби телендә дә, гарәп-фарсы сүзләре белән чуарланган стильдә дә, казах элементлары катнаштырылган телдә дә чыгыш ясый.

Акмулла,— әйткәнебезчә, чичән, аз сүзләр белән тирән, тапкыр мәгънә белдерү остасы. Хикмәтле сүз әйтүдә аның татар, казах, башкорт фольклорыннан, бигрәк тә төрки-татар язма әдәби казанышларыннан, мул һәм иҗади файдалануы сизелеп тора.

Бәла килсә, күрер күз күрмәз улыр,
Каза килсә, аяклар йөрмәз улыр,—

ди Акмулла бер шигырендә. Белгәнебезчә, моңа охшаш фикер инде борынгы рун истәлекләрендә, Мәхмүд Болгариның «Нәһҗел-фәрадис» әсәрендә үк очрый. Әмма шунысы мөһим: Акмулла шигырьләрендә күп кенә афористик юллар поэтик камиллекләре, мәгънәви эчтәлекләре белән бүгенге укучыны да таң калдырырлык:

Галим булса, лаф орсын хикмәт берлән!

* * *

Котырган эт һава карап өргән менән (белән.— *Х. М.*)
Асманда (күктә.— *Х. М.*) торган айның нуры китмәс!

* * *

Җүкәне майлау белән, каеш булмас...

* * *

Сезләрдә ярма булса, бездә тоз бар...

* * *

Дөньяга тую да юк, кую да юк —
Капчыгын канәгатьнең тычкан тишкән!

* * *

Бозыкка җир өстеннән асты артык.

Акмулла иҗатында аңа кадәр язма әдәбиятта күзгә ташланмаган, поэтик фикерне үтемле гәүдәләндергән сурәтләр шактый күп очрый. Шагыйрь, мәсәлән, бозык, тәкәббер кешеләрне тимерче күреге белән чагыштыра:

Якын барсаң, тимерче күрүгендәй,
Ул сине керләүгә бар, пакьләүгә — юк.

Көнчеләрне, гайбәтчеләрне автор кутырлы җирне эзләп йөрүче чебен белән тиңли («Кайда черек, кутыр бар — шунда кунар»; «Чебендәй кутыр йирне эзләп кунса» һ.б.). Акмулла Мәрҗанигә каршы көрәшүче Нургали хәзрәткә: «Котырсаң да, Уралдай тауны сөзмә!» — дигән киңәш бирә.

Акмулланың образлы фикерләвенә башка төрле үзенчәлекләр дә хас. Шуларның берсе — сатирик башлангыч. Ул, күрәсең, XIX йөз төрки-татар иҗтимагый һәм социаль тормышындагы үзгәрешләргә, идеологиядәге тәнкыйди юнәлешкә мөнәсәбәттә көчәйгән. Үзенең атаклы мәрсиясендә, «Нургали хәзрәткә...» әсәрендә һәм кайбер башка шигырьләрендә автор сатира чараларын шактый мул файдалана: «Симерсә, берен бере этдәй талар»; «Үзең симез, корсагың өлкән булсын!»; «Чаяндай, чыдай алмай чагарсыз» һ. б.

Акмулла, «Кыйссаи Йосыф»ның халыкта киң таралуын исәпкә алып, андагы образларга, мотивларга берничә мәртәбә мөрәҗәгать итә. Мәсәлән, сабырлыкны ул нәкъ Кол Гали әсәре рухында мактый:

...Сабыр кеше морадын табыр дигән;
Һәр эшдә сабырсызның төбе — хурлык,
Сабырсызлык башка бәла салыр дигән!

Акмулла үзенең төрмәдәге авыр язмышын Йосыфның тоткын хәле белән чагыштыра. Гаделлек тантана итә, нахак бәлаләр кире кагыла: Кол Гали каһарманы ахырда азат ителә. Акмулла үзе дә шушындый язмышка, ирек киләчәгенә өмет баглый.

Урта гасырның һәм XIX йөзнең күп кенә шагыйрьләре кебек, Акмулла да рифма, строфа төрләренең, поэтик фигураларның төрле формаларын иркен куллана. Мәсәлән, «Хатимә» («Дуст дигәнең») газәленең 8 строфасы да «улмасын» рәдифенә тәгәлләнә. Шуның белән бергә, 5 бәетнең икенче юлында «улса улсын» сүзләре дә эчке рәдиф рәвешендә кабатланып килә («Дөньясы тар улса улсын, күкрәге тар улмасын»). Автор шушы ук газәлендә поэтик фигураның телдәге омонимия күренешенә нигезләнгән тәҗнис төреннән дә файдалана:

Йорты Болгар улса улсын — йортны болгар улмасын!

Акмулланың икенче бер шигырендә «Күз алдында карманнан кармангандай!» юлы бар. Биредә охшаш яңгырашлы рус

һәм татар сүзләренең янәшә кулланылуы да тезмәгә үзенчәлекле яңгыраш бирә.

Мифтахеддин Акмулла иҗаты — меңьеллык төрки-татар шигъриятенең мөһим буыны, традиция һәм яңалык кушылуның күркәм бер үрнәге. Шагыйрь иҗатында XIX йөз төркитатар чынбарлыгының һәм рухи тормышының әһәмиятле мәсьәләләре гәүдәләнеш тапкан. Татар поэзиясен тормышка якынайтуда, Кандалый кебек үк, Акмулланың да роле ифрат зур. 1912 елда ук Җамал Вәлиди болай дип язган иде: «Татар шигырь вә назымының... интибах (яңарыш.— *Х. М.*) дәвере капкасын ачып кергәч тә, без анда иң әүвәл ярты казах, ярты татар Акмулла әфәндегә очрыйбыз». Әгәр дә XX йөз башы татар поэзиясе гаять зур үсешкә ирешкән икән, моңа, әлбәттә, Акмулла иҗаты да билгеле бер йогынты ясаган. 1911—1915 елларда Троицк каласында чыккан «Акмулла» исемле көлке журналы да шагыйрь исеме белән бәйле.

Акмулла еш кына үзенә һәм лирик каһарманына карата «дәрдемәнд» (кайгылы; сагышлы кеше) сыйфатламасын куллана: «Мин үзем бер дәрдемәнд диванәмен»; «Иншад иткүче (иҗат итүче.— *Х. М.*) мөләкъкаб (кушаматы.— *Х. М.*) дәрдемәнд Акмуллаңыз...» Шагыйрь Закир Рәмиев Акмулла иҗатын яхшы белгән, андагы күп кенә казанышларны да дәвам иткән. Бәлкем, ул «Дәрдемәнд» кушаматын да үзенә Акмулла иҗаты тәэсирендә алгандыр?!

«Билгесе ир-егетнең булсын мәйдан!» — дип язган иде Акмулла. Шагыйрь үзенә Ходай Тәгалә тарафыннан бирелгән гомерне мәйдандагы көрәшче, чын ир-егет кебек уздыра. Кушаматны да аңа халык, үз укучылары бирә. «Акмулла» (Акменла) дип пакь (ак) күңелле, тугры сүзле, белем, тәрбия бирүче кешегә әйтәләр. Шагыйрь үзе дә: «...Акмулла дип исем алдым, Бу исем бүләк булмыш тугрылыкка»,— дип яза. Шулай итеп, кылган хезмәт юкка чыкмый, шагыйрьнең үз сүзләре белән әйткәндә, «Һәр ни булса, тырышкан юлда калмый».

Сораулар һәм биремнәр

1. Акмулланың тормыш юлы хакында сөйләгез.
2. Ни өчен шагыйрьгә «Акмулла» кушаматы бирелгән?
3. Акмулланың иҗат мирасына идея-тематик яктан күзәтү ясагыз.
4. Шагыйрь ни өчен Мәрҗани тематикасына мөрәҗәгать итә һәм олуг галимне ничек тасвирлый?
5. Акмулланың шәхси язмышы һәм әдәби иҗаты үзара нинди мөнәсәбәттә?
6. Шагыйрь иҗатына нинди поэтик үзенчәлекләр хас?

7. Акмулла әсәрләреннән мәкаль-әйтемнәрне, канатлы сүзләрне билгеләгез, аларның мәгънәләрен, вазифаларын аңлатыгыз.

8. Татар әдәбияты тарихында Акмулла нинди урын тота?

9. «Акмулла — мәгърифәт һәм гаделлек җырчысы» темасына инша языгыз.

10. Шагыйрьнең бер шигырен яттан өйрәнегез.

ӘДӘБИЯТ ТЕОРИЯСЕ

Шигырьдә ритм һәм рифма

Моңа кадәр без үзара тыгыз бәйләнешле бу ике төшенчә һәм аларга мөнәсәбәтле мисаллар белән күп мәртәбәләр очраштык, ритм һәм рифманы тудыру чаралары хакында да сүз булды. Хәзер исә бу өлкәдә белгәннәрне гомумиләштереп үтик.

Ритм — бердәй яисә охшаш күренешләрнең үзара тигез вакыт аралыгында кабатланып килүе. Ул, гомумән, табигатькә, яшәешкә хас (көн-төннең, атна-айларның, ел фасылларының чиратлашуы; сәгать йөреше, йөрәк тибеше һ. б.). Гадәти сөйләм телендә ритм, кагыйдә буларак, нормаль, көйләнгән, тәртипле агыш, яшәеш төшенчәләрен белдерә.

Ритм музыка, поэзия кебек сәнгать төрләренең нигезендә ята һәм аларны оештыруда искиткеч зур роль уйный.

Поэзиядә ритм — шигырьне шигырь итүче, сөйләмне аһәңле, тәэсирле яңгыратучы мөһим чара. Аны барлыкка китерүдә аваз, иҗек, сүз, үлчәм, сүзтезмә, ритмик буын, пауза, басым, моң һәм сөйләмгә мөнәсәбәтле башка күптөрле элементлар катнаша. Шунысы мөһим: алар еш кына, үзара керешеп, кушылып, шигырьнең гомуми ритмын тудыралар. Галимнәр раславынча, шигъри текстның мәгънәсе һәм эчтәлеге дә гомуми ритмга билгеле бер дәрәҗәдә тәэсир итә.

Ритмны барлыкка китерүдә аеруча иҗекләрнең роле зур. Шигырь юлларында ничә һәм нинди (озын, кыска; ачык, ябык; басымлы, басымсыз һ.б.) иҗек булуы, тезмәләрнең ни рәвешле ритмик буыннарга аерылуы — болар бар да нинди ритм туута йогынты ясый. Шигырь системалары да (силлабик, гаруз, тоник, силлабо-тоник һ. б.) иң беренче чиратта иҗекнең нинди булуына, аның табигатенә карап билгеләнә. Ритмны барлыкка китерүче мөһим элементларның берсе — рифма.

Рифма (*грекча*: аһәңлелек, ярашучанлык; үлчәмлелек) — ике яки берничә шигырь юлының азагында (кайчак башка өлешләрендә дә) аваздаш кабатланулар (охшаш яңгыраучы иҗекләр яисә сүзләр). Мәгълүм булганча, иҗекләрнең бил-

геле бер санда яисә тәртиптә килүе шигырь юлларын тудыра. Ә шигырь юллары, үзара берләшеп, строфаларны барлыкка китерә. Бу процесста исә ритм белән берлектә рифма зур роль уйный. Ул шигырь юллары арасындагы чикне сиздертеп килә һәм аларны, ягъни тезмәләрне, строфага берләштерә.

Рифма шигырьне оештыруга, тезмә сөйләмнең мәгънәви һәм эмоциональ яңгырашын көчәйтүгә ярдәм итә.

Яңгырашларына һәм төзелешләренә карап, рифмалар берничә төргә бүленә: төгәл (мәйдан — кайдан, уйнатадыр — уйлатадыр), төгәл булмаган (әйдәле — файдалы, өермә — килергә), гади (тамчысы — илһамчысы, театр —император), катлаулы (вакыт белән — йакут берлән, һәр ягы — тау ягы). Кайда килүләренә, урнашу тәртипләренә мөнәсәбәттә рифмалар түбәндәгечә төркемләнәләр: парлы яки янәшә рифмалар *(аа, бб, вв* һ.б.*)*, аралаш яки юл аша *(абав)*, әйләнмә яки камаулы-боҗралы рифмалар *(абба, абва)*. Газәл һәм касыйдә жанрларында строфалар (икеюллыклар) *аа ба ва* рәвешендә рифмалаша. Робагыйларның рифмалары исә күпчелек очракта *ааба* схемасында була. Аваздаш иҗекләр яисә сүзләр горизонталь яктан шигырь юлының ахырында гына түгел, эчендә дә килергә мөмкин:

Күңел **һәр җирдә** юл эзли,
Кадәр (язмыш.— *Х. М.*) **һәр җирдә** тикән төзли (тигәнәк
түши.— *Х. М.*).
(Дәрдемәнд)

Тырышыңыз **үлгәнгәчә**, милләт рәхәт **күргәнгәчә**,
Тигез гомер **сөргәнгәчә**. Мин егламый, кем егласын?
(М. Гафури)

Бу төр аваздаш кабатлануларны эчке рифмалар дип йөртәләр.

Рифмалашуның омонимиягә нигезләнгән, ягъни бердәй язылучы, әмма төрле мәгънә белдерүче формасы да бар. Аны элеккеге әдәбият белемендә тәҗнис дип йөрткәннәр. Рифмалашуның бу төре аеруча Урта гасыр һәм XIX йөз әдәбиятында актив кулланылган.

Сораулар һәм биремнәр

1. «Ритм» һәм «рифма» төшенчәләренең мәгънәләрен аңлатыгыз.
2. Гаруз хакында белгәннәрегезне искә төшерегез.
3. Рифма һәм строфа үзара нинди мөнәсәбәттә торалар?
4. Рифмалашуның нинди төрләре бар?
5. Кандалый һәм Акмулла иҗатыннан омонимик рифмаларга (тәҗнискә) мисаллар китерегез.

ТАТАР ДРАМАТУРГИЯСЕНЕҢ БЕРЕНЧЕ АДЫМНАРЫ

XIX гасырның 80 нче елларында татар әдәбиятында моңарчы бөтенләй булмаган яңа бер төр — драма әсәрләре барлыкка килә.

Дөнья әдәбиятында, мәсәлән борынгы грекларда, драма төренең башлангычы фольклорга, халык уеннарына барып тоташкан кебек, безнең халыкта да драма элементларын эченә алган, кара-каршы сөйләшүгә, җырлашуга корылган уеннар, туй йолалары гасырлар буе яшәп килгән. Халык иҗат иткән дастаннарда да без персонажларның үзара сөйләшү-диалогларын очратабыз. Әхмәт Уразаев-Кормашиның «Таһир илә Зөһрә», «Буз егет» дастаннарында һ. б. әсәрләрдә бу традиция язма әдәбиятка да күчә. Персонажларның монологлары, үзара сөйләшү, бәхәс, сүз көрәштерү кебек алымнарны куллануда милли проза байтак тәҗрибә туплап өлгерә.

Шулай да безнең әдәбиятта драма төренең, поэзия һәм проза белән чагыштырганда, болай соңга калып мәйданга чыгуының сәбәпләре нәрсәдә соң?Бу — драма төренең үзенчәлекләре белән бәйле. Беренчедән, драма — иҗат итү өчен кыенрак жанр. Эпик әсәрләрдән аермалы буларак, андагы геройлар, автор катнашыннан, аның сөйләп аңлатуларыннан башка, үзләренең сөйләме, эш-хәрәкәтләре белән ачылырга тиешләр. «Драма» сүзе грекча «хәрәкәт» дигәнне аңлата. Шуңа күрә татар әдәбиятында гына түгел, бәлки күп кенә бүтән әдәбиятларда да драма төре бераз соңрак, лирикада һәм эпик төрдә тәҗрибә тупларгач кына барлыкка килә. Мәсәлән, рус әдәбиятында да ул XVIII гасырда гына мәйданга чыга. Кайбер яшьрәк әдәбиятларда мондый әсәрләр XX йөздә языла башлый.

Икенчедән, драма — әдәбиятның театр сәнгате белән тыгыз бәйләнгән үзенчәлекле төре. Мондый әсәрләр, кайбер чыгармаларны искә алмаганда, сәхнәдә кую өчен языла. Милләтебез тормышында театр туу өчен зарур булган тарихи, иҗтимагый-мәдәни шартлар чагыштырмача соң өлгерә.

Моның өчен халыкның аң-белем һәм культура дәрәҗәсе, җәмәгатьчелек фикеренең үсеше, мәгърифәтчелек хәрәкәте җәелү, театр сәнгате белән таныш булган кешеләр җитешү кирәк иде. Җәмгыять тормышында йогынтылары зур булган кадимче руханилар, динне берьяклы гына аңлап, театр сәнгатен мөселманга хәрәм дип тыеп килделәр. Әле хәтта 1905 ел революциясеннән соң да яңа туган татар театрына каршы көрәш алып бардылар.

Хәлбуки татарлар Казанда һәм башка шәһәрләрдә рус театрларына яратып йөргәннәр. Казан университеты галиме М. Рыбушкин «Казан шәһәренең кыскача тарихы» дигән китабында (1834) болай дип яза: «Бераздан соң татарлар бик һәвәс театр яратучылар булып киттеләр... Хәзер театрга гына түгел, төрле күңел ачу урыннарына да бик яратып йөриләр. Хәтта заманча укыган кешеләр дәрәҗәсеннән торып бу мәсьәлә турында фикер дә йөртәләр». Моңа бөек рус тәнкыйтьчесе В. Г. Белинский да игътибар иткән. М. Рыбушкин китабына рецензиясендә ул татар халкы арасында мәдәни хәрәкәтнең көчәюе турында шатланып һәм зур канәгатьләнү белән яза: «Казан татарлары күпмедер дәрәҗәдә цивилизацияле булулары, хәтта укымышлылык белән аерылып торалар икән. Алар — әдәпле һәм тәрбияле кешеләр... Татарлар бик теләп театрга йөриләр һәм аны бик яраталар икән».

Татар әдәбиятында беренче драма әсәрләре биргән Габдрахман Ильяси, Фатих Халиди, Галиәсгар Камал, Гаяз Исхакый кебек укымышлы яшьләр Европа, рус, төрек драматургиясенең күренекле әсәрләре белән танышалар, рус театрына йөриләр.

Гасыр азакларына таба җәмәгатьчелектә татарча спектакльләр кую, театр булдыру омтылышлары да көчәя. Моңа рус матбугаты да игътибар итә. Мәсәлән, «Волжский вестник» газетасы 1898 елда болай дип яза: «Мөселман халыкларында, алдынгы әдәбиятның үсә баруы белән бәйләнештә, ана телендә театр булдыру мәсьәләсе дә көн тәртибенә куела. Бу үз нәүбәтендә мөселманнарга театрга «җен шаукымы» дип түгел, бәлки башка күзлектән карауны көчәйтә». Шушы мәкаләдә татарлардан берничә кешенең сәхнәгә кую өчен пьесалар тәрҗемә итүгә керешүе турында да әйтелә.

«Татар телендә спектакль булдыру — Казан мөселманнары җәмгыяте алдынгыларының күптәнге хыялы,— дип яза «Казанский телеграф» газетасы шушы ук елда.— Изге хыял, әмма ул тиз генә тормышка ашырмы? Соңгы вакытта татар телендә

спектакльләр кую мәсьәләсе үзенең үсешендә яңа фазиска керде. Зыялы Казан мөселманнарыннан берәү Казанда татар театры мәсьәләсен хәл итүгә җитди алынырга булды. Хәерле сәгатьтә!»

Шушы елда Касыйм шәһәрендә беренче мәртәбә татарча спектакль — Г. Ильясиның «Бичара кыз» пьесасы куела. 1902—1904 елларда Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкертләре әдәби кичәләр үткәрә, спектакльләр куя башлыйлар. Студентлар, гимназистлар һәм шәкертләр катнашында аерым йортларда театр уеннары үткәрелә.

Габдрахман Ильяси
(1856—1895)

Татар әдәбиятында «Бичара кыз» дигән беренче драма әсәренең авторы Габдрахман Ильяси 1856 елда Казанда сәүдәгәр гаиләсендә туа. Аның әтисе Мөхәммәдәмин, гомеренең соңгы елларында бөлеп, зур бурычка бата. Бу бурычларны түләү улы Габдрахман өстенә төшә, йорт-җирләре дә, сатылып, шуңа кереп бетә. Габдрахман, төрле байларда конторщик һәм хисапчы булып, үз кул көче белән хезмәт итеп яши.

Мәдрәсәдә укуы белән бергә, ул, үзлегеннән һәм укытучыга йөреп, русча өйрәнә, рус әдәбияты белән таныша, театрга йөри, драматургия мәсьәләләре белән кызыксына. Ш. Мәрҗани, К. Насыйри кебек галимнәр белән якыннан аралаша. К. Насыйри белән бергәләп алар, җәй көннәрендә авылларга чыгып, авыл тарихларын өйрәнәләр, кулъязма истәлекләрне, фольклор материалларын җыялар, табигать күренешләрен күзәтәләр. Г. Ильяси, К. Насыйри һәм Ш. Мәрҗани шикелле, Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте утырышларына йөри, Пугачёв хәрәкәте турында кулъязма истәлекләр, Мәрҗани хезмәтләре хакында докладлар, чыгышлар ясый. 1885 елда ул әлеге гыйльми җәмгыятьнең әгъзасы итеп сайлана. Г. Ильяси бу елларда татар телендә газета чыгару өмете белән дә яши. Ләкин патша хөкүмәте аңа рөхсәт бирми.

Г. Ильясиның әдәби мирасы зур түгел. Безгә аның бары тик ике әсәре билгеле. 1887 елда «Бичара кыз» драмасы һәм шул ук елда «Яшь кыз вә хатыннарга һәдия (бүләк.— *Ш. С.*)» исемле кечкенә китабы дөнья күрә. Бу китапчыкта автор балаларны, бигрәк тә кызларны, ничек тәрбияләү турында фи-

кер йөртә. Шул китапка язган сүз башында: «Насыйп булса, тиз заманда татар телендә хатыннарга махсус бер зур китап тәртип кылачакмын»,— дип вәгъдә итә. Ләкин бу китапның язылу-язылмавы мәгълүм түгел.

Авыр тормыш зур иҗат планнары белән яшәгән Г. Ильясиның сәламәтлеген какшата. Ул 1895 елда 39 яшендә үлә.

«Бичара кыз» драмасы.

Драмада тормыш-көнкүрештә хөкем сөргән иске тәртипләр һәм аларга каршы чыккан яшьләр. Бер якта — каты күңелле, автор тарафыннан «бер кара бай кеше» дип тәкъдим ителгән Биктимер сәүдәгәр һәм «бик бай кешенең углы, ямьсез, аңгыра» Җантимер; икенче якта — заман үзгәрешләрен тоеп, үз язмышы турында борчылып уйлана башлаган, бәхеткә омтылган Маһитап һәм укымышлы егет Җанбай (шулай ук исемнәргә игътибар итегез).

Әсәр Маһитапның монологы белән башлана. Үзен Җантимергә бирәчәкләрен белеп, кыз бик кайгыра, елый, «шул кабахәт Җантимергә» бармау чараларын эзли.

Биктимер — иске гореф-гадәтләр белән яшәүче, патриархаль гаилә сакчысы. Ул, байлыкка кызыгып, бердәнбер кызын эчеп-исереп йөрүдән башканы белмәгән бай малаена — «надан, ямьсез, аңгыра» Җантимергә бирергә ике куллап әзер тора. Хатыны Фәрихә: «Маһитап яратырмы икән? Уртарак, диләр»,— дип икеләнү белдергәч, Биктимер: «Мин риза булгач әйтмәс!» — дип кырт кисә. Ул кызының бәхете турында да уйламый, аның ихтыяры белән дә исәпләшми.

Шул рәвешле, әсәр драматик конфликтка корылган. Ләкин чишелеш белән ул, драмадан бигрәк, комедияне хәтерләтә. Менә кияү көтеп утырган Маһитап янына укымышлы егет Җанбай килеп керә, алар кочаклашалар, үбешәләр, кызның ата-анасы, яучы, асрау Фатыйма бүлмәгә кереп, бу хәлне күреп «хәйран булалар». Ул арада Җантимер кияү килеп керә. Ул баштанаяк көлкеле персонаж итеп сурәтләнә. Кыз янына ул лаякыл исерек хәлдә килеп керә, абынып егыла. Җанбай «әнә синең хатының» дип асрау Фатыйманы күрсәткәч, Җантимер, алпан-тилпән, аның янына юнәлә, тегесе төртеп-төртеп җибәрә. Кияү кеше, «та-та-ллак!» дип, шунда ук хатынын да аера. Яшьләр, каршы көчләрне көлкегә калдырып, җиңел генә өстен чыгалар. Мондый чишелеш, гадәттә, комедияләргә хас.

Җанбай образында автор мәгърифәтчелек карашларын гәүдәләндергән укымышлы, аңлы, хатын-кызга кеше итеп ка-

раучы егетне сурәтли. Җанбайны без газета укып утырган хәлдә күрәбез. Маһитапны аңгыра бер бай егеткә бирәчәкләрен белгәч, ул ихлас күңелдән борчыла. Биктимерне ул «зөбани», «җәллад», ягъни палач дип атый. Маһитапны ирексез никахтан коткара. Җанбай да, билгеле бер дәрәҗәдә Маһитап та актив шәхесләр итеп сурәтләнә.

«Бичара кыз» драмасы сәнгатьлелек ягыннан йомшаграк язылган, аның күләме дә бик кечкенә, персонажларның эшхәрәкәтләре җәелдерелми. Шулай булса да ул безнең әдәбиятта мәгърифәтчелек идеяләре белән сугарылган беренче драма әсәре буларак әһәмияткә ия. Бу әсәр җәмәгатьчелек фикеренә уңай йогынты ясый, башка кешеләрдә дә пьесалар язу дәртен уята. «Бичара кыз» басылып чыккач, икенче елны ук Фатих Халидинең «Рәдде[1] бичара кыз» драмасы (1888) дөнья күрә.

[1] Рәдде — каршы булу, кире кагу.

Фатих Халиди
(1850—1923)

Фатих Халиди 1850 елда Казан губернасы Тәтеш өязе (хәзерге Татарстанның Кама Тамагы районы) Яңа Сала авылында мулла гаиләсендә туа. Әтисе Хаммат мулла, Фатихка бер яшь чакта Казанга күчеп, мулла һәм мөдәррис була. Фатих мәдрәсәләрдә укый, үзлегеннән белемен күтәрә. Бер байда приказчик булып хезмәт итә, үзе дә сәүдә эше, китап тарату белән шөгыльләнә. Бөтен гомерен Казанда яшәп, 1923 елда 73 яшендә үлә.

Ф. Халидинең иҗат эшчәнлеге 80 нче елларда «Рәдде бичара кыз» драмасыннан башлана һәм, нигездә, ике тармак буенча үсә: татар телендә пьесалар язу һәм «Мең дә бер кичә» әкиятләрен тәрҗемә итеп, шулар үрнәгендә «Мең дә бер сәхәр» һ. б. кыйссалар, хикәятләр чыгару. 1893 елдан башлап ул стена календарьлары чыгарырга керешә, аларда да кешеләрнең күңелләрен җәлеп итәрлек төрле әкиятләр, хикәятләр урнаштырып бара.

«Рәдде бичара кыз» пьесасында автор шәһәр ярлылары тормышын сурәтли. Ишек кагучы Мирзаның кызы Хәлимә «урта буйлы, сызылган кара кашлы, ак битле, энҗе тешле, озын кара чәчле», матурлыкта икенче Зөләйха дип тәкъдим ителә. Бу матур кыз ярлы булса да, приказчик Закир аңа яучы җибәрә, ләкин соңыннан, көнче хатын Мәхүпнең коткысына бирелеп, Хәлимәгә өйләнүдән баш тарта. Мирзаларның өе дә янып китә. Янгын вакытында Хәлимәне күреп, фабрикант Әхтәм байның улы Әптем аңа гашыйк була. Егетнең әтиәниләре дә, кызның чибәрлегенә, акылына, күркәм холыклы булуына сокланып, өйләнешергә ризалык бирәләр. Хәлимәнең

ата-анасын да үз яннарына алдыралар. Вәгъдәсен бозган Закир исә, ялгышлык белән булса да, револьвердан атылып үлә.

«Бичара кыз»да бай кызы Маһитап укымышлы ярлы егеткә кияүгә чыкса, «Рәдде бичара кыз» драмасында, киресенчә, ярлы кызы мәрхәмәтле һәм кешелекле бай улы Әптемгә бара. Драмадагы геройлар Маһитапны телгә алалар, кайберләре аны тәнкыйть тә итә. «Бичара кыз» драмасында укымышлы Җанбайның һәм Маһитапның өлгерлек күрсәтүе алгы планга чыгарылса, Ф. Халиди Хәлимәнең матурлыгын һәм өстәвенә бик тыйнак, күркәм холыклы булуын хуп күрә, шуның өчен аны бәхетле итә.

«Бичара кыз» пьесасы кебек, «Рәдде бичара кыз» әсәре дә, гуманистик идеяләрне яклавы белән, әдәбият сөючеләрне үзенә тарткан. Г. Тукай Уральск мәдрәсәсендә чагында бу драманы яратып укый, андагы кайбер рольләрне шәкертләргә уйнап та күрсәтә торган булган. Татар драматургиясенә нигез салучы Г. Камал шушы әсәрләр йогынтысында тәрбияләнә. «Г. Ильясовның «Бичара кыз», Ф. Халидинең «Рәдде бичара кыз» дигән театр китаплары чыкты,— дип искә ала ул.— Ильясов китабын ничә кат укыганымны белмим, әмма «Рәдде бичара кыз»ны 40—50 тапкыр укыганмындыр. Хәтта мин аны күңелдән, күрми укый да белә идем». 1905—1906 елларда Ф. Халиди «Морат Сәлимов», «Мәхрүсә ханым», «Саран, надан Теллә бай хикәяте» кебек пьесаларын бастыра.

Гасыр азакларында инде комедия жанры да мәйданга чыга. 1895 елда билгесез авторның рус әдәбиятыннан файдаланып язган «Комедия Чистайда» әсәре Казанда басыла. Бу комедиядә һәртөрле ырымнарга, хорафатларга ышанып яшәүче, иске карашлы, икейөзле Хәйрибикә карчык һәм аның дус-ахирәтләре көлкеле рәвештә сурәтләнә.

1898 елда Г. Камалның драма әсәрләре күренә башлый. Аның «Бәхетсез егет», «Өч бәдбәхет» драмалары, төрекчәдән тәрҗемә ителгән «Кызганыч бала» пьесасы 1900 елда басылып чыгалар. 1907 елда Ярулла Вәлинең «Оят, яки Күз яше» дигән драмасы дөнья күрә. 1903 елда Н. В. Гогольнең атаклы «Ревизор» комедиясе тәрҗемә ителә. Гаяз Исхакыйның драматург буларак иҗат эшләре дә шушы елларда башлана. Аның «Өч хатын белән тормыш» һәм «Ике гашыйк» комедияләре 1901—1903 елларда дөнья күрә.

Бу чордагы татар драматурглары төп ике жанрда — драма һәм комедия жанрларында иҗат итәләр.

Драма һәм комедия жанрлары

Драма (*грекча:* хәрәкәт) термины ике төшенчәдә кулланыла. 1. Матур әдәбиятның мөстәкыйль бер төре; конфликтка, вакыйгаларны, образларны геройларның эш һәм хәрәкәтләре аша ачуга корылган, диалог һәм монолог формасында язылган сәхнә әсәрләре. (Хәзер күбрәк драматургия термины белән белдерелә.) Бу төр үзе трагедия, комедия һәм тар мәгънәсендә кулланылган драма жанрларына бүленә. 2. Драма дип трагедия һәм комедиядән аермалы булган мөстәкыйль жанрны да атыйлар. Күбрәк ул шушы мәгънәдә кулланыла да.

Бу жанрдагы әсәрләрдә шәхеснең җәмгыять, башка кешеләр белән мөнәсәбәтләре вакытында килеп туган драматик хәл сурәтләнә. Драманы хәрәкәткә китерүче төп көч — конфликт. Персонажлар шушы көрәштә ачылалар.

XX йөз башы татар әдәбиятында Г. Камалның «Бәхетсез егет», «Уйнаш»; Гаяз Исхакыйның «Алдым-бирдем», «Тартышу»; Гафур Коләхмәтовның «Ике фикер», «Яшь гомер»; Фатих Әмирханның «Яшьләр», «Тигезсезләр» әсәрләре; Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану» пьесалары — драма жанрының уңышлы үрнәкләре.

Комедия (*грекча:* «күңел ачучылар» һәм «җыр» дигән сүзләрдән) — драма төренең бер жанры; иҗтимагый тормыштагы яки көнкүрештәге тискәре күренешләрдән көлеп, кеше характерының көлкеле якларын күрсәтүче сәхнә әсәре.

Комедия үзенең башлангычы белән, трагедия кебек үк, Борынгы Грециядә уңыш алласы Дионис хөрмәтенә үткәрелә торган йола уеннарына барып тоташа. Яз көне табигать җанлануны Дионисның үз дошманнарын җиңүе дип аңлаганнар һәм шатлыклы җырлар җырлаганнар, уйнап-көлеп бәйрәм иткәннәр. Борынгы грек комедиясенең чәчәк атуы безнең эрага кадәр V гасырга туры килә, һәм ул «комедиянең атасы» Аристофан исеме белән бәйләнгән.

Урта гасырларда чиркәү тарафыннан бик нык эзәрлекләнеп, комедиянең үсеше тоткарлана. Аны чиркәү әһелләре «шайтан сәнгате» дип эзәрлеклиләр. Яңарыш чорында комедия жанры зур үсеш ала.

Рус әдәбиятында комедия жанры XVIII гасырның икенче яртысында мәгърифәтчелек идеологиясе белән бәйләнештә «бозык әхлакны фаш итә торган комедия» буларак форма-

лаша (мәсәлән, Д. Фонвизинның «Җитлекмәгән егет», «Бригадир» әсәрләре). XIX гасырда Н. В. Гоголь, А. Н. Островский, А. П. Чехов реалистик социаль комедияләрнең классик үрнәкләрен тудыралар.

Татар әдәбиятында комедия жанры, алда күргәнебезчә, XIX гасырның соңгы ун еллыгында («Комедия Чистайда», 1895) мәйданга килеп, Г. Камал, Г. Исхакый, С. Рәмиев, И. Богданов, Ш. Камал, К. Тинчурин һ. б. әдипләр иҗатында үстерелә.

Сорау һәм биремнәр

1. Драма һәм комедия жанрының төп үзенчәлекләре нәрсәдә?

2. Г. Ильясиның «Бичара кыз» драмасындагы конфликт һәм аның чишелеше. Төп образларга характеристика бирегез.

3. Ф. Халидинең «Рәдде бичара кыз» драмасындагы конфликт һәм аның хәл ителешенә анализ ясагыз. Хәлимә, Закир һәм Әптем образлары хакында сөйләгез.

* * *

XIX гасыр, татар халкы тормышына һәм аңына мөһим тарихи үзгәрешләр алып килгән кебек, әдәбият үсешендә дә зур борылыш дәвере булды. Бу гасырда, бигрәк тә аның икенче яртысында, татарлар арасында иске феодаль-патриархаль тәртипләргә каршы мәгърифәтчелек хәрәкәте формалаша. Әлеге хәрәкәт татар халкының үз җирлегендә буржуаз мөнәсәбәтләр үсү, тормыштагы икътисади үзгәрешләр нәтиҗәсендә мәйданга чыга. Ул, бер яктан, Көнчыгыш мәдәнияте традицияләре, ә икенче яктан, рус һәм Европа фәне, мәдәни казанышлары йогынтысында үсә. Г. Курсави, И. Хәлфин, Г. Мәхмүдов, Ш. Мәрҗани, Х. Фәезханов, К. Насыйри, И. Гаспралы, Р. Фәхреддин һ. б. мәгърифәтче галимнәр һәм фикер ияләре, эшлекләләр үсеп чыга, яңа фикерле әдип һәм шагыйрьләр җитешә.

Мәгърифәтчелек идеологиясе, матур әдәбиятны үзенең көчле ярдәмчесе, тәэсирле һәм үтемле корал итеп алып, аның үсешенә, камилләшүенә гаять зур этәргеч ясый. Әдәбият татар халкының үз тормышын реаль тасвирлауга йөз белән борыла; үзәккә шәхес һәм милләт язмышын алып, тел-сурәтләү чараларында халыкчанлыкка омтылып, милли әдәбият буларак формалаша, мәгърифәтчелек реализмы баскычына күтәрелә.

Бу хәл әдәбиятта гасырлар буе тотрыклы яшәп килгән идеалларның да зур үзгәрешенә китерә (идеал — өлге, үрнәк, камиллек, ирешергә омтылган иң югары теләк, максат дигәнне аңлата). Әйтик, Урта гасырлар әдәбиятында зур урын

тоткан, сез күреп үткән мәгърифәтле, гадел патша идеалы бу гасырда инде тәмам сүнүгә йөз тота. Феодаль җәмгыятьтә иң зур көчкә ия кеше патша булса һәм әдәби әсәрләрдә дә еш кына үзәк урынны биләсә, мәгърифәтчеләр дәверендә инде хакимият башлыгын сайлап кую, гадел идарә идеясе алга чыга (мәсәлән, Ф. Халидинең «Мең дә бер сәхәр» әсәрендәге хикәятләрдә). Дөрес, әлегә ул идеал шактый тоныклык һәм хыялый характерда. Демократик идарә, ирекле республика идеалы татар әдәбиятында ачык булып XX йөз башында, 1905 ел революциясендә күтәрелә.

Дини-суфичылык идеалы да (җир тормышыннан бизеп, иң гүзәл сыйфатларны үзендә туплаган Аллага, аның белән рухи кушылуга омтылу) зур үзгәреш кичерә. Гасырның беренче яртысында Ә. Каргалый, Һ. Салихов, Ш. Зәки кебек шагыйрьләр иҗатында әле бу идеяләр шактый көчле булса, алга таба алар тоныклана. Шагыйрьләрне инде күбрәк милли тормыш, милли тарих, мәгърифәтчелек идеяләре били. Суфичылык рухындагы мәгърифәт идеясе дөньяви мәгърифәт булып үзгәрә. Бу мәгърифәтчелекнең иң күренекле вәкиле — Акмулла.

Дөньяви мәхәббәт, сөйгән кешең белән тигез, бәхетле тормыш кору идеалы гасырның беренче яртысында ук Г. Кандалый поэзиясенең үзәгендә урын ала, төп темага әверелә. Тигез мәхәббәткә нигезләнгән гаилә һәм хатын-кыз хокуксызлыгы темасы алга таба мәгърифәтче язучылар иҗатында бик әһәмиятле мәсьәләләрнең берсе булып кала.

Элекке әдәбияттан килгән күркәм кеше идеалы шулай ук үзгәреш кичерә. Яхшы холыклы, диндар, тәүфыйклы, юмарт, кече күңелле һ. б. шундый сыйфатларга ия булу өстенә, мондый кеше яңалык тарафдары, җәмгыять мәнфәгатьләре белән яшәүче, халыкны уяту өчен актив эшчәнлек күрсәтүче герой буларак сурәтләнә.

Шуңа бәйләнешле рәвештә XIX гасыр дәвамында татар әдәбияты тарихи яктан чагыштырмача кыска гына дәвер эчендә төп өч этапны үтә.

1. Урта гасырлардан килгән күркәм кеше идеясе, яхшы кеше нинди булырга тиешлеге турында фикер йөртүләр, начарлыкны тәнкыйть итү XIX гасыр әдәбиятында, бигрәк тә бу гасырның беренче яртысында дәвам итте.

2. Шул ук вакытта иң әүвәл Г. Кандалый лирикасында иске тәртипләргә протест белдерүче, рух һәм фикер ирекен, бәйсезлеген кайнар яклаган **шәхес** авазы яңгырады.

З. К. Насыйри, М. Акъегетзадә, З. Бигиев, Р. Фәхреддин, Ф. Кәрими һ. б. язучыларның әсәрләрендә инде төп игътибарны **милләт язмышы,** татар милләтен аң-белемле, һөнәрле һәм югары әхлаклы итү мәсьәләләре биләде. Мәдәниятле һәм бәхетле милләт идеалы, үзәктә торып, әдәбиятны әйдәүче булып әверелде.

XIX гасыр татар әдәбиятының **төрләр** һәм **жанрлар системасында да** зур үзгәрешләр бара. Көнчыгыш әдәбиятларыннан тәрҗемә итү һәм ияреп язулар белән бергә, рус һәм Европа әдәбиятлары үрнәгендә **реалистик роман, повесть, хикәя** жанрлары активлашып китә. **Сәяхәтнамә** жанры, башка илләрнең фән-техника, мәгърифәт һәм мәдәният казанышлары белән таныштырып кына калмыйча, мәгърифәтчелек идеяләрен пропагандалауның мөһим чарасы булып әверелә. Кешеләрне, бигрәк тә яшь буынны, әхлакый тәрбияләүгә зур игътибар бирелеп, күп кенә җыентыкларда һәм хрестоматияләрдә байтак тәрҗемә мәсәлләр басыла.

Татар әдәбиятында яңа төр буларак, **драматургия** беренче адымнарын ясый. Эчтәлеге һәм сәнгатьчә сурәтләү чаралары ягыннан поэзиядә дә яңарыш күзәтелә.

XIX гасыр әдәбияты башыннан ук, нигездә, **басма әдәбият** буларак үсә. Бу яктан ул Борынгы һәм Урта гасырлар әдәбиятыннан аерылып тора. Әдәби процесста яңа күренеш буларак, хрестоматияләр чыга башлый, рус әдәбиятын тәрҗемә аша укучыга җиткерү активлаша. Төрек әдәбияты белән иҗади бәйләнешләр ныгый бара.

XIX гасыр әдәбиятында антитезалы тасвир зур урын били. Г. Кандалый, Акмулла кебек шагыйрьләр, М. Акъегетзадә, З. Бигиев, Р. Фәхреддин, Ф. Кәрими, З. Һади һ. б. язучылар иҗатында иске — яңа, надан — белемле һәм һөнәрле, әхлаклы булу — әхлаксыз булу, пассивлык — активлык кебек төшенчәләр белән сәнгатьчә фикерләү көчәя.

Тел-сурәтләү чараларында да зур үзгәрешләр бара. Ә. Каргалый, Һ. Салихов, Ш. Зәки, Г. Чокрый кебек шагыйрьләрдә гарәп-фарсы сүзләре белән бик нык чуарланган тел кулланылышта булса, гасырның беренче яртысында ук Г. Кандалый халыкчан тел-сурәтләү чараларына кискен борылыш ясый. Язма телдә татар халкының үз телен гамәлгә кертү, туган телнең мул чыганагы булган фольклорны өйрәнү юлында К. Насыйри гаять зур эшчәнлек күрсәтте.

М. Акъегетзадә, З. Бигиев үз әсәрләрен төрек теле йогынтысындарак язсалар, Г. Ильяси, Ф. Халиди, Г. Камал кебек дра-

матурглар, Р. Фәхреддин, Ф. Кәрими, З. Һади, Ш. Мөхәммәдев кебек прозаикларның әсәрләрендә татар халкының үз сөйләм теле гамәлгә керә бара. Поэзиядә бу яктан Яков Емельянов аерылып тора. Бу чорда әдәбият пейзаж, портрет, индивидуаль сөйләм һ. б. сурәтләү чаралары белән байый, геройларны сатирик сурәтләү алымнары килеп керә.

Туган телдә вакытлы матбугат булмаган шартларда мәгърифәтче әдипләр үз әсәрләрендә сүз рәссамнары, педагог һәм публицистлар да булдылар, газета чыгару омтылышлары да ясадылар. Бу омтылышлар патша хөкүмәте тарафыннан буылып торса да, иҗтимагый әһәмиятле мәсьәләләр турында халык белән турыдан-туры сөйләшү, фикер йөртү тәҗрибәсе дә туплана килде. 1905 ел революциясе нәтиҗәсендә, буа ерылып китеп, татар вакытлы матбугаты бик тиз вакыт эчендә киң диңгез булып җәелде.

Мәгърифәтче язучылар капитализм алып килгән төрле бозыклыкларны, җинаятьчелек һ. б. шундый караңгы, ямьсез якларны кабул итмәделәр. З. Бигиев, Р. Фәхреддин, З. Һади, Ш. Мөхәммәдев әсәрләрендә феодаль-буржуаз җәмгыять тәртипләренә, аның моралена, кешелексез мөнәсәбәтләренә тәнкыйди караш көчле булды. Мәгърифәтчелек реализмының үз эчендә тәнкыйди реализм элементлары ишәя барды. Ә инде мәгърифәтче әдипләрнең гуманистик уй-хыялларын, идеалларын гәүдәләндергән идеаль башлангычта XX йөз башы татар әдәбиятында үсеп китәчәк романтизм яралгылары тамырланды.

XX йөз башы татар әдәбияты классиклары Г. Исхакый, Г. Камал, Ф. Әмирхан, Г. Тукай, С. Рәмиев, М. Гафури, Г. Ибраһимов һ. б. мәгърифәтчелек әдәбияты идеяләрендә тәрбияләнеп үстеләр, үзләре дә иҗат эшчәнлекләрен мәгърифәтче буларак башладылар.

IX СЫЙНЫФТА ӨЙРӘНГӘННӘРГӘ ГОМУМИ ЙОМГАК

Хөрмәтле укучылар! Бу уку елы эчендә без вакыт ягыннан никадәр озын юл үттек. VI—VII гасырлардан башланган юлыбыз менә XX йөзгә килеп җитте: мең ярымга якын ел! Бу озын-озак юл — безнең өчен кадерле, изге юл. Чөнки аннан безнең әби-бабаларыбыз үткән. Без өйрәнгән шигъри сүзләргә аларның йөрәк тибешләре, уй-кичерешләре, шатлык-моңнары сеңеп калган. Үткәнгә сәяхәт ясап, без изге эш тә башкардык: әби-бабаларыбызның рухын искә алдык.

Инде без, әдәбият тарихының Урта гасыр һәм XIX йөз өлешләрен өйрәнгәч, ул чорларга шактый җентекле йомгак ясаган идек. Хәзер исә үтелгән курсның кайбер үзенчәлекләре, гомуми мәсьәләләре хакында аерым фикерләребезне бәян итик.

Элеккеге чорларда әдәбиятның тормыш, халык тарихы белән бәйләнеше, соңгы дәвер белән чагыштырганда, йомшаграк, зәгыйфьрәк була. Авторлар күбрәк конкрет чор, җирлек, халык белән бәйләнмәгән материалларга мөрәҗәгать итәләр, фольклор, легенда сюжетларын һәм образларын, инде әдәби әйләнешкә кергән факт-мәгълүматларны яратып кулланалар. Әмма шуңа да карамастан сүз сәнгате белән чынбарлык, халык тормышы арасында үзенчәлекле бәйләнеш яши. Рун язма истәлекләрендә үк борынгы төркиләрнең тарихына, гореф-гадәтләренә һәм, гомумән, яшәешләренә мөнәсәбәтле шактый мәгълүмат бар. Бу ядкярләрнең тууы ук иҗтимагый шартлар һәм ихтыяҗлар белән бәйле. Мөхәммәдьяр поэмалары — Казан ханлыгын һәлакәттән ничек саклап калу турында шагыйрьнең уйланулары да ул.

Гомумән, сүз сәнгате, көч, җегәр җыя барган саен, реаль чынбарлыкка, үзен тудырган һәм яшәткән халык язмышына якыная бара. Сәйф Сараи әсәрләрендә, «Идегәй» дастанында, Мәүла Колый хикмәтләрендә һәм Урта гасырның кайбер башка ядкярләрендә күзәтелгән бу тенденция Утыз Имәни, Г. Кандалый, Акмулла иҗатларында тагын да көчәеп китә. Муса Акъегетзадә, Заһир Бигиев романнарында, татар драматургиясенең тәүге үрнәкләрендә татар тормышын һәм кешеләрен гәүдәләндерү, реалистик принцип хәлиткеч күренешкә әйләнә. Шуның белән бергә, традицион сюжетларны, хыялый күренешләрне чагылдырган романтик рухлы әсәрләр язу да дәвам итә. Әмма алар да татар иҗтимагый-эстетик ихтыяҗларыннан читтә тумады. Әхмәт Кормашиның «Таһир илә Зөһрә» әсәре, мәсәлән, шул чор татар тормышында актуаль булган шәхес иреге, хатын-кыз азатлыгы мәсьәләләрен яктыртуга бер җавап иде.

Әдәбиятның халык тормышына, реаль чынбарлыкка якыная баруы аеруча кеше образларын гәүдәләндерүдә ачык күренә. Сүз сәнгатенең үзәгендә — кеше, аның эш-гамәле, эчке дөньясы, җәмгыять һәм табигать белән бәйләнешләре. Гомумән, әдәбиятка кагылышлы бу хакыйкать Тукайгача чор сүз сәнгатенә дә хас. «Котадгу белек» һәм «Кыйссаи Йосыф» поэмалары, Өмми Кәмал һәм Шәмседдин Зәки газәлләре нәкъ менә кешене тасвирлаулары, аны үзәккә куюлары белән

мөһим. Әмма мең ярым еллык төрки-татар әдәбиятында чорга, жанрга, авторга мөнәсәбәттә шәхесне сурәтләү төрле булган. Әхмәд Ясәви, Сөләйман Бакырганый, Өмми Кәмалнең лирик каһарманнары — аллачыл, диндар, суфичыл затлар. Алар — илаһи мәхәббәт геройлары. Ә инде Котб, Сәйф Сараи, Г. Кандалый кебек авторларны дөньяви яшәеш, тормышчан мәхәббәт мәсьәләләре күбрәк кызыксындыра. Әмма нинди генә төрлелекләр булмасын, кеше образларын гәүдәләндерүдә Урта гасыр һәм XIX йөз әдәбиятында тормышка, конкрет тарихи чорга һәм халыкка якыная бару тенденциясе күзгә ташлана.

Йосыф Баласагунлы, Кол Гали әсәрләрендә гомумән кешене сурәтләү өстенлек итә. Йосыф, мәсәлән, конкрет бер чор, халык вәкиле түгел. Харәзминең лирик каһарманы,— гомумән, гашыйк кеше. Сәйф Сараиның Сөһәйл һәм Гөлдерсене, Утыз Имәнинең Хәмидәсе, Кандалыйның Сахибҗәмалы — татар тормышы, тарихи чынбарлык белән теге яки бу дәрәҗәдә бәйләнешле затлар. Әмма әле аларны тудыруда да романтик буяулар, традицион иҗат принциплары өстенлек итә. Ә инде Муса Акъегетзадә, Заһир Бигиев романнарында, Габдрахман Ильяси, Фатих Халиди пьесаларында кеше образларын бирүдә без кискен борылыш күрәбез. Бу авторлар, бер яктан, татар чынбарлыгын, татар кешеләрен гәүдәләндерүгә йөз тотсалар, икенче яктан, тормышка охшашлыкны, реализмны үзләренең иҗат кыйблалары итәләр. Сүз сәнгатендәге мондый борылыш, Г. Исхакый, М. Гафури, Г. Тукай һәм башка әдипләр тарафыннан тагын да үстерелеп, XX йөз башы татар әдәбиятының төп сыйфатын билгеләүче күренешкә әверелде.

Әдәбияттагы чорлар арасында бүленеш шактый дәрәҗәдә шартлы. Анда үзара керешүләр, янәшә рәвештә дәвам итүләр, кушылулар адым саен очрый. Әгәр дә әдәби процессның эчке хосусиятләрен исәпкә алсак, без Урта гасыр иҗат принципларының әле XIX йөзнең соңгы чирегенә кадәр татар әдәбиятында дәвам итүен күрербез. Аннан инде әдәбият үсешендә чын мәгънәсендә реализм чоры башлана. Конкрет татар милләтенә, татар кешесенә хезмәт итү, аларның мәнфәгатьләре өчен көрәш, кагыйдә буларак, әдәбиятның асыл максатына әверелә.

Тукайгача чор сүз сәнгатен әхлакый әдәбият дип атарга мөмкин булыр иде. Чөнки ул дәвернең барлык әдипләре диярлек шәхесне рәнҗетүгә, түбәнсетүгә каршы чыгалар, кешене тәрбияле, ярдәмчел, итагатьле итеп күрергә телиләр. Алар әхлаклылык төшенчәсен белем-мәгърифәт белән тыгыз

бәйләнештә карыйлар. Матур әхлакый сыйфатларга, күркәм эш-гамәлләргә ия булган укымышлы зат — Урта гасыр һәм XIX йөз авторларының төп идеалы. Кеше бу дөньяда, үзе үлсә дә, исеме үлмәслек, «игү аты» калырлык итеп яшәргә бурычлы.

Элеккеге әдәбият идея-тематик яктан шактый бай. Анда әхлакый мәсьәләләргә бәйле рәвештә күптөрле проблемалар гәүдәләнеш таба. Котб, мәсәлән, мәхәббәт, социаль гаделлек, имин тормыш турында уйлана. Өмми Кәмал һәм Шәмседдин Зәкине, барыннан да элек, яшәү һәм үлем, Алла һәм кеше мәсьәләләре борчый. Акмулла һәм Каюм Насыйри Әбүгалисина һәм Мәрҗани кебек хикмәт ияләрен мактап, аларны татар җәмгыяте өчен үрнәк затлар итеп куялар. Закир Һади һәм Заһир Бигиев тискәре күренешләрне, бозык эш-гамәлләрне тасвирлау аша татар тормышын алга җибәрергә омтылалар...

Урта гасыр һәм XIX йөз әдәбияты мәхәббәт тематикасын эшкәртүдә аеруча уңышлы адымнар ясады. Кол Галинең Йосыф һәм Зөләйха, Котбның Ширин һәм Фәрһад, Сәйф Сараиның Сөһәйл вә Гөлдерсен, Мәҗлисинең Сәйфелмөлек һәм Бәдигылҗәмал, Кормашиның Таһир — Зөһрә образлары мәхәббәтнең олылыгын, изгелеген гәүдәләндерүләре белән күптәннән инде татар укучысына үз һәм якын. Гомумән, татар әдипләре хатын-кызларны сөеп, хөрмәт белән тасвирлаганнар.

VII гасырларда ук Идел-Урал буйларына ныклап керә башлаган мөселман дине Октябрь революциясенә кадәрге татар рухи тормышында төп идеология булды. Шуңа мөнәсәбәттә әдәбият та ислам рухы белән сугарылган иде. Әмма әдипләр, кагыйдә буларак, дини аерымлыкны түгел, ә кешелеклелекне үзәккә куйдылар. Мәхмүд Болгари, Мөхәммәдьяр, мәсәлән, кешегә иң беренче чиратта диненә карап түгел, ә әхлагына, кылган эш-гамәленә мөнәсәбәттә бәя бирәләр.

Урта гасыр һәм XIX йөз татар әдәбияты үз яшәешенең мең елдан артык дәверен мөселман дөньясы, Шәрык классикасы белән тыгыз бәйләнештә үтә. Бу багланышларны да иң беренче чиратта ислам, дини уртаклык тәэмин итә. Гарәп, фарсы ядкярләре Идел-Урал буйларында оригиналда, төрле тәрҗемәләрдә гаять киң тарала. Аларга төрле нәзыйрәләр — әдәби җаваплар язылуы да мәгълүм. Үзбәк, төрек авторларының әсәрләре исә, нигездә, оригиналда укыла. Татар әдәбиятындагы шактый гына сюжет-мотивлар, образлар, жанрлар, шигъри формалар генетик яктан Шәрык классикасы белән бәйле. Үз чиратында татар мәдәнияте дә Шәрык рухи тормышына бил-

геле бер йогынты ясаган. Бу бигрәк тә Алтын Урда чорында көчле була. XIX йөзнең икенче яртысы, аеруча XX гасыр башы, татар мәдәниятенең башкорт, казах, кыргыз, үзбәк, төрекмән, каракалпак, комык һәм башка тугандаш халыкларга уңай йогынтысы тарихтан бик күпләргә мәгълүм. Йосыф Акчура, Садри Максуди һәм күп санлы башка татар зыялылары XX йөз төрек мәдәни, иҗтимагый һәм гыйльми тормышында да зур роль уйныйлар.

М. Иванов, К. Насыйри китапларында, Яков Емельянов, Заһир Бигиев һ. б. әсәрләрендә рус әдәбияты белән багланышлар да күзгә ташлана. XIX йөз азакларында, аеруча XX гасырның тәүге елларында, татар әдипләре төрек һәм рус әдәбиятлары аша да, турыдан-туры да Көнбатыш Европа, бигрәк тә француз, немец, әдәби казанышларын ныклап үзләштерә башлыйлар.

Тукай иҗатына кадәрге татар әдәбияты жанрлар төрлелеге, сәнгати байлыгы белән дә игътибарга лаек. Анда без проза һәм поэзия төрләрен дә, газәл, мәдхия, мәрсия, дастан, кыйсса, мәсәл, хикәят һәм башка күптөрле жанрларны да очратабыз. Шигъри һәм чәчмә романнар да бар (Котб, Муса Акъегетзадә, Заһир Бигиев һ. б.). XIX гасыр азагында драма үрнәкләре дә туа.

Урта гасыр һәм XIX йөз әдәбияты белән фольклор арасында тыгыз бәйләнешләр яши. Алар еш кына бер-берсе белән керешеп тә китәләр. Әдәбиятта романтик фикерләү, хикмәтле сүз әйтү өстенлек итә. Шагыйрьләр гаруз системасын яратып кулланалар. Нәзыйрә ысулы белән әсәрләр язу киң тарала.

Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорында зур мәйданга, хәтта Мисыр-Сүрияләргә кадәр таралган төрки-татар әдәбияты идея-тематик һәм сәнгатьлелек ягыннан гаять зур үсешкә ирешә. Әмма дәүләтчелектән мәхрүм ителү, милли-колониаль изелүгә дучар булу татар әдәбияты үсешенә гаять тискәре йогынты ясый. Күп кенә мәдәни казанышлар юкка чыга, иҗат өчен тиешле шартлар булмый. Әмма шуңа да карамастан татар әдәбияты әкренләп, бик авырлык белән тернәкләнә, үсә килде. XVIII йөздә көчәеп киткән бу процесс XIX гасырда тагын да киңәйде, тирәнәйде. Үзенең милли казанышлары белән берлектә, Шәрык һәм Гарепнең мәдәни табышларын да мул файдаланган, милләт язмышын үзәккә куйган татар әдәбияты Г. Исхакый, Г. Тукай, Дәрдемәнд, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан иҗатларында сыйфат һәм сан ягыннан яңа баскычка күтәрелде.

* * *

Әдәбиятны талантлы шәхесләр тудыра һәм үстерә. Күп гасырлык татар иҗади тормышы андый кешеләргә бай булган. Алар һәр чорда диярлек алтын багана кебек балкып, нурланып торалар.

Элеккеге әдипләрнең әдәби иҗатка, шигъри сүзгә гаять җаваплы караулары мәгълүм. Алар фикеренчә, сүз тылсымлы, кодрәтле көчкә ия. «Дөньяда сүземез бар — үземез юк!» — дип язган иде заманында Акмулла. Чыннан да, күпме әдип килгән, киткән. Әмма аларның уй-кичерешләргә бай сүзләре, кешелек өметләрен туплаган шигъри юллары һаман да яши, һаман да безне дулкынландыра.

Сораулар һәм биремнәр

1. Татар әдәбияты тарихы нинди чорларга бүлеп өйрәнелә?
2. Борынгы һәм Урта гасырда, XIX йөздә иҗат иткән төп әдипләрне атап чыгыгыз.
3. Татар әдәбияты тарихының тормышка һәм кешегә мөнәсәбәтендә нинди үзенчәлекләр күзәтелә?
4. Тукай иҗатына кадәрге татар әдәбиятының идея-тематикасы турында сөйләгез. Ни өчен без бу чор сүз сәнгатен «әхлакый әдәбият» дип атыйбыз?
5. Өйрәнелгән дәвердә язма әдәбият һәм фольклор үзара нинди мөнәсәбәттә торалар?
6. Татар әдәбиятының халыкара бәйләнышларын ничек күзаллыйсыз?
7. Әдәбият тарихында традицияләр дәвамчанлыгы нәрсәләрдә күренә?
8. «Борынгы һәм Урта гасыр, XIX йөз татар әдәбиятында жанрлар» темасына инша языгыз.
9. XX йөзгә кадәрге әдәбият тарихына нигезләнеп, «Әдәбиятта кеше язмышы, халык язмышы» темасына әңгәмә оештырыгыз.

ЭЧТӘЛЕК

Сәфәрегез уң булсын, дуслар! 3
Кереш 5

Борынгы һәм Урта гасыр әдәбияты

Төрки-татар әдәбиятының төп чыганаклары 14
Фольклор һәм язма әдәбият 14
Рун язулы истәлекләр 16
Уйгур язулы истәлекләр 22
Мәхмүд Кашгарыйның «Диване лөгатет-төрк» китабы 24
«Котадгу белек» 29
Әхмәд Йүгнәки 35
Әхмәд Ясәви һәм Сөләйман Бакырганый 38
Шәрык классикасы 43
Коръән һәм татар әдәбияты 47
Болгар-хәзәр чоры: тарихы һәм әдәбияты 54
Кол Гали. «Кыйссаи Йосыф» 61
Алтын Урда чоры әдәбияты 97
XIV йөз әдипләре 106
Мәхмүд Болгари һәм аның «Нәһҗел-фәрадис» әсәре 116
Сәйф Сараи 123
Казан ханлыгы чоры әдәбияты 145
Урта гасырның аерым ядкярләре 149
XV—XVI йөзләрдә иҗат иткән әдипләр 155
Мөхәммәдьяр 165
XVII йөз әдәбияты 174
Мәүла Колый 183
Габди 192
XVIII йөз әдәбияты 198
Тарихи-мәдәни күзәтү 198
XVIII гасыр татар әдәбиятында жанрлар 202
XVIII йөздә иҗат иткән әдипләр 210
Габдерәхим Утыз Имәни 217
Йомгак 229

XIX йөз әдәбияты

XIX йөзнең беренче яртысында әдәбият 237
Поэзия 251
Габделҗәббар Кандалый 261

XIX йөзнең икенче яртысында әдәбият 282
Каюм Насыйри 295
Реалистик проза үсеше 314
Муса Акъегетзадә 320
Ризаэддин Фәхреддин (Риза Фәхреддин) 329
Фатих Кәрими 335
Закир Һади 339
Заһир Бигиев 346
XIX йөзнең икенче яртысында татар поэзиясе 364
Мифтахеддин Акмулла 375
Татар драматургиясенең беренче адымнары 388
Габдрахман Ильяси 391
Фатих Халиди 394
IX сыйныфта өйрәнгәннәргә гомуми йомгак 400

Учебное издание

Миннегулов Хатип Юсупович
Садретдинов Шайхелислам Аляветдинович

ЛИТЕРАТУРА

(ТАТАРСКАЯ ЛИТЕРАТУРА:
ДРЕВНЯЯ, СРЕДНЕВЕКОВАЯ И XIX ВЕКА)

Учебник по татарской литературе для 9 класса
основной общеобразовательной школы
и средних учебных заведений с татарским языком обучения

Издание четвёртое, исправленное

Казань. Татарское книжное издательство. 2011

На татарском языке

Уку-укыту басмасы

Миңнегулов Хатыйп Йосыф улы
Садретдинов Шәйхелислам Әләветдин улы

ӘДӘБИЯТ

(БОРЫНГЫ ҺӘМ УРТА ГАСЫР, XIX ЙӨЗ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ)

Татар телендә төп гомуми белем бирү мәктәбе һәм гимназияләрнең
9 нчы сыйныфы, урта махсус уку йортлары, педагогия училищелары,
колледж һәм лицей укучылары өчен дәреслек

Төзәтелгән дүртенче басма

Мөхәррире *З. М. Гыйниятова*
Тышлык рәссамы һәм
бизәлеш мөхәррире *М. Д. Вәҗиева*
Техник мөхәррире һәм
компьютерда биткә салучысы *Г. С. Нуретдинова*
Корректорлары *Г. Р. Ногманова, Р. Ә. Фәйзуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 12.08.2011. Форматы $60\times90^{1}/_{16}$.
Шартлы басма табагы 25,5 + форз. 0,25. Тиражы 11000 д. Заказ Р-1029.

«Татарстан китап нәшрияты» ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс: (843) 519-45-22.
http://tatkniga.ru
e-mail: tki@tatkniga.ru

Безнең китапларны түбәндәге адреслар буенча сатып алырга мөмкин:

Казан, Декабристлар урамы, 2.
Татарстаң китап нәшриятының маркетинг бүлеге. Тел.: (843) 519-45-35.

Казан, Бауман урамы, 29/11.
Татарстан китап нәшриятының фирма кибете. Тел.: (843) 292-03-18.

«Татмедиа» ААҖ филиалы
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.

Әхлак берлә әдәбият бергә булырлар,
Бер кавемнең әдәбияты нинди рәвештә
булса, әхлагы да шул рәвештә булыр.

Риза Фәхреддин

9 785298 020695